Академия Наук Татарстана

# ГАЯЗ ИСХАКИ

## СОЧИНЕНИЯ

**В ПЯТНАДЦАТИ ТОМАХ**

**4**

Пьесы
(1900 — 1918)

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2003

Татарстан Фәннәр академиясе

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

## ӘСӘРЛӘР

**УНБИШ ТОМДА**

**4**

Пьесалар
(1900 — 1918)

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84(2Рос=Тат)-6
И84

Редколлегия:

М.Х.ХӘСӘНОВ (рәис), М.З.ЗӘКИЕВ, Л.Р.ГАЙНАНОВА,
А.Г.ӘХМӘДУЛЛИН, Х.Г.ӘЮПОВ

Томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче
ЛЕНА ГАЙНАНОВА

Фәнни редакторлар:
МАНСУР ХӘСӘНОВ, МӘСГУД ГАЙНЕТДИНОВ

Нәшрият редакторы
РАВИЛ РАХМАНИ

**Исхакый Гаяз**

И84 Әсәрләр, 15 томда. 4 том, – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 496 бит.

Томга әдипнең 1900–1918 елларда басылып чыккан сәхнә әсәрләре тупланды.

ISBN 5-298-01191-8

© Төзү, искәрмә һәм аңлатмалар, 2003
© Татарстан китап нәшрияты, 2003

## ӨЧ ХАТЫН БЕРЛӘН ТОРМЫШ

### *Мөкаддимә*

«Өч хатын берлән тормыш» драмам бундан тәмам тукыз ел элек (тукыз йөзенче елның җәендә) язылганга, әлбәттә, анда мин үземнең шул вакыттагы күз карашымнан шул вакыйганы тасвир вә тәфсир иткән идем. Шул вакыттагы үземнең хак дип белгән, ышанган фикеремне укучыларга да хак-дөрест дип күрсәтергә тырышкан идем. Шул вакытта ышанган әхлак кагыйдәләрене дә ригая кылып, драмамның әсасенә «һәр җинаятьнең җәзасы була» казыясене утырткан идем. Шуның өчен безнең татар тормышында бик күп очрый торган, бик ямьсез вакыйгаларга сәбәп була торган күп хатын алуны үземнең шул вакыттагы ноктаи нәзарымнан тәнкыйть кылып, шуның һәр тарафыннан караганда да өйләнүчеләр өчен дә зарарлы идекене күрсәткән идем һәм дә шул ук китапта фамилия сәгадәтенең ничек булуыны белдерер өчен, шул өч хатынлы тормышның мохалифе — Ризаның бер хатын белән тормышыны да тасвир иткән идем.

Бу драма татар матбугатында хатыннар хакы өчен тартышучы беренче китап булганга, бу драмам ул вакытта мөкатдәс дип игътикад кылынган «күп хатынлылык» мәсьәләсене тәнкыйть вә аннан көлү булганга, бу китап бик күп кешеләр тарафыннан укылып, «күп хатынлылык» мәсьәләсенең әдәбият мәйданына куелуына вә шул фикернең киңәюенә шактый хезмәт иткән иде.

---

*Тәфсир итү* — аңлату.
*Ригая кылу* — истә тоту, хөрмәтләү.
*Әсас* — нигез.
*Казыя* — кагыйдә.
*Ноктаи нәзар* — караш.
*Фамилия* — гаилә.
*Сәгадәт* — бәхет.
*Мохалиф* — киресе.
*Игътикад* — ышану.

Шуның өчен хәзерге Гаяз бундан тукыз ел элгәреге Гаязның бәгъзе фикерләренә каршы килсә дә, аның ул вакыттагы «дөрест» дип укучыларга тоттырган «һәр җинаятьнең җәзасы була» казыясенә ышанмаса да, китапта сөйләнгән вак-төяк фикерләргә ул вакыттагы кеби әһәмият бирмәсә дә, бу фикерләрне үзгәртү китапның әсасыны, маэлене үзгәртү булганга, халык арасында мәгълүм, әдәбият базарында билгеле «Өч хатын берлән тормыш»ны бетереп, икенче «Өч хатын берлән тормыш»ны язу булганга, мин иске хаталары, иске гаепләре белән бу китапны икенче мәртәбә бастырырга карар бирдем. Шуның өчен мин вак-төяк гыйбарәләрене төзәтүдән үтмәенчә, бөтен тасвирларымны элгәрегечә калдырганга, укучыларымнан бу китапка минем соңгы әсәрем иттереп, бундагы фикерләргә минем хәзерге фикерләрем иттереп карамаенча, иске фикерләрем, иске уйларым дип карауларыны, шул вакыттагы хаталары өчен хәзерге Гаязны гаепләмәүләрене үтенәм.

*Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый*
Пинега. 6 нчы май. 1908.

КЕШЕЛӘР:

Кәрим — Казанның бер яшь бае. Кылангыч һәм надан.
Әсма — Кәримнең беренче хатыны. Гакыйлә һәм арасында белүчерәге.
Мәрьям — Кәримнең икенче хатыны. Бозыклыкта гомерене үткәргән.
Сорур — Кәримнең өченче хатыны. Йомшак.
Фәхрия — күрше карчыгы.
Асламчы карчык — «Хатыннарны сөйдерәм, өшкерәм» дип алдап йөрүче бозык хатын.
Риза — Әсманың энесе. Үткен, укыган һәм гакыллы егет.
Шакир — маклер.
Хәсәнетдин — Кәримнең дуст бае. Чын Печән базары тиречесе. Тупас һәм надан шәхес.
Габбас — Кәримнең доверенные. Искечә генә бер гакыллы кеше.
Шәкүр — доктор.
Мәрзия — әдәпсез бер асрау кыз.
Гайни — аңсыз бер асрау хатын.

Вакыйга Казанда.

---

*Маэл* — эчтәлек, тоткан фикер.
*Гакыйлә* — акыллы.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бер хатын күренә. Хатын мендәрләр өя. Коридордан аяк тавышы ишетелә. Хатын, тиз генә яулыгыны салып ташлап, көзге өстәленә барып, өстәлдән калфак алып, көзгегә барып [каранып], ишеккә таба китә. Ишеккә барып йитүе белән ишек ачылып, утыз яшьләр чамасында, кечкенә кара сакаллы, матур гына кеше Казанның яңа мода җиләненнән, кечкенә бүректән килеп керә.

Кәрим *(ачуланган тавыш белән)*. Безнең Әсма исе китми инде, каршы да чыкмый башлады. Элгәре Кәрим кадерле иде, хәзер ник кадерләсен, кадерләсә дә, кадерләмәсә дә — үзенеке. Тукта әле, ничек булыр!

Әсма *(көлеп)*. Юк, мендәрләр җыештыра идем дә, сизеп өлгерә алмадым! Чын да шуңар күңелең дә калдымы әллә?

Кәрим. Хатын башың белән шулай мыскыл иткәч, ник калмасын!

Әсма *(моңаеп кына)*. Зинһар, әллә ниләр сөйләмәсәнә, мин сине нишләп мыскыл итим! Әйтәм ләбаса, белми калдым.

Кәрим. Юк инде, юк! Үзеңне үзең ничек йоларга теләсәң дә булмый.

Әсма *(бик моңаеп кына)*. Кәрим, җаным! Юк сүзләр белән җанымны кыйнамасана. Нишләп кайттың син, зинһар?

Кәрим *(ачуланып)*. Бер эш эшләмәдем, әллә инде мине тилегә санарга да телисеңме?

Әсма. Бер дә болай булмый идең ләбаса; әллә азрак башыңда бармы? *(Кулыннан тотып.)* Әйдә, алай булса, җаным, кереп ят!

Кәрим *(этеп йибәреп)*. Кит аннан! Әллә мин сиңа ияреп йөрергә балаң дип белдеңме? *(Барып, кәнәфигә утырып.)* Мин сине үзем боздым. Синең артыңнан йөреп, мәшәкатьләнеп алам. Тиле шул! Синнән башкасы бетәр иде, орлыгы Бохарададыр!..

Әсма. Миннән ни зарар күрдең? Нишләдем? Сөйдем. Рәхмәт, сөюемә күрә алдың. Хәзер дә сөям, кодрәтемчә хезмәт итәм, нәрсәмә ачуланасың?

Кәрим. Син миннән зарар күрдең, менә файда итә торганы белән торырсың.

Әсма *(гаҗәпсенеп, янына, каршысына барып)*. Кәрим, җаным, ни булды сиңа? Әллә бер-бер сүз ишеттеңме? Ник гаебемне әйтмәенчә ул чикле ачуланасың? Гаебем булса, әйт, ничек булуымны телисең? Син теләгәнчә булыйм.

Кәрим. Мине ир итмәгәч, каршы да чыгып алмагач,

ничек мин теләгәнчә буласың? *(Урыныннан тора-тора.)* Мин синнән теләгәнче, икенче кешедән телим. *(Чыгып бара.)*

Әсма *(янына барып)*. Җаным, кая барасың? Аш өлгергән, эшең булса, аштан соң барырсың. *(Кәрим дәшмичә ишекне ябып чыгып китә. Әсма, озатырга теләсә дә, чыгып өлгерә алмый. Ялгыз калып.)* Бу нишләп кайткан? Моңар ни булган?! Исергән дисәм, исергәч тә болай булмый иде! Ничек булса да монда бер хикмәт бар: йә берсе-берсе котырткандыр, яисә башкача бер-бер эш чыккандыр! Бу ни булды, йа Рабби! Яхшы гына торганда, әллә ниләр чыгармаса ярар иде! Уф Алла! *(Кәнәфигә утырып.)* Ирләр күңелен табу да читен! Ни гаебем бар икән соң? Булмаса, ник болай кылыр иде! Бардыр шул, үзем генә белми торганмын! *(Күзләреннән яшь чыгарып.)* Юк, юк, сөюемнән башка бер гаебем юк! *(Туктап, торып китә башлый.)* Аллага тапшырдым инде, эчем бик поша! Ничек тә бер хәл булыр.

Мендәрләр өя башлый. Хатын-кыз бүлмәсеннән ишек тавышы ишетелә башлый. Әсма, карангалап, тиз генә җиң очы белән күзене сөртеп, ишеккә карап торганда, ишектән кулына шәлене ала-ала картрак бер хатын керә.

Фәхрия. Сәламәтме, Әсма?

Әсма. Әлхәмдүлиллаһ, сез икәнсез, Фәхрия абыстай. Әйдәңез, узыңыз! Эчем пошып тора иде әле, ярый кердеңез! Чакыртыйм дамы әллә дип тора идем.

Фәхрия. Кәрим чыгып киткәнне күреп, кич белән нишләп тора икән дип, хәлеңне белеп чыгыйм дип кердем. Әниең мәрхүмә, рәхмәт, Алла разый булсын, яшь вакытымда бик зур файдалар итте. *(Икесе дә кәнәфигә утыралар.)*

Фәхрия. Йә, дога кылыйк! *(Кул күтәреп дога кылалар.)* Нишләп торасыз, Әсма? Кәримнең сатулары буламы?

Әсма *(моңаеп кына итәгенә карап, күлмәгене рәтләп)*. Чибәрдер, ахрысы, әле кайткан иде, аны сораша алмадым. Әллә нишләп ачуланып кайткан, рәтләп сөйләмәде дә. Өлгергән ашны калдырып чыгып китте.

Фәхрия. Андый вакытта, Әсма, иренеңне тешләп калырга тиеш. Ачуланган кешегә каршы сөйләп җиңеп булмый. Бара-тора үзе дә кайта ул. Дөньяда ир белән хатын арасында ачуланышу да булыр, сөешү дә булыр. Шундый вакытта телле булудан сакланырга кирәк. *(Озайтып кына.)* Барымызның да башыннан үткән шул! Сабыр итәргә кирәк! Китап әйткән: бер авырлыкка ике йиңеллек, дип.

Әлхәмдүлиллаһ, каенана җәфасын да күрдем, көндәш бәласе дә күрдем, барысына да сабыр иттем. Карт көнемдә рәхәткә ирештем: угылым, кызым йитте, картым сәламәт, кулымыз иркен, гөрләшеп гомер итәмез. Алла рәхмәт итсен, каенанам, әләкләп, бик җәфалар чиктерде, көндәшем дә булды! Тагы нинди көндәш, Әсма! Сабира яучыны беләмсең? Шул минем көндәшем булып алты ел торды! Таш астында башын асрар бит. Бер яктан каенатам, бер яктан ирем; ни эшләргә белми әниең мәрхүмәгә кереп җылый идем. Онытыр хәлем юк: утырта, сөйләтә, ашата-эчертә, үгет бирә, күңелемне ала, кайгыларымны тарата иде. Сөйләгән сүзләре — ата-баба нәсыйхәте: «Сабыр итсәң, морадыңа йитәрсең», «Хезмәт итсәң, хөрмәт күрерсең» кебек сүзләр иде. Әниеңнең шул изгелекләре күңелемә килгән саен сиңа якынлыгым арта; күңелемнән сине үз балаларым кебек күрәм. Дөньяда иң рәхәт яши торган кеше итәр идем, без дигәнчә булмый шул, Әсма!

Әсма. Рәхмәт инде, Фәхрия абыстай, анам биргән нәсыйхәтләрне бирәсең!

Фәхрия *(ашыга-ашыга)*. Шулай, шулай, Әсма! Бу сүзләрне мин сөйләсәм дә, барыбер, әниең сүзләре.

Ишектән тасрайган, арттан яулыгыны бәйләгән, алъяпкыч япкан асрау кыз килеп керә.

Асрау кыз. Бикә, аш өлгергән иде. Мин, абзый кайткач та, өлгертергә дип белеп, токмачны салган идем.

Әсма. Ул чыгып китте шул. Казан астын сүрелдеребрәк куй әле!

Асрау кыз. Ул куерыр шул! Бүген, ялгыш, шурпа да азрак салынган!

Әсма *(тора башлап)*. Үзем чыгып карыйм әле. Фәхрия абыстай, мин чыгып керим, гаеп итмәңез! Мәрзия, син шул мендәрләрне, минем бүлмәләремне җыештыр әле! *(Чыгып китә.)*

Фәхрия. Мәрзия, монда кил әле! Нишләп торасыз, бер-бер ят хәбәр юкмы?

Асрау кыз *(килеп, өстәл өстенә кулы белән таянып)*. Әле Зариф абзыйларга вак китаплар сатучы килгән иде. Бик матур яңа китаплар бар икән, акчам булмады, ала алмадым. Шул гына сөйләде: «Печән базарында Исхак байлар шартлаганнар»,— ди.

Фәхрия. Андыйны әйтмим! Үзеңезнең өеңездә бербер нәрсә юкмы, дим.

Асрау кыз. Бездә ни булсын?

Фәхрия. Бик кычкырып сөйләмә! Кәрим өйләнгән, ди!

А с р а у  к ы з *(күзләрене зурайтып)*. Нәгъләт яуган икән! Тагы кемне әрәм итә икән?

Ф ә х р и я. Юк, айарлык кеше түгел, әллә ниткән бер бозык хатын гына, ди.

А с р а у  к ы з. Әле бикә ишеткәнме?

Ф ә х р и я. Юк.

Тамак кыру тавышы ишетелә. Мәрзия тиз генә китеп, әйберләр белән маташкан булып тора. Ә с м а керә.

Ә с м а. Мәрзия! Ашны сосып китер инде. Аңар ит йылытып бирермез.

Мәрзия чыгып китә.

Ф ә х р и я. Әле шуны әйтәм, Әсма, дөньяда гомер буе рәхәт торып булмый: бер карасаң рәхәттә, бер карасаң михнәттә; ни күрсәң дә язмыштан дип белергә кирәк шул. Күргән рәхәтләргә шөкер кылырга кирәк, килгән бәлаләргә сабыр итәргә кирәк. Биргән бәлаләренә сабыр итсәң, казаларына разый булсаң, нигъмәтләренә шөкер кылсаң, дөньясында, ахирәтендә хур булмассың.

Ә с м а. Бик дөрест, Фәхрия абыстай! Никадәр күргән рәхәтләр арасында вак-төяк тынычсызлыкларны искә дә төшерергә ярамый. Әлхәмдүлиллаһ, тигезлек белән гомер итәмез, мәхәббәтемез бар, дәүләтемез бар. Мескен, икмәк катысына да мохтаҗ булып йөргән кешеләр бар, алар да безнең кеби адәм балалары ич! Тагы кайсыларының дәүләте дә бардыр, тигезлеге, рәхәте юктыр, йә мәхәббәте юктыр, яисә көндәше-фәләне бардыр. Шундый булырга бик мөмкин, илаһым күрсәтмәсен! Минем хәлем бигрәк рәхәт инде: эшем эшләнгән, ашым-суым хәзерләнгән, өстем-башым җиту, исәнлегем бөтен — ни әйтергә дә юк инде. Шул рәвешле гомер сөрсәм, үземне дөньяның иң бәхетле хатыны дип белер идем.

Ф ә х р и я. Рәхмәт, Әсма! Үзеңнең тынычлыгыңны беләсең икән, Ходага шөкер кыласың икән. Кайсы бай хатыннары үзләренең кем икәнлекләрен белмиләр, ни сөйләгәннәрен тоймыйлар, ул фәкыйрьләрне дисәң, аларны кешегә дә санамыйлар; илаһи, киерелеп, түр башында утыралар! Ул асрауларга кылынуларын күрсәң, шаккатарсың! Белмим, боларны нәрсә букадәр һаваландыра торгандыр?! Байлыклары һәммәсе үзләренең уңганлыгыннан гына килгән дип белерсең. Карап торсаң, кулыннан бер эш килми. Ата-ана дәүләте боза шул.

---

*Айау* — кызгану.

Ә с м а. Ул, Фәхрия абыстай, дәүләт гаепле түгел инде! Дәүләтле булып яхшы булырга бигрәк уңай: теләгән йиргә ярдәм кыла аласың, айаган кешеңне күтәрә аласың. Шәфкать булсын да, гакыл булсын! Уй булсын! Андый бай хатыннарын әйтер идем дә шул... Хәреф тә танымаганнар! Аларның кай йирләрендә шәфкать булсын, кайсы төшләрендә мәрхәмәт булсын? Гомерендә тотып бер гыйбрәтле хикәя укыганы юк, кызгандыра торган бер сүз ишеткәне юк! Өендә, шул, асрауларын көчләп, атнада бер-ике йиргә ашка бару белән гомерен үткәрә; дөньядан хәбәре юк, ахирәттән уе юк, дөньяга ашар өчен, эчәр өчен генә килгән дип беләә. Рәхәт ни дигән сүз? Гомер ни дигән сүз? Адәм баласы дөньяда ничек торырга тиеш — һичберсеннән хәбәре юк! Ата-анасыннан ни сүз ишетте — шуны сөйли.

Ф ә х р и я. Бик дөрест, Әсма. Картлар да: «Искеләрдән гыйбрәт ал, яңа юлга нигез сал»,— дигәннәр. Ата-ана сүзеннән гыйбрәт алырга кирәк, үз гакылыңа салып эш йөртергә кирәк! Бу заманга инде ата-ана сүзләре белән генә ярап булмый! Замана үзе безне әллә ниләргә куша инде. Безнең әниләр заманында башта аршын ярымлы ак калфак иде, өстә үзләре эшләгән күлмәк иде, камзуллары бөтенләй көмеш тәнкә, мәрҗән белән каелып беткән иде; ул читек-кәвешнең исеме дә юк иде. Әле аш-су тагы, ботка белән куастан башка нәрсә юк иде; өйләрдә чыра яндыралар иде; лампаны, бәлки, уйлаган кеше дә юк иде. Замана заманага охшамый шул, безнең заманада инде әлимичестваләр яндыра башладылар.

Ишектән а с р а у керә.

А с р а у к ы з. Бикә, Риза абзый килде.
Ә с м а *(торып)*. Ник керми?

Шул арада бер егермеләр чамасында, яхшы гына киенгән бер егет — Р и з а килеп керә.

Р и з а. Сәламәтме, апа? Фәхрия абыстай, сез дә монда икәнсез, күрми калдым, гафу итеңез, сәламәт торасызмы?

Ф ә х р и я. Әлхәмдүлиллаһ, әле әкертен генә торамыз шулай. Үзең сәламәт йөрисеңме?

Р и з а. Беркөенчә, Аллага шөкер! *(Әсмага карап.)* Апа, җизни кайда?

Ә с м а. Чыгып киткән иде.

---

*Әлимичества* — электричество.

Р и з а. Кая китте икән?

Ә с м а. Бер дә белмим.

Р и з а. Сиңа кая барасын әйтмәдемени?

Ә с м а. Юк.

Р и з а *(иренене кабып)*. Эм-м! Алай икән!

Ә с м а. Әллә берәр хәбәр ишеттеңме?

Р и з а *(туктап торып)*. Юк, сине алырга дип кенә килдем. Абзыйлар анда көтеп торалар.

Ә с м а. Кәрим сездәме әллә?

Р и з а. Юк.

Ә с м а. Ул кайтмыйча ничек барыйм, әле дә әллә нәрсәгә ачуланып чыгып китте.

Р и з а. Ул бүген кайтмас инде.

Ә с м а. Ник кайтмасын?

Риза. Шулай инде... Бүген кайтмый.

Ә с м а *(урыныннан торып)*. Зинһар әйт, Риза, ни бар?!

Р и з а. Баргач әйтермен. Әйдә киен, абзыйлар озак көтәрләр. Шатлык хәбәр булмагач... әйтүдә ни файда бар...

Ә с м а. Риза, зинһар, әйт әле! Әллә Кәримгә берәр эш булганмы?

Р и з а. Булмаган...

Ә с м а. Ни бар соң?

Р и з а *(туктап торып)*. Өйләнгән!

Ә с м а. *(катып торып)* Өйләнгән?! Уф Алла! Ул ниткән эш?! *(Күзләреннән яшь чыгарып, өстәлгә таянып.)* Алла! Ниләр күрәсем бар икән! Анам мине шул көннәрне күрсен дип тудырды микәнни! *(Кулларыны күкрәгенә куеп.)* Күргән рәхәтләремнең актык көнемени? Икенче шундый тынычлыклар, рәхәтләр күрмәммени? Күрмәм! Күрмәм! *(Карылып, туктап.)* Бетте, бетте! Кәримнән аерылып... ничек торырмын?..

Ф ә х р и я. Әсма, җылама! Кәрим сине аермаган ласа, нишләп аерыласың. Алла теләсә, тагы шулай ук рәхәтләнеп гомер итәрсең.

Ә с м а. Әй, Фәхрия абыстай! Белмисең хәлемне! Бүген әле тирес-морыс сүзе өчен дә... сулыгып-сулыгып җылаган идем... Монысына ничек түзим! Сөйгәнеңнән күргән хәсрәт... Бигрәк авыр тоела шул!

Ф ә х р и я. Әсма, балам, алай кылынма, сабыр ит! Беләм, хәлең бик авыр, хәлеңә сабырдан башка им юк! *(Аркасына кулыны салып.)* Сабыр ит, Аллаһе Тәгалә ярдәмчең булсын!

Ә с м а *(җылый-җылый)*. Сабыр итәм... Сабыр итәм! Раббемнең биргәненә разый! Нишлим йөрәгемне! Ярыла!.. Ярыла!..

Р и з а *(күзләреннән яшь чыгарып, җылаган тавыш белән)*. Апа бәгырем, җылама! Сабыр ит, безнең хакымыз өчен җылама! Дөньяда кара көннәрдә сабыр итәргә кирәк. Безгә дә бик авыр... Синең көндәшле булуыңны күрү күңелемдә нинди җәрәхәтләр ачканыны белсәң иде... *(Туктап торып.)* Бу бәлагә сине түгел, үземнең иң дошман кешемне дә төшерергә разый түгел дә, без дигәнчә түгел шул! Язмышыңда шулай булгач, бер эш эшләр хәл юк. Авыр булса да, апам бәгырем, сабыр ит!

Ә с м а *(күкрәгенә кулыны куеп)*. Әй, Риза! Минем хәсрәтләремнең ничек икәнлеген, көндәшнең авырлыгын, хатын-кыздагы көнчелекнең дәрәҗәсен белсәң иде!.. Хәзердәге хәсрәтем синдә булса иде... Ир булсаң да чыдый алмас идең!

Р и з а. Апам бәгырем, беләм авырлыгын, беләм! Хатын-кыз булмасам да, хатын-кыз кадәре беләм! Шунларны аңларлык гакылым бар, бөтен дөньяны айарга йитәрлек шәфкатем бар! Бик кызганам, бик айыйм! «Сабыр ит» диюдән башка дәва белмим шул!

А с р а у, тәрилкәләр тотып кереп, җылау тавышыны ишеткәч, туктап тора; Фәхрия аңар ишарә белән генә хәзерләргә куша.

Ф ә х р и я. Әсма, Әсма! Тукта, балам, әнә аш та алып керде.

Әсма торырга теләсә дә, тагы йомшак креслога яртылый егылып, үксеп-үксеп җыларга тотына. Риза, аптырап, идән буенда йөри. Фәхрия карчык катып басып тора. Әсма җылауны куәтләндергәннән-куәтләндерә бара. Асрау тәрилкәләр тоткан көенчә катып тора.

Р и з а *(тагын апасы янына килеп, бераз басып торганнан соң, асрауга)*. Нәрсә катып торасың? Бар, ичмасам, бер стакан салкын су керт!

Асрау, тәрилкәләрне куеп, су артыннан чыгып китә. Карчык, читкә борылып, яулык очы белән күзене сөртә. Асрау кыз су алып керә.

К а р ч ы к *(суны Әсманың алдына илтеп)*. Әсма, Әсма, эч, менә шул суны азрак эч! Бисмиллаһир-рахманир-рахим! *(Әсма, карчыкның кулыннан алып, берьюлы бөтен суны эчеп бетерә.)* Менә шулай, бәбкәм! *(дип, Әсманың аркасыннан кагып.)* Инде менә тор инде!

Р и з а *(килеп, торырга теләгән апасына карап)*. Әйдә инде, апа, безгә! Монда Фәхрия абыстай калыр.

Ф ә х р и я. Калырмын, Әсма, бар, күңелең ачылып кайтыр!

А с р а у  к ы з. Аш ашамый китәсезмени?

Ә с м а *(күзене сөртә-сөртә, туныны киеп)*. Ашамыйм, агу булып төшмәсен! *(Фәхрия тора. Риза ишек катына бара. Әсма тун киеп.)* Дөньяда иң сөйгәнемнән иң авыр хәсрәтләр күрәм! Белмим, киләчәк тагыниләр хәзерли торгандыр!

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук өй. Мәрьям — утырган, янында төенле бер карчык.

К а р ч ы к *(төеннәрене чишеп, чыгарып өстәлгә куя)*. Менә монысы — асыл. Кирәк булса, штоф та бар. Болар бик яхшы әйберләр инде

М ә р ь я м. Миңа андый әйберләр кирәкми. Энҗе, алтын кебек әйберләрең юкмы?

К а р ч ы к. Энҗенең бик яхшылары бар иде, бик эресе! Монда алып килмәгән идем шул, берара китерермен!

М ә р ь я м. Миңа хәзер булса, яхшы була иде шул. Син килгәндә ярый ла үзем генә өйдә булсам!

К а р ч ы к. Мин ирең кибеткә чыккач кына килермен.

М ә р ь я м. Ирем генә булса, алай итеп тә тормас идем, үзе дә ул, җаным ни тели, шуны алып бирер иде дә...

К а р ч ы к. Каенана, көндәшең бармы әллә?

М ә р ь я м. Көндәшем бар.

К а р ч ы к. Әй бәгырем, шул яшь башың белән көндәш бәласен күрәсеңме?

М ә р ь я м. Язмышың булгач, ни эшлисең соң?

К а р ч ы к. Әйтәм, бик ябыккансың! Йөзеңдә бөтенләй нур беткән! Көндәшең кем? Нинди нәрсә? Кем баласы?

М ә р ь я м. Мин үзем яшь хатын булып килдем, көндәшем Әсма исемле, бик зәһәр нәрсә. Әнә онсы Камалилар сеңелесе.

К а р ч ы к. Алар нәселләре белән зәһәрләр. Ничек чыдыйсың?! Сәламәтлегең дә юкмы әллә?

М ә р ь я м. Юк, Аллага шөкер, сәламәтлегем бар! Эчем генә поша!

К а р ч ы к. Әйтәм, бар дип! Мин сине күзеңнән карап белдем! Эч пошу бик йиңел авыру түгел ул! Алар бушлар түгел. Тагы, көндәшеңне күрсәң, йөрәгең ярылырга йитә торгандыр! Иреңнең аның белән көлеп сөйләшүен күрсәң, җылыйсың килә торгандыр? Алар һәммәсе дә шул бозудан!

М ә р ь я м *(колагыны салып кына тыңлап торып)*.

Аннан ары, йокы арамда һәрвакыт шуның белән булышам.

Карчык. Бозган, бозган! Иреңне дә суыткан, бу көенчә торсаң, көннән көн саргаерсың! Шулай итеп, сызып бетәрсең! Ничек булса да, тизрәк карат, им-том иттер, үзеңне ул бәладән коткар! Андый вакытта мал да кызганыч түгел. Башың сәламәт булса, мал табылыр. Вакыты үтсә, исәнлек табылмый!

Асрау хатын *(кереп)*. Бикә, кабарткан апарам ярар микән, аз булмас микән? Чыгып карамыйсызмы?

Мәрьям. Ярый, әйдә чыгам! *(Карчыкка карап.)* Абыстай, мин хәзер керәм. *(Чыгып китәләр.)*

Карчык *(чит-читкә карап, өстәл өстендәге шикәр савытыннан берничә кисәк шикәрне кесәсенә сала, чәй савытыннан бер уч чәй алып яулык очына төенли, тәрилкәдәге бер сумсаны алып, бер ишеккә карап, бер сумсага карап, зур гына кабып, сөйләргә тотына)*. Ярар, моны болай итим әле! Хәзер куркытып йиткердем! Безнең хатын-кызның да гакылы юк соң: эче поша, көндәшен күрәсе килми, төшендә шуны күрә, имеш. Көндәш булгач, шулай булмый нишләсен! Синең шикеллеләр булмаса, мин ничек дөньямны уздырыр идем. Инде мин синең авыруыңа дару бирим! *(Исәпләп торып.)* Бака кашыгым бар иде! Тырнак табыла инде! Бер ике-өч бөртек кыл кирәк, ул да булыр. Аннан ары... Менә дару сиңа! Сәламәтләнәсең! Ирең сине сөйсә ни файда, тегене сөйсә ни файда; егерме тәнкә акча алам, шул файда! *(Тагы исәпләп торып.)* Эм-м! Тукта әле, тагы бернәрсә исемә төште; монысын сихер кайтару өчен дим! Иреңне көндәштән суындырыр өчен дип тагы бер нәрсә бирермен. Аннан егерме биш тәнкә була! Алла җан биргәнгә җүн бирә; фатирыма кайдан алып бирермен дип торган идем, Алла бирде. Анысы өчен ни бирермен икән? Бүтән карчыклар, изеп эчәргә төя тизәге бирәләр иде; миндә ул юк инде. *(Туктап торып.)* Йә, тавык тизәген алырмын да, ваклап кына суган йибәреп, борыч салырмын! Исе чыкмасын дип, бераз канәфер суы салырмын. Ярар, алары булды! Моны, шул, җайлап эшләргә кирәк инде! *(Мәрьям килеп керә. Карчык тиз-тиз авызыны сөртә.)*

Мәрьям. Тагы, абыстай, аны нишләргә кирәк соң инде?

Карчык. Мин үзем дә көндәш күрдем; ирем көндәшем яклы иде. Күршемездә бик яхшы, намазлы-ниязлы карчык бар иде; шуңар серемне җылап-җылап сөйләдем. Миңа шул ясап биргән иде. Шуннан мин аны һәрвакыт кадер-хөрмәт иттем, көчем йиткәнчә ярдәм

иттем. Шуның өчен, үлгән вакытта, миңа өйрәтеп калдырган иде. Мин үзем аларны беләм, әйберләрем генә юк.

Мәрьям. Аңар нинди әйберләр кирәк соң?

Карчык. Аңар инде мин үзем беләм нәрсәләр кирәген. Белгән бер карчыгым бар, шунда бардыр инде. Ул бик кыйммәт сорамаса ярар иде. Син кушсаң, белешермен.

Мәрьям. Күпме сорар икән?

Карчык. Белмим, илле тәнкәгә бирсә ярар иде.

Мәрьям. Бик кыйммәт ич ул алай?!

Карчык. Үзеңдә булмаган нәрсә һәрвакыт шулай була ул. Сөйдерә торганына әллә никадәр нәрсә кирәк түгел, алар һәммәсе үземдә бар. Оренбурга киткән карчыктан алып калган идем. Улсына егерме биш тәнкә йитәр.

Мәрьям. Теге абыстай да егерме биш тәнкәгә бирмәс микән? Алай булса, менә яхшы булыр иде. Бу көенчә минем акчам йитмәс шул.

Карчык. Ярар, сөйләшеп карармын; сине бик айадым. Югыйсә аңар ия күп табыла.

Мәрьям. Аны нишләргә, абыстай?

Карчык. Аларны суындырырга дигәнен түшәкләренә тегәргә кирәк, үзеңне сөйдерергә дигәнен ireңә изеп эчерергә кирәк.

Мәрьям. Алай булса, син, абыстай, шул көннәрдә китер әле! Бу әйберләреңне дә алып кил. Көндәшем, ирем өйдә булса, асламчы хатын төсле генә булырсың, мин озатырга чыгармын да, шунда бирерсең.

Карчык. Ярар. *(Торып, әйберләрене күтәреп.)* Мин андыйларны күп күргән, ничек эшләргә белермен. Хуш бул, хуш! *(Чыгып китә.)*

Мәрьям *(көлеп)*. Болай да була! Алла теләсә, көндәшсез дә калам. Шулай бай хатыны булып үзем генә калсам, Хәсәнне дә онытмам. Көндәшем булмагач, ирем сөйгәч, ул вакыт нидән куркыйм? Теләсәм ни эшләрмен. Әле болай йөдәп чыгасың: ни бусы үзеңә генә түгел, ни башкалары белән очрашып булмый. Ул вакытта һәммәсе килә! *(Көлеп.)* Әй кызык соң минем киләчәк гомерләрем! Ирем өйдә юк вакытларда теләгән вакытымда чыгып китәрмен, теләгән төшемә барырмын, теләгән кешем белән йөрермен. *(Көзгегә карап.)* Картая төшсәм дә, акча булгач, яшь егетләр дә табып була. Әлгәре моны йибәрим әле. Шаулама, китәр ул. Монысы болай булсын әле, башкача йөрәген яндырырмын. Чыдатаммы соң? Әстәгъфирулла! Тегендәге кызлар да миңа чыдый алмый-

лар иде. Иремне бер кулыма алып бетергәч, эшне башкача йөртермен. (*Көлеп йибәреп.*) Алла бирде миңа бер тилене. Әгәр тегене дә йибәреп бетерсәм, бу дәүләт миңа беразга йитәр әле. Бетсә тагы, көенечем дә аз. Аз гына йомшый башласа, чыгам да китәм. Әллә тагы шуның төсле бер тилесе беткәндерме? (*Көлеп.*) Безнең Казан бай угыллары исән булсалар, һәммәсен Кәрим ясармын! (*Исәпләп торып.*) Яшем ничәдә икән? Уналтыда йөри башладым, Казанда дүрт ел тордым. Әүвәлге иремдә сигез ай, аннан соң янә Казанда ук дүрт ел, Оренбургта дүрт ел, Уфада бер ел. Кайткач моның белән очрашкалап бер ел үтте, алганча бер ел, хәзер тукызынчы аем. Утыздан узган икәнмен. Әллә яңлыш санадым! (*Башларыны боргалап, көзгегә карап.*) Юк, карт түгел әле. Тагы мин Кәримгә, егерме бердә генә, дим ич. Утыз яшемә чикле никадәр кешеләр тилертеп, хәзер шул хатыннан да үземне коткара алмаммыни? Акчасыз көенчә, үземнең үткенлегем белән ни чикле эшләр эшләдем. Хәзердә акча да бар, теләсәм ни эшли алам... Гайниҗамал! Монда кер әле!

Асрау хатын (*кереп*). Нәрсә, бикә?

Мәрьям. Карабрак тор, абзыеңнар кайта башласа, миңа бик тиз кереп әйт! (*Асрау туктап тора.*)

Мәрьям. Тагы нәрсә кирәк инде?

Асрау хатын. Чакырган идеңез түгелме?

Мәрьям. Чакырдым да әйттем.

Асрау хатын. Бикә, ишетмәдем.

Мәрьям. Ишетмәдең, тишек колак! Абзыеңлар кайтса, миңа кереп әйт!

Асрау хатын. Кайтмаса, ни эшлим?

Мәрьям. Тор шунда, кайтканын карап тор! Менә сүз?! Бар, чык инде! (*Асрау чыгып китә. Мәрьям көлеп.*) Бу гомерендә кулына бер ир төшерә алмас. (*Бер кесәсеннән ачкыч чыгарып, сандык ача да, бер төргәк әйбер алып, өстәл өстенә китереп куя. Урындыкка утырып.*) Яшь вакытларымны искә төшерим әле. (*Әйберләрне тарата башлый, төргәк кәгазьдән өстәлгә бик күп портретлар таратып йибәрә дә, икенче бер төргәк алып.*) Менә болары хатлар. (*Портретлардан берсене алып.*) Монда Хәйретдин белән икәү икәнмез. (*Карап торып.*) Моны да эшләдем: йортларына чикле саттырдым. (*Икенчесене алып.*) Монысы Хәсән белән төшкәнмез икән. Ай, бу вакытларны үзем дә сагынам. Аның белән кайларга йөрдек. (*Үбеп алып.*) Ай, бәгърем, иң әүвәл шуның белән йөри башладым. (*Тагы берсене кулына алып.*) Монысы Гали икән. (*Чыраены сытып.*) Череп бетте мескен!

Шул арада К ә р и м белән Ә с м а, артларыннан а с р а у килеп керәләр.

Асрау хатын. Кайттылар, бикә!

Мәрьям *(сикереп торып, бер кулы белән хатларны кесәсенә тыгып, икенче кулына портретларны учлап, иренә каршы килеп)*. Исән кайттыңмы? Озак тордыңыз! *(Шул арада мендәрләр арасына портретларны кыстырып куя.)*

Кәрим *(көлеп)*. Сеңелләре өстенә өйләнгәч, сыйлый башладылар. Бар әле әйт, Мәрьям, самавыр хәзерләсеннәр.

Мәрьям *(ишеккә бара башлап, бер мендәргә карап, бер ишеккә карап, ишекне ачып кычкыра)*, Гайни, самавырны хәзерлә! *(Шул арада Әсма каршы ишектән чыгып китә.)*

Кәрим. Ник чыгып әйтмисең?

Мәрьям *(янына барып, кулыны кысып торып, көлеп)*. Сине күземнән йибәрәсем килми.

Кәрим кулыны салып, Мәрьям куенына кереп, үбеп алу белән, тегеннән аяк тавышы ишетелә башлый. Мәрьям мендәрләр янына барып, бер иренә карап, бер ишеккә карап, мендәр арасыннан портретларны алып, кесәсенә тыга. А с р а у кереп, идәнгә чәй хәзерли.

Әсма *(калфакчан килеп чыгып, асраугa)*. Гайниҗамал! Апара кабарттыңмы?

Асрау хатын. Кабарттым, бикә чыгып карады.

Әсма *(Мәрьямгә)*. Мәрьям апа, апарасын чаклап кабартканмы?

Мәрьям. Мин синең хезмәтчеңме әллә?! Кирәк булса, кара!

Әсма *(көлеп)*. Ярар, мин хезмәтчең булыйм, үзем чыгып карармын.

Кәрим *(Әсмага карап, ачуланып)*. Тик тор!

Әсма әкертен генә чыгып китә. А с р а у әйберләр кертеп куя.

Мәрьям *(шкафны ачып, әфлисуннар китерә-китерә сөйләнә)*. Мине һәрвакыт үзәгемә үтә торган сүзләр белән җанымны кыйный ул! Син дә ир булып шунда, сакал салпайтып, дәшми торасың! Мине алганда ни вәгъдә кылган идең, оныттыңмы? Әйттем мин сиңа «Хатыныңны аерырга булсаң гына барам» дип. Бер ел булды инде, синең күңелеңә дә кергәне юк.

Кәрим. Мәрьям, беләм, беләм. Онытмам. Агаларында өч мең тәнкәләп аласы бар иде, яхшы чакта шуны алып калыйм, дим.

Әсма *(килеп кереп)*. Утырышыңыз! Икенде вакыты йитә, тизрәк эчик тә өйләрне бераз җыештырырга кирәк.

*(Утырышалар. Кәримгә карап.)* Син, ул иртәгә өйләдән чыгуга ук килерләр микән?

Кәрим. Өндәү шулай чыкты.

Әсма *(чәй ясап)*. Бик озак көтәргә булмаса ярар иде, ашлар бозыла башлый.

Кәрим *(Әфлисун кисеп, ашый башлап)*. Бер көнгә чыдарсыз инде!

Асрау хатын *(килеп кереп)*. Абзый, Шакир абзый белән Хәсәнетдин абзый килделәр, кабинетка кереп утырдылар.

Кәрим *(чыга башлап)*. Өстәлгә чәй әзерләңез!

Мәрьям. Бетми инде әллә кемнәр. Рәхәтләнеп чәй дә эчәр хәл юк.

Әсма *(сикереп торып)*. Гайни! *(Шул арада Мәрьям дә хатын-кыз ягына чыгып китә. Гайни килеп керә.)* Гайни, тиз бул, шуларны җыештыр!

Гайни җыештыра. Әсма шкаф ачып, әйберләр алып, түгәрәк өстәлгә эскәтер җәеп, байларча мәҗлес кора. Һәртөрле нигъмәтләр — мөкәммәл байлар мәҗлесе. Гайни җыеп бетереп, самавыр кертеп куеп чыга. Әсма, хәзерләнеп беткәч, звонок бирә дә хатыннар ягына китә. Ул арада коридордан аяк тавышлары һәм «Сату-алуда андый эш булмаенча булмый инде!» — дигән тавышлар ишетелә һәм күренешкә бер калын корсаклы, ялтыраган күзле, простой иске мода киемнәрдән Хәсәнетдин һәм мөкәммәл русча киенгән кечкенә кара бүрекле Шакир күренә.

Шакир. Бәлки әле урын чыгар. Бохарада үтәрлек булмасмы? Анда бер шундый суга баткан әйберләрне моннан элгәре Бохара товары белән алыштырган идек, Имамовларныкын. Хәзер дә менә Ташаякка килгән сартлар белән мин сөйләшермен.

Кәрим. Яхшы булыр иде, үземезгә дә ул хәзер бик кыйммәт түгел инде. Җыенысыннан биш йөз тәнкәләр алынса, сезгә сату хакы да чыга, үземез дә зарар итмимез.

Хәсәнетдин. Алай, бөтенләй сатылмаса да, әллә ни зарары юк икән.

Кәрим. Ул сатылмый калмый инде. Әле Зөһрә бикә кешесе дә «зәкяткә кирәк иде» дип, дүрт йөз тәнкә бирде. Мин алай бирәсем килмәде. Алай иткәнче, барыбер, үземез кибет бәһасеннән сикез йөзгә исәпләп зәкяткә бирермез. *(Чәй ясый башлый.)*

Шакир *(Хәсәнетдингә карап)*. Әлеге, теге, Тимерхан сарт өйләнергә тели. Чибәр генә бер кыз белмимсең? Бик бай кеше.

---

*Мөкәммәл* — бу урында: нәкъ.

Хәсәнетдин. Ник өйләнә? Хатыны юкмыни?

Шакир. Бар, «Казан кызы белән торасы килә» ди. Шәйхетдиннәр сеңелләрен бирмәкче булганнар иде, кызлары, Ташаякка төшеп сартларын күргән дә: «Мине маймылга бирмәкче буласызмыни?» — дип җылаган. Аннан ары алар да кире кайттылар.

Хәсәнетдин *(көлеп)*. Әһә! Менә булдыклы кыз икән, әллә үзем алыйммы?

Шакир *(көлеп)*. Яучы йибәреп кара, сиңа нинди исем табар икән?

Хәсәнетдин. Мыскыл итәр шул, «ак сакал» дияр. Белми ул синең күңелең яшьлеген.

Кәрим. Эчеңез әле, йә, нигъмәтләренә йитешеңез!.. Сарты бик ямьсезмени?

Шакир. Алай бик ямьсез түгел. Бер күзе сукыр да, борыны чалышрак; аннан ары, кыз күргәндә сакалын буямаган булган.

Кәрим. Алай аңар кыз табылыр микән?

Хәсәнетдин. Акча күп бирсә, үзем табып бирәм. Яшьләре ничек, ди?

Шакир. Илле, илле бишләр чамасында гына.

Хәсәнетдин. Алай, аның турысында сөйләшермез. *(Чәй эчәләр.)*

Кәрим *(чынаягыны күтәргән көенчә)*. Әле Гайнетдиннәрнең йорты миңа кала, түли алмыйлар. Сатканда күпмегә алырлар?

Хәсәнетдин. Биш меңгә. Синдә күпмедә иде?

Кәрим. Ике меңдә.

Шакир. Алар шулай беттеләрмени? Бик матур кызлары бар иде, байлыкта үсеп, фәкыйрьлектә кияүгә китә икән.

Хәсәнетдин. Миңа бирмәсләрме?

Шакир. Син үзеңә генә кайгыртасың; Кәримгә диген, ичмасам!

Хәсәнетдин. Мин аңар да разый. Әйдә, Кәрим, алып йибәр! Туй итик.

Кәрим *(икенчене ясап куеп)*. Бирсәләр, алам. Барыбер яманатым күтәрелгән: дүрткә тулсын инде.

Шакир. Аларның хәзер сиңа бирми хәлләре юк. Йә, кызыңызны биреңез, йә йортны алам, диген!

Хәсәнетдин. Әйдә туй итик, Кәрим! *(Чәй эчәләр.)*

Кәрим. Кызлары нинди, куштан микән?

Шакир. Әһә-һә-һә! Аның куштанлыгын кем белсен?

Хәсәнетдин. Менә ал да белерсең.

Кәрим *(чәй ясый)*. «Ал да ал!» дисең, Гайнетдин абзыйны күреп сөйлә!

Х ә с ә н е т д и н. Баш өсте! *(Сикереп торып.)* Хәзер киттем.

Ш а к и р. Тукта, ашыкма! Өйләнү түгел, сөйләнү. Ничек күрәсең, ни сөйлисең?

К ә р и м. Эчеңез әле! *(Эчә башлыйлар.)* Туй расхутларына биш йөз тәнкә бирәм, йортлары үзләренә кала.

Х ә с ә н е т д и н. Аламыз. Бәдретдингә минем сүзем үтә.

Ш а к и р. Бик бала җанлылар. Ике хатын өсте дип, бирми калмаслар микән? *(Ул арада эчеп бетерәләр, дога кылалар.)*

К ә р и м. Дөрест сөйлим.

Х ә с ә н е т д и н. Башка сүзләрең дөрест булмаса да, синең «өйләнәм» дигән сүзең дөрест буласына ышанам. *(Шакир көлә.)*

К ә р и м. Алай булса, ышансаң, бар, Хәсәнетдин абзый, белеш әле!

Х ә с ә н е т д и н. Ярый, ярый! *(Торып чыга башлыйлар.)*

Ш а к и р *(коридорга барып йиткәч)*. Туйдан мине дә калдырмаңыз!

К ә р и м. Шакир, исеме ничек?

Ш а к и р. Сорур.

Х ә с ә н е т д и н. Мин хәзер тугры шунда киттем. Хушыңыз, Кәрим, хуш!

К ә р и м. Тугры шунда! Хуш!

П ә р д ә т ө ш ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Риза өе. Матур гына, җыйнак кына бер өй; кич белән, утлар ягылган, идәндә мәҗлес хәзерләнгән. Р и з а белән Ә с м а күренә.

Р и з а *(Әсмага)*. Апа, бу көннәрдә ни эшләп торасың әле?

Ә с м а. Безнең тормышны син сорама, мин әйтмим инде, Риза! Сөйләргә ни булсын? Анда Сорур да килде инде. Һәрвакыт сугыш, кычкырыш! Кадерлерәк фамилиядә хезмәтчеләр арасында да болай булмый инде. Әле Сорур кичә төште, бүген шәм яндырып сугыш чыкты.

Р и з а. Кем чыгарды?

Ә с м а. Билгеле, Мәрьям.

Р и з а. Ни өчен?

Ә с м а. Ни өчен булсын? Кәрим базардан кайтканны Сорур күргән дә каршы чыгарга дип ашыгып барган.

---

*Фамилия* — гаилә.

Ишек төбендә Мәрьям очраган да үзе элек чыгарга теләгән. Сорур аны үтеп чыкмакчы булган. Мәрьям бәреп йибәргән дә, Сорур барып шкафка бәрелеп, шкафның тәрәзәсен ваткан; аннан алты пар чынаяк төшкән, шуннан торыр-тормас, Мәрьямгә: «Сары җылан, кулымны нишләдең!» — дип, пыяла белән киселгән кулын күрсәткән икән, Мәрьям ачуы килеп, чәченнән басып тоткан да кыйнарга тотынган. Кәримнең аяк тавышын ишеткәч, кереп йиткәнче эш бетсен дип, Сорурның чәчен тартып, бер уч булыр, өзеп чыгарган. Шул арада Кәрим килеп кергән. Мин үз бүлмәмдә әйберләр җыештырып тора идем. Сорурның яланбаш, канлы кулы белән башын уып ятканын күргән дә: «Нәрсә булды?» — дип кычкырды. Минем бүлмәмә чикле ишетелде. Мин, ни булды икән дип, йөгереп чыктым. Мин барганда бөгеп-бөгеп Мәрьямне кыйный иде. Мин Сорур янына барып кулыннан тотып торгыздым да: «Әйдә, Сорур, теге бүлмәгә чыгыйк, кулыңны бәйләрмен»,— дип, алып кына чыга башлаган идем, килеп йитте дә, миңа: «Кая идең син?» — дип, бер сугып йибәрде. Мин Сорур кулыннан ычкынып, мичкә барып бәрелдем. *(Кулыны чыгарып.)* Сөягем чартламаган микән, бик авырта... Сорурны да тибеп йибәргән иде, мескен, атылып, мич алдына барып егылды. Ул шуннан соң Мәрьям үзен таларга тотынды, әйтмәгән сүзен калдырмады. Әй әдәпсез икән, исем китте. Сорур мескен көн буе җылап утырды. Бөтен идәнемез канга буялган. Менә безнең тормыш шулай. Ахры, аның тегенди булып йөрүе дөресттер, Риза! Менә инде әйтмәгән әшәке сүзен калдырмады. Алладан курыкмый, бәндәдән оялмый, ир хакын да белми икән. Белмим, Кәрим ничек чыдап торды.

Р и з а. Шулай инде, апа! Бер әдәп качкач, сөйләп тә була, кылып та була. Алла шул оят белән әдәпне качырмасын. Оят качмаган кеше ул, начарлык кылса да, бер кайтып төшә дә инсафына килә, вөжданына кайта, эшләгән эшенә үкенә. Эч пошуы белән газапланып, икенче эшләмәскә тәүбә кыла. Әмма оят качкан, вөҗданы беткән кеше һичнәрсәдән курыкмый, нәфесе ни теләде, шуны эшли. «Кешегә зарар булмасын, үземә шундый зарар итсәләр, яратмас идем» дими. «Бу миңа файда итте, изгелеккә каршы изгелек итим» дими, «Бу кешенең хәле авыр, ярдәм итим» дими, бөтен дөнья кирәк асты-өсткә әйләнсен, аның кәефе килсә, һич исе китми. Болай итсәм, күз яшенә сәбәп булырмын, дими. Булдыра алса, бөтен дөньяны үз рәхәтенә корбан кылыр иде. Кыла алса, бу ярамас, әхлаксызлырак бу-

лыр, кешелек түгел, дими. Юк, алай итәргә ярамый! Эшләгән эшең әхлакка муафикъ булсын, кешелеккә туг-ры килсен! Югыйсә ул син үзең теләгәнчә, миңа файда булгач, сиңа зарарында ни эшем бар дисәң, мин тагы шулай дисәм, дөньяда адәм балалары ничек торырлар?! Һәм шундый кешеләр Аллаһе Тәгаләнең боерыгын тот-маганнары өчен дөньяда бервакыт та рәхәт гомергә ирешә алмыйлар. Үзләренең рәхәтләренә хезмәт дип, элгәре никадәр күз яшьләре түктерсәләр дә, ахырда үзләре дә аларныкыннан әллә ничә өлеш артык яшьләр түгәләр. Көчләнгән кешеләр бервакыт өсткә чыга, чөнки Аллаһе Тәгаләнең хикмәте шулай булган! Хаклык һич астта кал-мый. Шуның өчен, апа, үзең көчләнсәң көчлән, кешене көчләмә! Синең күз яшеңне түктерсәләр дә, син кеше яшеннән саклан! Күз яше бик зур нәрсә! Аннан ары, үзеңә зарар иткән кешедән үч алырга тырышма! Кеше сиңа зарар итсен, син аңар файда ит! Менә кешелек шун-да! Әгәр син шулай, усаллыкка яхшылык кайтарсаң, ул кеше вөҗданы газапланып, эче пошып, йөдәп чыга. Шул вакытта син аңар яхшылык кылган буласың. Әмма һәр эшкә бер җәза булганга, аны син кичерсәң дә, Аллаһе Тәгалә аны эч пошуы белән газаплаган була да, синең дә үчең алынган була. Менә инде, апа, мин бу эштә Сорур-ны бик кызганам. Син дә кызганыч, алай да аның кадәр түгел. Ул мискинә кыз, бердән, үзе төсле яшь егеткә барам дип торганда, этисе төсле бер кешегә бирделәр. Билгеле, риза булмаган.

Әсма. Риза булмаса, ни эшләп килгән соң?

Риза. Аталары көчләп биргәннәр. Шул туйларда ба-рысында да кызлар риза булып баралар дип беләсеңме? Һич юк. Атасы бирә, мулла никях укый, кызны курчак төсле бизәп кияү катына кертәләр. Югыйсә белмәгән, күрмәгән егет белән бөтен гомерен бергә уздырырга ни-чек риза булсын? Ул кайдан белсен, аласы егет белән холыклары киләме, юкмы? Ул егеткә моның холыклары ярарлыкмы, түгелме? Егет моның күңеленә туларлыкмы, юкмы? Билгеле, никях эшләрендә шуларны уйларга кирәк, кыз бирү артык мал сату түгел ич ул. Яисә бер артык тамакны чыгарып, аннан котылып калу түгел. Кем бул-са да никях кылган кешеләрнең икесенең гомерләрен бергә уздырыр өчен берсе-берсе белән вәгъдә кылулары, боларның бергә уздырган гомерләрен рәхәт бер тормыш ясарга мөмкин һәм дөньяда иң зур гаеп эшләгән кеше-ләргә җәза булырга ярарлык бер бәла ясарга мөмкин. Әгәр боларның холыклары берсе-берсенә килсә, бергә го-мер сөргәндә шул фамилиянең рәхәте өчен нинди эшләр

эшләргә кирәк, шуларны икесе дә үз эшләрен белеп кылсалар, берсенең рәхәтенә икенчесе тырышса, берсенең хәсрәтенә икенчесе кайгырса, билгеле, бу кешеләрнең тормышлары — оҗмах тормышы. Әмма башкача булса, болар икесе дә үз гомерләрен әрәм итеп, дөньядан ләззәт ала алмыйча калалар. Билгеле, Сорурны да шулай иткәннәр. Күңеле булсын дип, ризалык та сорамаганнардыр әле. Икенче, ул кыз ике көндәш өстенә килде. Андый гомердән сәгадәт көтү — корыган агачтан алма көтү шикелле. Атасын әйтәм әле, ни дип бирде бу кеше?! Ни дип тагы монысы килде?! *(Туктап торып.)* Мискинә шул, аталары бирде — эш бетте, минем ризалыгым да кирәк түгел дип белгәндер. Менә Сорур никях эшләрен белгән булса иде, бу көнге бәлаләргә ирешмәс иде.

Ә с м а. Атасы-анасы биргәч, белсә, ни кыла ала?

Р и з а. Ни кыла алмасын. Әүвәл анасына әйтсен, сүзенә каршы киләләр икән, разый булмаганын муллаларга белгертсен. Аннан ары муллалар никях укымыйлар. Укыйлар да икән, бу риза булмаганда никях булмый.

Ә с м а. Алай бик тәмсезгә китә шул. Ата-анасына шулай итәргә, бөтен дөнья алдында рисвай итәргә кем разый булсын!

Р и з а. Ул рисвайлыкка бу кыз сәбәп булмый, атаанасы була ич. Үзенең разый түгеллеген белгәч, шәригатькә каршы, гакылга каршы, [үз] баламыз, теләсәң ни эшлимез дип, балаларын зинданга салырга телиләр ич.

Ә с м а. Алар ни, һәммәсе шулай, сөйләгәндә генә сөйләргә ярый шул, дөньяга чыгарып эшләп булмый. Бик дөрест, кыз алу, кыз бирүдә синеңчә эш кылынса, Сорур төсле кызларның гомерләре харап булмас иде. Ләкин син сөйләгәнчә кылып бетерү бик авыр, бәлки мөмкин түгел.

Р и з а. Менә мин балаларымны шулай итәчәкмен. *(Гаҗәпсенеп.)* Син мине романнарда укып кына сөйли дип беләсеңмени?! Син, апа, минем мөселманча синнән күбрәк белүемә ышана торгансың?!

Ә с м а. Бик ышанам.

Р и з а. Инде минем гакылсыз түгеллегемә дә ышанамсың?

Ә с м а. Ышанам гына түгел, сине гакыллы кешеләрдән саныйм!

Р и з а. Алай булса, мин сиңа менә ничек мин сөйләгәнчә буласын сөйлим.

Ә с м а. Ишетим.

Р и з а. Мин былтыр өйләндем. Абзый өйләндерергә тели башлагач та, мин, өйләнү ни дигән сүз икәнне бик

яхшы белгәнгә, шул өйләнүемне, үземне фамилия рәхәтенә илтә торган юл булса иде дип тырыштым. Шуның өчен үземнең күңелемә тулган кыз эзләргә тотындым. Мәшәкать чиктем, эзләдем, таптым. Миннән эш калмый, ләкин миңа ярагач та, аңар ярармы, ул нишләр икән дип белер өчен, аңар хат яздым. «Эш шулай, шулай, син минем күңелемә туласың, син разый булсаң, сорыйм, разый булмасаң, бер-бер теләп йөри торган кешең булса, сиңа разый түгел дип ачык яз, һич аның өчен сиңа дошманлык касд кылмыйм»,— дидем. *(Әсма көлеп тора. Риза сүзендә дәвам итеп.)* Язган хатыма каршы: «Гаепләмәсәнә, тегәп куйган кешем бар»,— дип язган. Аңар мине бәладән коткарган өчен рәхмәт укыдым. Икенчесенә яздым. Улсы инде менә Фатыйма. Ул каршы: «Күңелем белән разый һәм үземне, сиңа бара алсам, бәхетле кыз дип уйлыйм»,— дип язды. Менә мин сораттым, бирделәр. Менә, Аллага шөкер, шулкадәр рәхәт торамыз инде, әйтеп бетерерлек түгел! Менә инде, мин монысын шулай иттем, үзем фамилия рәхәтенә тигендем.

Әсма. Син шулай итәсең дә шул, дөньяда син генә түгел.

Риза. Син дә балаңны-чагаңны рәхәт яшәтәсең килер ич?!

Әсма. Мин генә түгел шул, дөньяда бүтәннәр дә бар!

Риза. Һәммә кешегә бала бертөрле якын ич. Башкалар да шулай итсен! Балалары рәхәт яшәсә, аларга ни зарар?!

Әсма *(көлеп)*. Зарар түгел, шатлык кына. Әүвәлдә аларның күбесе ничек иттереп рәхәткә ирештерергә белми. Бертөрлесе бар: уйлый, исәпли, Аллага тапшырам, ди дә, теләсә эчә торган кеше булсын, теләсә начар холыклы булсын, тота да бирә. Менә, кияве начар чыга да, кызы рәхәт гомер сөрә алмый.

Риза. Ул Аллага тапшыру түгел, наданлык кына. Элгәре холыкларыны карарга кирәк: килешә алалармы? Шуларны уйларга кирәк, аннан Аллага тапшырырга кирәк. Терелә тә, Аллага тапшырдым дип, утка атарга ярамый. Никях ул, безнең халык уйлаганча, бер кечкенә эш түгел. Шуның өчен, ике якның да ата-анасы, боларның холыкларының килешүләренә, үзләренең охшашуларына карарга кирәк; аларга бер-берсе белән танышырга, белешергә юл бирергә кирәк. Бездә һич алай түгел. «Угылы бармы фәлән байның? Бар булса, шуңар кызымызны бирергә кирәк. Атасы яхшы, ишан хәзрәткә кул

---

*Касд* — ният, теләк.

биргән кеше». Юк, алай түгел, атасын ул кадәр карамаска кирәк, егетен карарга кирәк. Нинди, әчмиме, әллә нинди бозыклыгы юкмы, әхлагы ничек, кешелеге ничек? Аның угылының рәте булмаса, атасының ишанга керүендә ни файда! Дәүләт дисәң, тәүфыйксыз бай балаларына дәүләт бетерү бернәрсә түгел. Безнең белгәндә генә ничә бай кешеләр бөлде, никадәр кешеләр эштән чыкты. Аларда дәүләт юк идемени? Юк, байлык мәңгелек дәүләт түгел, әмма гыйлем, һөнәр, тәүфыйк — алар мәңгелек. Алар кешегә эләксәләр, ул кеше гомер буена рәхәткә тигенә. Бу байлык бүген миндә, иртәгә синдә, аның шикелле ышанычсыз нәрсә юк. *(Тышта арба тавышы ишетелә, Риза, торып.)* Җизни килә ахрысы!

Әсма да торып ишек катына бара. Риза чыгып китә. Ишек артыннан: «Әссәламе галәйкем», «Вәгаләйкем әссәлам!» «Сәламәт киләсезме, җизни?» «Әлхәмдүлиллаһ!» сүзләре ишетелә. Әсма карап тора. Күренешкә К ә р и м килеп чыга.

Ә с м а. Бик озак тордың, син, әллә бер-бер эш тә чыктымы?

К ә р и м. Сорурны Мәрьям янында калдырып китәргә шикләнеп тордым. Ахырда, аннан ары, Фәхрия абыстайны да чакыртып калдырдым.

Ә с м а. Бик яхшы иткәнсең!

Р и з а. Үзләре генә куркалармы?

К ә р и м. Юк, Мәрьям Сорурны көчли. Йә тагы бербер зур эш чыгара башлар.

Р и з а. Аларны син шулай һәрвакыт саклап йөрерсеңмени?

К ә р и м. Нишлисең соң аны?

Р и з а *(көлеп)*. Ул өч хатын алу — өч хатынга каравылчы булу дигән сүз генәмени?! *(Тагы гаҗәпсенеп.)* Фамилия рәхәте кая, тормыш кызыклары кая?! *(Ул арада мәҗлесне күрсәтеп.)* Утырышыңыз!

К ә р и м *(утыра-утыра)*. Юк әле, Риза, син дөнья күрмәгән! Дөньяда каравыл да куярсың, кычкырышырсың да, үпкәләшерсең дә — барысы да булыр!

Р и з а. Бүтәне бер дә юк шул. Әллә нигә бер үпкәләшсәң дә, башка вакытларда яхшы торсаң, тагы бер хәл иде. Икенче хатын алганыңа өч ел ярым булды, тавышсыз көнеңез булганы бармы?

К ә р и м. Әнә шуның өчен өч хатын шул! Аларны тоту бик йиңел эш түгел. Шулай кычкырыша-талаша үткәрсәң дә ярый!

Бүлмә ягыннан ишек шакылдавы ишетелә. Риза ишеккә китә.

Р и з а *(ишеккә бара-бара)*. Алай үзеңне бөтен рәхәтеңнән мәхрүм калдырып, ирекле баштан өч хатын алу ник кирәк?! *(Риза ишеккә барып йитә. Ишектән пылау сузыла, алып китерә башлый.)*

К ә р и м. Син аны шулай йиңелчә генә бетерәсең. Алай түгел ул. Элгәре берсен аласың, аннан ары икенчегә дәрт төшә; тагы алай-болай була, тагы яңа белән тормакчы буласың. Анысыннан да туела. Дәүләтле кеше тагы ала. Башта, яңа вакытларда, шул хатыныңнан аерылмассың төсле булсаң да, бераз үткәч, башкара ул.

Ә с м а. Сез шул хатын-кызның саф эчлелеге, мәхәббәте белән уйныйсыз гына икән.

К ә р и м. Тик тор, син! *(Аш куела.)*

Р и з а *(Кәримгә)*. Рәхим итеңез!.. Мин гомеремдә ике хатын белән тормам һәм Алладан һәрвакыт шуның белән бәлаләмәсә иде дип сорыйм.

К ә р и м *(ашый-ашый)*. Чү, Риза, килен бикә тыңлап тора торгандыр! Күңелеңдә шул булса да, хатын-кыз куркытыр өчен өйләнәм дип сөйләнергә кирәк. Югыйсә курыкмый башлыйлар.

Р и з а. Башкача күңеленнән якын күрмәсә, аның белән куркытып кына рәхәт тора алмассың. Әгәр күңеленнән якын күрә икән, аның күңелен җәрәхәтләүдә ни бар?! *(Һәммәсе ашыйлар.)* Өч хатыныңның берсе генә «Мин икенче иргә барам» дисә, яратыр идеңме?

К ә р и м *(ашый-ашый)*. Миңа ничек ул алай әйтә?! Кем булган ул?!

Р и з а. Менә сиңа ничек авыр тоела, аларга да шулай авыр ул. Син әле өч хатыныңның берәрсенең генә әйтүен күтәрә алмыйсың. Минем хатын, башка кешеләрнең хатыннары, бердәнбер сөйгән иреннән шундый сүз ишетсә, нинди авыр була торгандыр! *(Кашыгы белән пылау рәтләп.)* Ашый-ашый сөйләңез әле!

К ә р и м. Ярый, бик ашадык, булды инде... Үз хатыныңнан шундый сүз ишетсәң, ник авыр булмасын?

Р и з а. Менә хатын-кызга да, үз иреннән шул сүзне ишеткәч, авыр була. *(Торып ишеккә таба бара.)*

К ә р и м *(көлеп)*. Әһә, әһә, алар хатыннар ич, күтәрсеннәр! Аларның сүзләренә карап йөрергә ярамый, алар ярты гакыл.

Р и з а *(миски белән аш алып килә-килә)*. Ирләр бөтен гакыллы булып күтәрә алмаганны, хатыннар ярты гакыл булып күтәрсеннәр, имеш, ул ниткән сүз?! *(Мискине куя. Әсма иренең тәрилкәсене тота. Риза аш сала-сала.)* Юк ул, җизни, хатынлык гаеп түгел. Безнең халык аны шу-

лай дип белә. Хатыннар да адәм балалары, ирләр дә адәм балалары.

Кәрим *(ашый-ашый, көлеп)*. Хатын ич алар!

Риза. Аларны хатын итеп Алла яраткан. Үзләре теләп хатын булмаганнар ич.

Кәрим. Ярый инде, менә син шулай бер хатын белән генә торып кара инде. Сез бу заманның яшьләре инде, үзеңез теләгәнчә торырсыз. Без шәригать гаепләмәгән эшләрне гаепли алмадык инде.

Риза. Шәригатьтә шулай өч хатын белән торырга ярый дип беләсезмени?

Кәрим. Дүрт белән торырга тиеш! *(Тәрилкәсене куя.)*

Риза. Тиешлек кая, дөрест түгел әле! *(Кәримгә карап.)* Бер тәрилкә салыйк әле! *(Торып китә.)*

Кәрим. Йитте... Муллалар белмәенчә дүрт хатын алырга кушалармыни соң?

Риза *(аш алып килә-килә)*. Ул сүзне һич мулла әйтмәс.

Кәрим. Үземезнең хәзрәт әйтә: «Кәрим, дәүләтең бар,— ди,— өйләнү исемен күтәрдең, шәригатькә тутыр инде»,— ди.

Риза *(килеп утырып)*. Шул сүзне хәзрәт, дөрест, әйттеме?!

Кәрим. Ник алдыйм?

Риза *(башыны селкеп)*. Беләләр безнең хәзрәтләр шәригатьне! Синең туеңда өч тәнкә садака буласын белгәнгә шулай ди ул.

Кәрим. Шәригатьтә дөрест түгел дисеңме син?

Риза. Безнең динемезчә менә шулай: кеше бер хатын алырга кирәк, сәламәт булганда хатын алмаенча ярамый. Шул хатын белән яхшы берсен-берсе ригая кылып торырга кирәк; өстенә башка хатын алу дөрест түгел; мәгәр дөрест, әгәр бер кеше бер хатынга гынаканәгать кылмаса, начар эшләр, хатын-кыз артыннан рисвай булып йөрерлек булса. Ул вакытта да хатыннары арасын гаделләсә, югыйсә, алай да ярамый. *(Бәлешне тартып, бераз төбене кисеп куя. Әсма иренең тәрилкәсенә бераз куя.)*

Кәрим. Син, Риза, бөтенләй икенче төрле сөйлисең, минем өч хатын белән торуны да яратмыйсың!

Риза. Яратмыйм шул. Тагы яратмыйм гына түгел, мин сезне кызганам.

Кәрим. Безне ник кызганасың? Әлхәмдүлиллаһ, дәүләтемез бар!

---

*Ригая* — кайгырту, хөрмәтләү.

Р и з а. Рәхәтең булмагач, дәүләт өч тиен ул. Менә шуны кызганам: сезнең йортта шул дәүләт белән рәхәтләнеп гомер сөреп булыр иде. Хәзердә сезнең өеңездә дүрт кешенең гомере әрәм булып ята. Сез үзеңез белми дә каласыз. Бүген хатын-кыз арасында тавыш чыкты әле дип торасыз. Иртәгесен тагы шулай, өченче көнне тагы. Шулай иттереп, сез барыңыз да хәсрәт, тавыштан башыңыз айнымыйча торып, картаеп бетәсез. Кая рәхәт, кая тормыш? Картайгач та яшь вакытыңыздагы сугышканнарыңызны искә төшерерсез шул инде! *(Торып китә-китә аш арты алып килә. Ашыйлар.)*

К ә р и м. Соң шулай булса, ни зарар бар?

Р и з а. Менә сез рәхәт яши алмыйсыз, апам рәхәт яши алмый, тагы Мәрьям, Сорурның гомерләре әрәм китә. Алар да берәр кешегә китсәләр иде, рәхәтләнеп торырлар иде. Сез тагы үзеңезгә рәхәт гомер сөрер идеңез. Хәзер сезнең, бу көенчә, ни сиңа рәхәт, ни апага, ни Мәрьямгә, ни Сорурга. Һәм һичбер вакыт булмаячак!

К ә р и м. Аны кайдан беләсең?

Риза. Сезнең шикелле өч хатын белән торган кешеләрнең бик күбесен күрдем, һәммәсе рәхәт күрмәде. Сез дә шулай күрмисез, дим. Рәхәт күрмәвеңезгә сәбәп — үзеңез. Менә мин, әлхәмдүлиллаһ, дәүләтем дә сезнеке шикелле зур түгел, рәхәтем сезгә караганда кырык өлеш артык.

К ә р и м. Минем рәхәтем юкмыни?

Р и з а. Элгәре апа белән генә торгандагы вакытларыңны искә төшереп кара. Шул вакыттагы рәхәтләрне бу көнге көнгә чагыштырып кара, аннан ары белерсең! *(Һәммәсе кашыкларыны куялар.)* Мәгъзүр инде!

К ә р и м. Аш кайтарыйк!

Кул күтәреп дога кылалар. Риза, Әсма, Кәрим торалар. Риза өстәлдәге әйберләрне җыештырып ала башлый.

Р и з а *(Әсма белән Кәримгә карап)*. Апа, шул өстәлнең өстене ачып утырыңыз әле!

Кәрим түгәрәк өстәлнең сул ягындагы кәнәфигә кереп утыра. Әсма уң якка, аңар каршы утыра. Риза әйберләрне кайсыны алай итеп, кайсысыны болай итеп бетереп, бүлмә ягыннан самавыр алып килә дә түгәрәк өстәлгә куя. Әсма машинаны бора да «Казан алган» көене уйната башлый. Риза чәйнек кыздырып чәй сала. Ашамак, эчмәк — мөкәммәл, малы бик күп.

---

*Мәгъзүр* — бу урында: (сый кимчелекләре өчен) гафу итегез.
*Мөкәммәл* — тулы, мул.

К ә р и м *(Ризага карап)*. Кәсепләр яхшы буламы?

Р и з а. Әлхәмдүлиллаһ. Әле тагы башка бер эш башламакчы булам.

К ә р и м. Нәрсә, әллә син дә җон җыярга телисеңме?

Р и з а. Китапханә ачмакчы булам.

К ә р и м. Ул ничек китапханә?

Р и з а. Базар уртасында гына өй алып, анда һәртөрле гарәпчә, фарсыча, төрекчә, русча китаплар куям һәм гарәп, фарсы, төрек, рус журналлары һәм гәзитәләр алам. Теләгән кешегә укырга һәр китап хәзер була инде.

К ә р и м. Бөтен кеше кереп укырмы? Аннан сиңа ни файда?

Р и з а. Анда буфет ачыла, шул буфеттан чәй сатыла.

К ә р и м. Гел үзең, Риза, ят эшләр эшлисең. Анда син пәрәмәч, сумса да пешертү кирәк иде!

Р и з а. Китапханәгә аш ашар өчен кермиләр инде, укыр өчен генә. Әле, теге, чәй сатуымыз да ул китапханәнең никадәр чыгышлары *(расхутлары)* була, шуларны күтәрер өчен генә.

Ә с м а. Без аннан файдалана алмыймыз инде!

К ә р и м. Син түгел, Риза да чак файда итәр әле.

Ә с м а. Юк, мин, китаплар укый алмамыз, дим.

К ә р и м. Бездә китап беткәнмени? Әнинең иске бөтиләкләре һәммәсе шкафта ләбаса!

Р и з а *(көлеп, чәй ясый-ясый)*. Файдаланырга мөмкин. Сезгә өйгә алдырырга ярый!

Ә с м а. Алай уңай икән, мин алырмын.

Р и з а. Бай хатыннары бик күбесе алыр дип уйлыйм. *(Шул арада звонок ишетелә, Риза, торып, ирләр ягына чыгып китә.)*

К ә р и м. Нәрсә бар икән?

Ә с м а. Бер-бер кеше генәдер. *(Тыштан тавыш ишетелә, аңланмый.)*

К ә р и м *(Әсмага)*. Тыңла әле! *(Әсма коридор буена барып тыңлый башлый. Кәрим бераздан соң.)* Нәрсә ишетелә?

Ә с м а. Аңлап булмый, «Мәрьям бикә» дигән сүз генә ишетелә, кучер тавышы.

К ә р и м *(сикереп торып)*. Ни булды икән?

Ул арада Р и з а караңгыланып кына килеп керә.

Ә с м а, К ә р и м *(берьюлы)*. Ни бар, Риза?

Р и з а. Кучерыңыз килгән, Сорурның агалары дуктырлар, бабкалар алып килде, ди, Сорурны караячаклар, ди, сине көтәләр, ди. Сез өйдән киткәч, Сорурны тагы кыйнаган!

К ә р и м *(агарып)*. Нишләргә боларны?

Р и з а. Әллә нәрсә таба алмаслар ич!

Әсма. Таба алмыйлармы соң! Бер уч саче йолкынган, бөтен куллары әллә ни эшләп киселеп беткән. Аннан ары тагы «әчем» дип ята иде, йөген салмаса ярар иде.

К ә р и м. Тагыниләр белән мөбтәляләнәмез икән? Ай бу Сорур белән Мәрьям!

Әсма. Инде шунда Мәрьям белән Сорур гына булса ярар иде, үзеңне дә тыкмасалар инде.

Р и з а. Авызың чалыш булгач, көзгегә үпкәләргә ярамый шул! *(Катып торалар.)*

П ә р д ә  т ө ш ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кәрим өе. Шул ук зал; Мәрьям, С о р у р, Әсма, К ә р и м күренәләр.

К ә р и м *(йөреп)*. Менә мыскыл! Шул хатыннан үземне мыскыллатам! *(Мәрьямгә кычкыра.)* Чык өемнән!

М ә р ь я м. Алай икән! *(Җылаган тавыш белән.)* Мине өчәү кыйнап тагы куып та йибәрмәкчеләр! Менә мин эшне Духовный собраниягә салыйм әле. Аннан ни кайтыр, шул булыр!

К ә р и м. Әсма, җиктер ат! Төясеннәр шуның әйберләрен, йөз өсте түбән китсен, кадерен белмәде!

Ә с м а. Кәрим, зинһар, алай кылынма, аерасың килсә, мулла чакыр!

К ә р и м. Күп сөйләмә, мин үзем беләм! *(Мәрьямгә карап.)* Чык, бар! Җыештыр әйберләреңне! Миннән талак син! Талак, талак! Мәһәреңне дә ал, әйберләреңне дә ал, күземә күренмә! *(Сорурга карап.)* Тор, Сорур, бар, шуны йибәрешеңез!

Әсма да, Сорур да чыгалар.

М ә р ь я м *(яшенә карылып)*. Мине тагы талап чыгарып йибәрмәкче буласызмыни, гыйддәтемә нәрсә?

К ә р и м. Яхшылыкның кадерен белмәдеңме, хөкем белән сорап ал!

М ә р ь я м. Минем белән судка йөри башласаң, эш бүтән булыр! Мин — Мәрьям! Әстәгъфирулла, мин сине түгел, Оренбурның Ихсан байларны да йортларына чик-

---

*Мөбтәля* — хәсрәтләну, бәлагә тару.

ле яздырдым! Башыңны ашыйм мин синең, яхшылык белән бир!

Кәрим. Күп сөйләсәң, полициягә бирәм, аресныйга яптырам!

Мәрьям. Мине алай дип куркытырмын ди икән! Аресныйда түгел, казаматында яткан мин. Миңа Себер ни, Сембер ни! Мине судтан куркыр дип уйлагансың?! Куркыр, куркыр!

Кәрим. Ярар, сөйлисең булса, башка кешегә сөйләрсең! Бар, чык! *(Кулыннан тотып, чыгара башлый.)*

Мәрьям. Кит, тотма минем кулымнан, мин синең хатының түгел! Теләгән вакытымда чыгармын.

Кәрим. Әсма, ни эшлисез? *(Коридорга кереп китә.)*

Мәрьям *(ялгыз калып)*. Нишләдем! Гыйддәт сакларга бирмәсәң, аңар гына аптырамам әле, унике меңне эләктердем! Мәрьям ул белми тавыш чыгармый. Менә аер, китәм хәзер!

Коридордан чыгып китә, чыгып барганда хатын-кыз ягыннан Әсма белән Сорур килеп керәләр.

Сорур *(Әсмага карап)*. Менә, Әсма апа, сиңа тормыш! Кайчан бетәр безнең шул тавышлар, кычкырышлар?!

Әсма. Инде бетәр, Мәрьям китә. Әле үзе әйберләр төяшеп, озатып йибәрә.

Сорур. Менә сөйгән хатын, мактаулы хатын ни эшләде? Бигрәк әдәпсез икән инде, илаһым күрсәтмәсен, ир чикле ирнең шулкадәр күлмәкләренә кадәр аерырга! Аннан котылдың инде, Әсма апа, миннән кайчан котылырсың?

Әсма. Ник алай дисең? Бергә торырмыз инде. Син тынычлап кына калыр идең дә, мин яшьтән килгән иремнән аерыласым килми.

Сорур. Юк, Әсма апа, чират миңа, мин аерылам. Аннан ары, аерылу — миңа файда гына. *(Утырышалар.)*

Әсма. Ник алай дисең, Сорур?

Сорур *(сулап)*. Син мине, зинһар, көндәш дип белмә! Мин сиңа һич көндәшлеккә килмәдем. Шул чикле яратмыйм Кәримне, әле тик, Мәрьямгә сүз бирмим дип кенә тордым. Менә шул чикле инде, үземнең кичем булса, бер хәсрәт туа. Йөзен бер күрмәс өчен әллә никадәр хезмәт итәр идем. Бер генә дә сөймим инде.

Әсма. Алай булгач, ник килдең соң, Сорур, үзең яратмыйм дисең? Әллә элгәре сөя идеңме?

С о р у р. Юк, элгәре дә сөймәдем, хәзер дә сөймим. *(Моңаеп кына.)* Әй, Әсма апа! Минем сөюем белән йөримени! Мин бигрәк үзем теләгәнгә барыр идем дә, ата-ана бар шул!

Ә с м а. Әллә, Сорур, сөйгәнең дә калдымы?

С о р у р. Әсма апа, мин сине бик якын күрәм. Бар серемне сөйлим инде. Зинһар, кешегә чыгармасана! Кәримгә әйтеп аертыр дип курка дип белмә! Болай, йөргән егетем булмады, Аллага шөкер, үземне аннан сакладым, алай да...

Ә с м а. Ник бирделәр соң?

С о р у р *(моңаеп)*. Уф, саттылар мине, апа бәгырем! *(Җылаган тавыш белән.)* Әтиләр Кәрим белән элгәредән эш итәләр иде. Элгәре дәүләтемез чибәр иде. Бара-тора олуг абзый солдатка китеп барды, бу Шәмсетдин бик бозылып китте. Бик акча бетерә башлаган иде. Шуның белән ул да эш кыла алмады. Менә кәсепче юк, чыгыш күп. Тагы Мәкәрҗәгә бардылар, анда зарар иттеләр. Итмәсләр иде, һәрвакыт абзый исерек. Әти элгәре эшне ташлый башлаган иде, шуның белән ул да эшнең кай ягыннан да тота белмәгән. Менә бурычланып киттеләр. Кәримгә ике мең тәнкәгә йортлары залукта булган, ул саттырырга тели башлаган. Ни эшләргә белми йөргәндә: «Шул йортларын үзләренә бирәм, Сорурны бирсеннәр!» — дигән. Әти башта ни эшләргә белмәсә дә, башкача бөтенләй фәкыйрьлеккә калырмыз дип, вәгъдә кылган. Менә мине шулай бирделәр.

Ә с м а. Ата-анаң да бигрәк каты күңелле кешеләр икән! Ичмасам, «разыймы» дип сорадылармы?

С о р у р. Сорау кайда, белми дә калдым! Туем булды, ул арада кияү дә керде. Уналты яшем тулган гына иде. Харап иттеләр инде, Әсма апа! Ничек кенә башымны алып качыйм.

Ә с м а. Дөрест тә, бигрәк авыр икән хәлең. Сөймәгән кеше белән тору бик ямандыр шул.

С о р у р. Әсма апа! Алла гына белә инде ничек икәнлеген. Дөньяда моннан да авыр хәл юктыр. Ни кылырга да белмим. Аллага тапшырдым. Ничек котылыйм, ни хәйлә белән китим?!

Ә с м а. Аерып йибәрмәсме үзе, Сорур?

С о р у р. Аермый, Әсма апа, беләм, аермый! Аллаһе Тәгалә, әллә ни эшләп, җаен тугры китерсә генә, белмим.

Ә с м а. Юк, Сорур, ул синең сөймәгәнеңне белсә, тотмас әле.

С о р у р. Белә ул, алай да аермый. Һәркөнне әрләшеп бетәмез. Холкым да бозылып бетте. Куркам инде, шун-

дый талашырга өйрәнгән бер хатын булып калмасам ярар иде.

Әсма. Соң, Сорур, сөймәгәнеңне белә торып тотмакчы буламыни?

Сорур. Тота шул, нишлисең, бездә ирек юк!

Әсма. Соң, аңар болай көчләп тотып ни файда икән, ни кызыгы бар икән? Ичмасам, сөйсәң, тагы бер хәл иде.

Сорур. Үзем дә белмим. Хурлана торгандыр. Кәримне сөймәгән дә, аерып йибәргән исемен күтәрә алмый торгандыр.

Әсма. Аптырадым инде мин, Сорур, дөньяның кылынышларына! Дөньяда һич рәхәт юк! Кәримнең исәбе Мәрьямне алудан да, сине алудан да үзен тагы рәхәткә ирештерү булгандыр. Рәхәт эш ничек булып чыкты! Хәзер ни үзенә тынычлык юк, ни безгә юк. Без элгәре бик яхшы тордык. Безнең ул торуымыз чикле инде дөньяда бер кеше дә тора алмас.

Сорур. Ничә ел икәү тордыгыз?

Әсма. Сикез ел. Бер ел Мәрьям белән, сине алганча, тордык. Синең белән дә ике ел була торгандыр.

Сорур. Мәүлед бәйрәменнән ике ел тула шул инде. Бер ел да унбер ай тулып үтте... Бик күп хәсрәтләр күргәнсез сез дә, Әсма апа, алай булгач?

Әсма. Менә яшем утызга йитә, күргән рәхәтләремне, михнәтләремне исәпләп бетерерлек түгел. Сикез яшемдә чагымда әти үлде. Шулай гына рәтләп килә башлаган идек, мин уникедә вакытта әни үлде. Бөтенләй ага-җиңгә кулына калдым. Алай булса да, Аллага шөкер, агаларым яхшы иде, атамнан ким тәрбия кылмадылар. Ризаны укыттылар, мин шулай кыз булып үстем.

Сорур. Әсма апа, сүзеңне бүлмим, син ничек бик күп нәрсә беләсең, күп укыдыңмы әллә?

Әсма. И йа Рабби, күп укысаң ни файда соң! Баргач та «Хәмде бихәдд» белән «Дарелмәҗалис» укый башлаган идем, биш ел укыдым. Чыкканда да шуның белән чыктым. Безнең Риза һәр кече атна көнне кайтып куна иде. Ул мәктәптә укыды. Миңа китап алып кайта иде. Мин шуларны укый идем, аңламаганнарымны өйрәнә идем.

Сорур. Әсма апа, ул бик күп укыгандыр, ахры, бик үткен егет, авызыннан ут чыга.

Әсма. Ул әллә ничә төрле тел генә белә, аның китапларын күрсәң, исең китәр, гакылың бетәр.

Сорур. Фатыйма бигрәк бәхетле икән. Кыз чагында минем дустым иде. Беремез ничек торамыз, икенчемез ничек!

Ә с м а. Әй, Сорур, аларның тормышларының кызыклыгын әйтеп бетерерлек түгел инде. Ул безнең Ризаның холыклылыгы, йомшак сүзлелеге! Аларда шылт иткән тавыш булмас. Көлешү тавышы ишетсәң ишетерсең.

С о р у р. Әсма апа, тагы шуны кайтарып әйтим әле, безнең теге эшемез бар бит әле. Аннан миңа бер-бер файда булмас микәнни?

Ә с м а. Кайсы эш ул?

С о р у р. Былтыргы, сез өйдә юкта, Мәрьям, Фәхрия абыстайны кабинитка бикләп, мине чәчемне йолкып-йолкып кыйнаган иде. Шуннан соң эчем авыртып йөреп, авырымны да салган идем ич? Әнә шул эшне хөкемгә йибәрделәр. Белмим, ник бу чикле озакка кала торгандыр. Чын булса, Кәрим Мәрьямне хөкемгә илтергә хурланып, гел Мәрьямне «авыру» дип күрсәткән, имеш.

Ә с м а. Аннан ни файда булыр. Белмим, Мәрьям генә хөкемгә керер, шул.

С о р у р. Улсы шулай да, әллә Мәрьям Кәрим өстенә сөйләр. Кайткач Кәрим дә бик каты кыйнады ич. Шулай ничек тә безгә бер-бер килешергә эш чыкмасмы. Чыкса, этиләр инде, аерып алмыйча килешмимез, диләр.

Ә с м а *(өстенә карап)*. Бик авыр эшләрең бар икән, Сорур! Ничек мәхкәмәгә барып йөрерсең? *(Шул арада Кәрим зал ишегенә килеп, качынып тыңлый башлый.)*

С о р у р *(җылаган тавыш белән)*. Бу бәладән котылыр өчен инде, бер генә түгел, мең мәхкәмәгә керергә дә разый инде, Әсма апа! Белмисең, бик авыр! *(Җылап кына.)* Әйтеп аңлатырга телем кыска инде, Әсма апа! Мондый авыр булмас. Бигрәк яратмыйм шул!! *(Ишек төбендә Кәрим кулларын күтәреп, чыраены сытып тора. Сорур сүзендә дәвам итеп.)* Гомерем буена шулай изелермен микәнни? Коткар, йа Рабби! Бигрәк бәхетсез бала икәнмен! Бу күз яшьләрем кемнәргә төшәр икән! Коткар, йа Раббем, коткар!

Ә с м а. Сорур, алай бик хәсрәтләнмә инде! Нишлисең, язмышың шулай булгач. Үзең бозылып китә башларсың, сабыр ит. Үзе дә аерыр әле, үзеннән үтен!

С о р у р. Белмисең, Әсма апа! Аягын үбеп-үбеп сорасам да аермый! Хурланмас идем, котылыр өчен сорар идем. Менә, Әсма апа, моннан аерып алып, кучерга бирермез, дисәләр дә аерылыр идем.

К ә р и м *(ишектән ачуланып кереп)*. Әле син кучер белән йөрергәмени! *(ашыгып килеп, сугам дигәндә.)*

---

*Мәхкәмә* — суд.

С о р у р *(тезләнеп, кулларыны күтәреп, җылаган тавыш белән)*. Бәгърем бул, сукма, кабердәге бабаларымыз хөрмәтенә сукма! Валлаһи. Һич гаебем юк!

Ә с м а *(торып, Кәрим янына килеп, Кәримне тотарга теләп)*. Кыйнама, кыйнама! Ансыз да авырый. *(Кулына ябыша.)*

С о р у р *(иренең аягына ятып, аягыны кочаклап)*. Зинһар бул, Кәрим җаным, мине болай мәшәкатьләндермә! Дөньяда иң якын күргән нәрсәң хөрмәте өчен мине җылатма! Аерып йибәр, аер, бәгъремм, коткар мине бу бәладән! Синнән бүтән кеше коткара алмый. Шәфкатең булса, зинһар, коткар! Ни тотсаң да, күңелем сиңа урынлашмый. Болай идеммени мин? Нинди калдым!

К ә р и м *(Әсмага)*. Син тик тор! *(Сорурга.)* Коткарам! Синең тасма телеңә карап, аерып йибәрермен! Ярый, ярый! *(Ачуланып.)* Черетеп бетерермен, алай да йибәрмәм! *(Асрау кыз керә.)*

А с р а у  к ы з. Габбас абзый бар. «Бик тиз байны күрергә кирәк»,— ди.

К ә р и м. Үземезнең Габбасмы?

А с р а у  к ы з. Әйе.

К ә р и м. Әйт, керсен! Барыңыз, чыгыңыз! *(Сорур торып чыга башлый.)* Кара, ул уеңны күңелеңнән чыгар! Черетермен, изәрмен — аермам!

Г а б б а с *(кереп, акыртын гына карангалап)*. Әссәламе галәйкем!

К ә р и м *(мыгыр-мыгыр гына)*. Вәгаләйкем әссәлам! Ни бар, Габбас абзый?

Г а б б а с. Богдановлардан кеше килде. Кибетне бастылар, счут сорыйлар.

К ә р и м *(күзләрене акайтып)*. Уф! Тауар счутка йитәрлекме соң?

Г а б б а с. Юк. Бик күп таралган. Унсикез мең тәнкәлек вексель бар. Кибет бәһасе белән егерме биш мең тәнкәлек тауар бар, кырык ике мең дә сикез йөз илле сум аларга кирәк. Чыкмый!

К ә р и м. Ул кая киткән? Без алтмыш мең чамасы белән эш йөртәмез ич?!

Г а б б а с. Шулай шул, уналты мең сум Максимовларга бар, кибет арасына ике мең чамасы бар.

К ә р и м. Кая китте ул акчалар?!

Г а б б а с. Кая китсен! Теге баланы яшереп калыр өчен өч мең тәнкә марҗага бирдеңез, эчемлек кибетенә сикез йөз кырык сикез тәнкә түләп йибәрдек, приказчикларга һәммәсенә бирелгән; өй чыгымнарына дип, бикәләр өч йөз тәнкә алдырганнар; аннан ары үзең биш йөз сум

алган. Һәммәсе шул кассадан чыккан! Кергәне юк. Мин сиңа әйттем ич: «Бу кадәр кылынмаска кирәк, чыгымыңызга керемегез йитми!» — дидем ич! Ул акчаны этиең бик мәшәкатьләнеп җыйган иде, сиңа гына йиңел тоелды. Үз сумамыз кырык мең тәнкә ун елга кереп бетте. Хәзер нишлик инде? Йортны банкага салып булса да, рәтләмичә ярамый.

Кәрим. Кая китте ул кадәр акча?! Минем исем китә!

Габбас. Счутларны карасаң, кая киткәнен белерсең. Менә ике хатын алдың, аларга икешәр мең тәнкә. Мәрьяменә артыктыр әле. Өч хатын өстенә аена алтмыш-йитмеш тәнкә чыгым ясап содержанкалар тотасың, минем сүземне искә дә алмадың. Мин, әлхәмдүлиллаһ, дөньяны синнән күбрәк күргән, этиеңә ярап торган кеше мин.

Кәрим. Мин, кылынсам, үз чамамны белеп кылынам! *(Торып коридорга китеп.)* Әсма! Чуен сандык ачкычы кая? *(Чыгып китә.)*

Габбас. Беләсең син чамаңны! Унике елга, табыштан башка, илле мең акча бетердең! Пальто кигәч тә, акча шулай табыла дип белгәндер! Әй болар, әй болар! Инде нишләргә кирәк?!

Шарт-шарт басып, Кәрим килеп керә.

Кәрим *(кулындагы ачкыч белән чуен сандыкны ача башлап)*. Менә монда унике мең тәнкә акча бар әле. Тире җыя башлармыз дип, йортны залук салган идем, шуның белән рәтләрмез. Үземез җыенып Мәскәүгә китик. *(Шалдыр-шолдыр ачып, күзләрен акайтып.)* Кая монда акча? Әсма, монда кил әле!

Әсма *(ашыгып килеп)*. Мин белмим. Ачкычны да Мәрьям бүлмәсеннән таптым, урынында түгел иде.

Сорур ишеккә килеп чыгып, каршы торалар.

Кәрим *(җыларга теләп, ишеккә тотынып, көчкә генә сөйләп)*. Габбас абзый, зинһар, кучер белән барып тап! Кучер илтте!

Габбас. Ул киттемени? Син аны үзең җавап бирмәкче булып калдың ич! Аңар да, сиңа да окружной судтан повестка бар, егерме бишенче майда Сорур эше белән аңар хөкем.

Кәрим. Уф Алла, беттек! Шулай бу унике мең дә югалырмыни?

Әсмадан җылаган тавыш ишетелә.

Габбас. Үзең ике эш белән окружной судка керәсең, инде нишлик? Менә шулай була шул, һәммә эш бүген

килеп тыгылды. Шуның өчен картлар «яман сыер ярга бозаулый» дигәннәр! *(Кәрим аптырап, катып тора.)* Әй-әй-әй сезне!

Сорур басып тора, Әсма җылый.

П ә р д ә  т ө ш ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кечкенә генә, пакь кенә өй. Уң якта бер авыру яткан; өйне урталый бүлгән чаршау аз гына тартылып тора; сул якта иске генә ак күлмәкле, башында яулыклы бер хатын иске ямап утыра.

К ә р и м *(авыру тавыш белән)*. Әсма, Әсма, су бир әле!

Ә с м а *(чәйнек белән су тотып барып)*. Торгызыйммы? Утырып эчәрсең.

К ә р и м. Торгыз! *(Әсма торгызып, аркасына мендәр сөйи дә тотып су эчерә. Кәрим, моңаеп.)* Әсма, бик ашыйсым килә! Ашарга бер-бер нәрсәң бармы? *(Әсма, торып, пешергән ит алып килә дә, тәрилкә белән алдында тотып тора. Кәрим ашарга тотына, үзе сөйли; авызы тулган көенчә.)* Бу итне кайдан алдың?

Ә с м а. Энҗеле калфагымны саттырган идем. Ярты пот он, биш кадак ит, чирек чәй, бер кадак шикәр, биш кадак күмәч алдырдым; алай да утыз тин акча калды әле.

К ә р и м *(күзләреннән яшь чыгарып)*. Шул көнгә калдыкмыни? Уф Алла!

Ә с м а. Нишлисең соң, язмышымыз шулай булгач!

К ә р и м *(җылаган тавыш белән)*. Үзем гаепле, уф Алла! Хәлем бик авыр!

Ә с м а *(башыны тотып, күзләрене сөртеп)*. Әллә, Кәрим, дуктыр чакыртыйкмы?

К ә р и м. Өч елдан бирле күп чакырттык инде. Хәзрәтләрдән дә күп өшкерттек. Ходайдан вәгъдә ирешмәгәч, булмый икән. Ярар иде дә... Акча юк шул!

Ә с м а. Мәрҗәннәрем бар әле. Мифтах бай кызы алмакчы булган иде, шуны сатармыз.

К ә р и м *(җылаган тавыш белән)*. Кадереңне белмәдем, Әсма! Белмәдем кадереңне! *(Муеныннан кочаклап.)* Гомереңне мәшәкатьтә уздырдым, бурычлы мин сиңа, бурычлы!

Ә с м а *(җылаган тавыш белән)*. Миңа, син сәламәт булсаң, бүтән нәрсә кирәк түгел. Хәсрәтләнмә алар өчен! *(Аяк тавышы ишетелә.)* Чү, кем бар?

Әсма сикереп тора. Ул арада матур гына киенгән, он күтәргән, бер кулында ит, чәй-шикәр, толыпчан, кышкы киемдә Риза килеп керә.

Риза *(Әсмага карап)*. Исәнме, апа? Әнә шул әйберләрне алып куй әле! Кичә алган идем базардан, онытып кергәнмен. Андый-бундый әйбергә аптырамадыңызмы?

Әсма. Юк, калфагымны саттырган идем, шул акчага алдырдым.

Риза. Ник алай иттерәсең? Анда ук, бер-бер әйберен саттырмаса ярар иде, дигән идем! Мин бер дә авырсынмыйм ич. *(Кәрим янына килеп.)* Нихәл, җизни, тереләмсең?

Кәрим. Гел бертөрле.

Әсма. Рәхмәт инде, әле дә бик карадың, сиңа гына ышанырга ярамый.

Риза. Алай димә, апа, мин һич авырсынмыйм!

Кәрим. Рәхмәт, Риза! *(Җылаган тавыш белән.)* Бик рәхмәт! Алла разый булсын! Апаң белән сине тудырган атаң-анаңның урыннарын оҗмахта кылсын! Бурычлы мин, бурычлы мин сезгә, бурычлы! Түли генә алмыйм! Алла кайтарсын сезнең яхшылыкларыңызны! Әсма, китер әле, күзем белән күрим әйберләрен! *(Әсма күтәреп китерә.)*

Риза. Апа, анда җизнигә дигән алмалар бар иде, шуларны да ал әле!

Әсма, кызыл алмаларны кәгазь капчыктан чыгарып, Кәримгә берне тоттыра.

Кәрим. Уф Алла! *(Карап, ашый башлап, селкенеп.)* Алла, Алла, аякларым! Эһе-эһе! Бүген хәлем авыр, Риза. Белмим, үлә торганмын!

Риза. Сәламәтләнерсең әле, җизни... Әллә дуктыр китертикме?

Кәрим *(алмасының яртысыны куеп)*. Ярар инде, шулай да үләрмен! Үлүен үләрмен, бер үкенечем кала.

Риза. Алай да мин дуктыр алып килим әле. Тиз килермен.

Кәрим *(бер Ризага карап, бер Әсмага карап, кызарып)*. Акч-ч-ч-амыз юктыр шул!

Риза. Алары өчен хәсрәтләнмә, җизни, мин аларын карармын. Һич хәсрәтләнмәңез! Тәнемдә җаным бар вакытта сезне караудан һич тартынмыйм. *(Чыгып китә.)*

Кәрим. Әсма, бәгърем, кил, бер сүз генә әйтим! *(Кулыннан тотып.)* Уф, бер үкенечем кала!

Әсма. Нәрсә ул? Әйт, зинһар, калмасын! Кулымыздан килгәнчә эшләрмез.

К ә р и м. Әсма! *(Җылаган тавыш белән.)* Минем сиңа яучы йөретә башлауларымны, кияү булып кергәннәремне, аннан соң, синең белән генә гомер итүләремезне *(кычкырып җылап),* тагы минем, сине көчләп, өстеңә әллә нинди хатын алуларымны, уф-ф-ф! Шунысын әйтергә телем бармый... *(Әсманың кулына егыла.)* Шул эшемне, сине урынсыз, гөнаһсыз җылатуымны ничек бәхилләтим?.. Нинди йөз белән синнән ризалык сорыйм? Эчемнең иң көйгәне шуның өчен! Аллаһе Тәгалә бу көннәрне шуның өчен күрсәткәндер! Бир, бәгърем, кулыңны үбим! Бәхиллә мин гөнаһлыны... Оятсызны бәхиллә! Җаным бул, никадәр изгелекләр кылдың, минем эчемне яндырып, шул гөнаһым белән Алла каршысына йибәрмә! Башка гөнаһларым да йитәрлек!..

Ә с м а *(кочаклап)*. Бәхил, бәгърем, береннән меңенә кадәр бәхил! Һич рәнҗемим. Аллаһе Тәгалә сәламәтлек бирсә иде дә бергә тора алсак иде!

К ә р и м. Минем дә үкенечем шул шул, Раббем сәламәтлек бирсә, хезмәтчең булып хезмәт итәр идем!

Ә с м а. Хезмәт итүләрем өчен дә бер дә авырсынмыйм. Миңа дөньяның бар кызыгы да — сиңа хезмәт итүдә генә.

К ә р и м *(кулыны чуп-чуп үбеп)*. Чын дустым, дөрест хатыным! Үләм мин, үләм! Каласың, бәгърем! Чиктердем мәшәкатьләр... Гафу кыл, җаным, гафу кыл! *(Кулларыны күтәреп.)* Йа Раббем, күз яшьләрем бәрабәренә, чиккән михнәтләрем бәрабәренә, шул изге хатынга ике дөнья рәхәтләрен биреп, гомер бир, Йа Рабби, бир, бир! Мин гөнаһлыны да аның изгелеге хөрмәтенә ярлыка! Раббем, әй Раббем! Шулкадәр бурычлы көенчә үләммени? Тәрбияләнерлек мал да калдыра алмыйм. Йа Раббем, үзең асра!

Ишек тавышы ишетелә. Әсма, кулыны үбеп, тора, Кәрим ята. Д о к т о р, Р и з а ишектән керәләр. Чаршау тартыла. Әсма чаршау артында кала. Доктор Кәрим янына керә. Риза да шунда керә.

Д о к т о р *(Кәрим янына барып)*. Исәнмесез? Ни хәл, ничек ятасыз? Кай йиреңез авырта?

К ә р и м. Аякларым бик авырта, бүген бигрәк хәлем юк.

Д о к т о р *(Кәримнең аякларыны чыгарып карап)*. Күзеңез дә бозылганмы әллә? *(Ризага.)* Элек бай кеше идеме әллә?

Р и з а. Яхшы дәүләтле кешеләр иде. Морадовлар, бәлки ишеткәнеңез дә бардыр.

Д о к т о р. Салихҗан байның нәселеме әллә?

Р и з а. Салихҗан байның угылы. Бу — безнең җизни.

Д о к т о р. Бик якын кешемез икән. Мин Салихҗан

абзыйны бик яхшы беләм. Мин гимназиядә укыган чакта Уфага алар бик еш баралар иде. Кунак өйләре бездә иде. Менә ничек беленми торган!

Кәрим. Сәлим мирза угылымы әллә син?

Доктор. Әйе, без сезнең этиеңездән зур файдалар күрдек. Уфа янында яңа утарны алган вакытта әти Салихҗан абзыйдан сикез мең тәңкә акча алып торды. Изгелекле кеше иде: акчага каршы акча бирде. Монда килгәч сораштым, рәтләп белүче булмады. Аның баласының шулай авыру икәнен белсәм, һәркөнне үзем килеп караган булыр идем. *(Кәримгә.)* Авыруыңыз күптәндер?

Кәрим. Өч ел булды.

Доктор *(тагы Кәримгә карап, гаҗәпсенгән тавыш белән)*. Әллә сез элгәре спиртлы эчемлекләр күп эчә идеңезме?

Кәрим. Минем дөньяда кылмаган начарлыгым калмаган инде.

Доктор. Ятыңыз, озакламассыз, Алла теләсә, сәламәтләнерсез! Мин язган даруны көненә ике мәртәбә эчәргә кирәк! *(Кесәсеннән кәгазь чыгарып, язып Ризага бирә. Кәримгә.)* Хуш. Кәрим абзый, тизрәк сәламәтлән! Дөньяны бергә үткәрергә насыйп итсен!

Кәрим. Хуш, рәхмәт татлы сүзеңә!

Чыга башлыйлар. Риза докторның кулына төртә, доктор: «Юк, рәхмәт, алмыйм, алмыйм»,— дип, калушыны кия башлый. Чаршау артына күмеләләр. Чаршауның сул ягыны ачып, Әсма Кәрим янына керә.

Доктор *(Ризага карап, шул чаршау ачылган төштә)*. Торса, өч-дүрт сәгать торыр. Яныннан китмәңез! Хатынкыз белән күп чуалганнан булган.

Шул арада аяк тавышы ишетелә һәм аграк сакаллы Габбас абзый керә.

Габбас. Әссәламе галәйкем!

Риза *(акыртын гына)*. Вәгаләйкем әссәлам!

Габбас. Шәкүр дә монда икән. Ярый, үземезнең дуктыр ул.

Чаршауның сул ягыннан Кәрим янына барысы да керәләр, уң яктан Әсма чыга.

Габбас. Сәламәтләнәмсең, Кәрим?

Кәрим. Әлхәмдүлиллаһ, әкертен генә.

Габбас *(кесәсеннән гәзитә чыгарып)*. Бүгенге гәзиттә нинди билетларга акча чыкканлыгы белдертелгән. 17.841 нче нумир, минем белүемчә, сездә. Караңыз әле! Ул нумирга егерме биш мең тәнкә акча бар.

К ә р и м. Безнең билет бар иде дә, ул сатылгандыр инде.

Ә с м а. Юк, мин аны акчага йөргәнен белми идем, ул сандыкта.

Р и з а. Алай булса, күрсәт әле!

Г а б б а с. Әгәр шул булса, аннан ары, сәламәтләнергә генә кала.

Әсма сандыктан билетны алып бирә, Риза билетны тота, Шәкүр, Габбастан алып, гәзитәне тота.

Р и з а *(укый башлап)*. Унйиде мең сикез йөз кырык бер.

Ш ә к ү р *(гәзитәгә карап)*. 17.841 нумирлы билет, егерме биш мең тәнкә акча чыккан.

К ә р и м *(торып утыра, авыру тавыш белән)*. Әлхәмдүлиллаһ, әлхәмдүлиллаһ! Ничек шөкерләр кылыйм. Бу кадәр мәшәкатьләр чиккәч тә, иске дәүләтләр кайтыр дип уйламый идем. Бу акча белән үзем файдалана алмасымны белсәм дә, никадәр усаллык кылдыгым вә мең төрле мәшәкатьләр, урынсыз рәнҗетүләр белән гомерен харап иткән изге хатыным файдаланачагын белеп, бәлки, минем шул начарлыкларымның бәгъзеләрен гафу кылыр да *(җылап)*, мине дә Аллаһе Тәгалә хозурында йөземне кара кылмас дип, бу акчаны аңар һибә кылам. *(Докторга карап.)* Боларның менә монысы минем хәзерге хатынымның энесе Риза, монысы безнең этинең приказчигы булган. Мин бай вакытларда да доверенный иде. Минем үземә генә кырык мең тәнкә акча калган иде, кибетемездә алтмыш мең тәнкәлек товар бар иде. Менә хәзер эти үлгәнгә унбиш ел булды. Унике елда бөтен кибетемездән, йортымыздан мәхрүм калдык.

Ш ә к ү р. Аңар сәбәп нәрсә булды соң? Бик тиз вакытта шулкадәр акча беткән.

К ә р и м. Үзем сәбәп булдым, үзем. Син әле минем ниләр кылганымны белмисеңме? *(Селкенеп китеп.)* Алла, Алла...

Ш ә к ү р. Ят, Кәрим абзый.

К ә р и м. Юк... Ятмыйм... Уф... Сиңа үземнең... үземнең начарлыкларымны сөйлим...

Г а б б а с. Кәрим, булган эш инде, аны кайтарып булмый.

Ш ә к ү р. Кайсымызда начарлык юк...

К ә р и м *(көчләнеп кенә)*. Юк... түгел... менә мин хәзер... үземнең бөтен начарлыгымны күзем белән күргән

---

*Һибә кылу* — бүләк итү, багышлау.

кебек булам. *(Туктап торып.)* Әнә минем харап иткән кызларым... күземә күренә. *(Җылаган тавыш белән.)* Әнә сатлык кызлар... әнә... әнә эчемлекләр.

Ш ә к ү р *(әле Ризага карап, әле Габбаска карап)*. Саташа башлады.

К ә р и м. Әнә минем шул вакыттагы гостиница иптәшләрем... Әнә! Алар эчәләр... мин үләм... алар эчәләр. *(Ачуланган тавыш белән.)* Алар ник монда килмиләр? Юк... кирәкми... килмәсеннәр. *(Риза, Шәкүр, Габбас катып торалар. Әсма чаршауны ача.)* Килмәсеннәр... мин аларга иптәш түгел! *(Кулларын калтырарга тотына, әллә нинди куркыныч тавыш белән.)* Түгел! *(ди дә, урынына егыла.)*

Тегеләр барысы да тотарга телиләр, тота алмыйлар. Шәкүр башыны тотып, рәтләбрәк куя. Кәрим тик ята. Барысы да бер сүз дәшми, тик Кәримгә карап торалар.

Ш ә к ү р *(бераздан соң, акрын гына)*. Йоклады. Бераз хәл җыйсын.

К ә р и м *(күзене ачып)*. Уф-ф. Эссе... Ишекне ачыгыз.

Ш ә к ү р. Чын да, монда һава бозылды. Без китик. Хуш, абыстай! Рәхмәт, иреңне шулкадәр ихлас белән каравыңа рәхмәт! *(Әсма җылый.)* Хуш, Кәрим абзый!

Г а б б а с *(торып)*. Рәхмәт, килен бикә, ирлек хакын иттең! Риза, сиңа да рәхмәт! *(Кәрим янына барып.)* — Хуш бул, Кәрим, сәламәтлән: эшне тагы да рәтләрмез.

К ә р и м *(авыру тавыш белән)*. Хуш, бәхил бул! *(Җылап.)* Сине дә рәнҗеттем, бәхил бул! *(Кулыны үбә.)* Икенче күрә алмам. Шәкүр, зинһар, минем хатынымның хәер хаһы булыңыз! Риза, синең хезмәтләреңне кайтарып бетерә алмыйм. Гафу кыл мине, зинһар! Әсманы яхшы тәрбия кыл, сиңа тапшырам! Синең яхшылыгыңа ышанып, миннән соң, ичмасам, рәхәт күрер дип үземне җуатам!

Әсма җылый. Тегеләр дә катып торалар. Риза башыны иеп җавап бирә. Һәммәсе дә: «Хуш бул!», дип чыгып китәләр.

Ә с м а *(Кәрим янына бара да кулыны тотып)*. Азрак йиңеләймисеңме?

К ә р и м. Юк, бәгырем, үләм, бәхил бул! Аллага шөкер, сине дә бөтенләй мохтаҗлыкта калдырмыйм.

Ә с м а. Минем өчен бер дә хәсрәтләнмә. Бар хәсрәтем шул гына: синсез калам. *(Җылап кулыны үбә.)*

---

*Хәер хаһ* — теләктәш.

К ә р и м. Каласың, бәгырем, каласың, бәгърем! *(Туктап торып.)* Су бир! *(Әсма чәйнек белән су бирә. Кәрим су эчә дә.)* Җайлап яткыр! Үләм! *(Әсма җылый-җылый кыйблага йөзе белән яткыра. Кәрим Әсманың муенына кулыны салып.)* Актык сәгатьләрем, актык сәгатьләрем! Сәламәтлектә онытмадың, үлгәч тә онытма!..

Ә с м а. Онытмам, җаным, онытмам.

К ә р и м *(телләре бәйләнә-бәйләнә)*. Бәх-и-ил бу-у-ул!

Бөтен тәне селкенергә тотына. Әсма тик тора. Кәрим тагын бераз тына да, бик авырлык белән: «Алла»,— ди, тагы бераздан: «Хуш!» — ди. Тәннәре тагын калтырый. «Алла» ди дә, кулларыны сузып, җаны чыга.

Ә с м а. И Раббем! Ниләр күрде, ниләр чикте! Актык гомерләрендә рәхәт күрә алмады! *(Кулыны үбеп.)* Үлде, үлде!

Шул арада Р и з а килеп керә.

Р и з а *(апасының җылаганыны күреп)*. Үлдемени?

Ә с м а. Үлде, үлде!

П ә р д ә акыртын гына төшә.

# ИКЕ ГАШЫЙК*

*Комедия биш пәрдәдә, алты манзарәдә*

Габделкаюм — Казанның яшь егете укыган, гакыллы, тәүфыйклы, җиңелчә генә уйлы бер егет, 21 яшендә, бай угылы.

Хөршит — болгар кызы (татар кызы), гакыллы гына, абыстайда курс тутырган, бик саф күңелле, тотынган эшен булдыра торган матур гына кыз.

Рәхмәтулла — Казанның бай карты. Чын карт бай. Үзен галим дә, гакыллы да, сәүдә эшенә дә бик оста дип белә торган, яңы эшнең һәммәсенә каршы килә торган бер кеше.

Галимә — Рәхмәтулла байның яшь хатыны, елан йоткан зәһәр, бик хәйләкәр, начарлыктан бер дә курыкмый торган хатын, 32 ләрдә.

Гайни — асрау кыз, ахырында хатын, Галимәнең дусты.

Шаһидә — асрау кыз, һәммә сүзне үзенә бертөрле сөйли торган, һичнәрсә аңлата алмый торган җиңелчә генә гакыллы кыз.

Мөршидә — яшь кыз.

Асрау — асрау.

Бакча хатыны — иске замана хатыны, һәммә иске эшкә мөкатдәс дип карый торган бер хатын.

Габделгазиз — Казанның мәшһүр бай угылы, фасикъ, вөҗдансыз, әхлаксыз, фисыкны мәсләк иткән егет.

Рабига — икенче кыз булып чыккан Хөршит.

Казан халкы тормышыннан.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бакча. Табигый бакча, зур агачлар, үләннәр, еракта коймалар күренә, бер өстәл дә бар.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Габделкаюм, Хөршитбану, хатын.

Хатын. Теләсәңез, өстәлгә утырыңыз, теләсәңез, менә монда чирәмгә. *(Төртеп күрсәтеп.)* Менә монда агач

---

* Оригиналда: «Ике гыйшык».

Мөкатдәс — изге.

Фасикъ — әхлагы бозык кеше.

Фисык — бозыклык.

Мәсләк — тоткан юл, принцип.

күләгәсе бик яхшы икән! *(Хөршитнең кулында чапаны, башында серый шәл, калфак күренеп тора, өстендә дипломат.)* Уф, эссе! *(Габделкаюмга карап.)* Ярар инде, кая булса да утырыйк.

Габделкаюм. Менә шунда күләгәгә генә утырыйк. *(Күләгәгә утыра башлыйлар.)*

Хатын. Туктагыз әле, юрганнар китереп җәйим.

Габделкаюм. Монда яшел үләннәр хәтфә паластан да артык, шунда гына утырабыз.

Хөршит. Чын, бигрәк матур икән, кара әле, нинди чәчәкләр!

Хатын. Бакчабыз матур шул, үземез дә гел шунда чәй эчәбез, сезгә самавыр хәзерлимме?

Габделкаюм. Хәзерлә, утырырбыз әле без. Тагы, абыстай, монда кечкенә генә балаңны җибәр әле, кибеткә җибәрербез, монда кибет бардыр?

Хатын. Бар, бар, ни теләсәк, ул бар, бир, үзем генә алып килермен. Шуның өчен әйтәм, әле кызым өйдә юк иде, мөселман ягына апаларына кунак булып киткән иде.

Каюм *(кесәсеннән акча чыгарып)*. Чәй алырга кирәк, ярты кадак конфет ал, царский конфетыннан.

Хатын. Пирсичәнеме?

Каюм. Түгел, мин тәмәке тартмыйм, царский конфетның бер төрлесе ул.

Хатын. Ярар, ярар.

Каюм. Аннан чикләвек ал, сохари ал. Монда җиләк юктыр инде?

Хатын. Булса, алырмын. *(Китә башлый.)*

Хөршит *(Каюмга карап)*. Әйт әле, өстемезгә кешефәлән кертмәсен, харап булырбыз.

Каюм. Абыстай, тукта әле!

Хатын *(борылып килә)*. Әллә тагы бер-бер нәрсә кирәкме?

Каюм. Җук, кирәк түгел, шуны гына әйтәм, абыстай, өстебезгә кеше кертә күрмәсәнә! Безгә кешегә күренергә ярамый.

Хатын. Җук, җук, безнең өйдә бик аулак, үзебез генә, аулаклылыгына кызыгып муллалар да киләләр. Кичә генә ике мулла, бер кеше килгәннәр иде, өйлә вакытында утыра башлаганнар иде, таң аттырып киттеләр, ташый-ташый йөдәп чыктык. Киләләр шул, киләләр, урынымыз аулак. Сер чыгармыйбыз, килделәр дә киттеләр, без беркемгә сөйләмибез.

Хөршит. Аларның тагы бер хәл, безгә кешегә күренергә ярамый.

К а ю м. Без чисныйлар. *(Хөршитне күрсәтеп.)* Ата баласы ул!

Х а т ы н. Беләм, беләм, битеңезгә чыккан бит. *(Китә-китә сөйли.)* Чисный имеш! Чисыңыз корсын, ата баласы булмаенча ярыймы соң, шул чикле ят егетләр берлә аулак бакчаларга килеп йөрерлек булгач! Замана бозылды! *(Чыгып китә.)*

Каюм, Хөршит.

Х ө р ш и т. Бүген иртә берлә сәгать йидедә уянып киттем. Карасам, шыбыр-шыбыр яңгыр ява. И Раббем! Бара алмаенча калам икән, күрә алмыйм күрәсең, дим. Хан мәсҗеденә «Ясин» әйттем, ни эшләргә белмәенчә йөрим. Бетерәсе эшем бар иде, бик тиз намазны укып, аңарга тотындым. Асрау самавыр-чәй әзерләде, әниләр дә торды, чәй эчкәндә яңгыр туктамыймы дип, әле бер тәрәзәгә карыйм, әле берсенә. Әни, нәрсә ул чикле карыйсың, ди. Үзебезнең Мөршидә иртәгә сигезләрдә барып җитәрмен, бара алмасам, сәгать 12 ләрдә үзең кил, дип әйткән иде, дидем. *(Көлеп.)* Ә* үзем юл хәзерлим.

К а ю м. Минем хатымны күргәч ни әйттең?

Х ө р ш и т. Ни әйтим, әнидән сорап чыгарга хәйлә эзләргә тотындым.

К а ю м. Ничек дип чыктың соң?

Х ө р ш и т. Шул, дәү әтиләргә барам дип сорадым да, Мөршидә янына кереп чыктым, аңарга әйттем, кайтканда тагы керәм.

К а ю м. Ул беләмени? Әйтү кирәкмәс иде, миңа яхшы түгел.

Х ө р ш и т. Сиңа яхшы булмаган нәрсә миңа да яхшы түгел дә, ул белүдән зарар юк, син әллә кем егетләренә әйтеп бетермә.

К а ю м. Башкалар белмиме йөргәнемезне? Әниең белә торгандыр ич?

Х ө р ш и т. Әстәгъфирулла! Әни белгәч, ул нигә ярый аннары?

К а ю м. Аналар кызларының эшен беләләр, диләр, шуның өчен әйтәм әле.

Х ө р ш и т. Инде ул кызларның егеткә күзләре төшсә, хәзер үзгәрә, кылыныш башкара, йөреше башкара, бик

---

* Бу сүз урынында оригиналда «җәл» дип язылган.
*Чисный (честный)* — намуслы.
*Әстәгъфирулла* — Ходайның кичерүен телим.

билгеле була, белмим, никтер безнең әни белмәде, әллә белеп тә әйтмәде.

К а ю м. Белгертмәскә тели торгансың.

Х ө р ш и т. Теләсәм дә, мин үзем ана булсам — белер идем.

К а ю м *(көлеп)*. Син Хуҗа Насретдин кебек әйттең, ул бервакыт акчасын карак урламас җиргә яшерәм дип яшергән дә, ди, исәпләп торып, мин үзем карак булсам, монда икәнен беләм ич, монда куярга ярамый, ди имеш.

Х ө р ш и т. Дөньядагы нинди кызык бар, һәммәсен Хуҗа Насретдин дип сөйлиләр, бер яңы чыккан хикәят китабында Хуҗа Насретдин китабындагы көлкеләрдән кызык көлкеләр бар.

К а ю м. Әйе, чибәр китаплар бар, эчең пошканда укысаң, күңелең рәхәтләнеп китә.

Х ө р ш и т. Кайсылары эчне генә пошыра, бик кызганыч кешеләр була, мин, шуларны айап, кайвакытта җылыйм. Шәкертләр чыгара диләр шуларны, дөрестме?

К а ю м. Җук, шәкертләр түгел, алар үзләренә бертөрле кешеләр, роман язучы диләр. Мәдрәсә шәкертләреннән андый нәрсә булмый, дөрест, шәкертләрнең дә яхшылары була, күбесе анда фатир гына ясап тора. Мин мәдрәсәдә тордым ич.

Х а т ы н эскәтерләр, поднос, чынаяк күтәреп килә.
Хатын, Хөршит, Каюм.

Х а т ы н. Озаграк тордыммы әллә? Күрше кибеттә әйберләр булмады, самавырым да хәзер кайнаган.

К а ю м. Зарар юк.

Х а т ы н *(үзе әзерли)*. Ә, монда тәрилкәләр кирәк икән әле.

Х ө р ш и т. Әле мин яңы гына бер китап укыдым, бер киленне бик кызгандым мескенне! Минем күк атасының, анасының бердәнбер кызы булган. Үзе сала баеныкы инде ул, аны Казанга биргәннәр. Аның, шул, ире эчә торган булган, кайнанасы моны бик кыскан. Шул эчә торган угылын да моның өстенә өйләндерергә теләгән. Ахырдан бөлгәннәр, бу килен, шул, кул эше берлә хезмәт итеп, һәммәсен тәрбия кылган. Ахырда ире дә шунда әллә ни эшләп, эчеп үлгән, моның этисеннән бик зур дәүләт калган. Иреннән бер угылы калган икән, угылы үскән, шулай иттереп, бай бикә булып гомерен үткәргән.

Х а т ы н *(китә башлый, сөйли-сөйли бара)*. Үзләре шактый китап Коръән сөйләп утырган булалар, бу елда

---

*Айап* — бу урында: кызганып.

инде укыганын белмәссең, укымаганын; «Галимнәр чагыр эчеп зина кыйлгай!» *(Күздән югала.)*

Хөршит, Каюм.

Каюм. Менә шундый романнар кешенең холкына файда бирә. Менә син укыгансың инде, син каенана булсаң, менә шулай көчләмәзсең.

Хөршит *(көлеп)*. Тумаган тайны дагаламыйлар дигән шикелле, миңа каенана булырга кая әле, хатын булмаган. *(Көлеп, кулыннан тотып.)* Тизрәк ал да, менә, элгәре хатының булыйм, аннан ары, Алла теләсә, балабыз-чагабыз үссә, каенана да булырмын, көлке әле кыз башың берлә шулай сөйләп утырырга!

Каюм. Сөйләмәсәң дә шулай ич ул.

Хатын *(самавыр күтәреп килә)*. Менә самавыр, бик яхшы күңелеңезне тынычландырып эчегез, бер дә шикләнмәңез. Ә, әле синең акчаң калган иде, аны оныткан икәнмен. *(Кесәсеннән чыгарып, шалтыратып, Каюмга бирә.)*

Каюм. Үзең берлән алып тор әле, абыстай, монда акча кирәк түгел.

Хатын. Ярый. *(Алып китә башлый.)* Әйбер кирәк булса, кычкырыңыз!

Хөршит. Ярый, рәхмәт, абыстай!

Хатын. Никадәр акча бирде, тәнкәсе — сиксәнлек, өч тин, монда ике тин, инде ничә тин була, тагы биш тин бар икән. Җә, кызым кайткач санар әле. Кызы да йомшак кына икән.

Пәрдәдән чыга.
Каюм, Хөршит.

Хөршит. Бер чәй ясап эчерим әле, юлда сагынырсың, Хөршит чәй ясап эчергән иде диерсең. *(Чәй ясый, Каюм тәрилкәләргә кәгазь капчыктан конфетлар сала.)*

Каюм. Ни эшләр инде, сагындырырсың инде, Хөршит!

Хөршит. Сиңа ир кешегә бернәрсә түгел, миңа бик авыр булыр.

Каюм. Алай димә, Хөршит! Ир булсак та, таш йөрәк түгел, миңа бәлки аерылу синекеннән дә авыр була торгандыр.

Хөршит. Ул, авырлыгы никадәр булса да, кайтасы көнге кызыкларны исәпләп җуаныр идем, кайткач ничек буласы билгеле түгел. *(Чәйләр ясалган. Кулына конфет алып)*. Мин куркам шул, ташласаң, ни эшләрмен, дим, озак торырсың микән анда?

К а ю м. Өч атналап торылыр шул. Москвада бер ун көнлек эшемез бар, эти әле Петербургка да барырга кирәк булыр, ди. Озак түгел, монда торганда да барыбер берәр ай күрешмәенчә торабыз ич.

Х ө р ш и т. Улсы күп түгел! Өч атна түгел, өч ай булса да, санаулы көн бер җитә ул. Читкә киткәч, башка уйлар төшеп, мине бөтенләй ташларсың дип кенә куркам.

К а ю м. Хөршит! Син миннән ничек аерылмаска телисең, мин дә шулай ук аерылмаска тырышам, зинһар, минем җөрәгемне җандырып гел шул аерылуны сөйләмә!

Х ө р ш и т. Минем бар курыкканым шул шул, аерылсам, бөтенләй харап булам. Йә гакылдан ук шашармын инде. *(Үзләре чәй эчәләр.)*

К а ю м. Соң, Хөршит, син минем сине сөюемә ышанамсың? Ышансаң, мин, үземә хәсрәт алып, ни эшләп сине ташлыйм?

Х ө р ш и т. Ышанам да, шул, үзгәрерсең дип куркам.

К а ю м. Әллә ни эшләдең син, Хөршит! Мин сине сагынып, сөйләп, бер күңел ачып керер өчен дип чыгам, син минем җөрәгемне генә җандырасың. Элгәре бер дә болай түгел идең.

Х ө р ш и т. Ни эшлим соң, Каюм, җөрәгемә чыдый алмаенча сөйлим, бер елдан бирле йөрибез, аз гына да алырга теләгән эшең юк, мин сиңа гыйффәтемне кызганмадым, әйтсәнә, зинһар, синнән башка кеше кулымнан тотканы бармы? Төнем дә шуны уйлыйм, көнем дә шуны.

К а ю м. Хөршит! Ни эшлим соң, һәрвакыт шуның касдында да, Ходадан вакыт җитми торгандыр шул, мине генә гаепле итеп калдырма инде аның өчен. Ни эшлим, җае чыкмагач? Мин өйләнмәгән, син кияүгә китмәгән, ул кадәр хәсрәтләнерлек эш юк әле.

Х ө р ш и т. Уф Алла, улсын Алла күрсәтмәсен инде! Аннан ары эш тә бетә! Бу көенчә дә бик уңайсыз шул! Безгә дә җаучы да килә, ярый быел яшь әле, мин кияүгә китмим, дия идем, тагы инде нинди хәйлә табармын! *(Туктап торып.)* Хәйләсен табар да идең, синнән алам дигән сүз булса! Мин әниләргә Каюмнан бүтәнгә бармыйм дисәм, син мине алмый калсаң, минем исемем генә чыгып кала шул! *(Еглаган тавыш берлә.)* Безнең кызларның кадерләре дә шул гыйффәтлектә генә! Минем атымчабым чыкса, син алмасаң, мин кая барам? Кем алыр? Барсам да, күңелем синдә булгач, мин ни рәхәт күрермен?

---

*Касд* — ният.

Каюм *(моңланып)*. Хөршит! Еглама юкка! Мин беләм, син мине сөясең, үземнең ни дәрәҗә сөйгәнемне дә беләм! Безнең булачак тормышыбыз да ни дәрәҗә рәхәт булачагы билгеле, чөнки тормышның рәхәтлегенең иң зур сәбәбе булган сөешү табылган, мин ничек булса да ул тормышны корыр өчен сине алмаенча калмаска тырышам, ләкин минем дә атам-анам бар, аларның да ризалыгын алырга кирәк.

Хөршит *(еглаган тавыш берлә Каюмның итәгенә җыгыла)*. Алмаслар инде, алмаслар, гомер буенча кибеп бетәрмен инде! Хәер, шулай булса, гомерем дә озын булмас!..

Каюм *(ике иң башыннан тотып торгызып, җылап)*. Хөршит! Дөньяда сөйгәнең башы хөрмәтенә әйтәм, зинһар, еглама! Син болай калсаң, сәфәрем сәфәр булмый, эшем эш булмый, җаным бул, тукта!

Хөршит. Бәгырем бул! Итәгеңә ятып еглавыма гына рөхсәт бир! Зинһар, кәефең китмәсен, татлы яшьләремнән генә аермасана, җаным! Бу яшьләр... Бу яшьләремнең тәмен белсәң иде! *(Туктап торып.)* Болар әллә нилләрне исемә төшерәләр. Валлаһи, бөтен дөньядан сине артык күрәм. *(Муенына асылына.)*

Каюм *(кулын салып җылый)*. Җыла, җаным, җыла! Алла күз яшьләремезне кабул итсен! Дөньяда күз яшеннән... күз яшеннән... газиз нәрсә юк. *(Туктап торып.)* Минем өчен түгәсеңме бу яшьләрне?! *(Кочаклап маңлаеннан үбә.)* Җан дустым! Ташламам, ташламам!

Хөршит *(торып, ике кулын чуп-чуп үбеп)*. Бәгырем бул, ике күзем, вәгъдәңне онытма! Түккән күз яшьләрем бәрабәренә әйтәм, ташлама! Аяк астында туфрак булып хезмәт итәрмен, җаным, ал! Мин бай дип һаваланма! Алмасаң, үкенерсең, миннән артык сине беркем дә сөя алмас, валлаһи, күңелемнән сөям. *(Яшенә карылып.)* Күп сөйли дип үпкәләмә, җаным, мин хәлемне сиңа сөйләми кемгә сөйлим?

Каюм. Хөршит! Ышан миңа, җаным, ялганламыйм! Чын күңелемнән сөям, тиң күрми дип уйлый торгансың, валлаһи, һичбер андый уй күңелемә кереп тә чыкканы юк, холкыңны яратам, үзеңне сөям, миңа башкасы кирәкми, әти-әни генә разый булсыннар инде.

Хөршит. Белмим, җаным! Белмим! Күңелем бик курка, безнең бу кадәр күз яшьләребезне агыздыру кирәкмәсләр иде дә, картлар кашында ул күз яшенә бер дә бәһа юк шул! Ходай ни язды, шул булыр инде.

---

*Кашында* — каршында.

К а ю м. Болай еглап та бер дә файда юк, ничек булса да үзеңне үзең җуатып торырга кирәк.

Х ө р ш и т. Ул бер аңлаган кешегә еглап сөйләсәң, эчләр бушап китә, хәсрәтләр тарала, күз яше аккан саен баш җиңеләя, гүя баштагы авыру-хәсрәтләр күз яше булып агалар.

К а ю м. Улсы дөрест, ләкин куркам мин, ул яшьләргә мин сәбәп булмыйм дим. *(Моңаеп.)* Күз яше бик сыек, ләкин бик зәһәр, нинди нәрсәне дә ашый, нинди кешене дә харап итә. Күз яшенең бер тамчысы бер кешенең гомерен харап итәргә җитә, күз яше адәмнең сүз берлә әйтеп бирә алмаган нәрсәләрен аңлата! Бөтен хәсрәтләрен уйландыра, башыннан кичкән хәсрәтләр, кайгыларны яңарта! Кешенең кайгылы вакытындагы күренешләрен искә төшерә, алар өчен хәсрәтләндерә, бала вакыттагы хәсрәт, кайгы, рәхәт, сәгадәт кебек нәрсәләрдән хәбәрсез чакларны искә китереп: «Йа Рабби! Нинди рәхәт чакларым бар иде, хәзер нинди хәлдә мин! Гаҗәба! Шул рәхәтләрне күргән кеше минме?» — дидерә, үзеннән үзен биздерә, гүя дөньяның иң бәхетсез кешесе кебек күрсәтә! Менә миндә шундый вакытлар була, Хөршит! Дөньяда һичнәрсә күземә күренми! Дәүләт бернәрсә түгел! Азмаз белгән гыйлемең бер әйбер түгел, исәнлек, сәламәтлек бер шәй түгел!

Күз алдыма тау кебек өелеп-өелеп гаепләрем килә, күңелемә, дөньяда ни төрле хәсрәт-кайгы булса, гүя һәммәсе киләчәктә бәнем башымнан үтәчәк кеби күренә! Белмим, минем күңелем ни эшли торгандыр! Язмыш миңа ниләр хәзерли торгандыр?! Кибеттән кайтып бүлмәмә керсәм, нәрсәдер бүлмәмдә юк! Китап укырга тотынсам, ни өчендер, бернәрсә аңламыйм! Каядыр минем әүвәлге зиһенем! Ятсам урыныма, башыма килгән уйларны, түгел минем башым гына чишәргә, Әфләтун, Арестуның фәлсәфәләре, белмим, чишәр иде, белмим, юк! Ул кальбемне ярсалар, галәмгә чыгарсалар, белмим, нинди хәсрәтләр табылыр иде! Бер көндә башымнан кичкән вакыйгалар, күңелемдә уйланган фикерләр бер мөхәрриргә гомере буенча язарга җитәр иде! Ай әдип булмаган! Язар идем, белдерер идем, аңлатыр идем. Дөньяны аңладым!!! Аңлата гына алмыйм! Уф! Нидәндер мин дөньядан разый түгел! *(Еглаган тавыш берлә.)* Кяш-

---

*Гаҗәба* — бик гаҗәп, ни гаҗәп.
*Шәй* — нәрсә, әйбер.
*Кальб* — күңел, йөрәк.
*Кяшки* — бу урында: әгәр.

ки мин бер фәкыйрь баласы булсам иде дә үз эшемә үзем баш булсам иде, минем мөкатдәс уйларым бөтен дуст-ишләремнән көлкегә генә алынмасалар иде! Уф, Хөршит! Язмышымнан мин разый түгел! Мин разый түгел! *(Итәгенә егыла.)* Дөньяда күңелемне җуатыр бер кеше юк! Исмасам, син дә еглап, хәсрәтләрне чиштек! Минем хәлемне сөйләргә сүз аңлый торган дустым да юк! Сөйләсәм, дәүләткә чыдый алмый, диләр, шул дәүләт өстенә тагы ни кирәк, имеш? Мин, дәүләт юк, димим! Рәхәт юк, дим!

Дәүләт башка, рәхәт башка! Исмасам, сүз аңларлык сеңелем дә юк! Мин ни эшләсәм, эшем килешми, ни сөйләсәм, сүзем ишетелми, белмим, нидәндер болай итәләр! Эчемә җыелган хәсрәтләрне белсәң иде, Хөршит, кычкырып җылар идең! Әле дә мин үземнең көләчлегем берлән кешегә белдермим. Уф Алла!.. Безнең өйнең начарлыгын белсәң иде, безнең тормышның кызыксызлыгын күрсәң иде, Хөршит, хәйранга калыр идең!! *(Еглап, Хөршитнең кулыннан тотып, еглаган тавыш берлән.)* Үзем дөнья рәхәтеннән мәхрүм идем, сине дә мәхрүм иттем. Җаным, гаепле мин синең кашыңда! Гаепле! Сине алмасам, гыйшык уты берлән җандырам, алсам, үги ана уты берлән көйдерәм. Барысына да мин сәбәп улдым, барысына да. Рәхәтеңнән яздырдым. Күңелеңне аздырдым! Гөнаһсыз башыңны, дәртсез күңелеңне хәсрәт дәрьясына чумырдым. Мин гөнаһлы, фәрештәм! Мин гөнаһлы! *(Маңлаеннан үбә, битенә карап.)* Бу ал йөзләрең, озын сачләрең, җазибәле күзләрең, агудан ачы яшьләргә фида булырмы икәнни?! Атаң-анаң, бәгырь парәсе, күз нуры дип, сине шул көннәр өчен тәрбия кылдылар микәнни?! Сачәк вакытың минем кеби бәдбәхетләрнең дәрте берлән вәйран булырмыни? Мин сәбәп булдым, җаным, мин сәбәп булдым! Ни әйтим, таулардан зур синең кашыңда гаебем, ни әйтим?! Сиңа хат язмасам, болай булмый иде, ник яздым?! Ник яздым?! Үзем кызганыч түгел, сине харап иттем! *(Хөршит яулыгын алып Каюмның күзен сөртә.)* Уф Раббем! Үзең җайла, хәлем бик авыр, Хөршит!

Хөршит *(моң гына иттереп)*. Каюм җаным, җылама! Минем өчен бу кадәр хәсрәтләнмә! Үзеңне үзең ул дәрәҗә борчыма! Әлхәмдүлиллаһ, дәүләтеңез бар! Сәламәтлегең бар, атаң-анаң читрәк күрсә дә, ни эшлисең

---

*Исмасам* — ичмасам.
*Җазибә* — үзенә тартып торучы.
*Фида булу* — корбан булу.

соң? Башка кешеләрдә ул әллә ни җук. Сиңа анын өчен мин һич рәнҗемим, бәйләндек инде, ни эшлисең. Аласың икән — рәхмәт, мине морадыма тиендерәсең, алырга теләп тә, атаң-анаң рөхсәт бирмәсә, анда син гаепле түгел. Дөрест, мин харап булырмын, дөньяда мин тормыш рәхәтен күрмәм... Ир ләззәтен татымам... Бу эшләрем өчен бәлки газиз атам-анамның да ачуларын алырмын. Ләкин син, мине алып, әллә никадәр үзеңә авырлыклар йөкләргә тиеш булса *(еглаган тавыш берлә)*, ул вакытта алма мине!.. *(Калтырап.)* Мин сиңа рәнҗемим, Аллаһе Тәгалә сиңа изге көннәр бирсен. Әмма миңа авыр булыр гына дисәң, анысыннан курыкма, миңа син булсаң, һәммә мәшәкатьләр бернәрсә түгел, дөньяның ләззәте миңа синең берлә булуда гына. Әгәр мине ала алып та, үзең алмый калсаң, ул вакытта мин разый түгел. Күз яшьләрем көйдерер дип куркасың, күңелең дөрест булса, күз яшьләрем сиңа файда гына булыр. Күз яшьләремне тыя алам димим, тыя алмыйм, хәсрәтләнәм. Ләкин мин синнән бәхил, җаным! Үзең дә миннән разый бул. Белмәссең, дөньяның әллә нинди хәлләре булыр. *(Кулын үбә.)*

Каюм *(калтыраган тавыш берлә)*. Хөршит! Ни сөйлисең, сәламәтсең ич син? Ул ни дигән сүз?..

Хөршит. Сәламәт шул, сәламәт! Хәсрәтемнең урысы да шул. Кяшки бу көн синең кочагыңда актык күрешүләребез дип зәһәр яшьләрем берлән йөзләреңне буяганча, үлем түшәгендә актык сулышларымны суласамчы? Ул вакытта соңгы минутларым дөньяның ачыларыннан, бетмәс-төкәнмәс хәсрәтләреннән газиз җанымны коткарыр иде! Бу минутлар миңа язмышымның актык хөкемнәрен белдерделәр, гомеремдә рәхәттән мәхрүм иттеләр, яшьлегемдә яшьлек кызыкларыннан аердылар, артык дөньядан өметем калмады! Калмады!! *(Каюмның итәгенә җыгыла.)*

Каюм. Хөршит, ташла шул сүзләрне, безнең хәсрәтләр болай еглап кына бетмәс. Алай бөтен дөньядан өмет өзәрлек түгел әле синең хәлең дә, никадәр егласаң, шулкадәр яшь күбәя, зинһар, тукта. Актык күрешүләребез була икән, моннан соң егларга вакытлар булыр, очраган вакытта сөйләшеп калыйк. Әгәр актык булмый икән, еглау ни эшкә? Тор, җаным, сөрт күзләреңне! *(Хөршит әкертен генә торып күзен сөртә. Каюм да*

---

*Морад* — теләк.
*Зәһәр* — бу урында: ачы.

*чәйләрне савытка сала.)* Чәйләр дә суынып беткән икән, эчә алмаенча да калдык.

Хөршит чәй ясый башлый.

Каюм. Хөршит, әллә самавыр сүндеме! Мин теге хатынны чакырыйммы?

Хөршит. Кирәкмәс, шул көенчә генә эчәрбез. Кара әле, сәгатең ничә булган? Миңа кайтырга вакыт йитмәсен.

Каюм *(алтын сәгатьне ачып карап)*. Бер туларга унике минут.

Хөршит. Әле миңа бераз вакыт бар икән. Әтиең берлән барасызмы, Каюм?

Каюм. Әле үзем генә бармакчы булам, әтигә бүтән уй төшмәсә.

Хөршит. Үзең генә башкарасыңмы шул чикле эшне?

Каюм. Ике ел инде, андый эшләрне үзем эшлим. Бүтән эшне дә башкарыр идем дә, әти үзе ташламый әле, әни дә мине ул чикле эшкә керүемне күпсенә, үги ана бит, Хөршит, минем кеше булуыма бер дә разый түгел!

Хөршит. Шулайдыр шул, Каюм, безнең әни дә җылап-җылап үги әнисенең көчләүләрен сөйли. Әллә ниләр кылып бетергән инде, әйберләр арасына егетләр хаты итеп үзе язып тыккан, аны тапкан булып бабайга күрсәткән. Бабай бик көнче кеше булган. Ул вакытларда, ул, егетләр берлә хат алышу да бик сирәк булгандыр шул, әнине бик кыйнаган. Шуннан соң, элгәре ни өчен икәнен белмәгән икән, ахырдан бабай әйткәч, әни җылап-җылап ант иткән. Шуннан соң ышанган төсле булган да, алай булса да элгәрегечә булмады, ди. Шуннан ары әнине әлеге әтигә килешкәннәр. Шул үги әби инде әтинең булдыклылыгын белә икән, бик кайтартырга тырышкан, әнигә әллә нинди егетләр исеменнән дип хатлар китерткән. Әни әйтә, шул, алай да Аллага шөкер, берсенә дә алданмадым, ди.

Каюм. Минем әни генә шулаймы әллә дип тора идем, башкалар да бар икән. Минем әни дә шуның нәселе түгел микән?

Хөршит. Нәселе бер булмаса да, үгилекләре бер ич инде.

Чәй эчәләр.

Каюм. Шулай шул, ни кылса да, сиңа зарар итәргә тели.

Х ө р ш и т. Безнең җиңги дә, ана, үги балалар тәрбия кыла да, бер дә алай көчләми. Балалары үз аналарыннан артык күрәләр.

К а ю м. Мин дә бик якын күрер идем, усаллыгыннан һич айнытмый. Әле бертөрле усаллык кыла, әле бертөрле. Синең җиңгәң дә йә бик яхшы укыгандыр, яисә анасы бик яхшы карчык булгандыр. Ничек булса да, ул кеше рәнҗетүнең начарлыгын аңлагандыр. Ул шул андыйлар йөзгә бердер, йә меңгә.

Х ө р ш и т. Ул үзе шул йомшак күңелле, яхшы хатын, ул шул үги кызны да шундый яхшы карап бирде — бөтен карендәш-кабилә рәхмәт укыдылар, җиһаздан җиһаз ясады, эштән эшкә өйрәтте, аны, әнә Ягкуб байның приказчигы бар, Сөләйман исемле, шуңарга бирделәр. Үзе дә бик гакыллы кыз иде, киявен дә бик мактыйлар — эчми-тармый, үз эшендә генә, ди.

К а ю м. Алай яхшы егет икән. Приказчиклар арасында бөтен айлык акчасын әрәм итеп бетерә торганнары да бик күп була. Яңы мода казакиләренә, очлы бүрекләренә, майлы күзләренә карап, безнең Казан кызлары фәрештә төсле дип белсәләр дә, аларның күбесе шул кием калыбы гына булалар. Кайсы приказчиклар була, бөтен айлык акчасын киемгә тыгып бетерә. *(Көлеп.)* Аның, шул, хатын-кыз арасында кадере дә зуррак була инде. Безнең шундый бер Сәйфулла исемле приказчик бар иде, мескен, шул бар акчасын киемгә бетерә иде. Шул җыен вак-төяк хатын-кызның күңелен ала-ала гомере буенча өйләнә алмый калды. Беркөнне бу яңы киемнәр кигән, мин кассада утырам, приказчиклар берлән җүри җентекләп торабыз, хатын-кыз, кибеткә килеп керәләр дә, чапан астыннан гына элгәре кая кем бар, шуны карыйлар да, Сәйфуллага таба китәләр. Бер хатын, кибеткә кергәч каранды да бер якка бара иде, шунда көзге бар, көзгедә Сәйфулланы күрде, борылды да бара башлады, менә кибет халкы: «Элгәрерәк белмәдеңмени аның киеме яңы икәнлеген?» — дип көлә башладылар. Ярый, хатын бик әдәпсез түгел икән, бер сүз әйтмәенчә чыгып китте.

Х ө р ш и т. Оятлы иткәнсез икән мескенне?

К а ю м. Ни эшләп йөрергә кирәк, үз кадерен үзе китәреп. Безнең Казан хатыннарында хәзер гореф китте, бер кечкенә генә йомыш булса, киенә, ясана, бизәнә дә базарга чыгып китә, шәлләр бөркәнә, чапан ябына, ты-

---

*Ана* — әнә.

шыннан караганда бер әүлия хатын дип белерсең, эченә керсәң... күзләрендә май чабалар.

Хөршит. Гел хатыннарны гына гаепле итәсең. Базар халкы үзләре дә, бер хатын килеп керсә, хәзер елмая-елмая сөйләргә тотыналар.

Каюм. Мин дә аларда гаеп юк димим, алар сөйли шул, шуңарга өйрәнеп беткәннәр, алар аннан оялмый, хурланмый, аларның эшләре шул. Ләкин, алар шулай дип, кергән хатын-кыз алар төсле булырга ярамый.

Хөршит. Улсы шулай инде, вак-төяк хатын-кыз азрак эш эшләклиләр дә, әллә ниләр киенеп бетәләр, үзе кәләпүшче хатын була, йә тегүче кыз була. Улсы ярар, үзебез сөйлик әле. Беркөн сиңа Шәрәфетдин бай кызы Гарифәдән җаучы барды, диделәр, дөрестме ул?

Каюм. Шулай дигәннәр иде, бүтән бер эш тә булган юк, миңа бер кеше дә ул тугрыдан сүз сөйләгәне юк.

Хөршит. Сорасалар, риза булыр идеңме соң?

Каюм. Тагы каян китереп чыгардың, Хөршит! Ни эшләп разый булыйм! Булмас идем.

Хөршит. Әйе, булмас идең, минем алдымда гына шулай әйтәсең.

Каюм. Синең артыңда ни эшләгәнем бар соң, Хөршит!

Хөршит. Юк та...

Каюм. Сөйләргә бер сүз булсын дип кенә әйтәсеңме?

Хөршит *(көлеп, иркәләнеп кенә)*. Түгел.

Каюм. Алай булса, миннән «сөям сине» дигән сүзне ишетер өчен икән!

Хөршит *(кычкырыбрак көлеп)*. Аны кайдан белдең?

Каюм. Элгәрерәк, синең берлә яңы сөешә башлаганда синнән шул сүзне бик көтә идем, беркөнне сөям генә димәдең, әллә ниләр бизәкләп-бизәкләп, әдипләр төсле сөйләгән идең, минем шул көнге шатлыгым кеби шатлануымны гомеремдә белмим.

Хөршит. Мин ул сүзләрне үзем дә шатлана-шатлана сөйләгән идем, күрәсең, сиңа да шундый кызык булган, кара әле сөешү нинди ләззәтле!..

Каюм. Сөешү болай әле, сөешеп бергә гомер үткәрү ничек була икән?

Хөршит. Чын, бик кызыктыр, бөтен гомерең хәзергә сәгатьләр төсле була микән?

Каюм. Икең дә үз тугрыңа төшкән эшне эшләсәң, мәхәббәт искермәсә, билгеле, шулай була шул.

---

*Эшләклиләр* — эшләштерәләр.

Х ө р ш и т. Ә мәхәббәт искерәме?

К а ю м. Искерә дә... бетә дә.

Х ө р ш и т. Синеке бетмәсә ярар иде.

К а ю м. Синеке бетсә дә ярар идеме?

Х ө р ш и т. Минеке бетәрлек түгел, синекенә генә ышанып бетмим.

К а ю м. Мәхәббәтнең кызыгы да ышанмау берлән арта ул, син миңа «сөя» дип ышансаң, мин сине «сөя инде» дип йөрсәм, сүзләргә сүз дә калмый.

И к е с е б е р ь ю л ы. Әле, исмасам, чыккан саен шуны сөйлибез.

Х ө р ш и т. Ул вакытта көнләмәс тә идек, чын, әллә ни төсле була. *(Көлә.)* Менә сөешеп-сөешеп, кавышалмый калсаң, гомер үткәрү читен була торгандыр?

К а ю м *(көлеп)*. Мин сине «Сөешеп-сөешеп кавышалмый» дигәч, «Сөешеп-сөешеп кавышмаган бер без түгел — ил берлән!» дигән йырны йырлый дип белдем.

Х ө р ш и т. Мин йырласам, аны йырламас идем, менә шул йырны йырлар идем мин:

> Сөямен үзеңне, кашың берлән күзеңне.
> Кавышырбыз, кавышырбыз, онытмасаң сүзеңне!

Син ни әйтер идең?

К а ю м. Ни әйтим, мин әйтәсене үзең дә беләсең инде, шуны әйтим әле, Хөршит! Зинһар, аерылганда җылап калма.

Х ө р ш и т. Ярар, кайчанга китәсез әле?

К а ю м. Иртәгә «Самолет» парахутына төшәбез, син дә озатырга төшәмсең?

Х ө р ш и т. Мин ничек төшим, анда кая күрешербез, мин алай теләсәм ничек йөри торган кыз түгел.

К а ю м *(көлеп)*. Җүри генә әйтәм.

Күренешкә х а т ы н чыга.

Х а т ы н. Эчәсезме, эчеңез, эчеңез, эһ-эһ-эһ... Бая да килгән идем дә, әллә җылый идеңез, керми киттем, була ул, була яшь вакытта. Бер-бер нәрсә кирәкмиме?

Х ө р ш и т. Җук, утыр, абыстай, чәй эчәрсең!

Х а т ы н. Рәхмәт, нигъмәт кайтарырга ярамый, берне генә эчим алай булса. Кызым кайтмый әле, кияүгә дә кайтырга вакыт җитә инде.

К а ю м. Абыстай, үзең Казанныкымы син?

Х а т ы н. Җук, мин Арча юлыныкы, угылымыз да сол-

---

*Сүзләргә* — сөйләргә.

датка киткән иде, картым үлде, шуның өчен монда кызыма торырга килдем. Өченче генә аем әле.

Каюм. Алай икән.

Хатын *(көлеп)*. Әйтергә дә яхшысынмыйм, ирлехатынлымы?.. Алай дисәм, яшьрәкләр, менә бездә дә җыен вакытларында шулай кызлар берлә егетләр аулакларда күрешәләр.

Хөршит. Ата-анасы ачуланмыймы соң?

Хатын. Җук, ни эшләп ачулансын? Ата-бабалардан калган йола ич! Яшьләргә күңел ачу кирәк. Муллалар гына бу елда тыя башладылар! Шуның өчен безнең илкөннән бәрәкәт күтәрелде, ашлык та булмый башлады. Элгәре без яшь вакытта уены да була иде, ашлыгы да була иде. *(Бер чынаяк чәй эчә, чикләвекләр ашый.)*

Ерактан бер тавыш ишетелә: «Хәбибә абыстай!»

Хатын. Кем икән? *(Торып китә башлый.)* Иртәгә килербез дигән кешеләр бар иде, шулар микән?

Күренештән чыга.

Хөршит *(торып, чапанын ала да)*. Нинди кешеләр икән? Харап булмасак ярар иде, Каюм! Әйдә, зинһар, китик.

Каюм. Ул кадәр ашыкма, менә шул конфетларны ал.

Хөршит. Зинһар, анысы кирәк түгел, кем булса да мине калдырып чыкмасана.

Каюм *(конфетны алып бирә-бирә)*. Ни эшләп мин сине ташлап чыгыйм.

Хөршит. Әйдә, зинһар, китик, харап булам, кеше сүзенә чыгам. *(Китә башлый. Каюм зонтик ала да бара. Хөршит туктап көлеп карап.)* Каюм! Беләмсең, аерылабыз, хуш бул, җаным, исән йөреп, сәламәт кайт.

Каюм. Син дә сәламәт тор да, шатлык берлә күрешергә насыйп итсен.

Хөршит *(калтыраган тавыш берлә)*. Амин! *(Күрешә башлыйлар. Кулын тотып торып.)* Онытма вәгъдәңне! *(Каюмның муеныннан кочаклый.)*

Каюм. Онытмам, җаным, онытмам.

Хөршит *(алып, көлгәнрәк тавыш берлә)*. Москвадан кайткач та хат яз.

Шул арада карчык килеп керә дә, кызга карап,
күзендә яшь күреп:

Карчык. Җылама! Җылама! Китте, үзебезнең күрше-

күлән генә, тагы килегез. Ә... әйберләреңезне алмадыңызмыни?

Каюм *(кесәсенә тыгылып бер ак тәнкә алып)*. Мә, абыстай, әйберләрне дә ал, безне сораучы булса да, безне әйтмәсәнә.

Хөршит. Хуш, абыстай.

Хатын. Хуш.

Пәрдә төшәр.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Рәхмәтулла байның аш бүлмәсе, сул якта Габделкаюмның бүлмәсе, аш бүлмәсе артындагы ишек ачык, ашханә күренә һәм ике асрау арлы-бирле көлешеп-көлешеп йөриләр. Аш-су бүлмәсендә түгәрәк өстәлдә чәй әзерләнгән, Рәхмәтулла бай берлә бикәсе Галимә күренә. Бүлмә байларча зиннәтләнгән, Рәхмәтулла бай ак сакаллы, нечкә иттереп кырыккан мыеклы, эре кызыл төймәләр берлә ясаган кара постау казаки кигән, тездән аз гына үткән чалбар, саче алган, башына чуклы иске генә пол фәс кигән, Галимә бик кечкенә калфактан, яңы мода күлмәктән. Чәй эчәләр.

Рәхмәтулла. Бүген иртә намазда мәгъзүм Коръән укыган иде, өйлә намазында тамга җыйдык, хираәте яхшы икән, арттагы сафка ук ишетелде. Гыйлемен бик мактамыйлар да, ата баласы дидек инде.

Галимә. Инде тамга тулдымыни? Әллә өйләндерерләр инде.

Рәхмәтулла. Әйе, шулай да урысча укымаган ди, бу елда шул чыкты, мөселманнар арасында фетнә.

Галимә. Габдулла байлар, Гали байлар куймаска телиләр дигәннәр иде, разый булдылармыни?

Рәхмәтулла. Булдык инде, мәгъзүм дә бу яңы укытуны мәдрәсәгә кертмим дип сүз биргәч, дим-димнәш берлә разый булыштык.

Галимә. Ул элгәре Бохарага китмәс борын шактый ачык бер шәкерт иде, әллә нинди ямьсез чалмалар киеп, бик озын чапаннар киеп, нәкәсләнеп кайткан.

Рәхмәтулла. Мәшәихләр тәрбиясе!

Галимә. Алаен алай да, яшь кешегә ул чикле үк килешми инде, бер сүз сөйләмәенчә утыра, әллә бохар тәмәкесенә өйрәнде микән?

---

*Мәгъзүм* — мәхдүм, мулла малае.
*Хираәт* — кыйраәт (Коръәнне кычкырып уку).
*Нәкәс* — яраксыз, тупас, ялкау.
*Мәшәих* — бу урында: ишаннар.

Р ә х м ә т у л л а. Ул булмас, аңарга өйрәнгән кеше сүздән тукталмый, диләр, әфиюн булса булыр инде.

Г а л и м ә. Әфиюнын-мәфиюнын белмим, бигрәк сөкүтләнгән инде. Ул ничек мәдрәсәгә керер икән, ирләр эшен без белмибез дә, булмас аңардан, булмас!

К а ю м килеп керә, Галимә аңарга карап «Утыр!». Каюм утыра.

Р ә х м ә т у л л а. Белгән идек тә, атасы олуг кеше булганга, догасын алыйк, дидек, мәрхүм әтисе галим кеше иде.

К а ю м. Кем ул?

Р ә х м ә т у л л а. Үзебезнең мәгъзүмне әйтәм, аңарга тамга җыйдык бүген.

К а ю м. Мулла буламыни? Ә, алай икән, мәдрәсәдә нинди зур хәлфәләр бар, алар ни эшлиләр икән, мәдрәсәне таратасыз икән.

Р ә х м ә т у л л а. Яңы укытуны да кертмәм дигәч, атасы яхшы кеше дип, разый булдык.

К а ю м. Атасының яхшылыгы аңаргамыни! Ул яхшы булса, үз дәрәҗәсен алган, моның начарлыгын белә торып куясыз. Кыямәт көнне ни җавап бирерсез? Безнең халыкта бер сүз бар! Атасы яхшы, имеш, анасына ник бер дә карамыйсыз?!

Р ә х м ә т у л л а. Син яшь әле, тик тор, олугларга тел тиермә.

К а ю м. Мин тиеп әйтмим, шундый зур урынга кешесен карап куярга кирәк иде.

Р ә х м ә т у л л а. Урыны зур булгач, кешесе дә зур була. Гыйлеме бар дип, Шакир төсле нәселсезне куярга кирәкмени?

К а ю м. Ул менә русларда һәр урынга ярарлык кеше куялар, шуның өчен һәммә кеше үз дәрәҗәсендә тора, бездә шундый эш булмаганга, муллаларыбызның имгә ярамый торганнары була, Казан шәһәренә имам итеп шуларны куярга хурлыгы да бар бит!

Р ә х м ә т у л л а *(ачуланып)*. Бер белгәнең урыс, ни сөйләсәң дә, урыс катыштырмый сөйли алмыйсың, әллә урыс булырга телисеңме? Бу нинди бу, теләсәң ни хакында сөйлисең, синең ни эшең бар мулла сайлауда?! Мәхәллә байлары сайлаганнар, тагы ни кирәк, бәрәкәтсез? Әллә муллаларга курс тутырганны куяр идеңме? Ата баласы. Бохар йөргән, мәшаихләр күргән, тагы ни кирәк? Әдәпсез булмасаң, олугларга тел тиермәс идең!

---

*Сөкүтләнү* — дәшми тору.

Галимә. Гел сынап торам, кешегә яраган кеше безнең Каюмга ярамый, халык яратмый торган кешеләр берлә дуст була. Мөхсин байларны әле карт абыстай, кызын болардан укытмаган өчен, тирес кул берлә каргады, бу шуның берлә дуст. Хәдичә бикәнең урысча укып йөри торган угылы — тагы моның дусты. *(Каюмга карап.)* Син, кеше буласың килсә, этиең дустлары берлә дуст бул, аларны дошман күреп йөрисең. Шәкүр бай угылы Харис ник ярамаган? Үзе синең кебек яшь егет, атасы хәзрәт сабагына кергән. Кибеттән кергәч бераз чыгып керә дә, ди, синең шикелле күзен бетәштереп әкият китаплары укып ятмый, ди. Әле беркөнне этисе йортка килгән хәерчеләргә бирергә дип акча биреп чыгарды да, яртысын гына биргән, ди, бу кирәк булыр әле дип, яртысын үз кесәсенә салып куйды, ди. Менә шундый җыйнак, ди!

Рәхмәтулла. Моның атасы тапкан акча җиңел әле, бу әллә нинди мирзаларга ияреп убществаларга акчалар түләп йөри. Болар гына яхшы булганнар! Фәкыйрьләр ашаталар, имеш! Бик яхшы буласылары килә икән — сачләрен, мыекларын төзәтсеннәр. Балам үзем төсле булсын дип Аллаһе Тәгаләдән ни чикле сорадым, догам кабул булмады. Мин, әлхәмдүлиллаһ, синең кебек яшь вакытымда юк китаплар укып вакытымны үткәрмәдем. Кәҗит укыган булып та ялганнарга ышанып, анда сугыш бар, монда сугыш бар, дип йөрмәдем. Алай булса да, сугыш булганны белмәенчә калмадым. Сугыш булдисә, күккә кызыллык күтәрелә, тагы нәрсәгә акча әрәм итеп, күңел каралтып, гәзитләр укырга инде.

Галимә. Әле мин сиңа әйтмим генә, син Москвада вакытта һәркөнне кич берлә театрга барды, акча әрәм итеп, анда ни эшләп йөри торгандыр, исмасам, ат кәмитенә барса, кызыгы булыр иде.

Рәхмәтулла. Ул безнең сүзне тыңламый инде, анда соң ни эшләп күңел каралтып бер урысның сөйләгәнен тыңлап торыйм! Эчең поша икән, ал китап, укы, безнең китап азмыни? «Сәетбатталмы» дисең, «Фәттахетдин»-ме, нинди кызык китаплар! Без тыңлап торыр идек, син укыр идең. Мин сине азрак адреслар язарлык белсен дип укыттым, син әллә нәрсәләр укый башладың. Белмим, инде бу нинди кеше булыр?!

Габделкаюм. Эти, ул чикле ник битәрлисең, мин акча әрәм итеп йөримме? Әллә сезгә хезмәт итмимме? Минем яшьтәш егетләремнән үк аталарын бөлдереп бетерүчеләр бар ич! Ник аларга бер дә карамыйсыз? Русча укуымнан ни зарар бар? Мин аларның китабын укысам,

файдалыларын гына укыйм, әдәп өйрәтә торган, холык яхшырта торганын.

Рәхмәтулла. Аһ-аһ-аһ! Урыс китабыннан холык яхшырта торганын, файдалыларын укый, имеш! Бик анда ишаннар сабагын өйрәтә торгандыр. *(Торып чыгып китә.)*

Галимә. Гайниҗамал! Җыештыр самавырны!

Галимә дә чыга, Габделкаюм да чыга да,
үз бүлмәсенә барып керә.

Каюм. Менә болар берлән тор инде! Аталык хакы бар инде. Бу кадәр хатыннар сүзенә карап йөри торган кеше булыр икән! Шәкүр байның Харисы атасының фәкыйрьләргә дип биргән акчасын кесәсенә салып калган да, фәкыйрьләр хакын фахеш юлында әрәм иткән дә, шуның өчен мактаулы булган! Мин үземнең андан-моннан җыйган акчамны фәкыйрьләр ашатыр өчен биргән икәнмен дә — гаепле булганмын! *(Гайниҗамал самавырларны ала. Каюм акыртын гына укып, өстәл астыннан кәрзинкә чыгарып, китаплар актара.)* Күзләрем сине күзләр, күңелем Хөршитне эзләр! Хуш, җаным, Хөршитем! Аерылдык безләр. *(Шул арада Шаһидә килеп керә. Каюм, куркып сикереп торып, Шаһидәне күргәч.)* Куркыттың! Әти дип белдем. *(Китапларга төртеп күрсәтеп.)* Ул боларны күрсә, кыямәт кубарыр ич.

Шаһидә. Теге җегет килгән, сезне чакыра.

Каюм. Кайсы җегет?

Шаһидә. Ана теге безгә кунаклар килгән көнне бер кеше килгән иде ич.

Каюм. Ә, Гәрәй.

Шаһидә. Җук, ул түгел, иртәгесен син Москвада вакытта урыслар звонок куйдылар, шул көнне ул сине сораган иде.

Каюм. Аңламадым. *(Уйлап.)* Кунаклар килгән көнне бер кеше килгән, аның иртәгесен тагы бер кеше килгән, урыслар звонок куйганнар, бүген тагы бер кеше килгән, мондан нәрсә аңлыйм?!

Шаһидә. Теге җегет инде! Күзләре Җәмилә күзе төсле.

Каюм. Җәмиләңне белмим! Сүзеңне аңламыйм! Бар, кер, диң!

Кыз китә.

Каюм. Остазбикәләр вәгазе төсле сөйләп, башымны

---

*Сөкүтләнү* — дәшми тору.

әйләндереп бетерде, һәммәсе дә татар телендә сарыф, нәху юклыктан. *(Китапларын рәтләп, берсен алып.)* «Бәни бәшәр та хәзрәти Адәмнең холкатеннән бире сәгадәт арамактадырлар. Фәкать алмазы чүплекләрдән арамак кеби, сәгадәтләре дә фахеш юлларыннан, гаклән вә шәрган мәнһи шәйләрдән табмак эстәдекләреннән, бу вакыта кадәр сәгадәтнең ләфзыны көнһ белмешләрдер. Безем заманымыза кәләнчә, хәмделиллаһ, мәгариф сайәсендә һәр шәйне нәрәдән арамак лазем идекене белдек»* *(дип укыганда, сарырак кыяфәтле, озынча йөзле, урысчарак киенгән, бик кечкенә кара бүрекле егет килеп керә. Каюм каршы барып.)* У, сез икәнсез, Габделгазиз! Белмәдем, гаеп итмәңез.

Габделгазиз. Москвадан кайтканнан бирле күрешкәнемез дә юк шикелле.

Каюм. Әйе, әйе. *(Габделгазиз кулын суза да күрешәләр. Урын күрсәтеп.)* Утырыңыз.

Газиз *(дә утыра да, китапларга карап)*. У, синең китаплар ни эшләп яталар? Соң, иптәш, Петербургны яраттыңмы? Һәммә йирдә булдыңмы соң?

Каюм. Ничек һәммә йирдә буласың? Яраттым, чибәр шәһәр. Бердән, эти берлән идек, икенче, һәммә йирдә булу минем үземнең мәсләкем түгел. Музейда булдым, театрда булдым, көтепханәсендә булдым.

Газиз. Миңа әүлиялык сатасың инде! Нәрсәгә алай кылынасың? Үзең, иптәш, дуст булырга ярый торган кеше. Тартмаган, эчмәгән, алай-болай йөрмәгән булып әүлияланууыңны гына яратмыйм.

Каюм. Җук, алай түгел, һич әүлиялык сатмыйм, мәсләкем шул: эчмәү, тартмау һәм башка начарлыклар кылмау.

Газиз. Мин эшлим дә, сөйлим дә, сезнең төсле яшереп тормыйм.

Каюм. Газиз! Яшермим мин, ләкин кылганым юкны үземә-үзем яла ябар хәлем юк.

Газиз. Ул сүзне бүтәнгә сөйләрсез, мин андыйга һич ышанмыйм. Эчмә дә, тартма да, арлы-бирле йөрмә дә,

---

* Адәм балалары Адәм галәйһиссәлам яратылганнан бирле бәхет эзлиләр. Ләкин алмазны чүплекләрдән эзләгән төсле, бәхетләрне дә бозыклык юлларыннан — акыл буенча да, шәригать буенча да тыелган нәрсәләрдән табарга теләгәнгә күрә, бу вакытка кадәр «бәхет» дигәннең сүзен генә беләләр. Безнең заманыбызга җиткәндә, Аллаһе Тәгаләгә мактау, аң-белем аркасында нәрсәне нәрсәдән эзләргә тиеш икәнлекне белдек.

*Сарыф* — морфология.

*Нәху* — синтаксис.

*Мәсләк* — принцип.

ничек эч пошмаенча чыдап торырга кирәк. Заһидлар төсле өйдә утырып торырга кирәкмени?

Каюм. Соң, җә, ни эшләргә кирәк?

Газиз. Һәммәсен кылырга кирәк. Әле мин кайтып киләм бер җирдән... Ух, эшләдем дә... Әллә качаннан бирле дәртем төшеп йөри иде...

Каюм. Бернәрсә дә аңламадым, ачык сөйләсәңез лә!

Газиз *(көлеп)*. Ачыкмы?.. Баштан укмы?.. Безгә бер вакытны бер кеше фатирга асткы өйгә керде... Моның бер кызы бар... Мин беркөнне күрдем дә, монда бар икән дип, җай чыгарырга теләп йөрим... Кыз бер дә минемчә түгел... Бер әйттерәм, ике әйттерәм — җук, сүземне тыңламый... Бик ачуым килде... Ачу килсә, ни эшлисең?! (Гыйффәтле) түземле кызны бер эш эшләп булмый... Бервакытны хат яздым: эш шулай, шулай, әгәр сүземне кабул итмәсәң, эш башкача булыр, дидем. Кыз миңа җавап биргән, сөйсә, соратсын, барам, дигән. Мин шул сүзләрне ишеткәч, ә... белдем ни эшләргә, дидем дә, кызга хат яздым; мин сине сөям һәм соратам, ләкин элгәре үзеңне бер күреп сөйләшәсем килә, дидем. Кыз разый булган... Ник разый булмасын? Билгеле, миңа бару бер кәвешчегә баруга караганда артык була. Шулай итеп, без кыз берлән бер күрештек, теге кызга бер дә белмәгән төсле күрендем. Имеш, әүвәле уларак бу кыз берлә күрешәм. *(Көлеп.)* Ышанды! Ул белми минем Газизә берлә Фатыймага ниләр кылганны! Мин аңарга, безнең фатирдан чыгыңыз, югыйсә, мин сине соратсам, халык арасында әллә ниләр чыгар, дидем. Алар чыктылар. Шуннан мин икенче күрешергә чакырдым. Кыз чыккан. Бара торган җиремезгә бардык. Марҗага өчлекне күрсәттем дә чыгарга куштым, марҗа да чыкты. Без аулак калдык. *(Көлеп.)* Мин шуннан... Ахырдан мине җалындыра идең, хәзер менә син җалын инде, дип чыгып киттем, кыз шунда җылый-җылый калды. Миңа килеп бикә булып торасы!! Менә тор! Ул синең шикелләләрне генә өйрәткән инде.

Каюм. Мискинә кыз, ул нишләр инде?

Газиз. Җә, хатыннар төсле әллә ниләр кылынмасана. *(Көлеп.)* Эшләгәнме? *(Үзен күрсәтеп.)* Егетлек шундый була ул!

Каюм. Бу эшеңез өчен тәбрик кыла алмыйм... Гафу боерыңыз! Сезнең карашыңыздан үз файдаңыз хасыйл булган булса да... Гөнаһсыз кызны бөтен рәхәтеннән мәхрүм иткәнсез... Яхшы эш эшләмәгәнсез, дустым!

---

*Заһид* — дөнья мәшәкатеннән азат кеше; бу урында: монах.

Мискинәнең бөтен гомерен харап иткәнсез... Аның өчен җанының чыгуы (гыйффәте) түземенең югалуыннан артыграк булыр иде. Минемчә, шундый бер зур гөнаһ кылгансыз, дөньяда һич аның кебек кабахәтлек, начарлык булу ихтималы юк... Уйласаңыз ла! Мескинә хәзер ни эшләсен ул?.. Әй бөрадәр! Ничек вөҗданыңыз җитте шулкадәр золым кылырга?.. Мин шул эшне эшләсәм, эч пошуыннан (вөҗдан газабыннан) үләр идем. Моннан зур инсаниятсезлек...

Газиз *(ачуланып аягүрә торып)*. Мин синнән монда холык өйрәнергә килмәгән... Кылдым... Үзем кылдым, һәммәсен белеп кылдым. Тагы кылам... Инсаниятсезлек, имеш. Таптылар бер сүз!.. Әйләндерәләр дә шуны әйтәләр. Кызлар берлә йөрү дә инсаниятсезлек. Аларны ташлау да инсаниятсезлек. Анда-монда барып утыру да инсаниятсезлек...

Каюм. Ачуланмаңыз! Үзеңезне айап кына әйтәм; дөньяда кылган яхшылыклар һәм яманлыклар һичберсе үзләренә (муафикъ) тиеш җәза бирелмәенчә калмый. Бу эшләргә каршы озак онытылмый торган начар бүләкләр берлән бүләкләр, дип әйткәнем генә! Укыганыңыз бардыр романнар, милли хикәяләр, шулардан ничек бер дә гыйбрәт алмыйсыз?

Газиз. Мин ничек алардан гыйбрәт алыйм, әүвәл үк ничек хурланмаенча укыйм? Аларны кем яза дип беләсең? Мин аларны язучыларының атасын, бабасын, исемен, хәтта кая торганнарына кадәр беләм. Синең төсле авыз сулары агызып, мискинә ул кыз бик кызганыч, бер егет алдап ташлаган, фәлән егет бик аяныч булган, фәкыйрь дип сөйгәнен бирмәгәннәр, дип торыйммы? Аларны укып торганчы, мин утын ярсам, файдалы булыр.

Каюм. Утынчы буласың килсә, билгеле, утын яру файдалы. Минем әйтүем — инсан буласың килсә дигән сүз иде. Үзеңез карарсыз аннары.

Газиз *(торып, ачуланган тавыш берлә)*. Мыскыл иткән буласың, үзеңнең болай өйдә дүнегеп ятуың да саранлыктан гына! *(Чыгып китә башлый.)* Мин сине кеше дип йөри идем, түгел икәнсең. *(Чыгып китә.)*

Каюм *(ялгыз)*. Әйе, сез кеше булсаңыз, мин түгел шул... Мискин! Әхлаклы булса, нинди чибәр егет булыр иде. Ай әхлак! Әхлак! Бигрәк мөкатдәс нәрсәсең! Йа Рабби, шул холкымнан аерма! *(Торып, китапларын рәтли башлый, шул арада исенә төшеп.)* Мм... Минем Хөрширткә

---

*Бөрадәр* — туган.

язган хатым бар ич, мин аны бүген үк Шаһидәгә бирим, онытыла башлар. *(Звонок бирә, үзе әйберләр карап тора.)*

Шаһидә *(керә)*. Нәрсә, Каюм абый?

Каюм. Монда кил әле, Шаһидә! *(Акыртын гына.)* Иртәгә Хөршиткә хат бирерсеңме?

Шаһидә. Ярый.

Каюм. Мин бүген биреп куйыйм, онытыла башлар.

Шаһидә. Ярый, бир.

Каюм *(кесәсенә тыгыла да)*. Ачкыч кая минем? *(Икенче кесәләрен дә актара.)* Җук! Әллә монда калды микән? *(Өстәл өстенә барып карый.)* Әй Алла, калган, ачмаган булсалар ярар иде. *(Ачкычларны ала да ача.)* Ачканнар!! Шаһидә, хат җук монда! Уф Алла... Бөтен эшем чуалды... Әнидер...

Шаһидә. Гайни түгелме! Ул бик җөрде шунда, бикә берлән дә шыпыр-шыпыр сөйләделәр.

Каюм. Шаһидә! Җаным бул, бар әле, Гайнидән сора әле, нәрсә сораса да бирәм. *(Шаһидә чыга.)*

Каюм *(әйберләрне актарып)*. Балдак та җук, йитмеш биш тәнкәгә алган идем. Бәгыремә бөтен гомерлек бүләк булсын дигән идем — насыйп түгел икән! Уф, уф... Кем алды икән?.. Әнидер, әнидер, ни эшлим?! Әтигә ни әйтермен... Сөям диярмен... Ул, ул сүз аңлыймыни?... Ни эшлим, Раббем! Уф Алла!

Шаһидә *(килеп керә)*. Аңардадыр, ахрысы, әйтми дә, күпме акча бирә, ди.

Каюм. Ун тәнкә диң. *(Шаһидә чыга.)*

Каюм. Бирсә генә ярар иде... Харап булам... Ни дип алды?! Билгеле, бер-бер эш эшләргә... Уф, уф... Ни кылыйм, ни кылыйм?.. Ни кыла алам?.. Йа Рабби, үзең ярдәмче...

Шаһидә *(керә)*. Миндә, ди дә, үзе килсен, ди, Каюм абый!

Каюм. Акча бирә диденме?

Шаһидә. Әйттем.

Каюм. Ни ди соң?

Шаһидә. Мин акчасына бик исем китми, ди, үзе килмәенчә бирмим, ди.

Каюм *(кесәсеннән акча чыгарып)*. Менә шул акчаны бир! Бирсен, егерме биш тәнкә диң.

Шаһидә. Ярый.

Каюм *(ялгыз калып, идән буенда йөреп-йөреп сөйли)*. Ай бу Хөршит! Башымны ашады! Бу кадәр авырлыклар! Эч пошулар! Һәммәсе аңардан! Ник мин аның өчен шулкадәр мәшәкатьләр чигәм! Актыгы булсын! Хат та язмыйм, хат та алмыйм!.. Ул вакытта минем дөньяда нәрсә

рәхәтем булыр?! Бар җуанган нәрсәм дә бәгыремнең мәҗлесләре берлә хатлары ласа. Ни эшлим?! Ник эшне бу кадәргә җиткердем?! Ник мин ташламыйм!!! Ташлыйм! Ташлыйм!!! Миңа кызлар табылыр... Хөршиттән башка кызмы?.. Миңа... Миңа иптәш булырмыни? Булмас! Булмас! Сөям мин аны? Сөям! Сөям, бәгырем, сине!! Ташламыйм! Ни дип ул чикле сөям?.. Моңарда күз булса, башкаларда да бар, кашы кара икән, башка кызларда кара каш бар. Гали бай кызы моның кай төшеннән ким?! Булса, артык. Атасы-анасы бар, дәүләте бар. Җук! Җук! Әллә кайсы төшләре килми!!! Икенче бер Хөршит төсле бай кызы булса, менә алыр идем. Карчык берлән сихерләдеме бу мине?.. Җук! Гакылы берлә сихерләде! Гакылы берлән! Хөршиттә гаеп юк! Менә мин генә аның өчен шул мәшәкатьләрне күрәм!

Шаһидә килеп керә.

Шаһидә. Үзе килсен, башка кешегә бирмим, ди.
Каюм. Акчасы кая?
Шаһидә. Акчаны алды.
Каюм. Бирмәү кирәк иде. Әниләр ятканмы?
Шаһидә. Күптән яттылар.
Каюм. Алай булса, үзем чыгып сорыйм инде!

Шаһидә чыга башлый, Шаһидә берлән караңгы коридордан акыртын гына кухня ишеген ачалар.
Гайни, Шаһидә, Каюм.

Каюм *(акыртын гына)*. Гайни, минем әйберләремне бир! Ни дип алдың аларны, алар нәрсәгә сиңа?

Шаһидә чыгып китә.

Гайни. Аласым килде дә алдым.
Каюм. Шаһидә акча бирдеме?
Гайни. Бирде.
Каюм. Алай булса, минем әйберләремне бир!
Гайни. Ул хат кемгә, әйт элгәре, аннары бирәм.
Каюм. Бер дустыма язган хат.
Гайни. Дустыңа гына булса, ник ул чикле өтәләнәсең? Мин карадым инде аны.
Каюм. Ул сиңа һич кирәк түгел. Зинһар, бир дә, кешегә чыгарма! Кемгә булса да сиңа зарар да юк, файда да юк.
Гайни. Эшеңне сиздем, бирим инде, бикәгә күрсәтсәм, сиңа бик авырлык булыр.
Утны күтәреп, гостинный зал тугрысындагы бүлмәгә керә, Каюм ар-

тыннан керә. Гайни караватастыннан сандык чыгарып ача да, бер кучә кәгазь ала. Каюм карават янындарак тора. Шул вакытта коридорның икенче башыннан бауларын тишкән, күлмәгендә озын баулар салынып тора, яланбаш, яланаяк, ак сакаллы, ап-ак башлы Р ә х м ә т у л л а б а й берлә кичке ак күлмәктән, башына яулык кына ябып, Г а л и м ә б и к ә күренәләр һәм Гайни берлә Каюм өстенә килеп тә керәләр.

Каюм күрми тора.

Р ә х м ә т у л л а б а й. Ни эшлисең монда, оятсыз?! *(Каюм, калтырап, баш бармагын авызына каба. Гайни битен тотып идәнгә чүгәли.)* Шуңарга калдыңмыни? Оят сиңа, оят! Асраулар артыннан йөрергә! Ничек хурланмыйсың? Уйламадыңмы, бервакыт беленер дә оятлы булырмын дип! *(Башын селкеп.)* Әйе, әйе! Бу эшне кем кылганы бар иде?!! *(Битенә төкереп.)* Тфү, оятсыз! Үзеңне кызганмыйм, мине кеше алдында хур иттең!!!

Г а л и м ә *(Гайнигә карап)*. Сиңа оят кирәк иде. *(Сандыктагы кәгазьләрдән берсен алып Рәхмәтуллага бирә.)* Карасана, хатын. *(Рәхмәтулла, алып, Каюм язуын күргәч тә күтәреп бәрә.)* Әллә кайчаннан бирле мин синең бу эшеңне белә идем. Сине яклап атаңа әйтмәенчә тора идем. Син, шулай булса да, үги күрә дип йөрисең. Атасы, кара инде, никадәр хат. Ә монда бер балдак та бар. *(Гайнигә.)* Моны да ул биргән идеме?

Г а й н и. Әйе.

Р ә х м ә т у л л а *(тагы ачуланып)*. Ләгънәт суккан! Акчалар бетереп бүләкләр бирә, ояты гына җитмәгән! Ни эшлик инде? Алыйкмыни? Кеше күзенә ничек күренерсең?! Рәхмәтулла байның угылы асрауларын алган дигән сүзне мин ничек ишетим? Синең урысча укыганнарың арасында бернәрсә дә булмаса, безнең мөселманнар арасында бик зур оят ул! Дуңгыз төсле, нәрсә аска карап торасың? Ник әйтмисең?

К а ю м. Ни эшләп алыйм мин аны?! *(Калтыранып.)* Алмыйм!!!

Г а й н и *(җылаган тавыш берлә)*. Алмаска булгач, мине бу көнгә чикле ни эшләп алдап йөрттең? Бер ел алдап, мине харап итеп ташламакчы буласыңмыни?!!

Р ә х м ә т у л л а. Ай, бала, бала! Нәселемезне череттең. Һәммәсе шул урысчадан... Һәммәсе шуннан. Минем дә яшь вакытым булды! Әлхәмдүлиллаһ, гомеремдә бер асрау берлән тотылмадым! Бәрәкәтсез!!

Гайни җылый.

Г а л и м ә. Булган эш булган инде, хәерле булсын! Син

---

*Тишкән* — чишкән.

генә түгел инде, асрау кызларның һәммәсендә дә була диергә ярый. Барыбер, теләсәң риза бул, теләсәң җук, сине без Каюмга алмыйбыз. Инде харап итте, кая барыйм мин дисең икән — үзебезнең Шакирга бирик. *(Рәхмәтуллага карап.)* Атасы, әйберләр дә ясарбыз, үз балабыз кебек итәрбез. Бу эшне беркемгә дә чыгарма!

Рәхмәтулла. Шакирның жалуниясе хәзер яхшы, алмыйм дисә, мин аны хәзер чыгарам дим, ничек тә ул алыр. Алмый ни хәл бар аның?!! Баеның сүзенә карышыр идеме?!! Риза булсаң, тиз үк туй итәрбез.

Гайни. Бармыйм мин аңарга, бармыйм! Каюм булмаса, бөтен гомерем буенча кияүгә китмәсәм дә разый.

Рәхмәтулла *(ачуланып)*. Бармасаң менә, эзләп йөрерсең, куармын да чыгарырмын, әйтерсең лә бер сиңа гына булган эш, һәммә йортта асрауларда була ул. Сине без әле үзебез бирмәкче булабыз, башкалар төсле куып чыгарсак, ни эшләр идең?!! Барып керер идеңмени?!

Каюм *(сулап)*. Әти! Әти! *(Калтыранып.)* Минем, валлаһи, һич гаебем юк! Өстемә тел сөйли!

Галимә *(хатны алып)*. Бу кемнеке соң?

Каюм. Ул хат... Ул хат? Минеке тү... Минеке...

Рәхмәтулла *(аяк тибеп)*. Тагы, өстенә, алдап та тора инде, дуңгыз!!!

Каюм *(атасының кулыннан тотып, башын иеп)*. Әти!.. Гаебем җук!!!

Галимә. Соң ник җукны сөйлисең инде, Каюм? Үзем ничә күрдем инде, исмасам, тизрәк Гайнине ризаландырыңыз, диң!

Каюм. Әйтмим!!! Әйтмим!! Гайнине белмим!!! Эшем юк. Ул эшне мин кылган булсам? Аллаһем сакласын!!! Эчем пошып үләр идем. Сез усал дип белсәңез дә, гомердә андый инсаниятсезлек кылганым юк һәм кылмыйм!!!

Рәхмәтулла. Үзе никадәр тирес. Шулай да безнең сүзне ялганга чыгарырга тели? Исмасам, әти, яшь вакытта үзеңездә дә булгандыр, яшьлек-җүләрлек, күңелем азды шул, зинһар, кичереңез, диң!

Галимә *(Гайнигә)*. Разый буласыңмы? Җук исә, беләмсең, синең язмышларың кая? Безнең сүзне тыңламаенча кая бара аласың?! Гаеп үзеңдә.

Рәхмәтулла. Кыз, тизрәк уйла! Күп исәплисең, күп исәплисең.

Гайни *(җылаган тавыш берлә)*. Разый!

---

*Тирес* — кире.

Р ә х м ә т у л л а. Иртәгә үк менә мин Шакирга әйтермен. *(Каюмга.)* Икенче мондый эш кылма! Ахыры булсын!

К а ю м. Кылмадым, кылмыйм, кылмам!.. Болар... болар бар да үги...

Р ә х м ә т у л л а. Тагы сөйлисең, дуңгыз! Күрмисеңме, анаң синең өчен ни эшли! Шөкранәсез. *(Чыгып китә, Каюм да чыга.)*

Г а й н и, Г а л и м ә

Г а л и м ә. Күрдеңме, Гайни! Әйткән идем ич мин сиңа ул хезмәтләреңне буш калдырмам, сине ничек тә Шакирга бирдерермен дип. Синең җайланды хәзер. Минекен генә рәтлисе бар. Ничек булса да Каюмнан күңелен тагы биздерә төшеп, кибетләрне үз исемемә яздыра алсам, аннары минеке дә рәтләнер иде.

Г а й н и. Бикә, тизрәк шул эшләреңне кулыңа алып бетер дә, аннары бу картка гына дүнегергә кала! Әле дә яшь гомереңне бик күп әрәм иттең!

Г а л и м ә. Аның каравы Шаһимәрдән берлә рәхәт күрербез. Дәүләт бар.

Г а й н и. Каюмнан биздерер өчен тагы бер-бер эш кылмаенча ярамый әле, югыйсә, синең артыңа яздырмас.

Г а л и м ә. Әле дә инде кылдык, шундый үткен, тәүфыйклы, гакыллы егетне ничек күрсәттек! Әзрәк усаллык та кылдык та, инде ни эшлисең?

Г а й н и. Сиңа, аның малы калып, рәхәтләнеп гомер кылырлык та булмагач... Синең үз хакың ул! Яшьлегеңне бирдең, малын алдың.

Г а л и м ә. Иртәгә сөйләрбез, Гайни! Мин теге карт янына барыйм. *(Чыга. Гайни дә чыга.)*

К а ю м *(кабинетта креслода утырып, башын тотып тора, боларның сүзе беткәч)*. Ниләр күрә бу баш? Уф-ф-ф Алла!!! Бу хәсрәтләрнең!.. Бу дәртләрнең!.. Бу золымнарның! Бер-бер җәзасы булыр микән? Мине бу кадәр көчләүчеләргә, шулкадәр атам алдында пәрдәмне ертучыларга, үзләренең файдаларына минем намусым, гаразым берлән уйнаучыларга да бер-бер җәза булыр микән? Булыр! Булыр! Минем бу мәшәкатьләрем киләчәктәге рәхәт гомеремнең баскычларыдыр! Һәр мәшәкатьнең ахыры сәгадәттер, мин дә бервакыт, үги ана көчләүләреннән котылып, рәхәткә ирешермен. Уф-ф-ф! Үги ананың ях-

---

*Гараз* — хәл.

шысы тәмугъ утының чаткысы диләр, аның усалы ничек булсын соң?! *(Кулы берлән битен тотып.)* Минем дә рәхәтләнеп анам кочагында йөргән вакытларым бар иде, кая ул вакытлар?! Газиз анамның җаны мине бу кадәр көчләүләрен белеп никадәр кәефсезләнә икән?.. Анам! Җаным! Мине кемнәр кулында калдырдың?! Аһ, аналар! Ваһ, аналар! Нәдән залим үги аналар!.. Нәдән залим үги аналар??!!

Пәрдә төшә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Рәхмәтулла байның кунак бүлмәсе. Галимәбикә һәм Гайниҗамал. Гайни калфактан, бикәләнгәнрәк киемнән. Шакир берлә тора башлаган вакыты.

Галимә. Ул Шәйхи байларның киленнәре аерылуны бик кызык сөйлиләр икән. Әле кичә мәҗлестә Сәхилә остазбикә сөйләде. Ул шактый укымышлы кыз, ди, яшь вакытында миннән укыды, ди, укыла торган китапларны һәммәсен укыды инде, ди. «Бәдәвам»нан башлап «Хәмде бихәдд»кә кадәр сабакка йөреде, ди. Ул вакытта йомшаграк иде, ди. Шул, кияүгә киткәч тә бер дә рәтләп ир тәрбияли дә белми икән, йорт-җир карый да белми икән, ди. Иренең чыгуында, кайтуында эш юк, ди. Утырса — утырганча тора, бер дә аңарга исе китми икән, ди. Элгәре, әнә Камал тора бит, дип тора икән дә, Гали бай икенчегә әле Әхмәт табакчының хатынын алгач, ике хатын берлә тору кызык дигән дә икенчегә өйләнергә уйлаган. Үзе алырга теләгән җирдән хатын өстенә бирмәгәч, шуның өчен Камал аера башлаган. Ул аны уйламый да икән, ди, менә Әсма акырып-бакырып җыгларга тотынган. Күрәсең, үзе сөя. Камал, аңарга карамый, аерган. Өеннән чыкмаенча, җылап җөдәтеп бетергән, ди.

Гайни. Ирләрне кулга алыр өчен хатын-кызга тугрылык кына да җитми, куштанлык та кирәк.

Галимә. Кирәк кенәме соң! Безнең хатыннарның ирләренә яхшы күрсәтә торган, бөтен гаепләрен югалта торган беренче буяулары инде. Ирләрне кулга төшерергә бик зур хәйлә ул. Беләмсең, мине хәзер карт ничек дип белә, дөньядагы беренче тугры хатын, йорт хуҗасы, бөтен шул йортның артуына тырышучы дип белә. Менә мин аны куштанлык берлә ниләргә йиткердем. Куштанлыгымнан инде бер генә өметем калды, кибетләрне үз исе-

мемә яздыра алсам, аннары хатыннарда куштанлык иң беренче сыйфат икәнен белерсең. Әле Шакир теге эшне картка сөйлиме?

Г а й н и. Әле кичә генә сөйләде, ни чыкса, шунда Каюмның эшкә ярамавын, юкка акча бетерүен чыгарам, ди.

Г а л и м ә. Чын да хәзер бик күңеле кайткан. Алай да шул, бөтенләй ничек биздерәсең, безгә Каюм булса да, аңарга бала шул. Бара-тора ничек тә бизеп бетәр инде.

Г а й н и. Күңелен биздерер өчен тагы бер-бер нәрсә уйламыйкмы?

Г а л и м ә. Ни уйлыйк соң?

Г а й н и. Болай итик, кибетләр арасында эштә гел Каюм, ди. Хәзер Рәхмәтулла абзыйны рәтләп белмиләр дә, ди. Каюм менә шулай итә-итә бөтен эшне әтисе үлгәнче үз кулына алып бетерергә тели икән дә, сиңа бернәрсә дә бирмәскә тели икән дип, картка җылаган булып сөйлә. Шулкадәр дәүләткә бирәр күз яше әллә ни булмас.

Г а л и м ә. Бер түгел, ун мәртәбә дә җылармын... Рәхмәт сиңа, Гайни! Таптың, буш итмәм мин сезне.

Г а й н и. Улсында эш юк. Сездә булса, без ач булмабыз әле, булуын булсын әле.

Г а л и м ә. Исмасам, Гайни, бер ир балам да тормады. Болай мәшәкатьләнеп йөрергә булмас иде. Каюмга тигән аңарга да тияр иде. Әле бу көенчә бигрәк аз шул.

Г а й н и. Болай булдырсак, бигрәк яхшы. Акчасы да күбрәк кала, башың да тыныч. Ул вакытта бик уңайсыз булыр иде. Шаһимәрдән аны көнләр иде. Бу көенчә булса, рәхәтләнешеп торырсыз.

Г а л и м ә. Улсы дөрест шул. Алай булса, мин картка шуны җылап-җылап сөйлим әле, син дә Шакирга әйт, ул шулай әйтә дисен.

Г а й н и. Шакирдан калмый инде ул, әле дә әллә ниләр сөйләп бетерә.

Икенче яктан «Галимә кая?» дигән тавыш ишетелә.

Г а л и м ә. Кайтты. *(Торып каршы китә башлый.)*

Г а й н и. Мин чыгып торыйм әле.

Шул арада чалмадан, бертөрле генә чапаннан, үз кыяфәтендә Р ә х м ә т у л л а б а й килеп керә.

Г а л и м ә *(көлебрәк кенә)*. Кайттыңызмыни? *(Рәхмәтулла чалмасын сала. Галимә алып илтеп өстәлгә куя да.)* Чәй хәзерликме?

Рәхмәтулла. Хәзерләгез, эчәрбез!
Галимә. Мин әйтеп керим әле.

Рәхмәтулла кәнәфигә утыра. Галимә чыга.

Рәхмәтулла. Исмасам, өемә кайтып керсәм, рәхәтләнеп китәм. Хатынның йорт җанлы, мәхәббәтле булуы да бик кызык эш соң! Угылым да шулай булган булса иде, тагы башкача булыр иде дә, ни эшлисең, без теләгәнчә түгел шул. Яшь вакытында, үз анасы чагында, бик җүнле булыр төсле күренә иде. Зурая башлагач, бөтенләй башкарды! Күңелгә үк җат күренә башлады.

Галимә *(килеп керә дә, карт янына кәнәфигә утыра-утыра, сөйли)*. Кибетләр ни эшли, карт?

Рәхмәтулла. Үзенчә алар шулай баралар. Менә әле мәсҗедтә исемә төште, бер генә баламыз тормады, дим. Исмасам, Гарәфи генә булса да, үз урыныма дәүләт башы итеп калдырыр идем, дим.

Галимә. Аны уйлый-уйлый инде мин җөдәп чыккан. Балаларыбыз да нинди матурлар иде. Үкенечкә каршы туганнар шул. Минем бәхетсезлегемнән үлгәннәр. Әле Каюм, «мин әти үлгәнчә бөтен эшне үз исемемә аударып бетерәм дә, аннары куып чыгарам» дип әйтә, ди. *(Карылган тавыш берлә.)* Мин ун ел гомер иткән, үземнең ни чикле хезмәтем кергән картымның өеннән чыгып китәрменмени? Мин Алладан сезгә хәерле, озын гомер бирсен дә, исәнлек берлә яшик тә, минем дә җеназам шуннан күтәрелсен дип сорый идем, күрәсең, догам кабул булмады. *(Җылап.)* Миңа, Алла сакласын, андыймондый үлеп-нитеп китсәң, синнән аерылу хәсрәте генә булмый, күрәсең. Синең рухыңа Коръән укып, дога кылып торырмын, минем күңел җуатуым шул булыр, дип уйлый идем... Адәм уйлый, тәкъдир көлә, диләр, дөрест, күрәсең. Миңа *(җылый-җылый)* эниләр: «Шунда рәхәт күр! Шунда гомер ит! Шуннан җеназаң чыксын!» — дигән йортымнан чыгып китеп, калган гомеремне фәкыйрьлектә үткәрәм, күрәсең. Алладан азрак өмете булса, ул алай сөйләмәс иде. Мин аны тәрбия кылып үстердем, искесен алдым, яңасын кигездем, үз анасы кылмаган яхшылыкларны кылдым. Әле аның тәмсез телен, начар уен кара... Мине соң куып чыгармаса, бу өйдә үзенә урын табалмасмыни? Бу дәүләт әле аңарга да, миңа да җитмәсмени?

Рәхмәтулла. Ни эшлисең, догасыз булгач, яхшы бала булмады инде. Хәзрәтләр китереп, бүлеп калдырырбыз, ул вакытта үз дәүләтең берлә кая торсаң да торырсың.

Г а л и м ә. Кирәкмәс, кирәкмәс! Мин, бай хатыннары төсле, ирем үлде дип, штурмалар кубарып, бүленеп йөрер хәлем юк. Шул өемдә гыйбадәтемне кылып рәхәтләнеп тора алмагач, кирәге юк, миңа дәүләт кирәк түгел. Мал кирәк түгел. Ашарыма, эчәремә булса, өстемә шулай бер кат булса, шул җитә. Ул вакытта ирең булмагач, ниндине кисәң дә ярый. Бөтен дәүләт миңа калса да, миңа шуннан арысы кирәк түгел. Ул мине кызганмаса да, мин аны кызганам. Һәммәсен аңарга бирер идем.

Р ә х м ә т у л л а. Күптән шуңарга эчем пошып йөри идем. Сиңа әйтергә әле базмый идем. Беләм инде, ул баланың сиңа ничек кылынасын, ни эшләргә кирәк соң?

Г а л и м ә. Менә мине баш иттереп куеп булмыймыни? Аны куркытыр өчен. Ул барыбер шулай бай баласы булып торыр. Мин ул вакытта рәхәтләнеп гыйбадәт кылып үткәрер идем. Ул, миннән куркып, сүз әйтә алмас иде. Мин, билгеле, дәүләтеңезне, йортыңызны таратырга риза түгел инде. Шулай итсәк, икемезгә дә яхшы булыр иде!

Р ә х м ә т у л л а *(башын кашып)*. Ни әйтергә дә белмим. Алай итсәк тә кеше сүзеннән яхшы түгел. Аннары кыз да табып булмас!

Г а л и м ә. Ник булмасын? Дәүләт барыбер синеке була! Үзең исәндә ничек, ул вакытта да шулай була. Ник, Каюм дәүләтне бетермәсен дигән сүзем генә. Бу патша сарае төсле йортлар, башкаларныкы кебек, башлары бетү берлән вәйранга чыксалар, сезгә гүреңездә дә шул балаңыз өчен хәсрәтләнеп ятарга булмасын дим генә. Югыйсә, миңа син үзең булмасаң, дәүләт күземә күренми. *(Җылаган тавыш берлә.)* Аллаһе Тәгалә газиз гомерләремезне бирсен дә, дәүләтемезнең рәхәтен күрергә насыйп итсен! Тигезлек булмаса, рәхәт тә юк. Тынычлык та юк инде ул...

Р ә х м ә т у л л а. Шулай ук, Хәйрулла байлар, Ихсам байлар, Тәтеш Шәрәфиләр, Хаҗи Камалиләр төсле, минем дә тешем-тырнагым берлән җыйган малларым әрәм булыр микәнни? Үзе болай эчми дә төсле ләсак! Шулай ук чын көчем берлән җыйган малымны, шулкадәр зур мәшәкатьләр берлә тапкан дәүләтемне, әллә кемнәрдән туздыртыр микәнни?

Г а л и м ә. Әй карт! Аның мутлыгын белмисең икән!.. Аның сиңа эчмәгән булып күренүләре һәммәсе мутлыгыннан. Син генә арлы-бирле бул, Алла сакласын, елга җиткермәс. Аның эшләрен сөйләргә генә ярамый инде!..

---

*Штурма (штурм)* — бу урында: җәнҗал.

Анда бар эшләр!.. Мин дә аны бер-ике елга чикле белмәдем. Әле кибет арасында бөтен кешене кулына алып бетерә ди инде.

Рәхмәтулла *(башын селкеп)*. Болай калдырсам, сиңа авыр. Тегеләй итсәм, аны бөтенләй фәкыйрьлектә калдыру була. Әллә урталай яздырыйммы?

Галимә. Бик кызык сөйлисең. Әйтәм ләсә, миңа дәүләт кирәк түгел. Синең дәүләтеңнең генә таралуын, йортларыңның туздырылуын күзем берлән ничек күререм дип, шул дәүләтеңне, исмасам, үзеңнең балаң булмаса инде, балаң баласы хуҗа булмасмы дигән сүзем генә. Син, әйтерсең лә, мин үзем өчен сөйлим. Сиңа ун ел бергә торган хатынның сүзләре бу көнгәчә дөрест. Бүген генә ялганлый. Гаҗәп!! Әгәр шөбһәләнсәң, күңелемдә тузан бөртеге кадәре гаеп юклыгына нинди ант берлә ант иттерсәң — итәм!

Рәхмәтулла. Бу көнгә кадәр антсыз да ышанычкан идек ич. Бу юлы да ышанам. Синең тугрылыгыңны әллә ничә сынап белдем инде. Үз алдында кешене мактарга да ярамый да, бозыла башлый диләр дә, мин сиңа һәммәсенә ышанган инде. Ләкин дәүләтне бик мәшәкать берлә җыйдым. Ничек тә әрәм иттермәскә тырыш. Хәләленнән, хәрәменнән мин хисабын бирсәм, ул әрәм итеп бетерсә, бигрәк авыр булыр. Алай булса, мин бүген яздырам. Эмм... Әле миңа үзебезнең малай, Каюм абзый бирде дип, хат биргән иде, мә әле, укы әле! *(Әкертен генә күкрәк кесәсеннән бер кучә кәгазьләр чыгара.)* Ә, менә монысы икән *(Галимә пакетны ертып укырга башлый.)* «Газиз атам! Әдәпсезлек булса да, мин сезгә бу хатны, дөрестен әйтсәм, бу үтенечне яздым. Гаеп итмәңез! Шул көннәрдә олы байлардан җаучы килеп йөрүен һәм миңа аларның кызларын алырга теләвеңезне белдем. Бу эш (мәсьәлә) тугрысында минем дә сөйләргә хакым булганга, сезгә үземнең бу мәсьәләдә фикерем ни икәнне бәян кылмакчы булдым. Сөекле атам! Әгәр мине өйләндерү фикереңез булса, Габдулла талчукчы кызын алып бирсәңез лә! Әгәр мөмкин түгел икән, ул вакытта мин ул бай кызын алмыйм! Моның өчен мине орышма, атам! Чөнки мәхәббәт ихтыярлы нәрсә түгел. Минем дә дөньяда рәхәт торуымны эстәсәңез, минем сораганымны кабул итеңез! Вәссәлам.

Угылың Габделкаюм».

Ни яза! Оялмый бит! Без атабыз-анабызга шул тугрыдан сүз әйтү түгел, сөйли башласалар, кызарып чыгып китә идек.

Галимә. Бигрәк, аның эше түгел инде! Мин фәлән кызны алам дип, кыз алу аның эшемени ул? Ата-ана эше

ич ул. Яратсалар — алалар. Яратмасалар — җук. *(Каюм керә.)*

Каюм. Минһаҗ абзый килгән. Минзәләгә китәргә әйберләр хәзерләнде, ди. Сөйләшергә сүзләр бар, ди.

Рәхмәтулла. Ярар, керер. Син ни дип, уйламаенча, ул хатны яздың? Әй әдәпсез! Инде талчукчы кызын алмакчы булдыңмы? Элгәре асрау ала иде. Әй оятсыз! Бар, керсен. *(Каюм чыга.)*

Галимә. Мин чыгыйм алай булса, карт.

Галимә чыга. Минһаҗ, Каюм керә.

Минһаҗ *(кулына дәфтәр тоткан)*. Әссәламе галәйкем!

Рәхмәтулла. Вәгаләйкем әссәлам! *(Каюмга карап.)* Анда саилчеләр бардыр. Менә шуларны өләш. *(Бер калай савытка салган яртышар тинлек акчалар өстәл тартмасыннан алып бирә.)* Анда бар Садыйк, аңарга икене бир!

Каюм. Ярый.

Рәхмәтулла. Тагы анда сары сакаллы Әхмәди бар. Аңар да икене! Ишетәмсең? Ул безнең әзрәк карендәш тә, онытма! Анда бер аксак хәерче бар, аңарга бирмә! Ул беркөн миңа сәлам бирмәде.

Каюм. Ярый. И шәфкать! Ике ярты тин, карендәш, имеш! Бик зур файда итәсең.

Рәхмәтулла. Нәрсә дисең?

Каюм. Теге аксакка бирмәскә, дим.

Рәхмәтулла. Бирмәскә, бирмәскә. *(Каюм чыгып китә.)* Кая күпме товар җибәрелгән? Язганмы бар да?

Минһаҗ *(дәфтәрен ачып)*. Язган.

Рәхмәтулла. Кая монда?

Минһаҗ. Менә, биш кип Морозовлар товары. Өч кип Әҗемнәр бәзе.

Рәхмәтулла. Тфү! Тфү! Эшеңез бетмәгән, китәргә йөрисез! Ни дип цифр берлән язмадың?! Әйдә, ал дәфтәреңне! Әйдә магазинга! Һәрвакыт әйтәм мин сезгә! Миңа цифр берлә языңыз, мин танымыйм дип! Сез үзеңезчә чуалтасыз.

Каюм керә. Рәхмәтулла, Минһаҗ чыга.

Каюм. Бу хатым актык өметемне дә кисте. Уф Алла, ни эшлим? Хәзер ни миңа рәхәт гомер юк, ни Хөршиткә. Харап булды башым! Бу сөешү кадәр зарарлы нәрсә дөньяда бар микән?!! Ни эшлим! Хөршитнең дә сәгадәтен җуйдым! Үземә никадәр хәсрәтләр алдым.

Асрау *(керә)*. Каюм абый, сиңа хат бар!

---

*Кип* — бәйләм, төргәк.

К а ю м. Кемнән? Хөршиттәнме?

А с р а у. Мине бикә калфакчыларга җибәргән иде. Алар Салих байларда торалар икән. Аларның түбән өйләрендә бүрекче кем, шуларда безнең авылның Әсма асрау булып тора. Аның берлән сөйләшеп утырдык.

К а ю м. Шул әйттеме?

А с р а у. Әйе, ул әйтте, Салих старшина булды, ди. Балалары бик күп иде, атасыз калганнар, ди.

К а ю м. Менә җавап!

А с р а у. Угылы былтыр гына солдатка киткән. Ил ашаганда рәт буламы соң, ди.

К а ю м. Инде фәлсәфәдән китте. Шул бирдеме хат?

А с р а у. Ул түгел.

К а ю м. Ул булмагач, монда миңа нәрсәгә сезнең авылның Әсма! Нәрсәгә сезнең старшинаңыз! Рәтләп кенә сөйлә дә, вәссәлам. Кая хатың? Аның эченә кемнән икәнлеге язылгандыр.

А с р а у. Алла, кызлар хатына кемнән икәнлеген әйтәләрме?

К а ю м. Мин аны кайдан белим кемнән икәнлеген?

А с р а у. Мин әйтәм.

К а ю м. Җә әйт!

А с р а у. Шуннан соң...

К а ю м. Тагы әллә нәрсәләр сөйли инде.

А с р а у. Мин алай синең төсле китапча сөйли белмим шул. Алай булса, сөйләмим. *(Чыга башлый.)*

К а ю м. Тукта, сөйлә инде.

А с р а у. Шуннан соң...

К а ю м. Тагы бер «соң» төште.

А с р а у. Салих байларның асраулары төште дә миңа шул хатны бирде. Рәфига туташ сәлам әйтте. Аннары, шул хатны бир, дип әйтте. Мә, менә хат.

К а ю м *(хатны җырта-җырта)*. Менә хәзер аңланды. *(Укый башлый.)* «Әлхатты нисфелмөлякат, сагынып яздым син җанкаема сәлам хат! И җанымның җаны, ике күземнең нуры, сине бер күрергә зар вә интизар булып бер кош теледәй намә яздым. Кабул итеп аласың. Җаным, бәгырем, сиңа сүзем шулдыр, сине күрмәенчә һич тора алмыйм. Зинһар һәм зинһар, мине кызган. Көнемдә сине уйлыйм, төнемдә сине уйлыйм. Ятсам — күз алдымда, торсам — күз алдымда. И җанымның җаны, бәгыремнең каны, күктә — йолдызым, йирдә — кондызым, зинһар вә һәм зинһар, мине мәхрүм кылма, төнлә төшемдә сине күрәм, уянып киткәч, син булмыйсың, еглап җи-

---

*Намә* — язылган нәрсә, хат.

бәрәм, бәгъремм, бу хатны бер кешегә белгертмә. Егетләр күңелендә җөгәнле ат ята, диләр. И җаным, миңа кыска гына хат язсаң, күкрәгемдә генә саклар идем. И бәгырем, хат язган дип ачуланма. Синең һәркөнне базарга чыгуыңны көтеп кенә торам. Сине күрү күңелемә бер рәхәт бирә. Гыйшык тоту гаеп түгел, пәйгамбәрләрдин калган сөннәт. Хуш җаным, хуш!

Мәгълүмең.

Алтын да өстәл өстләрендә
Ал яулыгым калды, ал, җаный!
Мине дә ташлап ятны сөйсәң,
Оҗмахлардин мәхрүм кал, җаный.
Бакчаларда гөлләр бетәрме?
Арасындин былбыл үтәрме?
Үзеңне күреп сөйләшмәгәч,
Хатка язып сүзләр бетәрме?
Хуш, җаным, хуш».

Каюм. Бу миңа хат язган. Ни дип язган? Кызларда гакыл җук диләр иде, дөрест икән. Әле берсеннән котыла алмыйм, икенчесе берлән бәйләнергә.

Асрау. Бу бит бай кызы. Моны алырга да ярый. Теге ул бай кеше кызы түгел. Аны ни чикле сөйсәң дә, алып бирмиләр.

Каюм. Улсы дөрест. Ләкин миннән шул эш калмасын иде.

Асрау. Синнән түгел ич инде, бикәләрдән.

Каюм. Хөршит кызганыч шул. Хөршит! Аның күз яшен түктереп, мин нинди (сәгадәт) рәхәткә ирешермен икән? *(Уйлап торып.)* Эш миннән калмый инде, әтиәнидән ич ул. Алар рөхсәт бирмәсәләр, разый, дигән иде ич, ризалык түгел инде дә — ни эшлисең, барыбер алып булмый. Бу Салих бай кызының хатын ни эшләтим инде? Кара әле, Мәрзия! Исеме ничек әле ул кызның?

Асрау. Рәбига.

Каюм. Нинди Рәбига? Рәфига дигән идең ич.

Асрау. Икесе дә бер төсле ич.

Каюм. Ул кыз матурмы соң?

Асрау. Матур бик. Башында энҗеле калфак. Өстендә асыл киемнәр.

Каюм. Син үзең күрдеңме?

Асрау. Күрдем. Ул бакчада иде.

Каюм. Сез дә бакчада сөйләштеңезмени?

Асрау. Бакчалары кая икәнлеген мин белмим.

Каюм. Алай булгач, ничек күрдең?

Асрау. Күрдем инде ничек булса да. Син, бер эш булса, җөдәтергә тотынасың.

---

*Сөннәт* — бу урында: гадәт.

К а ю м. Әһә, Салих бай кызын миңа болай сорасак та бирәләр ич, ник мин аның берлә җөрмәкче булам? Дөрестен әйтсәк, ул җөрмәкче була инде. Күреп алырга тели идем ич. Күреп алуның бертөрлесе булыр инде, бер күрермен, яратсам — алырмын, яратмасам — җук. Улсы ничек булса да, хәзер мин Хөршиткә хат язарга кирәк, өметләнеп тормасын. *(Яза. Язып бетереп.)* Менә шуны Хөршиткә бир. Ә теге кызга иртәгә язып бирермен.

Г а л и м ә *(керә дә асраугa)*. Ни эшләп йөрисең син монда? Бар чык! *(Каюмга карап.)* Икенчесенияләштерә башладыңмыни?

К а ю м. Җитәр инде, мыскыл итүеңез! Тегесен дә мине шулай сезнең эшеңезне белми калды дип уйлый торгансыз?!! Һәммәсен белдем. Шакирга Гайнине бирергә хәйлә икәнен дә белдем. Әтине миннән суытыр өчен эшләгәнеңезне дә белдем. Тагы ни эшләргә теләгәнеңезне дә беләм. Ләкин берсенә дә каршы килмим. Кыла алсаңыз — кылыңыз. Сезнең гаебеңезне дә беләм. Әтигә дә әйтмим. Кешегә дә әйтмим. Сез мине шулай төрлечә кылындырып, әтинең дәүләтенә баш булып калмакчы буласыз?!! Дөньяда сезнең шикелле золым берлән сәгадәт эзләгән кешеләр бу вакытка кадәр (сәгадәткә) рәхәткә ирешә алмаганнар иде, белмим, сез генә ирешә алырсыз микән?!! *(Телефонда кеше бар. Каюм бара.)*

Т е л е ф о н. Баязитов?

К а ю м. Баязитов.

Т е л е ф о н. Каюм! Тиз бул, кибеткә кил! Рәхмәтулла абзый тик торганда һушсыз булып егылды. Ат дуктырга китте. Тизрәк бул! Апоплексически удар!

Каюм чыгып китә.

Г а л и м ә. Уф Алла, актык өметем дә бетте!! *(Җыгыла.)*

Пәрдә төшә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рәхмәтулла байның залы күренә. Әүвәл М ә һ р и карчык. Аннан ары К а ю м. Аннан — а с р а у.

М ә һ р и *(ялгыз гына)*. Арыслан күк кеше үлеп китте, дөньяның да вафасы юк соң. Дәүләт тә ярдәм итми, тәкъдир ни язды, шул була шул. Кеше әйтеп кеше ышанмас ич! Бу сәгатьтә исән, икенче сәгатьтә үлгән. Галимәне дә әйтәм!

Каюм *(килеп керә, җәйге киемнән)*. Уф, эссе!

Мәһри. Каян кайттың?

Каюм. Зиярәткә барган идем. Абыстай мине усал күрсәтсә дә, мин ата-ана хакын беләм. Әтигә дә зиярәт кылдым, әнигә дә зиярәт кылдым. Җомга көн ич.

Мәһри. Рәхмәт! Шулай кирәк шул, әле шуны әйтәм, Галимәне әйтәм, кырыгына чикле дә тормады.

Каюм. Торасы килмәде шул. Ни чикле әйттем. Абыстай, малыңны бүлеп ал, аннан соң да миндә тор, дидем. Бер дә булмагач, кешедән яхшы түгел, исмасам, гыйддәтең тулсын, дидем, ахырдан, кырыгына чикле тор, дидем. Өчен дә көтмәде, җыенды да китте.

Мәһри. Хәерле булсын инде! Синнән эш калмаган. Үзең тынычлап торырсың. Ул инде сөйләргә генә ярамый, барыбыз да белдек, торасы килеп тормады. Ул малга кызыгып торган иде. Эше тугрылыктан булмагандыр шул, сөйләргә генә ярамый, бик күп эшләр эшләде инде, әтиең мәрхүм бер дә шикләнмәде, бик оста иде шул.

Каюм. Әллә нинди кешеләр берлән катышы да булды, диләр, анысы дөрест микән?

Мәһри. Дөрест инде, дөрест! Һәммәсен эшләде, һәммәсен кылды. Алар һәммәсе булган да беткән, үз эшләренә үзе җавап бирер. Менә инде сиңа өйләнергә кирәк. *(Мыегына төртеп күрсәтеп.)* Яшь җитә инде.

Каюм. Кирәк инде, вакыт шул, кешем дә бер дә юк, әле рәхмәт, син карап торасың. Өйләнергә дә — каян өйләнергә?! Кемне алырга?!

Мәһри. Кемне алырга теләсәң, хәзер сиңа шуны бирәләр, Камали кызы бар, Исмәгыйль кызы бар, Икмән Шакир, Гайшә бикә кызы! Әле беркөнне Гайшә бикә берлән ашта туры килдек, ул сине сораша, Галимәне сораша, миңа барып утыр, ди, ахры, исәбе бардыр. Кызын мактыйлар. Чибәр, ди.

Каюм. Анысы кыз күп булыр, ничек белергә кирәк нинди икәнлеген! Мин, шул, күрмәенчә, белмәенчә алмаска телим.

Мәһри. Аңлыйм, аңлыйм, урыслар шулай итәләрмени?! Алай булса, мирза кызы алырга кирәк.

Каюм. Минем күреп алырга теләвем урысларга ияреп түгел. Минемчә, бүтәнчә алырга ярамый, гомерлек бит, ахрысы, бер-береңне белешергә кирәк, күрмәенчә, белмәенчә алганда, ярый ла тугры килсә, тугры килмәсә, икеңә дә бик авыр шул, мин хатын-кыз берлән чуалып йөрүне яратмыйм.

Шаһидә килеп керә дә кулындагы хатны күрсәтә.

К а ю м. Мәһри әби! Син миңа кофе керт әле?! Эчәсем бик килде.

М ә һ р и. Ярар, ярар. *(Чыгып китә.)*

А с р а у. Теге син җибәргән йомышка барган идем, үземнең дә йомышым бар иде. Мәһри әби дә өйләренә кереп, хәлләрен белеп чык дигән иде, исән торалар икән, Харисның угылы гына ва, ва, ва, мин сабакка бармыйм, дип еглап утыра иде. *(Кулына хатын тоткан.)*

К а ю м. Миңа шуны сөйләргә кердеңмени? Минем ни эшем бар синең йомышыңда, әбиең йомышында? Харис егласа ни, угылы егласа ни, бу хатың кемнән? Менә шуны әйт!

Ш а һ и д ә. Шуны әйтәм ич, син үзең сөйләп бетерергә ирек бирмисең.

К а ю м. Сөйлә, сөйлә.

Ш а һ и д ә. Шуннан соң Исхакның еглаганын уйлап көлә-көлә киләм! Исхак исемле икән угылы.

К а ю м. Тагы тотынды.

Ш а һ и д ә. Бүтәнчә белмим, шуннан соң урамнан бер кеше үтеп бара.

К а ю м *(читкә карап)*. Бетмәс инде, бөтен урам тарихын сөйләп бетерә.

А с р а у. Миңа каршы килә, яхшы гына киенгән, карап киләм, һаман каршы килә, казанлылар турысына килеп җиткән идем, үтеп китте.

К а ю м *(гаҗәпсенеп)*. Үтеп китте!

Ш а һ и д ә. Үтеп китте.

К а ю м *(күрсәтеп)*. Бу хатны каян алдың? Кем бирде? Шуны сөйлә, анда урамда кеше күп булыр. *(Хатны ача башлый.)*

Ш а һ и д ә. Хөршит апаның әтисе чыгып бара.

К а ю м. Кая чыгып бара?

Ш а һ и д ә. Мин каян белим. Мин сорамадым.

К а ю м. Белмәсәң, ник сөйлисең соң?

Ш а һ и д ә. Валлаһи, белмим. Шуннан соң, Хөршит апа...

К а ю м. Хөршит бирдеме?

Ш а һ и д ә. Әйе.

К а ю м. Менә шулай диң. *(Хатны тотып ачып.)* Ни диде? Сәлам әйттеме?

Ш а һ и д ә. Әйтте! Әйтмиме соң, ялганчы, диде.

К а ю м. Ярар, ярар, белдем. Бар, чыгып тор, үзем чакырырмын.

Ш а һ и д ә. Ул миңа каршы хат китерергә кушты, хат бир!

К а ю м. Нинди хат бирим әле мин сиңа, укымаган да,

бар чык, чакырырмын! *(Шаһидә чыгып китә. Каюм йөткергәләп укый башлый.)* «Габделкаюм! Әтиең үлгән көнне, мин сине ала алмыйм, гаеп итмә, әтиләр рөхсәт бирмиләр, дип язган идең. Бу хатыңны укыгач та дөрест дип белеп еглаган идем, кайгырган идем дә, язмышым шулайдыр дип калган идем. Иртәгесен үк әтиең үлүен ишеткәч, бу хат күптән язылгандыр, шул арада икенче хат булыр дип көттем. Бу көнгә кадәр көттем, бер хәбәр ала алмадым. Шуннан соң синең бу хатыңның ялган икәнлеген белеп, үзем хат яздым. Гаеп итмә, мин синең шикелле ялганлап язмадым. Үз күңелемнән яздым. Мин сине болай дип белми идем, Каюм! Синең ул сүзләрең һәммәсе ялган, күрәсең...» Ә, монда әйтмәенчә калдырган, бик каты сүздер. «Синең үзеңнең миңа сөйләгән сүзләрең берлән кылган эшләреңне чагыштырып кара! Вөҗданың булса, үзең дә белерсең. Шунысын да әйтим, мине болай итеп калдыруның җәзасын күрми калмассың! Җавап бирүеңне үтенәм. Актык хатың дип... саклар идем». Кара, бу төшенә яшьләр тамган! «...тотар идем. Хуш, Каюм! Хуш! Мине дә онытма. Хөршит». *(Каюм хатны кысып тотып идән буенда йөри башлый.)* Юк, юк, моны болай калдырырга ярамый... Мин шуны эшләмимме? Минме? Каюммы? Шундый эшләрне эшләгән кешеләргә үгет бирә торган кеше үземне үзем тыя алмыйммы?! Оят! Миңа оят! Кабахәтлек! Кабахәтлек! Бер фәрештә төсле кызның күңелен аздыртып, ташла! Тагы минем вәгъдәм бар. Булмас! Булмас! Аңлауларыңның файдасы, исмасам, шунда булсын! Мин үземне үзем тыя алмасам, башка кешеләрне ни дип гаепләргә кирәк? Вөҗдансыз! Ни дип мин бу көнгә чикле уйламадым. Хөршит!!. Хөршит мине ялганчы дигән! Ялганчы шул! Ялганчы! *(Йөреп, йөреп.)* Оятсыз ялганчы! Оятсыз ялганчы! Кабахәт мин! Кабахәт мин! Уф-ф-ф *(Туктап торып.)* И Раббем, үзең җай бир. *(Еглаган тавыш берлән.)* Мин соң Хөршитне күрер өчен ниләр кылып йөри идем! Нинди мөкатдәс уйларым бар иде. Кая китте алар? Кая китте? Бакчаларда күрешкән чакларымыз... Уф-ф-ф Алла! Ул көннәрдәге рәхәтләр (сәгадәтләр)!! *(Куркынган тавыш берлән.)* Кем бозды аларны?! Үзем! *(Көзгегә карап.)* Үзем! Менә шул залим. *(Көзгегә күрсәтә. Кәнәфигә утырып егларга тотына.)*

Мәһри *(чәйнек берлән кофе күтәреп керә дә моның янына китерә)*. Менә, булды. *(Каюмга карап.)* Син ни эшлисең?

Каюм. Бер эш тә эшләмим.

Мәһри. Әллә әтиеңне сагындыңмы?

Каюм *(күзен яулык берлән сөртеп)*. Әйе.

Мәһри. Һәммәбезгә үлмәк бер инде.

Каюм. Зинһар, мине үземне генә калдыр! Зинһар, әйтәм. Бүтән чакта сөйләрбез.

Мәһри *(гаҗәпсенеп карангалана-карангалана чыга башлый)*. Шулдыр, шулдыр!.. Әллә нәрсәләр сөйләгәндер. Бер-бер кыздан җә хат китергәндер. Карчыклар усал, диләр, кызлар берлән егетләр арасында сүз йөртә, диләр, бар да юк сүз, бар да юк сүз. Менә әле ничә кыздан әйтергә сүзләрем бар, берсен дә әйтергә вакыт таба алганым юк. Ул яшь булса да әйтеп өлгергән! *(Чыгып китә.)*

Каюм. Әле минем Салих бай кызы берлән эшем башланган. Анысын ни дип башладым?! Үзем кабахәт, үзем! Байлыкка кызыгам. Нәрсәгә миңа байлык! Әле этинең әллә кемнәрне талап җыйган акчасы өчен дә җавап бирергә кирәк! Ни эшлим? Аның берлән бөтенләй эшне бетерер идем. Тагы кабахәтлек! Уф-ф-ф Алла! Йа Рабби, үзең юл бир! *(Исәпләп торып.)* Салих бай кызына хат языйм, бер күрим. Билгеле, яратмыйм. Аннары Хөршитне алырмын. *(Язу өстәленә барып яза да пакетлап.)* Шаһидә! Шаһидә! *(Кычкыра. Шаһидә керә.)*

Каюм. Мә, шуны Салих бай кызына бир. Бүген чыксын дип әйтте диң. Кайтканда Хөршиткә кереп әйт, хат язам дип әйтте диң.

Шаһидә. Ярар, аннан соң?

Каюм. Сөйләмә, сөйләмә, бар шуны эшлә! *(Кулы берлән тотып чыгара.)* Тагы башымны авырттырырга тели. Уф-ф-ф Алла! Эчем азрак шиңеп китте. Ни була инде?

Пәрдә төшә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Габдулла талчукчы өе, өйдә көзгеләр, гөлләр. Каршыда бер ишек, уң якта кара ишек. Хөршит, Мөршидә, асрау өстәл янына утырганнар. Алларында фал китабы. Мөршидәнең кулында дүрт почмаклы бер шакмак.

Хөршит. Тәгәрәт, Мөршидә.

Мөршидә *(тәгәрәтеп)*. Х, *(тагы бер тәгәрәтеп)* б, *(тагы тәгәрәтеп)* а.

Хөршит. Х, б, а! (*Кулына китапны алып эзәрли.*) а, х, б, д, ә, х, а, д, б. Ә менә монда икән: х, б, а өченче биттә. *(Эзләп таба да укый башлый.)* «Җәгъфәр Садыйк диер ки, и фал иясе, бу фал кем сиңа килде, Даниялга фалыдыр. Нитәкки ул авырлыклар күрде һәм ко-

тылды, син дә котылырсың. Бер сәфәр күренә, изге, мөбарәк улур, югалган нәрсәң табылыр. Һәммә морадың хасыйл улур».

Асрау. Бер дә туры килмәде, бер дә туры килмәде.

Мөршидә. Икенчене! Бу дөрест чыкмады.

Хөршит ача икенчене.

Хөршит. Бигрәк туры килмәде, бер сәфәр күренә, имеш, анысы дөрест түгел.

Асрау. Югалган әйберең табылыр дигәне дөрестме? Синең нәрсәң җугалган?

Мөршидә. Җугалган әйбер Каюм абый булса. *(Өчесе дә.)* Аһ, аһ!

Хөршит. Чын ул булса, табылыр. Бик яхшы сүз, дөресе дә, Каюм минем җугалган әйберем. Ул миңа үзенең алмавыннан хат язды. Тагы югалмый нишләгән?

Мөршидә. Тагы бер кат, тагы бер кат, Хөршидә апа, тагы бер кат! Мин болай гына ышанмыйм. *(Кулына шакмакны ала.)*

Хөршит. Мин бөтенләй дә ышанмыйм да, әле тик үзең теләгән чыкса, күңелгә яхшырак була.

Асрау. Мин ышанам. Мин Шакир байларда торганда Хәлимә туташ берлә ача идек, бик туры килә иде, миңа бер чыккан иде: «Синең бер ир балаң булыр, сүзе үтемле булыр» дигән иде, һаман юк әле.

Мөршидә. Менә тапты. Кыз кешенең нинди ир баласы булсын!

Асрау. Мин аны, үземчә, балага җурамаган идем.

Хөршит. Кемгә җураган идең?

Асрау. Зурракка.

Һәммәсе. Әһә, әһә, әһә. *(Көлешәләр.)*

Мөршидә. Үзең җурый беләсең икән. *(Тәгәрәтеп.)* Д, *(тагы тәгәрәтеп)* а, *(тагы тәгәрәтеп)* д. Д, а, д! *(Китап алып эзләп.)* 4 нче биттә икән. *(Укый башлый.)* «Җәгъфәр Садыйк диер ки, әй фал иясе, бу фал кем синә килде. Синә белдерер ки, синең теләгәнең арыслан авызындагы сөяк шикелледер. Нитәкки арыслан авызыннан сөяк алынмас, синең эшең дә хасыйл улмас. Барча гөнаһларыңнан тәүбә кыл. Иншалла, морадыңа ирешерсең. Аллаһе Тәгалә синә бер бала багышлай ки, җумарт улур...»

Мөршидә. Монысы дөрест түгел, монысы дөрест түгел.

---

*Нитәкки* — ничек, ни рәвешле.
*Морад* — максат, теләк.
*Хасыйл булу* — үтәлү, барып чыгу.

Х ө р ш и т. Ташла шуны, үзе һәммә максудыңа ирешерсең, ди, үзе теләгән нәрсәң арыслан авызында, ди.

А с р а у. Шунысы бик кызык, Хөршиткә балаң булыр дигән. Чын, Хөршит, балаң булса, ничек кушар идең?

Х ө р ш и т. Ир бала булсамы?.. Габделкаюм.

М ө р ш и д ә. Балаңа дәшкән саен җөрәгең җанар ласак.

А с р а у. Син алай итмә инде. Үзеңә бигрәк авыр булыр, ул ташлаган, син дә ташла! Барыбер өмет юк ич!

М ө р ш и д ә. Ник булмасын? Өметсез шайтан, ди.

А с р а у. Җае юк шул.

Х ө р ш и т. Син безнең ни эшләгәнне белмисеңме әллә? Ә, чын да син белмәдең шул әле.

А с р а у. Ни эшләдегез? Ни эшләдеңез?

М ө р ш и д ә. Эшләдек инде.

Х ө р ш и т. Без Рәхмәтулла байның асравын сатып алдык. Каюмга Салих бай кызы Рәфига дип хат бирдек. Ул аны кабул итте. Каршы хат язды. Без тагы яздык. Бер өметме? Икенчесе, Каюм миңа вәгъдә кылган иде, әгәр ала алсам, алмый калмам дип. Аның хәзер әтисе үлде. Әнисе дә киткән, ди. Хәзер инде ала ала, бәлки алырга теләр. *(Моңаеп кына.)* Ул мине бик сөя иде.

А с р а у. Сез эшне бутагансыз гына. Каюм хәзер ни сине алырга белмәенчә, ни Салих бай кызын алырга белмәенчә йөри торгандыр. Билгеле, Салих бай кызын алмакчыдыр. Алар байлар. Аларга җаучы җибәрер дә туй да ясарлар. Без хәйләләребезне күтәреп калырмыз.

М ө р ш и д ә. Без аны уйлаган шул. Салих бай кызын алмакчы булыр иде дә, аның кызы юк.

Х ө р ш и т. Аннары тагы аның бер уе бар, кызны күрмәенчә алырга ярамый, ди. Шуның өчен ул күрмәенчә алмый. Әгәр дә күрәм дә алам дип Салих бай кызына хат язса, мин вәгъдә кылган урынына киенеп барам да керәм.

А с р а у *(гаҗәпсенеп)*. Ул таныса!

Х ө р ш и т. Әүвәл танытмыйм, ахырдан үзем дә танытам.

А с р а у. Бигрәк оста уйлагансыз. Ләкин сине алмакчы булган булса, сез бу хатыңыз белән зарар гына итәсез.

Х ө р ш и т. Мине алмаска теләве билгеле диергә ярый; чөнки ул әтисе үлгән көнне «Мин сине ала алмыйм» дип хат язды. Аннан бирле бер хәбәр дә юк. Әтисенең кырыгы җитә инде. Салих бай кызына дип әллә ничә хат алдык. Менә аерым ачык бүген белермез. Мин үзем булып хат язган идем. Бәлки, каршы җавап килер.

А с р а у. Алай яхшы булыр микән соң? Син икәнлеген белгәч, ачуланып бөтенләй ташламас микән?

М ө р ш и д ә. Бөтенләй ташлады инде.

Х ө р ш и т. Юк, минем күңелем усаллыкта түгел, сөям! Сөйгәнемә барасым килә. Болай итү бер дә гаеп түгел. Беләм мин аны — ул да мине сөя; алмакчы да була. Ләкин аның карендәш-кабиләсе ирек бирмиләр. Ул үзе дә бай түгелләр дип тартына.

М ө р ш и д ә. Менә болай булса, алмый калмый.

Х ө р ш и т. Миңа аңардан башка торуда бер дә рәхәт булмавы күк, аңарга да миннән башка торуда рәхәт юк, чөнки минем шикелле аны бер кеше дә сөя алмый. Ул үзе дә, мине алмаса, эче пошып дөньядан рәхәт күрә алмаенча кала, чөнки бик зур гөнаһ кылган була, бик зур! Кызлар күңелен бозып ташлау кадәр зур гөнаһ юк!

А с р а у. Шаһидә килде! Шаһидә килде!

М ө р ш и д ә *(тәрәзәдән карап)*. Юк ич!

А с р а у. Әнә керә, әнә керә!

Һәммәсе торалар, ишектән Ш а һ и д ә килеп керә.

М ө р ш и д ә. Шатлык хәбәр белән.

Ш а һ и д ә. Уфф! Эссе икән. Ул юлда халык, ул юлда халык! Фәйрүзә белән Вәли Арча кырына менеп киттеләр, чәй эчәргә бар, фатирымыз да әгерҗеләрдә, дип кычкырып киттеләр, йомышым бар, ди.

Х ө р ш и т. Нихәл? Ни хәбәр?

Ш а һ и д ә. Белмим, күрәсең, бер-бер эше бар; әле шуны әйтәм, безнең күршегә, Әхмәдиләргә, бер кәвешче кергән икән. Әй, кичә шулар хатыны берлән сугыштылар! Көлә-көлә эчебез катты.

М ө р ш и д ә. Тапты сөйләргә сүз. Каюм абзый нишли?

Ш а һ и д ә. Әле шуны әйтәм: Каюм абзый янына кичә Мәһри карчык килгән, өйләнә, ди.

Х ө р ш и т. Каюмнан хәбәр бармы?

Ш а һ и д ә. Бар дим, бар! Шуны сөйлим ич! Шуннан соң сиңа, яңлыш әйтәм, Салих бай кызына хат язды. *(Хатны чыгарып.)* Мә!

М ө р ш и д ә *(алып, Хөршиткә бирә дә.)* Укы, апа! Укы!

Х ө р ш и т *(ачып укый башлый)*. «Сөекле туташ!»

М ө р ш и д ә. У! «Сөекле туташ!» Миңа кайчан «сөекле туташ» диерләр икән?

А с р а у. Бүлмә инде хатны!

М ө р ш и д ә. Бүлмим, бүлмим! Укы, апа, укы!

Ш а һ и д ә. Миңа җаным дигәннәре бар! Валлаһи, бар! Менә төшкән идем түбән өйгә, аларда бер егет бар икән!

Менә валлаһи, алдамыйм, өй алдында кулымнан кысып тотты да: «Җаным, кая барасың?» — ди. Мин китәргә телим. Тагы әйтмәсме дип, тагы туктыйм. Бик кызык булды, валлаһи!

Хөршит *(тагы укый башлый)*. «Сөекле туташ!»

Асрау. Бүлдеңез инде!

Хөршит *(янә укый башлый)*. «...Сезнең нурлы йөзеңезне күрер өчен, дөрестен әйтсәм, сөйләшер өчен, күрешер өчен вәгъдә кылуыңызны үтенәм. Әгәр мөмкин булса, вакытыңыз сыйдырса, сәгать өчләрдә Шаһидә берлән югары урамга чыгуыңызны үтенәм. Сәгать өчләрдә, иншалла, мин дә анда булырмын. Һәр ни булса да, Шаһидә артыннан хәбәр йибәреңез. Вәссәлам. Язгучы — мәгълүмеңез».

Шаһидә. Алла! Бу да хат яздым дигәндер. Менә, исмасам, миңа язган иде. Валлаһи менә! «Көмеш бармагым, алтын тырнагым, күктә йолдызым, йирдә кондызым» дигән, әле әйтә генә алмыйм, «нурлы йөзеңне күрмәенчә ашый алмыйм» дигән. Менә валлаһи, ислемайлар сөрткән, чәчәкләр ябыштырган, ә бу — пуфф!.. Бернәрсәсе юк.

Асрау. Ярар инде. Хөршит, ни эшлисең?

Хөршит. Киенеп чыгам.

Мөршидә. Белер бит!

Асрау. Белсен! Киен, киен, Хөршит!

Шаһидә. Валлаһи, киен! Белмәс, белмәс!

Хөршит. Мөршидә! Энҗеле калфагымны, кара күлмәгемне, ботинкаларымны, дипломатымны китер!

Мөршидә. Дипломатыңны танымасын?

Хөршит. Танымый, танымый! Таныса тагы... Мин аны бер күрсәм...

**Асрау әйберләр китерә, Хөршит ашыгып-ашыгып көзге каршында киенә башлый.**

Хөршит. Уф Алла, йөрәгем леп-леп итә, белмим, ни булыр.

Шаһидә. Валлаһи, сөяр! Кара әле, нинди матур икәнсең, валлаһи, сөя. А, күлмәгең бик матур! Миңа да бикә үзенең иске күлмәгендин бәйрәмгә тегәрмез дигән иде. Валлаһи менә! Китте инде. Әле Салихларның асравы яңы күлмәк кигән. Валлаһи менә, бикәмез бик яхшы, ди. Иске пылау-бәлештән калса, һәрвакыт миңа бирә, ди.

Мөршидә. Тапты сөйләргә сүз. Менә шуны әйт, Каюм абзый ни эшли?

Шаһидә. Кай вакыт, аштан соңмы? Бүген белмим, бүтән көнне йоклый. *(Асрау көлә.)*

Шул арада Хөршит киенеп бетерә, асрау флүрен ябындыра башлый. Мөршидә дипломатын киерә.

Асрау. Флүреңне битеңнән ераграк тот, күренмәсен.

Шаһидә. Күренсен, күренсен! Валлаһи менә, бик чибәр икәнсең. *(Чыгарга хәзерләнәләр.)*

Хөршит *(асрауга)*. Син әниләргә Мөршидәләргә китте, диң. *(Чыга башлыйлар.)* Догада булыңыз!

Асрау. Хәерле юлга!!!

Пәрдә төшә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘНЕҢ ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШЕ

Казанның бер нумирасының бүлмәсе күренә, чиста гына бүлмә. Каюм берлән Хөршит (Рабига) килеп керәләр.

Каюм. Безгә чәй китер!

Хезмәтче. Сөт берләнме? Лимон берләнме?

Каюм. Сөт берлән. *(Хезмәтче чыгып китә.)*

Каюм. Рәтләп утырыңыз, туташ! Монда куркыныч йир түгел.

Рабига. Яхшы.

Каюм. Мин... сезгә... бик ашыктырып... дим әле *(Кыз гаҗәпсенеп карап тора.)* Мин сезне.. күрәсем килде. *(Читкә карап.)* Нәрсәдән сүзне башларга кирәк?.. Әниеңез сәламәтме?

Рабига *(читкә карап)*. Тапты сөйләргә сүз. Әлхәмдүлиллаһ, сәламәт әле.

Каюм. Мин сезне... эмм... Шаһидә сүзе берлән я... *(Читкә карап.)* Шуны әйтә алмыйм... Яраттым. Шуның өчен *(Калтырап.)* Сезне күрәсем килде.

Рабига. Мин дә шул... Сезнең һәрвакыт кибеткә чыгуыңызны карап тора идем.

Каюм. Мине шунда күрә идеңезмени? Мин сезнең һәммә хатларыңызны алдым.

Рабига. Әйе, минем, шул, шуннан соң күрәсем килде. Ни дим инде, һәрвакыт сезне күз алдымда тота башладым. Аннан ары сезгә хат яздым. Миңа ачуланмыйсызмы?

Каюм. Юк, юк! Нишләп ачуланыйм, рәхмәт илтифатыңызга.

Рабига. Менә инде күргән саен сезне күрәсем килде, шуның өчен сезнең берлән күрешергә чыктым, оят та инде...

---

*Киерә* — кидерә.

Каюм. Үзеңез һаман качынып торасыз әле.

Рабига. Мин оялам шул, сездән башка егеткә күренгәнем юк шул.

Каюм. Алай да... *(Кулыннан тотарга тели.)*

Рабига *(тартынып)*. Тотмаңыз, Каюм абый, минем кулымны... Әйтергә оялам, үземнең иремнән башка кешегә... тотарга ярамый. Яисә... әүвәл вәгъдә биреңез!

Каюм *(читкә карап)*. Мә менә! Хөршит миңа бер елдан соң да бу сүзне әйтмәде. Бу әле әүвәл күрешүдүк ниләр сөйли. *(Кызга карап.)* Мин алай кызлар алдап йөри торган егет түгел. Мин кызларның гыйффәтенең ни дәрәҗәдә икәнен беләм. Миннән курыкма! Андыймондый начар уйларым юк, мин үзем түгел, башка кешеләр кылган начарлыклар өчен дә йөрәгем яна! Кызларны алай алдап ташлауны бик зур гөнаһка саныйм, һәм бик зур гөнаһ!

Кыз. Һәммә егет әүвәл шулай сөйли дә, ахырдан ни сөйләгәнен оныта.

Каюм. Мин андый егет түгел, мин гомеремдә андый начарлык кылганым юк! Һәм кылмыйм. Дөрестен әйтсәм, сездән башка кыз берлән болай аулакта утырганым юк иде. Менә иң әүвәлге таныш кызым — сез. Монда да бер начар уй берлән чыкмадым.

Үзе, якынрак елышып, кулын тота башлый. Кыз да бу юлы бик тиресләнми, азрак кына тартынып кулын бирә.

Кыз. Алай булса, бик рәхмәт! Минем ышанмавымны да гаепләмәңез. Кызларга һәр әйткән сүзгә ышанырга ярамый. Дөньяда үзләрен гашыйк итеп күрсәтер өчен әллә нинди сүзләр сөйләгән кешеләр дә күп була. Шуның өчен мин дә үземчә сезне сынамакчы булдым. Гаеп итмәңез!

Каюм *(читкә карап)*. Бу нинди бу — бик гакыллы кыз! Хөршиттән генә шундый матур сүзләр чыгамы әллә диеп уйлый идем. Ахры, кызлар барысы да Хөршиттер. *(Кызга карап.)* Үзеңез һаман качынып утырасыз!

Кыз. Минем сүземә җавап бирмәдеңез.

Каюм. Нинди сүзгә?

Кыз. Сез оныттыңыз да инде!

Каюм. Ни дип җавап бирим, ышансаңыз, мин алдамыйм.

Кыз. Алдамыймсыз?

Каюм. Алдамыйм. *(Шул арада кыз флүрен ачып җибәрә, Каюм, ачуына, әүвәлге сөйгәне Хөршитне танып.)* Хөршит!!! Хөршит! *(Итәгенә җыгыла. Еглаган тавыш берлән.)* Хөршит, гафу кыл! Җаным бул, гафу кыл!

*(Идәнгә төшеп, аягына тезләнә дә, кулларын тотып.)* Хөршит! Җаным!.. Мин нишләдем? *(Кулын чуп-чуп үбеп.)* Гафу кыл! *(Хөршит бер сүз дә әйтми катып тора.)* Хөршит, нишлим? Валлаһи менә!.. *(Калтыраган тавыш берлән.)* Сине сөям... Хөршит! Ник син дәшмисең? Мине... син нишлисең?.. Ник? Мин... болай... сине... ни әйтим... *(Еглаган тавыш берлән, кулын үбеп.)* Ник дәшмисең?! Сөясеңме? Хөршит! Күңелем... усал түгел, синнән бүтәнне сөймим!.. Хөршит!!! Уф-ф-ф Алла!! Мин нишләдем? *(Калтыраган тавыш берлән.)* Валлаһи, сынарга дип кенә чыккан идем! Хөршит! Кичер мине!

Хөршит *(еглап Каюмның муенына атыла)*. Каюм! Каюм! Син нишләдең? Ник мине болай иттең? *(Еглап.)* Уф-ф-ф... Бәхил! Барысы да бәхил!

Каюм *(кулларын үбеп)*. Җаным! Алла, Алла... кушты! Салих... бай кызы дип чыккан идем... *(Тагы кулын үбеп.)* Мин дә гаепле түгел! Валлаһи гаепле түгел! Белмим, асрау алдады. Валлаһи... Асрау!

Хөршит *(Каюмның кулыннан ычкынып торып китә дә, икенче тавыш берләнрәк)*. Син әүвәлге вәгъдәңне онытмасаң, болай булмый иде!

Каюм. Миндә гаеп, Хөршит! Һәммәсендә мин гаепле! Алай да сине сөюемдә хәйлә юк! Хөршит! Бир кулыңны, җаным! Минем хатыным булдыңмы? Булдыңмы, Хөршит? Ни уйлыйсың, булдыңмы?!

Хөршит. Тагы әүвәлге төсле булыр дип куркам!

Каюм. Булмый, булмый!!! *(Утырып.)* Бир кулыңны, разыймы? Разыймы?

Хөршит. Разый!!!

Килеп кочакланышалар да аерылалар.

Каюм. Бу эшләрдә ни әйтергә белми идем, Алла үзе ярдәм итте. Әлхәмдүлиллаһ! Мәсгудмен, син дә бәхил! Туй киләсе якшәмбегә булыр! Җәмә? Әтиеңнән соратам. Син разый бит! Уф-ф-ф Алла... Бик авыр булды, күңелем дөрест иде.

Хөршит. Миңа рәхмәт диң инде! Менә сине ни чаклы сөям икән!

Каюм. Мин дә бик сөям; инде кыяматкә кадәр аерылмам.

Хөршит. Сөй, җаным! Сөй! Рәхәт яшик! Актык бер бүсә чыгамыз. *(Үбешәләр.)*

Пәрдә төшәр.

---

*Мәсгуд* — бәхетле.
*Бүсә* — үбеш.

# АЛДЫМ-БИРДЕМ

*Биш пәрдәдә, алты манзарәдә*

ПЬЕСАНЫҢ КЕШЕЛӘРЕ:

Хәлил бай Шакиров — үзенчә либерал татар бае. Кызылрак чырайлы, сарырак сакаллы, күзлек кия, яше 45 ләрдә.

Гарифә бикә — Хәлил байның хатыны, аяклары авырта, яше 37 ләрдә.

Галия — аларның кызы, бераз укыган, яше 18 ләрдә.

Ибраһим Шакиров — торговый домның кантуршигы, Хәлил байның якын карендәше, русча һәм татарча укыган, аңлы гына бер егет. Яше 21 ләрдә.

Садыйк — Хәлил байның да, Ибраһимның да якын карендәше, Шакировлар фамилиясенең иң карты; гакыллы гына, тугры гына бер кеше, яше 58 ләрдә.

Әхмәди — Хәлил байның энесе, бик һавалы; Шакиров фамилиясенең исемен сатмас өчен бик тырыша торган, надан гына бер яшь бай, яше 35 ләрдә.

Карт хәзрәт — шәригатьтән бер дә чыкмый торган бер мулла, яше 70 ләрдә.

Габдулла мулла — акчага һәрнәрсәне сата торган бер мулла, Шакировларның берсенең кияве, Бохарада укыган, чалмасы сартча, яше 32 ләрдә.

Мөәззин — җирәнрәк сакаллы, кызыл муенлы, таза гына бер кеше, яше 35 ләрдә.

Хәдичә — Шакировларның берсенең хатыны.

Фәхрениса — Шакировларның өлкәненең хатыны.

Мәрфуга — Ибраһимның анасы, карчык.

Сорур — Хәлил байның угылының хатыны.

Әсма — Шакировларның берсенең хатыны.

Әхмәтсафа — Шакировларның берсенең угылы.

Михаил Васильевич — становой пристав.

Наташа — асрау кыз, керәшен кызы.

Әхмәтсәгыйр Вәлиев — кода.

Фәйзулла<br>Исмәгыйль } Шаһитлар.<br>Сәгыйт

Өч кеше — мужиклар.

Вакыйга бер авылда.

---

*Манзарә* — күренеш.
*Фамилия* — гаилә, нәсел.
*Сартча* — үзбәкләрнекечә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур гына бер аш бүлмәсе. Бүлмә шактый байларча. Сул якта зур бер шкаф. Асрау кыз Н а т а ш а аш урыны хәзерли. Г а л и я килеп керә.

Г а л и я *(кулына серкә савыты күтәргән көенчә кереп, серкәне Наташага бирә дә, аңа карап)*. Тизрәк бир, Наташа. Әни хәзер генә тышка чыкты. Ни сөйләде? Күрдеңме?

Н а т а ш а *(кесәсене актарып)*. Әй, Галия, йөри-йөри җөдәп чыктым. Ул, хатны биргәч, бик озак хатка карап ачмаенча торды, бармагының очы берлә генә хатны тоткан да, менә шулай итеп *(кулындагы хатны тотып күргәзә)*, үзеннән ерак итеп тора. Үзе агарды, бүртенде. Маңгаеннан тирләр чыкты, аягы-кулы калтырый башлады. Хатны бер миңа таба китерә, бер үзенә таба илтә. Шуннан соң, тиле кеше кебек, ертты да укырга тотынды. Менә укуыны күрсәң иде, Галия, хатның эченә кереп китә дип уйларсың. Шуның соңында урындыкка утырды да бик озак уйлап торды. Мин: «Җә, Ибраһим абый, җавап язамсың?» — дигән идем, сискәнеп китте. Ул минем барлыгымны да оныткан икән. Шуннан соң: «Килерсең әле, уйлыйм әле»,— диде. «Галиягә ни дип әйтим?» — дигән идем: «Бер ни дип тә әйтмә»,— диде. Шуннан кичкә таба тагы бардым. Ибраһимның әнисен күрдем, аңардан теге мөгез салучы хатынның кайсы авылныкылыгын сорадым да, чәчәк җыярга дип, бакчаларына чыктым. Чыксам, ни күзем берлә күрим, Ибраһим абый сирин астында утырып тора. Акыртын гына янына бардым. Тагы: «Хат бирәмсең?» — дип сорадым. Тагы: «Юк әле, килерсең»,— диде. Үзе менә бөтенләй үзгәргән. Бертуктамаенча әллә нәрсә уйлый. «Тизрәк яз инде!» — дигән идем, күзене тутырып карады, бер сүз әйтә алмаенча, тизрәк киттем. Аннан менә бүген иртә берлә кантурга киткәнчә дип тизрәк тагы бардым. Чәй эчеп торалар иде. Ибраһим абыйның күзләре кызарган, үзе әллә нинди авырган кеше кебек булган, ахрысы йокламагандыр. Әнисе чыгып киткәч, кесәсеннән алды да бирде.

Г а л и я. Бер сүз дә әйтмәдеме?

Н а т а ш а. Бер сүз дә әйтмәде. Моңынча егетләргә хат илтсәң йә сәлам әйтсәң, авызы ерыла иде, бу әллә нинди.

Г а л и я. Ул нишләргә белми аптырап калгандыр, без бит аның берлә агалы-сеңлеле кебек үскән. Тагы этиләрдән

---

*Сирин* — сирень.

курка торгандыр. Менә син мине уйла! Мине! Мин ничек бүген аш янында утырырмын. Ашка килер микән?

Наташа. Ул шәт бүген килмәс тә, килсә дә, кодачалар кебек кып-кызыл булып утырыр.

Галия хатны ертып укырга тотына. Наташа һаман аш урыны берлә маташа. Аяк тавышы ишетелә башлый. Галия хатны кесәсенә тыгып куя. Гарифә аксап килеп керә.

Гарифә *(Наташага карап)*. Аш өеннән сөзмә алып кер. Аның соңында кан алучы хатынга аш ашатсыннар!

Галия. Тагы кан алдырасыңмы әллә, әни?

Гарифә. Теге сөлегем файдалы булмады. Аягымның авыртуы аз гына да кимемәде. Әллә азрак кан алдырсам, җиңеләймәсме дим. Син тагы әтиеңә әйтмә! Мин ул киткәч кенә, мунча яктырып, аз гына агызмакчы булам. Каным бик бозылган.

Галия. Аңардан бит бер дә файда булмыйдыр, ди. Әнә Фәхрениса абызтай никадәр сөлек салдырды, никадәр мөгез утырттты, үзе һаман начарлана гына барды. Син дә шулай булмассың микән? Ибраһим абый да кан алдыруны бер дә яратмый. Безнең Шакировларның хатыннары сөлек салдырып, кан алдырып кибеп бетәләр дә, аннан соң Казанга барып, Кырымга барып даруланырга тотыналар дип көлә.

Гарифә. Ул Ибраһим сүзен сөйләмә. Ул кан алдырудан гына түгел, торабы шифа изеп эчүдән дә көлә. Без аның артыннан йөри алмыйбыз инде.

Шул арада Хәлил берлә Ибраһим килеп керә.

Ибраһим *(иң әүвәл Гарифә янына барып)*. Тугдык җиңги, исәнмесез? *(Аннан Галиягә карап.)* Исәнмесез?

Галия. Исәнмесез. *(Хәлил утыра, Ибраһим да утыра.)*

Гарифә *(Ибраһимга)*. Әллә, Ибраһим, авыраймсың?

Ибраһим. Бүген әллә нәрсәгә төн буе йоклап булмады. Минем бүлмәдә кандала күбәйгән.

Хәлил. Хәзер печәнлеккә ятар вакыт җиткән. Без синең кебек чакта печәнлектә ята идек.

Ибраһим. Безнең печәнлекнең башы тимер берлә япканга, анда йоклар хәл юк. Бик бөркү була.

Хәлил. Галия, кызым, бар, кара әле, ашны тизрәк бирсеннәр әле, анда эшләр бар. *(Гарифәгә.)* Синең исәнлек ничек? Ә, әле Казаннан, Вахитлардан хат алган идем, Ибраһим, мә әле, укы әле!

---

*Торабы шифа* — шифалы туфрак.

И б р а һ и м *(укый).* «Казаннан, 1906 нчы ел, 20 нче май. Гыйззәтле Хәлил абзыйга һәм дә Тугдык җиңгигә бик күп догалар үтенеп, бик күп сәлам һәм дә Әхмәди берлә Хәдичә киленгә бик күп сәлам, Садыйк абзый берлә Мәрфуга җиңгигә бик күп сәлам вә һәм барча туган-карендәшкә сәлам. Үземез, әлхәмдүлиллаһ, беркөенчә торамыз. Фатыйманың аягыны хәзер ике профессор, бер дуктыр карый, килгәч үк янында торырга бер сестра алдык. Иртәгәдән башлап электрик берлә даруларга тотыналар. Үзе һаман әле аягына баса алмый. Дуктырлар чыгып йөрмәүдән диләр. Ничек булса да июнь ахырларына кадәр монда торырга тугры килер, үзем мондагы Дрейфусларның доверенныен күрдем, солыга 65 тин бирәләр, тиреләрне мондагы дуст-иш бераз сабыр итәргә куша. Исәнлек-саулыкта күрешергә насыйп булсын дип язгучы Вахит Шакиров».

Г а р и ф ә. Әле җавап хат язмадыңызмы? Язмаган булсаңыз, Әминәнең баласы үле тууыны онытмаңыз!

И б р а һ и м. Бу нидән бу, Хәлил абзый, безнең нәселдә аяк авыруы бик күп?

Х ә л и л. Ник, күп түгел ич! Менә мин исән, син исән, Әхмәди исән, Вахит исән, Садыйк абзый исән.

И б р а һ и м. Менә Тугдык җиңги, Әсма апа, Әминә җиңги, Хәдичә апа — барысы да ярты аяк кына ич.

Х ә л и л. Дуктырлар, өйдә торганга, ди. Хатыннар, -кан күплектән, ди, кайсыныкы дөрестер, белер хәл юк. Шулай булса да, безнең Шакиров фамилиясенә һәр елны аксак хатыннарның аякларыны дарулау өч меңнән кимгә төшми.

Г а р и ф ә. Сез бигрәк инде, нишләп өч мең китсен! Бу ел менә Фатыйма гына авырый.

И б р а һ и м. Салиха апа? Берсе Кырымга китте, берсе Кавказга бара.

Шул арада бик күп гәзитәләр күтәреп Г а л и я керә.

Г а л и я. Анда Садыйк абзый килә, әни.

Г а р и ф ә. Мин, алай булса, хатыннар янына чыгам.

Г а л и я. Әти, аш өлгергән.

Үзе бик күп гәзитәләрне өстәлгә ташлый, шул арада С а д ы й к килеп керә.

Х ә л и л. Садыйк абзый, әйдә!

Садыйк утыра.

И б р а һ и м. Абзый, исәнме?

С а д ы й к. Әлхәмдүлиллаһ.

Хәлил гәзитәләрне актарырга тотына.

И б р а һ и м *(берсен алып)*. Моны күрдеңезме! Яңы гәзитә!

С а д ы й к. «Таң»мы?

Х ә л и л. Бик шәпмени? Ни яза?

С а д ы й к. Ул безнең Закир кияүләрнең прокламацияләре берни түгел! Ничек бу кадәр яза алалар?

Х ә л и л. Кемнәр чыгара?

С а д ы й к. Әллә нинди күзгә күренмәгән, колакка ишетелмәгән кешеләр.

И б р а һ и м. Идән астыннан йөри торган кешеләр.

С а д ы й к. Шулайдыр шул, шулай булмаганда, ул гәзитә чыгарып иректә торырмын дип уйларга ярамый.

Х ә л и л. Бу елда яшьләр гайрәтлеләр бит. Безнең кебек куркып тормыйлар.

Г а л и я. Алай язган өчен аларны нишлиләр икән соң?

И б р а һ и м. Төрмәгә ябалар, аннан ары төрле якка, Себергә җибәрәләр.

Х ә л и л. Элгәре студентлар дип кенә сөйлиләр иде, хәзер бар да студентлар! Әле безнең Андрейне становой сорап киткән! Гәзитә укыймы, язулар таратамы, дип әйтәдер, ди. Мин үзен чакырып, Василий Иванович, сез, пожалыста, аны яба күрмәңез, безнең кирәкле приказчигымыз ул, дигәч, тимәде, калдырды.

С а д ы й к. Бездә дә шундый эшләр була башлады диген, ә?

Х ә л и л. Ие!

Шул арада Н а т а ш а аш алып керә. Барысы да салфетларыны алып утыралар. Галия аш сала.

С а д ы й к. Әле сез яңы хәбәр ишеттеңезме?

Х ә л и л. Ул тагы нинди яңы хәбәр?

С а д ы й к. Безнең теге тиле Әхмәтҗан кызын Сәлим хаҗига биргән!

Х ә л и л. Сәлим хаҗига? Ни дип? Әллә кызына урын таба алмаганмы? Әллә кызы утыз тутырганмы, тиле, тиле!

И б р а һ и м. Әгерҗе Сәлим хаҗигамы? Ул алтмыш яшьлек карт ич!

С а д ы й к. Алтмыш яшьлекме, түгелме, мин анысын белмим. Мин мәдрәсәдә укыганда ул зур шәкерт иде. Мин илле сигездә, менә үзеңез уйлаңыз!

Х ә л и л. Ни дип биргән! Әй тиле, әй тиле!

С а д ы й к. Тоткан да биргән!

И б р а һ и м. Җәмәгатьләре риза булды микән?

С а д ы й к. Нинди җәмәгатьләре, андый тиле кеше җәмәгатькә-фәләнгә карыймыни?

Х ә л и л. Ул үз башына кылана инде, йә кызы үзен оятлы итәр! Тиле, тиле!

Г а л и я. Кызы риза булган диме?

С а д ы й к *(көлеп)*. Безнең муллалар исән булганда кызның ризалыгы ике тин бер акча! Алар кычкырып егласа, мулла, шатлануыннан, ди, акыртын егласа, әссөкүт — галәмәте әрриза, ди.

Г а л и я. Бармыйм, дисә?

Ибраһим Галиягә карый.

С а д ы й к *(көлеп)*. Кара, нәрсә сөйли?

Х ә л и л. Бик дөрест әйтә. Хатын-кыз — ул хайван түгел ич. Аларның хакы бар. Шәригать, ахрысы, аларга да хак биргән.

И б р а һ и м. Безнең тормышның хатын-кыз ягы искиткеч. Ирләр теләсәләр нишлиләр, теләсә өйләнә, теләсә аера, теләсә кыйный, теләсә хатынының малын бетерә.

Г а л и я. Ул нидән, Ибраһим абый?

И б р а һ и м *(кызарып)*. Ул, бердән, хатыннарның наданлыгыннан, алар үзләренең хакларыны белмәенчә, үзләрен аяк астына таптаталар, икенчедән, безнең ирләремезнең хатыннарга кеше күзе берлә карамаенча, курчак дип кенә карауларыннан.

С а д ы й к. Курчак булгач, аларга курчак дип карамый нишлисең? *(Үзе көлә.)*

Г а л и я. Ник курчак булсын?

С а д ы й к. Курчак булмый нишләсен? Сез нишләгәнеңез бар?

Г а л и я. Барысын да эшлимез. Бу ашны кем пешергән, бу өйне кем җыйган?

С а д ы й к. Бу ашка итне кем алган? Бу өйгә җиһазны кем китергән?

Г а л и я. Алла, без ничек итләр китерә алыйк? Без ничек җиһазлар ала алыйк? Безне бит өйдән чыгармыйлар. Безне кешегә күренергә ярамый, диләр.

С а д ы й к *(көлеп)*. Менә шулай сез бер эш эшли алмыйсыз, шуның өчен сезне хайван урынына, курчак урынына йөртәләр, теләсәләр — кияүгә бирәләр, теләсәләр — аералар.

Г а л и я. Ирләр көчле шул, алар безне җәберлиләр. *(Наташа икенче аш кергезә.)* Алар теләсәләр ни кылыналар. Безнең аларга каршы көчемез юк.

С а д ы й к *(көлеп)*. Менә, шулай итеп, җәберләтмәскә кирәк шул! Менә гәзитә әйткәнчә, *(«Таң»га күрсәтеп.)* тартышырга кирәк.

---

*Әссөкүт — галәмәте әрриза* — дәшмәү — ризалык билгесе.

И б р а һ и м. Хәзерге хәлдә аларга тартышырга мөмкин түгел. Алай булса — шәригатькә сыймый, болай булса — гадәткә сыймый!

Г а л и я. Шулай шул. Әнә Садыйк абзый миннән ничек көлә!

С а д ы й к *(көлеп, Хәлилгә карап)*. Менә тартыша башладылар. Гәзитәнең файдасы булды.

Х ә л и л. Уйна да көл, Садыйк абзый, мин һаман шул тиле Әхмәтҗанның эшен аңламыйм, ни дип биргән? Син бераз сорашмадыңмы?

С а д ы й к. Уйламаганда-нитмәгәндә базарда килешеп кайткан да җәмәгатьләренә аш-су хәзерләргә кушкан. Иртәгесен Сәлим хаҗи килеп никях та укытканнар. - Никяхка кадәр хатыны да, кызы да берни дә белмәгән, ди.

Х ә л и л. Ул нинди эш ул! Мин шундый эшләргә гаҗәпкә калам.

И б р а һ и м. Минемчә, бу бик табигый эш, хатын-кызларга курчак итеп караганда, аталарга-агаларга кызларны теләсә кая, теләсә кемгә бирергә ирек булганда, мондый эшләр көннән-көн күбәячәк. Бертөрлеләре кызларын, сеңелләрен ирек баштан әллә кемнәргә сатачаклар. Бертөрлеләре үз сүзен итәр өчен кызларын, бөтен өй җәмәгатенә каршы килеп, Сәлим хаҗиларга бирәчәкләр, бертөрлеләре кызлары бер-бер кешене сөйгән өчен, кызларын үзләренең рөхсәтеннән башка сөйгәнгә җәзалау өчен, кызларының башларын югалтачаклар.

Х ә л и л. Шәригать бар бит! Хатыннар хаклары, шәригатьтә кысылган булса да, бар бит! Аларны сарык урынына сатарга ярамый бит!

И б р а һ и м. Шәригать андый кешеләрне бервакытта да үзләренең эшләреннән тыя алмаган, моннан соң да тыя алмаячак! Былтыргы Салих хәзрәт кызының вакыйгасын хәтереңездән чыгармагансыз? Үз сүзен итәр өчен, аңардан рөхсәтсез сөюе өчен кызын җәзалар өчен нишләде? Элгәре бирергә вәгъдә кылган булса да, араларында хат йөргәнне белгәч, Рәхим әфәндегә ник бирмәде? Сөю җинаять хисапланганда, никях кода-кодагыйлар булып, мунча керешеп йөрү өчен ясалган гадәт иттереп уйланганда, мондый эшләр бетәчәк түгел, артачактыр.

Н а т а ш а өченче төрле аш кертә. Ашыйлар.

Х ә л и л. Салих хәзрәт хата итте, анысында сүз дә юк!

С а д ы й к. Сөйләмә инде, алма төсле кызыны бер чулак муллага бирмәсә ярамый идемени?

Хәлил. Кызы качып кайткан шикелле?

Галия. Бер айдан ук кайткан.

Хәлил. Мин үзем шундый эшләрне яратмыйм. Ләкин ата-ана сүзеннән чыгып, үзләре теләсә ни эшләп йөргән балаларны мактый алмыйм.

Садыйк. Хәзер замана үзгәргән, Хәлил. Безгә бу эшләр бик җат тоела, ләкин яшьләр үзләре яшисе дөньяны үзләре теләгәнчә йөртмәкче булалар. Аларны да гаепләр хәл юк!

Наташа *(кереп, Хәлилгә)*. Абзый, анда бер хәзрәт бар. Абызтай, зәкят бирергә кирәк иде, ди.

Хәлил. Аш артын китер дә, менә чыгармын.

Садыйк. Ул нинди хәзрәт?

Хәлил. Күрше авылның Әшрәфулла мулладыр. Алардан да туеп беттем инде.

Садыйк. Туймаслык түгел инде.

Наташа аш арты алып керә.

Галия. Әти, без бүген урманга чыгыйкмы? Хәдичә апалар да барамыз диләр.

Садыйк. Әә, менә ни өчен ул шулчикле хатыннар хакын саклар өчен тартыша икән!

Хәлил *(көлеп)*. Әле үзе генә дә түгел, Ибраһимны да адвокатка яллаган! Анда нишләмәкче буласыз? Өйдә торырга гына ярамыймыни?

Ибраһим. Әле генә, Хәлил абзый, мин андый эшләрне яратмыйм дигән идең!

Хәлил *(кызарып)*. Ярый, ярый, барырсыз! Менә, Садыйк абзый, болар берлә сөйлә. Үз сүзең берлә үз авызыңны тыгалар. *(Дога кылалар.)*

Хәлил. Мин чыгыйм әле.

Чыга. Төрлесе төрле якка утыралар.

Садыйк. Нихәл, Галия, нишлисең, Мария Александровнаң килдеме?

Галия. Килә, Садыйк абзый.

Садыйк. Яхшы укытамы соң?

Галия. Мин аны кайдан белим, Садыйк абзый, укыйяза беләм, китаплар аңлый башладым, сөйләргә бик авыр шул!

Садыйк. Теге, мин Казаннан алып кайткан китапларны укыдыңмы?

Галия. Шәт шул көннүк укып бетердем. Аннан, Ибраһим абзыйдан алып, әллә никадәр китап укыдым.

Садыйк *(Ибраһимга)*. Нихәл, Ибраһим, эшләр барамы?

И б р а һ и м. Акыртын гына бара.

С а д ы й к. Әллә авырыйсыңмы? Әллә нинди кәефсез торасың!

И б р а һ и м. Юк. Эш бик күп, кантурда 12 сәгать эшләп кара, авырырсың! Тагы кичә әллә нишләп йоклап булмады.

Г а л и я. Ник?

И б р а һ и м *(Галиягә карап)*. Кандала ашады.

Г а л и я. Әһә! Ник соң кантурда шулкадәр күп торасыз?

И б р а һ и м. Эш күп.

Г а л и я. Башкалар эшләмимени?

И б р а һ и м. Башкаларга да күп.

Г а л и я. Алай булгач, тагы яңаларны ник ялламыйлар?

И б р а һ и м. Файда кими.

Г а л и я. Файданы Алла бирә ич.

И б р а һ и м. Алла бирә бирүен дә, без 12—13 әр сәгать эшләгәнгә бирә шул ул!

С а д ы й к *(көлеп, Галиягә)*. Әле син шул байлыкларны үзеннән-үзе генә килгән дип беләидеңмени? Менә Ибраһимның ике сәгать артык эшләвеннән калфагың булган, Андрейнең ике сәгать артык эшләвеннән читегең булган, бүтәннәре тагы шулай!

Г а л и я. Минем бөтен нәрсәм кеше хакымыни? Алар жалуния алмыйлармыни?

И б р а һ и м. Алсалар да, эшләре кадәре алмыйлар шул, менә мин 12 сәгать эшлим икән, алты сәгатьлек кенәсен алам, алты сәгатьлеге хуҗаларга кала. Бүтәннәре дә шулай.

С а д ы й к *(көлеп)*. Шуларга бирелмәгән жалунияләреннән сиңа әтиеңнәр калфаклар эшләтәләр, җиһазлар ясыйлар, Шакировлар аксак хатыннарыны кайсысын анда, кайсысын монда итеп даруландыралар — Кырымга баралар, Кавказга баралар. Шуларның эш хакларыннан зәкят бирәләр. Бәдәл хаҗга йибәрәләр. Шуңардан кунак сыйлыйлар. Шуңардан үзләре ашыйлар.

Г а л и я. Мин шул Андрейләр, Ибраһим абзыйлар, Салих бабайлар, Василийләрнең жалуниясенә киенеп тораммыни?

С а д ы й к. Аларныкы гына түгел, каравылчы Сабит, көтүче Хәйриләрнең дә жалуниясеннән киенәсең.

Г а л и я. Син көләсең, Садыйк абзый. Мин сиңа ышанмыйм. Ибраһим абый, дөресте шулаймыни?

---

*Итү* — илтү.
*Бәдәл* — үз урынына яллап хаҗга җибәрү.

И б р а һ и м. Шулай.

Г а л и я. Алла бирмимени?

И б р а һ и м. Алла эшчеләрдән башка үзе генә бирми!

Г а л и я. Менә хәзер әле сез, Ибраһим абзый, безгә кунакка килдеңез, сез безнең ашны ашамадыңыз алай булса, без сезнең ашны ашадык.

И б р а һ и м. Ие! Байлар һәрвакыт эшче ашын ашый, эшче акчасын тота, эшче байлыгына хатыннарын киендерә.

Г а л и я. Алай булгач, сез ник ул үзеңезнең эш бәһаңезне алып бетерергә тырышмыйсыз, менә бу гәзитә әйткәнчә, тартышмыйсыз?

С а д ы й к. Менә сез, хатыннар, ник үзеңезнең хакыңыз өчен тырышмыйсыз, менә син әле урманга барырга этиеңнән сорамаенча булдыра алмадың. Менә Әхмәтҗан кызы атасыннан карт Сәлимгә барган, ник тартышмаган?

Г а л и я. Шәригать аталарны баш иткән, хатыннарга качарга ясаган.

И б р а һ и м. Менә безне дә шул шәригать байларга кол иткән, безне дә байлардан качарга итеп закон чыгарылган. Шуның өчен без дә сезнең кебек ярты правалы булып торамыз.

С а д ы й к. Сезнең берлә сөйли-сөйли монда үз сүземне оныттым. Хәлил чыгып китмәсен, мин чыгыйм әле.

Ибраһим берлә Галия бераз бер-берсенә карап торганнан соң:

И б р а һ и м. Галия туташ! Сез нишләдеңез? *(Галия дәшми.)* Без агалы-сеңлеле үстек, әле дә шулай. Мин сезнең эшеңезне бер дә аңламыйм!

Г а л и я. Ибраһим абый! Зинһар, дип әйтәм, мине оялтма!

И б р а һ и м. Мин сезне оялтыр өчен әйтмим. Без синең берлә агалы-сеңлеле. Без синең берлә агалы-сеңлеле булуны синең этиең-эниең тели, шуның өчен дә без синең берлә агалы-сеңлеле булып калырга тиеш!

Г а л и я. Ибраһим абый! Әти-әни шуны теләгәнгә генә без шулай агалы-сеңлеле булып калырга тиешме? Хәзер генә үзеңез хатын-кызга ирек бирү тугрысында сөйләдеңез түгелме? Ул сүзләр аш янында гына сөйләнәмени?

И б р а һ и м. Мин, Галия туташ, үземнең фикеремне хатта да язган идем. Укыгансыздыр?

Г а л и я. Укып бетерә алмадым. Алай да күңелсез икәнен аңладым.

И б р а һ и м. Сез, Алла хакы өчен, Галия туташ, ул эшне онытыңыз. Мин сезнең гомергә агаңыз булып ка-

лыйм. Мин сезнең гомергә дустыңыз булып калыйм. Ләкин... бусы булмасын!

Галия. Ибраһим абый! Мин сезнең күңелеңез буш түгел икәнен белми идем, мин сезнең күңелеңез әллә кайчаннан бирле бер бәхетле кызның ихтыярында идекен белми идем. Хәзер инде ышандым. Без, без синең берлә *(еглаган тавыш берлә)* гомерлеккә дуст булып, гомерлеккә агалы-сеңлеле булып каламыз.

Ибраһим *(калтыраган тавыш берлә)*. Галия туташ, сез мине аңламадыңыз. Минем күңелемдә моңынча да беркемгә урын булганы юк. Минем сезнең берлә дуст булып кына калырга теләвем минем үземә гомерлек иптәш табуымнан дип уйлама, бөтенләй башка уйдан.

Галия. Әтиләр-әниләр нәкъ шуны теләмәвеннәнме? *(Ибраһим җавап бирми)*. Мине үзеңә тиң күрмәүдәнме?

Ибраһим. Галия туташ! *(Калтырап.)* Галия туташ! Сез мине аңламыйсыз!

Галия. Нидән? Сез ник безнең шул дустлык, шул якынлыгымызны тагы беркетәсеңез килми?

Ибраһим. Галия туташ! Эш сез уйлаганча гына түгел. Бу эшнең матур ягыннан битәр ямьсез ягы күп. Сез шуларны уйлаңыз!

Галия. Белерләр дисезме? Сәлим хаҗи кебек кешегә бирерләр дисезме?

Ибраһим. Барысын да дим! Сезнең бәхетсезлекеңезгә бик зур сәбәп булыр дип уйлыйм!

Галия. Шул гынамы? Мин барына да риза!

Ибраһим. Ул гына да түгел!

Галия. Тагы нәрсә бар?

Ибраһим. Бик күп, бик күп. Бу эшнең соңында җәһәннәм газабыннан каты эшләр бар! Буның соңында дәрьялар суы кадәре күз яшьләре бар! Менә мин шул яшьләрне түгәргә сәбәп буласым килми! Шул газапларның зобание буласым килми!

Галия. Шул гынамыни?

Ибраһим. Ул гына да түгел.

Аяк тавышы ишетелә. Ибраһим гәзитә ала.

Галия. Барысына да риза!

Ибраһим кулы берлә ишарә кылып Галияне туктата.
Гарифә килеп керә.

Гарифә *(Галиягә)*. Монда нишләп торасың, кызым?

Галия. Менә Ибраһим абзый гәзитә укыды, шуны тыңлап тордым.

Г а р и ф ә *(Ибраһимга карап)*. Син, Ибраһим, чын әллә авырумы? Әллә сез Галия берлә орышыштыгызмы? Күзеңә ачу галәмәтләре чыккан.

И б р а һ и м *(көчләнеп көлеп)*. Юк, Тугдык җиңги. Менә шуны укып көлештек кенә!

Шул арада Х ә л и л килеп керә.

Х ә л и л *(Ибраһимга карап)*. Ибраһим, бар әле син, Фәхри абзыйны йибәрмәсеннәр әле. Мине көттерсеннәр әле. Анарда йомышлар бар. *(Галиягә карап.)* Сез нәрсә бик кычкырып моназарә кылыштыгыз?

Г а л и я *(күзене төшереп)*. Юк, эти! Менә шундагы мәкаләне Ибраһим абзый укыды гына!

Г а р и ф ә *(Галиягә)*. Ибраһим синең агаң булса да, мөхәррәм агаң түгел, аның берлә әллә никадәр озын сүзләргә җитешергә ярамый, ул барыбер ят кеше.

Г а л и я. Әни, без бернәрсә дә сөйләмәдек.

Г а р и ф ә. Сөйләмәскә кирәк шул! Синең аның берлә эшең дә бик аз булырга кирәк. Ул барыбер шул Андрей кебек бер хезмәтче, аны аерып йөртүемез безнең яхшылыгымыздан гына! Син үзеңнең бай кызы икәнеңне онытмаска кирәк!

Х ә л и л *(Гарифәгә)*. Сез, хатыннар, бик тирәнгә керергә яратасыз. Әле бит бернәрсә булмаган, бергә гәзитә укыганнар икән, моннан соң менә укымаслар. Галия, бар, кызым, балкунга чәй хәзерлә! *(Гарифәгә.)* Әллә бер-бер нәрсә бармы?

Г а р и ф ә. Бернәрсә дә юк та, мин шул Ибраһимга исең китеп йөрүеңне яратмыйм. Шуның анасын яратмадым, үзен яратмыйм.

Х ә л и л. Ул бит хәзер бөтен кантурны алып бара, бөтен эшне башкара, тагы әтисе безне үз баласы итеп тәрбия кылган агамыз. Аны, шул инде, Андрейләр урынында йөртеп булмый.

Г а р и ф ә. Мин аның тасма телен яратмыйм, Алла сакласын, Галиягә әллә ниләр сөйләр.

Х ә л и л. Сөйләсә, тик сөйләсен!

Г а р и ф ә. Син шулай кызыңны теләсәң кем берлә теләсә нишләтеп йөрергә телисеңме? Алай булса, тагы бер ике-өч кеше алып кил!

Х ә л и л. Ибраһим үз кешең, дим. Ибраһимнан берни булмас дип ышанам. Булса тагын, әллә Ибраһим ярамый торган егетме?

---

*Моназарә* — бәхәс.
*Мөхәррәм* — хәрәм саналган, тыелган.

Г а р и ф ә. Менә әйтеп тә бетердең. Синең күңеләңдә, күрәсең, шул хәерчегә кызымны әрәм итү! Менә тотсын капчыгын, бердәнбер кызымны бирәмме соң? Ие, шул Мәрфугага килен булыр дип үстергән идем. Ул сүзне авызыңа да алма. Күңелеңә дә кертмә! Моннан соң монда Ибраһимыңны өстерәп кайтма! Әллә өйләрендә ашарга юк диме?

Х ә л и л. Алла, син бик ярсыдың!

Г а р и ф ә. Ярсымый, ул миңа бала ич!

Х ә л и л. Миңа бала түгелмени?

Г а р и ф ә. Син баланың кадерене белә торган кеше булсаң, шундый матамалларга бирергә уйлап тормас идең. Менә моннан соң актыгы булсын, кызымны Ибраһим янына чыгармыйм! Ишеттеңме, чакырма да!

Х ә л и л. Ярар, ярар, ярсыма! *(Шул арада Галия килеп керә.)*

Г а р и ф ә. Кызым, менә моннан соң Ибраһим берлә ашарга утырма! Ул синең агаң булса да, алар бик явыз кешеләр. Алла сакласын, анасы яисә исемеңне чыгара башлар, аңладыңмы? Ник дәшмисең?

Г а л и я. Ярар.

Г а р и ф ә. Бел, рөхсәт юк! Шакировларның җыен саяксандырагын бетерә алмассың!

Х ә л и л. Чәй өлгердеме?

Г а л и я. Өлгерде.

Хәлил берлә Гарифә чыга, Галия ялгыз кала.

Г а л и я. Бер яктан тегесе кыса, бер яктан болары кыса, менә юлын тап инде, гәзитә әйткәнчә, менә болар берлә тартыш инде! *(Исәпләп торып.)* Тартышам, тартышам! Актыгына кадәр тартышам!

П ә р д ә  т ө ш ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бер зур гына бакча күренә, бакчага таба тәрәзәсе караган өй. Җәйге төн. Ай яктысы гына бар. Г а л и я ялгыз.

Г а л и я *(тәрәзә төбенә утырган көенчә күккә карап)*. Төн нинди матур, нинди җылы, нинди тын! Йөрәгемнең сикерүеннән башка бернәрсә ишетелми. Уф, ничек күрешермен, ничек тагы сөйләшермен, аның боз

---

*Матамал* — төрле яктан җыелган, вак-төяк кешеләр.
*Саяк-сандырак* — бу урында: этрәк-әләм.

кебек йөрәген ничек эретермен! Ничек аны үземнең сөюемә, үземнең аңардан башка тора алмавыма ышандырырмын! Ничек үземнең бала түгеллегемне, үземнең аңлап йөргәнемне аңлатырмын! Ничек үземнең аның өчен һәр авырлыкка ризалыгымны белдерермен! Ничек бу матур төндә, бу энҗеләр кебек тезелгән йолдызлар алдында аягына тезләнеп, кулын үбеп, үземнең күңелемдәге бар уйны сөйләрмен! Ничек аның алдына ятып үземнең кайнар яшьләрем берлә башымдагы кайгыларымны, хәсрәтләремне юармын! Уф! Әнә, килә торгандыр ахрысы. *(Ерактан каравылчы шакылдавы ишетелә.)* Әнә шул, күренә, улмы? Улмы? Уф, йөрәгем сикерә, күреп сөйләшкәнемез юкка ике атна булды, никадәр хатлар яздым, никадәр ялынычлар йибәрдем, бу көнгә кадәр килергә риза булмады. Инде килә! Әнә килә! Уф, йөрәгем шатлыгыннан ярыла! *(Йөрәген тотып.)* Әнә, туктады! Әллә ул түгел? Әллә курка? Ибраһим! Ибраһим! *(Шул арада бакча арасыннан Ибраһим килеп чыга.)* Көтә-көтә йөдәп беттем. Уф! Ибраһим абый, ник бик озак тордың?

Ибраһим. Мин бик озак уйлаганнан соң гына килдем. Бакча янына ике мәртәбә килеп киттем. Өченчесендә дә, бәлки, китәр идем, синең тавышны ишеткәч, китә алмадым.

Галия. Ибраһим абый, син миннән ник куркасың? Ник ул кадәре мине ялындырасың? *(Ибраһимга.)* Кил монда, минем кулымнан тот, мин дә бакчага төшәм! *(Ибраһим акыртын гына барып кулыннан тота, Галия тәрәзәдән сикереп төшә.)* Ник синең кулың ул кадәре салкын? *(Ай яктысында йөзенә карап.)* Ибраһим абый, ник синең йөзең әллә нинди? Син ак киндер япкан кебек? Син нишлисең?

Ибраһим *(акыртын гына тын алып)*. Минме, мин, Галия туташ, үзем берлә сугышам. Минме, Галия туташ, минме? Мин, Галия туташ, хәзер ике! Бер Ибраһим монда килергә куша, бер Ибраһим килмәскә куша! Бер Ибраһим сиңа сөю хатлары язарга куша, бер Ибраһим синнән алган хатларны утка ягарга куша! Менә мин нишлим, менә ник битем киндер кебек ак, менә ник минем күзләрем тиле кешенеке кебек! *(Тын алып.)* Мин синнән ул хатны алганнан бирле йөдәп беттем, шул көннән бирле минем эчемдәге ике Ибраһим сугыша башлады. Бу көнгә кадәр берсе дә җиңә алганы юк. Бу көнгә кадәре кайсының фикере дөрестлеген дә белә алганым юк. Менә шуның өчен мин тиле кеше кебек йөрим. Шуның өчен мин сиңа һәрвакыт мәгънәсез хатлар язам. Менә шуңарга күрә монда килер өчен әллә никадәр гайрәт са-

рыф кылырга кирәк булды. Ахырдан синең берлә күрешеп сөйләшер өчен, сиңа үземнең актык сүземне әйтер өчен килергә уйладым. Менә, Галия, тыңла!

Галия. Тыңлыйм, тыңлыйм. Һәммәсен сөйлә.

Ибраһим. Мин уйладым, уйладым, башым катып бетте, очына чыга алмадым. Теге көнге аштан соң әниең безне аермаган булса иде, мин сиңа үземнең күңелемдә ни барлыгын сөйләргә башка юл таба алса идем, бүген монда килмәгән булыр идем.

Галия. Син шундый матур төндә, шундый матур йолдызлар яктысында минем берлә сөйләшәсең, минем берлә күзгә-күз калып аңлашасың килмәдемени?

Ибраһим. Әйтәм ләсә, бер Ибраһимның килде, берсенең — юк! Тукта, Галия, мин сөйлим, менә нәрсә! Бу эшне башламаган булсак, бик яхшы була иде, инде башлангач, очламый хәлемез юк. Без очламасак, эш үзе очлана. Менә нәрсә, син миңа ул кадәр тугры карама, Галия! Синең ул күз каравың минем күңелемдәге тагы ике Ибраһимны сугыштырырга тотына!

Галия. Ярый.

Ибраһим. Менә, Галия, нәрсә. Һәр эшнең ике ягы була. Файдалы ягы, зарарлы ягы. Мин менә монда синең өчен, үзем өчен кайсы ягы файдалылыгын, кайсы ягы зарарлыгын белә алмыйм. Уйлап кара, безнең бу эшемезне генә белсәләр дә, әниләрең нишләрләр иде, иртәгә үк Сәлим хаҗины эзләргә тотынырлар идеме? Менә мин, Галия, үземне шул җинаятькә сәбәп итәсем килми. Менә мин синең гомереңне әрәм итәсем килми!

Галия. Файдалы ягы, Ибраһим, менә хәзер сөйләшүләремезне файдага санамасаң, башка файда күрә алмыйм! *(Галия күзенә туп-туры карый.)*

Ибраһим. Галия! Минем күземә алай агулы күзең белән карама дим, минем сугышмый тора торган Ибраһимнарымны тагы оялтма дим!

Галия. Ибраһим абый, ник син үзеңне үзең алдарга телисең? Ник син минем кебек бер генә Галия булмыйсың? Менә мин берсеннән дә оялмыйм! Менә минем эчемдә ике Галия сугышмый! Менә күңелемдә бер Галия берлә бер Ибраһимнан башка бернәрсә юк! Ник син шуны аңламыйсың, ник син мине үзенең сөйгәне берлә бергә булу рәхәтеннән мәхрүм итәргә тырышасың? Син бит мине сөясең? Әнә күзең әйтә! Әнә мин хәзер синең бөтен күңелеңдәге уйларны китап укыган кебек укыйм, сөясең бит, Ибраһим?

Ибраһим *(нишләргә белмәенчә)*. Сөям, Галия! Сөям! Сине шулкадәр сөям, сине үземнән үзем көнлим! Сине

шулкадәр сөям, сине сөюем сиңа зарар китермәсен дип, сиңа белдермәскә тырышам! Хәзер, Галия, минем күңелемдәге теге Ибраһим җиңелде, мин үземнең уемны синнән яшерә алмадым! Сөям мин сине, сөям! *(Галиянең кулын алып үбә. Галия йөзеннән үбә.)*

Галия. Мин сине әллә кайчан белдем. Ләкин синең бу тиреслегең, синең бу гайрәтең минем гайрәтемне генә арттырды. Синең бу эшең минем алдымда синең бәһаңне генә арттырды. Мин хәзер синең чын кеше икәнлегеңә, синең гомерлек иптәш булырлыгыңа ышандым. Мин синеке, Ибраһим! *(Кочаклашалар.)*

Ибраһим. Галия, син мине җиңдең, син минем гакылымны алдың. Мин хәзер үземнең кем икәнлегемне оныттым, мин хәзер үземнең нишләгәнемне белмим, мин хәзер бу эштәнниләр чыгачагын аңлый алмыйм. Ләкин мин хәзер эчемдәге сугыштан котылдым. Эчемдәге революциядән котылдым. Мин хәзер ни күрсәм дә синең өчен күрергә риза. Мин хәзер синең рәхәтең өчен үземне корбан кылырга разый! Уф, Галия, мин ниләр уйладым, ниләр уйладым, ике атна буе, сине никадәр сөйсәм дә, үземне үзем сөймим дип ышандырмакчы булдым. Сине никадәр сөйсәм дә, синең хатларыңны күкрәгемдә йөртсәм дә, сиңа шундый суык хатлар яздым. Мин, Галиям, шулай итеп сиңа файда итәм дип белдем, мин шулай итеп синең яшь мәхәббәтеңнең утын сүндерәм дип белдем. Менә мин, менә бүген дә сиңа шуны сүндерергә килдем, чыдый алмадым, синең мәхәббәт утында үзем яндым. Мин хәзер синең колың! Ни теләсәң, минем берлә шуны эшлә!

Галия. Ибраһим! Миңа кол кирәкми! Миңа дуст кирәк! Син минем иптәшем, син минем гомерлек юлдашым! Мин синең, бүгенге кебек, тын, җылы төндә дустың булган кебек, җәһәннәм кебек дөньяның кайгыларында да мин синең иптәшең! Аңладыңмы, Ибраһим, мин хәзер синең теге мине яратмый торган Ибраһимны җиңдем. Күңелеңнең ул урынына үзем кереп утырдым. Хәзер без бер, хәзер синең берлә без бер. Син Ибраһим — Галия! Мин Галия — Ибраһим! *(Тагы кочаклашалар. Каравылчы шакылдавы ишетелә. Аерылалар да.)* Әйдә менә шунда утырыйк. *(Бер агач төбенә утыралар.)*

Ибраһим *(күккә карап)*. Кара, нинди матур! Кара, Галия, нинди тын! Агачлар нинди моң! Һәммәсе дә безнең шатлыгымыз берлә шатланган кебек күренә, һәммәсе дә безнең шул серләремезне тыңлаган кебек була!

---

*Тиреслек* — кирелек.

Г а л и я *(Ибраһимның кулын тотып)*. Менә син шул кичне күрмәс өчен, менә шул кулларны тотмас өчен, шул авызларны үпмәк өчен *(Үзе Ибраһимны үбә.)* ике атна буе качып йөрдең!

И б р а һ и м. Галия! Минем әүвәлге гаепләремне минем йөземә бәрмә. Минем кылган эшләремнең һәммәсе дә синең рәхәтең исеменә, синең сәгадәтең исеменә кылынган иде. Ул вакытта мин синең һәр кайгыга каршы торырлык гайрәтең барлыгын, үзең теләгән һәр эшне булдырырга тырышырлык көчең барлыгын белми идем. Мин синең үз хакың өчен тартышырга җитәрлек ирлегең барлыгына ышанмый идем. Хәзер ышандым, хәзер мин, син минем берлә булганда, үземнең һәр авырлыкка чыдый алуыма ышанам. Хәзер мин синең берлә бергә булыр өчен әллә нинди зур фидаилыкларга хәзерлегеңне күрдем. Мин хәзер сине әллә нинди Сәлим хаҗилар берлә куркыта алмауларына ышандым.

Г а л и я. Минем хурланганым моңынчага кадәр синең миңа бала дип каравың иде. Синең миңа күз карашыңның үзгәрүе миңа яңы гайрәт бирә. Мин моннан соң үземнең теләгемне булдырыр өчен яңа гайрәт берлә тотынамын, мин хәзер үземнең хакымны саклар өчен элгәрегедән артык итеп тартышамын! Беләмсең, Ибраһим! Мин моңынча ниләр уйладым? Мин барысын да уйладым.

И б р а һ и м. Нәрсәнең барысын да?

Г а л и я. Үземезнең киләчәгемезнең барысын да. Син әнинең сине яратмавын беләмсең?

И б р а һ и м. Мин үземне Шакировларның бөтен аксак хатыннары яратмый дип беләм.

Г а л и я. Ул үлсә дә мине сиңа бирергә риза булачак түгел! Әхмәди абзыйның кем икәнлеген беләмсең? Ул да сиңа бирүне бер зур хурлыкка санаячак!

И б р а һ и м. Садыйк абзый?

Г а л и я. Садыйк абзый ул гакыллы карт.

И б р а һ и м. Әтиең?

Г а л и я. Әтине белер хәл юк! Ул, бер карасаң, бертөрле, бер карасаң, икенче төрле. Әни аны үз ягына борыр!

И б р а һ и м. Алай булса, өметләнергә урын юк.

Г а л и я. Тартышмасаң, юк! *(Шул арада агачлар арасында бер карчык күренә, ул ышыкланып тыңларга тотына.)* Ләкин, минемчә, бар! Син ни әйтерсең?

И б р а һ и м. Җә, сөйлә!

Г а л и я. Әти Казаннан кайткач ук, Садыйк абзыйны җаучыга кушарга кирәк, бирсәләр бик яхшы, бирмәсәләр — качарга!

Ибраһим. Аларның кулында бөтен полиция, алар хәзер тотарлар да мине бер-бер гаеп берлә төрмәгә ябарлар, сине көчләп бер-бер Сәлим хаҗи кебек кешегә бирерләр.

Галия. Мин бармыйм!

Ибраһим. Алайга калгач, алар сиңа карамыйлар.

Галия. Ничек алар безне тотып алалар, ничек синең кебек кешегә гаеп тага алалар!

Ибраһим. И, акча булганда безнең... берлә, теләсәң кемне карак итеп була. Теләсәң кемне ут салучы итеп була. Тагы, иң җиңеле — сәяси дип була! Сезнең ул Әхмәди абзыеңыз андыйлардан курка да, ояла да торган кеше түгел.

Галия. Бер-бер муллага барып никях укытсак?

Ибраһим. Муллалар аларның үз кулында, хәзер бер ривайәт табар да аерып та алыр.

Галия. Ул нинди ул, барысы да акчага сатыла! Акчага сатылмый торган нәрсә бер дә юкмыни?

Ибраһим. Акчага сатылмый торган нәрсәме? Бар.

Галия. Нәрсә?

Ибраһим. Чын сөешү, дөрест мәхәббәт! Менә шул безне коткарса коткара!

Галия. Аны үзен әллә нинди муллаларның ялганнарыннан, залимнең золымыннан, әтиләрнең җәбереннән сакларга кирәк бит! Шуңарга юл тап!

Ибраһим. Таптым.

Галия. Нәрсә?

Ибраһим. Менә нәрсә! Шәригатьтә дә, законда да, ир берлә хатын ике шаһит алдында берсе берлә берсе ирле-хатынлы булып торуга риза булсалар, беркем дә аера алмый.

Галия. Шулаймы? Дөрестме? Әйдә хәзер Садыйк абзыйны уятыйк та, без ирле-хатынлы дип әйтик!

Ибраһим. Ашыкма! Мин шуңарга яраклы шаһитлар табыйм! Аннан соң бер-ике көннән эшне бетерермез.

Галия. Бүген ник ярамый?

Ибраһим. Бүген кемне табасың! Ул син тапкан кеше тагы акчага сатыла.

Галия. Андрей ярыймы? Наташа ярыймы?

Ибраһим. Алар ярамый!

Галия. Синең шуңарга ярарлык кешеләрең дә юкмыни?

Ибраһим. Бар да, хәзер ничек кешене уятып аңлатасың, ничек аларны алып киләсең!

Галия. Алар кантурда кунмыйлармыни?

Ибраһим. Андасын анда, Исмәгыйльгә, Сәгыйтькә ышанырга ярый... Фәйзуллага ышанып бетәр хәл юк.

Галия. Инде ни булса булыр, бар, зинһар, алып кил! Минем күңелем курка, бүгеннән калдырасым килми.

Ибраһим. Синең сүзең миңа закон, Галия! Алай булгач, язышырга кирәк, шул язуга кул куярмыз. Алардан да кул куйдырырмыз.

Галия. Кәгазь, кара алып чыгыйммы?

Ибраһим. Ярый, алай булса алып чык, аннан ары мин барып тегеләрне алып килермен!

Галия. Мине тәрәзәгә менгереш. *(Галия тәрәзәгә менә. Ибраһим көтеп тора. Бераздан.)* Мә!

**Ибраһим кәгазь, кара, каләм ала. Галияне күтәреп төшерә. Карчык һаман тыңлап тора.**

Ибраһим *(күккә карап)*. Көн дә яктыра икән. Менә мин шуны язып калдырыйм, син шуннан күчереп тагы бер кәгазьгә язарсың! Шул кәгазьгә алардан кул куйдырырмыз. Син язган кәгазь миндә калыр, мин язган — синдә калыр.

**Ибраһим язып бирә, үзе тиз генә чыгып китә.**

Галия. Тиз кил!

Ибраһим. Хәзер, монда гына.

Галия. Алар булмасалар, кемне булса да алып кил! *(Язарга тотына.)* Язып та бетердем, килсеннәр генә! Көн дә яктырды. *(Каравылчы тавышы ишетелә. Галия үләннәрне тотып карап.)* Чык та төшкән икән! Озакка калмасалар ярар иде.

**Шул арада Ибраһим, аның артыннан өч кеше киләләр.**

Карчык. Каһәр сукканнар икән, болар әллә нишләмәкче булалар. Барып әйтим! *(Югала.)*

Ибраһим. Менә алып килдем, йокыларыннан да уянмаганнар.

Галия. Рәхмәт килүләренә. Менә мин язып бетердем.

Ибраһим *(тегеләргә карап)*. Менә, иптәшләр, эш нидә: без Галия туташ берлә гакед ясыймыз, сезне шаһит булырга чакырдык! Моны таныймсыз?

Егетләр. Таныймыз.

Галия. Кем?

Егетләр. Хәлил абзый кызы.

Ибраһим. Алай булса, менә мин укыйм, шул кәгазьгә без барымыз да кул куярга тиеш. *(Укып.)* «1906 нчы елда, 5 нче июньдә без Уфа губернасы, Уфа өязе Чатыш

вулысы Чатыш авылының Ибраһим Габделсамат угылы Шакиров берлә Галия Хәлил кызы Шакирова үземезнең ризалыгымыз берлә йөз сум мәһәр бәрабәренә түбәндәге шаһитлар хозурында гакед кылыштык. Шул гакедне шул шартлар берлә кабул иттем. *(Галия дә, Ибраһим да кул куялар.)* Галия Хәлил кызы Шакирова. Ибраһим Габделсамат угылы Шакиров. *(Егетләр кул куялар.)* Исмәгыйль Миңнекәев, Сәгыйть Сәмиев, Фәйзулла Сәйфуллин».)

Ибраһим берсен алып, күкрәк кесәсенә тыга, Галия дә кесәсенә тыга.

Г а л и я. Рәхмәт, сезне шуның өчен мәшәкатьләдек, бик рәхмәт!

И б р а һ и м. Рәхмәт, егетләр!

И с м ә г ы й л ь. Туйдан калдырмаңыз!

Г а л и я. Калдырмамыз, калдырмамыз!

С ә г ы й т ь. Мөбарәк туйлар булсын! Без киттек.

И б р а һ и м. Хушыңыз!

Егетләр китәләр. Шул арада Ә х м ә д и күренә. Аз гына карый да, бик кызуланып югала.

Г а л и я. Бетте, һәммәсе булды. Без хәзер ирле-хатынлы, безне хәзер шайтанның үзе дә аера алмый, кил, җаным, бер үбим!

И б р а һ и м *(Галияне кочаклап)*. Чын дустым! *(Үбешәләр.)* Карасана, Галия, нинди көн матур, карасана бу агачларга, шул матур чыкка, ис китмәслек түгел! *(Шул арада казыклар күтәргән кешеләр килеп агач артына ышыкланалар.)* Кайтырга вакыт, Галия, җибәр, көн яктырды, күрешермез әле.

Г а л и я *(чуп иттереп үбеп)*. Тагы бер үбим дә китәрсең! Тагы бер үбим! *(Тагы үбә.)*

И б р а һ и м. Мин дә бер үбим. *(Үбә.)* Хуш! *(Кулларыннан тотышалар да тагы кочаклашалар.)*

Шул арада Ә х м ә д и: «Тот!» — дип кычкыра, Ибраһим йөгерергә тотына. Теге кешеләр күсәкләр берлән аның артыннан йөгерәләр. Галия сикереп тәрәзәгә менә. Әхмәди револьвердан атарга тотына. Кешеләр: «Тот! Тот!» — дип кычкырышалар. Револьвер тавышы ишетелә.

Ә х м ә д и. Урларга килгән! Урларга килгән!

К а р ч ы к *(килеп чыга)*. Урларга, урларга!

К е ш е л ә р н е ң  б е р с е. Ие, урларга! *(Кычкырышып көләләр.)*

П ә р д ә  т ө ш ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хәлил байның өе. Каршыда Галия бүлмәсе. Ике якта ике ишек.

Г а р и ф ә *(ялгыз гына. Галиянең ишеген кага)*. Галия! Галия! *(Галия дәшенми. Гарифә кычкырыбрак кына.)* Галия, димен, Галия! Оятсыз, оятсыз! Йөземезгә кара якты да ишек тә ачмый! Галия! *(Дөбердәтә)*.

Г а л и я *(ишек артыннан)*. Йөдәтмә! Ачмыйм!

Шул арада бер а к с а к  х а т ы н таякка таянып керә.

Г а р и ф ә *(аңарга карап)*. Менә, Хәдичә, кара инде, бикләнгән дә, ишеген дә ачмый!

Х ә д и ч ә. Уф Алла! Бу оятка ничек түзик! *(Ишеккә килеп.)* Галия! Галия! *(Акыртын гына утыра.)* Син, Тугдык җиңги, ничек карамадың? Ничек кеше күзенә күренербез?! Галия! Галия! Зинһар әйтсәнә, Тугдык җиңги, бу хәбәр бөтен авылга җәелдеме?

Г а р и ф ә. Белмим! Белмим, Хәдичә! Менә кара инде син баланы, нинди мәшәкатьләр күреп тәрбия кыласың! Никадәр аның өчен авырлыклар күтәрәсең, ул сине карт көнендә бөтен галәм алдында йөзеңне кара итә! Бу хурлыкка ничек чыдыйм! Бердәнбер кызың әллә нинди матамал, хәерче берлә йөрсен, имеш! Бу нинди хурлык, бу нинди гөнаһ шомлыгы!

Шул арада Ф ә х р е н и с а килеп керә.

Ф ә х р е н и с а. Уф Алла! *(Гарифәгә карап.)* Кая үзе? Каһәр суккан! *(Гарифәгә.)* Син гаепле! Син! Ана булып торасыз шунда, бердәнбер кызыңны карый алмадың!

Г а р и ф ә. Зинһар, йөрәгемә җәрәхәт салып утырмасана!

Ф ә х р е н и с а. Безгә җиңелмени? Шакировларның кызлары ябышып чыкты дигән сүзне ничек ишетик!

Х ә д и ч ә. Әле алай дип кем әйткәне бар соң?

Ф ә х р е н и с а. Бар да әйтә! Бөтен авыл сөйли. Әле мин монда килгәндә Әхмәтсафалар «туйга бара» дип калдылар.

Г а р и ф ә. Язмышың булгач нишлисең, без күрәсене әллә кем күрми шул инде!

Шул арада С о р у р килеп керә.

С о р у р *(Гарифәгә)*. Әнкәй! Асламчы хатын бар!

Ф ә х р е н и с а. Таптың сүз! Тагы бер-бер йомышың юкмы? Шуның берлә генә маташа торган вакыт!

Г а р и ф ә *(Сорурга карап)*. Шулар баламны бозып бетерделәр! Шул марҗалар баламның башын ашадылар!

Ф ә х р е н и с а. Ул киленме? Килен ул синең йортыңның бөтен ямен ала! *(Сорурга карап.)* Ник син анаңа әйтмәдең?

С о р у р. Мин бернәрсә дә белмәдем.

Г а р и ф ә. Белмәдең, ялганлама, черегән марҗа!

Х ә д и ч ә. Ник син, ичмасам, миңа гына әйтмәдең? Беләмсең, син бөтен нәселемезне буядың бит! Кеше күзенә күренерлегемезне калдырмадың!

С о р у р. Мин нишләдем? Мине әни үз бүлмәмнән чыкмаска кушты, мин чыкмадым. Мин Галиянең нишләгәнен кайдан белим?

Ф ә х р е н и с а. Кара, зәһәр, ни сөйли!

Г а р и ф ә. Шул, бар да бер Ибраһим нәселе, бар да бер килмешәк! Оятсыз! *(Сорур чыгарга тели.)*

Х а т ы н н а р *(ачуланып)*. Кая барасың? Ник качасың?

Г а р и ф ә. Гаебең чыктымыни? И оятсыз! Оятсыз! Мин сине кеше иттем. Мин сине угылыма алдым. Син, син, беләмсең, хәерче кызы идең бит! Без алмаган булсак, тутаң кебек кыз булып гомереңне үткәрә идең бит! Син яхшылыкны кайтардыңмыни?

С о р у р. Мин бернәрсә белмим, ник миңа бәйләнәсез.

Ф ә х р е н и с а. Тагы каршы сөйли. Шакировларның малына үзе хуҗа булганы җитмәгән, әллә нинди матамал энеләрене дә хуҗа ясамакчы була! Безнең Шакировларның малы зәкятлы мал! Безнең малымыз суга да батмый, утта да янмый. Ишеттеңме? Оятсыз!

С о р у р. Ибраһим ник минем энем булсын! Ул, миңа карендәш булган кебек, Хәдичә апага да карендәш, Галиянең үзенә дә карендәш, ник миңа сылтыйсыз!

Х ә д и ч ә. Тапты сүз, ул ник миңа карендәш булсын!

С о р у р. Аның әбисе берлә синең әниең бертуган!

Х ә д и ч ә. Түгел! Түгел! Күргәнем юк, ишеткәнем юк! Алар берсе дә миңа карендәш түгел! Аның анасы каһәр суккан, аның анасы сихерче!

Ф ә х р е н и с а. Алар нәселләре берлә сихерче! Нәселләре берлә зиначы! Аның үлгән тутасы аз гына ябышып чыкмады.

Г а р и ф ә. Кызымны да шул сихерләгәндер әле.

Ф ә х р е н и с а. Шул, каһәр суккан, шул! *(Сорурга күрсәтеп.)* Менә монысы ара йөргән! Елан!

Г а р и ф ә *(өстәлне кагып)*. Мин сине, Алла теләсә, Алла теләсә, рәхәт күрсәтмәм! Мин сине үз дәүләтемә баш ясап калдырмам! Мин сине, сары марҗа, кеше итеп калдырмам!

Ф ә х р е н и с а. Шулкадәр эшләрдән соң шуны үз өеңдә тотарга ярыймы? Ул әле әлләниләр эшләр. Аларның нәселе зәһәр!

Г а р и ф ә. Калдырмыйм, калдырмыйм! Атасы гына кайтсын, аертам! Оятсыз, сары марҗа!

Н а т а ш а килеп керә. Аңарга сүз әйтергә дә бирмиләр.

Х ә д и ч ә. Менә шул берсе! Оятсыз, чукынчык! Менә шул сөйдерүче!

Ф ә х р е н и с а. Шул, каһәр суккан! Шул, әллә нинди керәшен карчыкларыннан сихер ташучы!

Г а р и ф ә. Син ник әйтмәдең, курнус марҗа?

Н а т а ш а. Нәрсәне?

Х ә д и ч ә. Кара, каһәр суккан, белмәгәнгә салына! Зәһәр марҗа!

Ф ә х р е н и с а. Чәчеңне йолкып бетерермен! Ник син хат ташыдың?

Х ә д и ч ә. Син ник сихерләдең?

Г а р и ф ә. Ник син кызымның башын харап иттең! Ник дәшмисең?

Шул арада акыртын гына Сорур чыгып китә.

Ф ә х р е н и с а. Син, симердеңмени, курнус марҗа?

Х ә д и ч ә. Син, маеңа чыдый алмый башладыңмыни?

Г а р и ф ә. Син шул хөрмәткә риза булмадыңмыни?

Н а т а ш а. Мин бернәрсә белмим!

Г а р и ф ә *(өстәл кагып)*. Ялганлама!

Ф ә х р е н и с а. Кемнән сихерләттең?

Х ә д и ч ә. Ибраһимнан күпме акча алдың?

Г а р и ф ә. Кызымны күпмегә саттың?

Ф ә х р е н и с а. Ник дәшмисең? *(Натašaның янына барып, чәченнән тартып.)* Ник әйтмисең? *(Чәченнән өстерәп Гарифәгә китерә. Үзе чәченнән тотып.)* Әйт! Курнус марҗа! Күпме хат ташыдың? Күпме акча алдың?

Х ә д и ч ә. Ничә кич Ибраһимны чакырып китердең?

Н а т а ш а *(елый. Елаган тавыш берлә)*. Менә шул кояштыр, бернәрсә белмәдем.

Г а р и ф ә. Ялганлама! *(Ул да чәченнән тартып.)* Эм-м-м, каһәр суккан, дуңгыз! *(Шул арада бөтенләй селкенеп китеп.)* Алла, Алла, аягым, аягыма басты курнус марҗа! Аягыма басты! *(Үзе Наташаны кыйный. Шул арада Ә с м а килеп керә.)*

Ә с м а *(Гарифәгә килеп)*. Хәлил абзый хәзер кайтадыр, ди, телеграм килгән. Тагы, ишеттегезме, Исмәгыйль Габдерахманга сөйләгән. Габдерахман Миңнесафа җиңгигә, Миңнесафа җиңги Хәлимә кодачага

әйткән, аларның горбун кызлары безнең Сажидәгә сөйләгән, алар алдым-бирдем ясашканнар ди.

Гарифә. Минем кызым шул хәерче берлә алдым-бирдем ясашкан диме?

Фәхренисა. Безнең бөтен нәселемезне мыскыл итеп Галия шул матамал берлә алдым-бирдем ясашкан диме?

Гарифә. Уф! Уф! Йөрәгемә чыдый алмыйм. Ул ни дигән сүз, алдым-бирдем ясашкан! *(Наташа акыртын гына чыгып китә.)*

Әсма. Ясашкан, ясашкан! Галия Ибраһим берлә ясашкан! Исмәгыйль Габдерахманга, Габдерахман — Миңнесафа җиңгигә, Миңнесафа җиңги Хәлимә кодачага әйткән, аларның горбун кызлары безнең Сажидәгә әйткән: Ибраһим Галия берлә алдым-бирдем ясашкан!

Гарифә. Фәхрениса абызтай, Хәдичә! Бар, зинһар, сора шул мәлгун кыздан, дөрестме? Бар, зинһар, сора. Уф Алла, уф Алла, бусы гына җитмәгән иде, тагы алдым-бирдем ди, алдым-бирдем!

Әсма. Ие, алдым-бирдем ясашкан. Исмәгыйль Габдерахманга сөйләгән, Габдерахман — Миңнесафа җиңгигә, Миңнесафа җиңги — Хәлимә кодачага, Хәлимә кодачаларның горбун кызлары безнең Сажидәгә әйткән, алдым-бирдем ясадылар, дигән!

Фәхрениса *(Әсмага)*. Ярар инде, лыгырдама!

Әсма. Ышанмыйсызмы әллә? Валлаһи менә, Исмәгыйль Габдерахманга әйткән, Габдерахман — Миңнесафа җиңгигә, Миңнесафа җиңги — Хәлимә кодачага, аларның горбун кызлары безнең Сажидәгә әйткән, валлаһи менә, Галия берлә Ибраһим алдым-бирдем ясадылар, дигән!

Фәхрениса. Җитәр, дим, йөдәтмә горбун кызың берлә! *(Хәдичәгә.)* Әйдә Галиягә! *(Ишеккә баралар.)* Галия! Галия! И оятсыз! Ач ишекне! Ач ишекне! Анаңны кызганмыйсыңмы? И оятсыз, ач ишекне!

Хәдичә. Ач, Галия! Ач, Галия, йомышымыз гына бар. Ач!

Әсма. Галия, ач, ач!

Гарифә *(утырган йиреннән)*. Ач! Ач, кызым, орышмыймыз? *(Галия дәшми.)*

Фәхрениса. Ач, йөзең кара кыз! Ач! Ник анда качып ятасың? Алдым-бирдем ясадыңмы? Ач!

Әсма. Ышанмыйсызмыни? Ясаган инде, Исмәгыйль Габдерахманга әйткән, Габдерахман — Миңнесафа җиңгигә...

Фәхрениса *(Әсманы төртеп йибәреп)*. Кит, юкны сөйләмә!

Ә с м а. Ник мине төртәсең?

Ф ә х р е н и с а. Әллә сине төртмәскә, син падишаһ хатынымы? Син кем соң? Хәерче!

Ә с м а. Син кем соң? Син — себерке! Син — ана мачы!

Ф ә х р е н и с а. Син — хәерче! Синең атаң каравылчы булган!

Ә с м а. Синең анаң зиначы булган! Синең тутаң ябышып чыккан! Син әллә кемнәр берлә себерелгән!

Ф ә х р е н и с а *(Әсманың якасыннан тотып)*. Мин кем белән себерелгән? Мин кем берлә себерелгән? Күрдеңме?

Ә с м а. Себерелгән, себерелгән, бөтен авыл берлә себерелгән!

Г а р и ф ә. Туктаңыз, туктаңыз, сез нишлисез, монда сезнең генә тавышыңыз кирәк иде, туктаңыз, Фәхрениса абыстай, син тукта!

Хәдичә аксабрак кына Әсманы аерып ала.

Ә с м а. Себерке, себерке!

Ф ә х р е н и с а. Хәерче! Килгән вакытыңда өстеңә күлмәгең дә юк иде, хәерче!

Г а р и ф ә *(кычкырып)*. Туктаңыз дим! Башыма кабып бетте, туктаңыз!

Х ә д и ч ә *(Фәхренисага)*. Син карт бул, Фәхрениса абыстай, аңарга карама, ул ни сөйләгәнен белми!

Ә с м а. Бик белә. Синең дә кем икәнеңне бик белә. Син дә әллә кем булма! Күптәнме әле, яныңа әллә кемнәрне кертеп кундырдың!

Х ә д и ч ә. Менә тиле! Инде миңа бәйләнде!

Ә с м а. Мин тиле булсам да, әлхәмдүлиллаһ, ир өстенә ир тотмыйм!

Г а р и ф ә *(Әсмага)*. Әсма, син нишлисең? Монда синең тавышың тансыкмыни? Оршышасың килсә, өеңә кайтып оршыш!

Ә с м а. Алла, бик зур булган икәнсең! Син кем булдың соң? Хәлил бай хатыны ди торгандыр, мин синең кем икәнеңне беләм, синең атаң фидия козгыны, син фидия ашап үскән!

Г а р и ф ә. Теләсә ничек үссен! Мин, синең шикелле, котырган эт кебек, теләсә кем берлә оршышмыйм.

Ә с м а. Оршышыр идең дә, көчеңнән килми шул, минем кызым ябышып чыкмады шул. Минем кызым әллә нинди хәерчеләр берлә алдым-бирдем ясамады шул!

Г а р и ф ә *(өстәл сугып)*. Чык, хәерче марҗа, өемнән, күземә күренмә!

Ә с м а *(урыныннан торып)*. Бик исем китә! Сезне

күрмәенчә тора алмам, синең кызың берлә хәерче киявеңне күрми тора алмам!

Гарифә. Минем киявем юк, чык!

Әсма *(ишеккә җитеп).* Галия берлә Ибраһим алдым-бирдем ясаган, Исмәгыйль Габдерахманга әйткән! Габдерахман Миңнесафа җиңгигә...

Гарифә. Чык, хәерче марҗа!

Әсма сөйләнә-сөйләнә чыгып китә.

Гарифә. Менә каһәр суккан, ниләр сөйли!

Хәдичә. Шыр тиле!

Фәхрениса. Алты-биш! *(Тагы дөбердәтә башлап.)* Ач, Галия! Барыбер ачабыз, ач, ач!

Хәдичә. Ач, Галия!

Фәхрениса. Ачмаса ачмасын әле, мин кисәү алып килеп ачыйм әле! *(Чыгып китә.)*

Гарифә. Хәдичә, сора, алдым-бирдем ясаганнар диме?

Хәдичә. Галия, алдым-бирдем ясадыңмы? *(Галия дәшми.)*

Шул арада Фәхрениса кисәү, пумала, табагач алып керә. Кисәүне күтәреп бик каты дөбердәтә.

Фәхрениса. Ач, ач! *(Ишекнең тоткасына кисәүне эләктереп тартырга тотына.)* Хәдичә, тартыш! Тартыш! *(Хәдичә килеп тартышырга тотына.)* Ач, Галия, ач!

Гарифә. Катырак тартыңыз, катырак!

Шул арада ишек ачылып китә, ике хатын да егылып китәләр. Пумалалар дөбердәп төшә.

Фәхрениса. Каһәр суккан кыз, кулымны авырттырды!

Хәдичә. Алла, аягым, Алла, аягым!

Галия тагы ишекне яба башлый. Ашыгып ишеккә Гарифә килә. Хатыннар торалар, тартышырга тотыналар, Галия кертмәскә тели. Болар керергә тырышалар. Шул арада Хәлил кайтып керә. Аның берлә бергә Садыйк керә.

Хәдичә. Ирләр кайтты.

Хатыннар чабышырга тотыналар. Хәдичә пумалага абынып егыла. Фәхрениса өстәлне аудара. Гарифә подносларны җимереп төшерә. Мендәрләр җимерелә. Бөтен өй туза. Хәлил берлә Садыйк исләре китеп карап торалар.

Садыйк. Бу ни бу?

Хәлил. Белмим!

Галия тагы ишеген бикләп куя.

Садыйк. Болар Галия берлә бер-бер эш эшләгәннәрдер ахры.

Хәлил. Белмим, белмим! Аптыраган үрдәк күлгә күте берлә чума, ди. Бу пумалалар берлә нишләгәннәрдер

Садыйк *(утырып)*. Буласы эш булган, Хәлил. Эшне озынга сузмаска кирәк, мин әйткәнчә эшләргә кирәк.

Шул арада Наташа кереп, пумалаларны алып чыга.

Хәлил. Белмим! Белмим! Эш болайга киткәч, белмим! Мин егетне ярата идем. Мин күңлемнән һәрвакыт шул уйда идем. Үзеңә дә мәгълүм. Ләкин хәзер ничек итеп ул эшкә риза булмакчы буласың!

Садыйк. Эш әле берни дә булмаган, эшне әле үземез теләгәнчә йөртеп була. Әхмәди хатын-кыз сүзенә карап тавыш чыгарып кына бераз ашыккан!

Хәлил. Берни булмаган кая! Карт көнеңдә кызыңны тотсыннар әле! Ул бик кечкенә эшмени?

Хатын-кыз ягыннан дөбердәтәләр. Хәлил ишеккә бара.

Гарифә *(ишек артыннан)*. Алар алдым-бирдем ясаганнар, ди.

Хәлил. Кем әйтте? Юк сүз!

Гарифә. Дөрест, дөрест, бөтен авыл сөйли! Исмәгыль әйткән! Исмәгыйль — шаһитлары, ди.

Садыйк. Ул сүз дөрест булса, эш тагы башка. Хәлил, эшне күркәм вакытында бетерергә кирәк! Мин Мәрфуга җиңгигә барып әйтим. Син хәзрәтләрне алдыр.

Гарифә *(ишек артыннан)*. Минем сихерче Мәрфугага бирергә кызым юк! Кызың күп булса, үзең бир!

Садыйк. Мин, килен, сиңа зарарга сөйләмим. Алдым-бирдем дә булгач, хәзер бирсәң-бирмәсәң, кыз сиңа түгел! Эшне күркәмлек берлә бетерергә кирәк.

Хәлил. Белмим, белмим! Минем башым катты.

Гарифә *(ишек артыннан)*. Минем андый хәерчеләргә бирергә этем балаламаган әле! Авызыңызга да алмагыз!

Садыйк. Килен, килен! Кызуланма! Хәзер эш беткән, кыз синең кулдан киткән! Әгәр ул сүз дөрест булса, кыз хәзер Ибраһим хатыны! Яхшылык берлә туй итәргә кирәк! Ибраһим кемгә дә ярарлык егет! Хәлил! Озак уйлама. Пожарны чаткы вакытында бастырмасаң, зурайгач бастыру авыр булыр. Минем сүземне тыңлаңыз!

Гарифә *(ишек артыннан)*. Юкны сөйләмә дә, бирмим, бирмим!

Садыйк. Килен, килен! Уйлап кара, кызыңның теләве шул булгач, ни дип бирмим дисең? Ул сиңа бала түгелмени? Син аның рәхәт күрүен көнлисеңмени?

Гарифә. Бирмим! Бирмим дигәч бирмим!

Хәлил. Мин аптырадым. Мин әлдә әле алдым-бирдем булуына ышанмыйм! Бар да хатын-кыз сүзедер дим!

Гарифә. Анысы дөрест, дөрест. Әле тагы менә монда бер хатын килде. Ул Сәгыйтьтән ишеткән, ул да алдым-бирдем ясадылар, дигән.

Хәлил. Галия кая?

Гарифә *(ишек артыннан)*. Күрше бүлмәдә.

Хәлил *(барып ишекне кага.)* Галия, Галия! *(Галия ачмый.)*

Гарифә. Без көн буе ялындык, ачмый!

Садыйк. Хәлил, кая мин барып карыйм. Син аңардан нәрсә сорамакчы буласың?

Хәлил. Әнә шул алдым-бирдем тугрысында.

Садыйк. Ярый, мин керим! Сез килен бикә берлә сөйләшеңез. Минемчә, эшне тиз бетерергә кирәк, ахырдан үкенерсең. *(Килеп ишекне шакый.)* Галия, Галия!

Галия *(ишек артыннан)*. Нәрсә?

Садыйк. Бүлмәңә мине керт! Йомышым бар!

Галия. Бүтән кеше юкмы?

Садыйк. Үзем генә!

Галия ишекне ача, Садыйк керә, монда Гарифә чыга.

Хәлил. Аптырадым, әллә бирикме? Садыйк абзый безгә зararга йөри торган кеше түгел. Ул да, бирү мәслихәт, ди. Тагы алдым-бирдемнәре дә булса?

Гарифә. Алдым-бирдемнәре түгел, җәһәннәмнәре булсын, мин бирмим! Минем андый сихерче хатыннарга килен була торган кызым юк!

Хәлил*. Алдым-бирдеме булса, аны нишлисең?

Шул арада Әхмәди керә.

Гарифә. Әйтәм ләсә, алдым-бирдеме түгел, шайтаны булсын, мин бирмим!

Әхмәди. Ул ни дигән сүз! Кемгә бирергә телисез? Шул жуликкамы? Аңар кызымны түгел, мин этемне дә бирмәм. Аз гына соңгарак калдым, мин аңа кирәген бирә идем.

Хәлил. Алдым-бирдеме бар ди!

Әхмәди. Булсын, булсын! Бер түгел, йөз булсын!

---

* Оригинал нөсхәдә бу урында ялгыш «Садыйк» дип язылган.

Хәлил. Шәригать, ахрысы! Алар хәзер ирле-хатынлы!

Әхмәди. Шәригать! Ул нинди шәригать!

Гарифә. Ул нинди ул ата-анасыннан рөхсәтсез шәригать!

Әхмәди. Уйлап та карама! Бирмимез. Эш анда түгел, ул малайны ничек сабак укытырга кирәк!

Гарифә. Каһәр сукканны үтергәнче кыйнарга кирәк.

Хәлил. Сез юкны сөйләмәңез әле! Бик ерак китәсез, алдым-бирдемнәре бар ди!

Әхмәди. Син, абзый, анысын кайгыртма! Мин алдым-бирдемнәрен үзем карармын! *(Гарифәгә.)* Тугдык җиңги! Кичәге эшне син Сорурга багышла! Мин теге кешеләрне күрермен! Хатын-кыз арасында Сорур исемен чыгарырга кирәк!

Хәлил. Ничек Сорурга багышларга? Ул ни дигән сүз?

Гарифә. Анда синең эшең юк, хатын-кыз эшенә катышма! Әллә үземнең бердәнбер кызымның исемен сатыйммы?

Әхмәди. Шуннан яхшы юл юк!

Хәлил. Закир ни әйтер?

Әхмәди. Аерыр!

Гарифә. Аерса, әллә аңарга кыз табылмасмы?

Хәлил. Аның баласы бар ич!

Әхмәди. Булса.

Гарифә. Анасыз бала үсми диме? Сорур! Сорур!

Шул арада Садыйк килеп керә, Гарифә ишектән чыгып, ишекне яртылай ачып карап тора.

Әхмәди. Садыйк абзый, кичә бездә кызык эш булды.

Садыйк. Беләм, беләм!

Әхмәди. Юк, әле белмисең! Кичә Ибраһим Сорур килен янына килгән. Каравылчылар аз гына тотмаганнар.

Садыйк. Ул ни дигән сүз?!

Гарифә. Шулай шул, каһәр суккан, Сорур янына килгән! Ире бар өстенә зина кылып ята!

Садыйк. Сез ни сөйлисез? Әллә гакылдан яздыңызмы?

Әхмәди. Без бер дә гакылдан язмадык! Кичә Ибраһим Сорур килен янына килгән. Без аны күрдек, аз гына тотмадык!

Садыйк. Ничек ул, алай булгач, Галия берлә алдым-бирдем ясаган?

Гарифә. Ясамаган! Ясамаган! Сорур янына килгән. Минем кызымның атын сатма!

Садыйк *(Хәлилгә карап)*. Бу нинди сүз бу! Син дә шуны сөйлисеңме?

Хәлил. Мин белмим, аптырадым!

Әхмәди. Мин үзем күзем берлә күрдем, Сорур берлә икәү иделәр.

Гарифә *(кычкыра)*. Башкалар да күргәннәр. Сорур килен янына килгән, алдым-бирдем юк!

Садыйк. Мин әйтәм, бар! Мин хәзер Галия яныннан чыктым. Ибраһим аның янына килгән! Алар алдым-бирдем ясаганнар. Сез ни чикле гөнаһсыз кешегә сылтарга теләсәңез дә, хәзер булмый, эш беткән! Тизрәк туй ясарга кирәк.

Гарифә. Менә Закир кайтсын да, Сорурны аерырмыз да, үзләре теләгәнчә туй ясарлар.

Садыйк *(Гарифәгә)*. Ул уен сүз түгел, килен бикә, сөйләгәнчә, элгәре уйларга кирәк! *(Хәлилгә карап.)* Боларның уйлаган эшләрен мин аңладым. Ләкин ул була торган эш түгел! Галия үз сүзендә тимер кебек. Менә алдым-бирдем язулары!

Барысы да Садыйк янына киләләр. Садыйк Хәлилгә бирә. Хәлил Әхмәдигә бирә. Әхмәди укый. Тыңлап торалар.

Әхмәди. Булсын! Булсын! Без мондый гына язуларны күргән! Ул Сорур янына килгән, без шуны беләбез!

Садыйк. Сез әллә гакылдан яздыңызмы? Сез ничек кеше өстенә тел сөйлисез! Сез аның берлә нишләмәкче буласыз? Әллә бу кәгазь хәзер сезнең кулга кергәч эш бетте дип белдеңезме? Ибраһимда Галиянең үз кулы берлә язган язу бар, тагы никадәр шаһитлары бар! Хәзер монда арлы-бирле борылырлык калмаган! Тотамыз да туй итәмез! *(Хәлилгә.)* Хәлил! Йомшап торма, эшне озакка калдырырга ярамый.

Гарифә. Юк! Юк! Минем андый хәерчегә бирә торган кызым юк!

Әхмәди *(Садыйкка)*. Ул үзенең сөйгәне Сорур белә теләсә нишләр. Безнең анда эшемез юк!

Садыйк. Мин сезнең берлә уйнап сөйләмим! Сез мине мыскыл итәсез. Карт көнемдә ялган шаһитка йөртмәкче буласызмыни? Минем сезнең өчен ялганлар хәлем юк!

Хәлил *(Әхмәди берлә Гарифәгә карап)*. Садыйк абзый сүзе дөрест! Сез шәригатьне дә аяк астына басып, әлләниләр кылмакчы буласыз!

Г а р и ф ә. Анда синең эшең юк, Ибраһим Сорур янына килгән!

Ә х м ә д и. Ул эш бетте. Аның тугрысында сөйләргә дә юк. *(Садыйкка.)* Менә син, Садыйк абзый, безнең Шакировлар фамилиясенең чисен югалтасың килмәсә, Ибраһимны «Сорур иде» диярга күндер.

С а д ы й к. Мин, алтмышка кадәр яшем җитеп, андый начарлык эшләгәнем юк иде, хәзер чәчем агаргач кына ул эшкә тотынмам, юкны уйламаңыз, булмый торган эш берлә башыңызны ватмаңыз! Галия берлә Ибраһимны аера алмыйсыз!

Ә х м ә д и. Анысын без үзебез беләбез.

С а д ы й к. Хәлил, син бу тилеләр сүзенә карама! Вакыты үтмәс борын туй итик!

Г а р и ф ә. Кызың булса, ит!

Х ә л и л. Мин аптырадым, мин белмим!

С а д ы й к. Караңыз, алай булса, үкенерсез дә, вакыты үткән булыр! *(Чыгып китә.)*

Ә х м ә д и. Үкенсәк, сиңа үпкәләмәмез.

Х ә л и л. Соң сез шулай булдырып булыр дип уйлыйсызмы?

Ә х м ә д и. Син безгә генә юл бир! Менә күрерсең!

Г а р и ф ә. Син хатыннар эшенә генә катышма!

Х ә л и л. Мин белмим, мин аптырадым! *(Чыгып китә.)*

Ә х м ә д и *(Гарифәгә)*. Мин, Тугдык җиңги, становойны чакырырга җибәрдем. Аңардан теге хәерчедә тенту ясаттырып, алдым-бирдем язуыны алдырам. Үзен төрмәгә яптырам дип куркытам! Бер дә булмаса, яптырам да!

Г а р и ф ә. Шаһитлары бар!

Ә х м ә д и. Шаһитлар! Шаһитны теләсәң кайвакыт үз ягыңа аударып була! Сез хатын-кыз арасында Сорур эшен җайлаңыз. Аннан күп уйлап тормаенча, Галияне бирергә кирәк. Тимерне кызуында сугарга кирәк, диләр. Вәлиевләр күптән сорыйлар. Андый-мондый тавыш-тын чыкканча эшне бетерергә кирәк. Ә, туктаңыз әле! Мин Фәйзулланы чакыртыйм әле. *(Чыгып китә.)*

Г а р и ф ә *(акыртын гына Галия бүлмәсенең тишегеннән карый)*. Чыгып киткәндер, ахры, уф Алла! Дөнья булгач нинди эшләргә очрыйсың. Сорур өстенә тел сөйләргә кирәк. Ибраһимны төрмәгә яптырырга кирәк. Фәйзуллаларны, Исмәгыйльләрне ялган шаһит ясатырга кирәк. Балаңның рәхәте өчен беркемне дә кызганмыйсың шул! Монда безне гаепләргә дә юк! Ибраһим да дуңгыз, бөтен эшне бозды, ул булмаса, берни булмый

---

*Чисен (честен)* — бу урында: яхшы атын.

иде. Менә без шуның аркасында җилкәмезгә әллә никадәр гөнаһ йөкләргә кирәк. Алла ярлыкар әле, Алла гафур, рәхим! Йа Рабби, үзең ярлыка! Шул эшләр тын гына бетсә, Хуҗа Баһаветдин рухына җиде ният бирермен. Сәхилә әбигә сарфинкә күлмәгемне бирермен. Йа Рабби, үзең ярдәмче бул!

Әхмәди килеп керә.

Әхмәди. Хәзер менә Фәйзулла килә, кая әле, Тугдык җиңги, монда бер кадак чәй, бер казакилек чыгар әле. Аннан зәкят кенәгәсен чыгар! *(Гарифә чыгып китә.)* Уф, эштән чыгып беттем. *(Сәгатенә карап.)* Нишләп боларның берсе дә килми? Тукта әле! *(Бумажнигын ала да акчасын саный.)* Фәйзуллага егерме бишне бирергә кирәк. Становойның күпме бирәсе бар икән? 250 сумнар чамасы бугай. Аны да зәкяткә язарга кирәк тә, үзенә йөзне бирергә кирәк. Исмәгыйленә бер өч йөзсез булмас! Габдулласына биш йөз сумны хәзерлә дә тор! Зәкят күп чыга!

Шул арада бишмәттән, төлке бүректән Фәйзулла килеп керә.

Әхмәди. Әйдә, Фәйзулла, утыр. Нихәл, Фәйзулла, синнән без бу эшне көтмәгән идек. Синең әтиең безнең әтиләр хезмәтендә гомерен үткәргән иде, безнең әтиләрдән тамагын туйдырып торган иде. Карт гомеренә кадәре әтиең мәрхүмнән бер зарар да күрмәгән идек. Менә сине хезмәткә алган идек, синең дә балачагаң безнең тәрбиягә кергән иде. Син безгә шул хезмәтемезгә каршы, сезнең бөтен нәселеңезне туйдырып торуымызга каршы әллә нинди жуликлар сүзенә карап йөрисең!

Фәйзулла бүреген бер баса, бер төшерә. Шул арада Гарифә чәй, казакилек алып керә.

Әхмәди *(һаман сүзендә дәвам итеп)*. Синнән бу эшне көтмәгән идек. Абзый да, мин дә сине үзебезчә якын күреп базар йөртә башлармыз дип тора идек! Син нишләдең?

Фәйзулла. Мин, Әхмәди абзый, белми дә калдым, йокы берлә аңламадым да! Ахырдан гына белдем!

Әхмәди. Алай булгач, син тәүбә кылдың. Әле без ул эшне судка бирмәкче буламыз. Менә син ул эштән кайтсаң, әтисе дә бездә хезмәт иткән иде дип, калдырырмыз, дидем.

---

*Гафур* — ярлыкаучы, кичерүче.
*Рәхим* — айаучан, рәхимле.

Ф ә й з у л л а. Мин, Әхмәди абзый, валлаһи, белмәенчә килдем.

Ә х м ә д и. Ярар, хәерле булсын, алай булса, менә сине судка бирмәмез, ләкин син мулла-фәлән сораса, Ибраһим берлә кем иде дисә, Сорур иде диген!

Ф ә й з у л л а *(куркып)*. Сорур түгел иде! Хәлил абзый кызы иде.

Г а р и ф ә. Анысын синнән сорамыйлар.

Ә х м ә д и. Юк, монда шулай итмәенчә ярамый, югыйсә синең дә эшең судка китә!

Ф ә й з у л л а *(башларын кашый)*. Ярый, алай булса.

Ә х м ә д и *(чәйне, казакилекне бирә. Һәм кесәсеннән 25 тәнкә чыгарып бирә)*. Менә шуларны ал! Әгәр сүзне тыңласаң, үзеңне базар йөртә башлармыз.

Ф ә й з у л л а *(барын да ала да)*. Рәхмәт, Әхмәди абзый, алай булса да, Ибраһим берлә Сорур җиңги түгел иде, Хәлил абзый кызы иде!

Г а р и ф ә. Анысында синең эшең юк, син менә, Сорур иде, диген!

Ф ә й з у л л а *(башын кашый)*. Рәхмәт, Алла риза булсын! *(Чыгып китә.)*

Ә х м ә д и *(Гарифәнең кулыннан кенәгәне алып язарга тотына.)* «Алла ризасы өчен зәкяттән бирелде Фәйзуллага 25 сум акча, бер кадак чәй — өч сум, сикез аршин шведски — 12 сум, мәҗмугы — 40 сум». *(Гарифәгә.)* Тугдык җиңги, тагын шундагы зур кенәгәне дә китер әле. Становой нишләп килми? *(Гарифә чыгып китә.)* Ни Исмәгыйль килми, ни Габдулласы! Нишлиләр?

Бер е г е т килеп керә.

Е г е т. Абзый, Исмәгыйль дә, Габдулла да эшемез бар, килә алмыйбыз, диделәр.

Ә х м ә д и. Ә! Алай икән... Ярар, карармыз, бар, чык. *(Егет чыга. Әхмәди ялгыз гына.)* Ни кылынган булалар, этләр, өйрәтермен мин сезне, этне симертергә ярамый, хуҗасын тешли, диләр. Дөрест шул! Становой берлә монысын яптырсак, шөрепләре йомшарыр әле! *(Шул арада Гарифә кенәгә күтәреп керә. Әхмәди тиз генә алып актарырга тотына.)* Әхмәтҗановлар, Зариф мулла, Фәхри бабай, писарь Иван Иваныч, тирмәнче Федор. Ә монда икән. Становой — 382 сум. Шактый гына, тагы йөз сум бирсәк йитәр.

---

*Мәҗмугы* — барлыгы.
*Тирмәнче* — тегермәнче.

Гарифә чыгып китә. Шул арада становой килеп керә.

Әхмәди *(каршы алып)*. Исәнме, Михаил Василич!

Становой. Исәнме, Әхмәд Мөхәммәдич!

Әхмәди. Менә, Михаил Василич, нинди йомыш. *(Кенәгәне күрсәтеп.)* Мәкәрҗә җыенына акча кирәк иде.

Становой *(кычкырып)*. Акча юк иде шул, Әхмәд Мөхәммәдич.

Әхмәди. Алай икән, акча кирәк иде шул! Алай булса, ярар, ул калып торсын, әле безнең монда бер зур эш чыкты. Безнең Ибраһим приказчиклар арасында прокламацияләр, кәгазьләр тарата, становойларны сүгәдер, ди, шуңарда тенту ясарга кирәк иде. Үзен, алмасаң да, куркытырга кирәк иде, Моннан элек, сүз тыңлап, Закир кияүне дә куркытып йибәргән идеңез. Бусында да бер хезмәт итеңезче!

Становой. Ым-м, алай икән! Минем шул, Әхмәд Мөхәммәдич, бүген эшем бар иде, мин Василий Иванычларга барыйм дигән идем, монда Мөхәммәдшада ат бар, шуны алырга акча сорыйм дигән идем.

Әхмәди. Акчаны үзем бирәм, күпме кирәк?

Становой. Ике йөз.

Әхмәди. Бер йөз җитмимени?

Становой. Юк.

Әхмәди. Ярый. *(Акчасын алып санап.)* Мә! Алай булгач, йомыш тагы бар. Ибраһимда табылган язуларның барысын да монда безгә китерергә, анда безнең кирәкле язулар бар, кирәкмәсен мин кайтарып бирермен.

Становой. Аңлыйм, аңлыйм.

Әхмәди. Алай булса, хәзер үк.

Становой. Хәзер үк. Мин урядникка гына әйтим дә, хәзер барамыз.

Әхмәди. Күбрәк кеше барыңыз, малайны куркыта төшеңез. Ул борынын бик күтәргән!

Становой. Ярый, ярый, рәхмәт, хушыңыз!

Әхмәди. Туктаңыз, мин дә хәзер чыгам. *(Үзе, каләм алып, зәкят кенәгәсенә яза.)* Вә көнһ Аллаһ ризасы өчен 582 сум бер гарипкә зәкяттән бирелде. *(Язып куеп.)* Ярый, чыктык. *(Чыгалар.)*

Пәрдә төшә.

---

*Көнһ* — югарыларның югарысы.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘНЕҢ ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШЕ

Әхмәдинең өе. Ә х м ә д и ялгыз гына.

Ә х м ә д и. Нишләп бу бик озак тора? Кайтырга вакыт. Малайның котын алгандыр ахрысы. *(Тәрәзәгә карап.)* Ә, әнә килде, шатлык хәбәр берлә булсын. Ала алган гына булса ярар иде.

Шул арада с т а н о в о й килеп керә.

Ә х м ә д и. Бик озак тордыңыз! Эш бик күп булгандыр ахрысы!

С т а н о в о й. Бик озак эзләдем. *(Кулындагы төргәген күрсәтеп.)* Менә барсын да сезгә алып килдем.

Ә х м ә д и *(кулыннан ала, өстәл янына утыралар. Әхмәди кәгазьләрне актарырга тотына)*. Бусы «Әмин тәзәк», монысын алмаенча да ярый иде. Бусы «Мөһер шәриф», ым-мм... Бусы нәрсә? Ә, бусы, «Сөбател-гаҗизин» икән! Язулары юкмыни?

С т а н о в о й. Бар, бар. Бары да шунда, мин анда бернәрсә дә калдырмадым.

Ә х м ә д и *(актарып)*. Менә шул түгелме? *(Укырга тотына.)* «Мин тәнем сәламәт, гакылым камил улдыгы хәлдә Аллаһе Тәгаләнең ярдәме берлә шул васыятьнамәне яздым...» Бу да түгел. Әллә бусымы? *(Укырга тотына.)* «Мин Уфа губернасы, Уфа өязе, Кушар авылының Мөхәммәд Сафа Мөхәммәдҗан угылы үземнең өйдә туган атны саттым...» Бу да түгел! Ә!.. *(Тагы актара.)* Юк! Юк! *(Бер кәгазьне алып.)* Чү, бу нәрсә? «Мең дә сикез йөз дә сиксән тукызынчы елда бән кем Уфа өязенең Сатыш авылының Фәхретдин Хәйретдин угылы үземнең умарта аланымны 35 баш умартасы илә Габделсәмид Шакировка саттым...» Бу да түгел!

С т а н о в о й. Әнә тегендә әллә нинди яңа китаплар бар.

Ә х м ә д и *(актара. Китапларны алып-алып куя)*. Юк, түгел! Ым-м-м... Каһәр суккан, яшергән. Мин икенче юл берлә дә алырмын.

С т а н о в о й. Юкмыни? Мин анда бер язу да калдырмадым. Аннан соң үзеннән сорадым, юк, диде!

Ә х м ә д и. Менә бу язуларны алмаганда да ярый иде. Мин боларны алырга кушмаган идем.

С т а н о в о й. Мин бит татарча танымыйм. Мин берсен дә калдырмадым.

Ә х м ә д и. Юк, моннан файда булмады. Кара әле, Михаил Василич! Син аны арестовайт итәм дип куркытмадыңмыни?

Становой. Әйттем. Арестовайт ит, ди!

Әхмәди. Ул кәгазьләр бик кирәк иде. Ничек алырга кирәк соң?

Становой. Анда булса, мин калдырмый идем инде, анда юк.

Әхмәди. Кирәк булса, арестовайт итәрлек итебрәк син исправникка рапорт яз әле!

Становой. Ярый, ярый, Әхмәд Мөхәммәдич! Хәзергә, алай булса, башка эш юк?

Әхмәди. Юк, рәхмәт! Яптырырга уйласак, мин сезне чакыртырмын!

Становой. Ярый, ярый! *(Үзе чыгып китә.)*

Гарифә *(килеп керә)*. Алып кайтканмы?

Әхмәди. Юк!

Гарифә. «Алдым-бирдем» дә юкмы?

Әхмәди. Юк!

Гарифә. Хатлары да юкмы?

Әхмәди. Берсе дә юк!

Гарифә. Акча әрәм генә булды. Каһәр суккан! Акчаны кайтармадымы?

Әхмәди. Син, Тугдык җиңги, әкият сөйләмә әле! Акча дисең! Акча кыйбатмы, сүз итү кыйбатмы?

Гарифә. Анысы шулай да, акчасы да кызганыч шул.

Әхмәди. Икенче план кормаенча ярамый!

Гарифә. Нишләмәкче буласың?

Әхмәди. Нишләсәң дә аңарда ул язуны калдырырга ярамый. Акча биреп сатып булса да алырга кирәк!

Гарифә. Акча биреп, шул дуңгызга акча биреп, үз язуымызны сатып алмакчы буласыңмы?

Әхмәди. Бирсә, бик алырсың да, бирерме әле.

Гарифә. Шул алдым-бирдем язуын акча берлә сатып алмакчы буласыңмы! Ул нәрсәгә кирәк, ул бит бездә бар.

Әхмәди. Аның берсе генә бездә бар, тегесе берлә ул туй вакытында туеңны боза ала!

Гарифә. Ничек боза?

Әхмәди. Муллаларга Галия минем хатыным дип әйтә дә, шуның берлә муллалар никях укымыйлар.

Гарифә. Муллалар шул малайның сүзенә ышанып хәзерләгән ашны бозарлармы?

Әхмәди. Ие!

Гарифә. Алай булгач, аларга ник һәр елны әллә никадәр зәкят бирәсез, мин, алай булгач, ул бирәннәрне ай саен нишләп җыеп ашатам?!

Әхмәди. Ул икенче эш!

Гарифә. Юк, түгел! Түгел! Ул ни дигән сүз, имеш!

Үзеңнең хезмәтчеңнән үзеңнең кызыңның язуын акчага сатып ал, имеш!

Әхмәди. Шулай булмаганда, Ибраһимга бирәбез шул!

Гарифә. Ул тагы ни дигән сүз?

Әхмәди. Акча берлә алдым-бирдем кәгазене сатып алырга риза булмыйсың ич!

Гарифә. Аңардан башка ник булмый ул? Мин шунысына гына ышанмыйм!

Хәлил килеп керә.

Хәлил. Нишлисез?

Әхмәди. Ибраһимны акча берлә ризаландырмакчы буламыз.

Хәлил. Становой нишләп йөри иде?

Әхмәди. Ибраһимнарда тентү ясаган да, кәгазьләрен күрсәтергә монда китерде!

Хәлил. Тентү ясарга син куштыңмыни?

Әхмәди. Юк, үзе ясаган!

Хәлил. Шулай да бернәрсә дә тапмаган! Аның хурлыгын кая итәрмез? Шакировлар донос ясап үзләренең энеләрендә тентү ясатканнар дигән сүзне ничек ишетермез?

Гарифә. Тапты сүз! Аның шикелле малайларда тентү ясауга бик исләре китәр инде.

Хәлил. Инде тагы акча берлә сатып алмакчы буласызмыни? Бирмәсә, нишлимез?

Әхмәди. Теләсәңез нишләңез, кызыңызны кызганмасаңыз, теләсәңез нишләңез! Мин Шакировлар фамилиясенең чисен саклар өчен генә тырышам.

Хәлил. Мин тагы әллә Садыйк абзый сүзе дөрестме дим!

Гарифә. Тагы юк сүз сөйләргә тотынды. Әйтәм ләсә, Садыйк абзыең түгел, атасы әйтсә дә булмый! Мең тәнкәгә дә булмый!

Хәлил. Мин сезнең булдыра алуыңызга ышанмый башладым.

Гарифә. Син үзең шул эштә катышып йөрергә кирәк. Син читкә качып торасың!

Хәлил. Юк инде, мин становойлар берлә тентүләр ясап йөри алмыйм!

Әхмәди. Менә монысы тентү түгел, акча берлә ризаландырырга телимез, монысы ничек?

Хәлил. Караңыз, мин белмим! Минем башым каткан. *(Чыга.)*

Гарифә. Юк, юк! Аның сүзенә карарга ярамый.

Тизрәк тотарга кирәк? Каһәр суксын, килгән каза икән, акча китсә дә, ул кәгазьне алырга кирәк!

Ә х м ә д и. Аңарга ышанырга ярамый! Анысын да эшләргә кирәк, башкасын да. *(Тәрәзә ачып.)* Мөхәммәтҗан! Тегеләр килдеме?

М ө х ә м м ә т җ а н *(тыштан)*. Килде.

Ә х м ә д и. Керсеннәр!

Шул арада өч кеше килеп керә, Гарифә чыгып китә.

К е ш е л ә р. Әссәламе галәйкем!

Ә х м ә д и. Вәгаләйкем әссәлам!

К е ш е л ә р. Исәнме, бай. Йә, бер дога кылыйк. *(Дога кылалар.)*

Ә х м ә д и. Менә мин сезне бер зур йомыш берлә чакырдым. Менә безнең энемез булса да, бездән әллә никадәр хезмәт күрсә дә, Ибраһим безнең килен Сорур берлә йөри башлаган. Хәзер инде Сорур киленнең аты-чабы да илгә чыккан. Билгеле, без, Шакировлар, үземезнең йортымызда андый киленне тота алмыймыз.

Б е р  к е ш е. Билгеле.

Ә х м ә д и. Менә Ибраһимны шуның өчен бераз өйрәтергә кирәк иде.

К е ш е л ә р. Була! Була!

Ә х м ә д и. Менә шуны сез яхшы гына эшләсәңез, үзеңезгә дә саваб булыр иде; шәригать бит зина кылып йөрергә кушмаган.

К е ш е л ә р. Шулай! Шулай!

Ә х м ә д и *(кесәсеннән чыгарып)*. Менә бусы сезгә азрак башны җылытырга. Ахырдан тагы бирермен.

К е ш е л ә р. Бай, безгә зәкяттән берәр кадак чәй булмасмы дигән идек!

Ә х м ә д и. Ярый, ярый! Мин алай булса алып керим әле. *(Үзе чыгып китә.)*

К е ш е л ә р н е ң  б е р с е. Ничек ялганлый. Сорур килен, ди. Без кем икәнен белмимез инде.

Б е р с е. Шаулама! Безгә килене булды ни, кызы булды ни!

Б е р с е. Анысы алаен алай да, Ибраһимны кыйнарга мин риза түгел.

Б е р с е. Сиңа соң кем кыйнарга әйткәне бар әле?

Т е г е с е. Әнә кыйнарга куша бит!

Б е р с е. Син яшьрәк әле. Ярый, диген, әллә артыңнан йөрерме, әллә, кыйнамадылар дип судка бирерме!

Шул арада Ә х м ә д и бер кадак чәй күтәреп керә. Барысына да бирә.

Т е г е л ә р н е ң  б е р с е. Рәхмәт, Алла изге дәүләт бирсен!

Б е р с е. Алай булса, аны бераз караштырыйк әле! Кабыргаларын саныйк әле!

Ә х м ә д и. Бер хезмәт итеңез әле. Буш булмассыз! *(Чыгалар.)*

**Шул арада бер  е г е т бик күп кәгазьләр, гәзитәләр, хатлар, телеграмнар алып керә.**

Ә х м ә д и *(кәгазьләрне карарга тотына. Бер хатны алып.)* Ым-м... Вәлиевләр хаты! Абзый! Абзый! Тугдык җиңги! Тугдык җиңги! Әллә үлделәрме! *(Гарифә килеп керә.)* Вәлиевләрдән хат. Абзый кая?

Г а р и ф ә. Ул йоклый, җә, укы, аңарга ахырдан әйтермез.

Ә х м ә д и *(ертып укый башлый)*. «Сезгә, гыйззәтле вә хөрмәтле Хәлил абзыйга һәм Әхмәдигә барча җәмәгатьләреңез берлә бик күп догалар үтенеп, сәлам. Үземездән хәл-әхвәл сорасаңыз, әлхәмдүлиллаһ, сәламәтләрмез. Егерменче майда язган хатыңызны алып бик шат булган идек, алтынчы июньдә телеграмыңызны алып мәфһүменә төшендек. Безне кешегә санавыңызга бик рәхмәт! Мәһәр хакында сез ничек теләсәңез, шулай булыр. Иншалла, аның өчен бозылышмамыз. Туйны Мәкәрҗәгә кадәре ясасаңыз, бик яхшы булыр иде. Кияү кыз катыннан гына Мәкәрҗәгә барыр иде. Кодагыеңыз килен бикәгә дип бүләкләр җибәрде, кечкенә булса да, олуг итеп ала күреңез!

Хәерле гомерләреңезне теләп, язгучы кодаңыз Әхмәдсәгыйр Вәлиев.

Үтенәмез туйның кайчанлыгы хакында телеграм вә хат берлә җавап бирүеңезне».

Г а р и ф ә. Йа Рабби, үзең хәерле кыл!

Ә х м ә д и. Син әле, Тугдык җиңги, эш бетте дип беләсең. Әле эшнең иң начары башланды гына, аларга вәгъдә кылынган, Ибраһимга кыз бирелгән! Бер кызны ике бирергә кирәк, беләмсең шуны! *(Телеграмны алып.)* Монысы каян? Казаннан, ә, Закирдандыр. *(Ачып укый.)* Ә, Закир кайтам дигән! Менә хәзер бу боткадан чык инде. Инде Закиры да кайта. Анысы нишләп кайта? Ым-мм... ни булса да, теге язуны алмаенча ярамый. Бирмәс, каһәр суккан, бирмәс!

Г а р и ф ә. Тагы ни кирәк инде. Хат килде ич, риза

---

*Мәфһүм* — эчтәлек.

булганнар. Туй гына ясыймыз, Аллаһе Тәгалә изге сәгатьтә кылсын!

Ә х м ә д и. Алдым-бирдем? Алдым-бирдемне бетермичә берни эшли алмыймыз. Ым-м-м... Бар әле, Сорурны чакыр әле! Ым-м... син мин сөйләгәндә аның алдында миңа каршы сөйләмә! *(Гарифә чыгып китә.)*

Ә х м ә д и. Монысын шулай куркытып, язуны алдырып булмасмы?

Г а р и ф ә берлә С о р у р керәләр.

Ә х м ә д и. Менә, Сорур килен, эш нидә. Закирдан телеграм бар, ул бүген-иртәгә кайта. Синең эшең дә бүген-иртәгә бетәргә кирәк. Шуның өчен, сине кызганганнан, сиңа үзеңне алып калырга мин бер юл таптым. Әгәр чынлап аерыласың килмәсә, син хәзер шул эшне эшләргә тиеш.

С о р у р. Нинди эш?

Ә х м ә д и. Син Ибраһимдагы алдым-бирдем кәгазьләрен алып китерсәң, без сине аертмыймыз.

С о р у р. Мин аны ничек алыйм?

Ә х м ә д и. Аерылмаска теләсәң, юлын табарсың. Ибраһим синең энең, Мәрфуга җиңги синең тутаң!

С о р у р *(еглап)*. Минем ни гаебем бар? Ник юк эшләргә катыштырасыз? Ничек минем баламны кызганмыйсыз?

Ә х м ә д и. Анысы икенче сүз. Син, аерыласың килмәсә, теләсәң каян шул язуны алып китер. Булмаса, безгә үпкәләмә! Мин шуны әйтергә чакырдым.

С о р у р *(еглап, Гарифәгә)*. Әнкәй, ник мине — гөнаһсыз кешене еглатасыз, ник гөнаһсыз баланы анасыз калдырасыз?

Г а р и ф ә. Миңа үпкәләмә, язмышыңа үпкәлә! Әле тагы сине аерабыз дигән кеше юк. Шул язуны китерсәң, син элгәреге Сорур булып каласың!

С о р у р. Мин аны каян алыйм?

Ә х м ә д и. Менә тапты сүз. Ул язу синең энең Ибраһимда яисә синең тутаң Мәрфугада. Әгәр аерыласың килмәсә, бие дә ал, безнең анда эшемез юк. Ибраһимны яхшы кеше дисез ич, ул менә хәзер сине аертмас өчен бирергә тиеш! *(Сәгатенә карап.)* Менә сиңа, Сорур, бер сәгать вакыт, күп уйлап тормаенча Ибраһимнан алып кил! Булмаса, әйберләреңне җыештыр. Ярый, бар! *(Сорур еглый-еглый чыгып китә.)* Бусы да булмаса нишлимез?

Г а р и ф ә. Ник булмасын, барыбер Вәлиевләргә бирәмез.

Ә х м ә д и. Һаман син, Тугдык җиңги, әле бездә шәри-

гать бар икәнен, закон бар икәнен белмисең! Галия хәзер Ибраһим хатыны хисаплана, аны ул аермаенча икенче кешегә биреп булмый. Шуның өчен төрле юллар берлә без аларның алдым-бирдемнәрене бетерергә тырышамыз. *(Хәлил килеп керә.)* Менә Вәлиевләрдән хат килгән, җавап бирергә кирәк.

Хәлил *(хатны укый. Укып бетергәч)*. Ым-м... Сез аларга телеграм биргән идеңезмени? Алдым-бирдемне нишлимез?

Гарифә. Син йөдәдең шул алдым-бирдем берлә.

Хәлил. Ярар, анысы алай да булсын. Галия нишли?

Гарифә. Ата-анасыннан узып Галия нишләсен!

Әхмәди. Ул эшне без үземез карыймыз.

Хәлил. Мин Галиянең ризалыгыннан башка бер сүз әйтә алмыйм! Әхмәтҗанны Сәлим хаҗига үзеннән сорамыйча кызын биргән дип, никадәр көлеп, үземез шулай итикмени?

Әхмәди. Монда Сәлим хаҗи юк. Болар кыз берлә егет!

Шул арада Садыйк килеп керә.

Садыйк *(ачуланып сөйли)*. Исәнмесез? Сезгә килмәскә дә сүз биргән идем, ләкин эш бик зур булганга килмәенчә чыдый алмадым. Сез әйтеңез әле, сез нишлисез? Сезнең кечкенә генә инсафыңыз бармы, сез әллә Шакировларның чисен сакларга дип бөтен чисеңезне саттыңызмы?

Хәлил. Ни булган?!

Садыйк. Ни булганын син белергә тиеш. Миңа хәзер урамда Сорур очрады, еглый-еглый Мәрфуга җиңгиләргә таба бара. Ник еглыйсың дип сорадым. Әхмәди абзый берлә әнкәй: Ибраһим берлә Галиянең алдым-бирдемнәрене бер сәгать эчендә китермәсәң, ireңнән аертамыз, әйберләреңне җыештыр, диделәр, ди. Ул ни дигән сүз, бу нинди оятсызлык?! Аның ни гаебе бар?

Гарифә *(ишек артыннан)*. Минем кызым Ибраһимны сөйми, Сорур Ибраһимны сөя! Безнең аларда эшемез дә юк! Без кызымызны үземез теләгән кешегә бирәмез!

Садыйк. Ул әкиятне мин күптән ишеткән инде! *(Хәлилгә.)* Син миңа шуны гына әйт! Син шул гөнаһсыз хатынны, шуның баласын анасыз калдырып, шул хатынга ялган ялалар ябып, кызыңны әллә кемнәргә бирә алам дип беләсеңме? Бирәсең дә икән, кызым рәхәт күрә дип уйлыймсың? Әллә кызыңны, Салих хәзрәт кебек, сөйгәне өчен җәза кылмакчы буласыңмы?

Гарифә. Минем кызым сөйми!

Садыйк. Мин синең берлә сөйләмим. Минем синдә эшем дә бик аз, безнең сүзгә катышма!

Хәлил. Мин бер эш эшләгәнем юк, мин бернәрсә белмим!

Садыйк. Тирә-янында пожарны күреп сүндермәгән кешене хөкемгә бирәләр, ут салучы берлә бер дәрәҗәдә хөкем итеп, төрмәгә ябалар. Син хәзер белмәгән булып, *(Әхмәди берлә Гарифәгә төртеп күрсәтеп.)* боларга дөньядагы кабахәтлекләрне кылырга ирек бирәсең. Ярый, Сорур хәзер Ибраһимнан язуны да алып кайтсын. Мин, Сорурның күз яшен күрсә, Ибраһим чыдый алмас дип уйлыйм. Шул язу берлә эш беттеме? Галия нишли?

Гарифә. Ибраһим бирерме? Ул вакытта тизрәк туй итәмез.

Хәлил. Менә минем актык сүзем: мин, Галия үзе риза булмаса, Вәлиевләргә бирмим!

Гарифә. Ата-анасы биргән йиргә Галия ник риза булмасын?

Садыйк. Галия риза булырлык булса, төнлә берлә кешеләр чакыртып, Ибраһим белән алдым-бирдем ясар идеме, юкмы? Галиянең шул эше Галиянең Ибраһимнан бүтәнгә риза булмавын белдерә түгелме?

Әхмәди. Садыйк абзый, син бөтенләй юкны сөйлисең, элгәре, Галия алдым-бирдем ясамаган, икенче, була икән — яшьлек берлә булган.

Гарифә. Син безнең эшемезгә катышып йөрмә! Синең балаң түгел, Галия үз баламыз, теләсәк, утка ташлармыз, теләсәк — суга, ишеттеңме? Ибраһимга сатылдыңмы?

Садыйк. Рәхмәт, килен бикә, хөрмәтеңә! Мин моңынча мондый сүз ишеткәнем юк иде. Рәхмәт, хушыңыз, сезнең үзеңезнең гакылыңыз шулкадәр күп булгач, мин монда артык икәнмен! *(Чыгып китә.)*

Хәлил *(Гарифәгә).* Әти кебек агамызны мыскыл итәсең, артык ирек алдың.

Гарифә. Юкны сөйләп лыгырдап йөрмәсен!

Әхмәди. Карт башы берлә юк эш артыннан йөрмәсен!

Ишек ачыла. Сорур күренә. Аннан соң кәгазь күрсәтә. Әхмәди барып бик тиз кәгазьне алып килә.

Гарифә. Алдым-бирдем?

Әхмәди. Шул.

Гарифә. Әлхәмдүлиллаһ, әлхәмдүлиллаһ, Аллага шөкер, котылдым.

Хәлил *(акыртын гына).* Бир әле... *(Бик озак карап тора.)*

Гарифә. Котылдык, котылдык!

Әхмәди *(Хәлилгә)*. Йә, хәзер нишлимез?

Гарифә. Телеграм бирәмез, телеграм!

Хәлил. Кая телеграм бирәсең?

Гарифә. Вәлиевләргә.

Хәлил. Мин Галиянең ризалыгыннан башка риза түгел!

Гарифә. Галия риза, Галия риза! Минем кызым ата-анасы сүзеннән чыкмый. Менә алып керәм.

Гарифә берлә Әхмәди Галияне алырга чыгып китәләр.

Хәлил. Бу кадәр күз яшьләре түктереп ясалган туйда бәрәкәт булыр микән? Белмим, белмим, Аллага тапшырдым.

Акыртын гына Галия, Гарифә, Әхмәди керәләр. Утырышалар. Галия утырмый.

Гарифә. Кызым, менә монда сине көтеп торамыз, без барымыз да синең рәхәтең өчен бөтен җанымызны фида кылырга риза! Менә сине Вәлиевләргә сорыйлар. Әтиең дә, мин дә, Әхмәди абыең да бик риза! Актык җавапны язганчы синнән сорыйк дидек. Карт көнемездә *(Еглаган тавыш берлә.)* сүземезне кайтарма! Без биргән йиргә син риза бул!

Сорур, ишекне ачып, Галиягә хат күрсәтә. Галия күрми. Сорур йөткерә, Галия күрми.

Галия. Мин хәзер Ибраһим хатыны! Сез шуны әллә кайчан беләсез, нигә мине газаплап йөртәсез? Ник мине каравыллап тотасыз? Мин бер иргә киткән инде — икенчегә китә алмыйм!

Әхмәди. Әгәр син Ибраһим хатыны булмасаң, Ибраһим сине аласы килмәсә, ул вакытта риза булыр идеңме?

Галия. Булыр идем. Ләкин ул була торган эш түгел. Без икемез дә бер-беремездән аерылмас өчен җанымызны корбан кылырга риза!

Әхмәди. Бәлки, син шулайдыр... *(Сорур бик йөткерә, хатны күрсәтә, Галия һаман анда карамый.)* Ләкин Ибраһим сине бик очсызга хисаплый икән! Ибраһим синең үз кулың берлә язган алдым-бирдем язуыңны безгә биш йөз сумга сатты.

Галия. Ялган, ялган! *(Сорур йөткерә. Язу күрсәтә. Галия күрми.)*

Әхмәди. Ялган булса, менә кара! *(Кесәсеннән чыгарып, язуны бирә.)*

Г а л и я *(карап, еглаган тавыш берлә).* Ибраһим мине саткан! Ибраһим мине биш йөз тәнкәгә саткан! Ибраһиммы? Юк, юк! Ялган! Ибраһим мине саткан! *(Кычкырып еглап, «Ибраһим!», «Ибраһим!» дип егыла.)*

П ә р д ә  т ө ш ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хәлил байның өе, зал. Туй мәҗлесе хәзерләнгән. Ә х м ә д и,  Г а р и ф ә.

Ә х м ә д и. Тегене куркытып качырдык. Бүген бөтенләй өйдә юк. Казангамы киткән. Галия нишли?

Г а р и ф ә. Белмим, нишләр. Бармыйм, бармыйм, ди. Алла сакласын, туйны белсә, хәзрәтләргә бармыйм дип чыгып әйтер.

Ә х м ә д и. Шуның өчен туйны бу өйгә хәзерләдек. Сез анда хатыннар берлә аңа ничек тә монда никях барлыгын белдермәңез. Аның соңында ахырдан акрынлап кына әйтермез. Каһәр суккан кияве дә бүген үк керергә булды.

Г а р и ф ә. Теге язудан соң Ибраһимнан тәмам күңеле кайткан кебек күренгән иде, өмете бер дә юк иде, хәзер тагы әллә нишләде.

Ә х м ә д и. Тагы хат алгандыр, тагы араларында сүз йөри башлагандыр. Сез дә шуны да карый алмыйсыз. Ничек бер кызны өч хатын саклый алмыйсыз?

Г а р и ф ә. Нишлик инде. Тышка ялгыз чыгармыймыз! Янына кеше кертмимез, яныннан беремез бер дә китмимез, тагы ничек саклыйк!

Ә х м ә д и. Каян хәбәр ала?

Г а р и ф ә. Белмим, әллә алмый торгандыр, алса, тагы әллә ниләр кылыныр иде.

Ә х м ә д и. Никяхка кадәр ала алмаса, аннан соң эш үтә. Шул бер-ике сәгатьне бик яхшы саклаңыз! Сорур кермиме? Наташа кермиме?

Г а р и ф ә. Берсен дә янына китермимез.

Ә х м ә д и. Алай булса, берни дә белми торгандыр. *(Хәлил килеп керә.)* Кода янында кем калды? Аңарга андый-мондый язу китермәсеннәр. Садыйк абзый килә күрмәсен!

Х ә л и л. Кода үзе генә калды.

Ә х м ә д и. Салих юкмыни? Ничә әйттем мин шуңа, кода яныннан китмә, дип.

Х ә л и л. Ул ишек янында тора.

Ә х м ә д и. Алай булса ярый. Кода бер-бер эш аңлаган кебек күренмиме?

Х ә л и л. Әлегә юк.

Ә х м ә д и. Туйга кадәр ничек тә чит кеше берлә сөйләшергә ирек бирмәскә кирәк. Хат-фәлән булса, бер дә укымаенча бирергә ярамый.

Х ә л и л *(Гарифәгә)*. Галия нишли?

Г а р и ф ә. Берни дә эшләми. Бик яхшы тора.

Х ә л и л. Без шулай, мачы баласын яшергән кебек, туй итеп нишли алырмыз икән инде? Бер-бер файда чыгар микән?

Ә х м ә д и. Нишләмәкче буласың! Кодага, ашыгычлык берлә булганга туйны зур итә алмыймыз, дидек. Акча аз чыгарырга булганга, бик шатланып риза булды.

Г а р и ф ә. Әле ярый кодагый, кодагый килмәгән. Галияне ничек күрендерер идек!

Х ә л и л. Аны соң, кодагыйга да күрендерерлек булмагач, кияүгә ничек күрсәтермез, алар ничек гомер итәрләр?

Г а р и ф ә. Никях булгач, бик яхшы торырлар, никях берлә мәхәббәт игездер, ди.

Х ә л и л. Белмим, хәерле булсын! *(Әхмәдигә.)* Хәзрәтләр тиз киләме?

Ә х м ә д и. Тиз булырга кирәк.

Г а р и ф ә. Алла хәерле ярдәм биреп, очына чыга алсак, бик зур эшне башкарган буламыз.

Х ә л и л. Кияүгә кем каршы чыга?

Ә х м ә д и. Үзем чыгам, үзем!

Г а р и ф ә. Теге, каһәр суккан, кияүгә бер-бер кеше каршы чыгармасын!

Ә х м ә д и. Кияүнең килүен бездән башка беркем дә белми! Синең мунчаңны кем карый? Мунчаңа әлләниләр салмасыннар.

Г а р и ф ә. Мин аны әллә кайчаннан беләм. Мунчаны үзем әрчеттем. Мунчаның ачкычы үземдә. Хәдичәдән башка кеше мунчага керә алмый. Мунча янына Сабит бабайны көне-төне каравылларга куштым.

Ә х м ә д и. Анысы яраган. Ул яктан кайгы юк икән. Мин әле ат азбарларын сакларга ышанычлы кеше таба алганым юк. Атларның ялларын кырка күрмәсеннәр. Аннан бу арада кияү киткәнчә йортны бик сакларга кирәк! Капканы-фәләнне буяу ихтималлары бар, яисә ут салу ихтималлары бар. *(Хәлилгә.)* Әллә становойдан сорап бер-ике стражник алыйкмы?

---

*Азбар* — абзар.

Г а р и ф ә. Алыйк, алыйк! Болай да каравылчы куярга кирәк.

Х ә л и л. Теләсәңез нишләңез, бу кеше туе төсле булмады, монда һәрнәрсә ваенный палажениядә!

Ә х м ә д и *(сәгатен карап)*. Хәзрәтләр килергә вакыт җитте, Тугдык җиңги, сез тизрәк хәзерләңез. Без кода янына чыгыйк.

Хәлил берлә Әхмәди чыгалар.

Г а р и ф ә. Сорур, Сорур!

С о р у р *(керә)*. Нәрсә, әнкәй?

Г а р и ф ә. Тизрәк аш урыннарын хәзерләп бетер. Мин ашны кызулыйм. *(Чыгып китә.)*

С о р у р *(хәзерләргә тотына. Ялгыз)*. Бу нинди туй? Бөтен йирдә каравыл. Галия мескен тышка да чыга алмый, мунча бикләнгән, капка бикләнгән, кыз бикләнгән — менә туй! Болар нишләмәкче булалар? Мачы баласын яшергән кебек яшереп туй итеп, балалары рәхәт күрер дип беләләрме? Мескен Галия һаман әле Ибраһим алдады дип тора. *(Кесәсен тотып карап.)* Язу һаман монда. Ничек бирим? Ибраһим да хәзер, Галия хатны алса да, этиләре сүзенә яткан дип тора торгандыр. Монда Галия, Ибраһимны сатылган дип уйлап, нишләргә белми тора! *(Хатны кулына алып.)* Тагы бер сәгать эчендә бирә алмасам, Галиянең башы бетте. Ничек бирим? Ник өстемә алдым? Аерсыннар икән! Ул вакытта үзем өчен кайгырыр идем. Хәзер Ибраһим алдында ялганчы булып калам. Галиянең башын харап итәм. Ул алдым-бирдемне китермәгән булсам, эш бәлки болай булмас иде. Уф Алла! *(Уйлап торып.)* Нишлим соң? Мин хатны бирә алырмын дип уйладым. Миңа, тилегә, элгәре хатны бирергә кирәк иде. Аннан алдым-бирдемне. Мин аны уйлый белмәдем. Ул вакытта Галия кырык алдым-бирдемгә дә алданмый иде. Уф Алла, йа Раббем, ярдәмче бул! Шул хатны бирсәм, җилкәмнән зур йөк төшкән кебек булып калыр идем. Әгәр бирә алмасам, нишләрмен? Бер дә булмаса, муллалар килгәнчә бирә алмасам, сугышып булса да кереп бирәм, каһәр суксын, аерсыннар, бирәм, бирәм, валлаһи, бирәм! *(Хәзерли, Гарифә килеп керә.)*

Г а р и ф ә. Аш хәзер. Ирләргә әйтергә кирәк. *(Ишек кага.)*

Бераздан Ә х м ә д и килеп чыга. Сорур чыгып китә.

Ә х м ә д и. Нәрсә бар?

Г а р и ф ә. Аш өлгерде. Хәзрәтләр киләме?

Ә х м ә д и. Хәзер киләләр. Без, алай булса, коданы монда алып чыгыйк.

Әхмәди чыгып китә. Гарифә ялгыз кала.

Г а р и ф ә. Йа Рабби, хәерле кыл! Галия генә белә күрмәсен, йа Рабби, Хуҗа Баһаветдин! Шуның күзен бәйлә, дошманнарның юлларын кис!

Т а в ы ш *(теге бүлмәдән)*. Хуш, кода, хуш! Әйдә!

Т а г ы  б е р  т а в ы ш. Әйдә, кода, әйдә, кода!

К о д а. Үзеңез рәхим итеңез!

Х ә л и л. Сез кунак кеше! Хушыңыз!

К о д а. Сез карт кеше, хушыңыз! Хуш!

Х ә л и л. Ярыймы соң, сез кода кеше. Хушыңыз, хуш!

К о д а. Юк, кода, үзеңез рәхим итеңез!

Ә х м ә д и *(арттан)*. Ярый, сатулашмаңыз. Кода, сез кунак кеше, сез рәхим итеңез!

К о д а. Юк, юк! Әдәпсезлек була. Хәлил кода рәхим итсен!

Ә х м ә д и. Абзый, сатулашма инде.

Х ә л и л. Алай яхшы түгел бит...

Х ә л и л алдан керә. Аның артыннан к о д а керә. Аның артыннан Ә х м ә д и керә. Өстәлгә утыралар. Дога кылалар.

Ә х м ә д и. Сездә быел ашлыклар ничек күренә, кода?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Юк, яхшы түгел. Алай да бездә сезнең әтраф кебек үк түгел!

Ә х м ә д и. Сату-алу ничек булыр төсле күренә!

Ә х м ә т с ә г ы й р. Кызыл мал быел начар булыр төсле күренә. Ашамак-эчмәк товары үтәр! Шуның өчен без кызыл малны быел яртылап кына алмакчы буламыз.

Ә х м ә д и. Үткән елгы бастовкалар сездә бик зур булмадымы?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Урыс арасында шәп булды. Без, агай-эне берлә киңәш итешеп, мөселман арасында ясатмадык. Прикашчикләр арасында бер-ике кызылавыз бар иде дә, аларны чыгарттык. Аннан башкалары шикләнделәр.

Х ә л и л. Әле сезнең тарафта эшләр ничек, бу Думадан ни өмет итәләр?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Әлегә иминлек. Шул, ничек булса да мөселманга җиңеллек булмасмы дип уйлыймыз. Без-

---

*Әтраф* — як.
*Бастовка* — забастовка.

нең шәһәрдән бик яхшы кеше китте, дуктыр, болай бик кызыл да түгел, йортлы-җирле кеше.

Бер егет керә.

Егет. Абзый, кунаклар килде, кайда утыртамыз?

Әхмәди. Хәзрәтләрдән башкасын барын да теге өйгә. Кирәкләрен мин үзем карап алып керермен! *(Егет чыга.)*

Хәлил. Сездән бу ел хаҗга баручы булдымы?

Әхмәтсәгыйр. Вәлиулла абзый барды. Сез аны белергә тиеш. Вак мал берлә сату итә, яхшы кеше!

Хәлил. Сарырак сакаллымы?

Әхмәтсәгыйр. Әйе, әйе!

Хәлил. Беләм! Беләм, без аның берлә парахутта туры килгәнемез бар.

Әхмәди *(сәгатенә карап)*. Кияүгә каршы чыгарга вакыт җитә. Хәзрәтләр нишләп озак торалар?

Әхмәтсәгыйр. Аш-фәлән булгандыр. Безнең мулла халкы ашны ярата бит!

Хәлил. Бәлки, шулайдыр шул.

Шул арада бер егет керә.

Егет. Хәзрәтләр килә!

Әхмәди каршы чыга. Әхмәтсәгыйр дә, Хәлил дә аяк үзрә торалар. Тыштан: «Әйдәңез, хәзрәт, монда әйдәңез!» — дигән тавыш ишетелә. Аллыартлы карт хәзрәт, яшь мулла, мөәззин килеп керәләр.

Хәзрәт. Әссәламе галәйкем!

— Вәгаләйкем әссәлам!

Хәзрәтләр утыралар. Дога кылалар.

Әхмәтсәгыйр. Исәннәрмесез, хәзрәтләр? *(Күрешәләр, дога кылалар.)*

Хәзрәт. Мөбарәк мәҗлесләр булсын, Аллаһе Тәгалә әүвәлен, ахырын хәерле кылсын!

Әхмәтсәгыйр. Шулай дога кылыңыз инде, хәзрәтләр!

Яшь мулла. Исән килдеңме, кода? Син исәнме, Хәлил абзый!

Әхмәтсәгыйр. Әлхәмдүлиллаһ, хәзрәт, сезгә әле, хәзрәт, әманәт бар икән. Безнең Габделмәннан хәзрәт сезгә сәлам әйтте.

Карт хәзрәт. Вәгаләйкем әссәлам, сәламәт бул-

---

*Аяк үзрә* — аягүрә.

сыннар! Ничек, исән торамы соң үзе, намазга бик йөриме?

Әхмәтсәгыйр. Әлхәмдүлиллаһ, хәзрәт, бик истикамәтендә, хәзрәттән бик уңдык.

Яшь мулла. Габденнасыйр абзый сәламәтме?

Әхмәтсәгыйр. Әлхәмдүлиллаһ, бик сәламәт, хәзрәт, аны беләсезмени? Күргән-белгәнгә сәлам, диде.

Яшь мулла. Вәгаләйкем әссәлам, сәламәт булсыннар!

Карт хәзрәт. Анда сезнең Минһаҗ суфи булырга кирәк иде, хәзер сәламәтме әле?

Әхмәтсәгыйр. Вафат, хәзрәт, бик һәйбәт карт иде. Бер-ике ел бар инде.

Карт хәзрәт. Баласы-чагасы калдымы?

Әхмәтсәгыйр. Ике кызы, бер угылы калды.

Хәзрәт. Мәгыйшәтләре ничек?

Әхмәтсәгыйр. Яхшы, хәзрәт, яхшы. Карый хәзрәттән йорт-җир калды. Бераз акча калган иде. Мәхәллә халкы бик ригая кылалар.

Карт хәзрәт. Шулай кирәк, шулай. Яхшы кешене онытырга ярамый.

Әхмәтсәгыйр *(торып, Әхмәди янына барып)*. Кода, миңа тәһарәт алырга кирәк.

Әхмәди. Хәзер, хәзер! Гәрәй, Гәрәй!

Бер егет керә.

Әхмәди *(теге егеткә)*. Коданы тәһарәтләндер! *(Әхмәтсәгыйр чыга.)* Хәзрәт, озак тордыңыз!

Карт хәзрәт. Бик зур эш чыкты, килмим дә дигән идем, әмре мәгъруф нәһи мөнкәр өчен генә килдем.

Хәлил. Ул ни эш?

Хәзрәт. Хәзер сөйләмәенчә ярамый. Үзеңез, ахмаклар, эшне бу кадәргә китергәнчә миңа әйтмәгәнсез. Кызыңыз берлә Ибраһим арасында гакед бар икән ләсә!

Әхмәди. Юк сүз! Ибраһим безне мыскыл итәр өчен шулай кылына! Становой барып тентү ясаганын бездән күргән дә, шуның үчен алмакчы була!

Хәзрәт. Түгел, түгел! Миңа шаһитларын алып килде. Алар арасында никях бар! Сез шуны белмәдеңезме, белеп безне алдамакчы буласызмы?

---

*Истикамәт* — турылык, туры юл.
*Мәгыйшәт* — көнкүреш, тормыш.
*Ригая кылу* — карау, кайгырту.
*Әмре мәгъруф нәһи мөнкәр* — шәригать кушкан эшне эшләп, тыйганнан тыелырга боеру.

**Әхмәди.** Хәзрәт, юк сүз! Ышанмаңыз!

**Хәзрәт.** Ник ышанмыйм! Шаһитлар шәһадәт биргәч, мин ник ышанмыйм!

**Әхмәди.** Шаһитлары ялган!

**Хәзрәт.** Ахмак! Юкны сөйлисең! Фәйзулласы, Әхмәди абзый егерме биш сум акча бирде әйтмәс өчен, мин әйтәм, хәзрәт, ди! Шуңарга да ышанмыйммы?!

**Яшь мулла.** Бер ривайәттә: вәлинең ризалыгыннан башка гакед дөрест түгел! Шуның өчен аларның гакедләре, Хәлил абзый риза булмагач, фәсех кылына!

**Карт хәзрәт.** Бер ривайәттә, бер ривайәттә... Сезгә ривайәт күп! Сез гыйддәт эчендә никях укыйсыз, аерылмаганны да аерасыз, инде кеше хатынына никях укымакчы буласызмыни?

**Яшь мулла.** Укыйм шул! Ривайәте булгач, ник укымыйм!

**Карт хәзрәт.** Кая ривайәте?

**Яшь мулла.** «Җәмигъ»дә бар.

**Хәзрәт.** Андагы кыйльләр берлә гамәл кыла башласаң, ерак барырсың!

**Хәлил.** Хәзрәт, ривайәте булгач, гөнаһысы сезгә булмас.

**Карт хәзрәт.** Анда синең хатыныңа никях укырга ривайәт табылыр, риза булырсыңмы?

**Яшь мулла.** Мин, ривайәт булгач, укыйм!

**Хәлил.** Хәзрәт, карт көнемездә туемызны тавышсыз гына үткәрсәңез лә! Ривайәте булгач, ярар!

**Карт хәзрәт.** Ул нинди шәригатьне аяк астына таптау! Менә ахмаклар, кеше хатынын тот та кияүгә бир, имеш!

**Әхмәди.** Хәзрәт! Алла хакы өчен без дигәнчә эш бетсен лә, кода кергәнчә сүзеңезне бетерсәңез лә!

**Карт хәзрәт.** Монда яшерен эш юк. Кеше хатынына никях укымыймыз.

**Әхмәди.** Алай булса, хәзрәт, яшь хәзрәт укый. Сез дәшми торыңыз!

**Карт хәзрәт.** Юк, юк! Юкны сөйләмә!

**Әхмәди.** Алай булса, хәзрәт, яше җитми дип кенә укымаңыз. Бөтен галәм алдында хурлыкка калабыз. Без коданы кайтарып йибәрермез дә артыннан хат кына язармыз.

---

*Вәли* — хуҗа.
*Фәсех кылыну* — бозылу.
*Кыйль* — әйтелгән сүз.

Хәлил. Хәзрәт, Алла ризасы өчен карт көнемездә бөтен галәм алдында хур итмә. Монысыннан сезгә зарар юк.

Карт хәзрәт. Ахмаклар! Кеше хатынын кияүгә бир, имеш!

Хәлил. Зинһар, хәзрәт, кода кергәнчә тавышны бетериксәнә! Зинһар, яше җитмәгән генә дисәңез лә!

Әхмәди *(яшь мулланы чакырып алып)*. Карт хәзрәтне алдап чыгарыйк, син укырсың! Кода керсә, яше тугрысында сөйләңез!

Әхмәди чыгып китә. Әхмәтсәгыйр керә.

Яшь мулла. Хәлил абзый, кызыңызның яше җитеп бетми! Уналты туларга өч ай бар.

Хәлил. Хәзрәт, туларга кирәк иде.

Яшь мулла *(кенәгәне күрсәтеп)*. Менә монда апачык күренеп тора.

Шул арада бер егет чабып керә.

Егет. Карт хәзрәт! Асравыңыз килде. Угылыңыз өй түбәсеннән егылып төшкән, ди, абызтай хәзер кайтсын дигән!

Әхмәди *(керә)*. Менә, хәзрәт, бик зур казалы булгансыз, үлә генә күрмәсен!

Хәзрәт. Машалла, машалла! *(Торып, ашыгып чыга башлый.)*

Хәлил. Атны бир!

Әхмәди. Хәзер! Хәзер! *(Хәзрәт чыгып китә.)*

Хәлил. Менә нинди зур каза. Дөньяны бер дә белер хәл юк.

Әхмәтсәгыйр. Кара, туйның ямен җибәрде!

Хәлил. Хәерле каза кылсын!

Әхмәди *(кереп)*. Хәзрәт көтмәскә кушты!

Яшь мулла. Яшен нишлимез?

Әхмәди. Аннан гына бернәрсә дә булмас. Аллага тапшырып, укыңыз! Кода да ерак йирдән килгән. Бүген кияү дә килә.

Мулла. Духовный собрания бар.

Әхмәди. Мөфти хәзрәт моңынча алай безнең сүздән чыкмый иде. Берни дә булмас, Алла теләсә.

Әхмәтсәгыйр. Хәзрәт, туйны күркәмлек берлә бетерик инде, укыңыз инде.

Хәлил. Хәзрәт, бергә аш ашадык, бергә сый күрдек, эш моңар җиткәч, сездән генә калмасын инде.

Мулла. Теге кәбестә башы собраниягә куймасын, дим!

Ә х м ә т с ә г ы й р. Иншалла, хәзрәт, булмас.

Ә х м ә д и. Собраниягә эш китсә, сезгә зарар булмавына кулымны кисәргә бирәм.

М у л л а. Ярый инде, туйның ямен йибәрмәс өчен генә укыйм! Әгәр бүтән кешедә булса, һич тә укымас идем. Әле тик Хәлил абзый да үз кешемез, кода да якын кеше булып чыкты. Йә, алай булса, утырыңыз! Шаһитлар кемнәр?

Х ә л и л. Хәзрәт, Әхмәди берлә Мөхәммәтсафа булыр.

М у л л а. Хәлил абзый, сез шулай кызыңызны бирәсезме?

Х ә л и л. Әйе, хәзрәт!

М у л л а. Һадиулла Вәлиулла угылынамы?

Х ә л и л. Әйе, хәзрәт.

М у л л а *(Әхмәтсәгыйргә)*. Кода, мәһәр күпме?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Мең сум, хәзрәт!

М у л л а *(Хәлил абзыйга)*. Мәһәр тәмаммы?

Х ә л и л. Биш йөзе тәмам, биш йөзе мөәҗҗәл!

М у л л а *(Әхмәтсәгыйргә)*. Кода, шулаймы?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Шулай, хәзрәт, шулай!

М у л л а. Кыз тарафыннан вәли вәкил, Хәлил абзый, сез буласызмы?

Х ә л и л. Әйе, хәзрәт, мин.

М у л л а. Кияү тарафыннан, Әхмәтсәгыйр ага, сез буласызмы?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Әйе, хәзрәт, мин.

М у л л а *(Әхмәдигә)*. Сез, кыздан ризалык сораңыз! *(Әхмәди чыга.)*

М у л л а *(Әхмәтсәгыйргә)*. Кияүнең яше җитәме?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Тугыз йөз дә өченче елда солдаттан калган!

М у л л а. Запасной солдат түгелме?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Түгел, хәзрәт, ак билет берлә калды.

М у л л а. Билеты мондамы?

Ә х м ә т с ә г ы й р. Юк иде шул, хәзрәт.

М у л л а. Коданың, ахрысы, әүвәлге туедыр.

Ә х м ә т с ә г ы й р. Әүвәлге шул, хәзрәт. Шуның өчен ни кирәген белеп тә бетереп булмый.

М у л л а. Ярый инде, сезгә ышанамыз. *(Хәлилгә.)* Хәлил абзый! Тагы башка шартлар юкмы?

Х ә л и л. Юк, хәзрәт, юк! Алла бәхетләрен бирсен инде!

---

*Мөәҗҗәл* — соңыннан бирергә калдырылган.

Шул арада Әхмәди берлә Мөхәммәтсафа килеп керәләр.

Әхмәди *(элгәре)*. Әссәламе галәйкем!
Мулла. Вәгаләйкем әссәлам.
Әхмәди. Хәзрәт, Галия, мин эти биргән йиргә риза, ди.
Мөхәммәтсафа. Әссәламе галәйкем.
Мулла. Вәгаләйкем әссәлам.
Мөхәммәтсафа. Хәзрәт, Галия, мин эти биргән йиргә риза, ди.
Мулла. Алай булса, утырышыңыз, укый башлыйк. *(Памятный кенәгәсен алып.)* Кияүнең исеме Һадиулла Вәлиулла угылы.
Әхмәтсәгыйр. Вәлиев.
Мулла. Әйе, Вәлиев. Беренче никяхы?
Әхмәтсәгыйр. Беренче никяхы.

Бар да утырышалар.

Мулла. Әһем, әһем! Хәлил абзый, укыйкмы?
Хәлил. Укыңыз инде, хәзрәт, Алла хәерле кылсын!

Шул арада күрше бүлмәдә хатыннар тавышы күтәрелә:

Гарифә. Кая барасың?
Берсе. Тот, тот! Җибәрмә! Каһәр сукканны!
Гарифә. Картайган көнемдә йөземә кара ягасың! *(Әйберләр дөберди.)*
Галия тавышы. Җибәреңез, җибәреңез! Мин сезнең колыңыз түгел!

Ирләре бер-берсенә карана башлыйлар. Тавыш куәтләнә бара. Мулла туктый.

Бер тавыш. Җибәрмә! Җибәрмә!

Әхмәди торып каршы чыга. Тавыш тагы куәтләнә.

Галия. Җибәреңез!
Әхмәди. Кая барасың?!
Бер тавыш. Авызына сук дуңгызның, авызына сук!
Галия. Ник кыйныйсыз? Ник кыйныйсыз!

Ишектән дөбердәп Галия керә. Аның артыннан хатыннар керәләр. Галиянең бите канга буялган. Галия чабып муллага бара. Хатыннар аның артыннан.

Бер хатын. Тот каһәр сукканны!
Галия *(муллага)*. Хәзрәт, мин Ибраһим хатыны. Миңа никях укый алмыйсың! Ризалык биргәнем юк!

Ә х м ә т с ә г ы й р сикереп тора.

Г а л и я *(аңарга килеп)*. Син, абзый, миңа үпкәләмә! Сине мин алдамадым. Болар алдады. *(Аталарына күрсәтә.)*

Ә х м ә т с ә г ы й р *(Хәлилгә)*. Бу ни эш бу? Кода? Бу ни эш бу? Бу нинди хурлык? Ник безне мыскыл итәсез?!

Х ә л и л. Мин белмим, мин белмим.

Х а т ы н н а р кычкыралар: «Каһәр суккан! Каһәр суккан!»

Г а р и ф ә *(кычкырып еглый)*. Йөземне кара итте, йөземне кара итте!

Ә х м ә т с ә г ы й р *(Әхмәдигә)*. Бу ни дигән сүз, кода? Без мәшәкать чиккән, расхут тоткан.

Ә х м ә д и. Исең китмәсен лә биш йөз тәнкәгә!

Ә х м ә т с ә г ы й р. Ул тагы ни дигән сүз? Ник безне мыскыл итәсез? Мин бит бала түгел *(Сакалына күрсәтеп.)* сезнең берлә уйнап йөрергә!

М у л л а *(Хәлилгә)*. Эшеңнең рәте булмагач, безне мәшәкатьләп йөрмәскә кирәк.

Г а р и ф ә. Бу хурлыкка ничек чыдыйм?!

Ә х м ә д и. Шакировларның кызы туй көнне риза булмаенча туйны бозган дигән сүзне ничек күтәрим!

Г а л и я. Мин элгәре үк әйттем. Мин сезгә әллә кайчан әйттем. Сез мине кыйнап ризаландырмакчы булдыңыз. Сез мине сарык урынына сатмакчы булдыңыз. Мине, кеше хатынын, әллә ниләр ялганлап, яңадан бирмәкче булдыңыз. Мин күз яшьләре түккәндә сез миннән көлдеңез! *(Анасына барып.)* Хәзер сезнең күз яшеңездән мин көләм! Хушыңыз! Миңа үпкәләмәңез, үзеңез чәчкән ашлыкны үзеңез урыңыз! *(Тәрәзәдән сикерә.)*

Г а р и ф ә. Тотыңыз! Тотыңыз! Ибраһимга китте, Ибраһимга! Каһәр суккан икән!

Х а т ы н н а р кычкырышалар: «Тотыңыз! Тотыңыз!»

М ө х ә м м ә т с а ф а *(йөгереп чыга)*. Тотыңыз, тотыңыз! *(Ирләр югалалар.)*

П ә р д ә т ө ш ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ибраһим өе. Зур гына өй. Искерәк кенә мебельләр. И б р а һ и м ялгыз.

И б р а һ и м. Бу ни бу? Бу ни булды! Ник бер хәбәр дә юк? Шулай ук Галия үз сүзеннән кайтты микәнни? *(Сәгатенә карап.)* Хәзер никях вакыты булырга кирәк. Кем

белсен, шәт, никях та укыдылар. Һичнәрсә аңлый алмыйм. Галия бөтенләй алар ягына аугандыр дисәң, ул вакытта ник бу кадәр яшеренеп, урланган кебек туй итәргә? Хәер, алар бит мине Галия теләсә-теләмәсә алырга тели дип уйлыйлар. Алар бит бу эшләрнең барысы да Галия өчен, бу авырлыкларның барысы да Галия сәгадәте өчен икәнлеген аңламыйлар. Алай дисәң, Галия ник миңа үзе хат язмый? Ник миңа үзенең ни фикердәлеген белгертми? *(Туктап торып.)* Булдыра алмый торгандыр шул! Тирә-яны каравылдыр. Янына беркемне кертми-чыгармый торганнардыр. Кем белсен, бәлки, минем хакымда әллә ниләр ялганлый торганнардыр. Әллә минем алдым-бирдем язуын бирүемне элгәрege бөтен сүзләремнән кайту дип аңлады микән? Алай дисәң, Сорур апа аша язган хат! Ник ул Әхмәдиләрнең ялганнарына ышана да, минем хатыма ышанмый? Шәт, ул хатны да ала алмагандыр. Шәт, аның янына Сорур апаны да кертми торганнардыр. Берсен дә белер хәл юк. *(Уйлап кына.)* Берсенең дә очына чыгар хәл юк. Ике атна буе уйлый-уйлый башым катты. Уйладым, уйладым, әллә никадәр шәкерт фаразлары кордым, берни чыкмады, уф... Арыдым! Ике атна бербуйдан рәтләп йокламаенча үткәрдем, ике атна бербуйдан белемсез хәлдә тордым. Ни булса булды, үтәсе көн үтте. Бүген актык көн, бу сәгать актык сәгать. Шул сәгатьтә, шул минутта бөкмечөкме икәнлеге беленә. Тизрәк! Тизрәк! Туйдым. Бу өмет, бу көтү туйдырды, бу йокысыз кичләр, бу сагышлы көннәр егерме еллык яшьлегемне югалтты. *(Сәгатенә карап.)* Вакыт! Бик вакыт! Ни булса да бер хәбәр алырга вакыт! Нишләп торалар? Шулай ук бу карт хәзрәт тә сатылыр микәнни?

Исмәгыйль килеп керә.

Исмәгыйль. Ни булса да булды, карт хәзрәт, бик кызуланып чыгып, ат берлә өенә кайтып китте!

Ибраһим. Тизрәк бетсен иде, тизрәк! Шулкадәр арыдым. Шулкадәр туйдым, әйтеп бетерерлек түгел!

Исмәгыйль. Хәзер буласы булды инде, биш-ун минуттан бөтен эш мәгълүм була! Ләкин карт хәзрәт ник кайтып китте? Менә шуны белеп булмый. Минемчә, туй булмаган булырга кирәк. Мин карт хәзрәтнең сатылуына ышана алмыйм!

Ибраһим. Алай булса, аны бер сүз табып алдап йибәргәннәрдер дә, теге куянбаштан укытканнардыр. Ничек булса да, хәзер өметләнергә ярамый.

И с м ә г ы й л ь. Өметсез шайтан ди. Мин һаман әле эшнең алар теләгәнчә бетүенә ышанмыйм!

И б р а һ и м. Эшнең ахыры ничек буласы билгеле, ләкин алар ничек булса да, шулай алдаштырып никях укытып, кияү кертеп, Галияне тиз генә, берни белдермәенчә моннан озатмакчы булалар.

И с м ә г ы й л ь. Соң Галия шулай, язмышымдыр дип, риза булып калырмыни?

И б р а һ и м. Кем белсен! Дөньяда әллә нинди без аңламый торган эшләр була! Ләкин мин Галияне шулай калыр дип ышана алмыйм! Ул башка кызлар кебек түгел. Ул үз сүзен итәр өчен бернидән дә курыкмый торган, нинди авырлыкка да риза була торган кыз. Менә шуның өчен мин Галиягә тагы әллә нинди авырлыклар күрергә тугры килер дип куркам. Үзең уйлап кара, аны нинди юл берлә булса да алдап, мине ялганчы иттереп ышандырган булсалар, ул, эченнән миңа әллә никадәр дошманлык җыеп, никяхка риза булмый хәле юк. Кияү кергәч яисә кияү берлә бер ике-өч кич үткәргәч, ул үзенең алданганын белсә, нишләр? Кияү берлә элгәреге кебек калырга аның күңеле риза булмас, арада шулкадәр эшләр үткәннән соң миңа килергә вөҗданы күтәрмәс. Үзен минем алдымда гаепле дип белеп, анда барырга да белми, монда килергә дә белми, ут берлә су арасында калыр. Менә минем курыкканым шул минут. Шундый вакытта кешеләр үзләрен суга ташлыйлар, шундый вакытта кешеләр, үзләренең шул хәлләреннән котылырга юл таба алмаенча, үзләрен үзләре үтерәләр. Менә шундый вакытта Галия кебек саф күңелле кешеләр, үзләрен бик зур җани хисаплап, үзләренең җаннарыннан мәхрүм булырга сәбәп булалар. Менә Галия дә шулай булса нишләрмен? Галия дә үзенең шул хәленнән чыгарга, үзен шул үрмәкүч оясыннан коткарырга юл таба алмаса нишләрмен? Минем курыкканым шул, минем кайгыртканым шул!

И с м ә г ы й л ь. Әйе, алай булганда бу эшләрдән күз яшеннән башка нәрсә чыкмый!

И б р а һ и м. Менә шуның өчен мин ничек булса да бу эшне башламаска тырыштым, ничек булса да Галиянең күңелен кайтарырга дип, җавап язмаенча йөрдем, ахырдан үзем чыдый алмадым. Үземне тота алмадым. Менә хәзер шул хаталарның йимешен җыярга кирәк.

С а д ы й к килеп керә.

---

*Җани* — хыянәтче, җинаятьче.

С а д ы й к. Исәнме, Ибраһим, исәнме, Исмәгыйль.

И с м ә г ы й л ь.<br>И б р а һ и м. } Әлхәмдүлиллаһ, Садыйк абзый.

С а д ы й к. Ишеттеңме? Тегендә туй.

И б р а һ и м. Беләмез, беләмез.

С а д ы й к. Болар нишлиләр, болар нишлиләр?

И б р а һ и м. Кыз бирәләр, туй итәләр.

С а д ы й к. Әйе, кыз бирәләр, туй итәләр. Син хәзрәткә әйтмәдеңмени?

И б р а һ и м. Әйттем. Бөтен шаһитларны чакырып сораттым. Хәзрәт укымыйм дип вәгъдә кылды.

С а д ы й к. Алай булгач, ничек туй итәләр?

И б р а һ и м. Менә Исмәгыйль күреп килде, карт хәзрәт чыгып китте, ди.

С а д ы й к. Ә, алар, алай булса, бер-бер хәйлә табып, карт хәзрәтне чыгарып, теге акбаштан укытканнардыр.

И б р а һ и м. Без дә шулайдыр дип уйлыймыз.

Сцена артыннан аяк тавышы ишетелә.

И б р а һ и м. Бу кем бик ашыгып килә?

Бүлмәгә Г а л и я килеп керә. Һәммәсе сикереп торалар.

Г а л и я *(Ибраһимга таба килә. Садыйкны күргәч, бераз тартынып)*. Мин килдем... *(Ибраһим барып кулыннан тота.)*

И б р а һ и м *(Галиянең битендә кан күреп)*. Галия, сиңа ни булды?

Г а л и я. Кыйнадылар, кыйнадылар. Көчкә качтым. Уф! Аллага шөкер, котылдым, мәңгегә котылдым. Ибраһим, мин аларның кулыннан мәңгегә котылдыммы? Мине килеп алмыйлармы?

И б р а һ и м. Хәзер күңелеңне тыныч тот, Галия!

Г а л и я. Белмим, белмим! Котым калмады. Аз гына соңга калсам, башым беткән иде. *(Садыйкка.)* Садыйк абзый, син мине орышмыйсыңмы? Мин сине, Садыйк абзый, әтием кебек күрәм. Мин хәзер үз әтиемнең өеннән качып чыктым. Син хәзер минем әтием булырсыңмы?

С а д ы й к. Булырмын, булырмын, Галия!

Ишекне ачып, М ә р ф у г а карый да бик тиз тагы югала.

И б р а һ и м. Мин нишләргә белмәдем. Мин әле һаман үземне аңлый алмыйм. Чынлап ук, Галия, син килдеңмени?

Г а л и я. Чын, чын, мин килдем, мин бөтенләй кил-

дем. Мин синнән гүремә кадәр аерылмаска булып, бөтенләй килдем!

Исмәгыйль. Без инде, эш бетте, никях укыдылар, дип тора идек.

Галия. Мин ялганнарын тагы берәр сәгать соңрак сизсә идем, эш беткән иде.

Ибраһим. Ник соң, Галия, болай булырлык булгач, эшне иң чигенә калдырдың?

Галия. И, сез минем ничек торганымны белсәңез иде, исеңез китәр иде. Тәрәзәм бикле, ишегем бикле, янымда бертуктамаенча өч аксак хатын каравыл тора. Ялгыз бер адым да атлатмыйлар. Яныма беркемне дә кертмиләр. Өй тышында карлар, бозлар яусын, миңа бер сүз әйтмиләр. Чит кеше берлә сөйләтмиләр. Сорур апаны, Наташаны күрсәтмиләр. Менә шулай итеп тордым. Әүвәлдән үк качарга уйладым. Хатыннар миңа сөйләмәгән булып кына, сине качкан дип үзара сөйләшкәнгә, син монда юк дип уйладым, синнән хәбәр көттем, ала алмадым. Беркөнне мине әти, әни, Әхмәди абзый, яннарына чакырып, алдым-бирдем язуын синнән сатып алдык, диделәр. Мин шуннан соң үземнең нишләгәнемне белмим. Һушсыз булып егылдым. Мин һушыма килгәндә тагы шул аксак хатыннарны күрдем, тагы шулар каравылларга тотындылар. Өйдә ни эшләгәннәрен, сезнең нишләгәнне — берсен дә белмәдем. Ләкин алдым-бирдем язуын күргәч, бергә тору өмете бетте. Бу көнгә кадәр шулай тордым. Бүген Сорур апа әллә ничә мәртәбә ишекне ачып япты. Мин, бернәрсә бар, күрәсең, дип, көтә башладым. Ахырдан косасым килә дип чыгарга сорадым. Өч хатын тагы каравылга чыкты. Сорур апа бик ашыгып килде дә кулыма кәгазь бирде. Хатыннар аны кыйнарга тотындылар. Берсе минем кулыма ябышты. Аксак аягына типтем дә егылды. Үзем качып чоланга бикләндем. Анда язуны укыдым. Ибраһимның хатын күргәч исем китте. Аның соңында тагы бер кечкенә кәгазьне карасам: «Хәзер сине бирәләр, теге өйдә муллалар никяхка җыелдылар»,— дип язган. Хатыннар минем бүлмәмне дөбердәтергә тотындылар. Мин тәрәзә ваттым да муллалар өенә чаптым. Андагы хатыннар мине җибәрми башладылар. Әхмәди абзый чыкты да кыйнарга тотынды. Мин алай да, кайсысын тешләп, кайсысын тырнап, муллаларга әйттем дә тәрәзәдән сикереп качтым. Менә хәзер мин монда!

Ибраһим. Галия! Галия! Син никадәр минем өчен җәфалар күрдең. Никадәр егетлекләр берлә үзеңне үзең

саклый алдың. Син — каһарман! Син бөтен татар кызларына үрнәк булдың, син шул черегән татар галәменнән, шул сасы аксак хатыннар дөньясыннан үзеңне үзең коткардың, хәзер син киң-хөр дөньяга чыктың!

Шул арада кортлы май күтәреп Мәрфуга килеп керә.

Мәрфуга *(Галиягә килеп, аркасыннан кагып)*. Төкле аягың берлә кил! Кап, бәбкәм, кап! *(Галия аптырап тора.)*

Садыйк. Галия, кортлы май кап! Мәрфуга җиңги киленне кортлы май берлә каршы алмакчы була! *(Галия кортлы май каба.)*

Мәрфуга. Йа Рабби, Аллаһе Тәгалә хәерле изге көннәр бирсен! *(Галиянең аркасыннан тагы кагып, еглаган тавыш берлә.)* Алла хәерле гомер бирсен! Алла тынычлык берлә рәхәт күрергә язсын! Миннән бер дә курыкма! Мин үз әниең кебек булырмын.

Садыйк. Әйе, үз әнисе кебек булсаң шәп булыр?!

Ибраһим. Әни, улояла әле.

Мәрфуга. Ярый, ярый, мин чыгам.

Шул арада ишектән акыртын гына Хәлил берлә Гарифә керәләр.

Галия. Килделәр, килделәр! *(Кача башлый.)*

Ибраһим. Качма! Качма! Без монда вакытта берни булмас.

Бар да аягүрә торалар. Гарифә качыбрак керә.

Садыйк. Хуш килдегез, кодалар! Мәрфуга җиңги, кодагыйны каршы ал! Туйлар мөбарәк булсын! *(Хәлил акыртын гына килә. Галия читкәрәк китә.)* Кичә сезнең урамда бәйрәм булса, бүген безнең урамда бәйрәм. Хуш килдегез! Ибраһим, нишләп торасың, бабайны каршы ал!

Мәрфуга *(Гарифәгә килеп)*. Тәкъдир шулайдыр, Гарифә! Сөешү пәйгамбәрләрдән калган!

Ибраһим. Утырышыгыз! Тугдык җиңги, утыр! *(Хәлил дә, Гарифә дә утыралар.)*

Садыйк. Яңез, Хәлил, хәзер эш башка төс алды. Инде нишлисез, Гарифә килен? Син ни уйлыйсың?

Гарифә. Хәзер безнең эшемез юк. Картайган көнемездә шулкадәр хурлык күргәч, без нишлик? Әнә аңардан сора. *(Галиягә күрсәтә.)*

Садыйк. Кем кушты сезгә эшне шуңарга җиткерергә? Мин сезгә әйтмәдемме, сез ниләр кылындыңыз!

Мәрфуга. Әлхәмдүлиллаһ, барысын да күрдек. Өемезгә тентү дә керттеңез, үтерергә дә кеше ялладыңыз, Аллаһе Тәгаләнең кодрәте киң, тагын шул кешеләргә үк кода булып килдеңез!

Г а р и ф ә *(сикереп тора)*. Без кода булып килмәдек, кызымыз артыннан килдек.

И б р а һ и м. Әни, иске җәрәхәтләрне яңартма! Аларның ансыз да бүген авыр көннәре.

М ә р ф у г а. Ым-м... алай икән! Миңа да җиңел булмады. Өемә тентү керттеләр, әбиеңнән калган буй бөтиемне алып киттеләр, атаң төсе дип тоткан «Әмин тәзәк»емне югалттылар.

С а д ы й к. Ярар, Мәрфуга җиңги, алар бар да булыр. Хәлил, хәзер нишлисез?

Х ә л и л. Садыйк абзый, син ник бездән көләсең, ник син безнең кайгымыздан шатланасың?

С а д ы й к. Көлмәскә. Мин монда кайгы күрмим! Монда шатлыкка башка нәрсә юк! Ике сөешкән кешене әллә нинди юллар берлә аерырга тырышканнар, Алла ярдәм биргән, алар тагы кушылганнар. Моның кадәре зур шатлык булырмы? Дөрестме, Галия? *(Галия башын селкә.)* Йә, килен, сөйлә! Хәзер нишлисез?

Г а р и ф ә. Без кызымызны алырга килдек!

И б р а һ и м. Сезнең кызыгыз минем хатыным, ул хәзер сезгә бармый!

Г а л и я. Киселгән икмәк кире ябышмый. Мин ул өйгә ялгыз кайтмыйм!

С а д ы й к. Ишеттеңме, килен! Хәзер ул сүзләрне сөйләргә соңгарак калдың, аның базары үтте. Аларны Әхмәди берлә сөйләшергә ярый иде. Менә хәзер нишлисез?

Г а р и ф ә. Аның алдым-бирдеме бездә.

И б р а һ и м. Монда хәзер алай тартышып торудан эш үткән. Без Галия берлә сезгә мохтаҗ түгел! Хәзер сез икенче мәртәбә Галияне бикләп тота алмыйсыз, сез хәзер Галияне *(битенә күрсәтеп)* тагы авызын-борынын кан итеп кыйный алмыйсыз. Әгәр кеше төсле кылынасыңыз килсә, без сезнең ул усаллыкларыңызны онытырга хәзер!

М ә р ф у г а. Онытыр хәлем юк! Бик үзәгемә үтте. Алтмышка кадәр ишетмәгән сүзләрне ишеттем. Мин сихерче дә булдым, мин карак та булдым...

С а д ы й к. Мәрфуга җиңги, аларны оныт! Бүген күргән синең шатлыгың аларның барысын да оныттырырлык.

М ә р ф у г а. Әлхәмдүлиллаһ, Аллага шөкерләр кылып бетерерлек түгел. *(Елаган тавыш берлә.)* Бу көнне күрермен дип уйламаган идем.

Х ә л и л *(еглаган тавыш берлә)*. Бу эшләрдә без га-

*Буй* — хуш исле.

епле. Без көч берлә җиңелми торган нәрсәне көч берлә җиңмәкче булдык. Без акчага сатылмый торган нәрсәне акча берлә сатып алмакчы булдык. Без үземезнең сүземезне итәр өчен Ибраһимга әллә никадәр бәла китердек. Мин хәзер уйлап-уйлап карыйм да, үземнең эшләгән эшләремә үзем ышанмыйм. Үземнең кылган начарлыкларыма үзем оялам. Сезнең алдыңызда бик күп гаеплемез. *(Ибраһимга карап.)* Шулай булса да, шул кызның атасы — без, шуларны үземезчә кызымызның рәхәте өчен дип кылган! Безнең гаебемезне йөземезгә бәрмәңез! Без инде ул эшләргә җитәрлек җәза күргән. *(Гарифәгә күрсәтеп.)* Аның сүзенә карамаңыз. Ул йөрәгенә чыдый алмаенча сөйли, аны да аңлаңыз. Ул сезнең төсле тәрбия күрмәгән. Ул ничек үскән, ничек яшәгән, кызын да шулай яшәтмәкче булган! Безнең гаебемез бик күп булса да, безнең кылган яхшылыгымыз да бар. Без үземез нинди начар булсак та, аны начарлык берлә тартышырга өйрәткәнмез. Менә шуның өчен без, иске дөнья кешеләре булсак та, сезгә, яшьләргә яраклы кыз үстерүемез өчен, яңы тормышка яраклы кыз тәрбия кылуымыз өчен сез безне кичерергә кирәк. Мин хәзер *(Ибраһим берлә Галиягә.)* сезнең бер эшеңезгә дә каршы килмим. Бер-береңезне яратышасыңыз икән, Алла хәерле гомер бирсен!

Садыйк. Рәхмәт, Хәлил, күптән шул сүзне сөйләргә кирәк иде. Ул вакытта бу эшләрнең берсе дә булмый иде. Үткән эш үтте.

Ибраһим. Рәхмәт, Хәлил абзый! Син соңрак булса да инсафка килдең! Мин синең ни сөйләгәнеңне, ни әйтергә теләгәнеңне аңлыйм. Сезнең кылган эшләреңезнең дә үзеңезне аңламаудан икәнен белгәнгә, сезнең бу кылган эшләреңез дә карт дөньяның, үзенең көчен белмәенчә, яшь тормыш берлә тартышуы гына икәнен белгәнгә, шул эшләр хакында бер сүз сөйләмәскә, шул ямьсез вакыйганы бу көннән үк онытырга вәгъдә бирәм. Бу эш сезнең берлә безнең тартышу гына булмады, бу эш иске тормыш берлә яңы тормышның тартышуы булды. Бүген безнең җиңүемез — яңы тормышның җиңүе, бу көнге безнең бәйрәмемез — яңы тормышның бәйрәме!..

Гарифә *(еглаган тавыш берлә)*. Бу эшләр һәммәсе дә минем усаллыгымнан булды, мин кызымны сөйгәннән, кызыма рәхәт күрсәтәсем килгәннән шулай кылындым. Мин сезне белмәдем, мин үземчә уйладым.

Галия. Үтәсе эш үтте. Ул эшләрне хәзер яңартудан файда юк! Ләкин бу эш сезгә сабак булсын, мин китсәм дә, безнең нәселдә кыз бик күп. Моннан соң, аксак ха-

тыннар сүзенә карап, кызларыңызны җәһәннәмгә салырга юл хәзерләмәңез! Моннан соң кешенең сөюен гаеп итеп, шуның өчен аны җәзаларга юл эзләмәңез! Барыбер берни эшли алмыйсыз, барыбер, никадәр мәшәкать күрсәңез дә, яшь тормышны җиңә алмыйсыз, никадәр кыссаңыз, никадәр аның юлына чүп-чар өйсәңез дә, ул тиресләр яшь тормышның тазаруына гына сәбәп булалар, яңы тормышның ныгаюына гына сәбәп булалар. Үзеңезнең иске коралларыңыз берлә яңы тормышка каршы сугыш ачмаңыз! Үзеңезнең наданлыгыңыз берлә яктылыкка, киңлеккә каршы тартышмаңыз! Без сезне җиңгән кебек, яшь тормыш иске тормышны җиңәр!

Ибраһим. Яшәсен яңа тормыш!

Садыйк. Яшәсен яшьләр!

Пәрдә төшә.

# МӨГАЛЛИМ

*Драма биш пәрдәдә*

КЕШЕЛӘР:

Салих — авыл мөгаллиме. Халыкка хезмәткә тотынган егет.
Мәрзия — аның хатыны. Гыйлемнән аз гына да ләззәт ала алмый торган, вак тормыштан үтә алмый торган надан бер хатын.
Гайнелхәят — Мәрзиянең анасы. Үзен бик белә дип уйлый торган авыл бае хатыны.
Вахит — компаниядән калмый торган шәкерт.
Закир — аңлы гына авыл кешесе.
Мәрфуга — сүз йөртүче карчык.
Фазыл — үткен егет.
Кешеләр — малайлар, егетләр.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур гына бүлмә. Тәрәзәләр зур. Түшәм биек. Стенада харита. Өстәл өстендә көррәи мөҗәссәмә. Каршы тарафта такта берлә бүлгән тагы бер бүлмә, ишегенә пәрдә корылган. Идәндә таз, комган. Эңгер-меңгер вакыт. Салих кулына дәфтәр күтәреп килеп керә. Егерме ике яшьләрендә егет. Өстендә татар казакие, кара кәләпүш. Дәфтәрләрне өстәлгә куеп йөрергә тотына.

Салих. Нинди зур эш! Исәпләп карасаң, күңел рәхәтләнеп туя алмый. Бер ай эчендә утыз бала язу танысын, имеш! Элгәреге заманда моңарга кем әйтеп, кем ышаныр иде? Мәктәпкә керсәм, күңел рәхәтләнә. Шуннан чыгасы килми. *(Йөри.)* Әйе, минем шобагага менә бик зур эш төште. Мин, ялгыз, наданлык берлә эштән чыккан, тәгассыб берлә сасып беткән татар авылына килеп, гыйлем нуры сачә башладым. Минем кулыма зур мәктәп бирелде. Минем ихтыярыма бөтен авылның балаларының тәрбиясе тапшырылды. Мин аларның барысының да башларын нурландыручы булам. Мин аларның барысына да тугры юлны күрсәтүче булам. Мин бу

---

*Харита* — географик карта.
*Көррәи мөҗәссәмә* — глобус.
*Тәгассыб* — фанатизм.

авылга гына түгел, бөтен тирә-якка мәдәният орлыгы сачәм. Мин бу буын балаларын гына түгел, киләчәк буынның да тәрбиячесе булам. Мин боларның һәммәсенең рухани аталары булам. Нинди зур эш! Нинди зур бәхет. Бу бәхет кемгә мөяссәр була?

Бер малай кайнаган самавыр күтәреп килеп керә.

Малай. Хәлфә, самавыр өлгерде, хәзерлимме?

Салих. Хәзерлә. *(Үзе кулларын юарга тотына, малай тәбәнәк өстәлгә чәй хәзерли дә, лампаны алып чыгып китә. Салих чәй янына килеп утыра да чәй ясый, чәйне эчеп.)* Эчәсе килгән икән, эчәсе килүне дә онытканмын! Кешеләр мине килгәннән бирле ябыктың диләр. Ашау-эчү рәтләп вакытында булмагангадыр. Тәнем ябыкса ябыгыр, җаным симерде. Мин тән колы түгел, җан колы.

Кечкенә генә бер малай чәйнек күтәреп керә.

Малай *(чәйнекне сузып)*. Хәлфә абый! Әни сиңа каймак җибәрде, Гариф абзый өлеше, диде. Бик дога кылып чәй эчсен, диде.

Салих *(торып ала)*. Рәхмәт...

Малай *(читкә карангалап)*. Апа, матур китап юкмы, диде?

Салих. Нинди матур китап, укыргамы?

Малай. Әйе!

Салих *(торып, шкафын ачып актара да берне алып бирә)*. Мә, менә, ертмасыннар, буямасыннар, аннары китер.

Малай. Ярый. *(Чыгып китә.)*

Салих. Монда бер мәктәп кенә түгел, бөтен ирен, хатынын тәрбия кылып була. Мәктәпне, мәктәп кенә түгел, бер зур көтепханәгә әйләндереп була!

Шаулама! Вазыйфә алгач, Казанга хат язып, яңа китаплар алдырырга кирәк. Укысыннар, балалар гына түгел, зурлары да укысын. Чынлап әйткәндә, алар барысы да бала әле!

Малай ут күтәреп керә. Бүлмә яктырып китә. Салих чәй эчә, малай чыгып китә.

Салих. Каймак начар түгел. *(Каймак ашый. Торып, дәфтәрләрне алып төзәтергә тотына. Бер дәфтәрне кулына тотып.)* Садыйк малаеныкы. Бер ай тәртип берлә укыган малай ничек яза икән? Карыйк әле. *(Кулына*

---

*Мөяссәр булу* — бу урында: тию, эләгү.
*Вазыйфә* — хезмәт хакы.

*каләм тота.)* Ә, алай икән! *(Төзәтеп.)* Иҗек бик зарар итә! Ысуле саутия белми! Кара, малай нәрсә язган! Ярар, төзәлер әле. *(Икенчесен алып.)* Монысы нинди? Ә, монысы арттырыбрак җибәргән. «Хәкъ»не «хак» дип, «хлык»ны «халык» дип, мирзаларча яза. Әллә мирзалар нәселеннәнме?

Шул арада бер кеше килеп керә.

Кеше. Әссәламе галәйкем!

Салих. Вәгаләйкем әссәлам!

Кеше *(иске генә билле туннан, киез катадан авыл мужигы. Кесәләрен актарырга тотынып)*. Менә, хәлфә, миңа шул язуларны гына укып бир әле. *(Ыштан кесәсеннән язу эзли.)* Алып булмый. Ә, булды, мә! *(Бер-ике ертык кәгазь алып Салихка бирә.)*

Салих. Утыр. *(дип, урын күрсәтә.)*

Кеше. Ярар, рәхмәт, басып та торырмын! Иртәгә базарга барырга телим дә. Аллага тапшырып, бер атны сатыйм дигән идем. Азык кыйбат, барыбер кыш чыгарып булмый.

Салих *(укый. Бераздан соң бер кәгазьгә күрсәтеп)*. Менә монысы сары алаша тамгасы: уң колагы ярган, яше ундүрттә дигән.

Кеше. Ә, ансы булмады. Ул иске ат язуы, саткан атныкы. Мин ул атны, теге ачлыкта Әхмәдиләргә саткан идем, яхшы ат иде хайван. *(Салих карап тора.)* Менә тын да алмаенча, ике сәгатьтә шәһәргә барып җитә иде. Энем солдатка китеп барды, аңарга бурычландык, ул арада азык бик кыйбатланды. Сатмаенча булдыра алмадым.

Салих *(икенчесен укып)*. Монысы өйдә туган җирән бия. Сигез яшендә, тамгасы юк!

Мужик. Менә шул кирәк иде. Рәхмәт, хәлфә! Безнең әле, кара кеше, үзебез укып булмый. Малайны укыттым, укыттым — язу таныйрлык булмады. Суфи абзыйдан укыды.

Салих. Ничә ел укыды?

Мужик. Белмим, биш-алты ел укыды.

Салих *(көлеп)*. Менә минем шәкертләрем хәзер бер ай укыдылар, язу таный башладылар. Тагы ике ай укысалар, нинди язуны да укырлык булалар.

Мужик. Ул вакытта мондый машина берлә укыту юк иде. Суфи абзый гына укыта иде. Ул вакытта мөселманча гына иде.

Салих. Хәзер русчамыни?

---

*Ысуле саутия* — аваз методы.

М у ж и к. Мин белмим, шулай, диләр, кара такта берлә, бисмилласыз китап берлә, диләр. Сабак укыткан өчен жалунияне Булыгин марҗасы бирәме?

С а л и х. Нишләп Булыгин марҗасы бирсен. Миңа Шәһидуллиннар бирә.

М у ж и к. Безнең халык белер-белмәс сөйли инде шунда.

С а л и х. Әле син базарга барам дигән идең, менә миңа шул кәгазь берлә дару алып кайт әле. *(Рецептны тотып тора.)*

М у ж и к. Белмим, мин ала белермен микән соң? Минем бит әле баруым да икеле. Барсам, сүз дә юк иде.

С а л и х. Ярый, алай булса.

М у ж и к. Хуш, рәхмәт. *(Чыгып китә.)*

С а л и х. Синең вакытыңны бернигә санамый. Үзе биш минутка аптекка кереп чыгарга да авырсына! *(Тагын берне ясап эчә дә төзәтергә тотына.)* Менә мин үземнең хезмәтем берлә шуларны агартырга кирәк. Менә мин шуларның күңелендәге ышанмауны бетерергә кирәк. Шул мәгариф, мәдәният дошманнарын мәгариф, мәдәният колы итәргә кирәк, акрын гына бары да булыр.

Берсе артыннан берсен дәфтәрләрне төзәтеп читкә куя бара. Шул арада кулына чәйнек тотып бер к а р ч ы к килеп керә.

К а р ч ы к. Исәнме, бәбкәм? Хаматвафам (Мөхәммәтвафам) баярга иген тияп базарга барган иде. Атымыз авырып кайтты, бердәнбер атымыз иде. Өшкереп кенә бирсәнә, балакаем. *(Чәйнекне Салихка бирә.)* Тозлы су. Ауный да ауный, үлмәсә генә ярар иде. Көз көне имана түләргә кырыкмышымызны саткан идек, бу ел колыны да булмады. Бердәнбер атымыз! Керәшен зияраты яныннан әйләндереп карадылар, файда булмады.

С а л и х. Мин өшкерүдән ни файда булыр? Мин өшкерә белмим, әби!

К а р ч ы к. Алып килергә акчам булмады. Менә үзеңә җеп китердем, бик ихлас берлә генә эрләдем*. Өшкерсәнә, атымыз терелсен лә!

С а л и х. Миңа, әби, бернәрсәң дә кирәкми, мин өшкерә белмим, сез аны ат дуктырына алып барыңыз?

К а р ч ы к. Ә, урысча гына беләсеңмени? Син өшкерә белмисеңмени?

С а л и х. Белмим, белмим! Өшкерүдән барыбер файда юк. Ат дуктырына әйтеңез!

---

* Оригиналда: «бәйләдем».

*Тияп* — төяп.

Карчык. Алай булса, суфига барам, аңардан ат бирәсеннән өшкертим! *(Җебен алып чыгып китә.)*

Салих. Болар бөтенләй минем кем икәнлегемне белмиләр. Монысы миңа өшкертергә килгән. Менә мин шундый өшкерү-төкерү ялганнарын бетерергә килдем. Әй наданлык! Мескен авырган атны минем төкерүем берлә яисә әллә нинди бер сукыр суфиның өшкерүе берлә терелтмәкче була! Алай гына терелтеп булса, бер- кем дә унар ел гомерләрен әрәм итеп университетларга кереп укымас иде! Наданлык, наданлык! Бу караңгылыкта, бу наданлык дәрьясында әллә никадәр эшләргә кирәк! Әллә ничә еллар армаенча хезмәт итәргә кирәк.

**Тагын дәфтәрләрен төзәтә, шактый гына вакыт төзәткәч, бер егет килеп керә.**

Егет. Әссәламе галәйкем!

Салих. Вәгаләйкем әссәлам!

Егет. Бик исәнме, мулла абзый, мин сине иртәгә мулла янына чакырырга килгән идем.

Салих. Кай вакыт?

Егет. Мулла абзый сәгать уннарда диде.

Салих. Юк, миннән булмый. Ул вакытта минем эшем бар, мин ул вакытта укытам.

Егет. Әти калырга әйтмәде.

Салих. Әйтәм ләсә, мин ул вакытта мәктәптә булам дим, бик рәхмәт!

Егет. Баргач, рәхмәт булыр. Ашка барганнан әллә ни булмас әле. Суфи абзыйның да шәкертләре бар да, ул бара.

Салих. Мин бара алмыйм. Укыту вакытында алай китеп йөрергә ярамый.

Егет. Без дә мәктәптә укыдык та, мулла абзый бервакыт та аш кайтармады. Син бигрәк зур булгансың, аштан да олуг икәнсең. *(Егет чыгып китә.)*

Салих *(торып йөрергә тотына.)* Менә болар берлә нишлисең инде! Монысы үзенә тагын бертөрле мантыйк берлә килгән. Минем сабак вакытында сабак ташлап йөрмәвем минем аштан да олуглыгымнан, имеш. Бар, болар берлә сөйләш! Торган саен наданлык үзенең ямьсез якларын күрсәтә бара. Торган саен хезмәт мәйданы киңәя бара, бик күп эшләргә кирәк. *(Уйлап торып.)* Аның каравы монда сачелгән гыйлем, мәдәният орлыгы, урман әрчеп сачелгән йир кебек, бер орлыктан мең бөртек булыр. Караңгылык никадәр куәтле булса, утның яктысы шулкадәр ачык була. Аның каравы аның файдасы шулкадәр күп була! Менә монда бу караңгы дөньяда

минем мәктәбем әллә никадәр яктылык таратыр, әллә никадәр файда итәр.

Шкафны ачып бер китап ала да укырга тотына. Бераздан соң, кулыннан бер бала тотып, бер к е ш е килеп керә. Кешенең кулында китаплар.

К е ш е *(ачуланган тавыш берлә)*. Менә, хәлфә, бу минем малаем, шуның өчен синең яныңа килдем. Аңарга ник кеше төсле укытмаенча, «арба-чана» укытасың. Без дә, әлхәмдүлиллаһ, яшь вакытта укыдык, тирә-якта мәшһүр кеше мулла Әхмәт абзыйдан укыдык. Әгәр бер сүзгә генә яңлыш мәгънә бирсәң, бер колакка сугып җибәрә иде, икенче колактан кан чыга иде. Моның шикелле «арба-чана» укытмый иде.

С а л и х. Синең угылың да, зурайгач, мәгънәле китап укыр, аны әле төрки танымаенча бит мәгънәле китапка төшерер хәл юк.

К е ш е. Алай булгач, аңарга ник «Иман шарты»ннан башлатмадың? Мин үзем өйдә юк, хатын-кыз ни белә? Әле кичә генә кайттым, угылымны тыңлатып карасам, бернәрсә белми. Иман укытырга телэдем — аны белми. Иҗек укытырга теләдем — аны белми.

С а л и х. Без, шул, алай баштанаяк баланың башын ватып, иҗек укытмыймыз, элгәре төрки танытамыз.

К е ш е. Безгә шул синең «арбаң-чанаң» кирәк түгел, без арба-чананы үземез ясыймыз. Менә минем угылымны искечә укытсаң укыт, укытмасаң, кирәкми, суфига бирәм.

С а л и х. Син, абзый, юкка кызасың, бер айда угылың хәреф таныды. Элгәреге ысул берлә бер айда таный ала идеме?

К е ш е. Тиз таныса — тиз онытыр. Менә шулай укытамсың?

С а л и х. Юк. Мин, алай укытып, балаларның башын черетергә килмәгән.

К е ш е. Укытмасаң, кирәкми. *(Китапларын күтәреп бәрә дә чыгып китә.)*

С а л и х *(бераз гаҗәпкә калып катып тора да китапны идәннән алып өстәлгә куя)*. Үз файдасын үзе аңламаенча никадәр зарар итә! Баласы нинди яхшы укый иде. Аны хәзер инде суфига илтеп, башын черетергә тели. Наданлык, наданлык! Атасының наданлыгы, үзен бик күп беләм дип уйлавы аркасында баласы мескен надан калырга кирәк. Ул уку-укыту каторжный эш кебек булмаса, аны уку да түгел дип белә. Менә мин дә аның, мулла Әхмәт абзыйсы төсле, бер колагына сугып

җибәреп, икенче колагыннан кан чыгарсам, бәлки, яхшы мөгаллим булыр идем. *(Уйлап торып.)* Юк, мин, шул, монда зобани булырга килмәдем. Мин мәдәният, мәгариф таратырга килдем. Гыйлемнең ачы агу булмаенча, балдан да ләззәтле идекен исбат итәр өчен, «әбара, бәара, бәраә»нең заманасы үткәнен белдерергә килдем.

Тагы китабын алып укырга тотына. Малай кереп самавырларны җыештырып ала. Бераз укый, шул арада кызыл гына муенына шарф ураган, биленә кызыл билбау буган бер егет кулына бер бәйләм клиндер күтәреп, кәгазьгә төргән бал тотып килеп керә. Салих исе китеп карап тора.

Егет. Исәнме?

Салих. Аллага шөкер!

Егет. Синең яныңа кереп утырыйм, дидем. Егет кешегә күңелсездер, дидем.

Салих. Күңелсез түгел. Минем эшем бик күп. Эч пошарга бушар хәл юк.

Егет. Әйдә әле, самавыр куйдырып җибәр әле! Бал берлә үзеңне сыйлыйм әле.

Салих. Мин хәзер генә эчтем. Теләсәң, сиңа куйдырыйм. Үземнең эчәсем килми.

Егет. Бал берлә эчәрсең әле. Мин сыйларга дип килдем. Читтән килгән кеше, күңелсездер, дидем. Кызлар берлән дә таныш түгелдер, дидем.

Салих. Мин монда кызлар берлә танышырга дип килмәдем, мөгаллим булып килдем. Эчәмсең, куйдырыйммы?

Егет. Куйдыр, сөйләшеп утырырмыз әле. *(Өстен тишенә.)*

Салих диварны кага. Шул арада малай килеп керә.

Салих. Самавыр яңарт әле.

Малай. Ярый, мәктәптә мич яна, хәзер кайнатам.

Егет *(утыра. Кесәсеннән бер әллә ничә төрле буяу берлә буяп бетергән кызлар хаты алып Салихка бирә.)* Мә, укы әле! *(Салих укый.)* Шәпме? Менә шуңарга каршы хат язарга кирәк. Син бик төшертеп китап бәетләре берлә генә язып бир әле. Синең буяулы караң бармы?

Салих. Карам бар да, мин андый хат яза да белмим, язасым да килми.

Егет. Сездә андыйны язмыйлармыни? Алай булса, үзеңчә язып бир! Бер фурмы булсын!

Салих. Мин яза алмыйм.

---

*Тишену* — чишенү.

Е г е т. Син миннән курыкма, мин сер саклый торган егет. Бүген булмаса, иртәгә язарсың. Менә чәй эчик тә кызлар кич утырган йиргә барыйк. Бик шәп кызлар берлә үзеңне уйнатырмын.

Шул арада **м а л а й** самавырны кертә.

С а л и х *(малайга)*. Чәй сал.

Малай чәй сала, чәй урыны хәзерләп чыгып китә. Салих егеткә чәй ясап бирә, үзе эчми. Егет, кесәсеннән бер бутылка аракы чыгарып, бер дә сорамаенча-нитмәенчә стаканга сала да Салихка бирә.

С а л и х. Мин эчмим!

Е г е т. Нәрсә эчмисең? Монда беркем юк, син миннән курыкма! Эчеп җибәр.

С а л и х. Юк, юк. Юкны сөйләмә! Әллә син мине тилегә санадыңмы?

**Е г е т** үзе эчә.

Е г е т. Син әле әллә ни кылынасың. Безнең монда елның елында хәлфә була иде. Бер дә болай кыйланмыйлар иде, яше җиткән егетләр чыкмаенча хәлфә янында яталар иде. *(Үзе чәй эчә. Салихка.)* Син ник эчмисең? Эч әле бал берлә, бал бик яхшы.

С а л и х. Минем эчәсем килми.

Е г е т. Син кызык кеше. Хуҗа эчмәгәч, мин нишләп эчеп утырыйм. Хәерле булсын. Алай булса, әйдә кызлар янына барамыз.

С а л и х. Мин нәрсәгә барыйм анда?

Е г е т. Менә сүз! Кызлар янына нәрсәгә баралар? Күңел ачарга.

С а л и х. Юк, мин бармыйм.

Е г е т *(торып китә башлап)*. Син безгә серне белгертмәскә телисең. Бездән качып йөрмәкче буласың, юк, ансы булмас, без мондагы эшне барын белеп торамыз.

С а л и х. Белеңез, минем яшерен эшем юк.

Е г е т. Безнең монда хәлфәләр безнең сүздән чыкмыйлар иде. Без кызлар янына барсак, алар да баралар иде. Без утырышлар ясасак, калпаниягә (компания) керәләр иде. Син бит учитель, сиңа кешедән куркып торырга түгел; син падишаһлыктан жалуния ала торган кеше.

С а л и х. Мин бер кемнән дә курыкмыйм, үзем теләмим.

Е г е т. Юк, син итәк астан йөретмәкче буласың. Теләмәгәч, ник Сәлахи кызына китап бирдең? Ә, эләктеңме?..

С а л и х. Мин сиңа да бирәм. Укырга бирдем.

Е г е т. Бездән качырып йөретмә, барыбер булдыра алмассың. *(Чыга башлый.)*

С а л и х. Бу нәрсәләреңне ал! *(Клиндер, бал, шешәга күрсәтә.)*

Е г е т. Сиңа бүләк булсын. Мин киткәч эчәрсең.

С а л и х. Миңа синең бүләгең кирәк түгел. Ал. *(Алып бирә.)*

Е г е т *(кесәсенә тыга-тыга)*. Ярар. Кайткан малда бәрәкәт бар ди. Бездән башка булдыра алмазсың. *(Чыгып китә.)*

С а л и х *(ялгыз калып)*. Менә нинди нахал! Мәктәпне кабак дип белгән. Мине, урам буенча өстерәп йөреп, кызлар тәрәзәсе төбендә катырырга тели. Син мөгаллим түгел, учитель, имеш. Учитель булгач, теләсәң нинди начарлыкны кылырга ярый, имеш. Минем укырга дип биргән китабымнан нинди мәгънәләр чыгармакчы була! Кайдан белеп өлгергән. Китап биргәнне белгәч тә, мине үзенә иптәш дип белгән дә бутылкалар күтәреп монда килгән! Менә кабахәт! *(Идән буенда йөрергә тотына.)* Никадәр вакытымны әрәм итте, никадәр кәефемне җибәрде, барысы да наданлык!

Шул арада бер к е ш е килеп керә.

К е ш е. Әссәламе галәйкем. Исәнме, хәлфә?

С а л и х. Исәнме, Закир абзый?

З а к и р. Мин сиңа шатлык берлә килдем. Шәһәргә барган идем. Сирай малайларының кибетенә кердем, хатынга алъяпмалык аласы бар иде. Менә теге күзлеклесе касса артында гәзитә укып тора. «Кая, гәзитәңне миңа бир әле. Бездә мөгаллим бар, дидем дә «каян, кем?» дип сорашкач бирде. *(Гәзитәне чыгарып бирә.)*

С а л и х *(«Тәрҗеман»ны ачып карарга тотына)*. Менә рәхмәт. Мин үзем дә гәзитәгә акча җибәргән идем, әле килеп җитми!

З а к и р *(утырып)*. Җә әле, кара әле, безгә бер-бер мнафист (манифест) юкмы? Патшаның угылы-фәләне тумаганмы?

С а л и х. Юк. *(Үзе укый.)*

З а к и р. Кара, күзен алалмый. Күңелсездер сиңа бездә. Кеше берлә дә катышмыйсың, муллалар берлә дә дуст түгел.

С а л и х. Юк, түгел, минем эшем күп.

З а к и р. Минем дә эшем күп тә, көне-төне эшлим дә, хатын кунакка гына китсә дә күңелсез була. Сиңа өйләнергә кирәк.

С а л и х. Яхшы кыз булганда, ярый шул.

З а к и р. И, кызның, син дигәндә, җиләген табамыз. Син әле күпме жалуния аласың?

С а л и х. Егерме сум.

З а к и р. Күп акча. Безнең монда шәһәр асты булса да, яхшы кәсеп итеп була. Кибет ачарга ярый. Мәшәкать дисәң, акча биреп торырга ярый. Менә әле безнең Әхмәтҗан Садридан бер сумны ике сум түләргә алды. Ул бит синең егерме сумың кырык сум була. Тагы иген таратырга ярый. Хәзер менә яңыга дип арышны туксан тинбер тәнкәгә алалар, базарда арыш 44 — 42 тин, менә ул кая китә!

С а л и х. Юк, мин андый эшләр берлә маташа алмыйм. Ул минем эшем түгел.

З а к и р. Сиңа бер дә маташырга да кирәк түгел. Өеңдә генә ятасың. Менә мин барысын да үзем эшли алам. Әйдә өйләнеп җибәр. Аннан соң карармыз. Менә, беләмсең, Хәйретдин кызы бик шәп бит, бик укымышлы. Ул өст-башы, җиһаз дисәң, әйтеп бетерерлек түгел.

С а л и х. Миңа мөгаллимә булырлык кирәк.

З а к и р. Барын да булдыра.

С а л и х. Өйләнүдән мин кире тормыйм, яраpлык булса өйләнәм.

З а к и р. Сиңа ярарлык булмаганны сөйләргә дә ярамый.

С а л и х. Менә монда Әмин авылы еракмы? Анда минем берлә бергә укыган шәкерт бар, менә шуның илә сөйләшеп карыйсы бар. Менә шуңарга хат язарга кирәк иде. Шуны җибәреп булырмы?

З а к и р. Була. Безнең Фәтхетдин иртәгә базарга бара, анда алар авылы кешеләре була.

С а л и х. Алай булса, языйм әле. *(Утырып яза.)*

З а к и р. Безнең монда туйны бик шәп итәләр, өйләнгәч, алай да сиңа бер кәсепсез ярамый. Әнә шул иген өләшүдән файдалысы юк. *(Салих яза. Бераздан язып бирә.)*

З а к и р. Ай-яй сине карт мулла яратмый! Беркөн ашта сөйләп утыра инде, алай уку хәрәм инде, ди, әле тик байлардан гына шикләнеп, синең алда койрыкны бутый.

С а л и х. Мин аңардан бик аз куркам бит, аңарда эшем дә бик аз. Мә. *(Хатны бирә.)*

З а к и р. Ярый, мин әлегә киттем, хуш. *(Чыгып китә.)*

С а л и х. Бусы мине әрәм тамак ясамакчы була. Мине бер пот иген биреп, ике пот алырга өйрәтә! Кызык! Болар берсе дә мине аңламый. Мин монда кеше таларга

килмәгән, мин гыйлем, мәгариф таратырга килгән. *(Йөреп.)* Өйләнергә ярар иде. Яхшы гына кыз алганда, аны мөгаллимә ясыйсың, үзең мөгаллим, әллә никадәр хезмәт итеп була. Вахит килсә, аның берлә сөйләшим әле. Чын да мөгаллим булып авылда торырга карар биргәч, өйләнмәенчә ярамый. Яхшы кыз гына булсын, бик үк укымаган булса да үзем укытырмын, мин мөгаллимлеккә өйрәнгән хәзер. Ул вакытта бу авыл таныр-лык булмас, угылы дисәң, угылы укыган, кызы дисәң, кызы укыган. Нинди зур эш, нинди зур бәхет! Өйләнәм! Кызлар мәктәбе ачам. Безнең байлар мәктәпкә акча кызганмыйлар, өйләнәм! Үзем өчен генә түгел, халык өчен өйләнәм.

Шул арада бер м а л а й килеп керә.

М а л а й. Әссәламе галәйкем, мөгаллим абзый, сине мунчага алырга килдем.

С а л и х. Мунчага?

М а л а й. Әйе. Элгәре мунчага, аннары ашка.

С а л и х. Ярый, мин күлмәк-ыштан алыйм әле *(сандык ачып, күлмәк-ыштан ала да киенә, малайга.)* Суык түгелме?

М а л а й. Түгел. Ат берлә килдем.

С а л и х *(киенеп бетереп)*. Менә мин, сала хәлфәсе, мунчага киттем.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мәктәпнең сыйныф бүлмәсе. Зур гына бүлмә. Парталар бер тарафка өелгән. Б е р  к а р ч ы к  аш урыннары хәзерләп йөри.

К а р ч ы к. Язмыш диген, әллә кайда туган, әллә кайда үскән кеше безнең авылдан килеп өйләнә. Дүртенче кат күктә никях укылган булгач, бер эш эшләр хәлең юк, тугандук саче сачкә бәйләнеп туган шул... Менә, кайчан килде, кайчан бездә тора башлады, туй да итә. Аннары балалары булыр. Аннары үзләре кызларын бирерләр, угылларын өйләндерерләр. Менә шулай итеп, гомер үтеп тә китә. Мин дә бер вакытны яшь кыз идем. Аннары Сафага кияүгә бирделәр, гомер иттек, картайдык, ул үлде. Менә мин калдым. Әлхәмдүлиллаһ, угылларым яхшы. Алай да унике угылың булганчы, бөкре ирең булсын диләр. Дөрест шул! Бу, дим, үзе әле хәлфә кеше, китап Коръәнне дә укый. Үзе төскә-башка да бик

чибәр. Ник соң әллә нинди урысча укытулар берлә маташа икән? *(Парталарга күрсәтеп.)* Кара инде, болар нәрсәгә? Урыс шкуласында шулай ди шул. Менә балаларны шунда тезеп утырталар да, ди, укып бетермәенчә бер кайда чыгармый, ди. Кара такта дигәннәре кая соң? Бу почмакка карадым, монда юк, монсына карадым, монда да юк... Кая соң? *(Парталар янында кара такта күреп.)* Ә, әнә шулмы әллә? *(Барып.)* Шулдыр, ахры. Бисмиллаһи-рахманир-рәхим. *(Янына төкеренеп.)* Тфү! Тфү! *(Акыртын гына бармагын тиерергә тели дә курка.)* Йа Рабби, Хуҗа Баһаветдин. *(Тагы кулын ала.)* Күңел курка! Менә шуңарга акбур берлә язып кына күрсәтә дә, ди, хәзер укырга тотыналар, ди. Бисмилла әйтсәң, белмисең ди! Шайтаны бисмилладан кача күрәсең. Менә шуңарга язсаң, әллә нинди исәпләрне чыгарып буладыр, ди. Сихерле тактадыр шул.

Шул арада Салих килеп керә.

Салих. Әби, тизрәк хәзерлә! Кыңгырау тавышы ишетелә, килергә чыктылар. Ашың-суың хәзерме?

Карчык. Бар да хәзер. Самавыр да кайнаган! Әле соң никях котларга килмәделәрме?

Салих. Кем килә?

Карчык. Синең, шул, монда атаң-анаң юк, сине өйрәтүче юк. Менә, никях укылды дип сөенче алырга килерләр.

Салих. Сөенчегә нәрсә бирергә кирәк соң?

Карчык. Ансы синең эш.

Салих. Нәрсә бирәләр соң?

Карчык. Акча бирәләр. Әйбер бүләге дә бирәләр. Кем ни тели, шулай бирә.

Салих. Күпме бирәләр?

Карчык. Хәлле хәленчә.

Салих. Миңа күпме кирәк?

Карчык. Мин белмим, бит күпме бирсәң, шулай ярый, сорап алмыйлар.

Салих. Сорап алмаганнарын беләм. Гадәттә ничек?

Карчык. Бер дә белмим, бездә моңынча кара такта берлә укытучы кеше өйләнгәне юк иде.

Салих. Кара тактаның анда катышы бармыни? Байлар күпме бирә дә, фәкыйрьләр күпме бирә?

Карчык. Төрлечә.

Салих. Менә мин илле тин бирсәм, ярыймы?

Карчык. Ярый.

Салих. Әллә аз буламы?

Карчык. Аз була дисәң, күбрәк бирерсең.

С а л и х. Мин, гадәт ничек, дим?

К а р ч ы к. Әйтәм ләсә, хәлле хәленчә.

С а л и х *(читкә карап)*. Монардан бер гакыллы сүз алыр хәл юк. *(Карчыкка карап.)* Тагы нинди гадәтләр бар, син шуларны өйрәт.

К а р ч ы к. Менә читекне бик тыгыз иттереп аяк уравычыны сулап кияргә кирәк. Билбауның очын яшерергә кирәк.

С а л и х. Алар нәрсәгә?

К а р ч ы к. Менә бикәчең кияүне тишендерергә кирәк, билбау очын тиз тапмаса, уңмаган була. Минем карт, мәрхүм, Алла каберен киң кылсын, кызыл билбау ураган иде. Менә эзлим дә эзлим, очын таба алмыйм, кулым калтырый башлады. Менә, нишлим инде, табаммы дип торганда гына, урысчалап сүкте дә яңагыма сугып җибәрде. Күземә утлар күренде. Шуннан аның өненнән куркып калдым. Менә ул әүвәл көнне үк хатынны куркытып куяр өчен ясалган. Әнә безнең киленнәр ирләреннән курыкмый. Мин картымнан калтырап кына тора идем.

С а л и х. Кергәч үк сугышырга тотыныргамыни? Юк, миннән булмас. Читеге дә шуның өченме?

К а р ч ы к. Бездә гадәт шулай. Хатыннарны әүвәл көндә куркытып калсаң каласың, булмаса, башка басалар. Менә безнең киленнәр ирләрен бернигә дә санамыйлар. Аннары ул синең бүрекне башына кияргә теләр, син аны кидермә, ул баш булырга теләве була!

С а л и х. Мин андый ялганнарга ышанмыйм. Әйдә кисен.

К а р ч ы к. Анысы үз эшең, аннары кызның ишеге төбендә бер хатын ишек тотып торыр, аңарга бүләк бирергә кирәк.

С а л и х. Күпме?

К а р ч ы к. Хәлле хәленчә.

С а л и х. Ярый.

К а р ч ы к. Аннары иртә торгызып мунчага җибәрерләр. Мунчага киткәндә урын караучы хатынга түшәккә акчамы, бүләкме салып китәргә кирәк.

С а л и х. Монысы да хәлле хәленчәме?

К а р ч ы к. Әйе. Тагы мунчага кергәч, мунча караучыга салырга кирәк.

С а л и х. Шуның берлә бетәме?

К а р ч ы к. Түшәккә, мунчага өч көнгә кадәр салырга кирәк. Аннары каенененләреңә пәкеләр, каенсеңелләреңә кершәннәр, иннекләр, сабыннар алып барырга кирәк.

С а л и х. Алар барысы да бар. Карап булса ярый.

Кыңгырау тавышы ишетелә, шул арада тавышлар ишетелә.

К а р ч ы к. Кияү алырга килделәр. *(Салих чыга.)* Һәммәсе хәзер, самавырымны гына китерим.

Ул да чыгарга тели. Шул арада и к е е г е т, бер унҗиделәрдәге малай килеп керә, артларыннан С а л и х керә.

С а л и х. Әйдәңез! Әйдә! *(Карчык янында тора.)*
Е г е т л ә р. Әссәламе галәйкем.
С а л и х. Вәгаләйкем әссәлам.

Егетләр хәзерләгән урынга утыралар, дога кылалар.

Е г е т н е ң б е р с е. Туйлар мөбарәк булсын!
С а л и х. Шулай булсын. Сәламәт килдеңезме?
Е г е т. Аллага шөкер. Сиңа көтәргә бик ямансу булмадымы? *(Үзе көлә.)*
И к е н ч е е г е т. Кавышырга озак калмады.

Шул арада к а р ч ы к самавыр алып керә. Салих чәй ясый, эчә башлыйлар.

С а л и х. Ашап эчеңез, мин, мондагы гадәтне белмәгәнгә, аш-су да хәзерләтә белмәгәнмен әле. Вахит кына шунда азрак рәтләде.
Е г е т. Ярый, бик яхшы. Монысы уза. Кияү юллыгын гына күбрәк ал!
С а л и х. Вахит әллә нәрсәләр алып йөреде, белмим, нәрсәдер.
Е г е т. Ул булса булдырыр. Ул әле анда туйда ата булып утырамыни?
С а л и х. Әйе.
Е г е т л ә р н е ң б е р с е. Бигрәк яшьли ата булды. *(Көлешәләр, Салихка.)* Синең ривалвир-фәләнең бармы?
С а л и х. Нәрсәгә ул? Юк.
Е г е т. Бездә мушкатан гына бар да, ривалвир да булса, икедән атар идек. Безнең монда кыз йортына кергәндә — аталар. Пурх тавышыннан шайтан качадыр, ди.
С а л и х. Бездә дә аталар, ләкин мин шайтанын ишетмәгән идем.

Шул арада бик чабып б е р м а л а й килеп керә.

М а л а й. Хәлфә абый, никях укыдылар!

Аның артыннан ук тагы б и ш - а л т ы м а л а й килеп керә. Кергәне бер «никях укыдылар» ди.

С а л и х *(яннарына барып, кесәсеннән портмонетын чыгарып.)* Кайсыгыз элгәре килде?

М а л а й л а р *(барысы да)*. Мин! Мин! Мин! *(Бар да акчага таба кулын сузалар.)*

Е г е т л ә р н е ң  б е р с е. Әнә кызыл бишмәтле малай элгәре килде.

Б е р  м а л а й. Ул түгел, мин.

И к е н ч е  м а л а й. Мин барсыннан да элек килдем дә, мине Габдулла сугып екты.

Т а г ы  б е р  м а л а й. Мин элек әйттем.

С а л и х. Монда сезнең очыңызны табар хәл юк.

М а л а й. Мин.

И к е н ч е  м а л а й. Мин.

Ө ч е н ч е  м а л а й. Мин, мин, мин. *(Тавыш.)*

С а л и х. Менә мәңез, барыңызга да тигез бүлеңез, сез бишәүме? Утызар тин тия.

Малайлар чыгып китәләр. Салих килеп утырып тагы чәй ясый.

Е г е т. Менә хәзер эш бетте инде, кыз синеке булды. Хәзер куркырга ярамый.

С а л и х. Ашаңыз әле.

Шул арада тагы өч  м а л а й килеп керә.

М а л а й л а р. Хәлфә абый, никях укыдылар. *(Егетләр кычкырып көлә.)*

Е г е т. Соңга калдыңыз инде, сөенчене алдылар.

С а л и х *(торып)*. Туктаңыз! *(Кесәсеннән акча алып.)* Мәңез! *(Һәммәсенә дә акчалар бирә, малайлар чыгалар.)*

Е г е т. Син кияү юллыгы дигән акчаны малайларга биреп бетермә!

Чәй эчәләр, шул арада тагы б е р  е г е т килеп керә. Кулында бер төен.

Е г е т. Әссәламе галәйкем!

С а л и х. Вәгаләйкем әссәлам!

Е г е т. Никях котлы булсын! Менә сезгә туй ашы җибәрделәр.

Е г е т л ә р н е ң  б е р с е. Бу инде менә бабаңның хезмәтчесе.

С а л и х *(төенне алып)*. Уз, утыр.

Х е з м ә т ч е. Рәхмәт, минем вакытым юк, хәзер муллалар итәргә кирәк.

Салих кесәсеннән акча алып бирә.

---

*Итү* — илтү.

Е г е т. Хуш. *(Чыгып китә.)*

С а л и х *(төенне тишеп, бәлеш-сумсалар, как-төшне алып кунаклар алдына куя).* Менә туй ашыннан авыз итеңез.

Е г е т л ә р. Ярый. Бу синең өлеш.

С а л и х. Монда сезгә дә җитәр, миңа да җитәр. *(Барысы да ашыйлар.)*

Е г е т л ә р н е ң б е р с е. Сездә туй шулай буламы?

С а л и х. Шулай. Бездә мондагыдан шәп була әле. Бездә кияү алырга эскрипкә берлә киләләр.

Е г е т. Бездә дә шулай да, без, син яратмассың, дидек. Алай да эскрипкә бар, юлда азрак тарткаладык. Без әле аны чанада калдырып кердек. Яраса, бар әле, Нәҗми, алып кер әле.

С а л и х. Ярый, ник ярамасын.

Икенче егет торып чыгып китә, шул арада яшь егет чынаягын каплый.

С а л и х. Эч әле, Габдулла.

Г а б д у л л а. Җитте, рәхмәт.

Е г е т. Эч, сыйлаганда — сыйлан! Аннары үзеңә сыйларга чират кала. *(Егет скрипкәне алып керә. Салих тагы чәй ясый. Егет скрипкәне икенчесенә бирә. Теге скрипкәне сызарга тотына, әлгәре сызып карый, аннары уйнап җибәрә. Бераз уйнаганнан соң.)* Җә әле, Нәҗми, мәгънәсен әйтеп җибәр әле.

Н ә җ м и йырларга тотына, скрипкәче кушыла, үзе уйный.

Сусадым лай, җаный, сулар кайдай,
Дәрья суларындин юк файдай,
Алымсың, балымсың, әлләй бер затларың жәллимсең?
Инде безгәй, җаныем, күрешү кайдай,
Төшләремдә күрсәм, шул файдай.
Алымсың, балымсың, әлләй, бәгырем, мине жәллимсең?

Шул арада В а х и т килеп керә. Вахит яшь кенә бер егет. Толыптан, тирләгән.

В а х и т *(керү берлән).* Менә шулай! Менә шулай. *(Салихка.)* Мин сиңа ата була-була йөдәп беттем. *(Егетләргә.)* Сезнең муллалар бик усал икән, кырык төшкә кул куйдырдылар. Әле мин кияү озатасы бар дип рөхсәт сорап чыктым. Ник туктадың, әйдә инде. *(Үзе битеннән тирен сөртә.)*

Егет тагы уйнап җибәрә. Уенны бар да тыңлап торалар.

В а х и т. Син кыскарак көйләрне уйна әле.

Е г е т. Тамак кибеп китте әле.

С а л и х. Ясаган чәең бар, шуны эч, аннары уйнарсың.

В а х и т. Эскрипкәнең тамагын чәй берлә йомшатмыйлар. Әчкелтем-төчкелтем нәрсәң юкмы?

Е г е т. Әбүҗәһел куасы.

С а л и х. Монда, мәктәптә ярыймы соң!

В а х и т. Синең бар белгәнең — мәктәп! Бездә монда туйда бар да ярый. Туйда шәригать тә юк, закун да юк.

С а л и х. Мәктәп булмаса, тагы бер хәл иде. Мәктәпне, үзең беләсең, мәгариф урыны, аны кабакка әйләндерергә ярамый.

В а х и т. Ярар, синеңчә булыр. Бар, ашыңны карат. Сезгә китәргә вакыт җитә. *(Салих чыга.)* Мондый ишаннарның сүзенә карап йөрсәң, дөньяда да тора алмассың. *(Үзе барып кәрзинәдән бер бутылка ала да ача, егетләр карап торалар.)* Чынаякларыңызны биреңез әле. *(Барысына да сала.)* Яңез, кияү берлә кыз исәнлегенә эчик!

Б а р ы с ы  д а. Исән булсыннар! *(Эчәләр.)*

Е г е т. Менә, болай булгач, бөтенләй туйга ошады. Берне әйттереп җибәрик әле. *(Уйный башлый.)*

В а х и т. Теге кергәнче тагы берәрне кагып алыйк.

Тагы сала. Тагы эчәләр, шул арада С а л и х керә.

С а л и х *(стаканны күреп, Вахиткә)*. Мәктәп бит, яхшы түгел.

В а х и т. Син үзеңнең ишанлыгыңны читкә куеп тор әле. Туйда мәктәп тә юк, мулла да юк! Йә әле, уйнап җибәр әле. Мин дә кушылыйм әле. *(Скрипкәгә йырлыйлар.)*

Кашың кара, күзең күк, ди,
Сиңа сөйләр сүзем күп.
Ай җаный, җылама! Җылап эшләр булама?
Синең җылаганың күреп, минем күңелем тулала.

Сөйләр идем сүземне, ди,
Күрә алмыймын үзеңне.
Ай җаный, җылама! Җылап эшләр булама?
Синең җылаганың күреп, минем күңелем тулала!

Тагы шул көйгә җырлыйлар.

С а л и х. Эчеңез!

В а х и т. Эчтеләр, син ашыңны карат!

С а л и х. Аш хәзер.

В а х и т. Хәзер булса, карчыгыңа әйт, ашны бирсен.

Салих чыга.

Вахит. Без менә монда азрак аш алды ясап алыйк әле. *(Бутылканы алып.)* Безнең шәкерт халкы моңарга «мәкъбүл» ди. Яңез, җегетләр, чынаякларыңызны биреңез әле, «мәкъбүлләп» алыйк әле.

Чынаякларын бирәләр, барысы да эчә. Карчык кереп самавырларны җыеп ала. Егет тагы скрипкә уйный, тагы йырлыйлар. Шул арада карчык аш алып керә. Ашка утыралар. Салих керә.

Вахит *(Салихка)*. Монда хәзер без синнән башка да ашармыз. Син бар, киен.

Салих чыгып китә.

Вахит. Яңез әле, егетләр, ашап җибәрик әле. *(Аш ашыйлар, шурпаны бетергәч, Вахит тагы бутылканы алып.)* Менә монысын безнең шәкерт халкы «ма бәгыд» ди. Яңез әле, «ма бәгыд»ләп җибәрик әле.

Сала да эчәләр. Шул арада карчык бәлеш кертә.

Вахит. Алай булгач, бу ма бәгыд булмады. Мин аш бетте дип торам. *(Исеребрәк.)* Бу шурпага караганда ма бәгыд булса да, бәлешкә караганда мәкъбүл була! Алай булгач, моның ике хәйсыяте була инде.

Егет *(аңламаенча)*. Әйдә эч, хасыяте булсын!

Икенче егет. Бу көн хасыятьле көн! *(Ашыйлар.)*

Егет *(ашап туктап)*. Менә, син әйткәнчә «ма бәгыд»лим әле.

Скрипкәне алып уйнарга тотына. Шул арада Салих килеп керә. Ул уен беткәнне көтеп тора да Вахитне читкә алып.

Салих. Ничек киеним?

Вахит *(исерек тавыш берлә)*. Кыздан килгән күлмәк-ыштан, аяк ураугычларны барысын да киен, бүтәне ничек тә ярый.

Салих. Син, Вахит, шактый исергән. Саклан, оятлы булырсың.

Вахит. Бүген синең туймы? Бүген сине мужик кызына сатамызмы? Бүген оят юк! Бар, киен.

Салих чыга.

Вахит. Яңез әле, егетләр, ашаңыз әле. Әби! Әби! Кая, монда аш кара.

Карчык аш алып керә, бәлешне алып чыгып китә. Тагы ашыйлар.

---

*Мәкъбүл* — яраклы табылу.
*Ма бәгыд* — дәвамы, соңгысы.
*Хәйсыять* — тоткан урын.
*Хасыять* — үзенчәлек.

Е г е т. Ник кияү ашамый?

И к е н ч е  е г е т. Аның күңеле ашаудамыни әле?

В а х и т. Менә илтеп ябармыз да ашар әле. Ул безне сыйларга тиеш.

К а р ч ы к аш арты кертә, ашыйлар. Ашап бетерәләр.

В а х и т. Менә хәзер чын «ма бәгыд» ясыймыз. *(Барысына да салып бирә. Эчәләр.)* Йә әле, тагы бер бию көен уйнап җибәр әле.

Егет бию көен уйный. Бер егет бии, аның артыннан Вахит бии. Исерегерәкләр. Шул арада С а л и х киенеп килеп керә.

В а х и т. Кияү хәзер. *(Уен туктый, егетләр китәләр.)*

Б е р  е г е т *(киенеп)*. Мин атларны борам. *(Чыга.)*

В а х и т *(кәрзин янына барып, аны бикләп ала. Егеткә.)* Менә бу — кияү юллыгы. Алып чыгыгыз.

Габдулла алып чыга. Салих утырып тора.

Е г е т. Әллә берне уйныйммы?

Шул арада ат борганнан соң кыңгырау тавышы ишетелә.

В а х и т. Әйдә берне уйнап җибәр.

Егет уйный. Туктый. Егет скрипкәне алып чыга.

В а х и т *(Салихка)*. Менә бүген синең туй, ә, беләмсең? Салих, туй, ә? Дөньясын ваттырамыз! Мин кияү егете. Тукта әле, кияү егете, атларны чыгып карыйм. *(Чыгып китә.)*

С а л и х. Бүген яңа тормышка керәм. Бүген элгәрege шәкертлек галәменнән мәңгегә өзеләм. Бүген тормышымны җиңеләйтер өчен үземә гомерлек иптәш алам. Аның берлән кайгыларымны бүлешер өчен, шатлыкларымны бүлешер өчен бүген гомерлек бер дустлык ясыйм. Бүген халыкка хезмәт итәргә тагы бер яңа кеше арттырам. Бу авылның кызларына, тирә-якның хатыннарына гыйлем нуры сачәргә бүген эш башлыйм, бу көнге көн минем тормышымда тарихи көн, бу көнге көн бу тирәнең гыйлем-мәгариф тарихында атаклы көн булачак! *(Шул арада Вахит керә.)*

В а х и т. Хәзер, әйдә.

Е г е т л ә р *(керәләр)*. Атлар хәзер.

В а х и т. Хуш, Салихның егетлеге, хуш, Салихның ирке! Хуш, Салихның идеалы!

С а л и х. Түгел! Минем идеалым якынлашачак, минем иркем тазарачак, минем хезмәтем зураячак!

В а х и т *(исерегрәк)*. Әйе, синең хатының шул өйне

балалар берлә тутырса, иркең тазарачак. Әйдә, Салих, атлар хәзер. Син хәзер яңы дөньяга керәсең. Син безнең эти кебек бербуйдан ачкыч тугрысыннан уйларга мәҗбүр буласың.

Егетнең берсе тагы скрипкәне уйный, шул тавыш берлә чыгып китәләр. Кыңгырау тавышы ишетелә, мылтык тавышы ишетелә. Карчык килеп керә.

Карчык *(тәрәзәдән карап)*. Киттеләр. Кыз катына китте. Кешенең гомерендә бер генә була торган эш. Бәхетле кеше булса, бу көн яхшы көн була. Бәхетсез кеше булса, бу көн начар көн була! Кара такта берлә укыта торган хәлфә мужик кызы катына китте. Күңелгә бик үк ятып бетми дә, хәерле булсын.

Пәрдә төшә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Салихның фатиры. Зур гына өй. Салача җыештырылган. Диварларга сөлгеләр эленгән. Сандыклар, самавырлар, өстәл өстендә көррәи мөҗәссәмә, китаплар, дәфтәрләр. Салих берлә Мәрзия сценага каршы утыралар. Каршы якта чыбылдык корылган ятак бүлмәсе.

Салих. Йә, менә яхшылап утыр. Хәзер укый башлыймыз.

Мәрзия. Йә, укыйк.

Салих. Менә бөтен йир йөзенең ни төсле икәнлеген, нинди йирдә таулар барлыгын, нинди йирдә диңгез барлыгын, елгалар барлыгын, кай йирдә нинди халык торуын, аларның ничек яшәүләрен сөйли торган гыйлемгә җәгърафия диләр.

Мәрзия. Миңа нәрсәгә кирәк ул таулар? Мин аның берлән нишлим?

Салих. Син ашыкма. Менә шул җәгърафияне белгәч, бөтен дөньяны үз авылыңны белгән кебек белеп торасың.

Мәрзия. Мин үз авылымызны да бөтенләй белмим, мине казлар йолкырга йөретмәделәр. Әле беркөн керләр чайкарга барганда түбән очка исем китте. Анда карга балалары бөтен болынга җыелганнар.

Салих. Ярар. Тик җыелсыннар. Менә шулай авылыңны белеп тору кирәк булган шикелле, дөньяны белеп тору да кирәк.

---

*Көррәи мөҗәссәмә* — глобус.

М ә р з и я. Нәрсәгә кирәк? Әллә мине син авыл буенча иген җыештырып йөретмәкче буламсың.

С а л и х. Син әллә нәрсәләр сөйләмә әле. Мөгаллимә булган кеше иген җыеп йөридер димени?

М ә р з и я. Суфи хатыны йон җыеп йөрмимени?

С а л и х. Син суфи хатыны түгел, мөгаллим хатыны мөгаллимә буласың! Йә, менә шул мөгаллимә булыр өчен шул җәгъърафияләрне белергә кирәк. Йә, хәзер әйт инде, җәгъърафия дип нинди гыйлемгә әйтәләр?

М ә р з и я *(тора башлап)*. Тукта әле, мин казан астымны карап керим әле.

С а л и х *(тотып)*. Утыр, утыр. Аннары карарсың. Йә, әйт, җәгъърафия дип нинди гыйлемгә әйтәләр?

М ә р з и я. Җәгъърафия дип. *(Бик озын иттереп исни.)* Син әле элгәре сабак бир, аннары сорарсың. Сиңа барысы да берьюлы кирәк.

С а л и х. Менә шунда бергә укырга кирәк. Ул вакытта сиңа җиңел була.

М ә р з и я. Әле әйтмим әле, җәмә! Кичкә әйтермен.

С а л и х. Ул ни дигән сүз! Кичкә әйтермен! Йә, әйт!

М ә р з и я. Миңа нәрсәгә соң ул! Син менә мине мәгънәле китапка керт! *(Тора башлый.)* Менә алып килим әле, минем «Мораделгарифин»ем бар.

С а л и х *(тагы утыртып)*. Бер сабакны укыганда күңелне кырыкка борырга ярамый. Элгәре менә моны укыйк, аннары карармыз. Йә, җәгъърафия дип йирнең өстендәге елгалар, таулар, диңгезләр, аның өстендә тора торган халыклардан бәхәс кылган гыйлемгә әйтәләр.

М ә р з и я. Кит, кирәкми! Безнең монда диңгез бармыни?

С а л и х. Син нишлисең? Гакылдан яздыңмы әллә? Элгәре тыңлап тор, аннары җавап бирерсең.

М ә р з и я *(тагы иснәп)*. Минем казан астым янып беткәндер, чыгып карыйм әле.

С а л и х. Бетсен, бетсен! Кирәге юк.

М ә р з и я. Яисә менә алга чыгып янып тора торгандыр.

С а л и х. Янсын! Ярар, алай булса, җәгъърафиянең нинди гыйлем икәнен укый-укый белерсең әле. Менә хәзер йирнең ни төсле икәнлеген карыйк. *(Көррәи мөҗәссәмәне алып.)* Менә йир шуның төсле түгәрәк.

М ә р з и я. Түгәрәк?! Кит аннан, юкны сөйләмә! Йир түгәрәк буладыр димени?

С а л и х. Син элек тыңлап тор!

М ә р з и я. Син юкны сөйләмә! Йир түгәрәк буладыр димени?

С а л и х. Менә йир шуның кебек түгәрәк. Бу — йирнең сурәте. Менә бу төшләре — диңгез.

М ә р з и я. Ул түгәрәк булгач, ник безнең монда түгәрәк түгел. Әнә безнең авыл бөтенләй таба кебек типтигез.

С а л и х. Йир бик зур, шуның өчен аның түгәрәклеге кечкенә йирдә беленми! Безгә тигез төсле күренә.

М ә р з и я. Моңарга кем әйтеп, кем ышансын инде.

С а л и х. Менә укый төшкәч, үзең дә ышанырсың әле. Менә болары диңгез. Менә монда су уртасында калган утраулар. *(Көррәне әйләндереп.)* Менә йир шулай итеп кояш тирәсендә әйләнә!

М ә р з и я *(кычкырып көлә)*. Йир әйләнә?! Алай булгач, өйләр ник җимерелми? Кит, юкны сөйләмә! Алай булгач, диңгезнең суы ник түгелми? Ул кыяматтә генә булачак. Казаным эштән чыгып беткәндер! Тукта әле, барып карыйм әле!

С а л и х *(җибәрми. Кулы берлән кочаклап утыра.)* Һава басканга күрә җимерелми. Һава беркая җибәрмәенчә басып тота!

М ә р з и я. Кит аннан! Һава басып торырга ул гермени? Кит, укымыйм мин моны, синең юк нәрсәләреңне! Башны әйләндереп! *(Тора башлый, Салих җибәрми.)* Валлаһи, мин этиләргә барып килим әле. Үзеңә бал алып кайтырмын, җәмә?

С а л и х *(ачуланып)*. Юкны сөйләмә, утыр.

М ә р з и я. Алла, мине этиләргә дә җибәрми. Барыйм инде? Җә җибәр инде, җаным! Аннары укырмын.

С а л и х. Лыгырдама! Утыр. *(Утырта.)* Йә, хәзергә җәгърафиясе ярар. Кичкә укырмыз.

М ә р з и я. Алла, җәй көне ике сабак укыйлармыни?

С а л и х. Кирәк булса, өчне дә укыйлар. Беләмсең, сиңа көзгә мөгаллимә булырга кирәк. Йә әле, дәфтәрең кая, имля языйк әле.

М ә р з и я *(тора, бераз киткәч)*. Тукта әле. Мин казанымны карап керим әле. *(Чыгып китә.)*

С а л и х. Аннары карарсың. *(Ялгыз.)* Моны нишләргә кирәк? Һич ихласы юк. Бер айдан бирле эштән чыгып беттем. Аз гына да алга бармый. Анда миңа ышанып кызлар мәктәбе сала башладылар. Һич дәртләндерер хәл юк! Аның бөтен күңеле шул этиләренә баруда гына! *(Торып йөрергә тотына.)* Мин болай булыр дип уйламаган идем, эш бөтенләй хилафе фараз чыкты. Шулай ук моны укытып кеше төсле итә алмаммыни? Әллә укыта бел-

---

*Хилафе фараз* — уйлаганның киресе.

мимме? Алай дисәң, үземнең сеңелемне дә шул юл берлә укыткан идем, ул нинди булган иде. Менә хәзер чыгып китте. Укымас өчен әллә нинди хәйләләр табып керер әле. *(Уйлап торып.)* Тукта әле, мин аны икенче юл берлә укытып карыйм әле. Әлгәре укырга өйрәтер өчен хикәяләр, кыйссалар укырга кирәк. *(Өстәлгә барып китаплар актарырга тотына.)* «Кәләпүшче кыз»... Моны ул аңламас. «Мәгыйшәт»... Буны, бәлки, аңлар, бәлки, укырга дәртләнер. Ярый, моны читкә куйыйк әле. «Шәкерт һәм студент»... Ул шәкерт берлә студентның аермасын аңлый аламы соң? «Сәлимә». Мондагы фикерне дә, белмим, аңлар микән? Алай да моны да алып куйыйк әле. «Өч хатын берлә тормыш» — хатын-кыз мәсьәләсе, моны аңларга кирәк. Моны да аңламаса, бөтенләй өметне өзәргә инде. *(Алып куя.)* Ярар, шуларның берсен укый башларга кирәк. Әдәбият укырга дәртләнмәенчә булмас! Аннан башкаларны укыта башлармын. *(Кычкыра башлый.)* Мәрзия! Мәрзия!

Мәрзия *(ишек артыннан)*. Нәрсә? Синең берлә торатора казаным сүнеп беткән!

Салих. Казаныңны кабыз да кер әле! Бик кызык нәрсә бар!

Мәрзия *(ишек артыннан)*. Ярар.

Салих. Җанлы кеше укырга дәртләнми хәле юк. Менә шуларны әлгәре үзем укый башлыйм, аннары аңардан укытырмын. Әлгәре «Өч хатын»ны укытыйм әле.

Мәрзия *(килеп кереп)*. Нәрсә? Синең берлә юк артыннан утыра-утыра казаным сүнеп беткән. *(Күлмәгенә күрсәтеп.)* Менә күлмәгем нинди ямьсез, бер күлмәк тә алмыйсың. Ул Әхмәтҗан хатыны матур күлмәк кигән! Буй-буй. Ерактан караганда, әллә нәрсәсе җем-җем итеп тора. Унсигез тин, ди.

Салих. Бар да булыр, һәммәсе бер көндә булмый. Әле синең күлмәгең *(Сандыкка күрсәтеп.)* анда исәбехисабы юк.

Мәрзия. Минем бөтен күлмәкләрем искереп беткәнне көтеп торырга тели, күрәсең.

Салих. Ярар, менә алырмыз. Әле эш анда түгел. Үзең дә беләсең, яңы тереклек итә башлаган кешеләрнең бөтен кирәкләре тулып тормый. Менә син мөгаллимә булгач, вазыйфәмез күбәер, тормышымыз да иркенләнер.

Мәрзия. Әллә миңа төтен тавы тоттыра? Син бит әле миңа бер күлмәк тә алганың юк! Бөтен әйберем аталарымнан килгән.

---

*Вазыйфә* — хезмәт хакы.

С а л и х. Әле нәрсәгә соң аны кузгаттың? Кирәк булса, сиңа мин алмый, кем алыр дисең? Менә утыр әле, менә монда бик кызык китап бар, мин укыйм, син тыңлап тор!

М ә р з и я. Минем казанымда кортым эштән чыгып бетәр.

С а л и х. Бетмәс, бетмәс, утыр әле. *(Мәрзия утыра. Салих кулына «Өч хатын»ны алып).* Менә күрәмсең, «Өч хатын берлә тормыш», бик кызык китап. Менә бу китапта өч хатын берлә торган кешене сөйли.

М ә р з и я. Алла, ул бит дөрест түгел! Әкият кенә!

С а л и х. Ник дөрест булмасын. Дөрест! Менә укыйм әле. Менә бу театр китабы, театрда уйналыр өчен язылган.

М ә р з и я. Миңа нәрсәгә соң ул? Менә синең «Сәедбаттал»ың булса, укыр идек.

С а л и х. Бу «Сәедбаттал»дан да кызык. Менә тыңлап тор, үзеңнең дә исең китәр. *(Салих укый.)* Зур гына бер зал... *(Бераз укыганның соңында.)*

М ә р з и я *(торып).* Бер дә кызыгы юк ласа. Мин, кызык дигәч, әллә нинди баһадирлар сугышы дип торам. Әллә аның шикелле сүзләрне мин ишеткәнем юкмы? *(Торып чыга башлый.)*

С а л и х. Тукта, менә монда кызыгы! *(Тагы бераз укый.)*

М ә р з и я. Кит, бер кызыгы да юк. Минем анда эшем бар, синең юк нәрсәләреңне тыңлап торырга...

С а л и х. Тукта, тукта! Менә син азрак сабыр ит, аннары кызыклары чыга.

М ә р з и я. Бетмәс синең әкиятләрең. *(Чыгып китә.)*

С а л и х *(аптырап калып).* Бар, моның берлә сөйлә! Нишләргә кирәк моны? Аз гына да тәэсир итәр хәл юк. Шулай ук бер юл берлә дә моны кеше ясап булмасмыни? Һич ышанмый. Кеше булган кеше укырга теләмәсен, имеш! Юк, була торган эш түгел. Мин никадәр бала күрдем, укуны моның кадәре сөймәгәнне һич белмим! Юк, моның берлә чынлап сөйләп карарга кирәк, болай ярамый. Ул һаман элгәреге кебек без кияүле-бикәчле дип кенә уйлый. Киләчәктә тормыш берлә тартышырга кирәклеген, шул тартышуга гыйлем берлә коралланырга кирәклеген аңламый.

М ә р з и я *(килеп керә).* Мин самавыр куйдым, хәзер чәй эчәрмез.

С а л и х . Ярый. *(Салих Мәрзиянең янына барып, аның беленнән тотып.)* Менә нәрсә, Мәрзия! *(Алар идән буенда йөрергә тотыналар.)* Син минем кем икәнлекне беләсең бит?

Мәрзия. Ник белмим?

Салих. Минем бай түгеллегемне, минем нинди булса да бер эш берлә генә тамак туйдыра алуымны да беләсең?

Мәрзия. Тамак туйдыру минем эшеммени?

Салих. Тукта әле. Син чынлап тыңла әле! Мин чынлап сөйлим! Менә мин хәзер мөгаллим, балалар укытам! Шул эшне сөеп укытам! Шуңардан файда була дип, халык агара дип тырышам! Мин вазыйфәсенә кызыгып укытмыйм! Минем хезмәтемә ул егерме сум — берни түгел! Менә мин сине дә үзем кебек мөгаллимә итәсем килә, сине дә шул халыкка хезмәт юлына кертәсем килә!

Мәрзия. Ник!.. Аларны укытып, сиңа зур файда булыр инде.

Салих. Менә мин шул үземә файда булмаса да, халыкка файда булуына разый булып, шуңарга хезмәт сарыф кылам. Сине дә шулай үзем кебек иттерер өчен хәзер сине укытырга тырышам. Беләмсең? Сиңа дип байлар нинди зур кызлар мәктәбе салалар. Син шунда мөгаллимә булыр өчен укытырлык кадәр белергә кирәк. Син минем сүзне тыңламыйсың, син укымыйсың! Ник укымыйсың?

Мәрзия. Әллә мин аларны гына укытыр кадәр белмиммени? Миңа синең әллә нәрсәләрең, җәгъърафияләрең нигә кирәк? Менә мәгънәле китап укыт, укырмын.

Салих. Син анда ысуле җәдидә берлә укытырга кирәк. Шәкертләргә караганда күп белергә кирәк. Шуның өчен сиңа җәгъърафиясе дә кирәк, бүтәне дә кирәк. Мин сиңа кирәкмәгән нәрсәне укытмыйм.

Мәрзия. Йә, ярар, кирәкмәс, әллә ниләр бик озын иттереп сөйләмә! Мин алай сөйләгәнне яратмыйм. Мин ул кызларны гына укыта беләм. Мин бит укымыйм димим, син мине әниләргә дә җибәрмисең. Самавыр да каратмый, гел укытып тотмакчы буласың. Тукта әле, самавырым кайнагандыр. *(Чыгып китә.)*

Салих *(ялгыз)*. Моны ничек тә эшкә китерер хәл юк. Бу ни бу? Моның берлә нишлим?

Мәрзия самавыр күтәреп килеп керә.

Мәрзия. Менә әниләргә җибәрмәдең. Хәзер бал берлә чәй эчкән булыр идек.

Салих. Гел әниләр дә әниләр! Син чит авылга киткән

---

*Ысуле җәдидә* — яңа ысул.

булсаң, ничек гомер иткән булыр идең икән? Үзеңә дә ана булырга күп калмаган, азрак әниләреңне оныта башларга вакыт.

Мәрзия. Мин аларга да бармыйча, гел өйдә дөмегеп торыйммыни? Әниләргә баруны беркем дә гаеп итмәс.

Салих. Мин дә гаеп итмим, синең эшең бар, сиңа мөгаллимәлеккә хәзерләнергә кирәк, эшең бетмәенчә кунакка баруны кайгыртмаска кирәк.

Тыштан, «Әссәламе галәйкем! Хәлфә өйдәме?» дигән тавыш ишетелә. Салих чыгып китә.

Мәрзия. Менә йөдәтте шул сабагы берлә. Кайчанга кадәр башны әйләндерер. Бөтен китапларын утка гына ягарга.

Үзе чәй урыны хәзерли. Салих гәзитәләр тотып керә.

Салих. Менә чәйгә гәзитә дә килде.

Чәйгә утырышалар. Мәрзия чәй ясый, Салих гәзитә укый.

Мәрзия. Менә әниләргә барсам, лимун алып кайткан булыр идем, җибәрмәгән булдың. *(Салих дәшми.)*

Салих *(гәзитәне укып)*. Яңа китап чыккан, алдырырга кирәк.

Мәрзия. Юкка акчаңны әрәм ит инде, бик бай! Әй илаһи, кылануын күрсәң иде! Син алай юкка акча әрәм иткәнче, миңа күлмәк яса! *(Үзе чәй эчә, Салих дәшми, укый.)*

Мәрзия *(чәй эчә. Бераздан)*. Чәең суынып бетә, эч!

Салих. Ярар, эчәрмен. *(Үзе укый.)*

Мәрзия *(тагы ясап)*. Эч, чәең боз булды, эч!

Салих. Хәзер, хәзер.

Янә укый, Мәрзия тагы ясап эчә, Салих гәзитәне куя да торып идән буенда йөрергә тотына.

Салих *(үзеннән-үзе)*. Шулай шул. Мәктәп юклыгы иң зур сәбәп. Мәктәп булса, халык бу кадәр надан булмый. Үзенә кирәген аңлый.

Мәрзия. Әллә саташтыңмы? Тиле кеше кебек үзеңнән үзең сөйләп йөрисең. Чәй вакытында чәй эчә белми, чәе суынып бетте инде, йөрергә тотынды.

Салих. Миңа яңадан яса!

Мәрзия. Яңадан яса! Тагы чәе боз булып бетәр. *(Үзе ясый.)* Утыр, эч!

Салих *(һаман йөри, үзеннән-үзе көлеп)*. Бик шәп булыр. Әгәр ул мәктәпкә яхшы мөгаллимнәр дә китерсәләр, ул урысның гимназиясе кебек була! Без укыганда шундый мәктәп булмады.

Мэрзия. Утыр инде, тагы чәең суына!

Салих *(утыра)*. Син аңламыйсың, Мәрзия, Кырымда мәдрәсәи галия ясамакчы булалар, ул бит бөтен Русиягә бер була! Аннан нинди кешеләр чыгар, беләмсең?

Мәрзия. Салсалар, синең угылың бармы укырга?

Салих. Бар сөйлә синең берлә. *(Үзе икенче нумир гәзитәне алып укырга тотына.)*

Мәрзия. Әллә тилерденме? Тагы гәзитенә тотынды. Әллә чәй эчкәч качармы?

Салих дәшми укый.

Мәрзия *(чәй ясап, бераздан)*. Эч! Тагы чәең суына!

Салих. Хәзер, хәзер, бик кызык йире.

Тагы укый. Мәрзия эчеп бетерә.

Мәрзия. Тагы чәең боз булды. Сиңа ник соң мин самавыр куеп эштән чыгып йөрим, валлаһи, моннан соң куймам, чәй эчәргә утырсаң, рәхәтләнеп эчәр хәл юк! *(Салих дәшми.)* Дөмек шунда гәзитәңдә. *(Торып китә, читкә барып утыра.)*

Бераздан соң Салих гәзитәне укып бетереп читкә куя. Үзе чәйгә сузыла. Суык чәйне түгеп ясый да эчәргә тотына.

Салих. Мәрзия, миңа икмәк бир әле!

Мәрзия *(урыныннан тормаенча)*. Исеңә төштемени? Гәзитәң туйдырмадымыни? Валлаһи, моннан соң самавыр куймам.

Салих. Ярар, куймассың. Икмәк китер әле.

Мәрзия. Китермим, китермим. Бик ачуымны китердең.

Салих торып үзе барып икмәк ала да чәй эчәргә тотына. Шул арада бер карчык килеп керә.

Карчык. Исәнмесез? Син, Мәрзия, бүген әниеңнәргә бармадың, ахрысы? Мин гел тәрәзә төбендә утырдым. Үткәнең күренмәде. Исәнме, хәлфә?

Салих. Аллага шөкер.

Мәрзия. Чәй эчәргә утыр, Мәрфуга әби.

Карчык. Ярар, рәхмәт, хәзер генә эчкән идек әле, баланы-чаганы төш ашатып уракка җибәрдем дә, чебешләр генә ашаттым да, кереп чыгыйм, дидем.

Үзе утыра. Мәрзия дә, утырып, аңарга чәй ясый, Салих тагы гәзитә укырга тотына.

Карчык. Нишләп торасыз?

Мәрзия *(Салихка күрсәтеп)*. Күрәсең, әнә нишли!

К а р ч ы к. Менә сез нинди бәхетлеләр, өйдә ятасыз. Минем угылларым, кызларым шул кызуда урак урып йөриләр.

С а л и х. Кыш көне алар пич башында ятканда, без иртәдән кичкә кадәр балалар укытамыз.

К а р ч ы к. Әйе, шулай инде, дөнья тигез булмый. Менә бармак та, биш кенә булса да, бишесе биш төрле. *(Мәрзиягә.)* Нишләп бүген әниләреңә бармадың? Гел өйдә торырга күңелсездер.

М ә р з и я. Менә бу җибәрмәде.

С а л и х. Кияүгә киткән кыз көн буе аналарында тормый. Аңарга мөгаллимә булырга кирәк. Укырга кирәк.

К а р ч ы к *(чәй эчә)*. Шулай шул инде, бер кискән икмәк икенче кат ябышмас. Әле, хәлфә, мин сезгә бер сөенечле эш берлә килдем. Габделсаттар карт әҗәл якасында. Әле хәзер генә тагы карт мулланы алып киттеләр. Җомганы көтә, үлә, диләр. Фидиясен дә карт мулла да бик алырга тели, мөәззин дә алырга тели икән. Әле карчыгы безгә керде дә, шул сөйләп утырды. Фидиягә бик зур чиркәс сарык, ярымчыбык арыш, бер бик яхшы алты тәкә тиресеннән теккән тун, картымның читеккәвешен бирәмез, ди. Картым да, үзем дә муллага да, мөәззингә дә бирәсемез килми, сатып әрәм итеп бетерәләр, хәлфә алса, аңарга бирер идек, бик дога кылып картымның киемнәрен киеп, намаз укып туздырыр иде, ди. Шуны кереп сөйлә әле, дигәч кердем. Мин: «Алыр, ник алмасын?»,— дидем. Туны бик яхшы, читеге-кәвеше дә әле иске түгел.

С а л и х *(гәзитәсен ташлап)*. Мин монда фидия козгыны булырга килмәдем. Балалар укытырга килдем.

К а р ч ы к. Алай димә! Изге эш бар да ярый. Ярым [чыбык] арыш хәзер бит, урып кына алырга! Утыз пот бит! Бу көнге көндә аны кайдан аласың әле?

С а л и х. Саттар картның бөтен малын бирсәләр дә алмыйм. Мин аның бетле туны берлә нишлим?

К а р ч ы к. Юк, туны бик һәйбәт. Муллалар бик алырга телидер дә әле, бирмиләр.

М ә р з и я. Бу әллә ни кылынган булып тора. Әйтерсең лә, бөтен анбарлары иген берлә тулган. Үзе миңа бер күлмәк тә ясый алмый.

К а р ч ы к. Ул әле яшь кеше, өйрәнмәгән. Муллалар да элгәре килгәндә шулай кылыналар, бара-тора өйрәнер әле. Рәхмәт, Мәрзия, чәең бик тәмле икән.

М ә р з и я. Тагы берне эч.

К а р ч ы к. Рәхмәт. Балалар елый башларлар. Кече ки-

ленем дә бүген кызын калдырып китте. Мин әле сезне якын итеп кенә кердем. Әллә, хәлфә, аласыңмы?

Салих. Юк, юк!

Мәрзия. Ал, тиле! Әллә ярым чыбык арыш эчеңне тишәрме? *(Салих дәшми.)*

Карчык. Хушыңыз. *(Чыгып китә.)*

Мәрзия. Әллә кем дип белерсең, алмаган була! Үзе ачлы-туклы тора. Син, күрәсең, мине шулай гомерем буе ачлы-туклы тотмакчы буласың.

Салих. Мине син шулай фидия козгыны дип белә идеңмени? Мин мөгаллим, беләмсең шуны? Мин монда мөгаллим булып авылны агартыр өчен килгән.

Мәрзия. Бик! Алай ач торып кына агартырсың инде!

Салих. Әле ач торамсың, ниең җитмәгән?

Мәрзия. Алай иттереп кенә көннеке көнгә җитеп тору бик шәп инде. Рәхәтләнеп кунак чакырып, кунакка барып торырлык булмагач.

Салих. Чакыр, сине кем тыйганы бар?

Мәрзия. Чакыр. Кая дөгең? Кая җимешең? Кая балың, кая маең? Безнең әти базардан барысын да потлап китерә. Син тик шунда гәзитәң берлә өйдә бот күтәреп ятасың.

Салих. Мин мөгаллим! Мин синең әтиең кебек бер пот биреп, ике пот алып кәсеп итмим.

**Шул арада ишек шылтырый һәм дә ишектән Мәрзиянең әнисе килеп керә. Кулында төен.**

Гайнелхәят. Исәннәрмесез?

Салих. Аллага шөкер, үзең исәнме, әби. *(Мәрзия төенен ала.)* Утыр, әби. *(Гайнелхәят утыра.)* Самавырың сүнгәнме, Мәрзия?

Мәрзия *(төенне чишеп)*. Юк, юк! Сүнмәгән. Капкачын гына ал!

Гайнелхәят. Азрак умарта карадым да, сезгә бал алып килим дидем. *(Мәрзия төеннән бал чыгара, түгәрәк күмәчләр чыгаралар да, балны, күмәчне күтәреп, чәй янына килеп чәй ясарга утыра. Мәрзия барысына да чәй ясый, аннары күмәчне кисә.)* Балны кияү алдынарак куй.

Салих. Ярар, җитәрмен.

Гайнелхәят. Бабаң әле уракчыларга җир күрсәтергә китте дә, килеп китим, дидем. *(Мәрзиягә.)* Ник бүген үзең бармадың? Мин сине аш берлә көттем.

Салих. Без хәзер көненә ике мәртәбә сабак укый башладык, эш булды.

Мәрзия. Булды шунда, юк нәрсәләр берлә башымны әйләндереп бетерде.

С а л и х. Ул эш булмый, нәрсә? Хәзер июль, сентябрьдә сабак башларга кирәк, син бернәрсә белмисең.

Г а й н е л х ә я т. Ул абыстайда бик яхшы укыган иде. Ничек алай белми?

С а л и х. Ул абыстайда укудан зарардан башка бернәрсә юк.

Г а й н е л х ә я т. Без файда булсын дип укыткан идек. Әле соң ул кызлар мәктәбеңез бетәме?

С а л и х. Байлар ничек тә сентябрь башына бетерәмез, диләр.

Г а й н е л х ә я т. Әле бабаң урыска барган иде. Сезгә дип бер кибет алып кайткан, шуны мәктәп янына салып, азрак тауар куеп сату итә башларлар, ди.

С а л и х. Мәктәптә укыта башлагач, сату итәргә вакыт калмый. Тагы ул, алай итеп, әллә ничәгә бүленергә ярамый. Байлар да разый булмыйлар, мин үзем дә разый түгел. Ике көймәнең койрыгын берьюлы тотып булмый.

М ә р з и я. Үземезгә дә рәхәт булыр, ни кирәк, шуны чыгып кына алырмыз, ачыйк! *(Үзләре чәй эчәләр.)*

С а л и х. Ничек бер кеше укытырга да, сату итәргә дә өлгерсен, ул ни дигән сүз?

М ә р з и я. Мин буш булганда, мин сатармын, син буш булганда, син сатарсың.

С а л и х. Мин монда хатыннарның ирләреннән урлаган игеннәрен җыеп баер өчен килмәгән, юкны сөйләмә дә, булмый да.

Г а й н е л х ә я т. Ник булмасын, Мәрзия сатар.

С а л и х. Кем укытыр?

Г а й н е л х ә я т. Ул укытыр.

С а л и х. Укыткан вакытта кибеткә килсәләр, нишләр?

Г а й н е л х ә я т. Алла, икесе дә шунда янәшә булгач сатып керер.

С а л и х. Юк, укыту эшенә алай карарга ярамый ул! Укытырга тотынсаң — укытырга, сатарга тотынсаң — сатарга.

Тыштан «Хәлфә! Хәлфә!» дигән тавыш ишетелә. Салих чыгып китә, Гайнелхәят берлә Мәрзия кала.

Г а й н е л х ә я т. Нихәл, кызым, нишләп торасыз? Яхшы торамсыз?

М ә р з и я. Менә шул укытуы берлә йөдәтеп чыгара. Үзе алай кыйнамый, сукмый!

Г а й н е л х ә я т. Бик кызык кеше бу! Кибет ачуга каршы килергә тели. Әле бүтәннәр бик ачар иде дә, тәтеми.

М ә р з и я. Әле Мәрфуга әби кергән иде, Саттар карт-

ның фидиясен ал, дип, бик яхшы тун бирәләр, ди, ярым чыбык уҗым, ди, бер чиркас сарык, ди. Шуны алмыйм, ди.

Гайнелхәят. Бу ни ашап торырга тели икән соң? Әллә ул бабасы өстеннән гомер буе ашап тормакчы буламы? Үзеңә торырга уңайсыз түгелме соң?

Мәрзия. Менә шул сабаклары өчен гел тирги шул.

Гайнелхәят. Тиргәмә диген. Ул ни дигән сүз? Ул безнең бердәнбер генә кызымызны алай тиргәргә бирмәдек, кадерле урын дип, кадер күрергә бирдек.

Мәрзия. Аннары менә шул гәзитәләр берлә эштән чыгып бетә, әле бүген шуларны укый-укый чәе суынып бетте. Аннары үзеннән-үзе әллә кемнәр берлә сөйләшергә тотына.

Гайнелхәят. Ул гәзитә нәрсәгә ди соң? Аларны утка гына ягарга. Мин әле этиеңә әйткәнем юк, этиең ул эшләрен белсә, аерыр да алыр. Без сине урын табылмаганнан бирмәгән. Сине муллаларга сорадылар. Бик кадереңне белеп кенә торсын, төярмез дә алып китәрмез! Мин кайтыйм, этиең кайтыр. *(Гайнелхәят тора. Шул арада Салих килеп керә.)* Кем ул?

Салих. Фәхри карт. Угылыннан хат килгән дә, шуны укытырга килгән.

Гайнелхәят. Син аларга элгәре чәй янына чакыр диген.

Салих. Аның үзенә дә чәй юктыр әле. Актык угылы солдатка китте.

Мәрзия. Син гел кеше кызганып торырсың инде. Белмим, үзеңне кем кызганыр?

Салих. Миңа кеше кызгануы кирәкми. Мин кызгандырып гомер итә торган кеше түгел, эшләп гомер итә торган кеше.

Гайнелхәят башын селкеп тора.

Гайнелхәят. Хуш, кияү.

Салих. Ник утырмадың, әби?

Гайнелхәят. Эшем бар, үзеңез барып утырыңыз! *(Чыга, аның артыннан Мәрзия чыга.)*

Салих *(ялгыз кала. Идән буенда йөрергә тотына. Бераз йөрегәч)*. Моның болай кылынышы бик күп уйларны җимерде. Мин элгәре өйләнгән вакытларда үзем мөгаллим булып, хатыным мөгаллимә булып, бөтен авылны яктыртамыз, агартамыз дип уйлый идем. Хәзер ул фикер шактый еракланды. Мәрзиянең ихлас бирмәве бик күп ышанычымны җимерде. Ул түгел, бөтен авылны яктыртырга, үзен дә кеше итәргә ирек бирми. Ник бу бо-

лай? Шул ук тормыш, шул күлмәк кайгысы, ашка бару кайгысы моның сөягенә үк сеңгән микәнни? Белмим, белмим! Моны кеше итә алмасам, нишләрмен? Бу көенчә булганда, ничек аның кулына мәктәп тапшырырга риза булыйм? *(Йөри.)* Шулай ук минем өйләнүем хата булды микәнни? Шулай ук минем уйларым мәйданга чыкмас микәнни? Ул вакытта мин нишләрмен? Мин бу хатынны нишләрмен? Күлмәктән башканы белми торган бу хатын берлә ничек тереклек итәрмен? Бөтен яктан наданлык берлә чолганган бу авылда үземнең идеалымны ничек саклый алырмын? Белмим, белмим! Киләчәктә мине ни көтә торгандыр, белмим! Ләкин элгәреге ышанычымның яртысы гына калды. Элгәреге тынычлыгымның аты гына калды.

Шул арада Мәрзия йөгереп керә.

Мәрзия. Байлар килделәр, мәктәпкә таба киттеләр.

Салих киенергә тотына, Мәрзия өйне җыештырырга тотына.

Салих. Самавыр куй. Чәйгә алып килермен. *(Чыгып китә.)*

Мәрзия *(Салих артыннан кычкырып)*. Кибет тугрысында сөйлә! *(Ашыгып-ашыгып җыештыра.)*

Пәрдә төшә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Салихның фатиры, зур гына бүлмә, өстәл, самавырлар. Өелгән мендәрләр. Сул якта чыбылдык корылган. Яту урыны, уң якта бер ишек, пәрдәгә каршы тышка бер ишек. Чыбылдык янында бала бишеге асылган. Кыш көне кич берлә.

Мәрзия *(ялгыз бала тирбәтә, үзе көйли.)*

Алла, Алла, Алла һу!
Алла дигән бәндә бу!
Алла дигән бәндәләр
Оҗмах эчрә керер шул!
Кызым, кызым, кыз кеше!
Кызыма килер йөз кеше.
Йөз кешенең арасыннан
Алып китәр бер кеше.
Алла, Алла, Алла һу!
Алла, Алла, Алла һу!

*(Шуннан соң бишек чыбылдыгыны ачып карап)*. Йоклады. Йокла, бәбкәм, йокла! Бик тыныч йокла, бәгырем. *(Үзе торып китә. Сәгатькә карап.)* Сәгать сигез

булган, һаман әле кайтмый. Бу нишләп тора? *(Тәрәзәгә карап.)* Тагы буран күтәрелде. Тизрәк кайтса ярар иде, ашыйсым да килә башлады. *(Утыра.)* Уф Алла! Иртәдән алып кичкә кадәр өйдә юк. Син көн буе аны көт тә утыр. Элгәре, исмасам, әниләргә барып утыра идем. Әни орышканнан бирле анда барырга да юл киселде, әйтерсең лә көне буе шул мәктәбендә торырга ни җитмәгән! Кичен тагы анда барып дөмегә. Менә тагы кайтыр да гәзитәсенә ябышыр. Сөйләр дә хәл, нитәр дә хәл юк. Мин тик казык кебек катып торам. Җансыз кеше кебек гомер үткәрәм. Минем берлә рәтләп сөйләми, миңа киңәш итешми, үзе белгәнчә йөри. Ул шул мине эченнән хатын дип санамый торгандыр, болай булмас иде. Ярый әле юанып торырга балам бар, ул да булмаса, монда эчең пошып үләр идең.

Шул арада ишектән Мәрфуга карчык килеп керә.

Мәрфуга *(сузып кына)*. Исәнме, Мәрзия?

Мәрзия. Аллага шөкер, Мәрфуга әби, уз, утыр! *(Мәрфуга узып утыра.)*

Мәрфуга. Тыш бик җил. Угылларым бүген базарга тиягәннәр иде, ничек барырлар, азрак себерә дә. Менә мондый көнне юлдагы кешеләрнең хәлен Алла күрсәтмәсен. Без картым мәрхүм исән вакытта ишан хәзрәттән кайтканда, шундый көнгә очраган идек. Аз гына туңып үлмәдек. Хәлфә кайтмадымыни әле?

Мәрзия. Юк әле, нишләптер бик озак тора.

Мәрфуга. Эше бардыр, кызларны да ул карый, диләр бит.

Мәрзия. Юк, кызларның мөгаллимәләре бар, ул нишләп карасын?

Мәрфуга. Әйттем исә кайттым. Безнең Гәрәйнең кызы шунда укый да, шул гына сөйләде. Хәлфә абый килеп барыбызны да тыңлатты да, минем дәфтәремә «акарин»ме шунда, «афарин»ме, әйтә дә белмим, язды диде.

Мәрзия. Мин аның анда кереп йөрүен белми идем.

Мәрфуга. Керә, ди, керә, ди. Байларның рөхсәте шулай, имеш, ди, бик үк, күрәсең, укымышлы түгел! Хәлфә аны өйрәтә, ди.

Мәрзия. Әйтәм дә бик озак кайтмый тора! Мөгаллимә аңардан качмый диме?

Мәрфуга. Мин бит әле анысын бик үк ачык белмим. Мөгаллимә үз янына кунарга кызларны алып кала

---

*Исмасам* — ичмасам.

бит, менә бу арада Әхмәтсафа кызын ияләштергән, бөтенләй янында тота инде. Шул гына сөйләгән. Шуның сүзен чәй суда хатыннар сөйли, ди, хәлфәдән качмыйдыр, ди, сөйлидер, ди.

Мәрзия. Менә ул нишләп тора икән! Мин монда аның өен саклап торам.

Мәрфуга. Алар бит инде, кызым, шул мөгаллиме дә, мөгаллимәсе дә кара такта берлә укыган, алар качуны яратмый инде. Әле кичә хәлфә керде дә гәзитә укыды, ди.

Мәрзия *(курыккан тавыш берлә)*. Гәзитә укыды, ди?!

Мәрфуга. Шуннан бик кычкырып көлештеләр, ди!

Мәрзия. Мин монда, мескен, тик дөмегеп ятам, ул әллә кемнәр берлә, җиде ят хатыннар берлә гәзитәләр укып йөри.

Мәрфуга. Шулай, ди, шулай, ди. Бу арада көн дә кебек керә, ди. Тегесе дә бик усал, ул килгән вакытта киенеп-ясанып торадыр, ди. Ул инде, бәбкәм, атасын-анасын ташлап, кыз башы берлә чит авылларга килгән кеше, дөнья күргәндер инде. Югыйсә менә кайсымыз чит авылга барып тора аламыз? Соң әле үткен шул! Сиңа аны китертмәскә тырышырга кирәк иде.

Мәрзия. Ул мине үзе мөгаллимә ясатмады, син бернәрсә белмисең, син нәрсә укытырсың, ди. Мин ничек белмәгән хатынымны мөгаллимә ясап, балаларның гомерен әрәм итим, ди. Хәзер этиләр дә шул мине мөгаллимә ясамаганга үч итеп карамыйлар.

Мәрфуга. Йә, ул балаларны укытырга нәрсә кирәк, суфиның бөкре хатыны укыта алганны, син укыта алмыйсыңмы соң? Син бит ишанга сабакка йөрдең, зур булганча йөредең.

Мәрзия. Ул шул миңа әллә нинди китаплар укытырга теләде, мин укымадым, шуның өчен байларга, минем хатыным укытырлык түгел, дип үзе әйткән. Әти дә шунда икән. Әти шуның өчен бик ачуланган, байлар алдында бик хурланган.

Мәрфуга. Хурланмый хәле юк. Муллага бирергә, остазбикә ясарга дип үстергән кыз мөгаллимә була алмасын, имеш!

Мәрзия. Әти, шунда мәктәп янына кибет салырмын, дип, бура да алган иде. Хәзер инде аны да бирми.

Мәрфуга. Әле, кызым, һаман этиеңнәргә бармыйсызмыни?

Мәрзия. Аның барганы юкка өч ай булды инде. Мин көн дә барган кебек бара идем әле дә...

М ә р ф у г а. Үзе, ярый әле, сине тими икән!

М ә р з и я. Ул бит үзе бик яхшы, әти орышканда бер кайтарып сүз әйтмәде, торды да чыкты да китте. Берике көнгә кадәр мин әтиләргә бармаенча тордым. Аңардан сорарга курыктым. Аннан сорадым, бер сүзсез, бар, теләсәң нишлә, мин сине көчләмим, ди.

М ә р ф у г а. Кыйнамый, сукмыймы?

М ә р з и я. Юк, ул андый түгел.

М ә р ф у г а. Тел берлә дә шелтәләмиме?

М ә р з и я. Бернәрсә юк. Менә, бик ачуы килсә, дәшми генә. Без үземез шул бик яхшы торамыз. Менә тик шул укуы берлә башымны әйләндерә. Менә әтиләр аерып алыйк дип уйлашканнар икән. Мин аерылмыйм, дидем дә, әти шуның өчен бик тиргәде. Йортыма аяк басма, дип, куып чыгарды. Шуннан бирле барганым юк.

М ә р ф у г а. Ул соң әтиеңнең шул әйткәнен беләме?

М ә р з и я. Юк! Алай да бераз сизенә торгандыр, ахрысы, бүген: «Ник әтиеңнәргә бармыйсың?— диде. *(Торып йөри башлый.)* Менә нинди соң! Бөтен авыл ятып бетте. Ул һаман мөгаллимәсе янында тора. Андук бу арада бик аз сөйли башлады. Тегесе, каһәр сукккан, кеше иреннән башканы таба алмас идемени? Мин әле аның өчен җан өзелеп торам. Аның өчен атам-анамның сүзеннән чыктым. Ул әллә нинди кызлар берлә гәзитәләр укып йөри. Моңарга ничек хурланмаска кирәк, моңарга ничек чыдап торырга кирәк?

М ә р ф у г а. Шулай шул, бәбкәм! Ул ни дигән сүз, хатының бар өстеннән әллә нинди кызлар берлә йөрсен, имеш. Ул мөгаллимәнең күзе яман. Беркөн әле ашта күреп исем китте. Тагы үзе нинди! Олугларга юл бирмәенчә, ашта китап сөйләгән булып утыра.

М ә р з и я. Каһәр сукканны мин сачен йолкып бетерермен. Мин бөтен табын хатын алдында мәсхәрә итәрмен.

Шул арада б е р  м а л а й төен күтәреп килеп керә.

М а л а й. Мәрзия абыстай, менә әниең җибәрде, күчтәнәч, диде, иртәгә әтисе Казанга китә, килеп утырсын, диде.

М ә р з и я *(алып)*. Үзләре исәннәрме?

М а л а й. Исәннәр. Эскәтерен үзе алып килер, диде.

М ә р з и я. Ярый, иртәгә барырмын дип әйтте, диген.

М а л а й. Хуш.

М ә р ф у г а. Тукта, бәбкәм, мин дә чыгам, бергә китәрмез, хуш, Мәрзия.

М ә р з и я. Хуш, Мәрфуга әби, килеп утыр. Мин гел шулай буш өйне ялгыз каравыллап торам. *(Малай берлә карчык чыга).*

М ә р з и я *(ялгыз тәрәзәгә барып карап)*. Нинди җил! *(Тыңлап торып.)* Нәрсә кычкыра?.. Җил генә икән! Ни дип кайтмый? Мөгаллимәсе янында тора... Торсын, торсын! Кадалып бетсен! Бу кадерне белмәде. Әтиләр никадәр кадер иттеләр. Шуның да хакын хаклый алмады. Алты ай бербуйдан кияү сыйладылар, алты ай бербуйдан мунча яктылар, никадәр өст-башымны карадылар, никадәр өй җиһазы бирделәр. Самавыр минеке, чынаягысавыты минеке, сөлге-салфите минеке, бөтен җиһазы минеке! Шулай шул! Бер тинсез шундый кызны биргәч, кадерен белмәде, хәзер инде себерелеп кызлар артыннан йөри. *(Шул арада Салих кайтып керә.)* Кунып кайту кирәк иде. Мөгаллимәңә ялгыз кунарга күңелсез булыр.

С а л и х. Син нәрсә сөйлисең, әллә тилердеңме?

М ә р з и я. Тилерсәң, син тилергәнсең. Гакыллы кеше хатыны бар өстеннән әллә нинди себеркеләр артыннан йөрми.

Салих киемнәрен салып ташлый.

С а л и х. Син нәрсә сөйлисең? Синең гакылың бармы, юкмы?

М ә р з и я *(ачуланган тавыш берлә)*. Бик бар! Син генә мине тилегә санныйсың! Ни сөйләгәнемне бик белеп сөйлим. Менә синең гакылың бармы? Син ничек оялмаенча мөгаллимә берлә йөрисең?

С а л и х. Мөгаллимә берлә?.. Ул ни дигән сүз?

М ә р з и я. Ул ни дигән сүз? Үзең белә торгансың, белмәсәң, йөремәс идең.

С а л и х. Синең бөтенләй гакылың юкмы әллә? Шундый сүзне шулай җиңелгә санап сөйләргә ярамый.

М ә р з и я. Син аны элгәре уйлап карау кирәк иде. Аннары башлар идең.

С а л и х. Мәрзия! *(Ачуланган тавыш берлә.)* Мин орышышырга яратмыйм, ләкин үземне-үзем мыскыл итәргә дә ирек бирмим. Син минем берлә андый сүз берлә уйнама!

М ә р з и я. Мин уйнамыйм! Син мөгаллимә берлә йөрисең! Син яратмый дип мин шуңарга разый булып торыйммыни?

С а л и х *(Мәрзия янына туктап, ачуланган тавыш берлә)*. Ялганлама!

М ә р з и я. Йөрисең, йөрисең! Йөрмәсәң, ни дип анда ул чикле торасың, ни дип аның янына кереп гәзитә укый-

сың? Тегесен генә күрим, Алла теләсә, сачен йолкып бетерермен. Кеше ире берлә йөрмәсә, таба алмагандыр.

Салих. Мәрзия! Мәрзия! Син ни сөйләгәнеңне беләмсең? Син бит кеше өстенә тел сөйлисең. Син бит гөнаһсыз кешенең исемен сатасың, син ничек оялмыйсың?

Мәрзия. Дөрест, дөрест! Бар да сөйли. Йә, кереп кызлар тыңлатмадым диген! Йә әйт!

Салих. Тыңлаттым. Тыңлатса, анда ни бар?

Мәрзия. Гәзитә кереп укымадым диген!

Салих. Укымадым.

Мәрзия. Кичәге гәзитәңне кая иттең?

Салих. Анда синең ни эшең бар!

Мәрзия. Ә, шулаймы? Менә яшерә башладыңмыни?

Салих. Йә, синеңчә булсын, мөгаллимәгә бирдем! Аннан ни чыга?

Мәрзия. Менә бүген кереп утырмадыңмы?

Салих. Керүен кердем, утырмадым.

Мәрзия. Утырмадың! Мин монда иртәдән кичкә кадәр ашамый-эчми аны көтеп ятам. Мин, тиле, аның буш өен каравыллап ятам, ул мөгаллимәләр берлә чәйләр эчеп йөри. Бу хурлыкка ничек түзим! Бу мыскылны ничек күтәрим! Исмасам, кешесе кеше төсле булса ярар иде. Бер хәерче кызы бит! Син шул симердең! Әтиләр бит алты ай симерттеләр. Гомереңдә күрмәгәннәреңне күрдең! Шуның шөкранасын кайтарасыңмыни?

Салих. Мәрзия, син нәрсә тилерәсең! Син миңа ышанамсың, юкмы?

Мәрзия. Юк, юк! Син мине тагы алдарга телисеңмени? Мин синең өчен әтиләр берлә бозылыштым. Үсеп җитеп этинең орышуыны күрмәгән идем, синең өчен — күрдем.

Салих. Тукта, азрак миңа да сөйләргә ирек бир!

Мәрзия. Тагы ялганлар идеңмени? Андук эти, ул синең башыңны ашамакчы була, дигән иде. Мин, тиле, эти сүзенә ышанмый, моның сүзенә ышанам. Мин бит моңынча әллә кайчан этиләр түрендә утыра торган кеше идем! Беләмсең син шуны, мине муллага бирергә дип үстергәннәр иде? Синең шикелле хәерчеләргә бирермез дә, ул аның өстеннән кызлар берлә йөрер дип уйламаганнар иде.

Салих *(ачуланып)*. Алай үзеңне бик зурга санагач, килмәсләр, Мәрзия туташ, мин сине көчләп алмадым, мин сине көчләп тотмыйм!

Мәрзия. Ә алаймы? Хәзер аерып җибәреп, яңы бикәч алырга телисеңмени? Юк әле, мөгаллимәң бик ашыкмасын.

С а л и х. Сиңа кем аерам дигәне бар?

М ә р з и я. Син әйтәсең! Әллә инде мине аңламый, бөтенләй тиле дип беләмсең?

С а л и х. Мин әйтсәм, синең сүзеңә җавап итеп әйтәм. Син бик олуг кеше булгач, минем кебек хәерче берлә тормасын дим!

М ә р з и я. Мин сиңа хәерче диммени?

С а л и х. Белмим, кемгә әйтә торгансың? Син, Мәрзия, юкка тилерәсең, син эшнең төбен белергә кирәк, аннан соң сөйләргә кирәк. Дөрест, мин мөгаллимә янына керәм... Гәзитә дә укыйм, ләкин мөгаллимә берлә минем бер эшем дә юк.

М ә р з и я. Син, бер эшең дә булмагач, ни дип мөгаллимә янына керәсең, ни дип гәзитәләр укыйсың? Синең өең юкмыни, әллә син миннән туйдыңмы?

С а л и х *(туктап торып)*. Мин синең наданлыгыңнан, синең дорфалыгыңнан туйдым! Белдеңме, туйдым! *(Йөри башлый.)* Синең бертуктамаенча эчне пошырып этиләреңне сөйләвеңнән, синең бертуктамаенча үзеңнең бай кызы икәнлегеңне колакка тукуыңнан туйдым. Мин мөгаллимәгә хәл җыярга, сулыш алырга барам, белдеңме? Бел! Ләкин мөгаллимә берлә минем бер эшем юк. Мин аның берлә кызлар-хатыннар берлә сөйләгән кебек сөйләмим, кеше берлә сөйләгән кебек сөйлим. Син аңламаган гәзитәне ул аңлый, син ләззәт алмаган китаптан ул ләззәт ала! Менә шуның өчен мин анда барам! Аның берлә сөйләшеп күңел ачам.

М ә р з и я. Ник минем берлә сөйләмисең?

С а л и х. Синең берлә нәрсә тугрысында сөйлим? Мин синең күлмәгең тугрысыннан сөйли-сөйли арыдым инде. Син укыган булсаң иде, син, исмасам, мин укытканда гына укыган булсаң иде, мин үз өемне ташлап, чит өйләрдә эч пошуга дару эзләмәс идем. Мин күп вакытта, синең берлә сөйләргә телим, ләкин мин сөйли башлаган сүзне син аңламыйсың, яисә кирегә борып, шуңардан үзеңнең күлмәгеңне китереп чыгарасың.

М ә р з и я. Мине нишләтмәкче буласың соң?

С а л и х. Мин сине бер эш тә эшләмәкче булмыйм, әгәр хәзер минем көчемнән килсә иде, мин сине гыйлем дәрьясына чумдырып алыр идем дә, син дә мин аңлаган нәрсәләрне аңлый башлар идең. Син дә мин ләззәт алган нәрсәләрдән ләззәт алыр идең! Хәзер синең берлә минем арамда йир берлә күк арасы кадәре аерма бар. Шуның өчен син мине аңламыйсың, шуның өчен син мине көнлисең!

Мәрзия *(йомшарып)*. Мин нишлим соң? Мин бит ачуым килгәнгә генә әйттем, чын йөрмимсең, әйт?

Салих. Юк, йөрмим!

Мәрзия *(үбеп)*. Аңарга барма, йәмә, җаным! Гәзитәңне өйдә генә укы, йәмә!

Салих. Син үзең мин теләгән кеше булмаганда безнең арамыздагы аерма бетми, син укымаганда без бер-беремезне аңлаша алмыймыз.

Мәрзия. Мин укыйм! Менә бүген үк укый башлыйм. Син мине бик тырышып укытырсың, җәмә! Хәзер миңа ачуланмыйсың? Ачуланма, җаным. *(Үбеп ала.)*

Салих. Укысаң ачуланмыйм.

Мәрзия. Укыйм, укыйм. Синең чәй эчәсең киләме, эниләрдән әле күчтәнәч китерделәр.

Салих. Килә иде дә, хәзер оныттым.

Мәрзия. Самавырым кайнаган, хәзер ут кына салам. *(Чыгып китә.)*

Салих. Бу бер кызык кеше, мескен. Укымау никадәр эштән чыгарган. Үзенең күңеле нинди яхшы булса да, наданлык нинди дорфалаткан. Мещан тәрбиясе нинди ямьсез гадәтләр урнаштырган. Ярый, хәзер тагы укымакчы була. Бу юлы чынлап та укыр инде. Әл дә аның укымаганыннан бик күп зарар күрдек. Әгәр гел болай булса, бу тормыш түгел, бу төрмә иде. Аерыр идең... бала бар. Тагы берсе бүген таңда! Тагы — ул бит миннән аерыласы килми. Ул бит миннән аерылып тора алмый. Үзем дә шул дорфа хатынның әллә кай йирен яратам, үзем дә аны шул мөгаллимә берлә алыштырырга риза булмыйм.

Мәрзия килеп керә. Мәрзия кызуланып чәй хәзерли.

Мәрзия. Әни менә нәрсәләр җибәргән. *(Каз ите, сумсалар күрсәтеп.)* Менә бик һәйбәтләп чәй эчик әле, минем дә бик эчәсем килде. Чынаякларны син хәзерлә әле. Мин хәзер самавыр алып керәм. *(Чыгып китә.)*

Салих *(чәй урыны хәзерләп)*. Хәерле сәгатькә булсын! Тагы яхшырды.

Мәрзия самавыр алып керә. Мәрзия чәй сала, чәй эчәргә утыралар.

Мәрзия. Минем күңелем тынычланып китте. Чын, бик көнләшкән идем. Мин сине бик сөям шул. *(Үзе Салихны үбә.)* Йә әле, сөйләшеп утырыйк әле.

Салих. Менә, әле урыс гәзите укыдым.

Мәрзия *(бик озын иснәп, чәй ясап эчә)*. Әти иртәгә Казанга барадыр, ди. Менә, бозылышмаган булсаң, миңа каймалы читек алып кайтыр иде.

С а л и х. Мәрзия, әле генә андый сүзләрне сөйләмәскә вәгъдә бирдең ич!

М ә р з и я. Ярар, сөйләмим, сөйләмим! *(Ашыйлар.)* Менә каз ите ашаганым юкка шәт атна булды инде. Әниләргә барсам, ашар идем дә... Бармыйм шул.

С а л и х. Син тагы элгәргечә мине әтиеңнәр берлә сыйларга тотынасың.

М ә р з и я. Юк, юк. Менә күмәчен аша. Безнең әнинең күмәче бик тәмле була. Аның сөте-катыгы бик күп, безнең әти онны капчыклап китерә. Ярый әле әни җибәргән, рәхмәт, югыйсә бик ашыйсым килә иде.

С а л и х. Ник үзең бер-бер нәрсә пешермәдең?

М ә р з и я. Нәрсә белә пешерим? Синең онның бармы, маең бармы?

С а л и х. Анда акча юкмыни?

М ә р з и я. Булса, ул акчага алынган нәрсәнең бәрәкәте булмый. Менә безнең әти бер дә ваклап алганны яратмый. Онны, дөгене, җимешне потлап китерә. Күлмәк алса, өчләп ала. Әти миңа Казаннан бер-бер нәрсә алып кайтыр микән?

С а л и х *(чәй эчә)*. Сәгать ничә?

М ә р з и я. Сәгать унынчы.

С а л и х. Менә, эчеп бетерик тә, укый башлармыз.

М ә р з и я. Мәгънәле китапка керермез, җәмә!

С а л и х. Нинди мәгънәле китап? Үзең белмәгән эшкә катышма!

М ә р з и я. Алла, мине тагы әллә нинди китаплар укытмакчы була.

С а л и х *(гәзитә алып укырга тотына)*. Эчеп туйсаң, хәзер укый башлыймыз.

М ә р з и я *(эчә)*. Бүген бик соң инде, минем йокым килә. Иртәгә укырмыз.

С а л и х. Юк, юк! Хәзер укыймыз.

М ә р з и я. Алла, бүген сабак башлый торган көн түгел, бүген сишәнбә. Менә аннары үзем мөгаллимә булырмын, бу мөгаллимәне җибәрермен.

С а л и х. Яхшы укысаң булырсың.

М ә р з и я. Элгәре дә мин яхшы укыдым да, син мине мөгаллимә ясамадың бит, син әллә кайдан китерттең! Инде...

С а л и х. Тагы башлады, ал китапларыңны.

М ә р з и я. Тукта, самавыр җыештырыйм! *(Җыештыра, Салих гәзитә укый. Җыештырып бетерә.)*

С а л и х. Ал!

М ә р з и я. Минем йокым килә, иртәгә укырмыз.

С а л и х. Иртәгә кайчанга, тагы кичсез минем вакытым юк. Тагы йокым килә, диерсең.

М ә р з и я. Аннарыга.

С а л и х. Син шулай иттереп гел кичектерергә телисең. Кил, укы!

Мәрзия барып урын җәяргә тотына.

М ә р з и я. Бүген менә бик һәйбәтләп йоклыйк, иртәгә укый башлармыз.

С а л и х. Юкны сөйләмә! Әйдә, ал китапларыңны.

Мәрзия урын җәя.

М ә р з и я. Йә инде, җаным, бүген укымыйк. *(Моңланып.)* Мин бик арыдым. Менә иртәгә, Алла теләсә, бик тырышып укый башлармыз.

С а л и х. Иртәгә дә минем вакытым кич кенә була ич, иртәгә дә арыдым, дип тагы калдырмакчы буласың?

М ә р з и я. Иртәгә мөгаллимәң янында ул чикле озак тормассың?

С а л и х *(ачуланган тавыш берлә)*. Мәрзия!

М ә р з и я *(Сузып кына)*. Кычкырма, баламны уятырсың. Әллә дөрест түгелме?

С а л и х. Син мине мыскыл итәсеңме? Уйныйсыңмы?

М ә р з и я *(янына килеп)*. Бетте, бетте! Бер дә әйтмим, әйдә, җаным, ятыйк, иртәгә укырмын.

С а л и х *(ачуланган тавыш берлә)*. Бар, ят!

М ә р з и я. Алла, ятмаган була, ят инде, үзең дә арып беткәнсең. *(Салих дәшми.)* Дәшмәгән дә була. Ятмасаң, әллә бик исем китәме? Син мөгаллимәң яныннан туеп кайткан инде.

С а л и х *(ачуланып)*. Шул сүзне бүген авызыңнан ташлыймсың, юкмы?

М ә р з и я. Ә, ачуың киләмени? Менә минем дә бик ачуым килә.

С а л и х. Беләмсең, син бит юкны сөйлисең, син бит юк сүз берлә минем тормышымны агулыйсың! Ник син алай итәсең?

М ә р з и я. Миңа җиңелмени?

С а л и х. Нәрсә җиңелме?.. Син бит үзең дә сүзеңнең ялганлыгын беләсең? Ник юк берлә маза китәрәсең?

М ә р з и я. Алай булгач ник ятмыйсың? Син инде үз хатыныңнан бөтенләй бизеп беткән. Кеше кебек вакытында ята белми, вакытында тора белми, вакытында ашый

---

*Маза китәрү* — бимазалау, борчу.

белми. Көн буе ашарга көтеп торганым җитмәгән, төне буе йокларга да көтеп торыйм икән!

Салих. Кем соң әле сине көт дигәне бар, йокла!

Мәрзия. Йокла! Син йокыңны туйдырып кайттыңмыни? Инде төн буе шул гәзит берлә күзен бетәштереп утыра, күрәсең! Утыр, утыр! *(Салих дәшми.)* Алла теләсә, эти генә кайтсын, барысын да сөйлим! *(Салих дәшми.)* Көн буе мөгаллимә янына барып утыруын да сөйлим, барысын да сөйлим.

Салих. Сөйләсәң сөйләрсең, хәзергә генә лыгырдама, туйдым.

Мәрзия. Мин беләм бит синең туйганыңны, туймасаң, көне-төне мөгаллимә янында гомереңне кичермәс идең! Туйган шул! *(Бераз туктап торып, Салих һаман гәзитә укыган булып утыра.)* Кем инде үз хатыны бар өстеннән кызлар берлә йөридер, ди? Кыз булса, тагы ярар иде, әллә нинди бер матамал ич! Атасы юк, анасы юк!

Салих *(кычкырып)*. Йокла! Мазаны китәрмә!

Мәрзия. Алла, бик зур булган, нинди кычкыра, әллә инде мине сөйләтмәскә дә телисең? Мин шул синең мөгаллимәң кебек сөйли белмим, гаеп итмә! *(Туктап торып.)* Хәзер инде мин кирәк түгел... Элгәре мин кадерле идем... Мин хәзер инде сине туйдырдым... Син инде бүтән кешеләр эзлисең... *(Елаган тавыш берлә.)* Мин картайдым инде... Мин көне буе өй каравыллаудан башкага ярамыйм инде... Әһе... әһе. *(Еглый.)*

Салих. Нишлисең син, Мәрзия? *(Мәрзия дәшми, бераздан.)*

Мәрзия. Синең минем нишләвемдә эшең бармыни? *(Елаган тавыш берлә.)* Синең үз кайгың үзеңдә...

Салих. Әле соң егларлык нинди эш булды? *(Торып янына барып.)* Мин соң әле нишләдем?

Мәрзия *(елаган тавыш берлә)*. Син мине сөймисең... Син *(Озын иттереп.)* мөгаллимәне... сөясең!.. Син мине кешегә дә санамыйсың... Син миннән гәзитәңне артык күрәсең... Мин сөям...

Салих. Мин дә сине сөям.

Мәрзия Салихның кулын тотып, Салих бу вакытта чыбылдык янында тора. Мәрзия гел чыбылдык эченнән сөйли. Күренми. Еглавын туктатырга теләгән тавыш берлә.

Мәрзия. Мөгаллимәне сөймисең? Сөймә, җаным, җәмә!

---

*Матамал* — тиргәү сүзе.

Салих. Юк, юк.

Мәрзия *(аны кулыннан тартып үбә дә)*. Мин шул бик көнлим! Мөгаллимәгә бармассыңмы, барма, җәмә!

Салих. Ярар.

Мәрзия *(ачыграк тавыш берлә)*. Менә мин, әти кайткач, этиләргә барырмын, сине дә чакыртырмын. Барырсың, җәмә! *(Сузып кына.)* Тагы элгәреге кебек этиләргә барып-килеп йөрермез... Бик кызык булыр, җәмә? Мин кунаклар чакырырмын... Син шәһәргә барырсың... Миңа күлмәк алып кайтырсың... җәмә!

Салих. Ярый, еглама гына, мин еглаганны гына яратмыйм.

Мәрзия. Юк, егламыйм, бетте. Кил җат, җаным! Бар, утыңны сүндер!

Салих барып утыны сүндерә, үзе Мәрзия янына ятарга килә. Караңгы.

Мәрзия. Әти үзеңезгә иген сачәрмен дигән иде, иген сачәрмез. Ул игенемез күп булыр... Мин бер оя каз сатып алырмын. Чебешләр үстерермен, үзеңә йомырка ашатырмын, җәмә! Әминәгә (кызы) бик матур киемнәр киендерермез, аннары ат берлә трантас алырмыз... Әмин авылына кунакка... барырмыз, җәмә! Бик кызык булыр.

Салих. Җә!.. *(Салих чаршау эченә керә. Үбешкән тавыш ишетелә.)*

Пәрдә төшә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Дүртенче пәрдәдән соң бер ел вакыт үткән. Салих өе — дүртенче пәрдәдәге өй. Яту урыны янында ике бишек асылган. Идәндә ашъяулыклар, аш урыннары, салфетлар тузгып ята. Аштан соң. Кыш көне. Кич берлә Мәрзия ялгыз аш урынын җыештыра.

Мәрзия. Ашым бик яхшы булды. Илаһи! Әхмәтсафа хатынының кылынышыны күрсәң, исең китәр иде. «Безнең карт пирвый сурт он китерә. Синең, Мәрзия, фтаруй сурттыр, ахрысы»,— дигән булып утыра! Хәерче! Кайчаннан бирле әле безнең этидән бурычка алудан туктадыңыз? Менә җыештырып бетерәм дә ашка барам. Теге тиз генә кайтса ярар иде... Монда балалар янында калырга кеше юк. *(Үзе кызу-кызу җыештыра.)* Иртәгә менә тагы Әхмәтҗаннарга ашка әйттеләр, өйләдән соң Сәлахиләргә... Ирләргә дә иртәгә аш булса ярар иде...

*(Җыештырып бетерә. Барып көзгегә карап.)* Битем тулып киткән. *(Көлә.)* Ник тулмасын, башым тыныч, күңелем иркен... Менә хәзер кунаклар берлә кунакка йөримез... Аннары үземезне руза бәйрәменә чакыралар. Корбан бәйрәменә үземез кунак чакырамыз... Менә, күрми дә калырсың, кыш үтеп тә китәр... Аллага шөкер, бик яхшы тора башладым. Теге дә бөтенләй үзгәрде, элгәрегe кебек көне-төне мәктәбендә ятмый. Өйдә дә көне буе гәзитә укымый. Дөнья кайгырта башлады... Кичә шәһәрдән нинди яхшы нәрсәләр алып кайткан... Элгәре шәһәргә барса, әллә кайдан табып бер кочак гәзитәләр, әллә никадәр китаплар гына төяп кайта иде. Мөгалимәне дә ташлады, анда да бармый, бөтенләй башкарды. *(Шул арада Салих килеп керә.)* Тизрәк кайтсаң ярар иде дип тора идем. Минем ашка барасым бар.

Салих. Мин бүген дә мәктәпкә кермәммени?

Мәрзия. Әллә көне буе торганың җитмәгәнме? Балалар янында кем торсын?

Салих. Ярар, алай булса.

Мәрзия. Син, әти берлә старшинаны чәй эчәргә алып керү кирәк иде. Старшина хатыны әйтә, «картым быел сезгә дә муллалар берлә тигез йир бирдерәм дип әйтәдер», ди. Әйберем бик күп иде.

Салих. Бабайга әйттем, эшем бар, диде. Аңарга әллә кайсы авылдан мукшылар килгән, ди, җир сатулыйлар, ди.

Мәрзия. Мин хәзер киенәм дә китәм, син чәй эчәмсең? Эчсәң, анда самавыр кайнап тора. Әнә шкафта, ашарга кирәк булса!

Салих. Мин бик сыйланып кайттым әле. *(Мәрзия чаршау төшереп киенә.)* Син озак торма, балалар җылый башлар.

Мәрзия *(чаршау артыннан.)* Мин кечкенәсен үзем берлә алам, сиңа күңелсез булса, чәй эч! *(Шул арада Мәрзия яңа күлмәк киеп бу якка чыга да.)* Шәлем кайда? *(Салих өстәлдән шәлене алып бирә. Шәлен ябына да чаршауны тарта. Үзе бишек янына бара да бишекне ачып.)* Бик тәмле йоклый. Әллә, әтисе, алмыйммы? Уяныр шул. *(Ала башлый.)* Шулай, шулай, ай, бәбкәм. *(Алып шәленә төреп.)* Мин киттем. *(Чыгып китә.)*

Салих *(ялгыз)*. Йир бирсәләр, яхшы булыр иде, ул вакытта иген сачеп җибәрәсең. Старшинаны чәйгә алып кергәләргә кирәк. Таба майламый купмый... *(Йөрергә тотына.)* Юк, үзеңне-үзең онытып кына әллә нишләп булмый. Элгәре мин халык файдасы дип үземне-үзем корбан кылырга хәзер идем... Элгәре үзеңнең тор-

мышыңны яхшыртырга кирәк, аннары кеше кайгыртырга!

Ишектән З а к и р килеп керә.

З а к и р. Әссәламе галәйкем. Исәнме, хәлфә? Җәмәгатең киткәнне күрдем дә, тукта әле, кереп утырыйм әле дип кердем.

С а л и х. Уз, утыр.

З а к и р *(Киемнәрен салмаенча гына утыра)*. Нихәл, хәлфә? Шәһәрдә ниләр бар? Йир тугрысында ни сөйлиләр?

С а л и х. Аласы әйберләрем бик күп иде, сорашырга бушамадым.

З а к и р. Гәзитә алып кайткансыңдыр бит, анда ни сөйли?

С а л и х. Гәзитә алырга да онытканмын.

З а к и р. Син бигрәк ашыккансың. Элгәре, килгән вакытыңда, беләмсең, көн саен гәзитә алдырырга дип, малайлардан шәһәргә баручы эзләтә идең, хәзер үзең баргканда да алып кайтмаган.

С а л и х. Алып кайта идем дә, оныткамын.

З а к и р. Кирәкле нәрсә онытылмый ул, синең шул хәзер дәрт кайткан!

С а л и х. Белмим.

З а к и р. Соң бу йир нишләр икән инде? Әле бит тирәяк урыслары бик каты торалар, бу ел сачәмез, диләр.

С а л и х. Белмим. Ул миннән түгел.

З а к и р. Мин синнән димим, мин әле сөйлим генә. *(Туктап торып.)* Менә син дә үзгәрдең! Син инде менә безнең өчен өзелеп йөрергә кирәк иде. Безгә ничек эшләргә аңлату кирәк иде. Урыслар йир алса, без йирсез калсак, яхшы булмас бит! Авыл шул, каралта! *(Шул арада тәрәзәне дөбердәтәләр.)*

С а л и х. Кем бар? *(Тагы шакылдаталар.)*

З а к и р. Мин чыгып карыйм. *(Чыгып китә.)*

С а л и х. Бу да миннән әллә ниләр өмет итә! Мин хәзер кеше өчен селкенеп йөрер хәлем юк. Үземнең җәмәгатем бар. *(Шул арада: «Менә монда, монда!» — дигән тавыш ишетелә. Карга буялган кеше килеп керә.)*

С а л и х. Ә, Фазыл! Әйдә! Кайдан җил ташлады?

Ф а з ы л *(чишенә башлап)*. Сөйләмә инде.

С а л и х. Закир абзый, кызыңны Мәрзия артыннан җибәр әле, кунак килде, дисен. Алар Хәйриләрдә.

З а к и р. Ярар. *(Чыгып китә.)*

Ф а з ы л. Үлә яздык, көчкә авылны таптык. Мужикның аты бара алмый. Туңып үләмез күрәсең дип торам. *(Үзе тишенә.)* Сәгать ничә?

Салих. Сәгать тугызынчы.

Фазыл *(тишенеп)*. Туңдым, без өчтә чыккан идек. *(Идән буеннан йөрергә тотына.)* Синең өй йылы. Салих, нихәл соң, нишләп торасың?

Салих. Артык эш юк, искечә.

Фазыл. Син бөтенләй әллә нишләп киткән, ун еллык картайган, нишләдең?

Салих. Тормыш.

Фазыл. Тормыш! Хәзерге тормыштан исең китәр иде. *(Йөреп.)* Суык үткән.

Салих *(торып китә)*. Менә самавырга ут салыйм әле, хатын ашта иде.

Фазыл *(ялгыз)*. Бу нишләгән? Бөтенләй башка кеше. Картайган, изелгән, иске муллалар төсенә кергән. Әлгәре очкын Салих бөтенләй югалган. *(Туктап карап.)* Җиһазы-нисе һәммәсе сала мөәззиненеке кебек. *(Иснәп.)* Өеннән куй мае исе чыга, тегендә бишек, тагы бишек, бала... хатын... Бу бөтенләй харап булган, бу бөтенләй кешелеген югалткан.

Салих килеп керә.

Салих. Казан нишләп тора? Җәйдән бирле барганым юк!

Фазыл. Казан кайный! Тагы ничек кайный! Бокырбокыр кайный, асты өскә килә. Хәзер, туган, Казан — Кәҗә Ягъкублар, мөселман Мөхәммәтшалар Казаны түгел, Казан хәзер безнең Казан. Казанда хәзер әллә ничә гәзитә чыга, Казан хәзер әдәбият базары. Печән базары түгел. Без хәзер кырыкка ярыламыз. Беремез җәмгыятькә бара, беремез йөримез гәзитә редакциясенә, ул эшнең күплеген белсәң иде, исең китәр иде.

Салих. Ничек ул кадәр сез эшкә кереп киттеңез?

Фазыл. Без генә түгел, хәзер бөтен дөнья үзгәрде, бөтен Русия башкарды! Ихтилял! Син нишләп торасың, син бит мәгариф таратырга булып киткән идең. Синең эшләр ничек?

Салих. Акрын гына бара!

Фазыл. Акрын гына ул синең берлә миннән башка да бара, менә безнең вазифа шуны тизрәк, кызурак бардыру!

Салих. Алай артык эш юк!

Фазыл. Кызлар мәктәбе ачтыңмы?

---

*Ихтилял* — революция.

С а л и х. Ачтым.

Ф а з ы л. Хатының укытамы?

С а л и х. Юк, мөгаллимә укыта.

Ф а з ы л. Ник хатының укытмый?

С а л и х. Ул булдырырлык түгел.

Ф а з ы л. Ул соң әле миннән качамыни, син соң элгәре качуның дошманы идең түгелме?

С а л и х. Ул шәкерт вакыттагы фикерләр дә авылда үзгәрә.

Ф а з ы л *(исе китеп)*. Балаңыз да бармыни?

С а л и х. Икесе бар, берсе өметтә.

Ф а з ы л. Син бөтенләй тормышка яткансың, иптәш.

С а л и х. Әйе!

Ф а з ы л. Соң хатыныңнан уңдыңмы?

С а л и х. Ничек әйтергә кирәк, әйе, уңдым...

Ф а з ы л. Сөешәсез? *(Салих дәшми.)* Тормыш соң җиңел үтәме?

Шул арада М ә р з и я чаршау төшерә дә, самавыр кертә, Салих чәй урыны хәзерли.

С а л и х. Яман түгел, менә әле йир бирергә телиләр.

Ф а з ы л. Йир бирергә телиләр?!! Казаннан гәзитә аламсың?

С а л и х. Акча җибәргәнем юк, базардан алып кайталар.

Ф а з ы л *(гаҗәпсенеп)*. Бу ел соң, кеше гомерендә түгел, мәмләкәт гомерендә бер килә торган елда, гәзитәсез вакыт үткәрергә ярыймы?

С а л и х. Тормыш. *(Үзе, чәй урыны хәзерләп, чәйләрне өлгертә.)*

Ф а з ы л. Миңа кул юарга кирәк.

Шул арада чаршау астыннан ләгән берлә комган тыгыла.

С а л и х. Менә ю!

Фазыл барып кул юа, Салих чәй ясый. Фазыл кулын сөртеп килеп утыра. Шул арада чаршауны аз гына ачып Мәрзия карап тора да китә.

С а л и х. Син нишләп йөрисең?

Ф а з ы л. Менә сөйләрмен! Ашыйсы бик килгән әле.

С а л и х. Менә каз ите бар.

Ф а з ы л. Бабаң нинди кеше?

С а л и х *(Чыраен сытып)*. Авыл кешесе, начар кеше түгел, бай гына мужик, безне шактый карый.

Ф а з ы л. Яхшы торасызмы?

С а л и х. Яман түгел, элгәре яратмыйлар иде дә, хәзер яраталар.

Фазыл. Элек ник бозылыштыңыз соң?

Салих. Сәбәбе күп. Иң зурысы — минем яшьлегем, хәзер алай түгел.

Фазыл. Кемнәр берлә йөрешәсең соң? Мөгаллимәгә барып-килеп йөри торгансыз? *(Үзе эчә.)*

Салих *(чыраен сытып)*. Баргалыйм.

Фазыл. Ник бик куркып җавап бирәсең, әллә хатының берлә дуст түгелләрме?

Салих башын селкә. Фазыл исе китеп карап тора.

Салих. Ул көнли...

Фазыл. Муллалары нинди соң?

Салих. Иске муллалар. Мәгънәсез нәрсәләр...

Фазыл. Соң син кемнәр берлә генә йөрешәсең, ничек гомер үткәрәсең, әллә бик күп укыйммсың, әллә хатыныңны бик күп укытамсың?

Салих. Берсен дә эшләмим. Үзем укырга китап юк, элгәре кебек дәрт тә юк. Хатыным укырга яратмый. Барырга кеше юк. Мәктәпкә барып балалар укытам, аннары шунда муллалар янына берәр йирдә аш була, бабайларга барам, шулай көн үтеп тә китә.

Фазыл. Шуның берлә гомерең үтә. Мужиклар берлә эш итәсеңме? Алар берлә сәяси мәсьәләләр тугрысында сөйләп-фәлән итеп утырасыңмы?

Салих. Юк.

Фазыл *(торып йөрергә тотына. Бераздан соң)*. Синең, Салих, бу авылда эшләгән эшең шундагы кырык-илле балага язу таныту гынамыни? Син бит элгәре мөгаллим булганда, беләмсең, нинди зур өметләр берлә киткән идең? Син шул авылны гына түгел, шул тарафны яктыртырга уйлаган идең. Кая соң синең ул эшең? Син үзең укымыйсың, син хатыныңны укытмыйсың, син авыл халкы берлә эш итмисең, аларга хәзерге вакытның әһәмиятлелеген аңлатмыйсың. Син соң нишлисең? Син шул утыз-кырык малайны төрки таныту берлә канәгатьләнеп торасыңмыни? Әй Салих! Салих! Син тәмам үзгәргәнсең, син, Салих, элгәреге очкынлы Салих түгел. Син, Салих, иске заманнардагы авыллардагы балалар укыткан булып торган суфилар кебек булгансың. Син, Салих, нишләдең? Син миңа ачуланма, Салих. Мин синең дустың, мин синең иптәшең, мин бу сүзне йөрәгем әрнегәнгә сөйлим! Мин, монда килергә чыкканда, элгәре кебек шат, ачык, гайрәтле Салихны күрермен, аның берлә әллә никадәр эш эшләрмен дип уйлаган идем. Аның урынына мин элгәреге Салихның калдыгын таптым. Ни булды сиңа? Сөйлә! Ник син бу кадәр үзгәрдең?

С а л и х. Белмим, Фазыл, мин үземне моңынчага кадәр үзгәргән дип белми идем, әле хәзер үземне сиңа чагыштыргач кына белдем.

Ф а з ы л. Әй-әй! Минем күзләремә яшьләр килә, минем җылыйсым килә, син шул авылны агартыр өчен, аның гыйлемен үзеңә кадәр күтәрер өчен монда килдең, өч ел эчендә син үзең шул авыл кешеләре дәрәҗәсенә төштең. *(Салих дәшми.)* Без Казанда бу тараф бөтенләй Салих кулында, ул анда ялтыраган йолдыз кебек тора, аның аркасында әллә ничә авылны агарта аламыз, дип уйлый идек, һәммәсе җилгә очты! Һәммәсе бетте. Беләмсең, сине күргәч, бөтен эшемне оныттым. Әй Салих, Салих! Кайда синең элгәреге ышануың, кайда синең өметең?.. Шул тормыш кайгылары, шул авыл мужиклары, шул мужик кызы синең бөтен ышанычыңны, бөтен өметеңне бетердемени?

С а л и х *(йөреп)*. Фазыл! Фазыл! Син минем йоклаган элгәреге Салихны уяттың, син минем тормышымның иң авырулы йирен ачтың. Әйе, мин моңынча хатыным берлә тартышып, бабайлар, әбиләр берлә тартышып гомеремне әрәм иттем. Мин, сазлыкка баткан кеше кебек, шул наданлык дәрьясына үзем баттым. Мин, әллә нинди белмәгән кызга өйләнеп, үземне-үзем наданлык богавына богауладым. Мин вак нәрсәләр берлә тартыша-тартыша үземнең гайрәтемне, дәртемне югалттым. Мин сиңа хәзер эч серемне сөйлим, мин хәзер элгәреге Салих түгел. Мин хәзер элгәреге үземнең уйларымнан үзем көлә башладым. Элгәреге үземнең әллә нинди дәрт берлә эшләгән эшләремне тилелеккә хисап кыла башладым. Менә хәзер синең сөйләгән сүзләреңне дә, мин аңласам да, мин аларга ышанмыйм. Син Казанның кайнавына ышанасың, син, сәясәт галәменә кереп, анда әллә нинди авыл халыкларын беректерергә ышанасың, мин аларга ышанмыйм.

Ф а з ы л. Син нигә ышанасың?

С а л и х. Белмим... Бернигә ышанмыйм!

Ф а з ы л. Алай булгач, ни дип дөньяда торасың? Син шул ашап-эчәр өчен генә яшисеңмени? Юк, түгел, Салих. Мин сиңа ышанмыйм! Синең хәзер элгәреге Салихың әллә нинди тузаннар берлә капланган, әллә нинди ямьсез тормышлар астында калган. Син үзең үзгәрмәгән, сине менә, шул сазлыктан, шул былчырактан алып чыгарга кирәк. Сине саф һавада сулатырга кирәк. Менә мин сине бу сазлыктан чыгармаенча калмыйм. Мин синең иптәшең, мин синең дустың.

С а л и х *(башын селкә.)*

Ф а з ы л. Шулай булса, менә бу фатирыңны, менә шул

мәктәбеңне ташла да, Казанга китәмез. Сиңа хәзер монда торырга ярамый!

С а л и х. Минем хатыным бар... Минем балаларым бар...

Ф а з ы л. Булса, аналары берлә торырлар, бераз рәтләнгәч алдырырсың.

С а л и х. Белмим, мин анда барып нишләрмен?

Ф а з ы л. Кеше ни эшләсә, шуны эшләрсең. Мин сине алмаенча китмим, шуны бел! Синең бу изелүеңә син генә түгел, бөтен иптәшләрең риза түгел. Син бит, Салих, хәзер кеше түгел. Син бит, Салих... *(Әйтә алмаенча тора.)* Син бит, хәзер мещан! Син бит үзеннән-үзе разый тук мещан! *(Кызу-кызу йөри. Бераздан Салихның янына килеп туктый.)* Бир, Салих, кулыңны, бир кулыңны. Менә мин сине бу былчырактан өстерәп чыгарыр өчен кулымны сузам. Бир кулыңны! Бир. *(Салих тик катып тора.)* Үзеңне-үзең кызгансаң, бир! Минем берлә китәргә, бу сазлыктан мәңгегә китәргә вәгъдә бир! *(Салих тик катып тора.)*

С а л и х. Юк, юк! Миннән булмый! Булмый! Минем йоклаган җәрәхәтемне уятма, булмый!

Ф а з ы л. Салих! Синең үзеңнең монда киткән чагындагы уйларыңны хәтергә төшер әле. Син шул вакыттагы, эш өчен үлә торган Салихны күз алдыңа китер әле. Әй Салих, Салих! Син нишләдең... Син! *(Аның күзләренән яшь ага. Бик көчәнеп.)* Син бөтенләй кешеләр дәфтәреннән чыктыңмыни? Юк, мин моның берлә килешә алмыйм, юк. *(Урындыкка утырып, яулыгыны күзенә куеп, еларга тотына. Салих катып тора.)*

Ф а з ы л. Бу бит үлү, Салих! Бу бит тегенди үлүдән дә начар. Бу бит рухани үлү... Моны күргәнче, мин синең үлүеңне күргән булсам, җиңелрәк булыр иде.

С а л и х *(калтыраган тавыш берлә)*. Фазыл! Фазыл! *(Фазыл дәшми. Елый. Салих, янына килеп, башыны кочаклап.)* Фазыл! Фазыл! *(Фазыл дәшми.)* Мин... уйладым... мин китәм.

Ф а з ы л *(Сикереп торып, Салихны кочаклап үбеп)*, Салих! Салих! Рәхмәт, рәхмәт! Син әле, Салих, үлмәгән. Син, Салих, кеше! Син хәзер минем шатлыгымны белсәң иде, бүгенге көн минем гомеремнең иң шатлыклы көне! Бүген мин бер кешене әҗәлдән коткардым. *(Тагы Салихны үбә.)* Мин Салихны икенче кат анадан тудырдым.

С а л и х. Рәхмәт, Фазыл, килүеңә рәхмәт! Мин хәзер үзем дә үземне яңа кеше кебек хис итәм.

Ф а з ы л. Уф! Син минем, Салих, котымны очырдың. Мине өч еллыкка картайттың. Мине таш кискән кебек

арыттың. Уф, ярый, хәзер күңел тынычланды, калганын иртәгә сөйләрмез. Кайда, мине яткыр! *(Тагы Салихның маңлаеннан үбә. Салих чаршауны тартып урын күргәзә, Фазыл кереп китә.)*

Салих *(ялгыз гына)*. Миңа ни булды? Мин нишләдем, мин тәмам яңа кеше булдым. Әле ярый бу Фазыл килде. *(Уйлап торып.)* Мин соң чынлап яңа кеше булдыммы? Мин элгәреге Салих булдыммы? *(Бераздан.)* Юк, юк! Мин һаман әле мужик кияве Салих! Мин һаман әле муллалар арасында ашка йөри торган Салих! Ник ул килде, ник бу минем җәрәхәтемне ачты, ник бу минем йоклаган Салихымны уятты! Мин — Салих! Мин әллә никадәр хезмәт итәргә дип сызганып керешкән егет, нишләдем? Шулай ук мин шул өч ел эчендә бер эш эшли алмадыммыни? Мәктәп? Кызлар мәктәбе? Мәктәп? Әйе, мәктәп... Мәктәп соң мине канәгатьләндерәме? Мин соң шул мәктәптән зур эш эшли алмый идеммени? Өч ел гомер сарыф кылырлык мин файда иттемме?.. Юк!.. Юк!.. Мин өч ел эчендә нишләдем? Мин өйләндем... Өйләндем... Ике бала ясадым!.. Шулмы эш! Аны кем ясамый?! Үзем нишләдем? Гыйлемем арттымы? Арттымы?... Юк! Юк!.. Минем иптәшләрем өч ел эчендә әллә никадәр укыдылар. Мин нишләдем? Мин ике бала ясадым! Минем иптәшләрем Казанны кайнаталар. Мин нишләдем? Мин нишләдем? Мин иртәдән алып кичкә кадәр хатыным берлә оршышам. Мин беттем, мин кешелектән чыктым. Шул каһәр суккан тормыш, шул каһәр суккан мужик кызы мине эштән чыгарды. *(Йөри.)* Мин бәлки киләчәктә эшләрмен... Киләчәктә? Нәрсә эшләрмен?.. Ничек эшләрмен? Казанга барырмын... Укырмын... Эшләрмен... Хатыным... Балаларым нишләр? Юк, булмый, минем киләчәккә өметем юк. Минем киләчәккә ышанычым юк! Булмый. *(Туктап торып.)* Алай киләчәккә ышанычың булмагач, торуымнан ни файда була дип игътикадың булмагач, ни дип дөньяда торырга кирәк? Ни дип торырга кирәк? Үләргә кирәк... Үләргә кирәк? Ничек үләргә кирәк?.. *(Өстәл тартмасыннан револьвер алып, туктап.)* Шул револьверның шул шөребен генә борырга кирәк тә үләргә кирәк. *(Револьверны алып.)* Үләргә кирәк. Рухан үлгәч, җисмән да үләргә кирәк. *(Чикәсенә куеп карый. Туктап торып.)* Балаларым, хатыным нишләр? Юк, булмый. *(Револьверны куя.)* Менә тагы чынлап тора башлармын. Тагы иске Салих булырмын! *(Бала тавышы ишетелә.)* Менә бала! Әнә

---

*Игътикад* — ышаныч.

шуның өчен мин дөньяда торырга кирәк. Әнә шул баланы ашатыр өчен, шундый балаларны ашатыр өчен, киендерер өчен, минем ышанычым булмаса да торырга кирәк. Мин шулар өчен, көн дә хатыным берлә оршышсам да, торырга кирәк. Мин шулар өчен муллалар берлә ашка йөрергә кирәк. Шулар өчен фидия алырга кирәк. *(Туктап торып.)* Менә тагы берсе туар. Ике булыр, тагы берсе туар, өч булыр, дүрт булыр, биш булыр, бөтен өй бала берлә тулар... Минем шуларны тудырыр өчен, шуларны үстерер өчен дөньяда торырга кирәк. Шуның өчен хатыным берлә оршышырга кирәк. Шуның өчен иске идеалларны ташларга кирәк... Юк, юк... Миннән булмый... Булмый! Мин шул балаларны тудырыр өчен дөньяга килмәгән, мин хезмәт итәргә килгән. *(Туктап торып.)* Кемгә хезмәт итәргә?.. Халыкка... Халыкка!.. Ничек?.. Мин хезмәткә ышанмыйм... Мин бернәрсәгә ышанмыйм! Ышанмасаң, дөньяда торма!.. Торма... *(Тагы револьвер янына килә.)* Әйе, торма! *(Револьверны алып.)* Шул балаларны үстерер өчен, аларны тудырыр өчен дөньяда торма! *(Револьверны карап.)* Иске идеалыңны югалткан кеше, яңы идеалыңны таба алмаган кеше, дөньяда торма!.. Торма! Менә шуның шөребен бор да үл!.. Үл! *(Тагын чикәсенә револьверын куя да, үзе уйланып китеп.)* Иртәгә шылтырап-шылтырап тора торган салам берлә яккан мич гөр-гөр яныр, мин булмам... Мин булмам. Иртәгә туңып, катып, букчаларын күтәреп балалар мәктәпкә җыелырлар... Мин булмам. Иртәгә салкын көнне кызыктырыр өчен кебек чыккан кояш нуры берлә кар бөртекләре асылташ кебек җем-җем итәрләр, мин булмам... Иртәгә... һәммә авыл гөр килер... Һәммә кеше тормыш берлә ләззәтләнер... Мин булмам... *(Якындагы урындыкка бик каты утырып, кычкырып егларга тотына. Бераз елагач.)* Юк, юк! Торасым килә. Торасым килә! *(Револьверны куеп, ык-ык иттереп.)* Торасым килә. Мин дә кеше кебек тулы тормыш берлән торасым килә. *(Сикереп тора.)* Балалар кебек торасым килә. *(Тагы тавышланып еларга тотына, бераздан күзен сөртеп.)* Бетте... *(Тагы йөреп.)* Булды. Китәм. Бу тормыштан китәм... Мәңгегә китәм. Тормышның мәгънәсен эзләргә китәм. *(Өстәл янына утырып, бик кызуланып язарга тотына, берсе артыннан берсе ике хат язып конвертларга тыга да, өстенә киенергә тотына, тун кия. Биләй ала. Ишеккә барып җитәр алдыннан борылып китеп, ике бишекнең әле берсене, әле берсене ачып.)* Хушыңыз, балалар! Хушыңыз! Мине гаеп итмәңез! *(Үзе еглый.)* Мине гаеп итмәңез! *(Кулы берлән битене сыпы-*

*рып, бераз туктап торып.)* Хуш, Мәрзия! Син дә хуш! Син дә миннән бәхил бул!.. Син дә агызачак күз яшьләрең өчен бәхил бул! Хуш, мәктәп! Хуш, авыл! Хуш, Фазыл, син дә! Хуш үзеңнең кайнаган Казаның берлә, Фазыл, син дә хуш! *(Бик акыртын гына.)* Хуш, мине, минем кебекләрне эштән чыгарган бәдбәхет иске тормыш!

Ишекне ачып чыгып китә. Ишек бераз ачык кала. Ишектән су агымы кебек салкын ага башлый. Бүлмә салкынлана. Ыңрашкан тавыш ишетелә. Бүлмә ишегеннән Фазыл чыга. Ул калтырый.

Фазыл. Бу ни бу? *(Өстәлдә револьверны күреп.)* Бу ни? *(Аның тавышына Мәрзия уяна, чаршау селкенә.)* Салих! Салих! *(Җавап юк. Мәрзия ишекне ачып тышка кычкыра.)* Син! Син... Син! *(Җавап юк.) (Өстәлдә хатлар күреп)*. Ә, менә нәрсә. *(Укырга тотына.)* «Фазыл! Мин киттем. Бу тормыштан киттем. Тормышның мәгънәсен эзләргә, үземә идеал эзләргә киттем. Синең кайнаган Казаныңа түгел... Туп-туры киттем. Бәлки кыргыз сахрасына китәрмен. Бәлки Төркстанга китәрмен, бәлки Истамбулга, бәлки Парижга, бәлки тормышның теге ягына. Хуш».

Мәрзия *(йөгереп чыгып)*. Кая китте? *(Кычкырып еглый. Балалар еглавы ишетелде.)* Бу балаларны нишләрмен! *(Фазыл катып тора. Мәрзия ишекне ачып)*. Син! Син! Салих! Кайт! Кайт! Гәзитә укырсың!.. Кайт... Мөгаллимәгә дә... барырсың! Кайт, кайт! *(Җавап юк. Кычкырып елап урындыкка утыра. Аның тавышы, балалар тавышы бергә кушыла.)*

Пәрдә төшә.

*Соң.*

# КЫЯМӘТ

*Ике пәрдәле комедия*

КОМЕДИЯНЕҢ КЕШЕЛӘРЕ:

Ш а һ и я з д а н — Казанның бер бае.
С и т д ы й к х ә з р ә т — Казанның бик мәшһүр мөдәррисе, бохари, яше 70 ләрдә, кычкырып сөйли, каты басып йөри, кулыны бик бутый.
С ә г ы й т х ә з р ә т — Казанның 2 нче дәрәҗә мәшһүр мөдәррисе, бохари, 68 ләрдә.
Х ә м и т х ә з р ә т — тагы Казанның мөдәррисе, бохари, тирес кеше.
Х ә й р у л л а м у л л а — мәдрәсәсен япкан мөдәррис, надан моназарәче, 50 ләрдә.
К и я ү м у л л а — кечкенә генә мулла, бохари, 40 ларда.
М ө ә з з и н — ашыгып сөйли, халык алдында белемене күрсәтергә тырыша, 55 ләрдә.
Ф ә й з е р а х м а н м у л л а — яңарак фикерле мулла.
С а б и т к о д а, С а д ы й к а б з ы й, Г л а с н ы й а б з ы й, М ө х ә м м ә т җ а н а б з ы й — байлар
К е ш е л ә р.
И ш а н — ялганчы бер кеше.
Х а т ы н н а р.
Д в о р н и к, к у ч е р.
Ә х м ә т — яшь егет, ачык фикерле, кимияга дәртле кеше.

Вакыйга Казанда, 1897 нче елларда, яз башларында.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шаһияздан байның залы. Зал байларча, өстәлдә Ш а һ и я з д а н ялгыз чәй эчә. Алдында озын кулдагы дәфтәр. Үзеннән үзе сөйли.

Ш а һ и я з д а н. Никадәр расхут! Бу кадәр сабын нигә киткән. *(Кычкырып.)* Әй! Әсма, монда кара әле! *(Беркем дә килми, дәфтәрне ачып, тагы.)* Шикәр! Ике атнага пот ярым шикәр. Әсма! Әсма! *(Кычкыра, теге яктан «киләм, киләм» дигән тавыш ишетелә. Ә с м а чыга.)*

---

*Тирес* — кире, холыксыз.
*Моназарәче* — бәхәсләшергә ярата торган кеше.
*Кимия* — химия.

Ш а һ и я з д а н. Син ни дип карамыйсың, бер айга унбиш кадак сабын беткән. Ике атнага пот ярым шикәр беткән. Ул кая киткән? Әллә сез инде безнең тиремезне базарга чыгарырга телисезме?

Ә с м а. Приказчикларга әйт, һәр чәй саен зур шикәр савыты берлә тутырып бирәм, җитмәде, дип тагы менәләр.

Ш а һ и я з д а н. Җитмәсә, җиткән йирендә калыр. Моннан ары кеше саен берәр шакмактан артык бирмә! Асрауларның артын-алдын кара, бар да урлый, бар да урлый. Баерсың болар берлә.

Ә с м а. Әле бу байлык җитмәгәнме?

Ш а һ и я з д а н. Җә, җә, анысы синең эш түгел, син үз эшеңне кара. Асраулар өйрәгә ярманы күп салмасын. *(Әсма чыгып китә, Шаһияздан чәй ясап.)* Менә каһәр суккан, бар да урлый: асрау урлый, приказчигы урлый, кучеры урлый, дворнигы урлый, Алладан да курыкмый, байның бәддогасы төшәр дип тә оялмый.

Б е р  м а л а й *(кереп)*. Абзый, бер хәзрәт бар. Сезне күрәсе иде, ди.

Ш а һ и я з д а н. Өсте-башы яхшымы? Хәерче түгелме?

М а л а й. Яхшы.

Ш а һ и я з д а н. Бар, керсен. *(Үзе чәй эчә.)* Йөриләр шунда өстерәлеп, эш юкка. Менә аны чәй эчер инде.

Шул арада иске генә толыптан, чалмадан х ә з р ә т килеп керә.

Х ә з р ә т. Әссәламе галәйкем!

Ш а һ и я з д а н. Вәгаләйкем әссәлам, утырыңыз.

Хәзрәт утыра, дога кылалар.

Ш а һ и я з д а н. Хуш. *(Хәзрәт дәшми.)* Хуш! Яңез, хәзрәт, ни йомыш?

Х ә з р ә т *(кесәсен капшап кәгазь алып)*. Менә мин бер фәкыйрь авылның имамы идем.

Ш а һ и я з д а н. Без зәкят өләшмибез.

Х ә з р ә т. Мин зәкят сорамыйм. Менә шул карьямезнең мәсҗеде янган иде, әһле мәхәлләмез фәкыйрьгә күрә, мәсҗедкә иганә булмасмы дигән идем.

Ш а һ и я з д а н. Хуш.

Х ә з р ә т. Аллаһе Тәгалә газиз гомерләреңезне озайтсын дип, дәүләтеңез артсын дип әһле мәхәллә берлә дога кылып намаз укыр идек.

---

*Карья* — авыл.
*Әһле мәхәллә* — мәхәллә халкы.
*Иганә* — ярдәм, булышлык.

Ш а һ и я з д а н. Хуш, хәзрәт, хуш! Гаеп итмә, без бирә алмыйбыз, үземезнең эшебез күп, бирә алмыйбыз.

Х ә з р ә т. Аз гына булса да буш итмәңез инде, сезнең бу дәүләтеңез берлә сезгә берни түгел.

Ш а һ и я з д а н. Син, хәзрәт, безнең дәүләтне санамагансың, һәркемнең үзенә күрә эше. Без бирә алмыймыз.

Х ә з р ә т. Пәйгамбәремез бит бер-береңезгә иганәдә булыңыз дигән.

Ш а һ и я з д а н. Әйе, әйе, хуш! Менә, хәзрәт, китаплар алмыйсызмы? Хәзрәтләргә бик кирәкле китаплар бар, вәгазь китаплары: «Дөррәтен-нәсыйхин», «Фикъһе Әбүләис».

Х ә з р ә т. Юк, минем шул йомышымны йомышласаңыз...

Ш а һ и я з д а н. Мәгъзүр, мәгъзүр, хәзрәт. Хуш! Бик һәйбәт тәсбихләр бар. Мәккә-Мәдинә эше мәрҗәннәр, ислемайлар бар.

Х ә з р ә т *(акыртын гына кәгазьләрен җыеп)*. Пәйгамбәремез әйткән: малның каравылчысы — садака дигән.

Ш а һ и я з д а н. Әйе, әйе, хәзрәт. Хуш!

Х ә з р ә т. Син аның өммәте түгелмени? *(Чыгып китә.)*

Ш а һ и я з д а н. Барысына да бир! Мәсҗеденә бир, мәдрәсәсенә дә бир, мулласына да бир! Безгә беркем дә бирми, бар да ала.

Тагы карандашы берлә дәфтәрне тикшерергә тотына, ишектән бер к е ш е килеп керә.

К е ш е. Әссәламе галәйкем!

Ш а һ и я з д а н. Вәгаләйкем әссәлам!

К е ш е. Исәнме, Шаһияздан?

Ш а һ и я з д а н. Аллага шөкер, Әхмәди абзый.

Ә х м ә д и. Шаһияздан, минем шул тиешле акчаны биреп җибәрсәнә.

Ш а һ и я з д а н. Утыр. Хуш! Нинди акча?

Ә х м ә д и. Нинди димә инде, үзең дә беләсең, хезмәт акчам.

Ш а һ и я з д а н. Ярый, ярый. Хуш! Күпме, өч тәнкәме?

Ә х м ә д и. Ник өч булсын?

Ш а һ и я з д а н. Бишмени? Хуш!

Ә х м ә д и. Ник биш булсын, илле тәнкә.

Ш а һ и я з д а н. Илле тәнкә! Ул ни дигән сүз? Хуш!

Ә х м ә д и. Илле тәнкә шул: биш атналыгым алмаган.

Ш а һ и я з д а н. Синең бәһаң егерме биш идеме?

Ә х м ә д и. Ник егерме биш булсын, кырык.

---

*Мәгъзүр* — бу урында: гафу.

Шаһияздан. Кем берлә сөйләдең?

Әхмәди. Абзыең берлә сөйләдем.

Шаһияздан. Алай булса, абзыйны көт, мин белмим. Хуш!

Әхмәди. Зинһар, Шаһияздан, йончытма инде, көтә-көтә эштән чыктым инде. Кибеткә барсам — өйгә, өйгә килсәм — кибеткә бар, дисең. Инде абзыйны көт, дисең.

Шаһияздан. Хуш! Ник соң син әле йөдәтәсең? Синең акчаң бездә югалыр дип куркасыңмы?

Әхмәди. Мин, акча кирәк булмаса, үзем дә килмәс идем. Минем дә бит җәмәгатем бар.

Шаһияздан. Хуш! Ярый, ярый, алай булса, бирим. Күпме бирим, 15 сумга разый буламсың?

Әхмәди. Ник булыйм, булмыйм.

Шаһияздан. Үткән эш өчен тагы ни кирәк инде? Ярый, алай булса, егерме ясыйм, хуш!

Әхмәди. Син нишлисең, Шаһияздан? Минем кул көчемне көчләп алып калмакчы буласыңмы?

Шаһияздан. Әле мин сине көчлимме? Ихтыярың! Теләсәң, аласың, теләсәң, абзый кайтканны көтәсең.

Әхмәди. Соң бит, Шаһияздан, биш елдан бирле жалуниямне синнән ала килдем. Ник бу көн генә абзыеңа сылтыйсың?

Шаһияздан. Егерме тәнкәгә разый булмыйсың бит.

Әхмәди. Йә, уйнатма инде, бир!

Шаһияздан. Менә аласың килсә егерме биш сум, шуннан бер тиен дә артык бирмим.

Әхмәди. И Раббем. Кырык яса, ичмасам.

Шаһияздан. Юк.

Әхмәди. Утыз яса, ичмасам.

Шаһияздан. Ярый инде алай булса, карты яхшы. *(Шаһияздан торып кәгазь китерә.)* Шунда жалуниямне алып бетердем дип кул куй. *(Әхмәди кул куя.)*

Шаһияздан. Менә ун тәнкә акча, егерме тәнкәсенә кибеттән товар ал.

Әхмәди *(коты очып)*. Мин ул товар берлә нишлим?

Шаһияздан. Кирәгеңә тотарсың. Сабыннары кызларга юынырга булыр, мәрҗәннәр — тагарга булыр, китап, Коръән — укырга булыр.

Әхмәди *(курыккан тавыш берлә)*. Безнең әле бизәнү кайгымыз юк, ашау-эчү кайгысы. Зинһар, акчалата бир.

Шаһияздан. Юк, юк. Мә. *(Записка бирә.)*

Әхмәди *(алмаенча)*. Шаһияздан, уйнамасана!

Шаһияздан. Уйнамыйм, уйнамыйм, эшем күп, ал да юлыңда бул.

Әхмәди. Ичмасам, тагы ун тәнкә бир.

Шаһияздан *(ачуланып, кулыннан язуны алып төзәтеп)*. Башны әйләндерәсез. *(Кесәсеннән акчаны алып.)* Мә ал. Ярый, бар юлыңда бул. Алла хәерле ярдәм бирсен, бездән фатыйха.

Әхмәди *(читкә борылып)*. Унсигез ел хезмәт итеп хезмәт хакымны талап калалар. *(Шаһияздanга.)* Шаһияздан, кул куйсам, куйдым, ул егерме сумны мәңге бәхил түгел, эчеңә ут булып төшсен.

Шаһияздан. Әле, карт эт, биргәннең кадере юк, талашырга тели. *(Сикереп тора башлый. Әхмәди югала.)* Нинди инсафсыз, унсигез ел бөтен җәмәгатен безнең өсттән туйдырып торуы җитмәгән, байның бөтен малын кочакламакчы була! Әле биргәнгә рәхмәт дисен. Бирмәсәм, монысын да ала алмый идең бит. Язуың бармы әллә?

Чәй эчә. Шул арада хатын-кыз ягыннан акыртын гына ишекне ачып, Әсма күренә.

Әсма. Син, кеше юкмы?

Шаһияздан. Юк, кем кирәк иде соң?

Әсма. Беркем дә кирәкми, кеше юкмы гына, дим. Анда Зөләйха абыстай килгән. Шаһиязданда йомышым бар иде, ди.

Шаһияздан. Нәрсә шунда эчне пошырып йөри, акча сорый торгандыр әле. Бар, эше бар, диң.

Әсма. Ул бик зур йомышым бар иде, ди.

Шаһияздан *(ачуланган тавыш берлә)*. Бетмәс аларның йомышы.

Шул арада ишекне ачып бер карчык керә. Үзе сөйли.

Карчык. Миңа, карчык кешегә ярар әле. Мин инде хатынлыктан чыккан. *(Маңгаена зонтик итеп кулын куеп, туктабрак карап.)* Кеше бармы? *(Бераздан соң.)* Шаһияздaнмы? Сабирҗанмы? Күзләрем дә рәтләп күреп бетерми.

Шаһияздан. Шаһияздан, Зөләйха абыстай, Шаһияздан, утырыңыз.

Зөләйха. Ишракъ намазымны укыдым да кереп чыгыйм әле, дидем *(Зөләйха утыра.)*

Шаһияздан. Ни йомыш, Зөләйха абыстай?

Зөләйха. Менә Коръән чыгарыйм дигән идем. Шуның өчен Нәфисә остазбикәгә биш сум акча бирергә кирәк иде...

Шаһияздан *(аңламаган булып)*. Җә, хуш!

Зөләйха *(акыртын гына)*. Менә минем теге сездә эманәт акчамнан биш сум биреңез, дим.

Ш а һ и я з д а н. Әйе, әйе, хуш, ул соң син, Зөләйха абыстай, китап, Коръән тарату кирәк иде. Менә син бер-бер мәдрәсәгә китаплар кертү кирәк иде. Менә бездә зәкяттан калган «Әрбәгыйн» бар.

К а р ч ы к. Коръән чыгартудан саваплы булырмыни?

Ш а һ и я з д а н. Саваплы, саваплы, кое казыткан савабын алырсың, әйе, хуш! Аның савабын савабы җария, диләр. Хуш! Ягъни елга кебек агып тора.

К а р ч ы к. Бик авырып торам, әҗәлем якынлаша торгандыр, ахрысы, шуның өчен Коръән чыгартыйм дигән идем.

Ш а һ и я з д а н. Ә, авырыйсыңмыни? Хуш! Менә бездә торабы шифа бар, Мәккә-Мәдинәдән килгән, син шуны алдыр.

К а р ч ы к. Шифалымыни?

Ш а һ и я з д а н. Бик шифалы, бик... Тагы бездә мәгъҗүн бар. Бохара әмире үзе дарулана торган мәгъҗүн, бик файдалы, бик!

К а р ч ы к. Алдырыйм, алай булса.

Ш а һ и я з д а н. Алдыр, алдыр. Мин кибеттә чакта асравыңны чыгар.

К а р ч ы к. Коръән чыгартмыйммыни?

Ш а һ и я з д а н. Китап өләш, китап! Коръәнне үзең дә укый аласың.

К а р ч ы к. Ярый, алай булса.

Ш а һ и я з д а н. Малай! *(Кычкыра.)* Кая китте малае.

Ә с м а *(теге карчыкка)*. Әйдә, Зөләйха абыстай, без чыгыйк, аның эше бардыр.

К а р ч ы к *(кузгала)*. Хуш, Шаһияздан, үлсәм, намаз артыннан догаңнан калдырма.

Ш а һ и я з д а н. Хуш. *(Шул арада малай керә.)* Син кая йөрисең? Бар, Әхмәт абзыеңны кантурдан чакырып мен, бай чакыра, диң. *(Бары да чыга. Торып)*. Бу карчыгына да акча бир! Буңарга ни калган инде, үләргә генә бит. Ул да акча, ди. Йә, хуш, инде ни калды? Буңарга теге китап тугрысында кушарга кирәк. *(Шул арада русчарак киенгән зур гына мыеклы егет күренә. Шаһияздан тиз генә аңарга карап, кызу-кызу.)* Хуш! Менә ни йомыш, типографиядә теге Зыя казыйның китабы басыламы?

Ә х м ә т. Басыла.

Ш а һ и я з д а н. Ул базарлы китап булырмы? Сатылырмы?

Ә х м ә т. Сатылырга тиеш, яхшы китап.

---

*Торабы шифа* — шифалы туфрак.
*Мәгъҗүн* — бу урында: дару, төнәтмә.

Ш а һ и я з д а н. Ул өч мең басыламы?

Ә х м ә т. Әйе, заказ өч меңгә.

Ш а һ и я з д а н. Алай булса, үземезнең кәгазьгә ике мең басыңыз, теге шома кәгазьгә.

Ә х м ә т. Заказ өч мең генә бит.

Ш а һ и я з д а н. Шуңарга күрә әйтәм шул, ике мең үземезгә басыңыз, дим. Нәрсә аңламаган булып торасың?

Ә х м ә т. Аңламыйм шул, өч мең заказга биш мең басарга кушасыз.

Ш а һ и я з д а н. Хуш! Өч мең аңарга үз кәгазенә. Хуш! Булдымы? Ике мең безгә, үз кәгаземезгә, булдымы? Хуш.

Ә х м ә т. Ул бит хыянәт була.

Ш а һ и я з д а н. Ни дип хыянәт булсын? Үз кәгаземез берлә басабыз бит. Аңардан ул ике меңе өчен басу бәһасе дә, набор бәһасе дә алмыймыз бит, хуш! Моның кай йирендә хыянәт?

Ә х м ә т. Ник хыянәт булмасын? Без аңардан ризалык алмаган ич.

Ш а һ и я з д а н *(көлеп)*. Әһе, әһе, син әле, энекәш, бик нечкәләмәкче буласың, кылны кырыкка ярмакчы буласың. Ярый, мин кушканча эшлә.

Ә х м ә т. Яравын ярый да...

Ш а һ и я з д а н *(сүзне бүлеп)*. Ярый, ярый, беләм. Хуш! Тагы ни сөйләмәкче буласың?

Ә х м ә т. Теге мөхәррир килгән. Сез китабын карарга алып калган идегез. Монда менсенме, җавап әйтәсезме?

Ш а һ и я з д а н. Ул тагы кайсы?

Ә х м ә т. Әнә беркөн китап калдырып китте.

Ш а һ и я з д а н. Ә, беләм. Теге шома егетме? Тар чалбармы? Ярый, алабыз, диң. «Фәзаилешшөһүр»дән калган кәгазь бардыр. Шунда берара, малайлар буш чакта басып алырсыз.

Ә х м ә т. Бәһасе?

Ш а һ и я з д а н. Нинди бәһасе? Аның ни бәһасе бар? Әкият бит. Менә аңарга шөһрәте булыр, шөһрәте. Хуш! Ул җитмәгәнмени? Шөһрәт!

Ә х м ә т. Ул акча сорый.

Ш а һ и я з д а н. Акча! Ни өчен? Әкият өченме? Ярый, ярый, хуш! Егерме данә китап бирермез, диң.

Ә х м ә т. Акчалата юкмы?

Ш а һ и я з д а н. Юк, юк. Хуш! Китабы сатылырлыкмы?

Ә х м ә т. Бу елда инде андый китаплар сатыла.

Ш а һ и я з д а н. Хуш! Сатыла, диң. Сатылса, егерме китап өстенә өч сум акча, диң.

Ә х м ә т. Бирмәсә?

Ш а һ и я з д а н. Ник бирмәсен, шөһрәте булыр диң, шөһрәте. Бирер, бирер. Хуш! Ярый, бар. *(Әхмәт югала. Шаһияздан ялгызы)* Әкият язучысына да акча бир. Бастырганы өчен рәхмәт укырга кирәк бит.

Шул арада, ишек дөбердәп, к у ч е р берлә д в о р н и к күренә. Икесе дә пышнаган.

К у ч е р *(ике кулын учлап ачып әллә нәрсә тоткан)*. Шаһияздан абзый, Шаһияздан абзый!

Д в о р н и к *(алга чыгып)*. Йомырка!

Ш а һ и я з д а н *(гаҗәпсенеп)*. Ни булды? Хуш!

К у ч е р. Йомырка, йомырка! Алтын йомырка.

Ш а һ и я з д а н *(барып йомырканы карап)*. Алтын йомырка? Бир, бир! *(Бик тиз кулына ала.)*

К у ч е р. Мин таптым, чуар тавык салды.

Д в о р н и к. Мин таптым, әтәч салды.

К у ч е р. Мин, дим.

Д в о р н и к. Мин. Әтәч салды.

К у ч е р. Алдама.

Шул вакытта Шаһияздан әйләндереп-әйләндереп карый.

К у ч е р. Тавык салды. Мин таптым.

Ш а һ и я з д а н *(гаҗәпсенеп)*. Язулы. Әй, Әсма! Әй, Әсма! *(Кызуланып, ике кулы берлә учлап йомырканы күтәреп йөри башлый.)*

К у ч е р. Алтын йомырка. Бай, чәйлек!

Д в о р н и к. Мин таптым. Бай, миңа чәйлек!

Ш а һ и я з д а н *(йомырканы карап-карап)*. Чәйлек-чәйлек! Ахырзаман галәмәте! Алар — «чәйлек».

Ә с м а килеп чыга, дворник, кучер, икесе дә «мин таптым» дип сөйләргә тотыналар.

Ә с м а *(бисмилла әйтеп)*. Мин шикләнәм, хәерлегә булсын. Язуы бар. *(Карап-карап.)* Алла сүзе бар. Тәһарәтем дә юк. *(Укырга тели, укый алмый.)*

Ш а һ и я з д а н *(карап-карап)*. Бар, бар. Менә «Ля иляһе» дигәнме. Тагы, тагы кара, кара, могҗиза, могҗиза. *(Кучерга.)* Әй, әй, бар! Кияү мулланы алып кил, хәзер, диң. Тавык алтын язулы йомырка салды, диң. Бар, бар, тиз, тиз. *(Кучер чыгып китә.)*

Ә с м а. И Раббем, хәерлегә генә булсын.

Д в о р н и к. Әтәч йомырка салса, казага каршы була.

Ш а һ и я з д а н *(һаман кулына тотып укырга маташып)*. Әсма, Әсма! Менә монда кара әле. Бу ни дигән сүз?

Ә с м а *(янына килеп)*. Белмим, белмим! Мин куркам.

Шул арада З ө л ә й х а карчык чыга.

Ш а һ и я з д а н. «Ля иляһе...» Менә тагын укый алмыйм.

З ө л ә й х а. Нәрсә бар?

Ә с м а. Тавык алтын язулы йомырка салган.

Д в о р н и к. Тавык түгел, әтәч.

З ө л ә й х а. Хәерлегә булсын. Садака бирергә кирәк. Мин яшь чакта безнең дәү этиләрнең әтәче салган иде — бөтен авыл янып бетте.

Ш а һ и я з д а н. Бу — язулы.

К а р ч ы к. Ахырзаман галәмәте.

Ә с м а. Мин куркам, Зөләйха абыстай. Бер-бер нәрсә булмас микән? И Раббем, гөнаһым бигрәк күп, күрәсең. *(Дворникка.)* Бар, ичмасам, Гайшә кодагыйны чакыр, тавыклары язулы йомырка салган, диң.

Д в о р н и к. Тавык түгел, әтәч. *(Үзе чыгып китә башлый.)*

Ш а һ и я з д а н. Әй, син кара әле. *(Дворник ишекне ачып башын тыга.)* Син Сәлах кодага да әйт. Барышлый Хәмит кодага кер, аннары Ситдыйк хәзрәт берлә Хәким хәзрәткә әйт. Күргән бер кеше берлә сөйләшеп торма, тиз йөр! *(Дворник югала.)*

Ш а һ и я з д а н. Әсма, мә әле, тотып тор әле, мин тәһарәт төзим, дим.

Ә с м а. Кирәкми, мин куркам.

З ө л ә й х а. Бир үземә!

Ш а һ и я з д а н. Синең кулың калтырый!

Ә с м а. Мин куркам.

Ш а һ и я з д а н. Нәрсәдән куркасың? *(Укый.)* «Илля Аллаһе...»

Ә с м а. Тукта, мин тартма китерим. *(Шкафны ача да бер тартмадан брошкалар бушата.)*

Ш а һ и я з д а н. Алла хәерле кылсын, мин дә шикләнә башладым. Монда әллә ни бар. Менә бу сүзе тагы әллә нинди! Могҗиза шул.

Ә с м а. Әллә мамык китеримме?

З ө л ә й х а. Китер шул. *(Әсма чыга.)*

Ш а һ и я з д а н. Замана бозылды, гөнаһ шомлыгы, әллә нинди тар балаклы малайлар китап яза башлады. Элгәре бит имам әгъзамнар гына язган. *(Әсма мамык күтәреп алып керә дә тартмага мамык куя. Шаһияздан килеп, бисмилла әйтеп, салават әйтеп, тартмага куя да тартманы өстәл өстенә куя.)* Мин тәһарәтләнеп керим, боза күрмәңез. *(Чыга.)*

---

*Имам әгъзамнар* — бөек, дәрәҗәле имамнар.

Ә с м а. Зөләйха абыстай, син карчык кеше, бу нигә булыр икән?

З ө л ә й х а. Әтәч йомырка салганын күргәнем бар. Язулы йомырка салганын ишеткәнем дә юк. Ни әйтергә дә белмим, бәбкәм. Хәерле булсын, диң.

Ә с м а. Хәерле булсын инде. Бәлки, байлыкка гынадыр әле.

З ә л ә й х а. Шулай булсын. Замана бозылды, бәбкәм. Бөтен урам тулы хатын, бөтен бакча тулы хатын, әл дә әле Аллаһе Тәгалә чыдый. Моңынча безнең Казанны әллә кайчан йир убу кирәк иде.

Ә с м а. Барымызның да гөнаһымыз күп инде.

Шул арада күзен акайтып м у л л а  к и я ү килеп керә. Әсма ашыгып чыга, Зөләйха акыртын гына чыга.

К и я ү  м у л л а. Кая? Кая?

Идән буенда эзләргә тотына. Шул арада Ш а һ и я з д а н юеш бит берлә кулына сөлге тотып, битен сөртә-сөртә килеп керә.

К и я ү  м у л л а. Кая? *(Шаһияздан авыз эченнән «Иннә әнзәлнаһ» сүрәсене укып, кулы берлә өстәл өстенә төртеп күрсәтә.)*

М у л л а *(килеп алып)*. Машалла! Машалла!

Бисмилла әйтеп, салават укып, укырга тотына. Шаһияздан сөлгесен ташлап килә.

М у л л а. Башы кая? Башы. *(Кулы калтырый.)*

Ш а һ и я з д а н. Менә «Ля иляһе» дигән.

М у л л а. Әйе. «Ля иляһе» дигәне! Эммм... *(Күрсәтеп.)* Менә монысы нәрсә, каенагай?

Ш а һ и я з д а н *(якынрак килеп, күзләрен кысып)*. «Ля иляһе». Белмим, кияү, тагы... Ә, ә менә тагы бер сүз таптым, «әннас» дигән.

Йомырканы әйләндереп карый. Шул арада дөбердәп С и т д ы й к  х ә з р ә т килеп керә.

С и т д ы й к  х ә з р ә т *(сәлам бирмәенчә)*. Кая ул әтәч йомыркасы, китер сасыкны!

Ш а һ и я з д а н. Хуш, хәзрәт!

С и т д ы й к  х ә з р ә т *(кызуланып)*. Җә, сафсата! Кая йомыркаң? Җә, җә!

К и я ү  м у л л а. Менә, тәкъсир, монда.

Х ә з р ә т. Җә, китер, сасык. *(Кияү китерә.)*

---

*Әннас* — кешеләр.

Х ә з р ә т *(күзлеген китереп)*. Җә, кая язуы? *(Карарга тотына.)*

К и я ү. Менә, хәзрәт, монда «Ля иляһе» дигән сүзе бар.

Х ә з р ә т. Кая? *(Кияү төртеп күрсәтә.)*

Х ә з р ә т. Юк, сасык, юк, димен.

К и я ү. Менә, хәзрәт.

Х ә з р ә т. И, утын авыз, юк, сасык. Әй, сафсатаны! Юк! *(Көлеп, кулын болгап-болгап)*. Ялган, бар да ялган.

К и я ү. Хәзрәт, менә, менә! Караңыз әле.

Х ә з р ә т *(рәтләп карамаенча)*. Юк ла, сасык, һи, син дә кабилиятле генә ласак, мохальгә ышанасың.

Шул арада Х ә м и т х ә з р ә т, Г а й н и к а р ы й килеп керә, икесе дә сәлам бирәләр. Шаһияздан каршы ала.

Г а й н и к а р ы й. Кая ул гаҗәбе галәм?

К и я ү м у л л а. Менә монда, монда!

С и т д ы й к х ә з р ә т. Юк! Юк! Ахмакны! Юкны сөйли. *(Кулын болгап.)* Җук.

Хәмит хәзрәт, Гайни карый кияү мулла янына баралар.

С и т д ы й к х ә з р ә т. Юкмы, дамелля Хәмит?

Д а м е л л я Х ә м и т *(күзлеген киеп карап)*. Тәкъсир, бар!

С и т д ы й к х ә з р ә т. Юк, дим, сасык, син дә сафсата сөйлисең.

Г а й н и к а р ы й. Бар, хәзрәт.

К и я ү м у л л а *(Хәмит хәзрәткә)*. Менә, хәзрәт, монда «Ля иляһе» дигән. *(Йомырканы әйләндереп-әйләндереп.)* Менә монда «әннас» дигән. Менә башкаларыны танып булмый.

Шул арада хатын-кызлар ягыннан ишек ярыгыны ачып тыңлап торалар. Шул арада җуан гына корсаклы С а б и т к о д а килеп керә. Аның артыннан ук Х ә й р у л л а м у л л а керә. Хәйрулла мулла Кышкар шәкерте. Сүзне борын аша сөйли. Шаһияздан каршы ала. Бер сүз дә дәшмәенчә өстәл янына киләләр. Һәммәсе дә бик кызуланышалар. Хәйрулла мулла бәреп-сугып йомырканы Гайнулла карыйның кулыннан ала.

Г а й н у л л а к а р ы й. Туктаңыз, хәзрәт. Мин укый идем.

Х ә й р у л л а м у л л а. Мин дә укыйм. Мин монда мәхәллә имамы, минем сездән элегрәк хакым бар.

Ш а һ и я з д а н. Хәзрәт...

---

*Кабилият* — аңлый алу сәләте.
*Мохаль* — кеше ышанмаслык хәл.
*Гаҗәбе галәм* — гаҗәп әйбер, галәмәт; дөнья гаҗәбе.

Ситдыйк мулла. Җә, җә, ахмак, ни, әй сасык?

Хәмит хәзрәт. Монда без синең мәхәлләңә керешмибез, менә харикыльгадә йомырканы гына укыймыз.

Хәйрулла мулла. Мин үзем укый алмыйммыни? Мин, әлхәмдүлиллаһ, Кышкар дамеллядә хәтме көтеб кылган кеше.

Ситдыйк хәзрәт *(көлә)*. Кара, сасык, шактый тугры сөйли.

Сабит кода. Хәзрәтләр, бу, ахрысы, бөтен әһле ислам эше. Монда моназарә булмаска тиеш дип беләм.

Хәмит хәзрәт. Әлбәттә, ахыры, аны укымаенча ярамый, бәлки бу бер ишарәттер, казаи иляһедер.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, укы, укы. *(Йомырка янына килеп.)* Җә, укы?

Шул арада Сәгыйть хәзрәт килеп керә. Карт хәзрәт сәлам бирә.

Ситдыйк хәзрәт. Менә, дамелля Сәгыйть, тавык пәйгамбәр булган. Язулы йомырка салган.

Сәгыйть хәзрәт. Әйе. *(Шаһияздангa.)* Садака бирмисез, әһле голяманы тәрбия кылмыйсыз. Зәкят чыгармыйсыз. Сезне әле җир убар, без ничек әһле гаялны тәрбия кылырга кирәк?

Ситдыйк хәзрәт. Дөрест, дөрест! *(Шаһияздангa.)* Җә, сасык!

Хәйрулла мулла. Әле сез миңа күпме садакалары була дип сораңыз. Мәхәллә байлары, менә күреңез, *(Чапанын күрсәтеп.)* имамнарын нинди чапаннан йөртәләр.

Сабит кода. Хәзрәтләр, монда аны сөйләргә мәслихәт булмас кебек күренә, шуны укысаңыз ла!

Хәмит хәзрәт. Әйе, әйе, укырга кирәк.

Тагы бөтен мулла йомырканы чорнап укырга тотыналар. Шул арада Хәким ишан килеп керә. Башын иеп кенә, вәкарь берлә генә килә.

Ситдыйк мулла. Менә ишан килде, ишан. Җә, ишан, син ишан кеше, белә торгансың.

Хәким ишан. Мәшаихлар мәдәд бирсә, укырмыз.

---

*Харикыльгадә* — гадәттән тыш.
*Әлхәмдүлиллаһ* — Аллага дан булсын, Аллага шөкер.
*Хәтме көтеб кылу* — укып бетерү, укуны тәмамлау.
*Әһле ислам* — ислам динен тотучылар.
*Казаи иляһе* — Алланың хөкеме.
*Әһле голяма* — руханилар.
*Әһле гаял* — гаилә әгъзалары.
*Мәшәихләр* — руханилар, суфи шәехләре.
*Мәдәд* — ярдәм.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Мәшәихләр дигән була, әй сасык. Нинди мәшаихлар сиңа мәшаихлар? Мәшаихлар камчы берлә кыйнаганмыни, ахмак, сасык! Мәшаих дигән буласың, утын авыз.

К и я ү  м у л л а. Мәхәллә бозып бетерде, тәкъсир, авыруларны камчы берлә кыйный.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Сасык, утын авыз, изаи мөэмин кыла, изаи мөэмин — хәрәм!

Х ә к и м  и ш а н. Мин мәэзүн кеше.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Мәэзүн! Халык алдарга, мәхәллә бозарга!

Х ә й р у л л а  м у л л а. Безнең Кышкар дамелля котыбы заман иде. Ишаннарга ышанмый иде.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Әй сасык, агач авыз, котыбы заман иде, котыбы заман иде. Синең дамелляң сафсата иде.

Шул арада тагы и к е  җ у а н  к о р с а к л ы кеше килеп керәләр. Кияү мулла һаман йомырка янында маташа. Теге кешеләр берлә Сабит, Шаһияздан әллә нәрсә сөйләшәләр. Шуннан.

Б е р  җ у а н  б а й. Хәзрәтләр, сез ул эшеңезне калдырып торыңыз әле. Моны бит укымый ярамый, бу бит бик зур эш, без моның кадерен белергә кирәк, Аллаһе Тәгалә безгә шулкадәр зур ингам иткән, шуның өчен хәмед әйтергә кирәк.

К и я ү  м у л л а. Менә бит мин өч сүз укыдым, дамелляләр укышмыйлар.

С а б и т  к о д а. Хәзрәтләр, мин Шакирҗан мулланы чакыртыйк дим. Ул яшь кеше, зиһене үткен кеше.

Ш а һ и я з д а н. Әйе.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җукны сөйләмә, сасык. Ул шигый, шигый ул! Ул Шиһап мулла шәкерте.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ул чәһаръяр гыйзамны инкяр кыла.

Х ә м и т  м у л л а. Ул, әллә нинди бидгатьләр чыгарып, китаплар яза.

Г а й н и  к а р ы й. Менә бу могҗизаны Аллаһе Тәгалә шул шундый кешеләрнең гөнаһысы өчен безнең башка төшерде. Урыс булып беттеләр, кара такталар керттеләр.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Кәрамәт диң, сафсата. Могҗиза булыр өчен масдарәган нәби булырга кирәк, монда табык пәйгамбәрмени?

---

*Изаи мөэмин кыла* — мөселманны газаплый.
*Мәэзүн* — рөхсәтле, ирекле.
*Ингам итү* — нигъмәтләндерү.
*Хәмед әйтү* — рәхмәт әйтү, мактау.
*Бидгать* — бу урында: начар эш.
*Масдарәган нәби* — пәйгамбәрдән чыккан.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим! Нәби булуы шарт булмас!

К и я ү  м у л л а *(йомырканы куеп)*. Әлбәттә, шарт булырга кирәк шул, чөнки ул вакытта могҗиза берлә кәрамәт арасында фәрекъ калмый.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим, калыр.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Ул вакытта әүлилулла пәйгамбәр булырга кирәк!

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим! Булмас! Ля нөсәллим!

С и т д ы й к  х ә з р ә т *(Хәйрулла муллага)*. Җә, сасык, жукны сөйләмә, утын авыз.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Тәгърифмин хәйсиһи — тәгъриф әгъярен манигъ булырга әфраден җамигъ булырга кирәк.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим! Булмас. Булмас. Тәгърифәттә әтраф ингыйкяс булмас.

Ж у а н  б а й. Хәзрәтләр, болай ярамый. Сез моназарәңезне куеңыз әле.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Сез — әһле мәхәллә, гыйлем эшенә катышмаңыз.

Х ә й р у л л а  х ә з р ә т. Сез имамыңызны ничек тәрбия кыласыз?

С а б и т  к о д а. Болай ярамый, хәзрәтләр, ни булса да укырга кирәк.

Шул арада тагы бер-ике кеше килеп керә. Килгәне бер йомырка янына барып йомырканы әйләндереп-әйләндереп карый.

Ш а һ и я з д а н. Башка эшеңезне калдырып торырга кирәк. Әйе, хуш, хәзрәтләр, укырга кирәк, хатын-кыз да көтә!

Х ә м и т  х ә з р ә т. Мин тагы танылым. «Мөхәммәд» дигән сүз бар.

Сәгыйть хәзрәт кулына алып карый, кияү мулла күрсәтә.

С ә г ы й т  х ә з р ә т. Ә, алай икән. Монысы «Ля иляһе», монда «Мөхәммәд», алай булгач бу «Ля иляһе илля Аллаһе Мөхәммәд рәсүлуллаһ» булырга кирәктер.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җә, җә.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим! Булмас.

Б е р  б а й. Хәзрәт, син туктап тор әле. Без барыбыз да эш кешесе, ахрысы.

---

*Ля нөсәллим* — алай түгел, бәхәсләшәм, риза түгел.

*Фәрекъ* — аерма.

*Мин хәйсиһи, әгъярен манигъ, әфраден җамигъ* — бөртекләрен үзенә генә җыючы, башкасына каршы килүче *(берәр төшенчәнең төгәл булуы турында әйтелә)*.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Әйе, әйе, «Ля иляһе илля Алляһе Мөхәммәд рәсүлүллаһ».

Ш а һ и я з д а н. Йа Рабби, хәерлегә булсын!

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Тагы танып булмый.

Ш а һ и я з д а н. Хәзрәтләр, безнең зурайта торган пыяламыз бар иде, әллә шуның берлә укыйсызмы?

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Ахмак, тәүбә кыл! Зурайту, кечерәйтү Алладан!

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Галәм — галәме әсбаб, дамелля, мин Бохарада вакытта, әмире Бохараның өч чакрымнан күрсәтә торган аләте бар диләр иде.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Жук, сафсатаны, жук.

Б а й л а р н ы ң  б е р с е *(Шаһияздангa)*. Син бар әле, ул пыяланы китер әле.

Ш а һ и я з д а н. Әллә безнең кантуршикны чакырыйкмы?

Х ә й р у л л а  м у л л а. Сез безнең әһле гыйлемне мыскыл итәсез, ул кантуршик ни белсен?

Б е р  к е ш е. Сез Шакирҗан хәзрәтне дә чакыртмадыңыз, үзеңез дә укымыйсыз.

Шул арада тагы б е р н и ч ә  к е ш е төртешеп-төртешеп килеп керәләр.

Я ң а л а р д а н  б е р с е *(карап)*. Ни язылган, ни язылган?

Ш а һ и я з д а н. Әле укыган кеше юк!

К е ш е. Ник укымыйлар, менә ишан хәзрәт укысын.

И ш а н. Монда дамеллялар укыр!

К е ш е. Ишан хәзрәтне кәефсезләндергәннәр, шуның өчен аның бәддогасында укый алмый торганнардыр. *(Шул арада Шаһияздан пыяла алып килә.)*

К и я ү  м у л л а *(пыяланы алып укып карый)*. Карагыз әле, дамеллялар, нинди эре күрсәтә.

Х ә м и т  м у л л а *(укып карый)*. Аннан соңын танып хәл юк.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т *(карап)*. Мин ап-ачык күрәм.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Шайтан зурайта, сафсаталар, шайтан!

Б е р  б а й. Шайтан булса булыр, кайвакыт шайтанның да файдасын күрик әле, укыңыз әле, хәзрәт.

С ә г ы й т  м у л л а. Юк, укый алмыйм.

Шул арада Шаһияздан к о н т у р ш и г ы менә.

Б е р  б а й. Җегет, син укый алмыйсыңмы?

Ә х м ә т. Хәзрәтләр укысын, без яшь кеше!

---

*Галәм — галәме әсбаб* — дөнья — әсбаплар (җайланмалар) дөньясы.-
*Аләт* — корал.
*Әһле гыйлем* — гыйлем ияләре.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, сасык! Укы, укы! Фатыйха алырсың!

Муллалар *(беравыздан)*. Укы! Укы! Синең күз үткен.

Әхмәт *(йомырка янына килеп, кулына теге пыяланы тотып укырга маташа, һәммәсе тик торалар. Әхмәт күзен алып.)* Менә боларны укыдым, «Ля иляһе...» дигән.

Кияү мулла. Анысын без дә укыдык.

Ситдыйк хәзрәт. Син, сасык, тегесен укы! Тегесен!

Әхмәт *(тагы укырга тотына. Бераздан)*. «Әйүһәннас түбү илля Аллаһе».

Хәмит хәзрәт. Тагы, тагы!

Ситдыйк хәзрәт. Җә, сафсата, укы! Укы!

Әхмәт. Моннан соң танып булмый.

Кияү мулла. Монда, дамеллялар, «түбү»нең замиры кая кайтты инде?

Ситдыйк хәзрәт. Утын авыз, замиры бармыни?

Хәйрулла мулла. Ля нөсәллим! Булыр. Ник булмасын!

Хәмит хәзрәт. «Түбү»нең ма тәхтендә замир бар.

Сәгыйть хәзрәт. Ма тәхтендә дә, ма фаукында да замир юк!

Хәйрулла хәзрәт. Ник юк, ля нөсәллим! Булыр! *(Кычкыра.)* Булыр!

Ситдыйк хәзрәт. Кычкырма, сасык! Сафсата сөйлисең.

Хәйрулла мулла. Мин ля нөсәллим дим, ник сафсата булсын. Сафсата булса, исбат кыл! Исбат кыл!

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, ташла! Ташла!

Гавамнан берәү. Хәзрәтләр, сез элгәре яшь егеткә укырга ирек бирегез әле, аннары кычкырышырсыз.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, син ни сөйлисең, агач авыз, син ни беләсең?

Хәйрулла мулла. Гыйлем эшенә син катышма!

Сәгыйть хәзрәт. Ахрысы бит аның тәркибене белмәенчә ярамый, аның мәгънәсен тугры аңларга кирәк.

Кияү мулла. Бу, дамеллялар, «түбү» әмер була, әмре вөҗүб өчен китаплар тәүбәнең олугсы — сәҗдә, ди. Бәс, безгә дә сәҗдә кылу лазем була.

---

*Замир* — зат алмашлыгы.

*Ма тәхтендә* — астында.

*Ма фаукында* — өстендә.

*Тәркиб* — төзелеш.

*Бәс* — димәк.

*«Түбү» әмер була, әмре вөҗүб өчен...*— «тәүбә итегез» — боерык фигыль була, боерык фигыль булсын өчен...

Хәйрулла хәзрәт. Әлбәттә, шулай, без дә сәҗдә кылырга кирәк.

Сәгыйть хәзрәт. Нинди сәҗдә? Сәҗдә ике төрле була: сәҗдәи тилавәт, сәҗдәи сәһү.

Хәйрулла мулла. Ля нөсәллим! Икегә мөнхәсыйр булмас!

Хәмит хәзрәт. Бохараи шәрифтә мәкабире әүлияга сәҗдә кылу бар.

Ситдыйк хәзрәт. Жукны сөйлисең, үземнең алдымда Казый кәлян хәзрәте Хуҗаны зиярәт кылды. Сәҗдә кылмады.

Шул арада тагы бер мулла берлә кешеләр керә. Мулла — яшьрәк, аңлырак Фәйзулла мулла.

Сәгыйть хәзрәт. Сәҗдә 14 урында гына ваҗиб.

Хәйрулла мулла. Булмас!

Сәгыйть хәзрәт. Син, мулла Хәйрулла, юкны сөйлисең.

Яңы кергән мулла Әхмәт янына килеп укырга маташа.

Гавамнан берәү. Йә, хәзрәт, укы әле. Менә болар йөдәттеләр инде, һаман кычкырашалар.

Әхмәт берлә Фәйзулла мулла укырга тотыналар, аларны кешеләр чорнап ала, шул арада мөәззин килеп керә.

Мөәззин *(Шаһиязданга)*. Ник мине чакыртмадың? Мин, әлхәмдүлиллаһ, биш вакыт азанга өндим, әлхәмдүлиллаһ, мөәззин булсам да, минем дәрәҗәм — имам, хатиб, мөдәррис.

Хәйрулла мулла. Җә, мөәззин, шаулашма.

Мөәззин. Сез сыйган йиргә мин сыймыймыни? Мин, әлхәмдүлиллаһ, хәтме көтеб кылган кеше.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, сафсата, сөйлә!

Бер бай. Мөәззин, оршышыңны бүтән вакытка калдырып тор әле.

Мөәззин. Мин бит, Ситдыйк абзый, оршышмыйм, безнең дә хәтер кала шул, мөәззин диләр дә кешегә санамыйлар. Менә сезгә, рәхмәт, садакаңыздан калдырмыйсыз, зәкятеңездән калдырмыйсыз.

Хәмит хәзрәт. Менә монда, дамеллялар, «Йә әйүһәннас» та эш бар инде.

---

*Икегә мөнхәсыйр булмас* — ике белән генә чикләнмәс.
*Мәкабире әүлия* — әүлиялар каберлеге.
*Казый кәлян* — баш казый.
*Ваҗиб* — тиешле.
*Мөнди* — чакыручы.

Кияү мулла. Йә, әйүһәннас — мөнди була!

Хәмит хәзрәт. Әйе, мөнди була! Ләкин менә монда хитабы җәмигүәннаскамы? Әллә бәгъзе әннаскамы?

Сәгыйть хәзрәт. «Йә әйүһәннас»ның әлиф лямы әлиф истигъраф ыймы, түгелме? Менә шуны карарга кирәк.

Кияү мулла. Монда дүрт төрле ихтимал бар инде.

Хәйрулла мулла. Әйе, дүрт төрле.

Мөәззин *(кызу-кызу)*. Әлиф лямы, тәгъриф, әлиф истигърафый, гаһед харижи, гаһед зиһни.

Әхмәт берлә Фәйзулла мулла кешеләр берлә сөйләшә башлыйлар.

Бер кеше. Кыямәт була диң!

Тагы берсе. Кыямәт! *(Хатыннар ягында ишек ачыла төшә.)*

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, ни?

Фәйзулла хәзрәт *(укый)*. Ля илаһе илля Аллаһе Мөхәммәд рәсүлуллаһ йә әйүһәннас түбү илля Аллаһе вә әгъләмү иннә әссәгате ляэтият кариб.

Муллалар *(бердән)*. Кыямәт! Кыямәт!

Бөтен кеше. Кыямәт! Кыямәт!

Хатын-кыз ягыннан елау ишетелә. Ишек зуррак ачыла. Хатын-кыз тарафыннан — «Йа Раббем! Гөнаһымыз күптер шул, кыямәт, ди» дигән тавыш берлә еглаган тавыш ишетелә. Муллалар, кешеләр бар да бергә җыелалар. Алар аптырап калып: «Кыямәт! Кыямәт!» — дип кенә куялар. Зөләйха карчык, тагы бер карчык кулына табагач тоткан, битләренә шәл ябып, акыртын гына ирләр ягына чыгалар. Ирләр арасында берничә кеше егларга тотына. Хатыннар тавышы куәтләнә бара. Ишектән тагы берничә начар гына киенгән кеше килеп керә. Керүчеләрнең берсе, еглаган тавышны ишетеп: «Ни булды? Ни булды?» — дип сорый.

Бер хәзрәт. Кыямәт булды. Кыямәт! Ахырзаман!

Теге кеше. Ахырзаман! Ахырзаман!

Зөләйха карчык. Ахырзаман шул! Гөнаһымыз күп булды, ахырзаман. *(Муллалар бар да әйләнеп карыйлар.)*

Зөләйха. Хатын-кызымыз азды: киенде-ясанды, анда чапты, монда чапты. Муллаларымыз тыймады.

Ситдыйк хәзрәт. Сафсатаны сөйли, ахмак! Ирләр берлә сөйләргә сиңа дөрест түгел. Чык, ахмак!

Зөләйха. Мин карчык инде, бүтәннәрне тыеңыз!

Хәйрулла мулла. Әһле голяманы эшкә алмады-

---

*Хитабы җәмигүәннаскамы, әллә әннаскамы* — мөрәҗәгать бөтен кешегәме, әллә аерым кешеләргә генәме?

*Әлиф лямы, тәгъриф, әлиф истигърафый, гаһед харижи, гаһед зиһни* — грамматик терминнар.

лар. Байларымыз садакаларын туктаттылар. Гыйлемнең кадере бетте.

Сәгыйть хәзрәт. Мәдрәсәләремездә гыйлем нуры күтәрелде, әһле taлəбə гыйлем урынына гәзит-мәҗит укый башладылар.

Мөәззин. Мөәззиннәрнең кадере бетте, фидия садакасын әллә нинди соры кортларга бирә башладылар.

Кияү мулла. Мәхәллә халкы голяманы гаепли башлады, голяманың вәгазен, нәсыйхәтен тыңламады.

Хәмит хәзрәт. Әһле гыйлемнең, мәдрәсәләрнең, дамелляларның мәгыйшәте тарайды. Әгъния арасында әрбабе сәхавәт бетте. Дөнья әллә нинди бидгатьләр берлә тулды. Типография дигән чыкты. Китапның кадере бетте. Фотограф дигән чыкты. Һәркем өендә, фәрештә качырып, рәсем тота башлады. Теш авыруыннан сабыр итмәенчә, пакьлеге шөбһәле нәрсәләр берлә тешләрен ямата башладылар. Тәһарәт, госелнең шәраитын ригая бетте.

Ишан. Әрбабе тарикатькә ригая бетте, аларның кәраматләрене, әлгаязе билляһ, инкяр кыла башладылар. Олуг әүлияларның мәәзүннәренә игътибар кылмый башладылар. *(Хатыннар һаман еглый.)*

Ситдыйк хәзрәт. Шигалар чыкты, голяма арасында бидгать күбәйде, әллә нинди китаплар яза башладылар. Сәләфләр юлын ташлап, әллә нинди җәдит-мәҗит-кәҗит юлы берлә укыта башладылар. Гавам Шакирҗан муллаларга иярә башлады. Ислам киеменә, ислам гадәтенә ригая бетте.

Бер кеше *(Әхмәткә күрсәтеп)*. Менә шулар инде ахырзаман галәмәтләре: киемен карасаң — киеме кяферчә, кылынышын карасаң — кылынышы.

Ситдыйк хәзрәт *(Әхмәткә)*. Сасык! Ни дип син мыегыңны алдырмыйсың? Ахмак!

Сәгыйть мулла *(килеп)*. Ни дип син мондый тар урыс казакие киясең?

Ситдыйк хәзрәт. Сафсата, тәүбә кыл! Бу киемнәреңне ташла, агач авыз! Әһле ислам зөмрәсенә керергә тырыш! Менә бит сезнең хакта ахырзаман була!

Әхмәт әллә нәрсә әйтергә тели, аңарга ирек бирмиләр.

---

*Әһле taлəбə* — шәкертләр.
*Мәгыйшәт* — тормыш-көнкүреш.
*Әгъния* — байлар.
*Әрбабе сәхавәт* — юмартлык иялəре.
*Фотограф* — фотография.
*Әрбабе тарикать* — бу урында: ишаннар, суфилар.
*Әлгаязе билляһ* — Алла сакласын.
*Мәәзүн* — бу урында: хокуклар.
*Зөмрә* — төркем, җәмәгать.

С ә г ы й т ь м у л л а *(Шаһиязданга).* Шундый ахмак дәһриләргә жалуния биреп, аларга ярдәм итәсез. Әһле голямага садака бирмисез.

Ш а һ и я з д а н. Әйе, хәзрәт, әйе, хәзрәт! Типография эшен белә шул, хуш, хуш.

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җукны сөйләмә! Сафсата! Мөселманга эш беткәнме? Әһле ислам кулында кәсеп эше бәрәкәтле булыр дигән.

С а б и т к о д а. Җук шул, хәзрәтләр, кантура эшләрендә русча укыган кеше кирәк шул. Рус берлә эш итәмез.

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җукны сөйләмә, сасык! Китап бер мөселманны ун кяфер дәрәҗәсендә күрә.

С ә г ы й т ь х ә з р ә т. Шулай дип шул менә безнең байларымыз бозып бетерделәр.

И ш а н. Үзләре элгәре угылларын русча укыттылар, кызларын урамга чыгарып йөртә башладылар. Хәя бетте, хәя беткәч, иман бетте.

Б е р ә ү. Хәзрәтләр! Голямада да гаеп юк түгел, менә нинди мәдрәсәләр таркалды! Нинди зур мәдрәсәләр мөдәриссез калды. Мөдәррисләр дәрескә керми башладылар.

Х ә й р у л л а м у л л а. Мәдрәсәгә утын биреңез, керосин биреңез, мөдәррисеңезне әһле гаялын тәрбия кылырлык караңыз! Без гаеплемени?

Б е р ә ү. Хәзрәтләр, Шакирҗан мулла ник алай сорамый соң?

С и т д ы й к х ә з р ә т. Ул шига, сасык, шига. Аны шайтаннар күтәрә, аның эшен шайтаннар җиңеләйтә!

Б е р ә ү. Утынны шайтан китерми торгандыр, ахрысы?

С и т д ы й к х ә з р ә т. Китерә, сасык! Китерә. *(Шул арада бер мөәззин килеп керә.)*

М ө ә з з и н. Хәзрәтләр! Анда Печән базарында әһле ислам көтеп тора. Ни булды икән, ди.

С ә г ы й т ь м у л л а. Кыямәт булды, кыямәт. Мөәззин, кыямәт, диң! Кыямәт.

М ө ә з з и н. Соң, хәзрәтләр, гавамга ни диик!

З ө л ә й х а к а р ч ы к. Без ничек, хәзрәтләр, тәүбә кылыйк? Мин җиде рәкәгатьле тәүбә намазы укый торган идем. Әүвәлге ике рәкәгатендә уникешәр «Колһуалла», калганнарында җидешәр «Әлһәкүмүт — тәкәсүри». Шул ярыймы?

Б е р м у л л а. Ярый, ярый!

---

*Хәя* — оят.

Б е р ә ү *(еглаган тавыш илән).* Соң, хәзрәтләр, без нишлик инде?

Б е р  х ә з р ә т. Садака биреңез! Садака! Китап әйткән, садака бәлаларне кире кайтарыр, гомерне арттырыр дигән! Әһле голямага садака биреңез.

М ө ә з з и н. Мөәззиннәрне өлештән калдырмаңыз.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Дамеллялар, безгә, ахрысы, әһле гавамнан башка бу әмере мөһим хакында утырышырга кирәк. Моның хакында мөзакәрә кылышырга кирәк.

Г а в а м н а н  б е р ә ү. Без соң нишлик, хәзрәтләр, бүген үк булмас микән?

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җук, сасык, җук. Кыямәт җомга көн булыр дигән!

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Җук, хәзрәт, бер риваятьтә чәршәнбе дигән.

К и я ү  м у л л а. Минемчә, дүшәнбе булырга тиеш, чөнки пәйгамбәремез дүшәнбе тугды һәм дүшәнбе вафат булды.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим! Вафат булмаган булыр.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Дүшәнбе, сасык, дүшәнбе!

Х ә й р у л л а  м у л л а. Исбат кыл!

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Бөтен голямаи ислам монда мөттәфикъ.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим! Булмас! Имам Газали мохалиф.

Ф ә й з у л л а  м у л л а. Тарихи мәсьәлә хакында алай моназарә кылышып булмый. Бүгенге чәршәнбе көнне чәршәнбе түгел дип инкяр кылып булмый.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ник булмасын, булыр, ля нөсәллим! Булыр, аның чәршәнбелеге игътибари гына булыр. Нәфселәмердә ул чәршәнбе булмас.

Б е р ә ү. Хәзрәтләр, безнең сүзгә җавап бирсәңез лә! Кайчанга була инде кыямәт? Кайчанга инде?

Б е р - и к е  т а в ы ш *(берьюлы).* Ни вакыт була?

И ш а н  х ә з р ә т. Кыямәт кояш чыкканда булыр дигәннәр.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Алдама! Ахмак! Ашау-эчү вакытында булыр дигәннәр.

---

*Әһле гавам* — бу урында: кара халык.
*Әмере мөһим* — мөһим әмер.
*Мөзакәрә кылышу* — фикер алышу.
*Мөттәфикъ* — бер фикердә.
*Мохалиф* — каршы.
*Игътибари* — ышану буенча гына.
*Нәфселәмердә* — чынлыкта, нигездә.

Кияү мулла. Минемчә, әһле исламның намазы вакытында булырга тиеш. Һәм дә намазның олугсы вакытында булырга тиеш.

Ситдыйк хәзрәт. Намазның олугсы бармыни?

Кияү мулла. Әлбәттә, бар! Мәсәлән: өйлә намазы олуг намаз булырга тиеш. Чөнки җомга көнне өйлә вакытында җомга намазы укыла, вә шул вакытта күк капусы ачыла!

Хәмит хәзрәт. Минемчә, иртә намазы олуг намаз булырга кирәк, чөнки иртә намаз берлә әһле ислам иманын яңарта!

Сәгыйть хәзрәт. Ястү намазы олуг булырга кирәк, ястү намазы берлә кеше эшен тәмам итә һәм дә ястүдән соң витер укыла, ул да олуглыкка дәлил.

Хәйрулла мулла. Ахшам намазы олуг булыр, чөнки ул так. Алла такны сөяр дигән!

Мөәззин. Иртә намаз олуг булырга тиеш, чөнки иртә намазның азаны башкача.

Ситдыйк хәзрәт. Җук, сасыклар, җук. Бары да бер. Намазның бары да бер. Сафсата сөйлисез.

Бер кеше. Хәзрәтләр, соң кайвакыт булыр, ник безгә әйтмисез? Үзеңез генә сөйлисез.

Фәйзулла мулла. Аның кайвакыт буласы мәгълүм түгел.

Тагы бер кеше керә.

Кеше. Хәзрәтләр, ахун абзый сезне, монда килсеннәр, диде.

Муллалар *(торып)*. Ахунга, ахунга!

Ситдыйк хәзрәт. Аның чәе бардыр.

Сәгыйть хәзрәт. Мәгъҗүн булырмы?

Кияү хәзрәт. Бар, бар.

Ситдыйк хәзрәт. Җәңез, җә, алайса, барыйк.

Берәү. Хәзрәтләр, без нишлик соң?

Хәзрәтләр. Садака биреңез, садака! Әһле голямага садака биреңез!

Ишан. Мәшәихләрдән мәдәд сораңыз.

Мөәззин. Мөәззиннәрне хәтердән чыгармаңыз. *(Чыга башлыйлар.)*

Хәмит хәзрәт. Бу кәрамәтне нишлимез?

Кияү мулла. Бу Алланың әманәте инде!

Сәгыйть хәзрәт. Бу һәр авырудан шифа инде.

Сабит кода. Шаһияздан кода карасын инде.

---

*Мәшәихләр* — руханилар, суфи шәехләре.
*Мәдәд* — ярдәм.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Син кара, сасык. Олуг урынга тәгъзыйм берлә куй.

Чыгалар. Шаһияздан берлә берничә кеше калып йомырканы өстәл өстенә куялар да йомырканы үбеп чыга башлыйлар. Шул арада ишектән бик күп хатыннар килеп керәләр. Алардан елаган тавыш ишетелә.

Б е р  х а т ы н. И Раббем! Шулай үләрмез? Ничек җавап бирермез, ничек синең катыңа барырмыз? Ничек кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күпереннән кичәрмез? *(Тавыш куәтләнә.)*

Б е р  х а т ы н *(икенче хатынга)*. Абызтай! Ирен рәнҗеткәннәргә нинди газап булыр дигән?

А б ы з т а й. Ирен теле берлә рәнҗеткәннәргә җиде хокыб теленнән асып, тәмугта яндырырлар дигән. Гайбәт сатканнарның һәм шулай ук кулы берлә рәнҗеткәннәрнең кулы тимер кадак берлә тәмуг стенасына кадакланыр дигән. *(Еглау тавышы куәтләнә. Хатыннардан* «И Раббем, хур булдык!» *дигән тавыш ишетелә.)* Зина кылганнарны сасы су, канлы эрен эчерәләр дигән.

Б е р  х а т ы н. И Раббем, ничек эчәрмез, и Раббем?

Шул арада хатыннар бар да берсен-берсе үтеп, ерактан гына карыйлар.

З ө л ә й х а  к а р ч ы к. Әсма бәбкәм, колакларым тыгылып китте, тәһарәтем барда колагыма тиерим әле.

Ә с м а *(бер хатынга күрсәтеп)*. Менә абызтайдан сора.

А б ы з т а й. Менә ишетмәдеңезмени, бу һәрнәрсәдән шифа инде. *(Йомырканы савыты берлә күтәреп.)* Йә, Зөләйха абызтай, салаватыңны әйт. *(Үзе йомырканы тегенең колагына сыйпап.)* И Раббем, шифа бир, гөнаһларымызга кәффарәт кыл! *(Зөләйхадан соң.)*

Б е р  х а т ы н. Абызтай, менә минем тешем сызлый, өзә инде үзәгемне. Ятсам — йоклый алмыйм, торсам — тора алмыйм. Шуннан шифалы булыр микән?

Шул арада Зөләйха карчык кулындагы беләзеген салып абызтайга китерә.

З ө л ә й х а. Әбиемнән калган инде, талир тәнкә көмешеннән ясаттым, дия иде мәрхүм. Үзең кеби җиткән кызың булса, аңар кидер. Миңа намаз артыннан дога кылып кисен иде.

Абызтай кул күтәрә, хатыннар да кул күтәрә, кул сыйпап.

А б ы з т а й. Рәхмәт, Алла разый булсын. Аллаһе Тәгалә җиде оҗмахның ишеген ачык кылсын.

---

*Тәгъзыйм* — олылау.
*Хокыб* — гасыр.
*Кәффарәт кыл* — (мәхшәр көнендә) гафу кыл.

Т е ш е  с ы з л ы й  т о р г а н  х а т ы н. Абызтай! Миңа да сөртсәнә!

Абызтай авызыннан әллә ни укып сөртә. Теге хатын авызын сузып тора, аның артыннан берсе: «Күзем авырта иде»,— ди. Абызтай аңар күзенә сөртә. Ике хатын аллы-артлы садака бирәләр. Дога кылалар. Шул арада ишек ачыла, ике хатын бер хатынны күтәреп китерәләр. Һәммә хатыннар туктап тегеләргә карарга тотыналар... Хатыннар арасыннан «Бу кем? Бу кем?» дигән тавыш ишетелә.

Б е р с е. Болар бик бай булганнар. Фамилиясен генә белмим, Апаковмы шунда? Менә моңарга фалиҗ булган.

Теге хатынны абызтай янына китереп кәнәфигә яткыралар. Хатын кулы берлә ишарә кыла, дога кылалар.

Я н ы н д а г ы  б е р  х а т ы н. Менә, абызтай, шул хәбәрне ишеткәч, илтеңез дип йөдәтте, Аллаһе Тәгалә шифа бирмәсме? Шуны чайкатып эчерсәңез лә. *(Абызтай бисмилла әйтеп тегенең бөтен әгъзасыны сыйпарга тотына. Бик озак сыйпап бетергәч тә дога кылалар. Теге фалиҗ хатын янындагы хатынга ишарә кыла. Ул абызтайга бер йөзек бирә.)* Менә, абызтай, бик кадерле йөзеге, ире Мәкәрҗәдән бүләк итеп китергән икән. *(Теге фалиҗ хатын кулын селкетә, «Үзе генә кисен, сатмасын, рөхсәтем юк» ди. Абызтай рәхмәт әйтә.)*

А б ы з т а й. Әсма кая? Су китер әле. *(Әсма су һәм бер савыт китерә. Абызтай әллә ниләр укыгалап, йомырканы өч мәртәбә салават укып суга манып ала да теге хатынга эчерә, аның йөзләренә, кулларына сөртә. Аннан соң үзләренең йөзләренә сөртә.)* Йа Раббем, шәфагатьче кыл *(дип йота. Аның артыннан.)*

З ө л ә й х а  к а р ч ы к. Остабикә, минем дә күзләрем тонып тора, сөртсәнә. *(Сөртенә һәм дә эчә.)* Алланың рәхмәте, суының тәме үк башка.

Шул арада хатыннар, берсе артыннан берсе килеп, йөзләренә сөртеп, эчә башлыйлар. Теге фалиҗ хатынны алып чыгып китәләр, аның берлә бергә Әсма да чыга.

Б е р  х а т ы н *(кулына чынаяк тотып килеп)*. Абызтай, киленем балага авырган иде, шуңарга, зинһар, азрак бирсәнә!

Абызтай салып бирә, аның артыннан.

Б е р  х а т ы н. Минем угылым, абызтай, аяксыз булып авырый, миңа да бирсәнә!

А б ы з т а й. Савытыңыз юк бит!

Т е г е  х а т ы н. Әсмабикә, бер чынаяк кына бирсәнә!

---

*Фалиҗ* — паралич.

Б е р  х а т ы н. Нәрсә сорап торырга, барыбер — кыямәт. *(Шкафтан алып бирә.)*

Шул ара да булмый, бөтен хатын шкафка барып кайсы чынаяк асты, кайсы чынаяк өсте күтәреп, кайсы чәйнек, миски алып абызтайга киләләр. Шкафта бернәрсә дә калмый. Барысы да абызтайны кысып: «Абызтай, миңа сал, минем ирем сары авыруы берлә авырый». «Миңа — минем кызымның эчендә кату бар». «Миңа, миңа, минем энемнең бабасыр зәхмәте бар». «Миңа, миңа, минем иремнең эчү гадәте бар». «Миңа, миңа — минем ирем начар хатыннар артыннан йөри».

А б ы з т а й. Туктаңыз, барыңызга да җитәр.

Шул арада тагы мискигә яңы су салып тагы өч мәртәбә чайкый башлый. Хатыннар куллары берлә посудаларын күтәреп көтәләр.

Ә с м а *(килеп кереп)*. Ул нинди ул сорамаенча-нитмәенчә кешенең әйберсен алу, ул бит кеше хакы була!

Б е р  х а т ы н. Барыбер — кыямәт, әллә аны гүреңә алып китмәкче буламсың?!

Б е р с е. Исе киткән ун тиенлек чынаягына, түләрмен. Әлхәмдүлиллаһ, синең чынаягыңа калмаган әле.

Б е р с е. Бигрәк зурайгансың. Әле ireңнең безнекеләрдә унбиш тәңкәлек приказчик булып торганын оныттыңмы?

Ә с м а. И Алла, алыңыз, алыңыз! Оятыңыз булмаса, алыңыз.

Б е р  х а т ы н. Менә шундый көнне, оятың булса, син шундый сүз сөйләп тормас идең.

А б ы з т а й *(су өләшүен туктатып)*. Җитәреңез. Әле шул гөнаһ шомлыгымыз хакында ахырзаман җиткәнне оныттыңызмы? Әллә инде башымызга таш яудырмакчы буламсыз?

Хатыннардан «уф Алла» дигән тавыш ишетелә. Берничәсеннән «тәүбә, тәүбә» дигән сүз ишетелә.

Б е р с е. Үзең уйлап кара әле, абызтай, шундый олуг көнне шулкадәр дәүләт өстеннән чынаяк кызганып тора. Әллә теге дөньяга алып китәргә тели.

А б ы з т а й. Җитәреңез, бер-береңез берлә бәхилләшеңез. *(Абызтай су өләшә.)*

З ө л ә й х а  к а р ч ы к. Һәммәңез миннән бәхил булыңыз, сезнең гаебеңезне сөйләгән булсам, рәнҗеткән булсам, хакыгызны ашаган булсам, кыямәт көнне Алла хозурында мине оятлы ясамаңыз.

Х а т ы н н а р. Бәхил, бәхил.

Б е р  х а т ы н *(икенчесенә килеп, еглаган тавыш илән)*. Миннән бәхил бул. Көндәшем булган вакытта сине

бик рәнҗеттем, өстеңә яла яптым, ястыгыңа инәләр кадап җәфа чиктердем, иремнән кыйнаттым.

Теге хатын. Үзең бәхил бул. Мин дә сине боздырыр өчен ашыңа әллә нинди сихерләр салып ашаттым. *(Күрешәләр.)*

Бер хатын *(тагы берсенә)*. Миннән бәхил бул, сезнең теге үрмәле гөлеңез бик матур күренде дә, шуны урладым.

Берсе *(тагы берсенә)*. Миннән бәхил бул, синең кызыңның яманатын саттым.

Бер хатын. Миннән бәхил бул! Мин калфак эшләгәндә энҗеңне алып кала идем.

Бер картрак хатын. Миннән бәхил булыңыз, Фәхрениса, Гайнимҗамал *(Биш-алты хатынның исемен әйтә.)* Алдап-йолдап сезнең кызларыгызны начар урынга бирдем.

Бары да. Бәхил, бәхил.

Абызтай һаман су өләшә. Шул арада бер карт кеше килеп керә. Хатыннар бары бердән куркынып китәләр. Барысы да савытларын югары күтәреп ишеккә таба йөгерешәләр. Чынаяк, мискиләр ватыла, су түгелә. Берничә хатын егыла. Башкалары дөбердәшеп чыгып китәләр. Идәндә әллә никадәр ватылган чынаяклар, түгелгән су, калфаклар, яулыклар, шәлләр кала. Абызтайның садакага алган беләзеге, акчалары, йөзеге кала. Шул ара да булмый, ишектән букчалар, чемоданнар күтәреп бер кеше килеп керә. Ул исе китеп катып тора.

Кеше. Бу ни, бу ни?

Зөләйха карчык акыртын гына ишектән чыга, абызтай теге әйберләргә кул бутый. Зөләйха аңламый.

Зөләйха. Гөнаһымыз күп икән, этәч йомырка салды. Кыямәт булды.

Теге кеше *(йомырканы күтәреп)*. Кыямәт, кыямәт!

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шаһияздан бай өе. Шаһияздан ялгыз гына идән буенда йөри. Шул арада бер карт кеше килеп керә. Кеше сәлам бирә.

Шаһияздан. Әхмәди абзый! Дөнья булгач, төрле вакыт булгандыр, бергә ашадык, эчтек, яшьлек берлә каты-коты да иткәләгәнмез. Бәлки, хакың да калгандыр, кил, зинһар, мине Аллаһе Тәгалә хозурында оятлы итмә инде. Бәхил бул инде.

Ә х м ә д и. Булды инде булды, бик рәнҗеттең, Шаһияздан, карт көнемдә хезмәттән чыгарып җибәрдең. Җитмәсә, жалуниямне басып алып калдың.

Ш а һ и я з д а н. Үзем дә беләм инде, бәхил бул! *(Кесәсеннән бумажнигын чыгарып.)* Менә калган хакың өчен ал. *(Әхмәдигә бер уч көмеш акча бирә.)*

Ә х м ә д и. Рәхмәт, Шаһияздан, миннән тыныч бул, мин бәхил.

Ш а һ и я з д а н. Үзеңә рәхмәт, Әхмәди абзый.

Ә х м ә д и *(читкә)*. Ә, кыямәт куркыттымы? Үзең чакырып бирәмсең. *(Чыгып китә.)*

Ш а һ и я з д а н. Әсма, Әсма. *(Әсма килеп чыга.)* Син рәнҗеткән кешеләрең берлә бәхилләш. Асрауларның ризалыгын ал. Алла кашында йөзең кара булмасын. Менә мә, акча кирәк булса. *(Бер уч акча бирә.)* Аннары чәй урыны хәзерләңез, хәзрәтләр килә. Теге карчык килсә, хәзер миңа чыгар.

Шул арада тагы бүреген басып кына кигән б е р  к е ш е килеп керә.

К е ш е. Бай, синме мине чакырдың?

Ш а һ и я з д а н. Әйе, әйе, менә ахырзаман җитте, һәрберемезгә кыямәткә хәзерләнергә вакыт җитте. Шуның өчен синең берлә бәхилләшеп калыйм дидем, миннән бәхил бул.

К е ш е. Бәхил булыр идем дә, түләгән бурычны суд берлә ике кат түләттеңез, актык йортымны саттырдыңыз, анам мәрхүмне үз йортыннан куып чыгарттыңыз.

Ш а һ и я з д а н. Бездә гаеп инде, булган инде, бәхил бул! Кыямәт көнне кулың минем якамда булмасын!

К е ш е. Акчамны кайтарып бир, бәхил булырмын!

Ш а һ и я з д а н. Хәзер барыбер кыямәт була, аның берлә нишлисең?

К е ш е. Нишләсәм дә, эшләрмен.

Ш а һ и я з д а н. Бирәм, бирәм. *(Кесәсеннән чыгарып.)* Күпме иде, 700 ме?

К е ш е. 750 сум. *(Шаһияздан акча санап бирә.)*

Т е г е  к е ш е *(читкә)*. Ә, кыямәт шүрләттеме? Ул менә бар да сезнең кеше хакы ашавыңыз аркасында килгән. *(Чыгып китә.)*

Ш а һ и я з д а н. Ярый, моны да бәхилләттем.

Шул арада хатын-кыз ягыннан б е р  к а р ч ы к берлә Ә с м а чыга. Әсма чәй урыны хәзерләргә тотына. Карчык таякка таянган.

Ш а һ и я з д а н. Исәнме, Гайникамал абыстай?

К а р ч ы к. Нәрсә?

Ш а һ и я з д а н. Исәнме, дим.

К а р ч ы к. Уф Алла, буылдым. *(Колагына күрсәтеп.)* Колагым тыгылган, теге йомырканың суы берлә тәһарәт алсам, ачылыр иде кебек тора.

Ш а һ и я з д а н *(кычкырып)*. Инде барыбер кыямәт булды — тиз үләмез, бәхил бул!

К а р ч ы к. Нәрсә?

Ш а һ и я з д а н. Бәхил бул!

К а р ч ы к. Картымның хаҗга дигән акчасын алып калдыңыз шул. Ул Алла каршында кара йөзле булды.

Ш а һ и я з д а н. Менә хәзер бәдәлче чакырырга җибәрдем, шуңарга бирәм. *(Шул арада чалма чалган бер яшь кенә кеше килеп керә.)* Хуш, әфәнде, хуш! *(Бәдәлче сәлам биреп утыра.)* Менә, әфәндем, бу абызтайның иренең бәдәле бар иде. Алты йөз сум, шуны алырсыз микән? *(Карчык якынрак килә.)*

Б ә д ә л ч е. Ярый, бик яхшы булыр.

Ш а һ и я з д а н *(карчыкка)*. Менә, Гайникамал абызтай, шуңарга бирәмез.

К а р ч ы к. Ә, ярый! Миңа тәсбихләр алып кайт, аннары зәмзәм алып кайт, хөрмә алып кайт, аннары колакларым авырта, шуларга салырга дару алып кайт.

Б ә д ә л ч е. Ярый, ярый.

Ш а һ и я з д а н. Алай булса, мин сезгә шул әманәтне тапшырыйм инде, сез шул бәдәл хаҗны кабул итеп аласызмы инде?

Б ә д ә л ч е. Ярый, алам.

Ш а һ и я з д а н *(акчаны санап карчыкка биреп)*. Мә, менә шуны хәзер әфәндегә бир!

К а р ч ы к. Тәсбих берлә хөрмәне онытма! *(Үзе бирә. Өчесе дә дога кылалар. Бәдәлче торып чыга.)*

Шул арада б е р е г е т килеп керә.

Ш а һ и я з д а н. Ни бар?

Е г е т. Менә, абзый, Фәхри саткан сабынның акчасын кесәсенә салды.

Ш а һ и я з д а н. Ә, ярар, ярар, барыбер кыямәт була инде. Шул гынамы йомышың? Бар чык, миннән бәхил бул.

Е г е т *(исе китеп карап тора. Читкә.)* Каушаткан йомырка. *(Чыгып китә.)*

Менә шул арада дөбердәгән тавыш ишетелә. Берсе арты берсе м у л л а л а р килеп керәләр. С ә г ы й т ь  х ә з р ә т, С и т д ы й к  х ә з р ә т, Х ә м и т  х ә з р ә т, Х ә й р у л л а  м у л л а, К и я ү  м у л л а, Ф ә й з е р а х м а н  м у л л а, м ө э з з и н, тагы дүрт-биш м ә х ә л л ә  б а е — барысы да керәп чәй янына килеп утыралар да озын гына дога кылалар.

К и я ү  м у л л а. Соң, хәзрәтләр, шул хәзер инде иттифакы кыямәт җомга көн булуына булдымы?

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Әйе, шулай булды инде. Ахун да шуны куәтләде.

Ш а һ и я з д а н. Җомга диң, җомга. *(Башын селкә.)*

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Менә монда, дамеллялар, шөбһәле нәрсә шул инде: ник Җәнабе Алла кыямәтне йомырка аша белдертте? Китапларда ахырзаман галәмәтләре хакында, дамеллялар, шул хакта бер-бер ривайәт күргәнегез юкмы?

К и я ү  м у л л а. Ахырзаман галәмәтләре әле китап күрсәткәнчә булып җитмәгән. Мәсәлән, Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ чыкмаган, Дәҗҗал чыкмаган, Диббәтел арыз чыкмаган. Хәзрәте Гайсә, хәзрәте Мәһди зоһур итмәгән.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим, чыккан булыр.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Әйе, мәсәлән, ул да бар. Аннан соң, дамеллялар, ник Аллаһе газыйм йомырка аша белгертте?

Х ә м и т  х ә з р ә т. Анысы, дамелля Сәгыйть, Алланың әмереннән ник дип соралмый. Аның сәбәпләре үзенә генә мәгълүм. Мәсәлән, Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ хакында...

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ урыс ул, сасык! Сәмәркандны басты. Дагыстанны басты: Хивәне басты; мотлакан — урыс.

К и я ү  м у л л а. Әйе, ул вакытта, хәзрәтләр, бәни әл-әсфар кем була инде ул? Әле «Мөхәммәдия»дә «Бәни әл-әсфарлар салих ула. Янә гозер әйләйә анлар» дигән.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. «Бәни әл-әсфар»дан морад фәрәнк халкы, диләр. Шул агылчан инде, шул инде бик гаддар.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Шул инде, агылчан ул, ул бик дошман ул. Ул хәлифәгә дә дошман, ул Мисырны алды. Шул инде ул сасык!

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Бу, дамеллялар, Бохараи шәрифтә дамелля Хәлим бәни әл-әсфарга русны кертә иде. Шул рус бит бик истиля итте: Һиндстанны да алды, Төрекстанны да алды.

Ф ә й з е р а х м а н  м у л л а. Һиндстан руста түгел.

---

*Иттифакы кыямәт* — кыямәт хакында бер фикергә килү.
*Зоһур итү* — чыгу.
*Газыйм* — бөек.
*Салих* — изге.
*Гозер* — ялыну, ялвару.
*«Бәни әл-әсфар»дан морад фәрәнк халкы* — «бәни әл-әсфар» дигән сүз — европалылар дигән сүз.
*Гаддар* — хыянәтче.
*Бохараи шәриф* — изге Бохара.
*Истиля* — басып алу.

Сәгыйть хәзрәт. Ник булмасын! Дамелля Хәлим алдый торган кеше түгел иде. Аның сүзенә Казый кәлян да, мәрхүм әмир Мозаффар да ышана иде.

Ситдыйк хәзрәт. Ник руста булмасын? Шул бит синең Гаспарың язды, Бомбейдә әһле исламны руслар җәбер кыла дип. Сасык!

Фәйзерахман мулла. Юк, дамелля, рус түгел.

Ситдыйк хәзрәт. Сасык, соң кем әһле исламны җәберли, мөселманны?

Фәйзерахман мулла. Англичаннар, дамелля.

Кияү мулла. Англичан рус булмаенча, мөселманмыни?

Ситдыйк хәзрәт. Утын авыз, юкны сөйлисең. Сафсата!

Фәйзерахман мулла. Алар мөселман булмаса да, рус түгел.

Хәмит хәзрәт берлә Сәгыйть хәзрәт. Соң, мөселман булмагач, урыс булмыймыни?

Фәйзерахман. Алар телләре, гадәтләре берлә руска бөтенләй башка.

Ситдыйк хәзрәт. Әй, сасык, юкны сөйләмә! Бары да бер, бары да бер. Русы да шул тәмуг кисәве, агылчаны да тәмуг кисәве. Бары да бер тәмугга яначак. *(Бөтен муллалар көләләр.)*

Кияү мулла. Соң инде ул рус Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ булса, агличан бәни әл-әсфар булса, бу Дәҗҗал кем була соң инде?

Сәгыйть хәзрәт. Дәҗҗал әүсафы хакында голяма мөттәфикъ, аның маңлаенда бер күзе булыр, дигәннәр; күз күргән йирне бер адымда атлар, дигәннәр.

Хәмит хәзрәт. Юк, дамелля Сәгыйть, Бохарада үзем мәрхүм Лотфулла мәхдүмнән ишеттем. Дәҗҗалның колагы ишәк колагы кебек булыр, дигән.

Ситдыйк хәзрәт. Түгел, сасык, ул Дәббәтел арызныкы: бер кулында таяк булыр дигән, бер кулында йөзек.

Мөәззин. Йөзек берлә мөселманнарның маңлаена пичәт басар, таяк берлә кяферләргә сугар, дигән!

Ситдыйк хәзрәт. Алдама, сасык! Агач авыз, сафсата! Йөзек берлә кяферләргә.

Хәйрулла мулла. Ля нөсәллим, билгакес булыр.

Сәгыйть хәзрәт. Бөтен китабе сәләф бу хакта мөттәфикъ.

---

*Әүсаф* — сыйфат.
*Мөттафикъ* — бер фикердә.
*Билгакес* — киресенчә.
*Китабе сәләф* — борынгыларның китаплары.

Хәйрулла мулла. Мөттәфикъ, мөттәфикъ, син исбат кыл, ник мөселманга таяк берлә суга, ник мөселманны иза кыла? Изаи мөэмин хәрәм ич.

Берәү. Хәзрәтләр, алай булгач, бу безнең Камчылы ишан Диббәтел арыз түгелме? Аның кыяфәте ишәккә охшый.

Ситдыйк хәзрәт. Түгел, сасык, түгел. Ул ялганчы, ахмак, ул сафсата!

Хәйрулла мулла. Ул — мәхәллә бозучы.

Мөәззин. Ул мөәззиннәрнең ризыгын ашаучы.

Сәгыйть хәзрәт. Дамеллялар, соң инде кыямәтнең галәмәтләре булган димезмени инде? Соң инде Мәһди хакында ни димез?

Берәү. Соң бу көннәрдә бит Мисыр тирәсендә бер Мәһди дигән кеше заһир булды, бәлки, шулдыр.

Хәмит хәзрәт. Мәһди, дамеллялар, минемчә, Бохараи шәрифтән чыгарга кирәк. Бохараи шәриф кенә ислам йорты инде. Ул Истанбул дисәң, анда фисык-фәсад инде. Низам-интизам дип, аларда да Гарәбстанга кадәр тимер юллар ясау китте инде.

Сәгыйть хәзрәт. Миңа Бохарада вакытымда һинд голямасыннан берәү, Мәһди Бохарадан чыгачак, дигән иде.

Ситдыйк хәзрәт. Бохарадан, Бохарадан. Бохара мәхфузәте билмәләкәте дигән! Бөтен йирне урыс басканда Бохарада гына ислам хөкеме калды. Анда гына рус керә алмады.

Фәйзерахман мулла. Хәзрәт, Бохара бит рус тәхте тәсаррыфында. Бохарага хәзер тимер юл барып җиткән.

Ситдыйк хәзрәт. Юк, сасык! Юк. Әмире Бохара гаять гакылыннан русны алдап кына тота. Бохара мәхфузәте билмәләкәте, сасык. Хәдискә инкяр кыласың.

Сәгыйть хәзрәт. Ул заһирән шулай кебек күренсә дә, руслар әмире Бохарага илтифатларыннан гына шулай иткәннәр.

Хәмит хәзрәт. Әйе, әйе. Мин мәхдүмнәрне итәргә барганда, дамелля Салих русларның әмире Бохарага тәгъзыймнәрен сөйләп бетерә алмады. Юл буенда бөтен полициясе, приставына чикле чис биреп кенә торадыр, ди.

---

*Иза кылу* — газаплау.
*Фисык-фәсәд* — бозыклык, азгынлык.
*Низам-интизам* — тәртиплелек.
*Бохара мәхфузәте билмәләкәте* — Бохараны фәрештәләр саклый.
*Тәхте тәсаррыфында* — кул астында, буйсынуында.
*Заһирән* — тыштан караганда.
*Итү* — илтү.
*Тәгъзыйм* — олылау.

К и я ү  м у л л а. Соң, хәзрәтләр, Мәһди һаман юк шул әле.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Ул Бохараи шәрифтә яшеренеп тору ихтималы бар.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Менә Бохарада дамелля Габдулла бар иде, затән фазыйль кеше, сез дә аны, дамеллялар, беләторгансыз. Мин шул булмасын, дим, аның үзен мәҗнүн кебек итеп күрсәтүе Алланың әмере берлә булмасын, дим.

Ф ә й з е р а х м а н  м у л л а. Мәһди әүляде нәби булыр дигән.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Әүляде нәбидән булу шарт булмас, ля нөсәллим!

Х ә м и т  х ә з р ә т. Ул, дамелля Габдулла әүляде нәбидән булыр.

Ф ә й з е р а х м а н  м у л л а. Ничек сарт әүляде нәбидән булсын? Нәби гарәп булган.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Сасык, мөселман барыбер: гарәп ни, фарси ни, төрек ни! Казый кәлян, исламның иң олуг хакиме — үзе фарси иде.

Ф ә й з е р а х м а н  м у л л а. Казый кәлян башка, хәзрәт, Мәһди башка. Мәһди корәеш кабиләсеннән булыр дигән.

М ө ә з з и н. Һашим ыругыннан булыр, дигән.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Дамелля Габдулланы Аллаһе Тәгалә Һашим ыругыннан корәеш кабиләсеннән ясаса, гаҗәпмени? Аллаһе Тәгалә һәрнәрсәгә кадир.

Ф ә й з е р а х м а н  м у л л а. Гадәте Аллаһ алай җари булмаган.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Булыр. Ля нөсәллим! Булыр, анамыз Хаваны балчыктан яратканны Габдулла дамелляны кораеш ыругыннан ясамасмыни?

М ө ә з з и н. Кораеш кабиләсеннән...

Х ә й р у л л а  м у л л а. Син, мөәззин, тик тор, мин синең имамың, син шуны онытма.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Хава анамызны балчыктан яратмаган, сасык, Адәм атамызның сул кабыргасыннан. Сафсата сөйлисең.

М ө х ә м м ә т җ а н. Соң, хәзрәтләр, сезнең җыелышыңызның сәбәбе бит әле бөтенләй башка иде.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Әйе, дамеллялар. Без бик читкә кит-

---

*Затән* — бу урында: асылдан.

*Мәҗнүн* — дивана.

*Әүляде нәби* — пәйгамбәрләр токымыннан.

*Кадир* — һәрнәрсәгә кодрәтле.

*Гадәте Аллаһ алай җари булмаган* — Алланың гадәте алай үзгәреп тормаган.

тек әле. Менә соң инде, шул ахырзаман галәмәтен кәрамәт диик инде. Шуны руска-кяфергә әйтикме, юкмы?

Хәмит хәзрәт. Әйе, минемчә, әйтергә кирәк, ахрысы, әмре билмәгъруф нәһи ганилмөнкир һәркемгә фарыз.

Сәгыйть хәзрәт. Әйе, әйе. Чөнки кыямәт көнне безнең алар өчен мәсьүл булуымыз бар.

Берәү. Тагы, хәзрәтләр, үземез өчен дә күңелле: шулкадәр халык мөселман булса, шундый зур чиркәүләр мәсҗедкә әверелсә, һәркемгә кәефле булыр.

Бер кеше. Моны күреп тә мөселман булмаса инде. Анда эш тә калмады. Ул шул инде — аның тәкъдиренә үк «тәмуг кисәве» дип язылган була.

Мөәззин. Ул могҗизаны күреп, алар мөселман булмый хәле юк инде. Тавык шикелле тавык кәрамәт йомырка салсын имеш тә...

Берәү. Тавык түгел, әтәч!

Берәү. Хәзрәтләр, инде ул, алар мөселман булса, аларның кызларын безгә алырга ярый инде, алардан мөселманга чыгарга теләүче бик күп, ди инде. Безнең мөселман бит әле сач алдыруы, мыек төзәтүе берлә кыяфәткә дә матур килә.

Сәгыйть хәзрәт. Әлбәттә, ярый. Әллә алырга исәп бармы?

Теге кеше. Тәкъдир язса, алырсың да шул. Өйләнү бит изге эш.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, сасык! Ахмак, нечкә биленә кызыгасыңмы?

Сәгыйть хәзрәт. Тагы, дамеллялар, читкә киттек. Соң инде ул әһле кяфергә тавык салган диикме, әтәч диикме?

Хәйрулла мулла. Минемчә, әтәч дигәндә яхшырак булыр.

Фәйзерахман мулла. Әтәч бит, вакыйган, йомырка салмый ул, хәзрәтләр! Без аның берлә көлке генә булмыйк.

Ситдыйк хәзрәт. Сасык, син ни беләсең? Таш ярылып төя чыккач, ник әтәч йомырка салмасын? Әтәч дисен! Әтәч.

Кияү мулла. Әйе, әтәч дию мәслихәт булырга кирәк. Ул вакытта харикылгадәлеге ике кат була инде.

---

*Мәсьүл* — җаваплы.
*Әһле кяфер* — кяфер халык.
*Вакыйган* — чынлыкта.
*Харикылгадә* — гадәттән тыш.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Әтәч мәслихәт булыр, дамеллялар, әтәч!

Б е р ә ү. Соң, хәзрәтләр, ул, аны салганын кем күрде дисә, ни әйтермез?

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Әйе, дамеллялар, ул хакта безнең шаһитларымызны хәзерләргә кирәк.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җә, син Шаһияздан, сафсата, китер шаһитларыңны! Кем күргән?

Ш а һ и я з д а н. Хуш, хәзрәт, кучер күргән, кучер!

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Китер ул кучерыңны, сасык, җә, китер. *(Шаһияздан торып чыгып китә.)*

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Соң, хәзрәтләр, анда инде кем сөйләр? Монда рус лөгатенә кем оста инде?

Х ә м и т  х ә з р ә т. Менә яшь дамеллялар инде! Русча укыган кешеләр.

К и я ү  м у л л а. Бездән булмас, хәзрәт, без кабзыятьләнәмез.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Рәхмәтулланы чакырыңыз. Сасык, ул белә инде. Ул, сасык, шайтан инде, урысыңны сатыр, «Мәвакыйф»ен дә күргән. «Хикмәтел-гайн»ен дә күргән.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Минем, дамеллялар, бер бик һәйбәт хәлфәм бар, Сәлахетдин дигән, русчага бик дана инде, өч ай укыды, хәтта аена бишәр тәңкә түләдем, ди. Бөтен карточкаларымны шул яза.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җук, җук, Рәхмәтулла урысның үзеннән артык белә, Габидулла бутышник та аңардан укыта.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Юк, безнең Сәлахетдин артык булырга кирәк, ул бик кабилиятле бала. Хәтта муллалыкка имтихан да тотты. Имтиханда бөтен урысларның исе киткән, ди.

К и я ү  м у л л а. Безнең мәдрәсәдә, хәзрәтләр, бер бик оста шәкерт бар. Солдатта хезмәт иткән кеше, һәртөрле олуг кешеләр берлә сөйләшә белә инде.

Б е р ә ү. Соң, хәзрәтләр, әле сез ник ул мәдрәсәдән әллә нинди шәкертләр чакырырга телисез, без, әлхәмдүлиллаһ, барымыз да икмәк-тозлык русча беләмез бит. Менә Садыйк абзыйдан барырга үтенермез, хаҗи кеше.

С а д ы й к. Юк, миннән булмый. Мин урыс берлә сөйләшә алмыйм. Безнең приказчиклар сөйләшә.

Шул арада Ш а һ и я з д а н, к у ч е р һәм д в о р н и к килеп керәләр.

---

*Лөгать* — сүз, тел.
*Кабзыятьләнү* — каушау.
*Дана* — фикерле, белүче.
*Кабилиятле* — сәләтле.

Ш а һ и я з д а н. Менә, хәзрәтләр! Икесе дә, күрдек, диләр. *(Тегеләр тезләнәләр.)*

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җә, сасык, сөйлә! Кем күрде?

К у ч е р. Менә, мулла абзый, мин абызтайларны Миңнесафа кодачаларга итим дип ат җигә башлаган идем, чананың тешләре чыккан икән. Шуннан Гайни, өйгә кер, дип кычкырды. Мин өйгә кергән идем, анда базарга чык, диләр! Әле ат җик дип, әле базарга чык дип йөдәтәләр; хатын-кыз хуҗа булгач, шулай була инде.

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җә, сасык, ничек йомырка күрдең?

К у ч е р. Менә шуннан, хәзрәт, тавык кытаклады.

Д в о р н и к. Тавык түгел, әтәч! Ул көн буе кытаклап йөрде, үзем күрдем, әтәч!

К у ч е р. Әтәч анда бөтенләй юк иде.

С ә г ы й т ь х ә з р ә т. Сез береңез генә сөйләңез!

К у ч е р. Карасам, алтынлы йомырка ята.

К и я ү м у л л а. Җә, син инде шуны күргәнлегеңә шәһадәт бирә аламсың? *(Кучер тик тора.)*

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җә, сасык, «әшһәде» диң. *(Кучер башын кашырга тотына. Дворник торып: «Болар бик тирәнгә китәргә кели»,— ди дә чыгып китә.)*

К у ч е р. Минем, мулла абзый, тәһарәтем юк шул!

С ә г ы й т ь х ә з р ә т. Җә, аңарга тәһарәт кирәкми. Шәһадәтең кабул булсын өчен син «әшһәде» ләфызын әйтергә кирәк. Җә, «әшһәде» диң.

К у ч е р *(маңлайларын сөртеп)*. Мулла абзый, башка вакытта әйтермен.

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җә, ахмак, «әшһәде», диң.

Ф ә й з е р а х м а н м у л л а. Хәзрәтләр, соң ник «әшһәде» диюе кирәк. Ул бит, күрдем, ди. Шул шәһадәт булмыймыни?

С и т д ы й к х ә з р ә т. Булмый, сасык, булмый. Шаһитның шәһадәтендә «әшһәде» ләфызын әйтергә кирәк.

С ә г ы й т ь х ә з р ә т. Әйе, мәсәлән, ай күрү мәсьәләсендәге кебек була инде. Анда бит «әшһәде» кәлимәсен әйтергә кирәк.

Ф ә й з е р а х м а н м у л л а. Ул бит гарәпчә аңламый. Ул ничек әйтсен?

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җукны сөйлисең, сасык. *(Кучерга.)* Җә, «әшһәде» диң.

---

*Шәһадәт* — таныклык.
*Әшһәде* — шәһадәт бирәм, таныклыйм.
*Кели* — тели.
*Ләфыз* — сүз.
*Кәлимә* — сүз.

Шаһияздан. Әйт инде.

Кучер *(башын кашып)*. Юк, абзый, булмый миннән, алай булса, пашпортымны бир. Муены булса, камыты табылыр.Мин китапча сөйли белмим.

Ситдыйк хәзрәт. Ахмак, «әшһәде» диң.

Кучер *(торып)*. Үзең әйт! *(Шаһияздангa.)* Хезмәтем ярамаса, пашпортымны бир!

Шаһияздан. Син хәзрәт сүзен тыңла! Ни сөйлисең?

Кучер. Монда бетмәс сезнең, тегендә абызтайлар утын керт, ди, монда монысы иман тыңлатырга кели. *(Чыгып китә.)*

Ситдыйк хәзрәт. Кая барасың, сасык?

Сәгыйть хәзрәт. Гавам надан инде. Шәргы шәрифне ригая кылмый инде.

Хәмит хәзрәт. Голяманың игътибары бетте инде.

Берәү. Соң, хәзрәтләр, үзеңез дә бик каты тотындыңыз.

Берәү. Соң инде, бу галавага баруны нишлимез?

Кияү мулла. Ник галавага булсын, губернаторга, диң.

Гласный. Галава инде, галава бик шәп кеше, безнең мөселманга да дошман түгел. Әле теге шкула ачу тугрысында мин, безнең шәригатькә шкула ачу сыймый, дигәч, бер сүз әйтмәде. Алай булса, ул акчага Мукригә урысларга ачармыз, ди.

Хәмит хәзрәт. Алай булгач, исламда ихласы бар кеше икән!

Гласный. Бар, бар. Әле безнең мөселман гласныйлары өчен Думага тәһарәтханәгә комган куйдырта дип сөйләгәннәр иде.

Ситдыйк хәзрәт. Ул, алай булса, шөбһәсез, мөселман, мөселман, сасык, хәфитан мөселман.

Кияү мулла. Болай гына исламны сөйсә дә сөяр.

Тагы бер гласный. Аннан соң Иван Ивановичка да барырга кирәк. Ул бик яхшы кеше. Ул да, хәзрәтләр, гласный. Бик мөселман яклы кеше. Без теге мирзаларның әллә нинди бер йорт ачарга йөрүләрен дә шуңарга барып гозер иткән идек, ләм дә димәде. Үзенең бер танышына хат кына язды, ясатмадылар.

---

*Шәргы шәриф* — изге шәригать, ислам шәригате.
*Ригая кылу* — хөрмәт итү.
*Хәфитан* — яшерен.
*Гозер итү* — ялвару, йомышны үтәүне сорау.
*Ләм дә димәде* — бер сүз әйтмәде, каршы килмәде.

Б е р ә ү. Юк, хәзрәтләр, губернаторга барырга кирәк. Ул барысыннан да зур — галавадан да зур, полисмейстердан да зур, ул янарал чинында.

Г л а с н ы й. Юк, галава зур. Фонарь куйдырумы, каравылчы яллаумы — берсе дә галавадан башка булмый. Тагы бер зур эш булса, Петербургтан аны телеграм берлә генә чакыралар.

Т е г е б е р ә ү. Губернатор зур, аның әмереннән башка хаҗ паспорты да бирмиләр. Галавадан хаҗ өчен рөхсәт тә сорамыйлар.

С и т д ы й к х ә з р ә т. Бары да бер урыс, бары да бер.

С ә г ы й т ь х ә з р ә т. Юк, дамеллялар, соң аны белергә кирәк инде! Аның кайсы Казый кәлян дәрәҗәсендә була инде?

Х ә м и т х ә з р ә т. Минемчә, губернатор булырга тиеш. Без указны бит аның аша аламыз.

К и я ү м у л л а. Әйе, губернатор олуг булыр, губернатор. Ул галава дигән, Садыйк абзый, губернаторның помощнигы гына булырга кирәк.

Г л а с н ы й. Юк, түгел, аңар үз исеменә Петербургтан гәзитә килә.

Ф ә й з е р а х м а н м у л л а. Анысы, алсаң, ул сиңа да килә.

Г л а с н ы й. Юк, бөтенләй адреслары-ниләре, исемнәре — һәммәсе баскан. Аны анда министрлар белмәсә, алай булмас иде.

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җә, сасык, җә, галавага барыйк! Әһле исламга мәхәббәтле дә булгач, аңарга барыйк, сафсатага!

С ә г ы й т ь х ә з р ә т. Җә, соң, дамеллялар, кем бара инде?

Х ә м и т х ә з р ә т. Анда әһле голяма кирәк инде. Дамелля Садыйк бара инде, андый-мондый мөшкел мәсьәләдән сүз сораса, җавап бирергә дә кирәк инде.

К и я ү м у л л а. Мин, хәзрәтләр, «Шәрхе викая»не алып бармыйкмы, дим! Ахрысы, дөньяның төрле хәле була. Мөшкел мәсьәлә булса, хәзер генә карап җавап бирергә җиңел булыр.

С и т д ы й к х ә з р ә т. Җә, җә, җарый, җарый.

С ә г ы й т ь х ә з р ә т. «Шәрхе мәвакыйф»ны да алып бару мәслихәт булыр. Алар әһле урыс бит, хөдүсе галәмгә инкяр кылучылары бар.

---

*Янарал* — генерал.
*Хөдүсе галәм* — галәмнең яратылуы.
*Инкяр кылучылар* — каршы килүчеләр.

Хәмит хәзрәт. Әйе, әйе!

Берәү. Хәзрәтләр, инде анда безнең сәүдәгәрдән дә берәр кеше кирәк. Менә Шәмсетдин абзый барсын димез, үзе урыс күзендә дә игътибарлы кеше. Карт кеше.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә... Бик яхшы, җә... җә...

Сәгыйть хәзрәт. Соң, инде урыс лөгатен белүчемез кем була инде?

Шәмсетдин абзый. Әлхәмдүлиллаһ, әле, хәзрәт, моңанчага кадәр урысчага аптырамаган идек. Петербургка да бардык, министрны да күрдек, һәммәсе берлә сөйләшә алган идек.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, бик яхшы! Бик яхшы!

Мөәззин. Хәзрәтләр, анда инде ул мөәззиннәрдән дә берәү кирәк. Азан-фәлән әйтергә тугры килсә, безнең азан әле бит кальбкә тәэсир итүчән була.

Кияү мулла. Әйе, әйе. Үзем күргәнем бар, азан әйтелгәндә урыслар авазның күркәмлегенә шаккатып торалар.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, җә, барсын. Менә шул ахмак барсын. Барсын.

Мөәззин. Соң, хәзрәт, анда инде гает намазының ниятләре кирәк булмасмы? Мин «Гайде рисалә»мне алмыйммы?

Ситдыйк хәзрәт. Җук, сасык, җук.

Сәгыйть хәзрәт. Җук, алай димә, дамелля Ситдыйк, бәнагяһ гаетнең тәкбирләрен сораса, без һәрнәрсәгә хәзер булып барырга кирәк.

Фәйзерахман мулла көлеп тора.

Кияү мулла. Соң инде, хәзрәтләр, әлбәттә, алар шулкадәр зур эшне күргәч, мөселман булмый хәлләре юк. Исламның хаклыгына моннан да зур дәлил булу ихтималы юк. Соң инде, мәсәлән, алар исламны кабул итсәләр, иң әүвәл без аларга ни өйрәтергә кирәк?

Хәмит хәзрәт. Бинаи ислам өйрәтергә кирәк.

Мөәззин. Бинаи ислам биштер: иман, намаз, рузә, хаҗ, зәкят *(Тиз-тиз әйтә.)*

Сәгыйть хәзрәт. Әйе, бинаи ислам өйрәтергә кирәк. Аннан соң, дамеллялар, алар хәез-нифас хөкемен белмиләр инде, шушы хакта берәр китап алмыйкмы?

---

*Кальб* — күңел, йөрәк.
*Бәнагяһ* — көтмәгәндә, кинәт.
*Тәкбирләр* — олылау сүзләре.
*Бинаи ислам* — ислам нигезләре.
*Хәез-нифас* — күрем, бала тудыру.
*Истинҗа* — тәрәттән соң пакьләнү.

К и я ү  м у л л а. Минемчә, истинҗа мәсьәләсе дә алар өчен илляһум-фәлаһум, чөнки аларда тәһарәт дигән нәрсә юк.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җә, җә, ал, сасык, ал!

К и я ү  м у л л а. Алай булгач, хәзрәтләр, берәү-берәүне китаплар алырга җибәрергә кирәк. Менә мөәззин барып килсен. Соң, хәзрәтләр, «Шәрхе викая» кирәк булдымы?

Х ә м и т  х ә з р ә т. «Шәрхе викая» кирәк. Анда инде фикъһедән сүз чыкса, дамелля Сәгыйть, сез сүз ачарсыз, сез фикъһегә оста инде.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Алай булса, минем үземнең «Шәрхе викая»мне алып килсен, нәфис тышлы, Бохар мөҗәлләде, хашияле.

М ө ә з з и н. Ярар.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Хикмәттән сүз чыкса инде, сезнең кем сөйләр?

Х ә й р у л л а  м у л л а. Мин, әлхәмдүлиллаһ, «Хикмәтел-гайн»не күргән кеше. Гыйлем бәхәсендә без үрдәк кебек йөзәмез инде.

К и я ү  м у л л а. Әлбәттә, мәсәлән, заман мәүҗүдме, түгелме дигән бәхәс китсә.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Әлбәттә, мәүҗүд булырга кирәк... Чөнки мәүҗүд булмаса, мәгъдүм булыр. Мәгъдүм булса, мафиәззаман да мәгъдүм булырга кирәк. Ул вакытта җәмигы мәүҗүдат — мәгъдүм булырга кирәк, бу мохаль, бәс, гадәме заман — мохаль.

К и я ү  м у л л а. Ля нөсәллим. Заман мәүҗүд тә булмас, мәгъдүм дә булмас. *(Муллалар кулларын бутарга тотыналар.)*

Х ә й р у л л а  м у л л а. Иртифагыйннәкыйзин, иртифагыйннәкыйзин.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Заман мәүҗүд булса, йә мөмкин булырга, йә ваҗиб булырга кирәк.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ваҗиб булыр.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Тәгаддеде ваҗиб.

---

*Илляһум-фәлаһум* — булды ни, булмады ни.

*Мөҗәлләде* — төпләмәсе.

*Хикмәт* — фәлсәфә.

*Заман мәүҗүдме* — заман бармы.

*Мәүҗүд булмаса, мәгъдүм булыр* — бар булмаса, юк була.

*Мафиәззаман* — вакыт төшенчәсен белдергән нәрсә.

*Җәмигы мәүҗүдат — мәгъдүм булырга кирәк* — барлыкның барысы да юк була.

*Мохаль* — дөрес түгел.

*Бәс* — димәк.

*Гадәме заман — мохаль* — заманның булмавы да мөмкин түгел.

*Ваҗиб* — һичшиксез.

*Тәгаддеде ваҗиб* — күплеге һичшиксез.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Тәгаддеде важиб дөрест булыр, аның вөҗүд заты булмас.

К и я ү  м у л л а. Вөҗүд заты булмаса, гариз булырга кирәк. Ул вакытта ул гариз берлә заттан мөрәккәб булырга кирәк. Һәр мөрәккәб мөмкин. Бәс, имкяне вөҗүб лязим була.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Булмас, сасык! Булмас.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Мөмкин дә булмас, важиб дә булмас, мөмтәнигъ булыр.

К и я ү  м у л л а. Ә, мөмтәнигъ булырмы? Мөддәгый сабит, мөддәгый сабит. *(Үзе сикерә.)* Мөддәгый сабит: мөмтәнигъ булса, заман мәгъдүм булган була.

Х ә й р у л л а  м у л л а *(бик кычкырып)*. Булмас, булмас! Ля нөсәллим, мөмтәнигъ мәүҗүд булыр.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Һәр мәүҗүд йә мөмкин, йә важиб.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Ля нөсәллим, икегә мөнхәсыйр булмас.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Заманның вөҗүде игътибари булыр.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җук, сасыклар, җук, туктаңыз! *(Кияү муллага.)* Җә, ахмак, сафсата сөйлисең, «Шәрхе мәвакыйф» заман-мәүҗүд, ди. Ләкин заманның вөҗүде игътибари, ди.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Юк, дамеллялар, алай гына ярамый. Без шул хакта — вөҗүде заман вә гадәме заман хакында һәр дәлилне карарга кирәк.

Х ә й р у л л а  м у л л а. Мин барысын да дәрхәтер тотам. Заман хакында үзем сөйлим.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җә, сасык, сөйлә! Сөйлә!

К и я ү  м у л л а. Әле тагы нинди китаплар соң? «Шәрхе мәвакыйф» бездә бар. «Хикмәтел-гайн» дә кирәк булыр.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Әле соң хәез-нифас хакында дигән идеңез.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Әйе, әйе, алар хакында «Мохтәсарел-викая» кирәк. Моталәгасы авыр инде дә, ул кирәк. Бохарада шуның берлә хөкем итәләр.

---

*Вөҗүд заты булмас* — барлыгы билгеле булмас.

*Гариз* — киңлек.

*Мөрәккәб* — барлыкка килгән.

*Имкяне вөҗүб лязим була* — «вөҗүб»нең мөмкинлеге һичшиксез кирәк була.

*Мөмтәнигъ* — кире кагылган.

*Мөддәгый сабит* — нык таләп итүче.

*Мөнхәсыйр булмас* — чикләнгән булмас.

*Игътибари* — ышану буенча гына.

*Вөҗүде заман вә гадәме заман* — вакытның барлыгы һәм юклыгы.

*Дәрхәтер* — хәтердә.

*Моталәга* — бу урында: эчтәлеге, аңлатмалары.

К и я ү  м у л л а. Бар, мөәззин, шуларны алып кил.

М ө ә з з и н. «Җәнаиз» кирәк булмас микән? Үлекне юуу тугрысында, кәфен сару тугрысында сүз чыкмас микән?

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Ал, сасык, ал! *(Мөәззин чыгып китә.)*

Б е р ә ү. Соң, хәзрәтләр, инде безнең Печән базары халкыннан Шәмсетдин абзыйга башка харчевняче Фәхретдин абзыйны алмыймызмы? Аның да урыс күзендә бик игътибары бар.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Әйе, мәслихәт булыр!

Ш ә м с е т д и н. Соң, хәзрәтләр, без нишләрмез?

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Без иман тәлкыйн кылырмыз, сез шуны шуларга аңлатырсыз.

Ф ә х р е т д и н. Җарый, җарый, хәзрәтләр. Ләкин, хәзрәтләр, урыс каршына барганда башны-күзне төзәтеп барырга кирәк инде.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Әйе, мәһабәтрәк күренергә кирәк. Дамелля Сәгыйть, минем сачем йитүле түгелме?

Бөтен мулла кулллары берлә сачләрен, мыекларын тартып карыйлар.

Д а м е л л я  С ә г ы й т ь. Җук, дамелля! *(Кияү муллага.)* Менә моның гына мыек зуррак.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Төзәтергә кирәк.

К и я ү  м у л л а. Каенагай, син кайчы китер әле.

Ш а һ и я з д а н кайчы китерә. Кияү мулла мыегын кыркырга тотына.

Ф ә х р е т д и н. Хәзрәтләр, чалмаларыңызны яхшылап чалмыйсызмы?

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Җук, сасык, җук, Бохараи шәрифтә бөтен дамеллялар шундый чалмадан йөриләр.

Ш ә м с е т д и н. Алай да, хәзрәтләр, чапаннарыңызны алмаштыру кирәк. Ситдыйк хәзрәтнең җиңнәре бик майга буялган.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Сасык! Мөселманнарның эче пакь!

Х ә м и т  х ә з р ә т. Юк, дамеллялар, нәзафәткә рус халкы мәхәббәт иткән, анысы дөрест. Шаһияздан, кая синең чапаннарың бардыр, китер!

Х ә з р ә т л ә р *(беравыздан)*. Китер, ахмак! Китер!

Ш ә м с е т д и н. Китер, Шаһияздан, барыбер әрәм булып калачак әйберләр. *(Шаһияздан чыгып китә.)*

---

*Тәлкыйн кылу* — инандыру.
*Нәзафәт* — пакьлек.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Менә әле, дамеллялар, бер мәсьәлә каралмаган икән! Бу хиҗаб хакында ни әйтәмез. Әһле урысның хатын-кызы хәясезлеккә өйрәнгән!

К и я ү  м у л л а *(мыекларын кырып бетереп)*. Әйе, әйе, менә сирәк-сорак вагунга утырганда да шул урыслар синең янгук килеп утырып, кальбкә вәсвәсә төшерәләр.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Моның хакында китабе фикъһедә ачык гыйбарәләр бар инде, без Бохараи шәрифчә инде хиҗабны тәмам ясатырга тиеш!

Ф ә й з е р а х м а н  м у л л а. Ул хиҗаб мәсьәләсе Бохарада чигеннән чыккан инде, алар шәригать күрсәткән чиктән үтеп киткәннәр.

Муллалар бар да кулларын селкетергә тотыналар.

С и т д ы й к  х ә з р ә т. Ахмак, агач авыз! Бохараи шәриф хакында ни сөйлисең? Андагы һәр хөкем исламча, әлегә кадәр анда сирка өчен кул кисәләр, зина өчен хәд кылалар. Сасык. Хәзрәте Хуҗаның зиярәтен мыскыл итәсең!

К и я ү  м у л л а. Әлбәттә, хиҗаб хакында Бохара инде иң шәригате исламны ригая кыла!

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. Әйе, әйе, ул хатын-кыз ул вакытта фетнә генә була. Ул качмаса, хәзер безнең арага кереп сөйли башласа, кайсыңызның күңеленә шайтан вәсвәсә салмас иде.

Х ә м и т  х ә з р ә т. Ләкин, дамеллялар, аның хакында аяте хәдистән ачык дәлилләр кирәк, чөнки ул хакта Мисырлар, Истанбулларда бидгать бик киткән.

С ә г ы й т ь  х ә з р ә т. «Шәрхе викая»дә бар инде. Аның хакында сүз чыкса, дамеллялар, дамелля Ситдыйкка кушармыз инде.

Шул арада Ш а һ и я з д а н чапаннар күтәреп керә, муллалар, аны чормап алып, өстләрендәге чапаннарны салып ташлап, чапаннар киярге тотыналар. Бер чапанга икешәр мулла ябышып, тартышып эштән чыгып беткәннең соңында, бар да төрлесе төрле төстәге алалы-колалы чапаннар кияләр. Муллалар, чапаннарын тотып-тотып карап, бер-берсе илә сөйләшәләр. Шул арада бер кочак китаплар күтәреп, м ө ә з з и н килеп керә. Мөәззин боларның яңы чапаннарын күргәч үк, чапаннар янына

---

*Хиҗаб* — йөзне каплау, яшерү.
*Әһле урыс* — урыс халкы.
*Хәясезлек* — оятсызлык.
*Сирка* — караклык.
*Хәд кылу* — чыбык белән суктыру җәзасы.
*Бидгать* — бу урында: көферлек.
*Хисса* — өлеш.

килеп: «Минем хиссам кая? Мин мәхәлләмөәззине, мине ник өлештән калдырасыз?» — дип орышырга тотына. Шул ара да булмый, ул салынган чапаннардан берсен алып өстенә кия башлый.

Хәйрулла мулла. Ул, мөәззин, минеке.

Мөәззин. Миңа чапан кирәк түгелмени? *(Кия.)*

Хәйрулла мулла. Сал, мөәззин.

Мөәззин. Кая минем хиссам?

Фәхретдин *(Шаһияздганга)*. Бар инде, мөәззингә дә берне чыгар.

Шаһияздан мөәззингә дә берне чыгарып кигезә. Шул арада һаман муллалар чәй эчәләр.

Ситдыйк хәзрәт. Җә, сасыклар, барамызмы?

Хәмит хәзрәт. Атлар җиккәнме?

Шаһияздан чыгып китә. Муллалар залда йөрергә тотыналар. Ситдыйк хәзрәт ясаган чәен эчеп, авызын чапанның җиңе берлә сөртә.

Шаһияздан. Хәзрәтләр, атлар җигелә, ди.

Фәхретдин. Шаһияздан, син ислемай китер әле, рус халкы хуш исне ярата. Аларның марҗалары да гел шул ислемай сибеп кенә йөри инде.

Сәгыйть хәзрәт. Әйе, әйе, ул әһле голяманың исе гатырша мае дигәннәр. Дамеллялар, сезнең хәтердәме, дәрескә дамелля Нәҗиб нәфис гатырша мае сөртенеп керә иде.

Хәмит хәзрәт. Әйе, әйе.

Шаһияздан шкафтан гатырша мае алып китерә. Муллалар гатырша мае сөртергә тотыналар. Гатырша мае исе берлә зал тула. Муллалар, китапларны кулларына күтәреп, чыгарга хәзерләнәләр. Шул арада ишектән бер малай килеп керә.

Малай. Менә кияү мулла абзыйга Әхмәт абзый хат биргән иде.

Кияү мулла. Ул тагы нинди хат икән? *(Барып алып, ачып укырга тотына. Тегенең битенә гаҗәпкә калу галәмәте чыга.)*

Кияү мулла. Дамеллялар, эш харап, кара бу дуңгызны, ни яза?!

Муллалар. Җә, ни, ни?

Кияү мулла. Менә ни: *(Укый башлый.)* «Хәзрәтләр! Ул йомырка Алла тарафыннан җибәрелгән бәшарәт түгел.

---

*Гатырша мае* — ислемай, хушбуй.
*Бәшарәт* — хәбәр.

Сез аңарга ышанып, русларны иманга өндәргә бармаңыз. Аны мин генә кимия маддәләре берлә сезнең наданлыгыгызны халыкка күрсәтер өчен, сезнең бернәрсә белмәвеңезне белдерер өчен яздым.

Әхмәт».

Муллалар төрлесе төрле урында катып калалар. Фәйзерахман мулла көлә. Бераз катып торгач:

Ситдыйк хәзрәт. Ахмак сафсатаны китер монда! Китер дуңгызны! *(Идәнгә кулын суга.)* Үзем тәгъзир кылам кяферне.

Пәрдә төшә.

---

*Тәгъзир кылу* — җәза бирү.

# ҖӘМГЫЯТЬ

*Комедия ике пәрдәдә*

КЕШЕЛӘР:

Шәриф бай — мәдрәсәләр, мәктәпләр сала торган, ысуле җәдид сөя торган тугры гына фикерле карт бай.
Җуан бай — Шәриф байның энесе, тупас бай.
Хәзрәт — гади хәзрәт.
Мулла — гади мулла.
Мөәззин — хәйләкәр мөәззин.
Муса мирза — үзене бик динле дип күрсәтергә тырышучы, һәммә кешегә ярарга теләп йөрүче, банктагы бер писарь.
Салих — яңа татар егете. Тугры фикерле. Риясыз.
Җәмал кода — бик мөтәгассыйб татар бае. «Бәдәвам»чы.
Бикә — гади бай хатыны.
Килен — гади яшь хатын.
Хуҗа угылы.
Асрау.
Халык — яшьләр, картлар.

Вакыйга Оренбургта, унтугызынчы йөзнең башларында.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур гына зал. Уртасында озын өстәл. Өстәл өстендә, графиналарда кызыл куаслар. Залда халык күп: кайсы озын өстәл буена утырган, кайсысы читләргә утырган. Өстәлнең башында күзлекле, чуар бишмәт кигән, чалма кигән бер мулла. Аның янында чапаннан, чалмадан тагы бер мулла. Аның янында ак бүректән бер хәлфә. Аның янында русча киенгән, кара мыеклы, яланбашлы бер мирза. Тагы мөәззин, бәдәлче, байлар, уртача халык, бай балалары.

Шәриф бай. Менә инде, җәмәгать, сезне шуның өчен өшәндердек. Хәзрәтләр килми...

Бер җуан бай. Чакырылгандыр бит, Әхмәди? *(Шул арада яшь кенә бер приказчик килә.)* Хәзрәтләрне чакырткан идеңме?

Әхмәди. Чакырттым. Барысына да әйттердем.

---

*Мөтәгассыйб* — фанатик.

Б е р  б а й. Әллә, җәмәгать, хәзрәтләргә ат йибәрикме?

М у с а  м и р з а. Әйе, вәт, хәзрәтләр үзләре булдырырга кирәк кебек күренә түгелме? Вәт, милләткә хезмәт эшендә алар, вәт, үзләре алдан йөри торган кешеләрдер? Шәриф абзый, сезнеңчә ничек?

Б е р  к е ш е. Юк, алай ярамый, хәзрәтләргә ат йибәрергә кирәк. Андый-бундый эшләре булгандыр.

М ө ә з з и н. Әйе, үлем-җитем фәлән бардыр. Ил булгач, төрле хәл була.

Ш ә р и ф  б а й. Яман, пычак эшләре дә юк әле! Тик дошманлык белән генә килмәгәннәрдер. Аларга милләтең кадалып бетсен!

Б е р  к е ш е. Алар бидгатьтән куркалар. Әһле голямага, шул, бундый убществалар арасына да йөрергә ярамый инде. Пәйгамбәр заманында убщества булмаган.

М у с а  м и р з а. Ул, Садыйк абзый, алай булып бетәр микән соң? Ул инде, вәт, менә мин инде бу мөселманнарны да, барысын да убществага килмәгәннәр, болар җәмгыятькә *(«Җәмгыять» дигән сүзне бик мишәрчә әйтә.)* килгәннәрдер дип уйлыйм. Мин үзем убществага килмәдем, җәмгыятькә килдем.

Х а л ы к *(беравыздан)*. Убщества түгел! Җәмгыять, җәмгыять! Түгел!

С а л и х *(аяк үзрә торып)*. Минемчә, җәмәгать, ул чакырылган хәзрәтләр, киләселәре килсә, килерләр иде. Килмәсәләр, шул: алар безнең җәмәгать эшләренә илтифат итмәгән булалар. Шуның өчен аларны көтмәенчә эшкә башларга кирәк.

Б е р  к е ш е *(утырган йиреннән)*. Убщества эшеме, җәмгыять эшеме?

С а л и х. Ул бит җәмгыять берлә убщества арасында аерма юк!

Х а л ы к *(кычкыра)*. Бар, бар!

М ө ә з з и н. Убществаның бидгатьлеге бәдиһи!

Б е р  б а й. Бидгать, бидгать!

С а л и х. Сез миңа сөйләргә бирмәдегез. Җәмгыять — җыелыш дигән сүз, убщества да шулай дигән сүз!

Т а в ы ш. Түгел, түгел! Убщества кирәкми! Җәмгыять кирәк!

Б е р ә ү. Пәйгамбәр заманасында убщества булганмыни?

---

*Бидгать* — ярамый торган эш.
*Әһле голяма* — гыйлемле кешеләр; бу урында: муллалар.
*Аяк үзрә* — аягүрә.
*Бәдиһи* — ап-ачык.

С а л и х. Пәйгамбәр заманасында булган.

Т а в ы ш. Тәүбә кыл, тәүбә кыл! Юк, юк!

Җ а м а л  к о д а *(ачуланган тавыш берлә)*. Мин, әлхәмдүлиллаһ, яшем йитмешкә йитте, моңынча андый убществаларга кермәдем. Аллаһе Тәгалә бундан шундый убществалардан сакласын! Бөтен мөэмин-мөселманны убществадан сакласын! Әнә бит әле, бакчаларда шул убщества кешеләре музыкалар уйныйлар. Безнең мөселманны да шулай итеп музыкалар уйнатырга телиләрмени?

М у с а  м и р з а. Җамал абзыйның сүзе бик дөрест. Без беремез дә, вәт, ул әле урысларның менә бундагы музыкальный убществалары кебек убщества ачарга риза түгел! *(Тавыш: Түгел, түгел!)* Без менә, хәзрәтләр фатиха бирсәләр, җәмгыять ачмакчы буламыз. Җәмгыять, вәт, ул убщества түгел. Ул Салих әфәнденең сүзе дә дөрест. Ну, вәт, без — мөселман! Без дин кушканча йөримез.

Х а л ы к. Дөрест, дөрест.

Ш ә р и ф  б а й. Соң ул алай дөрест булгач, ул җәмгыять бидгать булгач, ник башка шәһәрләрдә ачканнар? Ник анда муллалар шул җәмгыятькә язылганнар? Менә, хәзрәтләр, сездән сорыймыз инде. Ул бидгать булса, сез безне тыеңыз инде.

Х ә з р ә т *(күзлекле)*. Китапларда убщества дигән нәрсә юк. Инде аның хакында ачык ривайәтләр күренми. Ләкин инде, ул бит инде, менә әле Җамал абзый әйткәнчә, ул убществалар музыкалар уйнасалар инде, әлбәттә, ул музыка ләгу вә ләһәб була инде. Ләгу-ләһәб хәрәм инде.

И к е н ч е  м у л л а. Әйе, аннан соң инде әле бу убщества дигәнемез урыс лөгате инде. Бу инде без убщества ачуымыз берлә урыска охшаган буламыз. Мин тәшәббәхә минһүм фәһүә минһүм. Инде шуның өчен бу убщества дигән сүз хатадан хали түгел инде!

Б е р  я ш ь  б а й. Соң бит инде, хәзрәтләр, без убщества ачмаска булдык. Бу җәмгыять хакында китапларда ни әйтә инде?

Хәзрәтләр бераз дәшмәенчә торалар.

Б е р  х ә л ф ә *(ак бүрекле)*. Алар хакында китаплар-

---

*Ләгу-ләһәб* — уен-көлке.
*Лөгать* — бу урында: сүз.
*Мин тәшәббәхә минһүм фәһүә минһүм* — кемгә охшарга тырышсаң, шул булырсың.
*Хатадан хали түгел* — хатадан азат түгел.

да ривайәт юк. Белмим, менә хәзрәтләр ни әйтер. Мин «Җәмигы-р-рөмүз»дә күргәнем юк!

Хәзрәтләр. Юк, юк!

Җамал кода. Ул соң алай китапта булмаган эшне эшләү, хәзрәтләр, ничек булыр инде? *(Муллалар аптырабрак торалар.)* Ул алай китапка каршы килеп эш йөрткәнче, без китап кушканнарны эшлик. Менә, җәмәгать, Каргалы юлы буенда, анда уйсу йир бар. Әнә шунда мөселман каберләре бар диләр. Менә шул йирне тотып алырга кирәк. Узган-барган, урыс-улак аларны мыскыл итмәсен.

Халык. Әйе, әйе, бик мәслихәт!

Җамал кода. Аннан ары, аларның өстенә агач утыртырга кирәк. Алар зикер әйтеп торырлар. Зикерләренең савабы үлекләргә барыр. Хәзрәтләр, шулайдыр бит, агач зикер әйтә торгандыр?

Мөәззин. Әйе, китап әйткән: агачлар, үләннәр — һәммәсе дә Аллаһ дип торырлар дигән.

Бер кеше. Ул инде, әлбәттә, зиярәтләр тирәсен тоту бик яхшы эш. Ләкин бит башка кирәкләремез дә бар. Менә фәкыйрь картлар була, ятим балалар була. Шуларга торырга урын ясасак, шәригатьчә гөнаһ булмас иде дип уйлыйм.

Арттан берәү. Ул приют буламы инде? Теге базар почмагындагы кеби приют буламы инде?

Халык. Юк, юк! Приют кирәкми!

Бер хәлфә. Ул инде приют йортында, аның ирләре берлә хатыннары бергә торалар икән инде. Ул шәргы шәрифкә мохалиф инде.

Халык. Ул урыс эше, урыс эше!

Салих. Сез бик кызык икән. Приют ачып фәкыйрьләрне тәрбия кылу да урыс эше, җәмгыять ачып балалар укыту да урыс эше. Кая соң мөселман эше?

Мөәззин. Үлекне каберенә кадәр озата баруда.

Бәдәлче. Хаҗилар берлә күрешә баруда.

Берәү. Биш вакыт намазны җәмәгать берлә кылуда.

Салих. Мин аларны әйтмим.

Халык. Безгә шул кирәк, шул. Безгә убщества кирәкми.

Салих. Алай булгач, соң, сез урыс эшеннән бик курыккач, ник урыслар кәсеп итә торган тире-яры берлә сәүдә итәсез? Урыска охшау була ич!

Халык *(көлә)*. Ул дөнья эше! Кәсепсез торып булмый!

---

*Шәргы шәрифкә мохалиф* — изге шәригатькә каршы.

Ш ә р и ф  б а й. Мин әле, җәмәгать, бу эштән гөнаһ булыр дип әйтүгә бер дә алай ышанмыйм. Минем фәкыйрь, зәгыйфь картларны җыеп ашатуым, хәзрәтләр, китапка сыймыймыни?

Б е р  х ә з р ә т. Әйе, анда инде, шул сезнең гарызыңыз фасид булмаса, мәсәлән, убщества ачу булмаса, әлбәттә, саваплы эш инде.

Ш ә р и ф  б а й. Ятим балаларны җыеп укыту гөнаһмы инде?

М ө ә з з и н. Анысы инде укытуына карап, әгәр инде сәләфләр юлы берлә булса - саваплы инде. Ысуле җәдидә берлә булса, кара такта булса — хәрәм инде.

Б е р ә ү. Ысуле җәдид кирәкми!

Б е р н и ч ә  к е ш е. Кирәкми, кирәкми!

Ш ә р и ф  б а й. Туктаңыз әле, сез миңа җавап биреп бетереңез әле. Менә инде, мин шул фәкыйрьләрне җыеп ашатсам, аларны һөнәргә өйрәтсәм, шуның өчен мине кыяммәттә тәмугта яндыралармы инде? *(Муллалар берсенә берсе карашалар.)*

Б е р  м у л л а. Әйе, анысы инде Алла эше, без белмибез. Теләсә гафу кыла, теләсә газап кыла.

Җ а м а л  к о д а. Аны белер хәл юк. Бәрсыйса әүлия 126 ел гыйбадәт кылган да, ахырдан Аллаһе Тәгалә каһәренә лаек булган.

Ш ә р и ф  б а й. Мин синең Бәрсыйсаңны белмим. Менә минем акчам бар. Менә мин үләм. Шуның өчен фәкыйрь балаларга укырга акча калдырмакчы булам. Шул ярыймы, юкмы? Шәригатькә сыямы, юкмы?

Җ а м а л  к о д а. Син ысуле җәдид мәктәбе ачмакчы буласың? Менә шул шул, менә шул инде, җәмәгать, очы кая килеп чыкты!

Х а л ы к. Юк, юк! Безгә ысуле җәдид кирәк түгел!

М у с а  м и р з а. Әле, вәт, Шәриф абзый ысуле җәдид дигәне юк, җәмәгать. Ул менә үзеннән соң акча калдырам, ди. Укырга инде, фәкыйрьләргә укырга. Бу соң, хәзрәтләр, саваплы эш түгелме соң? Бу яхшы нәтиҗә түгелме соң?

Б е р  я ш ь  к е ш е. Бик яхшы, безгә хәзер Шәриф абзыйга рәхмәт укырга кирәк тә, шул эшкә ярдәм итешергә генә кирәк.

М ө ә з з и н. Ул бай акча калдырырга теләсә, әлбәттә,

---

*Гарыз* — теләк.
*Фасид* — бозык.
*Ысуле җәдид мәктәбе* — яңача ысул белән укыта торган мәктәп.

бик яхшы эш инде. Ләкин бит, ул фәкыйрь балалар укытудан кирәгрәк эшләр бар — мәсәлән, мулла-мөәззин халкының хәле бар бит. Мәхәллә халкы, үзеңезгә мәгълүм, карый алмый.

Бер мулла. Әйе, әйе, голяманың эше авыр, көн күрүе кыен инде. Аларны онытырга ярамый.

Салих. Менә ни өчен сез баядан бирле шәригатькә сыймый дип торасыз икән!

Тавыш. Ни сөйли! Хәзрәтләргә каршы килә! Алладан оял!

Муса мирза. Ул инде, мулла-мөәззиннең хәле кыенлыгын беләмез шикелле инде. Әле һәр эш алардан башка булмый инде. Вәт, шулай да менә, вәт, бу җәмгыятьне инде аерым ясыйк, дим инде. Голяманы Шәриф абзый үзе онытмас инде, дим.

Берәү. Бунда бит эш әле менә шул җәмгыятьтә инде. Шул менә шәригатькә муафикъмы, түгелме?

Янә берәү. Тагы шул приютта инде.

Муллалар. Ул приют дигәне китапларда күренми инде. Ул пәйгамбәрдән соң чыккан эш була инде, шулай булгач, ул бидгать була инде.

Җамал кода. Менә, җәмәгать, ишеттеңезме? Бидгать буладыр, ди.

Салих. Минемчә, мәсьәләне бөтенләй үзгәртергә кирәк. Менә халкымыз арасында зәгыйфь картлар бар. Шуларны ашатып тәрбия кылырга кирәкме, түгелме? Тагы фәкыйрьлек сәбәпле укый алмый кала торган балалар бар. Шуларны укытырга кирәкме, түгелме? Менә Шәриф абзый шул эшне файдалы дип тапкан да, шуларга ярдәм итәр өчен бер җәмгыять ясамакчы була. Сездән киңәш вә ярдәм сорый.

Бер мулла. Менә шул шул инде. Эшнең иң нечкә йире шул җәмгыять дигәнемез инде.

Салих. Җәмгыять димә алай булса!

Берәү. Убщества диикмени?

Салих. Бер сүз дә әйтмә. Укыт та ашат кына.

Берәү. Юк, җәмәгать, бунын артында бер-бер нәрсә юкмы? Бунын арт ягы начар булып чыкмасмы? Без инде шул җәмгыятьне ачыйк, инде бу кяферләр безгә килеп, инде шул җәмгыять — убщества инде. Убщества булгач, ул урыс эше инде. Шулай булгач, ник сезнең почмагыңызда юк димәсме? Без шуларны уйларга кирәк!

Халык. Дөрест, дөрест! Урыска ышанырга ярамый!

*Муафикъ* — туры килгән, яраклы.

Ш ә р и ф  б а й. Әле бит бунда урыс юк ләбаса. Әле бит үзара кычкырышамыз.

Б е р ә ү. Аның арт ягыннан урыс килеп чыкмасын димез!

М ө ә з з и н. Куркыныччлы хәл инде. Бай, шул, шундый шөбһәле эшләр ясап калдырганчы, үзенә әһле голямадан догачылар калдырса?

Ш ә р и ф  б а й *(кызып)*. Менә инде, җәмәгать, актык сүз: мин инде карт кеше. Мин инде үләргә хәзерләнәм. Менә шул, башка шәһәрләрдәге кеби җәмгыять ачсаңыз, шунда мөэмин-мөселман бергә булып карарга булсаңыз, мин ун мең сум акча калдырам. Юк икән инде, ул акчаны мин бүтән шәһәргә бирәм.

Х а л ы к. Ачамыз, ачамыз!

М у с а  м и р з а. Менә инде, җәмәгать, ишеттегезме инде? Шәриф абзый бик зур акча калдырырга тели. Вәт, без инде, хәзрәтләр фатиха бирсә, шул җәмгыятьне ачыйк инде.

Б е р  к е ш е. Кирәкми, кирәкми!

С а л и х *(бер кешегә)*. Син кирәкми дисең дә, шул фәкыйрьләрне үзең карарсыңмы соң?

К е ш е. Мин карый алмасам, Алла карар.

М у с а  м и р з а. Менә, хәзрәтләр, сез шуңарга фатиха биреңез инде.

Б е р  м у л л а. Әйе, ул шул, мирза әфәнде, китапта бер дә андый җәмгыять дигән нәрсә күренми. Без дә шул Алла хозурында җавапка калмыйк димез.

Б е р  б а й. Хәзрәтләр, без усаллыкка тырышмыймыз инде. Шул фәкыйрь-фокарага ярдәм итешергә инде.

М ө ә з з и н. Соң инде, ул убщества булгач!

М у с а  м и р з а. Убщества түгел, җәмгыять.

М ө ә з з и н. Йә, җәмгыять диик инде. Мулла-мөәззинне бөтенләй онытмасламмы инде? Менә Казанда әле, мулла-мөәззин хакы булган зәкятне дә шул убществага бирергә телиләр, имеш. Бездә дә шундый бидгатьләр булмасмы?

Б е р ә ү. Ул бит имамине карау һәркемгә тиеш инде. Иншалла, алай булмас. *(Муллалар бер-берсе берлә сөйләшәләр.)*

Б е р ә ү. Әле, хәзрәтләр, без барымыз да шунда бит. Андый-бундый дингә мохалиф эш булса, агай-эне берлә киңәш итеп туктатырмыз.

Җ а м а л  к о д а. Вакыт үтеп китмәсме?

Б е р  м у л л а. Аллага тапшырдык инде, җәмәгать.

---

*Мохалиф* — каршы килә торган.

Шәриф абзый да мәхәллә картымыз, аның күңелене дә калдырмыйк инде. Инде, алай булса, бер фатиха бирик. *(Кул күтәреп дога кылалар.)*

Бер мулла *(шуннан соң)*. Әһле исламга файдалы булсын инде.

Халык. Амин!

Шәриф бай. Менә инде, алай булса, Муса мирза, син инде уставны укы.

Муса мирза *(кесәсеннән кәгазьне чыгарып, күзлегене киеп караштыргалап, Салихка бирә)*. Мә әле, сез укыңыз әле, Салих әфәнде!

Салих *(укый башлый)*. «Җәмгыятьнең, кавычкада убщества, максаты...»

Халык. Убщества кирәкми, убщества кирәкми!

Җамал кода. Сез безне шулай алдап, безнең артта убщества ясамакчы буласызмы? Әйттем бит, арты начар дип! *(Халык тавышлана.)*

Шәриф бай. Шул сүзне сыз!

Салих *(кулындагы карандашы берлә сызып)*. «Җәмгыятьнең максаты — халкымызның мохтаҗ тарафларына ярдәм итмәктер...»

Бер кеше. Ул ник карандаш берлә генә сызды? Убщества дигән сүзне бөтенләй кырырга кирәк!

Муса мирза. Әйе, әйе, дөрест, каләм *(«Каләм» дигән сүзне мишәрчә әйтә.)* берлә сызарга кирәк.

Халык *(кычкырып)*. Боз! Боз! *(Салих кара берлә боза.)*

Берәү. Бунда «халкымыз» дигән. Нинди халкымыз? Ник аны бөтен мөселманның димәгән?

Салих. Безнең максат бөтен мөселманга хезмәт түгел.

Бер кеше. Ник булмасын, бөтен мөселманга хезмәт! Бөтен мөселман безнең дин карендәше түгелмени?

Тавыш. Бөтен мөселман, бөтен мөселман!

Салих. Бөтен дөньяның мөселманына без ярдәм итә дә алмыймыз, аны үземезгә максат итеп ала да алмыймыз. Безнең анлык көчемез юк!

Берәү. Ник булмасын? Әлхәмдүлиллаһ, без мөселман!

Бер хәлфә. Әйе, Аллаһе Тәгалә җәнабләре һәрнәрсәгә кадир инде. Алла ярдәм бирсә, барысына да көчемез йитәр!

Берәү. Әлегә, җәмәгать, бит көчемез йитмәгәне күренеп тора. Без хәзергә карап эш йөртергә кирәк. Көчемез булса, тагы җәмгыять ачармыз.

---

*Кадир* — көче чикләнмәгән.

Б е р ә ү. Юк, аны хәзер ныгытып куярга кирәк. Ул калган эшкә кар ява, ди.

Х ә з р ә т. Әйе, «бөтен мөселманга» дияргә кирәк.

М у с а м и р з а. Әйе, җәмәгать, ул шулай кирәк инде, «бөтен мөселманга» дияргә кирәк. Вәт, без барымыз да шул уйда инде. Ну, вәт, бездә тагы бернәрсә бар: миссионерлар дигәнемез риза булырмы? Миссионерлар, вәт, алар бик дошман; минем нишләгәнне карап кына торалар. Алар, вәт, бу Муса мирза мөселманга файдалы эш эшләмәсен дип, аяк чалырга гына торалар. Вәт, алар мине банкка кертмәс өчен сенатка кадәр барып йиттеләр.

Х ә з р ә т. Әйе инде, мирза әфәнденең керүе яхшы булды. Шундый банка кеби акчалы йирдә үз кеше булгач, агай-энегә йиңел була инде.

М у с а м и р з а. Вәт, алар шуның өчен мине кертмәскә теләделәр. Менә вәт, әле беркөн бер мөселманга акча бирмәскә телиләр. Тегене глупый татарин дип тиргиләр. Мин шуны күрдем дә, вәт, сез законга каршы киләсез, дип, законны ачып күрсәткән идем, үзләре исләре киттеләр. Вәт, анда закон белүнең дә нәтиҗәсе күп. Шуннан соң мине мөселманский частька директор баш итеп куймакчы булды. Теге бәдбәхетләр, вәт, риза булмадылар. Шуның өчен әйтәм: без бик зур башлап кечкенәсеннән калмыйк, дим! Безне тегеннән, банктан шылдырмасыннар, дим!

Х а л ы к. Әйе, әйе, анысы дөрест!

М у с а м и р з а. Вәт, беркөн бер миссионер килгән. Директордан, бер баланы урыс итәргә акча биреңез, ди. Мин дидем: не смей, закон юк! Бирмәделәр. Мин булмасам, вәт, бирерләр иде.

Х а л ы к. Рәхмәт, мирза! Рәхмәт!

М у с а м и р з а. Вәт, минем үземә дә йиңел килми. Бер көн карасам, урамда баралар. Тукта әле, бу бәдбәхет нишли икән, бу безнең мөселманга зарарга йөрмиме, дип уйладым. Чыктым, исәнлек-саулык сораштым. Беләм, теге бәдбәхетләрнең минем берлә сөйләшәселәре килми. Берсе миссионер, берсе чиновник. Миссионер тегене миннән аерырга тели. Мин: юк, дидем, мирзаң сезнең кебекләрне күргәне бар, дидем, чиновникны аерып алдым. Вәт, вәт, шул каһәрнең *(мишәрчә әйтә)* эч серене алыр өчен гостиницага алып кердем. Тегенең бөтен эч серене түктердем. Шуннан теге миссионер, вәт, миннән куркып шәһәрдән китте. Ә шуны берсе күргән дә, мирза эчеп йөри, ди. Юк, мирза эчеп йөрми! Мирза дин өчен үз акчасын да кызганмаенча серләр алып йөри, серләр! Аны белергә кирәк!

Х а л ы к. Рәхмәт, рәхмәт!

Б е р м у л л а. Әйе, мирза сүзе дөрест, җәмәгать. Буны инде шул көенчә калдырырга кирәк. Ул андый-бундый эш булып китеп, банкта сизә күрмәсеннәр!

С а л и х *(тагы бер кат укый)*. «Җәмгыятьнең максаты — халкымызның мохтаҗ тарафларына ярдәм итмәктер». Менә бу маддә ярыймы инде? Шуны кабул итәмезме?

Б е р ә ү. Ник «халкымыз» дигән? Урыслар: «Без дә халык, безгә дә ярдәм ит!» димәсләрме?

М у с а м и р з а. Бу сүз дөрест. Вәт, җәмәгать: «Мөселман халкымызның» дияргә кирәк.

Х а л ы к. Әйе, әйе!

Х ә л ф ә. «Мөэмин-мөселман» дияргә кирәк.

М у л л а. Ул инде, «мөселман» булса, «мөэмин» кирәк түгел. «Мөэмин» булса, «мөселман» кирәк түгел. Алар әлфазә мөтәрадифә инде.

Х ә л ф ә. Юк, хәзрәт, «мөэмин» «тәэмин»дән мөштәкъ, «мөслим» — «исламият»тән мөштәкъ.

Б е р м у л л а. Әйе, әйе, икесе дә кирәк.

Җ а м а л к о д а. «Мөэмин-мөселман» урынына «хак мөселман» дияргә кирәк. Хак мөселман булмаган кешегә ярдәм итү — гөнаһлы эш.

С а л и х. Ничек кешенең хак мөселманмы, түгелме икәнене беләсең? Кешене эченә кереп карап булмый!

Җ а м а л к о д а. Әһле голяма юлы берлә йөргән кеше хак мөселман була.

Х а л ы к. Дөрест, дөрест!

М у с а м и р з а. Әйе, ул сүзне куй, ул зарарлы түгел.

С а л и х *(яза)*. Алай булса, менә болай булды инде. *(Укый.)*

«Җәмгыятьнең максаты — хак мөселманның мохтаҗ тарафларына ярдәм итмәктер».

Б е р ә ү. Бу, җәмәгать, инде бунда — хак мөселман дигәнмез. Шул хак мөселманның кем икәнене аерыбрак әйтмимезме инде?

Җ а м а л к о д а. Ачык кирәк, ачык кирәк!

Т е г е к е ш е. Менә бит, инде замана бозылды, төрле бидгатьләр күбәйде. Пәйгамбәремез заманасында булмаган нәрсәләр чыкты. Менә шул инде, безнең җәмгыятемез шул бозыклыклар, шул бидгатьләрне бетерергә тырышырга кирәк инде.

---

*Маддә* — статья (законда, уставта), параграф.
*Әлфазә мөтәрадифә* — мәгънәдәш сүзләр, синонимнар.
*Тәэмин* — инану.
*Мөштәкъ* — ясалган, чыгарылган.

Х а л ы к. Дөрест, дөрест!

Т е г е  к е ш е. Шуның өчен менә хак мөселманнан морад әһле голяманы игътибарга алучы, сәләфе салихин юлы берлә йөрүче дигән сүзне кушыйк, дим!

Х а л ы к. Мәслихәт, мәслихәт!

Т а г ы  б е р  к е ш е. Җәмәгать, бит әле менә шул: соңгы елларда ата-ана сүзене тотмау бик куәтләнеп китте. Менә күз алдымызда: Әхмәди абзыйның угылы атасыннан фатиха сорамаенча чыгып китте. Хәлил абзыйның угылы аталарына каршы килеп өйләнде. Менә шундый начарлыкларны бетерер өчен мин, ата-ана фатихасыны алган кеше дигән сүзне дә кушыйк, дим!

Т а в ы ш. Кирәк, кирәк!

Б е р  б а й *(калын корсаклы)*. Мин инде әйтә дә белмим. Менә шул инде, әле менә без хезмәт иткәндә байдан калтырап тора идек. Байны ата урынына күрә идек. Ул суга керергә кушса, суга керә идек; ул утка керергә кушса, утка керә идек. Бу елда менә шул, приказчиклар арасында шул инсаф бетте. Байлардан рөхсәт алмаенча чыгып китә башладылар. Аз-маз акча ясап, байларына көндәш булып, аларның фатихасыннан башка үзләренә эш башлый башладылар. Эшкә өйрәтер өчен суксаңнитсәң, судларга бирә башладылар. Болар бит инде, җәмәгать, мөселманлык түгел. Менә шуларны да шул җәмгыятемезгә кертәсе иде, дим. Анда инде үзеңез ничек икәнлегене карарсыз.

М у с а  м и р з а. Бу инде, әле Вәли абзыйның әйткәне, инде шул булды кебек күренә. Ул әйтә: вәт, бу безнең хезмәтче халык бозылды, диде.

Х а л ы к. Дөрест, дөрест!

М у с а  м и р з а. Ул инде, вәт, шуларны да шунда кушыйк, ди. Минемчә, бу мәслихәт! «Баеннан фатиха алган хезмәтчеләргә» дияргә кирәк.

М у л л а. Әйе, әйе, ул инде, андый бидгатьләр күбәя башлады инде. Әле үземезнең асрау гына, кем булган соң инде, шул да абыстасының сүзенә тел кайтарып, ирек бирсәң, оршышмакчы булып тора инде.

Х ә з р ә т. Әйе, китап инде хуҗасына итагать кылсын дигән. Улсы инде шәргы шәрифкә муафикъ.

М у с а  м и р з а. Йә инде, соң безнең бу беренче маддә ничек була инде?

С а л и х *(укый)*. «Җәмгыятьнең максаты — хак мөселманның мохтаҗ тарафларына хезмәттер». Шуннан соң инде йолдыз берлә: «Хак мөселман»нан морад: әһле голя-

---

*«Хак мөселман»нан морад* — «хак мөселман» дигән сүз ул...

маны игътибарга алучы, сәләфе салихин сүзе берлә йөрүче, ата-ана фатихасыны алучы, байларның рөхсәтеннән башка үзеннән эш башламаучы», димез инде.

Җ а м а л к о д а. Мин әле буны аңламадым. Менә инде, бу соңгысы кая языла инде?

С а л и х. Ул бу маддәдән соң языла инде.

Җ а м а л к о д а. Юк, ул алай булгач, аны беркем дә санга санамавы бар. Ул шунда, «хак мөселман»нан соңда булсын!

С а л и х. Алай мәгънәсе тугры килми.

Х а л ы к. Килер, килер! Җамал кодача булсын!

М у с а м и р з а. Шулай булсын. Йә әле, укып кара әле. Без аны мәгънәсе тугры килмәсә, үзгәртермез, вәт.

Б е р ә ү. Үзгәртмимез.

С а л и х *(укый)*. «Җәмгыятьнең максаты — хак мөселманның («хак мөселман»нан морад: әһле голяманы игътибарга алучы, сәләфе салихин юлы берлә йөрүче, ата-ана фатихасыны алучы, байларның рөхсәтеннән башка үзеннән эш башламаучы») мохтаҗ тарафларына ярдәм итүдер».

М у с а М и р з а. Әйе, сүзе бик колакка ятып бетми кебек күренә. Сезгә ничек, Җамал абзый?

Җ а м а л к о д а. Ярый, ярый!

Х а л ы к. Ярый, ярый!

С а л и х. Мәгънәсе дөрест булмый, аңлашылмый бит!

Х а л ы к. Аңлашыла, аңлашыла! Шулай кирәк, шулай!

Б е р п р и к а з ч и к. Әле бу заманаларда байлар арасында хезмәтчеләрне гөнаһсыз йиргә рәнҗетүчеләр күбәйде. Аз гына ачуы килсә, куып чыгара. Менә бундый «урынсыз йиргә хезмәтчеләрене рәнҗетмәүчеләргә» дигән сүзне кушарга кирәк.

Т а в ы ш. Юк, юк!

Б е р ә ү. Яхшы хезмәт иткән кешене беркем дә рәнҗетмәс! Кирәкми!

Т а в ы ш. Кирәкми!

Х ә з р ә т. Ул инде, мөселман кеше алай рәнҗетмәс инде. Гөнаһ икәнлегене белә бит инде. Рәнҗетә икән, әле бит кыямәт бар. Сезгә Аллаһе Тәгалә аның өчен әҗерене бирер. Китап әйткән: гөнаһсыз золым кылынган кешене сират күпереннән яшен кеби үткәрер, дигән. Аның алдында инде оҗмахның ишекләре ачылыр, дигән!

Б е р к а р т. Әйе, әйе, сабыр итәргә кирәк шул!

П р и к а з ч и к. Ник без генә сабыр итәргә кирәк? Көчләсәләр дә сабыр итәргәмени?

М у л л а. Әйе, әйе! Шуның өчен савабы булыр.

П р и к а з ч и к. Байлар сабыр итсен, савабы аларга да булыр.

М у л л а. Әй ахмак, кафер сөйлисең! Тәүбә кыл, китапка ышанмыйсың!

Т а в ы ш. Ташла, ташла! Ни сөйлисең! *(Приказчик туктый.)*

М у с а м и р з а. Соң, җәмәгать, шулай ярыймы инде?

Х а л ы к. Ярый, ярый!

М у с а м и р з а. Икенче маддәне укы инде.

С а л и х *(укый)*. «Шул максатыны тотар өчен җәмгыять мәктәпләр ачарга, кичке дәресләр ясарга, зурлар вә кечкенәләр өчен кирәкле һөнәрләр өйрәтергә юл ачачак һәм дә кирәкле китаплар бастырырга тырышачактыр».

М у с а м и р з а. Бусы ничек, җәмәгать?

Җ а м а л к о д а. Ул ник анда «мәктәп» дигән? «Мәктәп» бит урысча «ышкул» дигән сүз. Безгә ышкул кирәк түгел! Без, әлхәмдүлиллаһ, мөселман!

Х а л ы к. Дөрест, дөрест! Ышкул кирәкми! Кирәкми!

С а л и х. «Мәктәп» дип низамлы мәдрәсәне әйтәләр.

Җ а м а л к о д а. Ул нинди низамлы мәдрәсә! Мөселманның низамы буламыни? Бездә, әлхәмдүлиллаһ, низаммизам юк!

Х а л ы к. Кирәкми, кирәкми! Ышкул кирәкми! Низам кирәкми!

Б е р ә ү. Туктаңыз әле, җәмәгать! «Низамлы мәдрәсә» дигән сүз ул бик куркынычлы сүз түгел. Мәсәлән, балаларның вакытлы сабакка килүләре-китүләре, аның соңында бергә-бергә шәрик булып укулары дигән сүз. Бу бит, хәзрәтләр, инде шәригатькә каршы түгелдер?

Х ә з р ә т. Әйе, ул инде шул, мулла кем, әһле голяманы кысу була инде. Мәсәлән, сабакны вакытлы ясыйк инде. Әлбәттә, бит вакыт инде намаз вакыты берлә йөри. Мәсәлән, инде иртә намаздан алып өйлә намазына кадәр диик инде. Ярый инде, үлем-җитем булса, мәсәлән, бит җеназа намазы, ахрысы, фарыз бит инде. Әһле голяма вакытлы дип җеназадан кала алмый шул инде.

М у л л а. Тагы аш була, туй-төшем була. Вакытлы булгач инде, безгә шул бер йиргә дә бармаска кирәк була инде. Ул теге урысларныкы кеби вакыты берлә кыңгырау кагып керергә, кыңгырау кагып чыгарга була инде.

Т а в ы ш. Кыңгырау кирәкми, кирәкми!

Ш ә р и ф б а й. Әле соң кыңгырау дигән кеше юк ләбаса! Менә шулай тәртипләбырәк укытсын димез шул. Менә мин йиде ел укыдым, уникe «Һәфтияк» туздырдым, язу

---

*Низамлы* — режимлы, тәртипле, кагыйдәле.

да танымадым. Шул инде, хәзрәтләр, минем язу тануым, дин белүем гөнаһмыни?

Хәзрәт. Юк, эш анда түгел, Шәриф абзый. Сез менә, әлхәмдүлиллаһ, укый алмасаңыз да әһле голяманы никадәр карадыңыз. Аллаһе Тәгалә әҗерене насыйп итсен. Ул инде, «низамлы уку» дигәч, ысуле җәдиткә тарту була инде.

Тавыш. Ысуле җәдит кирәкми! Кирәкми!

Муса мирза. Ул «мәктәп» дигән сүзне «мәдрәсә» дип алмаштырыйк алай булса. Җәмәгать, шулай ярыйммы?

Мөәззин. Ул, «мәдрәсә» дигәч инде ул, шул яңа мәдрәсә ачу буламыни инде? Безнең шәһәрнең, әлхәмдүлиллаһ, мәдрәсәләре бар бит. Әле ул, мәдрәсә булгач, мәсҗеде дә кирәк була инде. Ул вакытта мәхәллә аеру була инде. Үзеңезгә мәгълүм бит, җәмәгать, әлхәмдүлиллаһ, мәсҗедләремез әһалисене сыйдыра бит әле.

Хәзрәт. Әйе, әйе. Ул инде, җәмәгать, шул бар мәдрәсәләремез, мәсҗедләремез берлә канәгатьләнү мәслихәт булыр инде.

Берәү. Хәзрәтләр! Бит ул мәсҗед салу инде дин арттыру була инде. Ул саваплы эш инде.

Хәзрәт. Һәр йирдә түгел инде. Мөселман арасында фетнәгә сәбәп булса, файдалы түгел инде.

Муса мирза. Ул, вәт, хәзрәтләр, әле мәдрәсә ачамыз дигән сүз түгел. Бервакытны безгә мәдрәсә кирәк булса, мәдрәсәләр янып китсә, Алла казасыннан сакласын, шул вакытта мәдрәсә салырга права алып калыйк димез. Вәт!

Халык. Ул гакыл, ул гакыл!

Муса мирза. Без инде аны бик нечкә уйладык. Ул мирза инде белми эшләми. Әле инде җәмгыять дип без рөхсәт ала аламыз. Тегеләй, вәт, җәмәгать, мәдрәсә ачарга дип сорасаң, вәт, ул каһәр миссионерлар, бу Муса мирза безнең башка бәла ачмасын дип куркалар. Вәт, алар бирмәсләр.

Халык. Алай булса калсын, калсын!

Җамал кода. Сәләфләр юлы берлә «Иман шарты» укыта торган мәдрәсә диеңез!

Салих. Улсы нәрсәгә инде аның? Мин анда укырга керсәм, мин ни дип «Иман шарты» укыйм инде? Мин аны белмиммени?

---

*Әһали* — кешеләр, халык.

Җ а м а л  к о д а. Белсәң, укып күрсәт!

С а л и х. Мин монда имтиханга килмәгән.

Җ а м а л  к о д а. Менә алар бар да шулай. Бар да «Иман шарты» белми.

Х а л ы к. «Иман шарты» укылсын! Укылсын!

Б е р ә ү. Җәмәгать, әбҗәде калдырылмасын!

Х а л ы к. Дөрест, дөрест! Калдырылмасын!

М у с а  м и р з а. Дөрест, җәмәгать! Имансыз эш булмый. Әбҗәд кирәк. Син аны, Салих әфәнде, яз. *(Салих яза.)*

Б е р ә ү. Җәмәгать! Менә бит әле, бу ел шул мәдрәсәгә спиктыр (инспектор) керә дип һаман куркыталар. Без шунда инде аны беркетеп куйыйк. Эспиктыр кермәсен дип языйк!

Х а л ы к. Языйк. Языйк!

М у л л а л а р. Әйе, әйе, мәслихәт!

С а л и х. Җәмәгать! Бу әле бер җәмгыятьнең уставы. Анда без җәмгыятьне нинди ясарга теләгәнне генә күрсәтәмез. Без бит алай инспектор кермәсен дип закон чыгара алмыймыз. Без бит падишаһ түгел.

Җ а м а л  к о д а. Юк, кермәсен!

Х а л ы к. Кермәсен, кермәсен!

С а л и х. Мин дә керсен, димим. Ләкин аны уставка язу мәслихәт түгел.

Б е р ә ү. Минемчә дә шулай, җәмәгать. Ул, алай булгач, әллә нindирәк булып китә инде. Без бит әле, әлхәмдүлиллаһ, менә шул тугрыда министрга да прашения бирдек. Шул безнең файдага чыгар димез бит. Шулай булгач, бу сүзне калдырырга кирәк.

М ө ә з з и н. Министр үз алдында, монысы үз алдында. Юк, бунда да беркетеп куярга кирәк!

Т а в ы ш. Анда да яз, яз! Эспиктыр кермәсен! *(Салих яза.)*

Җ а м а л  к о д а. Ул анда «кичке дәресләр» дигән. Ул ни дигән сүз була инде?

С а л и х. Менә яшь вакытында укый алмаган кешеләргә, көндез вакыты булмаенча укый ала алмый торган кешеләр өчен кичләрдә сабак укытулар инде.

Б е р ә ү. Ә ул кичке сабак була инде. Сүрәләр бикләү, «Иман шарты»ны ядка алу, догалыклар өйрәнү була инде.

С а л и х. Ул гына түгел. Язарга, укырга да өйрәтелә.

М ө ә з з и н. Ул ул чакта ничек булыр икән инде? Ул алай кичке сабак булмый була инде. Ул инде урысларча-

---

*Прашения* (прошение) — үтенеч, гариза.

рак була. Ул инде искедән калган гадәтнең киресе була. Әле бит кичке сабакта вирдләр өйрәнү, сүрәләр ятлау була иде. Бу башка була инде. Белмим инде, бунын хакында китап ни әйтер?

Берәү. Бундый эшләр соң, хәзрәтләр, пәйгамбәремез заманында булганмы инде?

Хәзрәт. Анысы шөбһәле инде.

Җамал кода. Ул алай шөбһәле дә булса, аны калдырып торыйк!

Халык. Калдырыйк, калдырыйк!

Салих. Юк, аны калдырырга ярамый. Менә хәзер укыйсы килә торган зур кешеләр бар, ул шулар өчен инде.

Берәү. Ә, мин белдем. Бу урысларның теге баскрисни (воскресный) ышкуллары була икән! Ул кирәкми!

Халык. Юк, кирәкми! Кирәкми!

Шәриф бай. Туктаңыз әле, җәмәгать! Мин аны нинди икәнене белмим. Менә шундый укыта торган йир булса, мин яшь вакытымда укырга өйрәнгән булыр идем.

Берәү. Ышкул булса дамы?

Шәриф бай. Ышкул булса да.

Халык. Юк, безгә ышкул кирәкми! Кирәкми!

Муса мирза. Бу да, җәмәгать, үземезчә гакыл берлә эшләнгән, вәт! Без, вәт, аны теге каһәр кяферләрне алдарга дип эшләдек. Вәт, алар тик менә: болар безнең кебек укытырга тели икән, дисеннәр. Ә без тотармыз да үземезчә укытырмыз. Без кичке сабак ясармыз. Ул, вәт, җәмәгать, безнең эш.

Халык. Дөрест, дөрест! Мирзача булсын, мирзача!

Берәү. Юк, җәмәгать, ул кичке дәресләр дигән сүзне кичке сабаклар дияргә кирәк!

Салих. Дәрес берлә сабакның аермасы юк, ул барыбер.

Берәү. Юк, җәмәгать. Бу боларның ул «дәрес» дигәннәрендә минем шөбһәм бар. Аларның максудлары кичке сабак булса, ник алар үзләре үк «кичке сабак»-димәгәннәр? Буның арты хәерле булмас!

Мөәззин. Бунда, тагы бит әле, эшнең дин ягы бар. *(Салихка күрсәтеп.)* Менә бу әфәнделәр инде дингә илтифат итмәсәләр дә, безгә дингә бик нык ябышмаенча ярамый. Әлхәмдүлиллаһ, динемез — дине ислам. Шуның шөкранәсене белергә кирәк.

Тавыш. Бик дөрест! Бик дөрест!

Мөәззин. Шулай булгач, китапларда әйтә: кич берлә намаз-нияз берлә мәшгуль булсын, ди. Дөнья булгач төрле хәл була, җәмәгать, кайвакыт намаз казага кала. Ул кич

берлә дәрес укылса инде... намазлар каза кылып булмый инде. Ул намазны калдырырга ярый инде дигән сүз була инде... Бу бит, җәмәгать, намазны йиңелгә санау була. Ул бит көфер инде.

Т а в ы ш. Дөрест, дөрест!

Б е р я ш ь б а й. Мөәззин әфәнде әле бик эчкә кереп китте...

М ө ә з з и н *(аны бүлеп)*. Безгә эчкә кермәенчә ярамый. Без мулла-мөәззин кайгыртмасак, динне кем кайгыртыр инде!

Я ш ь б а й. Дин кайгырту бик яхшы эш. Ләкин һәрнәрсәдән дингә зарар китереп чыгару ярап бетми. Кич берлә дәрес укуда диннең кай тарафына зарар була?

Х ә л ф ә. Улсы инде аның укытуында. Сәләфләр юлы аяк астына тапталмаса, кич укуда зарар булмас инде. Безнең дамелла да тәбәррек китабыны кич караучан була иде. Кич зиһен ачык булучан дия иде.

С а л и х. Алай булса, бу маддә ярыймы инде?

Җ а м а л к о д а. Йә әле, тагы бер укы әле.

С а л и х *(укый)*. «Шул максатыны тутырыр өчен җәмгыять мәктәпләр...»

Б е р ә ү. Мәктәп түгел, мәдрәсә бит?

С а л и х. Анысы шулай калды бит?

Х а л ы к. Юк, юк! Мәдрәсә, мәдрәсә!

С а л и х. Алай булса, менә болай була инде. *(Укый.)* «Шул максатыны тутырыр өчен җәмгыять «Иман шарты» һәм «Әбҗәд» укыла торган мәдрәсәләр ачарга, кичке дәресләр ясарга, зур вә кечкенәләр өчен һөнәрләр өйрәтергә юл ачачак һәм дә кирәкле китаплар бастырырга тырышачактыр».

Җ а м а л к о д а. Бунда, җәмәгать, бер бик зур эш бар икән әле. «Китаплар бастырырга» дигән. Бу инде китаптан морад бунда «Бәдәвам» булмый инде?

С а л и х. Китап «Бәдәвам» гына түгел, кирәкле китапның барысы да.

Җ а м а л к о д а. Юк, «Бәдәвам» инде. Әле бит шул «Бәдәвам»ны бастырмыйлар шул инде. Менә шуны, җәмәгать, беркетеп куярга кирәк. Ул андый бастырмау булмасын.

Б е р ә ү *(Муса мирзага)*. Син, мирза, инде аны банкада сөйлә! Без «Бәдәвам»сыз ничек торыйк? Балаларымызни укыр?

Я н ә б е р ә ү. Җәмәгать, бу бик зур эш! Аллаһе Тәгалә ярдәм бирсә, без шуны шулай итик инде. Ул «кирәк

---

*Китабтан морад* — китап дигән сүз ул...

китаплар» урынына «Бәдәвам» гына дисәк яхшы булыр. «Бәдәвам»нан кирәк китап юк бит!

Халык. Шулай, шулай!

Мулла. Җәмәгать! Бит әле бу мохтәсарда «Китабе җиһад»ны бастырмый башладылар. Шуны да кертик инде!

Халык. Кертик, кертик!

Салих. Ул инде «кирәкле китап» дигәч, шунда барысы да керә. Ник аны «Бәдәвам» диярга кирәк?

Халык. Юк, юк! «Бәдәвам» диик, «Бәдәвам»!

Бер мулла. Җәмәгать! Менә бит бу урыс халкы әле рәдде нәсара китапларыны бастырырга рөхсәт бирми. Мисал инде: ул аларның диннәрене рәдде кыла торган китаплар. Ул бит бик файдалы инде. Аларны берсе-берсе укыса, һидайәт тапмаенча калырлык түгел инде. Менә шуны да, җәмәгать, кертик инде. Менә минем үземнең дә шул миссионерлар берлә моназәрә хакында язган нәрсәләрем бар.

Халык. Ә, куркалармы? Безнең диннән куркалармы? Кертик, кертик!

Муса мирза. Менә, җәмәгать, вәт, без шуларның барысын да уйлаган. Ул, вәт, «Бәдәвам» дисәк, теге каһәрләр: «Хәзер бу Муса мирза нишли»,— дип киртә салмасын димез.

Җамал кода. «Бәдәвам»нан башка тора алмыйбыз инде.

Муса мирза. Мин, вәт, Җамал абзый, беләм. Мин бик үк күп укымасам да, әлхәмдүлиллаһ, мөселманга ни кирәкне беләм. Мин, вәт, аны әллә кайчаннан кайгыртам. Әле, вәт, кичә генә шуның хакында банкның башы берлә сөйләштем. Иван Васильевич, вәт, закун юк бит, дим. Ник, дип сорый. Мин тегеңәр закун ачып күрсәтәм. Син, ди, Муса Сапиич, безнең профессорлардан күп беләсең, ди. Синең сүзне тутыру авырын авыр инде, миссионерларга көч була инде, әйдә, синеңчә булсын, «Бәдәвам» басылсын инде, ди. Менә вәт, ул белеп йөрткәч ниләр була.

Халык. Рәхмәт, мирза, рәхмәт!

Муса мирза. Әле тагы хәзрәт миссионерлар берлә моназәрә кылышу тугрысында сөйләде. Ул бит минем эчне күптән тырный. Вәт, әле шул арада гына без шул банкта сөйләшеп киттек. Вәт, мин үземезнең диннең

---

*Рәдде нәсара* — христианлыкны кире кага торган.
*Һидайәт* — туры юл.
*Моназарә* — бәхәс, сүз көрәштерү.

*(динне «днъ»* ди)* артыклыгыны сөйләгәч, шаккаттылар. Барысы да, Муса Сапиич, вәт, без бүген мөселман булыр идек... тә, ярамый гына, диләр. *(Салихка.)* Өченче маддәне укы!

Салих *(укый)*. «Җәмгыятьнең члены булу өчен елына ун сум түләү тиештер. Гомерлек члены буласы килгән кешеләргә берьюлы өч йөз сум түләргә тиештер...» Бунсында инде һәммә йире ачык күренә. Бунда сөйләп торырга урын юк инде. Бу һәммә җәмгыятьтә шулай була инде.

Бер хәлфә. Бунда инде менә, хәзрәтләр, мин «члин» дигән сүзне аңламыйм. Ул инде әле безнең Духовный собраниянең члиннәре бар бит. Ул шулар кеби, мирза була дигән сүзме инде? Алай булса инде, җәмәгать, мин риза түгел. Имтиханга барган һәркемгә мәгълүм бит, андагы мирзалар шәкертләрнең кәвешләрене яшереп йөдәтеп бетерәләр, һәм дә үзләре шәргы шәрифкә сыймый торган киемнәрдә йөриләр.

Берәү. Ул «мирзалар шәкертләрнең кәвешене яшермәсен» дигән сүзне шунда кертсәк ярамасмы, җәмәгать?

Мулла. Юк, анысы мәслихәт түгел, мөфти хәзрәттән яхшы түгел! Бит без һәммәмез дә аның кул астындагы кеше.

Мөәззин. Ул «члин» дигән сүз бунда сабрания члине дигән сүз түгел инде. Бу урысча инде. Менә безнең акружный судка ант иттерергә барганда «члин суда» дигән кешеләр була. Шулар кеби буламы инде?

Берәү. Ул шул безнең мөселманнар инде, шул «члин суда» кеби, әллә нинди укалы киемнәр киеп йөрергә булыр микән? Ул бит безнең шәригатьтә, хәзрәтләрдән узып булса да әйтим, көмеш кием кияргә ярамый.

Хәзрәт. Әйе, әйе! Алтын-көмеш, ефәк нәрсәсе ирләргә мәмнугъ инде.

Мулла. Ул «члин» дигәне, мөәззин, урыс лөгате булмаска кирәк.

Мөәззин. Урысча, урысча. Мин бит урысча беләм. Мин бит 18 елдан бирле акружныйга антка йөрим.

Хәлфә. Ул урысларда истигъмаль кылынса да, Әндәлес гарәпләреннән кергән булырга кирәк. Ул, асылда, «җәлин» булырга кирәк. Ләкин урыс халкында «җ» хәрефе булмаганга, аны «члин» дип әйтәләр.

---

*Бу сүз оригиналда рус хәрефләре белән басылган.
*Шәргы шәриф* — изге шәригать.
*Мәмнугъ* — тыелган.
*Лөгать* — бу урында: сүз.
*Истигъмаль кылыну* — кулланылу.

Х ә з р ә т. Әйе, әйе! Ул урысларның һәрнәрсәсе гарәпләрдән алынган инде.

Х ә л ф ә. Ул инде ул вакытта «җәлән яҗлину»дән килгән буламы? Дараба йәдрибу бабыннан?

Х ә з р ә т. Юк, ул фигыль вәзенендә бит! Исме сыйфат була инде. «Дараба йәдрибу»дан түгел инде, «хәмидә йәхиму»дән булырга кирәк.

Б е р ә ү. Аның инде, бу, гарәпчә мәгънәсе ничек була инде, хәзрәтләр?

Х ә з р ә т. Менә бунда, Шәриф абзый, лөгать китабы булса яхшы булыр иде. Бар микән?

М у л л а. «Әхтәри»дә юк. «Укыянус»та булмаса.

Б е р я ш ь е г е т. Бездә «Укыянус» бар.

Х ә з р ә т. Китер әле.

Я ш ь б а й. Хәзрәтләр! Ул бер дә гарәп сүзе түгел, ул урыс сүзе. «Члин» дигән сүз — «әгъза» дигән сүз. Мәсәлән, алар кулны «члин» диләр. *(Шул арада егет китап китерә. Муллалар карарга тотыналар.)* Шуның өчен бу сүзне «әгъза» дигән сүз берлә алмаштырып була һәм дә китап карарга ихтыяҗ да калмый.

Б е р ә ү. Китап карауның зарары юк. Без һәммә эшемезне китап боерыгынча йөртергә кирәк.

Муллалар, мыкыр-мыкыр сөйләшеп, китаплар актаралар.

М у с а м и р з а. Әйе, әйе! Без шул китап Коръән өчен, вәт, инде тырышамыз. Хәзрәтләр карасыннар. *(Салих янына бер яшь кеше килә. Анлар янына Муса мирза килеп.)* Көлкеме, Салих әфәнде! Вәт, менә мин шулар берлә унике ел торам. Вәт, мин шуларны латлап килгән кеше шул. Вәт, эш булсын, милләткә файда булсын дип тырышамыз.

С а л и х. Мин болай тырышудан файда булыр дип белмим. Без укыган кеше, аларның наданлыкларына карап, үземезнең эшемезне аларның наданлыкларына муафикъ итеп эшләмәенчә, аларның эшләрене үземезнең белүемезгә карап эшләргә кирәк. Аларны үземез баскан баскычка кадәр күтәрергә тырышырга кирәк.

М у с а м и р з а. Мин дә, вәт, аны беләм. Ул вакытта, вәт, алар берлә дошман булырга кирәк. Алар, вәт, безгә кире күз берлә карый башларлар.

С а л и х. Карасын. Аюдан курыккан урманга бармый, ди.

М у с а м и р з а. Минем, вәт, җәмәгать бар. Минем, вәт, аларны тәрбия кыласы бар. Вәт, аларны шул ден берлә

---

*Латлап* — җайлап, рәтләп.

бутамасаң кузгатыр да хәл юк! Үзенә шулай кирәк икән, шулай итсен. Ник мин, үземнең мазамны китәреп, аларга каршы килим. Мин аларга шулай-шулай дип кул куеп торган кеби күренәм. Ә эчемнән мин гел сезнең кебек.

Яшь кеше. Анысы шулай да бит, аннан бернәрсә дә чыкмый. Ул бит бу урында таптау гына була.

Салих. Хезмәт итәргә теләсәң, шул авыр йөкне өстерәргә кирәк. Шуны, Иделдә ләмкә тарткан бурлаклар кеби, аны агымга каршы сөйрәргә кирәк. Агым астына ул үзе дә бара.

Муса мирза. Вәт, алар надан: алар бай, вәт, куәт алар кулында; акча алар кулында.

Салих. Бездә гыйлем бар, бездә аңлау бар.

Муса мирза. Шулай, шулай. Вәт, шуның өчен алар безгә үзләренең наданлыгыннан пошлина түләргә кирәк. Безнең гыйлемемез берлә файдаландылармы, безгә процент түләргә кирәк.

Салих. Бу тире сату түгел!

Муса мирза. Шулай ул. Вәт, хәзер мин шул Җамал байга каршы килсәм, ул, вәт, миңа мәңге дошман була. Ул, вәт, хәзер минем юлга киртә сала. Мин аңарга аның яклы күренсәм, мине, вәт, ул үзе кебек күрә. Мин үземне ныгытып йиткәч, вәт, киләм дә, юк, не смей, Җамал абзый! Синеңчә түгел, дим. Бу әле латлау гына! Латламаенча ярамый.

Муллалар сөйләшә башлыйлар. Муса мирза китә.

Салих. Бигрәк былчырак кеше! *(Яшь бай башыны селки.)*

Хәзрәт. Бунда булмады!

Шул арада зур поднослар күтәреп китереп чәй урыны хәзерлиләр, самавыр чыгаралар.

Муса мирза. Бу маддәне, Җамал абзый, кабул итикме инде? *(Халык дәшми тора.)* Бу кирәк инде. Бу тегеләрнең борынына сугар өчен ясалган инде.

Халык. Кабул итик! Кабул итик!

Халык торып йөри башлый. Салих берлә яшь бай бергә торалар. Муса мирза Җамал кода янына килә. Аның янына тагы берничә кеше җыела. Салих берлә яшь бай көлеп торалар.

Муса мирза. Менә әле тегеләр берлә сөйләштем. Аларның күңел каралган, вәт, Җамал абзый! Иман нуры качкан. Вәт, алар безгә мишать итәләр. Әле шуларны үгетләдем. Ден, вәт, бар, дим. Синең денең кирәкми, ди. Вәт, ул андый сүздән Алла сакласын!

Җамал кода. Алар кяфер инде, кяфер!

Халык. Кяфер, кяфер!

Муса мирза. Вәт, шулар ук миңа дошман булып йөри. Бер яктан тегендә миссионерлары, бер яктан болары. Муса мирзаң чыдасын гына!

Халык. Рәхмәт инде, рәхмәт!

Шул арада бер кеше килеп керә.

Кеше. Хәзрәтләр! Җеназаны алып килделәр.

Муллалар *(торып.)* Җеназа укып йибәрик инде алай булса.

Мулла. Тәһарәте булмаганыңыз тәяммем генә кылыңыз! Паласка, киемгә тәяммем дөрест дигәннәр.

Берничә кеше кулларыны сугып-сугып тәяммем кылалар.

Хәлфә. Җәмәгать! Тәяммем кылып бетерүчеләрне көтик инде!

Биш-алты кешенең паласлардан тузан чыгарып тәяммем кылуларыны туктап көтә башлыйлар.

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук өй. Шул ук бүлмә. Өстәл өстендә самавыр вә башка әйберләр беренче пәрдә ахырында хәзерләнгән көе торалар.

Бикә *(кешеләр чыгып киткәч тә, сценага каршы ишекне сызык кына ачып карап)*. Беркем дә калмаган икән. *(Сценага чыга. Өстәл янына килеп, әйберләрне, ашамлык-эчемлекләрне урыныннан кузгата башлап.)* Әсма! Әсма! Килен! Килен! *(Кычкыра. Бер ишектән алъяпма япкан асрау, икенче ишектән килен килеп керә.)* Тизрәк булыңыз, тизрәк! Хәзер керәләр. Ул ирләр ни, чәй урыны хәзерли беләмени! Иң кадерле әйберләремне муллалар алдына куйганнар бит! *(Тегеләр өстәл янына килеп торалар.)* Беркөн дә шул муллалар әфлисун, вареньеләремне барысын ашап бетереп киттеләр. *(Киленгә.)* Нәрсә карап торасың! Күчер әйберләрне! Әллә буны Казан дип белдеңме? *(Үзе тәрәзә янына килеп, тәрәзәдән карап.)* Варенье савытларыны кодаларга якын йиргә куеңыз. Муллалар алдына шикәр савыты берлә лимун куеңыз. Как-төшләрне Вахит кода урынына куеп, как-төш урынына чүрәкләр куеңыз!

---

*Как-төш* — чәкчәк.

К и л е н. Бунда шул, әнкәй, чүрәк бөтенләй юк.

Б и к ә *(тәрәзәнең парыны сөртеп-сөртеп)*. Алып киләңез!

А с р а у. Бүгенге чүрәк юк шул.

Б и к ә. Кичәге булса ярамаганмыни? Ул әллә нинди гомерендә тамагы туймаган хәлфәләрне бүген генә туйдырырсыңмыни! *(Асрау чыгып китә. Килен һаман әйберләрне маташтыра.)* Мескен, никадәр бала-чагасыны ятим калдырды.

К и л е н *(икенче тәрәзәгә барып)*. Кара, бик кызык икән! Әнкәй, мин җеназа намазыны күргәнем юк иде.

Б и к ә. Бик якын килмә! Хәзер сәлам бирәләр. Йөзеңне күрә башларлар.

К и л е н. Юк, әнкәй, бунда тәрәзә парлы.

Б и к ә. Әнә синең турыңда, ул бит Салих бай угылы. Шулар бит безгә кызларыны бирергә теләгәннәр иде. Үзеңне күрмәсен. Киленнәре тай кеби тәрәзәгә атланып ирләр карап тора дип сөйләп йөри башлар.

К и л е н *(бераз чигенеп)*. Әнкәй! Әнә ул, өченче сафтагы, кырыйдагы карт кем?

Б и к ә. Ул Җамал кода.

К и л е н. Шулмыни? Гел кычкырышып торды.

Б и к ә. Син аларның сүзләрене тыңлап тордыңмыни?.. Башка эшең юк шул. Башка киленнәр кеби кулыңны сызганып аш өендә йөрсәң, тыңларга бушамас идең.

К и л е н. Юк, әнкәй, мин чәй биргәндә генә ишеттем.

Б и к ә. Ирләр сүзене тыңлау киленнәр эше түгел!

К и л е н. Әнә сәлам бирәләр. Әнкәй, ул яшь егет кем, әнә синең турыңда?

Б и к ә. Сиңа нәрсәгә! Кызыктыңмыни?

К и л е н *(кызарып)*. Тегеләй генә сорыйм.

Б и к ә. Керәләр! *(Шул арада асрау зур тәрилкә берлә чүрәкләр китереп куя. Бикә тагы өстәл янына килеп, килененә карап.)* Сине аналарың нигә өйрәттеләр? Тагы шул муллалар алдына балымны куйганнар! Бүләк балымны шул бирәннәргә ашатырга гына дип саклаган идем инде! *(Урныны алыштыра. Асрауга.)* Нәрсә карап торасың? Шәриф абзыеңа теге тай итене китер. *(Асрау чыгып китә. Бервакыт варенье алып, киленгә.)* Менә шуны теге почмакка куй. Анда бай балалары утыра. Үзеңне уңмаган икән дип гаеп итеп китәрләр. *(Бер варенье савытыны карап.)* Карасана, нәрсә куйганнар! Мин бит сезгә кура җиләк вареньесы дидем. Сез нәрсә куйгансыз!

К и л е н. Әнкәй! Анда кура җиләк вареньесене мин таба алмадым.

Б и к ә. Таба алмагансың! Таба алмагансың! Бу шул атаң өе түгел. Бунда күзеңне ачып йөрергә кирәк. Сез мине шулай итеп оятка калдырмакчы буласызмыни? Мә, бар, ал буны. *(Килен чыгып китә.)* Бернәрсә белмиләр. Аларга берни дә түгел. Минем бит бирәсе кызым бар, өйләндерәсе угылым бар. Аларның ике ятып бер төшләренә керми! *(Асрау бик зур агач табак берлә бик күп өелгән тай ите алып кереп өстәлгә куя. Ишектән аяк тавышлары ишетелә башлый. Бикә асрауга карап.)* Самавырың нинди! Ичмасам, сөрт азрак! *(Үзе китеп, ишектән карап тора.)*

Асрау кыз самавыр сөртә. Ишектән баягы х а л ы к дөбердәшеп керә. Асрау кыз чыгып китә.

М у л л а *(сөйли-сөйли керә)*. Аллаһе Тәгалә Мөнкир-Нәкир җавабыны йиңел кылсын инде.

Х у җ а  у г ы л ы. Яңез, утырыша башлаңыз!

Шул арада ишектән варенье савыты күтәреп к и л е н килеп чыга да, халыкны күреп, бик тиз борылып керә. Бөтен халык ишеккә таба карап тора. Хуҗа угылы ишек янына барып, бик каты иттереп ишекне яба. Берничә кеше җыелып сөйләшәләр.

Б е р с е. Син күрдеңме?

Я н ә  б е р с е. Күрдем.

Б е р ә ү. Матур бит?

Я н ә  б е р ә ү. Күкрәк тә шәп икән! Казан кызлары шулай булучан инде!

Б е р ә ү. Юк шул! Бик нечкә, чыра кеби, тотар йире дә юк! Безнең кызлар, ичмасам, кочакка сыймаслык була!

Я н ә  б е р ә ү. Өст-баш шәп бит?

Б е р ә ү. Казаннар алар киенә белә инде!

Анлар янына х у җ а  у г ы л ы килеп: «Хушыңыз! Хушыңыз!» Чәй янына китә башлыйлар.

Х ә л ф ә *(үз-үзенә генә)*. Ахмак! Ба җәмал икән! Күңелгә вәсвәсә төшерде.

Бар да чәй янына утырышалар. Шул арада тагы килен кергән ишек сызык кына ачыла башлый. Хуҗа угылы барып бик нык шап иттереп яба.

---

*Ба җәмал* — матур, чибәр.

Б е р  я ш ь  к е н ә  к е ш е *(икенчесенә)*. Берсене берсе көнли!

И к е н ч е с е. Казан кызлары бит алар, үткен була! Көнләрсең шул.

Өй хуҗасы икенче ишекне барып шап иттереп яба. Хуҗа угылы чәй ясарга тотына. Муллалар ашарга тотыналар. Шәриф бай кулына пычак күтәреп ит ашарга тотына. Бөтен зал авыз чапылдавы берлә тула.

Ш ә р и ф  б а й. Менә, хәзрәтләр, инде шул, элгәреге голямалар шул уку юлында хезмәт иткәннәрдер бит? Без дә менә шулай итеп укырга юл ачуымыз берлә сәләфләргә охшый торганмыз бит?

Х ә з р ә т. Әйе, әйе. Ибне Хаҗиб ундүрт яшендә дәрес укыды дигәннәр.

Ш ә р и ф  б а й. Алай булса, без шул инде сәләфләр юлыннан чыкмаган буламыз. Җамал кода, ишетәмсең?

Җ а м а л  к о д а. Ишетәм, ишетәм! Менә шул, шулай булса да, Кәбир хәзрәтләр, Вәли хәзрәтләр менә бундый убществалар ачмыйлар иде шул. Ярый, хәерле булсын инде. Хәзрәтләр гөнаһысыны өстләренә алсалар... безнең гавамның эше түгел инде.

Х у җ а. Ашый-ашый сөйләңез!

Х ә з р ә т л ә р. Ашыймыз, ашыймыз!

Б е р ә ү. Хәзрәтләр! Менә минем бер сүз сорыйсым бар иде.

Х ә з р ә т. Йә, хуш!

Б е р ә ү. Менә инде, хәзрәт, әле китапларда хәзрәти Мусаның таягы бар, диләр.

Х ә з р ә т. Әйе, әйе! Теләсә аждаһа булган, теләсә җылан булган, теләсә яфрак ярып хөрмә биргән.

Т е г е  к е ш е. Менә шул агач нинди агач булган инде? Мин әле шуның хакында хәлфә берлә сөйләштем. Ул миңа җавап бирә алмады. Ул инде ысуле җәдит хәлфәсе, бәлки, белми дә торгандыр. Шул, ул таяк, хәзрәт, бит артыш агачыдыр инде? Артыштан бит әле җен кача диләр.

М у л л а. Юк, ул оҗмах агачы. Аны Җәбраил фәрештә Адәм атамызга биргән булган. Аннан хәзрәти Мусага калган.

Т е г е  к е ш е. Алай икән. Бу соң инде, хәзрәт, артыш агачыннан һәртөрле җен, шайтан кача дигәнме инде?

Х ә л ф ә. Әйе, әйе, аның хуш исенә шайтан чыдый алмас дигән. Аның исенә шайтанның йомыркасы чери дигән!

С а л и х. Соң, ул, алай булгач, менә бу төн ягы тарафларында, Архангель, Вологда губерналарында, артыш агачы бик күп йирләрдә, шайтан бер дә булмаска кирәк инде. *(Халыкның бертөрлесе көлә.)*

М у л л а *(ачуланып)*. Ахмаклар! Ул көлкемени? Китап сүзеннән көләләрмени?

Җ а м а л к о д а. Алар, менә шулай шул, китапны эшкә алмыйлар! Менә шул, без дә шуларны күреп, баратора шундыйлар берлә дөнья тулып китеп, ахырзаман булмасын димез. *(Тегеләргә карап.)* Ичмасам, тәүбә кылыңыз! *(Тегеләр тагы көләләр.)* Менә, хәзрәт, болай шыркылдап көлү бит китапта ярамый торгандыр?

Х ә з р ә т. Юк, юк! Ул инде урыс эше. Һәр көлүеннән китап йитмеш мең шайтан яратылыр дигән. *(Халык чәй эчә.)*

Б е р ә ү. Соң бу, хәзрәт, шайтан ничек ярала инде? Аларның да ире-хатыны буламы?

Х ә з р ә т. Ул анда ике ривайәт бар. Берсе: шайтан йомырка сала, дигәннәр; елан кеби, шул йомыркасыны йота да, шуннан шайтан балалары туа, дигәннәр. Бер ривайәттә инде шайтанның бер аягы ир, бер аягы хатын; шуннан һәркөнне йитмеш мең шайтан туа, дигәннәр.

М у л л а. Аннан соң һәр бидгать эштән йитмеш мең шайтан ярала, дигәннәр.

Җ а м а л к о д а. Менә, хәзрәт, безнең инде бу убществамыздан да шайтан яралмас микән?

Х ә л ф ә. Улсы инде — Алла эше. Алла хәерлегә боерсын!

Б е р ә ү. Соң, хәзрәтләр, бу инде шайтаннарның туе буламы?

Х ә з р ә т. Була, була! Китап әйткән, аларның туенда йитмеш мең ир, йитмеш мең хатын зина кыла, дигән. Йитмеш мең мичкә исерткеч эчелер, дигән. Аларның туена очраган кеше һәлак булыр, дигән.

Т е г е к е ш е. Менә бит әле, хәзрәт, безнең шайтан туе дигәнемез бар. Ул, шул, шайтанның никях мәҗлесе буламы инде?

Х ә з р ә т. Әйе, әйе! Шул, ул шайтаннарның биюе була инде. Ләкин шайтан никяхы диергә ярамый, аларның никяхы юк. Никях, әлхәмдүлиллаһ, әһле исламда гына.

Б е р ә ү. Хәзрәтләр, менә бит әле, пәйгамбәремез Мәккәдән Мәдинәгә киткәндә гар тишегенә кергән. Шунда аның өстенә үрмәкүч оя ясады, дигәннәр. Шул үрмәкүч ата үрмәкүч булганмы, анамы?

---

*Гар тишеге* — тау тишеге, мәгарә.

Х ә л ф ә. Ана үрмәкүч, ана үрмәкүч!

Килен ишеге тагы аз гына ачыла.

Х ә з р ә т. Минемчә, ата булырга кирәк. Әле бит, шәригать ирләрне хатыннардан артык күрә. Аллаһе Тәгалә инде пәйгамбәремезне коткарырга, әлбәттә, ата үрмәкүчне йибәргән булырга тиеш.

М у л л а. Ул мәсьәлә әле тәмам ап-ачык мәгълүм түгел. Голяманың бунда ихтиляфы бар!

Җ а м а л к о д а. Менә, хәзрәтләр, бу бит бик зур эш инде. Гавам аңларлык иттереп инде, шул үрмәкүчнең анамы, атамы идекене бәян кылып, җомгаларда вәгазь сөйләсәңез, яхшы булыр иде.

М ө ә з з и н. Аны инде китап иттереп, рисалә иттереп бастырырга яхшы булыр иде. Бу кирәк инде.

Х ә з р ә т. Әйе, әйе! Мәслихәт, мәслихәт!

Б е р ә ү. Соң, анда бит әле күгәрчен дә булган. Ул күгәрчен хәзер сәламәтме? Әллә үлгәнме инде?

Ишек тагы ачыла. Халык ишеккә таба карый башлый, хуҗа угылы барып, тагы бик нык иттереп ишекне яба.

Х ә л ф ә *(көлеп)*. Эһе, эһе, шулкадәр зур урынга мөстәххикъ булган күгәрчен үләме соң инде ул!

Х ә з р ә т. Юк, аны пәйгамбәремезгә гыйшкыннан вафат булды, дигәннәр.

Б е р ә ү. Хәзрәт, ул үрмәкүч берлә ул күгәрчен оҗмахка керерләрме икән инде?

М у л л а. Керерләр, керерләр. Китап: хәзрәти Салихның тәвәсе, хәзрәти Галинең Дөлделе, гар тишегендәге үрмәкүч һәм күгәрчен керерләр, дигән.

Б е р ә ү. Аларга да хур кызлары булыр микән?

Х ә з р ә т. Китап: булыр, дигән.

Һәммәсе чәй эчәләр. Яшьләр көлеп утыралар.

С а л и х. Калган маддәләрне укыйммы?

М у с а м и р з а. Хәзрәтләр чәй эчә-эчә сөйләрләр. Укы!

С а л и х *(кәгазене алып, халыкка карап укый)*. «Җәмгыятьнең эшләрене карар өчен ун кешедән мөрәккәб бер правления сайланачактыр һәм дә аның расходларыны тикшерер өчен өч кешедән мөрәккәб ревизионный комиссия сайланачактыр».

Х а л ы к. Бу ярый, бу ярый!

---

*Ихтиляф* — фикер каршылыгы.
*Мөстәххикъ* — лаеклы.
*Мөрәккәб* — төзелгән.

С а л и х *(тагы укый).* «Правлениягә һәм дә ревизионный комиссиягә сайлаулар вә башка җәмгыятьнең эшләре җәмгыятьнең гомум мәҗлесендә каралачаклардыр. Һәм дә күп тавыш алган кешеләр сайланган хисап кылынып, аз тавыш алганнары сайланмаган хисап кылыначак, һәм дә күп тавыш алган эшләр җәмгыять тарафыннан кабул ителгән хисап кылыначаклардыр».

Җ а м а л  к о д а. Ул ни дигән сүз? Менә хәзрәтне сайламакчы булырмыз. Ул аз тавыш алса, ул сайланмасмыни? Ул мөселманлыкмыни?

С а л и х. Әйе, хәзрәт аз тавыш алса, сайланмаган була шул!

Җ а м а л  к о д а. Ул, хәзрәтләр сайланмагач, ул нинди мөселман җәмгыяте була ди инде!

С а л и х. Ул хәзрәтләр сайланмаган мөселман җәмгыяте була.

Х а л ы к. Андый җәмгыять кирәкми, кирәкми! Без хәзрәтләрдән калмыймыз!

С а л и х. Җәмгыятьләрдә башкача булмый. Алай булгач, ничек иттереп сайларга кирәк?

Җ а м а л  к о д а *(Салихка).* Менә син күп тавыш алсаң, син сайланган буламсың?

С а л и х. Әйе, мин күп тавыш алсам — мин, син күп тавыш алсаң — син!

Б е р ә ү. Алай булгач, син үз дуст-ишеңне җыярсың да үзеңне сайлатырсың.

С а л и х. Шулай шул. Син дә үз дуст-ишеңне җый да, син үзеңне сайлат.

Т е г е  к е ш е. Миннән булмый. Минем үз эшем бар.

Җ а м а л  к о д а. Минем берлә синең хакта шулай да булсын. Бу хәзрәтләр хакында ничек алай итәргә ярый? Ул бит хәзрәтләрне мыскыл итү була! Әһле голяманы аяк астына таптау була! Бу бит, әлгаязе билла, көфер була!

Х ә з р ә т. Әйе, әйе!

Җ а м а л  к о д а. Бөтен мөселманның голямасы мөселман җәмгыятенә сайланмасын, имеш тә, әллә нинди тарбалаклар сайлансын, имеш!

С а л и х. Хәзрәтләр сайланмасын дигән кеше юк, сайлансын. Әгәр халык аларны ярата икән, аларга шар салырлар, аларны сайларлар. Яратмый икән, сайламаслар.

Җ а м а л  к о д а. Соң, син хәзрәтләргә шар салырсыңмы?

С а л и х. Минме? Мин — юк!

---

*Әлгаязе билла* — Алла сакласын.

Җамал кода. Менә әйтеп тә бетерде! Менә ул вакытта шул шуның кебиләр әллә ни чикле җыелырлар да, хәзрәтләрне төшереп калдырырлар.

Салих. Хәзрәтләр дә үзләре кебиләрне җыйсыннар да безне төшереп калдырсыннар.

Мулла. Юк инде, бу маддә әһле нифакъның таралуына сәбәп булыр.

Муса мирза. Минемчә, җәмәгать, бу бик кирәк маддә. Вәт, без хәзрәтләрдән башка тора алмаганны беләмез. Без аларны үземез сайлыймыз.

Хәзрәт. Ярый, мирза әфәнде, сез шулай. Замана хәзер үзгәрде, төрле кеше бар. Безнең дусттан битәр дошман күп.

Җамал кода. Тагы, җәмәгать, әле менә ни бар икән. Ул инде күп тавыш берлә кабул ителер дигән. Менә шундый кешеләр җыелырлар да, анда әһле голяма да булмагач, күп тавыш берлә хатын-кыз качмаска ясарлар. Без шуңарга риза булыйкмы инде?

Бөтен кеше киленнең ишегенә борылып карый.

Бер бай. Бунда бернәрсә дә юк инде. Җәмгыятьнең мәгънәсе шул-шул инде. Халык бер-бер кешене яратса, аны сайлый, яратмаса — юк!

Җамал кода. Ул чын мөселман булса дамы?

Бай. Чын мөселман булса да. Шуның өчен, сайланасы килгән кеше халыкка ярарга тырышырга кирәк.

Берәү. Җәмәгать! Әле бунда тагы куркынычлы йире бар. Безнең җәмгыятькә миссионерлар язылырлар да, үзләре теләгәнчә күп тавыш берлә эш йөртә башларлар. Менә тотарлар да мәктәпләргә урысча укытырга ясарлар. Без шуның берлә үземезгә бәла генә алмыйк!

Җамал кода. Тагы, тотарлар да, күп тавыш берлә безнең мәктәпләремезгә тәре куярга ясарлар!

Берәү. Тагы, менә аларның пасхаларында чучка ите берлә авыз ачу бар инде. Алар безнең мәктәпләргә чучка ите кертерләр дә, күп тавыш берлә балаларны шуны ашарга ясарлар. Аннан элгәре уенчык итеп кенә, аннан ары чынлап та чиркәүләренә алып китә башларлар. Без шуңарга риза булыйкмы инде?

Халык. Юк, юк! Бу кирәкми!

Теге кеше. Руза вакытында күп тавыш берлә балаларны руза тоттырмаска ясарлар.

Мөәззин. Куркыныч хәлләр инде!

---

*Әһле нифакъ* — икейөзлелек тарафдарлары.

Я ш ь б а й. Монда, җәмәгать, сезне әллә ниләр сөйләп куркыттылар. Имеш, алар күп кеше, безнең җәмгыятькә язылып, үзләренчә эш йөртмәкче булалар, имеш! Элгәре алар язылмыйлар әле, язылсалар бик ярар иде. Аларның үз эшләре башларыннан ашкан. Аннан, язылалар икән, алар ун язылса, без егерме язылырмыз, алар егерме язылса, без кырык язылырмыз. Шулай итеп, аларны җиңәрмез. Тагы, алар языла да икән инде, ул вакытта, алар безнең балаларның рузасыны ачтыру, безнең балаларга чучка ите ашату кеби куркулар бик урынсыз куркулар. Алар бит миссионер булса да, алар шайтан түгел. Аларга синең руза тотмавыңнан, биш вакыт намаз укымавыңнан файда юк. *(Халык тавышлана.)*

М у л л а. Бар инде, бер мөселманның күңеле каралуга алар шатлана инде.

Җ а м а л  к о д а. Шатлана, шатлана! Менә үземездә тора торган еврей генә әле, кем булсын, шул, әле менә Казанда мөселман кызлары гимназияләрдә укыйлар дип шатланып сөйли.

Х а л ы к. Юк, кирәкми! Кирәкми!

М у с а  м и р з а. Юк, бу маддәне, җәмәгать, без ташларга кирәк. Теге каһәрләр, бу Муса мирзага аяк чалыйк дип килеп язылып, чынында безне хур итмәсеннәр!

Х а л ы к. Шулай, шулай!

Б е р ә ү. Буның урынына «Правления әһле исламның мәслихәт күргән эшене эшләр, әһле исламның мәслихәт күргән кешесе сайланыр, әһле голямага юл бирелер» дияргә кирәк.

Х а л ы к. Шулай, шулай! *(Яшь бай сөйләргә тели.)*

С а л и х *(яшь байга)*. Тимә, үзләре теләгәнчә кылынсыннар. *(Яшь бай утыра.)*

Җ а м а л  к о д а. Шулай кирәк, шулай! *(Салихка.)* Син шуны яз!

С а л и х. Җәмәгать, соң шуңарга ризамы?

Х а л ы к. Риза, риза!

М у с а  м и р з а. Син, Салих әфәнде, аны тагы укып кара әле!

С а л и х *(укый)*. «Җәмгыятьнең правлениесенә әһле исламның мәслихәт күргән кешесе сайланыр. Әһле голямага юл бирелер. Правления әһле исламның мәслихәт күргән эшләрене эшләр».

М у л л а. Әһле голяманың төрлесе бар бит. Әүвәл бит пәйгамбәребез заманасында да монафикълар булган. Менә

---

*Монафикъ* — икейөзле, эчкерле.

шунда әһле голямадан элек «сөннәт юлында гамәл кыла торган» дигән сүзне арттырырга кирәк.

Җамал кода. Шулай, шулай! Хәзрәтләр авырга алмасын, мулла-мөәззин арасында да төрлесе бар.

Салих. Алай булса, менә болай инде. *(Укый.)* «Җәмгыятьнең правлениясенә әһле исламның мәслихәт күргән кешесе сайланыр. Сөннәт юлында гамәл кыла торган әһле голямага юл бирелер».

Тавыш. Яхшы, яхшы!

Муса мирза. Шуның берлән беттеме инде, Салих әфәнде?

Салих. Бетте!

Муса мирза. Алай булса инде, хәзрәтләр, тагы бер фатиха бирегез инде!

Хәзрәт. Яңез! *(Кул күтәрәләр.)* Аллаһе Тәгалә һәр мөэмин-мөселманга йиде оҗмах ишегене ачык кылсын! *(Халык: Амин!)* Һәммәмезгә оҗмах нигъмәтләрене насыйп кылсын! Һәммә мөэмин-мөселманга хурелгаеннәр берлә кочышырга насыйп кылсын!

Халык бик кычкырышып: Амин! Битләрене сыйпыйлар.
Киленнең ишеге тагы сызык кына ачыла.

Муса мирза. Салих әфәнде! Син аны инде акка яз. *(Халыкка.)* Менә инде Салих әфәнде язсын да, җәмәгать, куллар куярмыз инде.

Халык. Әйе, әйе!

Тагы чынаяк тавышлары, чәй тагы куәтләнә.
Салих читкә утырып яза.

Муса мирза. Менә инде, җәмәгать, Аллага шөкер, җәмгыятемез дә булды. Инде менә шунда теге каһәрләргә сер белгертмәскә кирәк. Әле берсе миңа әйтә: «Син, Муса Сапиич, үзең мөселманнар өчен тырышасың, алар сине эшкә дә санамыйлар, алар сине городской Думага гласный иттереп тә сайламадылар, ди. Алар сине гел читкә кагалар, син безнең якка чык, без сине күккә күтәрермез»,— ди. Мин дидем: «Ни смей безнең мөселманны хурларга! Сайламасалар, минем үземдә сәбәп булгандыр, дидем... Менә син бу сайлауны карап тор...» Шуннан үзе дә яшен суккан шайтан кебек китте дә, тагы бер каһәренә барып шыпыр-шыпыр сөйләргә тотынды... Ул мине Думага сайлатмас өчен юл эзли икән! Менә, вәт, әле нишләргә тырышалар!

Бәрәү. Әйе, әйе, җәмәгать! Теге вакытта Муса мир-

---

*Хурелгаеннәр* — матур күзле хур кызлары.

заны сайламаенча хата иттек. Бу юлы сайлыймыз, Алла теләсә.

Х а л ы к. Сайларга кирәк, сайларга!

М у с а  м и р з а. Вәт, мин шунда теге каһәр миссионерларның минем сайланмавыма шатлануына, вәт, хурландым. Вәт, губернаторда миссионерлары җыелып бәйрәм иттеләр. Мин эчемнән «ярый», дидем. Мин, дидем, киләсе Думага сезнең ашыңызга таракан булырмын, дидем.

Х а л ы к. Хата булды, хата булды!

М у с а  м и р з а. Менә шул, җәмәгать, шундый эштә уйлашырга кирәк. Менә вәт, инде хәзер безнең җәмгыять булды. Бөтен мөселманның җәмгыяте булды. Ул, вәт, тегеләрнең борынына сукты инде. Вәт, алар хәзер белгәч тә, бөтен теше-тырнагы берлә, буның председателе Муса мирза булмасын иде, диерләр. Менә, вәт, әле кая эшләр бара!

Б е р ә ү. Шул кяферләргә үч итеп Муса мирзаны сайлыйк!

Х а л ы к. Сайлыйк, сайлыйк!

Х ә з р ә т. Әйе, әйе! Мирзаны сайлыйк, мирзаны!

М у с а  м и р з а. Мин, җәмәгать, мине сайлаңыз димим. Әле тик теге каһәрләрнең мине ден дошманы күрүләрене генә әйтәм.

С а л и х *(кулына бер табак кәгазь күтәреп килеп)*. Язып бетердем.

М у с а  м и р з а. Алай булса, хәзрәтләр, бу тагы бер укысын.

Х а л ы к. Укысын!

С а л и х *(укый)*. «Җәмгыятьнең максаты хак мөселманның, («хак мөселман»нан морад: әһле голяманы игътибарга алучы, сәләфе салихин юлы берлә йөрүче, ата-ана фатихасыны алучы, байларның рөхсәтеннән башка эш башламаучы) мохтаҗ тарафларына ярдәм итмәктер».

Х а л ы к. Бик яхшы, бик яхшы!

Җ а м а л  к о д а. Буның әгузе бисмилласы юкмыни? *(Муса мирзага.)* Бу, мирза, бисмилласыз буламыни?

Х а л ы к. Куй, куй! «Әгузе бисмилла» куй! Куй!

Б е р  м у л л а. Әйе, бисмилласыз башланган эш тәмам булмыйдыр, ди.

С а л и х *(«әгузе бисмила» яза. Яңадан укый башлый.)* Икенче маддә. «Шул максатны тутырыр өчен җәмгыять «Бәдәвам» һәм «Әбҗәд» укыла торган мәдрәсәләр ачарга, кичке сабаклар ясарга, зур вә кечкенәләр өчен һөнәр өйрәтергә юл ачачак, һәм дә кирәкле китаплар бастырырга тырышачак».

Җ а м а л  к о д а. Бунда ник «Бәдәвам» дигәне калган! Яз, яз! Ник калдырдың?

Х а л ы к. Яз, яз! *(Салих аптырап тора.)*

М у с а  м и р з а. Яз, Салих әфәнде!

С а л и х *(тагы укый)*. «Һәм дә «Бәдәвам»ны бастырырга тырышачак».

Җ а м а л  к о д а. «Тырышачак» димә, «бастырадыр» диген!

Х а л ы к. Әйе, әйе!

С а л и х *(төзәтә)*. «Һәм дә «Бәдәвам»ны бастырадыр». *(Укый.)* Өченче маддә. «Член булыр өчен елына ун сум түләү тиештер. Гомерлек член буласы килгән кешеләргә берьюлы өч йөз сум түләргә тиештер». Дүртенче маддә. «Җәмгыятьнең эшләрене карар өчен ун кешедән мөрәккәб бер правления сайланачактыр һәм дә расходларыны тикшерер өчен өч кешедән мөрәккәб ревизионный комиссия сайланачактыр». Бишенче маддә. «Правления әһле исламның мәслихәт күргән эшене эшләр һәм дә правлениягә әһле ислам муафикъ күргән кешене сайлар. Сөннәт юлында гамәл кыла торган әһле голямага юл бирелер».

Хуҗаның угылы тагы торып китеп ишекне бик нык яба. Салих туктап тора.

М у с а  м и р з а. Беттеме, Салих әфәнде?

С а л и х. Бетте.

М у с а  м и р з а *(кәгазьләрне алып)*. Менә яңез инде, хәзрәтләр, кул куйыйк.

М у л л а л а р. Мирза, син үзең куй инде!

М у с а  м и р з а. Миңа, хәзрәтләр, сездән узып кул куярга ярыймы соң! Сез, вәт, ден башлыклары.

Х ә з р ә т *(муллаларга)*. Куйыйкмы инде, җәмәгать? Буннан андый-бундый перепись-фәлән, урысча укытулар, китап җыюлар килеп чыкмас бит инде, Муса мирза?

М у с а  м и р з а. Бунда булганда бернәрсә булмас!

Х а л ы к. Куй, хәзрәт, куй!

Хәзрәт кул куя. Аның артыннан мулла куя. Аның артыннан тагы мулла, тагы бер карт бай, артыннан Шәриф бай, аның артыннан Җамал кодага бирәләр. Халык тик тора.

Җ а м а л  к о д а *(озак кына карап, Салихка)*. Ник «әгузе бисмилла»дан соң «әбҗәде» юк?!

Х а л ы к *(шаулап китә)*. Ник юк?!

М у с а  м и р з а. Яз! Яз! *(Салих көлеп яза башлый.)*

Җ а м а л  к о д а. Гаиб ирәннәренең исемене калдырырга ярамый! Шундый зур эштә әбҗәдсез ярыймы соң! Ул кяферләргә керә алмаска койма булып тора. *(Казаки астыннан муенына таккан зур бөтине күрсәтеп.)* Менә, әлхәмдүлиллаһ, 47 ел тагам. Бер авыру күргәнем юк.

С а л и х. Язып бетердем.

Җ а м а л  к о д а *(алып, күзлегене киеп укый)*. Әбҗәд, һәүвәз, хоттый, кәләмән, сәгъфәс, коришәт... *(Шуннан кәгазьне утка каршы тотып карый. Бик озак карап торгач.)* Җәмәгать! Бу нәрсә?! *(Кәгазь эчендә ут яктысында күренгән гербны күрсәтеп.)* Бу ни бу?!

Халык бар да чәй яныннан торалар. Ишек тагы ачыла төшә. Берсене берсе бәрешеп кәгазьне карарга тотыналар.

Б е р с е. Кош сурәте, кош сурәте!

Я н ә  б е р с е. Тәресе бар, тәресе бар! Менә, менә! *(Төртеп күрсәтәләр. Салих кәгазьне алып карый.)*

М у л л а л а р. Бу ни бу, бу ни бу?! Сез шулай безне алдап кул куйдырып урыс итмәкче буласызмыни?!

Җ а м а л  к о д а. Андук, җәмәгать, бунын арты бозыктыр, дидем!

Х а л ы к *(дулый)*. Менә ышан! Менә ышан! *(Салихлар аптырап торалар.)*

Ш ә р и ф  б а й. Соң, анда кош булса ни була?

Җ а м а л  к о д а. Ишеттеңезме? Кош булса ни була, ди! Сиңа тәресе булса да шулайдыр! *(Халык тавышлана.)*

М у с а  м и р з а. Җәмәгать! Бу начар эш. Бу теге каһәрләр эше булды. Вәт, мөселман дип Салих әфәндегә ышанган идем. Менә яшьләргә ышан!

Х а л ы к *(Салихка)*. Син безне урыс итәргә кул куйдырдыңмы?! *(Салих янына йодрыкларыны төеп киләләр.)* Ник дәшмисең?! Безне урыс ясамакчы булдыңмыни?

Б е р ә ү *(шул арада)*. Аллага шөкер, әле кул куеп өлгермәгән идем!

Б е р с е. Бир кәгазьне, бир кәгазьне! Ул яшерергә тели! Кул куйган кәгазьләрне яшерергә тели! Ул яшереп тегеләргә бирергә тели! Җәмәгать, харап буламыз!

Х а л ы к. Бирмә! Бирмә!

Салих кулыннан кәгазьне тартып алалар да, барысы да: «Минем кулым бар, минем, мин кырам!» — дип кычкырышалар. Берсе-берсе берлә тартышып, кәгазьне ертып бетерәләр.

Җ а м а л  к о д а *(вак-төяк ертык кәгазьләрне алып, тагы erткалап Салихның битенә бәрә.)* Мә, кара йөз, убществаңны!

Х а л ы к. Сөягене көл итик!

Салихка таба барысы да киләләр. Йодрыкларыны йомарлыйлар. Яшь фикерлеләр сцена буена яшеренәләр. Салих тик катып тора. Ишектән х а т ы н н а р башы күренә.

П ә р д ә  т ө ш ә.

# МӨГАЛЛИМӘ

*Драма өч пәрдәдә*

КЕШЕЛӘР:

Фатыйма — мөгаллимә.
Габдулла — беренче мөгаллим.
Әсма — Фатыйма белән бер мәктәптә мөгаллимә.
Шакир — Габдулланың иптәш мөгаллиме.
Хәзрәт — мәхәлләнең имамы.
Абызтай — аның хатыны.
Сабир — яшь сәүдәгәрләрдән.
Гайшә — аның хатыны.
Габделкадыйр — яшь, фикерле сәүдәгәрләрдән.
Балалар — мәктәптә укучы шәкертләр.
Хәзрәт, остазбикә абызтай — Габдулланың аталары.

Вакыйга Себердә

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур, озын өстәл тирәсенә кунаклар утырганнар. Бүлмә байларча. Бер почмакта рояль дә бар. Бик якты. Бүлмәнең җыелышы ярты татарча, ярты аурупача. Өстәл башына яшь кенә хәзрәт утырган (яңы мулла). Аның күршесендә остазбикә. Аның күршесендә мөгаллим Габдулла әфәнде. Аңарга каршы мөгаллимә Фатыйма туташ. Мөгаллим Шакир, икенче мөгаллимә — Әсма. Шәһәрнең яшьләреннән Габделкадыйр әфәнде. Шәһәрнең ачык байларыннан Сабир әфәнде, аның хатыны Гайшә ханым. Пәрдә ачылганда бары да өстәл янында утырышкан.

Сабир *(хатынына карап)*. Йә, Гайшә, синнән!

Гайшә. Мин әйтә алмыйм. Ярар инде, үзең генә башла!

Шакир. Юк, без риза түгел, сездән, Гайшә ханым, сездән! Шундый зур, хөрмәтле ханымнар бар чакта без ирләргә башлап сүз сөйләргә оят, сездән, Гайшә ханым, сездән.

Габделкадыйр. Без бит, Гайшә ханым, хатыннарны тигезләү тарафында. Шулай булып, сездән узып сүз сөйләсәк, ул ни булыр?

Хәзрәт. Шулай, шулай.

Остазбикә, Фатыйма, Әсма көлеп торалар. Кыска гына тик тору. Гайшә ханым акрын гына аякка калка. Кулындагы озын бокалда тулы кымыз.

Гайшә. Әфәнделәр... Әфәнделәр... Бу олуг мәҗлес безнең барымызның хөрмәт итә торган, барымызның да сөя торган... Әй яңлыш ла, ярата торган *(Бераз туктап торып.)* Габдулла әфәнденең туган көненә карап ясалды...

Аның безнең милләтемезгә иткән хезмәтләре бик күп: ул мәктәп ачты... кызлар укытты... безгә һәр эштә ярдәмче булды... Мин аның исәнлегенә кадәх күтәрәм...

Габдулла. Рәхмәт, Гайшә ханым, рәхмәт! *(Һәммәсе Габдулла берлә чүкешәләр.)*

Һәммәсе. Габдулла әфәнде, сезнең исәнлеккә, Габдулла әфәнде, сезнең исәнлеккә! *(Кымыз эчәләр.)*

Сабир *(торып)*. Җәмәгать! Ханымнар, әфәнделәр!.. Үз кешеләр бит, гаеп итмәссез, без сөйләргә өйрәнмәгән... Мин бит, беләсез, сатучы... Аның да агы берлә түгел, карасы берлә. Агай-эне әйтмешли, тире-ярычы. Алай да минем күңелем сезнең берлән. Менә шуны әйтмәкче булам: моннан сигез ел элгәре, монда мәктәп түгел, яза белүче дә юк иде. Себернең суыгы белән туңган йир кебек, безнең күңелемез дә, башымыз да туңган иде. Хәзер караңыз менә, җәмәгать! Габдулла әфәнде килгәнгә сигез ел үтте, мәктәбемез булды, кыйраәтханәмез булды, мәчетемез булды, имамымыз булды, без бер мәхәллә халык булдык. Аллага шөкер, кеше төсле тора башладык. Менә шуның өчен Габдулла әфәнденең туган көне хөрмәтенә, Габдулла әфәнденең безгә сигез ел иткән хезмәте хөрмәтенә мин кадәх күтәрәм. Яшә, Габдулла әфәнде!

Һәммәсе. Ура, ура! *(Һәммәсе чүкешәләр.)*

Габдулла. Рәхмәт, рәхмәт, Сабир әфәнде, рәхмәт! Һәммәңезгә рәхмәт!

Габделкадыйр. Миңа бер-ике генә сүз әйтергә рөхсәт бирецез әле! Мин, әфәнделәр, Сабир абзый әйткән кебек, бер тирече егете. Әтием мине үзе төсле тирече булып, азмы-күпме акча җыеп, дөньяда торырга, аныңча, бик шәп иттереп, сезнеңчә, хайван кебек булып торырга хәзерләмәкче иде. Менә шул юлдан бара идем. Менә безгә Габдулла әфәнде килде. Мин аның шәкерте булдым. Ул минем туңып килә торган күңелемә җылы салды. Мин аны мөгаллим итеп яраттым, сөйдем. Аның сүзен атам-анамныкыннан артык күрә башладым. Уникe-унөч

---

*Кадәх* — шәраб эчә торган савыт, бокал.

*Кыйраәтханә* — уку залы, уку өе.

яшемдә мин, тәмәке тарту, эчү нәрсә икәнене татыган егет, китап, әдәбият, шигырь нәрсә икәнене белмәгән идем. Габдулла әфәнде мине шул юлга сәвекъте. Укырга, уйларга дәрт салды. Күңелемне нечкәртте дип һавалана алмыйм, ләкин минем башымнан эчү-тарту кебек былчырак нәрсәләрне алып ташлап, алар урынына милләт мәхәббәте, әдәбият сөю кебек матур мәгънәле нәрсә тутырды. Менә мин бүген, әтине алдап, шул олуг мәҗлескә, шундагы хөрмәтле затларның мәҗлесенә — Габдулла әфәнденең туган көне бәйрәменә килдем. Габдулла әфәнде сигез ел элек монда килеп, батып бара торган мине коткарып калмаса иде, мин менә бүген шулай ук, әтиемне алдап, исемен монда әйтергә ярамый торган әнә теге өйгә *(Кулы берлә күрсәтә.)* барып кергән булыр идем. Габдулла әфәнде мине икенче мәртәбә тудырды. Бүген аның туганына утыз ел тулган көн булса, бу аның туган бәйрәме булса, бу минем туганыма да сигез ел тулган көн, бу минем дә бәйрәмем, олуг бәйрәмем. Менә мин шул үземнең мәгънәви атамның сәламәтлегенә, тагы минем кебек йөзләр, меңнәрне тудыруына кадәх күтәрәм!

Һәммәсе. Шулай, шулай, браво, браво!

Бар да чүкешәләр, кымыз эчәләр, хуҗа торып тагы кымызлар сала.

Хәзрәт *(калкып)*. Мин мәхәлләнең имамы икәнне беләсез. Без, муллалар, вәгазь сөйли-сөйли халыкны туйдырып бетергәнгә, безнең сүземез дөрест булса да, йә инде, мулла ни сөйләсен, дип тыңламау дәрәҗәсенә йиткән. Менә хәзер, җәмәгать, миңа бер мулла, бер вәгазьче дип карамаенча, араңыздагы бер кеше, бер иптәш, бергә баручы бер юлдаш дип кенә караңыз әле!

Һәммәсе. Карыймыз, хәзрәт, карыймыз!..

Хәзрәт *(туктап)*. Әнә шулай караңыз, бүген мин хәзрәт булмыйм әле. Мин Габделвахит... Менә бүген чынлап та безнең Себернең шул ук суык почмагын йылыткан, шуның бозын эреткән Габдулла әфәнденең бәйрәме безнең арадагы пәрдәне дә бетерсен әле!

Халык. Бетте, бетте!

Фатыйма. Бетте, Габделвахит әфәнде!..

Хәзрәт. Рәхмәт, Фатыйма туташ. Менә әйтәсем шул: Габдулла әфәнденең иң зур хезмәте безнең мондагы мәктәптә укыту гына түгел, тәрбия итү булды. Безнең мөгаллимнәремезнең күбесе укыта гына белә, Габдулла әфәнде тәрбия итте. Габделкадыйр әфәнденең сүзе дөрест.

---

*Сәвекъ* — алга этәрү, юнәлтү.

Ул балаларның күңеленә чаткы салды. Менә шул чаткы, атәшкә әйләнсен өчен мөгаллимәләремезнең дә бик зур хезмәте тиде. Балаларның ире-кызы бергә укуының да файдасы зур, мин каршы килгән идем. *(Туктап тора...)* Тагы ни әйтим?.. Вәгазьгә өйрәнгән кеше, шул, башкача булдыра алмый икән!.. Көлсәңез көләрсез инде. Габдулла әфәнде балаларга дин рухы сеңдерде, мин моны муллалыктан гына әйтмим. Бу — зур эш!

Халык. Рәхмәт, хәзрәт, рәхмәт.

Хәзрәт. Менә тагы хәзрәт булдым... *(Чүкешәләр, тагы эчәләр.)*

Асрау кыз *(кереп)*. Абызтай, балалар килде... Балалар... *(Һәммәсе борылып карый.)*

Сабир. Нинди балалар?..

Асрау. Мәктәп балалары... Мөгаллим абыйга килдек, диләр.

Әсма. Котларга килгәннәрдер, котларга... *(Урыныннан сикереп торып.)* Кая? Керсеннәр... *(Гайшә ханымга.)* Керсеннәр бит, Гайшә ханым?!

Сабир, Гайшә ханым. Керсеннәр, керсеннәр... *(Бары да тора.)*

Хәзрәт. Аларны кем өйрәткән?

Шакир. Үзләре белгәннәр... Үзләре!..

Әсма. Менә сез бер генә көнгә хәзрәт булмаска теләдеңез, балалар да бүгенгә генә зур булырга теләгәннәрдер...

Абызтай. Балалар һәрвакыт зур булырга телиләр инде...

Өч-дүрт кыз, өч-дүрт малай килеп керәләр. Кызлар бары да калфактан. Ак алъяпма япканнар: малайлар кәләпүштән, бертөсле киемнән.

Малайлар. Әссәламе галәйкем!

Кызлар күкрәкләренә кулларын куеп баш ияләр. Бер кыз кулына төргән бернәрсә тоткан, бер малай да бернәрсә эләктергән. Ишек төбенә туктыйлар.

Хәзрәт. Вәгаләйкем әссәлам. Боерыңыз, кечкенә туташлар!

Гайшә, Сабир. Боерыңыз, боерыңыз! *(Балалар берберсенә карашалар.)*

Әсма *(яннарына барып чыгып)*. Әйдәңез! Әйдәңез!
Балалар акрын гына киләләр дә туктыйлар... Пауза... Хәзрәт хаты-

*Атәш* — ут, ялкын.

ны белән колактан колакка сөйләшә... Һәммә кеше көтә... Балалар, бер-берсен төртешәләр. Бер кыз алгарак чыгып кулындагы кәгазьне ача башлый. Акрын гына тавыш белән укырга тотына.

Кыз. Без, мәктәп балалары, сөекле хәлфәмез Габдулла әфәнденең туган көнен үземезгә бәйрәм санап, шул шатлыклы көнне күрүемез өчен үземезне бәхетле санаймыз. Ул безне һәрвакыт сөйгәнгә, безне баласы кебек күргәнгә, без дә аны абыебыз, әтиемез кебек олуглыймыз вә аңарга Аллаһе Тәгаләдән бик зур бәхет, шатлыклы тормыш бирүне телимез... *(Пауза.)* Безнең мәктәпнең кызлары сезнең хезмәтеңезне түләп бетереп булмаганны белсәләр дә, сезгә, Габдулла әфәнде, күңелемездән чыккан шул рәхмәтне әйтергә куштылар вә шул чәчәкне тәкъдим итәргә боердылар.

Кызларның берсе кәгазьне ташлый, букет чыга, алга таба баралар.

Теге кыз. Габдулла әфәнде, без — балаларның шул кечкенә бүләген кабул итеп алыңыз. Гомереңез чәчәк кебек матур, чәчәк кебек хуш исле, чәчәк кебек пакь, саф булып үтсен! Рәхмәт сезгә, Габдулла әфәнде!

Балалар. Рәхмәт, рәхмәт, Габдулла әфәнде!

Габдулла. Рәхмәт, рәхмәт! *(Балаларның һәммәсен сөеп, кайсын башыннан сыйпап, кайсын кулыннан тотып чыга.)*

Әсма *(чыгып бер кызга)*. Хәдичә, кара әле, алъяпкычың җыерылган *(Бала төзәтенә.)* Менә шулай, шулай!.. *(Бер малайның кәләпүшен төзәтебрәк куя... Әйбер тоткан малай кәгазен ташлап.)*

Малай. Габдулла әфәнде, сөекле хәлфәмез яхшы китаплар язганда безнең кара савытымызга манып, безнең каләмемез берлән язсын, дип, дүртенче сыйныф шәкертләре исеменнән үзара җыешкан акчага шул кечкенә бүләкне алып бирергә батырчылык иттек. *(Габдуллага суза.)*

Габдулла *(алып)*. Рәхмәт, рәхмәт.

Барысы да килеп кара савытка карый. Гайшә зур ваза алып килеп букетны суга куя.

Әсма *(балаларга)*. Менә шулай, менә шулай, нинди гакыллылар! Килеңез монда, чәйгә утырыңыз. Гайшә ханым, балаларга чәй эчерергә ярый бит!

Гайшә. Ярый, ярый, рәхим итеңез, балалар!

Абыстай *(бер кызга)*. Син кем кызы?

Кыз. Камәретдиннеке.

Абыстай. Әһе, әниең исәнме, ник безгә бер дә килми?

Әсма. Әйдәгез! Әйдәгез!

Габделкадыйр берлән Шакир әллә ни хакында сөйләшәләр. Балалар каушап торалар.

Бер кыз. Без чәй эчмимез...

Әсма. Эчегез... Эчегез...

Кыз балалар *(бердән)*. Юк, рәхмәт!

Әсма *(кулында бер поднос чикләвекләр, конфетлар күтәреп балаларга таба барып, Сабир әфәндегә)*. Мин аз гына балаларга бирим әле! *(Сабир баш ия, Фатыйма җылмаеп карап тора.)*

Әсма. Алыгыз! Алыгыз! *(Балалар алмый торалар. Ул үзе кулы берлән учлап берсенә бирә. Баланың кулыннан чикләвек аккач.)* Ал, яулыгыңны, ал! *(Балалар яулыкларын алалар. Әсма һәммәсенә өләшә. Бер малайга килеп.)* Менә конфетны ал! *(Малай тартына.)*

Әсма *(бармак селкеп)*. Ал, ал, мин бит сине беләм. Син конфетсыз мәктәпкә дә килмисең!

Малай. Хәзрәт ачуланыр.

Әсма. Юк, юк, бүген ачуланмый.

Абыстай. Юк, ачуланмый.

Балалар конфет, чикләвек ашарга тотыналар. Бер малай мич янына килеп бер вазага карап тора. Аның янына Фатыйма барып:

Фатыйма. Нәрсә карыйсың, Хәмит?

Малай. Менә, Фатыйма ханым, бу савыт нәрсә?

Фатыйма. Бу — савыт түгел, бу — ваза. Бу кытай эше, матурмы?

Малай *(башын иеп)*. Бик матур.

Фатыйма алып күрсәтә, малай тотып-тотып карый. Әсма һаман балаларга конфетлар ташый. Фатыйма, Гайшә, абыстай Әсма янына баралар. Әсма һаман балалар белән мәшгуль.

Фатыйма *(Әсманың кулыннан тотып)*. Әсма, син нинди бәхетле!

Әсма *(кызарып)*. Ник, ник, ни булды?

Фатыйма. Бер ни булмады, син бәхетле генә дим!..

Әсма аптырап тора. Фатыйма, Әсманың кулына кереп.

Фатыйма. Бәхетле булу гаепмени?

Әсма. Юк, гаеп түгел, мин гаеп димим.

Фатыйма. Алай булгач, ник кызарасың?

Әсма. Менә мин синең төсле булсам иде, бәхетле булыр идем.

Ф а т ы й м а. Мин синең төсле булсам иде, бәхетле булыр идем дип уйлыйм. Юк, Әсма, син барыбыздан да бәхетле: Габдулла әфәндедән дә, миннән дә, Сабир әфәндедән дә, Гайшә ханымнан да. Синең эчеңә бәхет салынган. Аңлыймсың? Кайсы кешеләр бәхетле туа, бәхетле үсә, бәхетле яратыла. Менә син — шул!

Ә с м а. Син бәхетле түгелмени, Фатыйма?.. Мин сине бик яратам. Мин сиңа кызыгам, син бәхетле!

Ф а т ы й м а. Мондый шатлыклы мәҗлестә андый сүзне сорамыйлар. *(Үзе акыртын гына китә. Әсма аптырап карап кала.)*

Ш а к и р *(килеп)*. Әсма ханым, әйдә балаларны йырлатыйк.

Ә с м а. Әйдә, әйдә!

Балалар янына барып сөйләшергә тотыналар. Абыстай берлә Гайшә читтәрәк сөйләшәләр.

А б ы з т а й. Мин бу Фатыйма туташның монда килүен бер дә аңламыйм. Өч ел мөгаллимә булган исеме бар, белеме бар, аны бит нинди йиргә дә алырлар иде.

Г а й ш ә. Үзе дә шулай, күп йиргә сорадылар, Себергә киләсем килде, ди.

А б ы з т а й. Мин аны Габдулла әфәнде тартып китермәдеме, дим. Элгәре танышлар иде микән?

Г а й ш ә. Белмим, юктыр ахрысы. Булса ни, пар түгелләрме әллә?

А б ы з т а й. Парын пар да, Габдулла әфәндегә тагы бер дәрәҗә югарысы да кызганыч түгел.

Фатыйма йөреп тора, боларның яныннан барганда.

А б ы з т а й. Фатыйма туташ, менә без әле сезнең монда килүеңезгә исемез китеп тора. Казан, Идел буен ташлап, салкын Себергә килгәнсез!

Ф а т ы й м а. Дөньяда кайвакыт салкын да кирәк булганы сезгә туры килгәне юкмыни? Пешереп бетерә алмаган ашны бозылмасын өчен суыкка да куялар бит. *(Фатыйма китеп бара. Ике хатын әллә нәрсә сөйләшәләр.)*

Ш а к и р. Җәмәгать, хатыннар, әфәнделәр! Балаларны йырлатмакчы буламыз.

Х а л ы к *(беравыздан)*. Бик һәйбәт, бик һәйбәт!

Ә с м а берлә Ш а к и р, кулга-кул тотынып, Гайшәгә киләләр.

Ш а к и р, Ә с м а. Гайшә ханым, рәхим итеп рояльгә утырсаңыз!

Г а й ш ә. Мин бит бик начар уйныйм. *(Үзе рояльгә таба бара. Балалар рояль янына киләләр.)*

Г а й ш ә. Нинди көй?
Ш а к и р. «Бәйрәм бүген».

Гайшә уйный, балалар йырлыйлар.

**Бәйрәм бүген**

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген,
Нәрсәдән бу? — Мин беләм: бәйрәм бүген,
бәйрәм бүген!
Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген!
Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын;
Ул киенгәндер, дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
Хис итеп һәр җирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын,
Ислемай сөрткән икән дөнья! дидем: бәйрәм бүген!

Ахырдан һәммәсе кул чабалар.

Һ ә м м ә с е. Шулай, шулай!..
Ә с м а *(балаларга карап)*. Теге «Садә көе»н, «Садә көе»н...

Гайшә музыканы үзгәртә, балалар «Садә көе»н җырлыйлар.

Кояш чыкты, нур балкыды,
Тәрәзәдән һәм калыкты.
Уян, атам, атам, уян!
Уяныргa вакыт җитте!
Укыт мине, газиз атам,
Югыйсә мин таштай катам,
Һич ни белми, һич ни күрми
Ихтыярсыз әрәм ятам.

Бик озак кул чабалар.

Г а б д у л л а. Рәхмәт, шәкертләр. Барыңыз инде, курыкмыйсызмы?
Ш ә к е р т л ә р. Юк, юк!

Әсма балаларның тагы кайсысының алъяпкычын төзәтә, кайсысының кәләпүшен төзәтә, бер малайга.

Ә с м а. Син ката киеп килдеңме? Бүген суык!
М а л а й. Ката...
Ә с м а *(барысына да)*. Туңмаңыз, киемнәрегез җылымы?
Б а л а л а р. Җылы... Әсма туташ, җылы!
Ә с м а. Барыңыз, барыңыз, сабакка соңга калмаңыз...

Барысы да чыгып китәләр.

Г а й ш ә. Утырышыңыз әле, кунаклар, утырышыңыз әле! Мәҗлес бетмәгән. Фәхрия, Фәхрия! *(Асрау килеп керә.)* Яңа самавыр керт әле.

Асрау самавыр күтәреп чыгып китә.

Х ә з р ә т. Балалар килеп керүе мәҗлесне бозды.

Ф а т ы й м а. Төзәтте дә: матурлык, сафлык бирде.

Ә с м а. Сез, хәзрәт, балаларны сөймисезмени?

Х ә з р ә т. Сезнең кадәр үк сөймим!

Ф а т ы й м а. Ирләр, гомумән, хатыннар кадәр үк сөймиләр.

Ш а к и р. Бу — балалар хакында гынамы, Фатыйма туташ, әллә гомумәнме?

Ф а т ы й м а. Булса ни була?

Ш а к и р. Гомумән булса, бәхәсем бар!

Ф а т ы й м а. Сезнең шул бәхәсеңез булуда бәхетеңез.

Ш а к и р. Рәхмәт, туташ!

С а б и р. Утырышыңыз, утырышыңыз!

Барысы да утыралар. Самавыр килә. Яңадан бокалга кымыз салына.

Г а б д у л л а *(торып)*. Ханымнар, әфәнделәр! Шулкадәр зур мәшәкатьләр ясап, минем кечек башымны олугка санап хөрмәт мәҗлесләре ясавыңыз өчен һәммә шунда булган ханымнар, әфәнделәргә эчемнән рәхмәт укыйм. Хосусән, Гайшә ханым вә Сабир әфәндегә хезмәтләре өчен бурычымны түләүдән гаҗиз икәнлегемне белдерәм. Туташлар, ханымнар, әфәнделәр! Бервакытны тормыш дулкыны мине Сибириягә, суык Сибириягә ыргытты. Халкыма хезмәт итү уе бөтен башымны, йөрәгемне, куймаенча, үзенең генә ихтыярына алган чакта, шул суык Сибириядә мин җылы күңелләр таптым. Боларның берсе монда хазир булган Габделвахит әфәнде, яңы имамымыз Габделвахит әфәнде, берсе өй хуҗамыз Сабир әфәнде иде. Аларның култыклаулары, аларның ярдәмнәре аркасында күңелемдә тулган дәртемне тормышка татбикъ итә алдым. Сибириянең шул караңгы почмагында беренче мәктәп ачтым. Ничек укытканнарым, нинди юллардан үткәннәрем һәммәңезгә мәгълүм. Ләкин сезгә мәгълүм булмаган бер нокта, кечкенә генә бер нокта минем шул эшемдә миңа ярдәмче, сәбәпче булды: ул да — минем хатын-кызга карашым. *(Фатыйма туташ зур бер хәрәкәт ясый, Габдулла дәвам итеп.)* Мин монда булган

---

*Хосусән* — аеруча.
*Хазир булган* — шунда, күз алдында булган.
*Татбикъ* — ашыру.
*Нокта (ноктаи нәзар)* — берәр нәрсәгә караш.

ханымнарга күңеллерәк булсын өчен әйтмим. Бөтен барлыгымны ярып каралса, бер ягыннан халкыма мәхәббәт чыкса, икенче ягыннан хатыннарга ихтирам чыгачак. Бу миңа китап аша гына кергән сонгый бер тойгы гына түгел. Бу миңа анам сөте берлә кергән, минем берлә бергә үскән табигый бер сыйфатым. Минем анам — дөньяның иң шәфкатьле, иң яхшы бер хатыны. Минем туталарымның минем өчен йокламаган йокылары, минем өчен иткән мәшәкатьләре, һичбер файда өчен түгел, мине сөйгәннән генә иткән эшләре — минем күңелемнең иң эченә хатын-кызга ихтирам тойгысын тутырды. Мин шул тойгыны яшьлегем буе өстерәп чыктым. Шуның кушуы буенча, менә хәзрәтләр берлә оршышып булса да, мөгаллимә китерттем. Ир балалар берлә кыз балаларны бергә куштым. Нәтиҗәсе күз алдыңызда: менә мөгаллимәләремез, менә шәкертләремез. Өч елдан бирле Әсма туташ берлә бергә укытамыз. Ике ел бербуйдан Мәрфуга туташ берлә укыттык. Хәзер менә Фатыйма туташ берлә иптәш булып бергә укытып барамыз. Тәҗрибәләргә таянып әйтә алам: укыту эшен без, мөгаллимнәр, мөгаллимәләр белән бүлешә алсак та, тәрбия эше бөтенләй аларда. Мин менә бүгенге шул бәйрәмне, минем бәйрәмем генә ясамаенча, бөтен мөгаллимнәр, бигрәк тә мөгаллимәләр бәйрәме дип уйлыйм, шуңар ышанам. Шуның өчен шунда хазир булган Әсма, Фатыйма туташлар вә монда хазир булмаган Мәрфуга ханымнарның исәнлеге өчен кадәх күтәрәм. Яшәсен татар мөгаллимәләре! Алар яшәсә, без яшәрмез!

Габделкадыйр. Яшәсен бөтен татар хатыннары!

Габдулла иң әүвәл Фатыйма туташ белән чүкешә. Габделкадыйр һәммәсе берлә чүкешә. Шакир Әсмага карап әллә нәрсә әйтә. Кадәхләрне күтәргәч тагы.

Һәммәсе. Яшәсен татар хатыннары!

Шакир. Мин төбенә кадәр эчәм!

Габделкадыйр. Мин тамчысына кадәр!

Хәзрәт, Сабир, Габдулла. Һәммәмез, һәммәмез, беткәнчә!

Фатыйма торган йиреннән утырмаенча, кымызны эчеп бетермәгән көенчә сөйләмәкче була.

Сабир. Фатыйма туташ, сез бетермәгәнсез, сез бетермәгәнсез!

---

*Сонгый* — ясалма.

Г а б д е л к а д ы й р. Фатыйма туташ, сез бетермәгәнсез, татар хатыны исеменә эчкәндә сез бетермәгәнсез!

Ф а т ы й м а. Бәлки мин татар хатынында бер тамчы калдырмаенча эчәрлек сез күргән каһарманлыкны күрми торганмын!

Г а б д е л к а д ы й р. Фатыйма туташ, сез ни сөйлисез, сез ни сөйлисез? Безнең бөтен мөхәррирләремез, бөтен шагыйрьләремез, бөтен олуг кешеләремез хатыннарымызга ихтирам итә, бөтен алдагыларымыз аларны тәкъдис итә. Һәм шулай тәкъдис итәргә тиеш!

Х ә з р ә т. Шулай, Фатыйма туташ, шулай!

С а б и р. Минем дә фикер шул!

Ф а т ы й м а. Мин дә, бәлки, сезнең белән фикердә бермен. Ләкин шуны уйлаңыз: мин үзем — хатын! Мин сез күрмәгәннәрне күрә алам.

Ә с м а. Мин дә хатын, мин күрмим!

Ф а т ы й м а. Мин, Әсма, чын хатын, син — бәхетле хатын!

Ә с м а. Син — Фатыйма!

Ф а т ы й м а. Син... *(Пауза... Сабир кымыз салып йөри. Хәзрәт хатыны берлә әллә нәрсә сөйләшә. Гайшә чәй ясый. Габдулла күзен тутырып Фатыймага карап тора. Фатыйма яңа кымыз бокалын күтәреп.)* Әфәнделәр, ханымнар! Миңа иптәшләрем Шакир әфәнде, Әсма туташ, мәктәпнең бөтен укытучылары исеменнән сөйләргә кушканнар иде. Мәҗлестә сөйләшкән сүзләр минем планымны бозды да йомгагымның очын югалттым. Габдулла әфәнде, мин монда ике айлык кына мөгаллимә булсам да, сезнең мәктәпкә никадәр кирәклегеңезне күрдем. Сез — мәктәпнең рухы, сез — мәктәпнең нигезе. Тәрбиядә, укытуда иң зур вазыйфаны сез эшләп киләсез. Унар мөгаллимле мәктәпләр эшли алмаган эшне сез ялгыз эшлисез. Без, сезнең иптәшләреңез, сезгә олуг хөрмәт билимез вә сезне арамызда күрүемез берлә шатланамыз. Дөрестен әйтим, Идел буеның болыннарын, моңлы яланнарын ташлап Себергә таба сәфәр иткәндә минем иң курыккан эшем — иптәш мөгаллимнәр, мөгаллимәләрнең хәлен белмәү иде. Беренче күрү берлә сезнең чын мөгаллим, чынлап мәктәп ясаучы икәнеңезне күрдем. Сезгә иткән эшләреңез өчен, бар укытучылар исеменнән рәхмәт укыган кебек, үз исемемнән дә рәхмәт укыйм! Өч еллык мөгаллимәлек тормышымда сезнең кебек мөгаллимне мин беренче күрәм!

Г а б д у л л а. Мин дә шулай, туташ!

---

*Тәкъдис итү* — изге күрү.

Ф а т ы й м а. Илтифатыңызга рәхмәт, Габдулла әфәнде! Вә шундый мөгаллимнәр белән бергә укытучы булуыма бик сөенәм. *(Пауза.)* Шуннан чыккан бәгъзе мәсьәләләр безнең барымызга да бик якын булганга, урынсыз булса да, бер сүз әйтеп китмәкче булам: монда һәммәңез, хосусән, ирләр, хатын-кызга әллә никадәр ихтирам күрсәтте, хатын-кызны әллә никадәр олуглады. Бу хәзер бер бунда гына түгел. Безнең бөтен татар дөньясында, Шакир әфәнде әйткәнчә, бөтен әдәбиятымыз шул ихтирам исенә буялган. Матбугатымыз шуңарга әллә никадәр әһәмият бирә. Бәлки курыккан, йөдәгән шул хатынны чаршау артыннан өстерәп чыгарыр өчен шундый олуглаулар, хөрмәтләүләр кирәктер. Олуг мөхәррирләремез, бөек шагыйрьләремез шул эшне әллә нинди зур бер көчнең илһамы берлә эшли торганнардыр. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы бар. Шул олуглау, шул кадерләү берлә сез, ирләр, безгә зур, без күтәрә алмый торган бер бурыч йөклисез! Безнең ул бурычны түли ала алмавымызда сезнең эшеңез юк. Без — хатыннар, без — бурыч ияләре... Без шул хисапны түли ала-алмауны уйламаенча хәлемез бармы? Хисап көне җитә... Бәлки безнең янчыгымызда әбиләрдән калган иске чүпрәккә башка берни юктыр?.. Сез безнең хөрмәткә бокалны тутырып эчеп бетерденез!

Ш а к и р, С а б и р. Кирәк булса, тагы эчәмез.

Ф а т ы й м а. Беләм, ышанам, сабыннан күтәреп эчәсез, чөнки сездә безгә каршы хөрмәт, безгә каршы иман бар... Мин эчә алмыйм, эчкән һәр тамчым йөрәккә таш булып катмасын дип эчә алмыйм... Бурычларны түләшүгә хисап килгәндә түли алмам дип, куркуымнан эчә алмыйм...

К ы ч к ы р а л а р. Хата, туташ, хата!..

Ф а т ы й м а *(дәвам итә)*. Татар тарихына бер күз салыңыз, шунда бер татар хатыны симасын, сөйкемле бер татар хатыны симасын табасызмы? Әдәбиятта, матбугатта, башка юлда татар хатыны нишләде?.. Бер олуг баш, татар хатыныннан нинди дә булса бер олуг баш күрсәтә беләсезме?..

Х ә з р ә т. Ир — баш, хатын — муен, туташ!

Ф а т ы й м а. Тәмам сезнең берлә разый. Олуг башны тота торган, олуг башны бора торган муен булу — кечкенә баш булудан йөз мәртәбә артык... Ләкин татар хатыны муен да була белдеме? Сукыр Каюмны хәтерләңез!.. Кырык ел гомерен татар тормышында ялгыз үткәргәнен, үлгәндә янында йомшак сүзле бер кешесе булмаганын исе-

---

*Сима* — чырай, йөз.

цезгә төшереңез. Кичә генә әле үлгән Габдулла Тукаевны, гомерендә бер мәртәбә татар кызыннан сөйкемле сүз, сөйкемле бер хәрәкәт күрмәгән шул татар шагыйренең хәлен, трагедиясен уйлаңыз!.. Мин боларның икесендә дә татар хатыны бурычлы калды, вазыйфасын үти алмады, дия алам һәм дим. Сез бер җавап та таба алмыйсыз?

Сабир, Кадыйр, Шакир. Аламыз, аламыз, һәммәсенә җавап бирәмез.

Шакир. Зур башлы булмасалар, зур йөрәкле булдылар, зур йөрәклелек зур башлылыктан киммени?

Фатыйма. Кая?.. Андый һичнәрсә күрмим... Шуның өчен сез ирләргә безне олуглавыңызга, хөрмәтләвеңезгә рәхмәт, ләкин арттырып җибәреп, көткәнеңез буш чыкмасын дип куркам, мин татар кызы, татар хатынының җылы сүзенә, матур күз карашына мохтаҗ егетләр, татар хатынының вазыйфасын үти алмаганын да онытып, хатыннар хакы өчен тартыша торган татар каһарман егетләре хөрмәтенә, аларның саулыгы-сәламәтлеге хөрмәтенә кадәх күтәрәм!

Бар да эчәләр. Фатыйма бер тамчысын калдырмыйча бетерә дә утыра.

Һәммәсе. Браво, браво!..

Габделкадыйр, Шакир *(сикереп торып икесе дә)*. Безгә бирәр генә сүз...

Фатыйма. Башым авыртты... *(Торып чыга башлый.)*

Гайшә. Минемчә, җитте. Ашамыйсыз да, эчмисез дә, болай гына сөйләшеп утырыйк әле...

Габделкадыйр. Мин бер генә сүз әйтәм.

Шакир. Мин Фатыйма туташның сүзләрен җавапсыз калдыра алмыйм.

Хәзрәт. Мәҗлеснең рәсми кыйсьме ябылды.

Сабир. Шулай, хәзрәт, болай гына сөйләшеңез!

Фатыйма чыгып китә... Аның артыннан Әсма барып култыклый.

Сабир *(Гайшәгә)*. Бер-бер нәрсә уйнап ал, азрак һава ачылсын!

Абызтай. Уйна әле!..

Габдулла. Уйнагыз әле, Гайшә ханым!

Гайшә торып китеп рояленә утыра, ноталар актара башлый, мәҗлес катында Шакир берлә Кадыйр кул селкеп сөйлиләр, теге очында Әсма берлә Фатыйма.

---

*Кыйсем* — өлеш, бүлек.

Ә с м а. Йә, шәп сөйләдең, Фатыйма, менә синең кебек булсаң иде.

Ф а т ы й м а. Булма, булма! Үзең бул, Әсма, үзең!

Ә с м а. Габдулла әфәнде йотарлык булып сиңа карап торды.

Ф а т ы й м а. Ул гына җитмәгән иде, шул бәхетсезлек кенә калган иде.

Ә с м а. Ник, сөю бәхетсезлекмени?..

Ф а т ы й м а. Бөтен йөрәкне биреп, тирә-яныңны күрмәенчә сөю — бәхетсезлек!.. Һәрвакыт йөрәкнең бер почмагын гына буш калдырырга кирәк.

Ә с м а. Син ничек сөясең?

Ф а т ы й м а *(биленнән кысып)*. Ташла шуны! Минем берлә һич бервакыт сөю тугрысында сөйләмә! *(Күзеннән яшен сөртеп.)* Җәмә, Әсма!

Ә с м а. Фатыйма, мин сине туганым кебек күрәм, ләкин син әллә нинди.

Ф а т ы й м а. Куркынычмы?

Ә с м а. Юк, юк, түгел...

Ф а т ы й м а. Беләм, Әсма, беләм... Сиңа минем кебек булырга Алла язмасын. Син булмыйсың! Менә Шакир әфәндегә кияүгә чыгасың. Син аны сөясең, ул сине. Сезнең тубырдап тора торган балаларыгыз була. Бергә мөгаллим буласыз, бергә дәфтәр төзәтәсез, бары да бергә.

Ә с м а *(көлеп)*. Рәхәтме, Фатыйма?!

Ф а т ы й м а. Рәхәт! Рәхәт!

Ә с м а. Син авырсынма, мин синең дә рәхәт торуыңны телим, синең дә тыныч, әнә әллә нәрсәң бармы, әйтә алмыйм, шунсыз...

Ф а т ы й м а. Әнә шул әллә нәрсә — ул минем бәхетсезлегем... Аңлыйсыңмы? Бәхетсезлегем. Шул мине Идел буеннан Себергә куды. Шул мине моннан инде кая куар?

Ш а к и р б е л ә н К а д ы й р *(кулларын бутап-бутап Фатыймаларга киләләр)*. Юк, ул хаксыз, ул хаксыз, татар хатыны чапанын атты, татар хатыны сәхнәгә чыкты, татар хатыны курсларга керде...

Фатыйма янына килеп җитүгә, музыка уйнарга башлый. Гайшә ханым «Тәфкилеф» көен уйный. Бары да моңланып тыңлый... Уйнап бетергәч:

Х ә з р ә т. Шул көй тамырлардан йөри...

С а б и р. Барымызга да шулай.

О с т а з б и к ә. Сезгә, Фатыйма туташ, нине хәтерләтә шул көй?

Ф а т ы й м а. Бормалы, бормалы Ак Идел буйларын, киң, озын Дим буе яланнарын.

Г а й ш ә. Миңа Казанны.

С а б и р. Миңа бала вакытларны...

Ә с м а. Миңа да бала вакытларымны.

Г а б д у л л а. Миңа хәзерге хәлемне... Йөрәгемне ярып кулыма тоттырып бирә.

Габдулла акрын гына басып Фатыйма янына килә.

Ш а к и р, К а д ы й р *(Гайшә ханымга).* Йә, тагы берне генә, тагы берне генә, Гайшә ханым, берне генә!

Габдулла Фатыймага әллә нәрсә сөйли. Әсма китә.

Г а й ш ә. Юк, Шакир әфәнде, җитте.

Х ә з р ә т. Йә инде, Гайшә ханым!

С а б и р. Инде, кыстатма инде!

Г а й ш ә. Нәрсә уйныйм соң?

Ш а к и р. «Кара урман!»

Х ә з р ә т. «Кара урман!»

А б ы з т а й. «Әллүкәй-бәллүкәй».

Ш а к и р, х ә з р ә т. «Кара урман», «Кара урман».

Г а й ш ә. Мин шул аны чыгара алмам. Ул бик авыр. Чәбәлчек.

Г а б д у л л а *(икенче очта Фатыймага).* Сезнең сүзләргә, туташ, мин риза түгел.

Ф а т ы й м а. Мин үзем дә риза түгел дә, хакыйкать шул! Мин анда бик күп дәлилләр китерә алмадым, мин татарның олуг кешеләренең бик күбесенең тормышын беләм. Бу ел уйламаганда гына бер хатыннар яклаучы кешегә очрап: «Сез үзеңезнең хосусый тормышыңызда яхшы татар хатынына очрагансыз да, бөтен татар хатынын шул ноктадан карап идеализировать итәсез»,— дигән идем, кып-кызыл булды. Аңладым, иң авырта торган җәрәхәтенә барып бәрелдем. «Мин, туташ, татар хатыныннан җәфадан башка бернәрсә дә күргәнем юк, минем хатын-кызны тәкъдис итүемнең тирән сәбәпләре бар»,— диде. Шунда кәефе бозылды, сүзенең тәме китте. Андыйларны мин берне түгел, унны беләм...

Г а б д у л л а. Сезнең кебек туташларны йитештергән аналар башкаларны да йитештерер әле.

Ф а т ы й м а. Рәхмәт илтифатыңызга, Габдулла әфәнде! Андый шаяруны яратмавымны беләсез бит!

Г а б д у л л а. Мин шаярмыйм, хакыйкать, сезне бик олуг күрәм.

Ф а т ы й м а. Хата итәсез. Мин гадәти татар кызы. Башыңыздагы татар кызы хакында ясаган идеалыңыз буявы берлә мине буяп, миннән әллә кемне чыгармаңыз! Мин — мөгаллимә Фатыйма.

Габдулла. Мин — мөгаллим Габдулла, менә мин һич буямый-нитми сезнең үзеңезне генә олуглыйм... Яратам...

Фатыйма. Рәхмәт! Иптәш кешеләр бер-берсен олугларга, яратырга кирәк. *(Гайшәләргә таба китә.)*

Габдулла тик кала. Ул ялгыз әллә ни уйлап идән буйлап йөри. Музыка «Кара урман»ны уйный. Беткәч, кул чабалар. Габдулла букетны күтәреп Фатыймага таба бара да туктый. Фатыйма карап тора.

Габдулла. Фатыйма туташ! Фатыйма туташ... Шул чәчәкне рәхим итеп кабул итүеңезне үтенәм...

Фатыйма. Рәхмәт, Габдулла әфәнде! Иң әүвәл ул кадерле балаларның сезгә пакь мәхәббәтләренең мөҗәссәме булган шул чәчәкне очраган бер хатынга бирү балаларны җиңелгә санау була... Икенчедән...

Габдулла. Нинди очраган бер хатын? Мин сезгә бирәм! Сезгә, аңлыймсыз, Фатыйма туташка! Шул балаларның мәхәббәтләренең мөҗәссәме, шул чәчәккә үземнең сезгә булган пакь ихтирамымны кушып бирәм...

Фатыйма. Илтифатыңызга рәхмәт, ләкин сез дә миннән бер бүләк алачаксыз!

Габдулла. Баш өсте.

Фатыйма букетны ала да арасында иң пәҗегән бер розаны алып күкрәгенә кадый да

Фатыйма. Монысы сезгә, Габдулла әфәнде.

Габдулла. Туташ, туташ, сез нишлисез? Ичмасам, монысын, иң пәҗегәнен алдыңыз.

Фатыйма. Мин үземә муафигын алдым. *(Фатыйма китеп бара.)*

Хәзрәт *(торып)*. Бик рәхмәт өй хуҗаларына вә бөтен дуст-ишкә. Безгә рөхсәт.

Гайшә. Утырыңыз әле, утырыңыз әле!

Әсма берлә Шакир да кулга-кул тотышып, күрешергә килеп.

Шакир, Әсма. Бик рәхмәт!

Габдулла *(Фатыймага килеп)*. Без, Фатыйма туташ, бергә кайта торганмыз?

Фатыйма. Юк, Габдулла әфәнде, мин Гайшә ханымда беразга калам...

Габдулла. Бик яхшы, мин Сабир әфәндедә калырмын...

---

*Мөҗәссәм* — гәүдәләнеш.
*Пәҗегән* — шиңгән.
*Муафикъ* — лаек, тиешле.

Ф а т ы й м а. Юк инде, Габдулла әфәнде, мине көтмәңез... Мин, бәлки, озак торырмын.

Г а б д у л л а. Мин дә озак торырмын...

Ф а т ы й м а. Көтмәңез инде, көтмәңез...

Г а б д у л л а. Минем берлә кайтасыңыз килми?.. Мин... *(Акыртын гына китеп барысы берлән дә күрешә.)*

Ә с м а *(Фатыйма янына килеп)*. Син нишләдең? Габдулла әфәндене күзләре ут яна...

Ф а т ы й м а. Ташла, Әсма, ташла!

А б ы з т а й *(хәзрәткә)*. Болар арасында да башлана.

Х ә з р ә т. Башланса, мин никях укырга хәзер...

С а б и р *(ишетеп алып)*. Мин туй итешергә.

Һәммәсе күрешеп чыгалар. Гайшә берлә Сабир озатырга чыга, Фатыйма ялгыз кала... Пауза.

Ф а т ы й м а. Теге җәрәхәтеннән кан агуы йитмәгән, тагы башлана!.. Чыда, Фатыйма! *(Кәнәфигә утырып башын тота.)*

А к ы р т ы н г ы н а п ә р д ә т ө ш ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мәктәпнең мөгаллим өе, сәхнә икегә бүленгән. Уң якта Габдулла бүлмәсе, сул якта Фатыйма бүлмәсе. Пәрдә ачылганда ике бүлмә дә буш. Ерактан гына хор йырлый торган балаларның йырлаулары ишетелә. Ф а т ы й м а, аның артыннан Ә с м а килеп керә. Фатыйманың кулында дәфтәрләр. Фатыйма бара да өстәл янына утыра...

Ә с м а *(кулына башын тоткан, ачык көенчә)*. Минем сыйныфта көлке булды. Теге кара малай бар бит, шуны тактага чыгардым. Әллә нигә бик акрын гына, кыек-кыек басып кына чыкты. Мәсьәлә бирдем, әллә ни йире авырткан кебек көчләнеп кенә сузыла. Карасам, бер балагы озын, берсе кыска. «Алай ярыймыни, киемнәреңне рәтлә!» — дип куштым. Теләмәенчә генә чалбарын төзәтергә тотынган иде, зур ук шалкан төшеп тәгәрәп китмәсенме?!

Ф а т ы й м а *(көлеп)*. Синең сыйныфта да көлке, рәхәт, тормышың да шулай. Син, Әсма, чынлап бәхетле кеше. Минем сыйныфта да булды, ләкин үз язмышымча булды: бер малайның күзе шулкадәр минем бервакытны таныган, шул күзләрдән Себергә кадәр качып килгән күзләргә охшаган... Аның селкенүе, ябылуы, кысылуы, көлүе, ачулануы... һәммәсе... Шуның баласы дип белерсең... *(Торып йөри башлый.)* Язмыш мине, Әсма, җәбер-

ли, көчли... Мин нишләгән?.. Ни өчен... Мин шулкадәр начар, усал кешемени?..

Әсма. Юк, Фатыйма, юк! Син бик һәйбәт, менә бик һәйбәт, мин сине кем диим икән... Дустым, тутам — кечкенә була... Мин сине анам итәр идем... Син, Фатыйма, мине синнән карт дип көлә диярсең. Валлаһи, болай гына анам итәр идем...

Фатыйма. Аңлыйм, Әсма! *(Килеп анын битен сөеп.)* Синең мине сөюеңне бик зурга саныйм. Сине чынлап яратам... Чын да мин анаң булсам, нинди кызык булыр иде. Минем синең кебек бәхетле кызым, Шакир әфәнде кебек сиңа җанын җарып бирергә хәзер киявем булыр иде... Аннары балалары китәр иде. Мин шулар белән чубырдашыр идем. Юындырыр, киендерер, үти-үти иттерер идем.

Әсма. Фатыйма, син ничә яшьтә?

Фатыйма. Туганыма 24 ел. Яшем кырыкта...

Әсма. Ник син, Фатыйма, алай сөйлисең?!

Фатыйма. Дөрест шул, Әсма! Мин бер сәгатьне ун ел яшәдем — утыз дүрт булдымы, бер көнне биш яшь картайдым — утыз тугыз булдымы, бер минутта бер еллык вакыйга кичердем — кырык булдымы?

Әсма. Юк, түгел, син әле бик яшь, менә, Фатыйма, үз бәхетең булыр. Синең дә шундый сиңа җанын бөтенләй җармаенча бирә торган матур, гакыллы бер кияүгә чыгарсың, синең дә матур балаларың булыр. Әнә теге малайның күзе төсле күзле балаларың булыр...

Фатыйма *(кычкырып)*. Булмас! Булмас! Бер вакытта да андый күзле балаларым булмас! *(Торып йөреп китә. Әсма тик катып тора... Фатыйма барып сөялеп башын тота. Пауза... Бераздан соң.)* Әсма, син мине гафу ит, сиңа яңлыш кычкырдым.

Әсма *(барып)*. Фатыйма, Фатыйма, ачуланма! *(Биленнән кочаклый.)* Синең бөтен тормышыңны җәрәхәтли торган шул җәрәхәтне миңа ач! Мин синең кебек гакыллы, укыган булмасам да... *(Йөрәгенә күрсәтеп.)* Менә мин йөрәк белән аңлый беләм... Ач миңа йөрәк сереңне!! Беркемгә дә, беркемгә дә... Шакирга да сөйләмәм. Үзеңә җиңел булыр, Фатыйма. Йә, бәгырем, Фатыйма...

Фатыйма. *(Әсманың җилкәсенә башын куеп үкереп еглый)*. Бер сөйләрмен, Әсма! Чыдый алсаң, сөйләрмен. Юк, сөйләмәм, сорама! Сөйләмәм, аңларлык түгел!..

Әсма *(кулы белән Фатыйманың башын сыйпап)*. Бар да бетәр, Фатыйма! Бар да бетәр. Менә мин дә шулай булган идем... Сөйгән чакта һәрвакыт шулай була икән...

*(Әсма бераз туктый.)* Беләсең, Фатыйма, бу бүлмә минеке иде... Тегесе, әнә теге яктагысы Шакирныкы иде... *(Йөри башлыйлар.)* Менә шунда минем караватым иде... Теге якта Шакирның караваты мондарак иде... Акыртын гына күчерә-күчерә аныкы тугрысына китереп җиткердем. Йә, шунда бердән китереп куйсам ни була инде. Бүлмәмдә бер кеше дә юк бит, әллә нидән куркасың... Менә монда, Фатыйма, безнең тишек тә бар иде... Ахырга таба төн буе сөйләшеп ята идек... *(Барып карап.)* Әй, әле дә бар! Бар! *(Төртеп күрсәтеп.)* Менә, Фатыйма! *(Әсма карарга тотына.)* Чынлап күренә, бөтен бүлмә күренә...

Фатыйма *(ачуланып)*. Син гакылдан яздыңмы әллә, Әсма, кит, кит, томала, томала... *(Барып томалый, бер кәгазь алып килеп ябыштырып маташканда ишек шакыйлар.)*

Фатыйма *(күзләрен сөртеп)*. Боерыгыз!

Габдулла килеп керә, ул яңы киемнәрдән.

Әсма. Котлы булсын, Габдулла әфәнде!

Аның артыннан тыштан:

Шакир. Керергә ярыймы, Фатыйма туташ? *(Шакир күренә.)*

Фатыйма. Ярый, ярый.

Шакир. Алай димиләр аны... Аның догасы бар: Әлбиси җәдидә вә гашыйк* Хәмидә, ә... ә... Актыгын әйтеп булмый инде...

Фатыйма. Мин Габдулла әфәндегә шул актыктан башлар идем...

Габдулла. Шулаймы, Фатыйма туташ?

Фатыйма. Шулай, Габдулла әфәнде, ак нәрсә кер күтәрми бит!

Габдулла. Сезнең мине шулай пакь күрүеңезгә рәхмәт, туташ! Ләкин шул пакьлек мине сезнең күзеңездә фәрештә дәрәҗәсенә менгереп, кешелегемне оныттыра торган булса, ул пакьлекне җәһәннәмгә кадәр ыргытып, былчырак диңгезендә чумарга гына кала!

Фатыйма. Минем сыйныфта бер баланың күзе авырый, шуны нишлимез, Габдулла әфәнде?

Габдулла. Күзе авырый... чын, күзе авырый. Уйлашырга кирәк.

---

*Оригиналда «гыйшык» дип язылган.

Шул арада Әсма Шакирга карават куйган йирне күрсәтә, кулы берлә әллә нәрсә сөйли... Шакир көлеп тора, Әсма буталганда Шакир үбеп ала.

Әсма. Кит, тиле, күрәләр, күрәләр. *(Акыртын гына кулына суга.)*

Фатыйма. Мин, әтиләренә әйтик, дим!..

Габдулла. Әйе, әйе, әйтик!

Фатыйма. Без бит, Габдулла әфәнде, мөгаллимнәр, балаларның сәламәтлеген карау — безнең вазыйфа!

Габдулла. Әйе, әйе, безнең вазыйфа... Ләкин, туташ, без соң шулай мөгаллимнәр генәме?.. Ничек дип әйтим, без — кешеләр дә, иң гади кешеләр дә түгелме?.. Миндә хәзер шул уй туды, туды гына түгел... үсте. Мин, мөгаллим Габдулла, Себердә зур мәктәп ясый алган Габдуллалыктан аерыласымы, дим, кыскасы гына, гади Габдулла гына буласым килә башлады... Себердә мин мәктәп ачмасам, минем мөгаллимлегемә сигез ел тулмаса, минем бертөрле кыйммәтем булмас идемени?.. Мин кеше түгелмени?

Фатыйма. Булыр иде. Ул вакытта сезнең бер гәзитәдә, бер журналда эшләвегезнең юбилеясе җиткән булыр иде, яисә бер-бер китапханәме диим, ни булса да шундый бер эштә исемегез шөһрәт алган булыр иде.

Габдулла. Менә мин шуларның барысыннан да арынып, Габдулла гына [булып] каласым килә... Аңлыймсыз, Габдулла гына буласым килә! Әни күзендә мин бит Габдулла гына, шулай буласым килә... Сезнең күздә... мин бер дә Габдулла түгелмени, туташ? Гафу итеңез, туташ!

Фатыйма. Мин — мөгаллимә, Габдулла әфәнде, сез — мөгаллим. Без бер милләтнең укытучылары. Вазыйфамыз, бурычымыз бергә-бергә булыр. Бер-беремезгә укыту, тәрбия эшләрендә ярдәм итешермез. Мин һәрвакытта вазыйфамны үтәргә хәзер, Габдулла әфәнде!!

Габдулла. Рәхмәт, туташ, вазыйфа үтәргә сез хәзер! Кирәк булса, минем дәфтәрләремне төзәткәләрсез?..

Фатыйма. Төзәткәләшермен...

Габдулла идән буенда йөри.

Әсма *(Фатыймага килеп)*. Беләмен, Фатыйма, бу бит сине сөя! Беләмсең?..

Фатыйма. Белмим, белмим, беләсем килми... җитте...

Габдулла *(борылып килеп)*. Фатыйма туташ, мин әле шуны әйтмәкче идем. Безгә икенче рөшдинең про-

---

*Рөшди* — урта мәктәптәге сыйныф.

граммасы хакында сөйләшергә кирәк... Бүген кичкә сез миңа киләсезме, минме сезгә?

Фатыйма. Программа хакында? Алай булгач Шакир әфәнде берлә Әсма да була...

Габдулла. Юк, безнең икемезнең программаларымыз хакында гына...

Фатыйма. Сез ничек телисез?

Габдулла. Мөмкин булса, мин сезгә килим. Сездә әллә нинди йомшак, җылы һава бар. Минем бөтен авырткан йирләрем язылып китә... Ярыймы, туташ!

Фатыйма. Рәхим итеңез, Габдулла әфәнде...

Звонок ишетелә.

Габдулла. Әсма ханым, Фатыйма туташ, мин сезгә бөтен мөгаллимәләр, мөгаллимнәр бергә бер рәсем чыгартыйк, дим! Мәктәпнең сигез еллык бер ядкяре булсын.

Фатыйма. Мин бит, Габдулла әфәнде, монда ике айлык кына мөгаллимә, минемчә, сез өчеңез генә чыгарырга тиеш!

Габдулла. Юк, алай түгел, бөтен мөгаллимәләр, мөгаллимнәр... Ул ни дигән сүз ди? Сез моңынча безнең арада булмасаңыз, Фатыйма туташ, ул бер язмышның хатасы гына булган! Сез безнең арада булырга тиеш булган һәм хәзер дә булырга тиеш!

Фатыйма. Аны белеп булмый, Габдулла әфәнде. Бәлки, минем хәзер сезнең арада булуым — язмышның хатасыдыр...

Габдулла. Разыймы?

Шакир, Әсма. Разый, разый!

Габдулла *(Фатыймага)*. Сез, туташ?

Фатыйма. Кирәк булса, ярый... Минемчә, мин анда артык...

Габдулла. Анысы хакында сөйләшермез... Сез риза, шул җитте... Дәрескә.

Габдулла, Шакир чыгып китәләр, Габдулла үз бүлмәсендә күренә. Ул зур-зур атлап йөри, ике арасы булган дивар янына килеп туктап тора да тагы китә. Бераздан.

Габдулла. Туташ! Туташ! Син минем йөрәгемнең кайнаганын ишетәмсең? Син минем газабымны, минем җәһәннәм газабымны күрәмсең? Туташ! Син күрмәскә тырышасың... Туташ, минем йөрәгемне кырыкка ярасың! Туташ, ишет! Туташ, тыңла, мин сине сөям. Сөям... сөям... Бөтен дөньядагы бөтен сөючеләрнең сөюеннән артык сөям... Туташ, мин синсез тора алмыйм... Мин

синсез яши алмыйм... Син миңа җан, син миңа һава. Синсез томаланам, тончыгам... Туташ, туташ! Ишет, туташ!.. Туташ, ишет минем зарымны! Ишет минем моңымны!.. Ишет, туташ!..

Башын тотып утыра...
Теге якта Фатыйма ялгыз йөреп тора, Әсма утырып карап торганда, бер малай дәфтәрләр күтәреп килеп керә.

Фатыйма *(малайга)*. Кил монда, кил! *(Аны кулыннан тотып тәрәзә янына китерә. Бөгелеп күзенә карый, башын сыйпый. Әсма аптырап карап тора.)* Синең исемең ничек?

Малай. Садыйк!

Фатыйма. Әхмәтсадыйк... Әхмәтсадыйк... Садыйгы җитмәгәнме, аның ник Әхмәте кирәк булды инде...

Малай. Әти үземезнең мулла абзыйның угылының исеме булсын дип шулай куштырды...

Фатыйма. Мулла абзыеңыз кай ягы?..

Малай. Еракта, еракта. Мин анда барганым юк, әни генә сөйли. Анда безнең урманда кура җиләге, чия, карлыган үсәдер, ди, күлләрдә, суларда балык бик күп, ди. Чабак балык, беләсез, Фатыйма туташ, чабак балык... Ул Казан ягында, Каенлык авылы.

Фатыйма. Каенлык авылы... Шул, шул!.. Син Каенлык авылының... Синең исемеңне муллаңызның угылы исеменә охшасын дип Әхмәтсадыйк куштылар... *(Кулыннан тотып урындыкка бастыра да, тагы күзенә карый.)* Шул, шул... *(Малайның ике күзеннән чуп-чуп үбә дә борылып китеп әйләнеп килә, малай аптырап тора: Фатыйма өстенә карамаенча гына.)* Бар чык, Әхмәтсадыйк.

Бала карана-карана гына чыгып китә.

Әсма. Шулмыни, Фатыйма?

Фатыйма *(калтырап китеп)*. Син мондамыни? Син мондамыни?..

Әсма. Монда, Фатыйма! Миннән курыкма!

Фатыйма. Әйдә, әйдә, сыйныфка. Без — мөгаллимә! Без балалар укытырга, киләчәк буынны бәхетле, сәгадәтле булырга хәзерләргә тиеш. Без — мөгаллимә, бу безнең вазыйфамыз. Йөрәк эшләре, йөрәк шатлыклары безгә хәрәм. Хосусый сәгадәт, тормыш рәхәте безгә хәрәм ителеп яратылган. Әнә анда дивар артында тагы бер мөгаллим газап чигә. Минем кебек үк газап чигә. Чигәчәк... Чөнки без гомум мәхәббәтнең корбаннары. Шул гомум мәхәббәтне бер минутка да, бер сәгатькә дә үземезгә борырга, үземезгә

иялəндерергə хакымыз юк. Ул безгə хəрəм... Ул безгə катрəсе каннан яман хəрəм... *(Чыгып китə.)*

Шул арада Габдулла да торып чыгып китə. Сəхнə беразга буш кала... Габдулла ягында акрын гына ишек ачыла да, юл киемнəреннəн, толыплар, туннардан Габдулланың атасы, анасы юлдан килеп керəлəр.

Карчык. Шул микəн?

Карт. Шул, шул! Хезмəтчесе, ди бит.

Зур-зур ике букча куялар. Алар артыннан бер кеше тагы өч-дүрт төен алып керə.

Карчык *(аптырабрак тора.)* Безнең Габдулла шунда торамыни?

Хезмəтче. Шунда, абыстай, шунда.

Карчык *(картка)*. Əйберлəрем онытылмасын. Казым, күркəм бар иде, Габдуллага ашатырмын дигəн идем. Калдырма. *(Карт чыга башлый.)* Кортлы маены, юачасыны, чəкчəгене, балыны онытма! *(Карт чыгып китə. Карчык туннарын сала-сала.)* Шунда тора. Ризык язып кына китермəгəн булса ярый инде, гомерендə бер мəртəбə авылыннан чыкмаган кеше алты мең чакрымга кил, имеш. Будыр менə угылымның караваты...

Хезмəтче тагы өч-дүрт төен алып керə.

Карчык. Анда минем ястыгым бардыр. Аннары, кара əле, кызыл салфетка тыккан билчəннəрем бар иде. Бер савытта сөзмə алган идем. Шуларны калдырма.

Хезмəтче. Ярар, абыстай.

Хəзрəт өч-дүрт төен күтəреп керə. Хезмəтче аның артыннан бер кочак төеннəр күтəреп кереп идəнгə ташлый. Бөтен өй əйберлəр берлə тула. Хəзрəт тишенергə тотына. Абыстай бөтен əйберлəрне акрынлап-акрынлап чөйлəргə элə. Сандык, өстəленə куя. Караватка сала. Бөтен өй əйберлəр берлə тула.

Хəзрəт *(тишенə-тишенə)*. Əйттем мин, икенде намазын вагунда гына укы, дидем. Менə хəзер кояш кереп бара торгандыр... Синең əле фарызың өстеңдə.

Остазбикə. Минем, хəзрəт, шул, вагунда укыган намазым намаз булмый кебек, анда кеше, монда кеше. Дөберди, шатырдый. Угылым өендə рəхəтлəнеп укыйм, дидем.

Хəзрəт. Габдулла кая соң?

Остазбикə. Укыталардыр.

---

*Катрə* — тамчы.

Х ә з р ә т. Укытса ни?

О с т а з б и к ә. Боларда бит, теге, яңы укыту — сәгатьләп, яисә дәшмәгәннәрдер дә. Менә син тишенгәләгәнче килеп тә керер.

Х ә з р ә т *(кырык кат киемне тишенеп маташа. Габдулланың сәгатенә карап)*. Моның сәгате ничә? Алда бу. Мин Казанда гына тигезләп чыктым. Сәгать ярым алда... *(Торып, сәгатен артка итә.)*

К а р ч ы к *(китаплары янына барып)*. Хәзрәт, китабы, Коръәне шактый икән. Син юктан куркасың, дидем. Безнең Габдулла, Аллага шөкер, ул азып-тузып йөрерлек түгел.

Х ә з р ә т. Шулай да күзең күрмәенчә күңел тынычланмый.

О с т а з б и к ә *(караваты астына карап, әллә никадәр керле күлмәкләр өстерәп чыгара)*. Менә шулай булыр инде ирләрнең, күлмәк-ыштаны кая өстерәлеп йөри... Күптән өйләндерергә вакыт.

Х ә з р ә т. Вакыт та бит, тәкъдир язмаенча булмый.

О с т а з б и к ә. Мин шул үземезнең Садретдин мулланың кызын никадәр алыйк, дидем... Син шуны иплә йөремәдең.

Х ә з р ә т. Юк угылыңа ничек иплә йөрисең. Без алырмыз да, ул нишләр?

О с т а з б и к ә. Габдулламы? Габдулла ул этисе-әнисе сүзеннән чыкмас.

Х ә з р ә т. Йә, күп сөйләмә, намаз вакыты үтә. Тәһарәтең бармы?

О с т а з б и к ә. Хәзер, хәзер. *(Барып комган карарга тотына.)* Әллә комганы юк?

Х ә з р ә т. Булмас та аларның...

Шул арада Г а б д у л л а чабып килеп керә. Габдулла этисе белән күрешеп кулын үбә. Әнисен кочаклый.

Г а б д у л л а. Сез килдеңезмени?.. Менә рәхмәт... Миңа әйтмәгәннәр. Исән килдеңезме? Бик арымадыңызмы?

О с т а з б и к ә. Юк, угылым... Нинди зур булгансың, кил әле, башыңнан сөярмен дигән идем.

Габдулла килеп әнисенең күкрәгенә башын куя, әнисе сөяргә тотына, Габдулла җылап җибәрә.

Х ә з р ә т *(бераз карап торганның соңында якынрак килеп)*. Ни булды, угылым, сиңа? *(Ул да килеп башын сыйпарга тотына. Остазбикә яулык очы берлән күзеннән яшен сөртә.)*

Г а б д у л л а. Юк, эти, берни булмады. Шатлыгымнан гына чыдый алмадым. Сезне бик сагынган идем. *(Китә.)*

Хәзрәт. Сагынмаслык та түгел, дүрт ел уен түгел.

Остазбикә. Күрше Галим угылы солдаттан кайтты, син һаман юк.

Хәзрәт. Йә, җитәр, әниеңнең икендесе укымаган, комганың кая?

Габдулла. Хәзер, хәзер, менә монда, әни, монда. *(Әнисене умывальникка китереп куша.)*

Остазбикә *(кулыны сызганып, умывальник янында маташа да)*. Габдулла, Габдулла, бәбкәм, теге комганың юкмы, мин моны белмим.

Габдулла *(килеп)*. Менә, әни, шулай *(суыны агызып күрсәтә.)*

Хәзрәт *(килеп)*. Комган юкмыни? Тәһарәтнең фарызлары күп, моның берлән ничек эшләп бетерәсең.

Габдулла. Бар иде, бар иде. Әле ага башлады да, төзәтергә җибәргән идем. *(Хезмәтчегә.)* Миңлебай, Миңлебай! *(Хезмәтче керә.)* Самавырың кайнадымы?

Хезмәтче. Кайный.

Габдулла. Алай булса, менә шул акчага Сабир әфәнделәрдән ашамлык-эчемлек алып кил, үзе белеп бирер, кунаклар бар, диген. Гайшә ханымнан бер комган берлән таз сора, тиз йөре!

Хезмәтче. Мин самавырны кертеп китим, алай булса.

Хәзрәт. Угылым, монда сезнең имам кем?

Габдулла. Габделвахит әфәнде!

Хәзрәт. Алай икән, кайда укыган?

Габдулла. Казанда.

Хәзрәт. Кыйраәте кемнән?

Габдулла. Белмим. Шаһи морзадан микән, корыч мәкаме берлән укый.

Хәзрәт. Эһе, эһе. Корыч мәкаме булса, Шаһи морзадан булмас.

Самавыр керә. Габдулла кызуланып-кызуланып чәй урыны хәзерли, карчык тәһарәт төзеп маташа.

Габдулла. Габдерахман сәламәтме?

Хәзрәт. Сәламәт. Ул да, шул, синең арттан бармакчы була, әллә нәрсәләр язган иде, хәлфәләремез андый, хәлфәләремез мондый, дигән булган. Мулла булырга русчага имтиханга хәзерләнәм дигән. Син дә шулай дигән идең бит. Сез бит барыңыз да мулла булырга имтиханга хәзерләнәсез, мулла булырга рәт җитсә — сез юк.

---

*Кыйраәте кемнән?* — Коръәнне укырга кемнән өйрәнгән?
*Мәкам* — көй, тон, мотив.

О с т а з б и к ә. Ник алай булсын, юкны сөйләмә әле, хәзрәт, тәһарәтемне бүлдерәсең. Менә, Аллаһе теләсә, Габдулла кайтыр да бик һәйбәт мулла булыр. Бөтен мәхәллә халкы, угылым, үлеп көтеп торалар...

Г а б д у л л а. Рәхмәт... Кая инде бездән мулла булулар, күңел каралган инде, әти...

Х ә з р ә т. Биш вакыт намазны калдырмасаң, җәмәгать намазына дәвам итсәң, каралмас. Мин ахшамга бармасам, яхшы түгел инде. Чәй дә әчәсе килде.

Г а б д у л л а. Юк, бу бит шәһәр, монда бит алай тикшереп тормыйлар.

О с т а з б и к ә *(Габдуллага килеп)*. Бу нәрсәңне әтиең бер дә яратмас. Бу шул, теге, түгәрәк берлән кул юа торган — марҗалар өчен генә. Әнә шунда безнең комган бардыр, чишеп ал. Мин намаз укып алыйм. *(Бер бүлмәдән чыга.)*

Г а б д у л л а. Утыр, әти...

Х ә з р ә т. Мин монда кая утырырга да белмим.

Г а б д у л л а. Менә шунда.

Урындык күрсәтә, хәзрәт акрын гына, куркынып кына утыра. Габдулла чәй ясый. Хезмәтче комган, таз, конфетлар, печеньелар, чикләвекләр алып кайта. Габдулла ашамлыкларны тәрилкәгә салып куя.

Г а б д у л л а. Йә, әти, эч.

Х ә з р ә т. Дүрт көннән бирле юньле чәй эчмәдем. Самавыр кайнап тормагач, чәйнең тәме буламыни? Үтәмишевләр чәеме?

Г а б д у л л а. Белмим, әти...

Х ә з р ә т. Ничек белмисез? Цәйлүн чәйләре түгелдер бит.

О с т а з б и к ә. Намазымны яңлыштырып бетердеңез, цәйлүн чәе булмый соң, исе үк нәхуш ла соң, хәзрәт. Йә, угылым, яса әле. *(Догасыны кыла-кыла килеп утыра... Урындык батып киткәч.)* Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, куркып киттем...

Шул арада Ф а т ы й м а үз бүлмәсенә дәфтәрләр күтәреп керә. Акрын гына лампасыны яндыра да кулына гитара тотып уйнарга тотына.

Х ә з р ә т *(колагыны салып)*. Бу нәрсә тавышы, Габдулла?

О с т а з б и к ә. Сәгать уйный торгандыр. Безнең мөәззиннәр дә уйный торган сәгать алып кайтканнар, уникe тәнкә дигән була. Булыр инде, дидем.

Х ә з р ә т. Бу сафсатаны шактый моң уйный... *(Абызтай да тыңлый.)* Шәкерт вакыттагы хозурларны искә

төшереп җибәрде. Чәең Үтәмишевнеке булмаса да, нәшьәле икән, Габдулла.

Остазбикә. Бик моң уйный, бу кем, угылым?

Габдулла. Фатыйма туташ... Минем иптәшем...

Хәзрәт. Ничек соң иптәшең? Син өйләндеңмени? Атаң-анаңа хат-хәбәр дә итмәенчә өйләндеңмени?

Габдулла. Юк, әти, юк. Мәктәптә укытучы мөгаллимә... Бергә укытамыз, ул шунда тора...

Хәзрәт *(барып диварларны тотып карап)*. Ул шуның теге ягында тора?!. Ялгыз тора?!. Бу, әлбәттә, хәлвәте сахихә булмый. Ләкин шәрган, мотлакан, дөрес түгел.

Остазбикә. Син, хәзрәт, бәли, юкны сөйләмә әле, ул аерым өйдә, Габдулла аерым өйдә. Шулайдыр бит, угылым?

Музыка дәвам итә. Шул ара да булмый, дөбердәшеп Әсма килеп керә. Аның артыннан Шакир килеп керә дә, Әсманы тота.

Шакир. Кәдаҗ, кәдаҗ.

Хәзрәт, абыстай, Габдулла аптырап калалар. Тегеләр дә, картларны күргәч, катып торалар.

Габдулла *(кызарып кына)*. Болар минем иптәшләрем.

Хәзрәт. Синең иптәшләр бик күп икән.

Габдулла. Мөгаллим Шакир әфәнде... Аның иптәше — нишанлысы Әсма туташ!

Абыстай яулыгын төшереп борылыбрак утыра.

Габдулла. Әйдәңез, Әсма туташ. Әйдәңез, Шакир әфәнде, утырышыңыз.

Әсма. Гаеп итмәңез, хәзрәт, без монда үзләшеп беткән инде. Габдулла әфәндегә чәй эчәргә дип кергән идек.

Хәзрәт. Сез дә укытасыз икән...

Әсма. Әйе.

Тегендә гитара тавышы тагы ныграк ишетелә.

Остазбикә. Син кай ягы, кызым?

Әсма. Мин, абыстай, Уфа ягы.

Остазбикә. Атаң-анаң бармы?

Әсма. Бар, абыстай, мөэзиннәр. Мин инде дүрт елдан бирле монда. Габдулла әфәнделәр берлән гел бергә.

---

*Нәшьәле* — кәефне хушландыра торган.
*Хәлвәте сахихә* — чын ялгызлык.
*Шәрган* — шәригать законнары буенча.
*Мотлакан* — һичшиксез.
*Кәдаҗ* — ядәч.
*Нишанлы* — вәгъдәле, ярәшелгән.

Х ә з р ә т. Гел бергә диген. Менә ул ни өчен авылына кайтып аталарының хәлен дә белми икән.

Ш а к и р *(утырып)*. Бу, хәзрәт, минем нишанлым.

Х ә з р ә т. Нишанлы. Шәригать, мәхрәм, намәхрәм. Мәхрәм, намәхрәм табигый булыр. Ана, сеңел, тута кебек — йәмәхрәм никяхы булыр. Бу берсе дә түгел.

Г а б д у л л а. Нишанлы. Алар бер-берсенә кияүгә чыгышырга сүз бирешкәннәр.

О с т а з б и к ә. Сүз бирешкәч, чыксалар ярамыймыни?

Ә с м а. Чыгамыз, чыгамыз, абызтай, курыкмаңыз... Габдулла әфәнде, тегендә Фатыйма ялгыз утыра. Мин барып алып килимме?

Г а б д у л л а. Бөтен күңелемнән, ләкин Фатыйма туташ килмәс шул.

Ә с м а. Килер. Мин үзем алып киләм, киләм.

Диварны шакый. Гитара туктала. Фатыйма дивар янына каушап кына килә.

Ф а т ы й м а. Габдулла әфәнде!

Ә с м а *(көлеп)*. Мин, Фатыйма, мин. Монда Габдулла әфәндедә чәй эчеп утырамыз. Хәзер сине алырга керәм. Хәзерлән.

Ф а т ы й м а. Минем башым авырта.

Ә с м а. Киттем. *(Чабып чыгып китә.)*

Х ә з р ә т. Синең нишанлың күбәләк кебек.

О с т а з б и к ә. Яшь вакытта барымыз да шулай буламыз.

Музыка дәвам итә. Габдулла идән буенда йөри.

Х ә з р ә т *(Шакирга)*. Син кая укыдың, егет?

Ш а к и р. Оренбургта.

Х ә з р ә т. Хәтме көтеб кылдыңмы?.. Әллә болай аяк өстеннән генәме?

Ш а к и р. Дөресте, хәзрәт, аяк өстеннәнрәк.

Х ә з р ә т. «Гакаид», «Тәүзыйх» күрдеңме?

Ш а к и р. Күрдем, хәзрәт.

Шул арада Әсма Фатыйма бүлмәсенә чабып керә.

Ә с м а. Әйдә, җаным Фатыйма! Әйдә.

Ф а т ы й м а. Юк, Әсма, бармыйм. Ник кешегә юк өметне бирергә кирәк.

Ә с м а. Бирү түгел. Аңарга сине күрү генә әллә никадәр шатлык бирә. Ул хәзер нинди сабырсызлык берлән көтә. Әйдә, ул кадәр каты күңелле булма! Әйдә. Анда

---

*Хәтме көтеб кылу* — укуны тәмамлау.

бик кызык. Габдулла әфәнденең әтисе берлә әнисе килгән. Әй кызык картлар.

Фатыйма. Кайдан?

Әсма. Казаннанмы шунда, әллә кайдан, ерактан, ерактан! Әйдә, күрерсең.

Фатыйма. Өметләндерү булыр дип куркам...

Әсма. Булмый... Аннары, беләмсең, безгә китәмез. Әйдә, әйдә. *(Фатыйманы тотып өстерәгән кебек алып чыгып китә.)*

Габдулла ягында:

Абызтай. Габдулла бәбкәм, Озын Салих бит үлде.

Габдулла. Ай мескен! Нишләп үлде?

Хәзрәт. Базардан кайткан да, «угланнар атларны караңыз», дип кергән дә, «карчык, арып киттем, мендәр сал әле», дигән. Мәхбүп абызтай мендәр салып чыгып киткән, тәһарәтләнеп кергәнче, карты җанын биргән. Алла иманын юлдаш итсен.

Шул арада Фатыйма берлән Әсма килеп керәләр.

Габдулла *(каршы барып)*. Боерыңыз, Фатыйма туташ. Рәхмәт илтифатыңызга. *(Кулындагы шәлене.)* Биреңез монда алып куйыйм.

Фатыйма *(абызтай янына килеп)*. Исәнмесез, абызтай, сәламәт килдеңезме. Юл бик ватмадымы? *(Хәзрәткә.)* Исәнмесез, хәзрәт, гаеп итмәңез. Без шулай качмаска өйрәнгән инде...

Хәзрәт. Шулай икән, шулай.

Абызтай. Килә-килә йөдәп беттек. Бала шул, китерә. Синең, кызым, атаң-анаң бармы?

Фатыйма. Атам бар, абызтай, анам вафат.

Хәзрәт. Кайдагы? *(Габдулла күзен тутырып карап тора.)*

Фатыйма. Без мишәр, Бөгелмә өязе. Өчөйле авылының.

Хәзрәт. Син әллә Хәмит мулланың кызымы?

Фатыйма. Әйе, хәзрәт... Шул.

Хәзрәт. Минем мәдрәсә иптәшем.

Остазбикә *(торып)*. Йә әле, Габдулла, син бер дә кунакларны кыстый белмисең икән. *(Шакир берлән Әсма чәй эчәләр. Карчык майлар, юачалар, чәкчәкләр китереп.)* Йәңез әле, ашаңыз әле. Үзем пешергән. Менә бал, үз умартамыздан, йәңез әле, кызым.

Фатыйма. Рәхмәт. *(Чәй эчә. Әллә ниләр ашый.)*

Хәзрәт. Шулай диген... Сезнең берлән сөйли-сөйли ахшам намазым кала язды. Кая, тәһарәт барда укып ка-

лыйк. *(Торып.)* Намазлыгың кая, Габдулла? *(Габдулла эзләргә тотына.)*

А б ы з т а й *(торып)*. Менә шуны җәяргә ярый бит. *(Габдулланың пальтосыны ала да чыгып китәләр.)*

Ф а т ы й м а *(торып)*. Рәхмәт, Габдулла әфәнде.

Әсма берлә Шакир йөриләр.

Ә с м а. Бу синең бүлмә иде, караватың шунда иде. *(Китеп, кулларыы берлән буташа, көлешә-көлешә әллә ни сөйлиләр.)*

Г а б д у л л а. Мин бүген, Фатыйма туташ, сезгә программа хакында керә алмыйм инде.

Ф а т ы й м а. Безнең бит, Габдулла әфәнде, программаларымыз бөтенләй аерым. Мин аларны берләштерергә һич мөмкин түгел дип уйлыйм.

Г а б д у л л а. Мин, туташ, шулкадәр газап чигәм, шулкадәр янам... Менә хәзер көчкә-көчкә аяк өстендә торам... Сез, туташ... *(Сүзен әйтә алмый.)*

Ф а т ы й м а. Аңлыйм, Габдулла әфәнде. Ләкин сезнең авыруга миндә дару юк, аңлыймсыз?

Г а б д у л л а. Аңламыйм... Аңламыйм...

Ф а т ы й м а. Аңламавыңызны да күрдем. Ләкин, Габдулла әфәнде, шуны аңлаудан башка чара юк. Әйдә, Әсма! Хушыңыз, Габдулла әфәнде. *(Бары да чыгалар.)*

Г а б д у л л а *(ишек янына килеп)*. Туташ! Туташ!

Җавап юк. Габдулла урындыкка тотынып катып тора.
К а р т л а р килеп чыгалар, кулларында тәсбихләр.

Х ә з р ә т. Син нишләдең, Габдулла?

А б ы з т а й. Ни булды, угылым?.. Йөзең китән кебек.

Г а б д у л л а. Юк, юк. Башым авыртып китте... *(Умывальникка барып битен юа... Бит сөртеп.)* Сез, әти, утыра торыңыз әле, чәй эчеңез, мин мәктәп эше белән тизгә генә барып киләсем бар. *(Кызу-кызу пальтосын киеп чыгып китә.)*

Х ә з р ә т. Баланың йөрәгендә бернәрсә бар, карчык!

О с т а з б и к ә. Бар, хәзрәт, бар!..

Х ә з р ә т *(кулын диварга күрсәтеп)*. Мин шуннандыр дим... Йә әле, самавырың сүнмәгән булса, кеше төсле чәй эчик әле, эчемә аш булып төшмәде.

Кызу-кызу өстәлне күчерәләр, хәзрәтнең толыбын түшәп, бер кызыл эскәтерне җәеп идәнгә утыралар.

Х ә з р ә т. Менә болай, ичмасам, күңелгә тулды. Чәе нәшьәле, остазбикә. Бу кызый миңа үзе ошады, салмак, сабыр.

О с т а з б и к ә. Габдулла ничек алдында бии...

Х ә з р ә т. Син караш, анасы, күптән өйләндерергә вакыт.

О с т а з б и к ә. Шулай, хәзрәт, шулай. Карашырга кирәк, карашырга!

Х ә з р ә т. Өйләндерү бит ата-ана вазыйфасы... Өйләндерергә кирәк, өйләндерергә.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Фатыйма туташның бүлмәсе. Тышта суык җил ыжгыра. Фатыйма җилкәсенә шәл салган да өстәл янында басып тора, кулында бер кәгазь. Пәрдә ачылгач озын гына пауза. Җил сызгыра, өй түбәсе шатырдый.

Ф а т ы й м а *(кулындагы кәгазьне укырга тотына)*. «Туташ! Сез минем күршемдә, шул диварның теге ягында, бәлки, мин утырып шул хатны язган йирдүк тынычлап йоклап ятасыз... Сез төшеңездә аллы-гөлле бакчаларда, бормалы-бормалы буйлы Идел буйларында, киң яланлы Дим тирәләрендә йөри торгансыз? Сез җәннәт хурларының җырларын ишетә, андагы гыйльманнар, вилданнарның нечкә, нәзек милли көйләремезне уйнауларыннан ләззәтләнә торгансыз, сез, туташ, бәлки, төшеңездә үзеңезне-үзеңез бала иттереп күрә торгансыз да әниеңезнең кочагында тәгәрәп-тәгәрәп уйный торгансыздыр...

Бәлки сез үзеңез сөйгән, үзеңез җаныгызны фида итәргә хәзер булган бәхетле егетнең кочагында ауный торгансыздыр, аның авызын, йөзен уттан кайнар, җәннәт нигъмәтеннән татлы бүсәләр белән бизи торгансыздыр. Мин, туташ, сезнең табан астыңызны үбәргә, дөньядагы бөтен зурлыклар, бөтен олуглыклар,бөтен бөеклекләрне корбан итәргә хәзермен, күз яшьләремә карылып, кичнең яртысында шул хатны каралап ятам. Сезнең күңелегездә кечкенә дә бер эз калдырмаячак, сезнең кулыңызда кирәкмәгән баш әйләндергеч, эч пошыргыч шул кәгазьне йөрәк маем, күз яшем белән язып маташам... Туташ, сез рәхәт-рәхәт йоклаңыз, төшеңездә генә түгел, көнеңездә дә гөлбакчаларында гизеңез, бәхеткә, сәгадәткә коеныңыз, чумыңыз... Сезнең хакыңыз бар, дөнья сезгә никадәр бәхет бирсә дә, тормыш сезгә никадәр рәхәт багышласа да, ул үзенең бурычын үтәп бетермәгән була. Сез, туташ, олугсыз, сез бөексез, сез — мәсгуд, шат, рәхәт булырга тиешсез. Сез бәхетле, шат булыңыз!..

---

*Бүсәләр* — үбүләр.
*Мәсгуд* — бәхетле.

Туташ! Минем янган йөрәгемнән чыккан утны, туфанны күрмәвеңезгә, минем эчем-тышым, бөтен барлыгымны яндырып-көйдереп көл итә торган шул янгынга су сипмәвеңезгә, шул ямьсез манзарәле пожардан җирәнеп, чирканып, мөмкин кадәр миннән ерак булырга тырышуыңызга, миннән качарга теләвеңезгә, качуыңызга тары бөртеге кадәр дә ачуланмыйм. Ачулана алмыйм. Ачуланырга хакым юк... Ләкин, туташ, мин иксез-чиксез газап чигәм. Иксез-чиксез көям, янам. Сезне сөйгәннән, сезне өметсез сөйгәннән корыйм...Бетәм... Бөтен тәнем сызлый, күңелем сыкрый. Йөрәгем парча-парча килә... Сезне күрмәсәм, һавасызлыктан тончыгам, сезнең берлән сөйләшмәсәм, бөтен сүзләрнең мәгънәсене онытам, мин сезнең өчен генә яшим, сезнең хыялыңыз берлән генә торам. Сезнең исемеңезне генә тәсбих кебек зикер итеп гыйбадәт кылам. Туташ! Мин сездән берни сорамыйм, берни теләмим, теләргә хакым юк... Үземнең бөтен өметем буш икәненә, сөюемнән газаптан башка бернәрсә күрмәвемә ышандым, иман китердем... Һәркөнне китәргә, үземнең башымны алып китәргә карар бирәм. Тагы сезне ташлап, сез тора торган йирне ташлап китә алмыйм... Кулым бәйләнә, аягым атламый... Китә алмыйм.

Туташ! Кызгана алсаңыз, мине кызганыңыз... Бөтен тәнем, җанымны каплап алган җәрәхәтнең сыкравы, авыртуы хакына, сөйгәнеңезнең башы хөрмәтенә әйтәм, минем берлән бер генә мәртәбә, гомереңездә бер генә мәртәбә Габдулла иттереп сөйләшеңез!!

Мин, туташ, үземнең сөйләвемә әллә нинди өметләр баглый дип уйламаңыз. Минем йөрәгемдә кайный-кайный таш булган шул сагышлар, сезнең берлән сөйләшсәм эрер, изелер кебек күренгәнгә, әллә нинди бер куәт шул кайгы, шул хәсрәтне сезгә генә, сездән башкага түгел, тиеш дип әмер биреп торганга, егерме минутлык вакытыңызны әрәм итеп мин бәхетсезнең канлы кайгысыны тыңлавыңызны үтенәм. Туташ! Бу үтенечем минем актык үтенечем, бу сорау актык соравым, актык ялваруым... Бөтен әүлиялар, пәйгамбәрләр, олуглар хөрмәтенә сорыйм, шуны кайтарып йөземә бәрмәңез! Бер генә минутка миңа бер генә тамчы шәфкатеңезне айамаңыз... Габдулла». *(Фатыйма торып йөрергә тотына. Берәр әйләнгәч.)* Мескен! Мескен, кызганыч егет... Шул җәрәхәтләре җитмәгән дә, тагы аннан тирән, аннан ачы җәрәхәт ачмакчы була!.. *(Җил ыжылдый. Морҗалар сызгыра. Фатыйма йөреп-йөреп, уртада туктап.)* Китсәм?

---

*Парча-парча* — парә-парә.
*Зикер итү* — күп тапкыр кабатлау.

Хәзер беркемгә бер сүз әйтмәенчә китсәм? Китәм... Китәм. *(Тагы туктап.)* Кая барам?.. Китеп котыла аламмы? Казаннан киттем. Шул кара бәхетемне анда калдырдым дип киттем. Ул миннән алда монда килеп утырмаганмыни? Юк!.. Юк... Минем вазыйфам... Минем вазыйфам. Шул сөйкемле кызганыч егеткә гомерендә төзәлми торган яра ачу. Әйе. Шул хәзер минем вазыйфам. Фатыйма, ир бул!! Синең әбиең үз өстенә үзе сорап көндәш алды... Син үз вазыйфаңны үтәүдән нинди авыр, нинди ачы булса да тартынма! *(Тиз-тиз атлап килеп утыра да шатыршотыр хат яза.)*

Ишектән акыртын басып Габдулланың анасы килеп керә. Фатыйма, язып бетереп, әйләнеп карагач, аптырап китә.

Остазбикә. Мин генә. Күршедә торып, күреп чыгыйм, дидем... *(Акыртын гына атлый.)*

Фатыйма. Уз, абыстай, уз...

Остазбикә. Узам, азрак утырырга килдем. *(Кәнәфигә утырып озын гына дога кыла. Кулындагы төенене.)* Мә, кызым, сиңа азрак күстәнәч китердем. Әнисе юк, дим, мескен, ялгыз чит илләрдә горбәттә тора, дим. Менә аз гына булса да чәкчәге, мае, балы, корты... Бер генә боты булса да, үрдәк ите куйдым, ашарсың әле...

Фатыйма. Рәхмәт, абыстай. *(Алып куя.)*

Остазбикә. Синең бүлмәң матур икән, кызым. Безнең Габдулланың анда тузан, монда чүп, әрчи-әрчи эштән чыктым. Өйләнергә вакыт инде. Өйлән, димез... Авыз ачтырмый... *(Пауза.)* Син, кызым, ничә яшьтә?

Фатыйма. Егерме дүрттә, абыстай, дүртенче ел менә мөгаллимәлек итәм.

Остазбикә. Алла ярдәмче булсын, ялгызлык авыр, кызым, безнең хатын-кыз әллә нигә ялгызлыкка өйрәнмәгән, сезнең яшьтә тагы, Алла сакласын, аты-чабы чыгып китсә, бу елда кыз утырды да калды... *(Пауза.)* Мин озын иттереп, җайлап сөйли белмим, кызым, гаеп итмә! Габдулланың хәле бик начар бит. Бала көя, яна... Төн йокламый. Көн ашамый... Шәм кебек күз алдымда эри... Гаеп итмә. Ул синнән!.. Ул сиңа бик каты мәхәббәт тоткан... Миңа әйтмәде... Бала, ахрысы, сорадым, әйтми... Күзеннән беләм... Сиңа, кызым, менә шуны әйтәм әле, чәчеңез чәчкә бәйләнешкән булса дим, кызым. Атасы да: «Бар, остазбикә, белешеп кил»,— диде дә, әйтим дидем, кызым... Мин карчык кешене гаепләмә! Угылымны бик кызганам шул... Менә көя, эри... *(Карчык күзеннән яшен сөртә.)*

---

*Күстәнәч* — кучтәнәч.

Ф а т ы й м а. Рәхмәт, абыстай! Илтифатыңызга рәхмәт.

О с т а з б и к ә. Илтифат-фәлән түгел, кызым. Эш аннан үткән булса, эшне тиз тотарга кирәк! Аллага шөкер, кызым, әле монда мәңге кеше өстендә тормассыз, йортымыз-җиремез бар, атымыз-сыерымыз җиту, мал-туарымыз бөтен. Бары да сезгә булачак. Бердәнбер кызым бар иде, үлде. Ул җиһазы, җиһазы гынамы иде, барысын да сиңа бирермен. Кызым булырсың... *(Фатыйманың җилкәсенә кулын сала.)* Еглатма шул баланы... Мин аның күңелен беләм, анда зәррә кадәр усаллык юк... *(Башын сыйпый.)* Алла сиңа бәхет бирер, матур балалар бирер. Ал да гөл булып гомер итәрсез. Без, картлар, сезгә догада булырмыз. *(Башын сыйпап.)* Уйла, кызым! Син бит үзеңә үзең падишаһ кеше... Юкка күз яше түктермә! Тәҗрибә белән әйтәм, кызым. Күз яше әрәм булмый...Күз яше тими калмый... *(Фатыйма тиз генә торып китеп арты берлән урындыкка тотына, күзеннән аккан яшен яулык берлән сөртә. Пауза. Остазбикә торып, акыртын гына килеп.)* Менә моннан ишек ачтырырсыз, ике бүлмәне тоташтырырсыз... Рәхәтләнеп торырсыз, кызым! *(Тагы барып кулыны сала.)* Хәзрәт тә үзеңне яратып калган... Каенеш булгач, улсы да кирәк бит. Син, бәлки, кызым, сөймим дип курка торгансың, Аллаһе Тәгалә сөюне никях берлән җибәрә... Хәзергә аз гына сөйсәң ярар... җитәр... Безнекеләр канәгатьлеләр.

Ф а т ы й м а *(борылып, карылган тавыш берлән)*. Аз гына да сөймәсәм, абыстай?

О с т а з б и к ә. Габдулланымы! Габдулланы аз гына сөймәскә мөмкин түгел, кызым, мөмкин түгел, кызым! Фәрештә кебек егет. Укуымы дисең? Кыйланышы, йөрешеме? Һәммәсе килгән. Син, кызым, Аллага тапшыр. Хатын-кыз шәфкатьлерәк булырга кирәк. Хәзрәтем дә көтә торгандыр... Минем сүземне онытма, кызым. Кирәк булса, төплерәк башкода да җибәрермез. Әтисе дә туйны күреп китмәкче була. Алты меңнән килдек, кызым. Хуш, колагыңа сал әле. *(Абыстай ишеккә җиткәч.)*

Ф а т ы й м а. Абыстай, шул язуны Габдулла әфәндегә бирерсезме? Бу мәктәп хакында гына!

О с т а з б и к ә. Бирермен, бирермен!! *(Фатыйма кәгазьне тоттыра.)* Изгеләр, әүлиялар, мәдәдче булыңыз... Алла боерса, башланды... башланды. Үзе хат яза... Ярый, хуш, кызым.

---

*Зәррә* — бөртек.
*Мәдәдче* — ярдәмче.

Ф а т ы й м а. Хуш, абызтай, рәхмәт. Олуг башыңызны кече итеп йөрүеңә рәхмәт. Хәзрәткә сәлам әйт.

О с т а з б и к ә. Ярый, ярый... *(Чыгып китә. Җил улый, сызгыра. Ыжгыра.)*

Ф а т ы й м а. Мескен карчык! Мескен карчык... Нинди юньле, нинди сөйкемле... Аз калды, муенына ташланып, янган, көйгән йөрәкне чишмәдем. «Аз гына сөйсәң», ди... Аз гына сөйсәң?.. Әйтергә җиңел! Аз гына сөйсәм, аз гына сөя белсәм... Мин болай бәхетсез дә булмас идем. Минем бөтен тормышым, бөтен уем, бөтенгә, бүленмәүгә беркетелгән. Мә бөтенләй! Бир бөтенләй!! *(Ишекне шакыйлар. Калтырап китеп).* Вакыт йитте, Фатыйма. Дөрестне дөрест дип дөрестнең бәбәгенә әйтергә, тере тәннән агулы пычакны йөртергә, үзеңнең иң ихтирам иткән бер егетеңнең зур йөрәгенә утлы пычак тыгарга вакыт йитте. Ир бул, Фатыйма! Намус синнән актыгына кадәр шул агуны эчәргә, эчерергә куша, вазыйфаң башында бул! *(Борылып китеп каты тавыш белән.)* Боерыңыз! Рәхим итеңез!

Ишек акыртын гына ачыла да танымаган б е р к е ш е килеп керә.

К е ш е. Гаеп итмәңез, Фатыйма туташ, беләсез, дөньяда төрле хәлләр була... Менә дөньяның дулкыннары мине сезнең Сибириянең караңгы почмагына ташлады, урамдагы җилне ишетәмсез, шундый ыжылдап торган вакытында ташлады, мин артист Габдерахман!

Ф а т ы й м а *(аптырап).* Боерыңыз...

А р т и с т. Боерам, рәхмәт.

Ф а т ы й м а. Утырыңыз.

А р т и с т *(утырып).* Минем аяклар да бик шәп түгел... Беләсез, Фатыйма туташ, без бит әле халыкның яңы уянган вакытында хезмәт итәмез... Басылмаган сукмакны үземез сугамыз... Юк театрны бар итәбез... Безгә әллә ниләр тугры килә... ашамыймыз да, эчмибез дә, җәяү дә йөрибез. Ләкин безне йөретә торган бер идеал бар, ул идеал, туташ, татар театры ясау... *(Өстәлгә сугып.)* Мин ач та булырмын, мохтаҗ да булырмын, ләкин театр ясамаенча калмам... *(Фатыйма аптырап куркып китә.)* Минем хакта сез, Фатыйма туташ, күп ишеткәнсез, ә? Шулаймы? Мине шарлатан ди торганнардыр.

Ф а т ы й м а. Юк, ишеткәнем юк.

А р т и с т. Әйтәләр, әйтергә хаклары бар... Ләкин театрны аңламаучылар әйтә!.. Туташ, барысы да хәл юктан эшләнелгән!.. Мин артист, туташ. *(Торып, күкрәгенә сугып.)* Мин татарга театр ясап бирү уе белән җенләнгән, пәриләнгән артист! *(Кычкыра.)* Артист, туташ, мине аңламыйлар гына!..

Менә көннәр үтәр. Безнең урамда да кояш чыгар, мин шул татарның таркау артистларын җыярмын. Аны мин генә җыя алам. Мин генә җыярга тиеш. Беләмсез, туташ, мин генә. Бөтен татар шәһәрләрене гизәрмен, чит мәмләкәтләрдә турне ясармын... Татар театрын бөтен мөселман дөньясына, Истанбулына, Измиренә, Тәһранына, Калькуттасына күрсәтермен... Парижы, Венасына, Берлинына татар артисты, татар театрының бәһасен исбат итәрмен. Итәрмен, туташ!.. Менә мин кем, туташ! Шуның өчен, туташ, минем берлә эш иткәндә Габдулла угылы Габдерахман дип йөрену хата, зур хата!.. Бу бөтен татарның иң зур артисты... *(Күкрәгенә сугып.)* Шулай булгач, мин театрның дәрәҗәсен, татар театрының дәрәҗәсен югары тоту, ачылынып килә торган байрагына тап тамызмау минем бурычым түгелмени?.. Минеке, туташ!..

Менә шул олуг юлда шул зур бурычны үтәр өчен хәзер сезнең шәһәрдән үтеп барамыз. *(Тавышына мескенлек куша.)* Бөтен труппамыз ач, нумирымыз юк, шул ыжгыра торган җилдә без урамда, туташ! Сез аңлыйсыз, алдыңызда хәерче тормаганны беләсез... Сез, шәһәрнең зыялылары, безгә, безгә түгел, татар театрын җилкәсендә күтәреп бара торганнарга ярдәм итешергә тиешсез! Тиешсез, бу сезнең бурычыңыз!..

Ф а т ы й м а. Мин бит, Габдерахман әфәнде, бер мөгаллимә генә! Миннән зур эш чыкмас. Ашыйсыңыз килмиме? Менә монда самавыр бар.

А р т и с т. Рәхмәт, туташ. Бераз туңдым, кайнар чәй зарар итмәс. *(Фатыйма чәй ясап бирә. Абыстай китергән әйберләрне куя.)* Сез эчә торыңыз әле, менә шуларны ашаңыз, мин берәр кешегә хат язып бирим.

Фатыйма язарга утыра. Артист авызын тутырып ашарга башлый, үрдәкне ботыннан тотып кимерә... Чәйне «колт» иттереп кабып эчеп ташлый. Самавырга карап тора да, аягы шыкырдамасын дип, әкрен генә басып чәй ясарга китә. Чәй ясап килгәндә урындыкка абына да, Фатыйма борылып карагач, аптырап.

А р т и с т. Гафу итеңез, туташ... Тән җылынып китте дә сезне мәшәкатьләмимим дидем...

Ф а т ы й м а *(борылып)*. Эчеңез! Эчеңез! Ашап эчеңез...

А р т и с т *(авызына майлар, кортлар тутырып)*. Ашыймыз... Ашыймыз... Рәхмәт. Тегеләргә дә берәр нәрсә алганда зарар итмәс иде, яхшы түгел. Мөгаллимә генә бит... Хәдичәгә генә булыр, алыйммы әллә?.. *(Икеләнеп торганда.)*

Ф а т ы й м а *(торып)*. Менә, Габдерахман әфәнде.

Артист *(торып, авызы тулган көенчә)*. Аңлыйм, туташ.

Фатыйма. Менә, Габдерахман әфәнде, шул хат берлән иртәгә Сабир әфәндегә барырсыз. Мин анда барысын да яздым... Бүгенгә менә шунда берәр нумирга кереп торырга ярар. Менә монысы үземнән. *(Кәгазь акча бирә.)*

Артист. Рәхмәт, туташ! Монда яхшырак нумир кайда икән? Вак-төяк нумирга эләгеп, татар артистының исемене былчыратмыйк, дим.

Фатыйма. Белмим, сорарсыз...

Артист. Бик рәхмәт, туташ! Бик рәхмәт. *(Кулыннан тотып.)* Сез бер сүздән артист йөрәгене аңладыңыз! Сезнең үзеңездә, туташ, артист күңеле... Артист күңеле... Күзеңездән беләм... Караңыз әле, туташ! Сез монда ни дип шул суык, салкын Сибириядә мөгаллимәлек итеп череп торасыз! Сезнең күңел бит артист күңеле. Сезнең канатларга очарга киң-киң татар дөньясы кирәк... Мин артист күзе берлән күрәм, сезнең очарлык көчеңез бар... Беләмсез, сезгә генә әйтим, минем труппа татар труппалары арасында беренчесе. Бары да шулай ди, ләкин хатын-кызлар йомшак. Менә сез керсәңез! Караңыз әле, сез трагический рольләргә коеп куйган... Кылынышыңыз, күз карашыңыз, валлаһи, сез хатыннардан беренче трагичка булыр идеңез...

Фатыйма. Рәхмәт! Мин болай да трагический роль уйныйм...

Артист. Алай булгач, эш бетте. Без сезне өрмәгән йиргә утыртмамыз... Бөтен көчемез берлә судан, суыктан саклармыз. Сезне хан кызы кебек итәрмез. Ул вакыт, беләмсез, бер елда эшләнә торган эшләрне айда, көндә эшләрмез... Безнең труппаның беренче труппа булыр өчен хатын-кызлар йөрәгенең шунда кушылуы кирәк. Беләмсез, туташ, нинди генә эш булса булсын, аның башында хатын-кыз йөрәге кушылмаса, ул арпа камыры булып чыга. Ул оешмый. Аңлаңыз, туташ, татарның иң зур артисты, татар театрының тәрәкъкыйсе исеменә сезне зур мөкатдәс артистлык хезмәтенә өнди...

Фатыйма. Рәхмәт! Рәхмәт! Иртәгә шул иртүк Сабир әфәндегә барыңыз.

Артист. Рәхмәт, туташ!.. Вакытыңызны калдырдым, йылынып киттем. *(Чыга башлый, борылып.)* Алай да минем предложениемне* онытмаңыз.

Фатыйма башын ия... Ишек ачылганда җил ыжгыра, пауза.

---

*Бу сүз оригиналда рус хәрефләре белән язылган.
*Тәрәкъкый* — алга киту, прогресс.

Фатыйма. Әллә чын да шуның артыннан китимме? Үземнең кайгы-хәсрәтемнән тугып, күз яшем берлә чигеп, моңым, зарым берлә челтәрләтеп, татар хатынының трагический бер тибын ясый алсам... Бөлгән йөрәгемне базарга чыгарып, татар дөньясында милли бер байлык тудыра алсам. *(Ишекне шакыйлар. Фатыйма тагы сискәнеп китә. Көзгегә карап алып, куәтле тавыш берлә.)* Боерыгыз!

Акрын гына ишек ачыла. Акрын гына басып Габдулла килеп керә. Ул аякларын акрын гына, өстерәп кенә атлый. Башы иелгән, йөзләре, төсләре кыйналып ташланган кебек булган. Фатыйманы күргәч, акрын гына башын иеп, калтыраган тавыш берлә:

Габдулла. Исәнмесез, туташ!

Фатыйма *(тиз генә янына барып)*. Исәнме, Габдулла әфәнде, әйдәгез! Әйдәгез. *(Елмаеп.)* Без бүген күрешмәдек бит әле. Исәнмесез. *(Кулыны бирә. Габдулла кулыны тота да җибәрә алмаенча тора. Ул акыртын гына бөгелеп үбә.)*

Фатыйма. Анысы кирәкми, анысы кирәкми, Габдулла әфәнде, әйдәгез, боерыгыз... утырыгыз. *(Габдулла акрын гына утыра. Пауза.)*

Фатыйма. Чәй эчәмсез, Габдулла әфәнде?

Габдулла. Рәхмәт, туташ... Юк.

Фатыйма. Юк, юк, Габдулла әфәнде, эчегез... Ясыйммы?.. Эчегез...

Габдулла. Ярый...

Фатыйма *(чәй ясап китереп алдына куя. Барып конфет савыты алып килеп.)* Менә, Габдулла әфәнде, рәхим итегез!

Габдулла *(көчләнеп көлеп)*. Сез, туташ, мине бүген бик сыйлыйсыз?.. *(Фатыйма каршысына утырган. Пауза.)*

Фатыйма. Әниләрегез исәнме?

Габдулла. Аллага шөкер...

Фатыйма. Үзегез нишләп торасыз?

Габдулла. Үзем? Менә монда... Үзем менә сезнең алдыгызда... Нишләп торганымны, туташ, әле дә күрмисезмени?.. Шул газапның тавышы, шул утның ялкыны сезгә әле дә күренмимени, туташ?

Фатыйма. Күренә, Габдулла әфәнде, күренә. Тавышы да ишетелә, җәрәхәте дә күренә.

Габдулла. Күренсә? Күренсә... Шуңарга сәерче булып көлеп карап торырга сезнең *(Йөрәгенә күрсәтеп.)*

---

*Сәерче* — ерактан гына, битараф карап торучы.

йөрәгеңез юкмыни?! Әллә ул таштан ясалган җансыз ит кисәгеме?

Фатыйма. Габдулла әфәнде! Мин көлеп тормыйм... Сезнең дә, минем дә бәхетсезлегемә каршы, көлеп тормыйм, аңлыймсыз? Сезнең кайгыңыз, сезнең хәсрәтеңез алдында мин дә еглап торам... Безнең мөнәсәбәтемезнең трагедиясе, Габдулла әфәнде, менә шул көлүнең юклыгында... Сезнең уттан кайнар шул сөюеңезне, Габдулла әфәнде, шул сүзләрне чын күңелемнән ышанып әйтәм... мин елмаеп сөенеп каршы алмыйм... Ала алмыйм... чөнки, чөнки *(Кулларын селкетә.)* ала алмыйм... Сезнең шул җәһәннәм газабыңызны көлеп, мыскыллап каршы ала алмыйм, чөнки... чөнки... сезнең чын сөюеңезгә ышанам... Сезне ихтирам итәм, аңладыңызмы, Габдулла әфәнде?

Габдулла. Юк, минем аңлаганым бер генә. Мин сезне, туташ, сөям... Сөям түгел, ул сүз бик кечкенә, бик мәгънәсез... Мин сезгә табынам... Мин сезгә гыйбадәт итәм. Мин сезсез сулый алмыйм, сезсез тора алмыйм, сезсез яши алмыйм... Сез миңа, туташ, җан, сез миңа кан, сез миңа һава, сез миңа Алла! Сез миңа бөтен дөнья, бөтен барлык... Нәрсәгә генә карасам да, мин, туташ, сезне күрәм. Минем күзем сездән бүтәнне күрми, томаланган. Ул үзенең вазыйфасы сезне генә күрү, сезне карау икәнне белгән. Минем колагымда өзелмәенчә сезнең тавышыңыз, фәрештә йыры кебек саф тавышыңыз! Күз алдымда, өнемдә, төшемдә — сез... Сез, ялгыз, сез... туташ, сез никадәр миннән аерылырга тырышыңыз, сез никадәр шул диварлар артында миннән яшереneңез, мин сезне күрми-ишетми бер минут торганым юк... Сез минем бөтен барлыгымны биләдеңез, сез минем көчемне, куәтемне, тойгымны, гакылымны — һәммәсене бушка чыгардыңыз. Һәммәсе урынына сез кереп утырдыңыз... Сезнең исемеңезне мин зикер кебек, дәрвишнең зикере кебек әйтәм. Авызымнан төшермим... Шул янган йөрәгем, дулаган күңелем берлән сезгә таба барам, сездән өмет итеп бер генә тамчы — кечкенә генә көзге ягъмур тамчысы кадәр генә шәфкать тамчысы көтеп сезгә барам... *(Еглап җибәреп.)* Сез, туташ, минем янган йөрәгемә төкерергә дә хурланып борылып китәсез... Минем бөтен көчем бетте, артык чыдый алмыйм, туташ! Синең мәрхәмәтеңә, шәфкатеңә килдем... *(Аягына егыла.)*

Фатыйма *(сикереп торып)*. Габдулла әфәнде... Габдулла әфәнде. *(Карылган тавыш белән тотып торгызмакчы була.)*

Габдулла *(башын күтәреп)*. Туташ! Тимә, зинһар,

тимә! Шул кечкенә сәгадәтне генә миннән кызганма. *(Кулын тотып авызына китереп үбә.)*

Ф а т ы й м а *(кычкырып еглап)*. Габдулла әфәнде, Габдулла әфәнде, уян! Уян! Мин синең күз яшеңнең кыйммәтенә тормыйм. Син аңламыйсың, мин аңлатып тормыйм...

Г а б д у л л а *(тагы кулын үбеп)*. Миңа аңларга кирәкми... Миңа җан кирәк... Миңа син кирәк...

Ф а т ы й м а *(сикереп тора)*. Юк ул... Ул юк, Габдулла әфәнде, мәңгегә юк... Юк... *(Басып тора.)*

Г а б д у л л а *(торып, карылган тавыш белән)*. Мин ачлык күрдем, мохтаҗлык күрдем... Алган юлымдагы тавына-ташына карамадым, алга киттем... Үзем өчен түгел, туташ, сине дә, мине дә яндыра-көйдерә торган хезмәт өчен... Атлаган саен киртәләр куелды. Һәммәсе белән тартыштым, сугыштым, һәммәсене үттем, башымны имәенчә, башымны югары күтәреп үттем. Бөтен тәнем тырналган, өзгәләнгән, кисәк-кисәк булган... Һәммәсе сызлый, сыкрый, әрни... Шуларны тынычландырырга, шул яраларны ямалдырырга бер-ике көн генә хәл җыярга, тагы алга атлар өчен хәл җыярга минем хакым юкмыни, туташ?

Ф а т ы й м а *(кычкырып)*. Юк, синеке дә юк, минеке дә юк! Юк! Шакир белән Әсманыкы гына бар! Безнеке юк, Габдулла әфәнде, юк!!

Г а б д у л л а *(каршысына килеп)*. Бар, бар. Мин, бар, дим... *(Кычкыра.)* Мин, бар, дим... Бар. *(Сабырланыбрак.)* Мин сине иксез-чиксез сөям... Мин, син булсаң, бөтен дөньямны, ахирәтемне онытам... Мин дөньяның иң бәхетле кешесе булам. Ул «юк» кайдан килгән? Нинди хак белән минем тормышыма ябышкан? Күрсәт миңа шуны!.. Мин аны тетеп-тетеп ташлыйм... Күрсәт! *(Фатыйма тик тора. Габдулла барып әкрен генә.)* Фатыйма! Фатыйма! Син ул «юк»ны күрсәтмә... син бар. Менә син бар. Менә син... *(Кулын алып үбә.)* Менә син... Менә син... Менә мин... Мин бөтенләй синеке булыйм. Бөтенләй, беләмсең?.. Бер дә калмаенча!.. Син аз гына, аз гына, тары бөртеге кадәр генә минеке бул... *(Кочаклый башлый.)*

Ф а т ы й м а. Җибәр. *(Ычкынмакчы була.)* Җибәр, дим, Габдулла әфәнде, җибәр...

Г а б д у л л а. Җибәрмим, җибәрмим... Син минеке, минеке, җибәрмим... *(Кочаклый, үбә...)*

Ф а т ы й м а *(ычкынып китеп, килеп баса да)*. Сиңа минем тәнем кирәкме? Тәнем кирәкме?.. *(Шәлен ташлап җибәрә дә алдына ук басып.)* Мә ал! Мә ал!.. *(Өстенә*

*таба бара. Габдулла тартына.)* Аның беркемгә дә кирәге юк. Мә ал!!!

Габдулла *(карылып)*. Гафу ит, туташ! Үземне-үзем онытпым. Миңа... Миңа йөрәгең кирәк. Коры йөрәгең кирәк!.. Мин сине сөям. Мин синнән сөеләсем килә. Сөюем кадәре көчле сөеләсем килә...

Фатыйма. Мин сөймим. Габдулла әфәнде, мин сине сөя алмыйм. Сөя алмаячакмын... Аңлыймсың... Юк... Юк.

Габдулла *(каушап китеп)*. Син бер-бер кеше хатыны? Син берсенең сөйгән дусты?..

Фатыйма. Берсе дә түгел... Мин дә синең төсле йөрәге яна-яна көлгә әйләнгән, сөярлеге калмаган бер кеше! Мин дә синең кебек көне-төне шул газаптан аерыла алмаган бер сөюче... Мин дә синең кебек сөюеннән бер тамчы да, язгы ягъмур тамчысы кадәр дә бәхет ала алмаган бер көюче... Аңладыңмы? Аңла!.. Синең йөрәгең ут янса, минем йөрәгем көл булган... Шул сөю мине Казаннан монда куды, шул сөю мине моннан әле кая куар... Ул сөю өметсез сөю... Мине гомерем буе куачак... Аңладыңмы?

Габдулла. Менә аңладым. Йөрәккә хәнҗәр тыккач, әле аңлый алам икән, туташ. Аңладым, аңладым... Рәхмәт, туташ! *(Катып тора да борыла башлый.)*

Фатыйма *(килеп кулыннан тотып)*. Чү!.. Юк, хәзер китә алмыйсың! Хәзер китә алмыйсың. Юк... Әле синең эчәсе агуың эчеп бетмәгән. *(Кулын биреп.)* Без бәхетсезлек иптәшләре, икемезнең дә, Габдулла әфәнде, әле түгәсе яшьләремез бетмәгән.

Габдулла. Ул сине мыскыл итте. Ул сине көчләде...

Фатыйма. Юк... Мин фәрештә кебек пакь...

Габдулла. Син аны бик сөйдең, бик сөясең?..

Фатыйма. Бик сөйдем, бик сөям, ул гына түгел... Бик сөячәкмен.

Габдулла. Бик сөячәксең?.. Ул?

Фатыйма. Ул?.. Ул... Ул минем сөйгәнемне белмәде... Йә белмәгәнгә салынды... Ул мине күрмәде...

Габдулла. Ул сине күрмәде. Бөтен дөньяны томалый торган, бөтен кешенең йөзен яшерә торган сине күрмәде...

Фатыйма. Ул сукыр иде...

Габдулла. Ул сөя иде?..

Фатыйма. Мине түгел, башканы сөя иде...

Габдулла. Син белдермәдең, менә мин килгән кебек син килмәдең...

Фатыйма. Килдем... Килдем... Ул мине кертмәде... *(Акырып еглый... Габдулла катып тора.)* Көз көне иде...

Мин өемнән көлмәкчән чыгып китеп бардым... Тәрәзәсе төбенә туктадым... Ул утыра иде... Аннан хатын-кыз тавышы, көлү, уйнау ишетелә иде... Мин тәрәзәне шакылдатырга булдыра алмадым. Минем яшем буды, мин тәрәзә төбенә ятып еладым, еладым... Салкын ягъмур бөтен сөягемә үткәнгә кадәр... Мин теге хатын киткәнен көттем. Ул китмәде... *(Акырып елый.)*

Габдулла *(килеп тезләнә, кулыны сыйпый-сыйпый)*. Фатыйма! Фатыйма! *(Фатыйма үксеп елый.)*

Габдулла. Фатыйма! Фатыйма! *(Кулыны селкеп.)* Туташ, минем сөюем кимемәде... Туташ, минем сөюемнең уты сүнмәде... Синең салкын суың аңарга куәт кенә бирде... Фатыйма! Фатыйма! Аңлыймсың?.. *(Башын тезенә куеп.)* Туташ! Аңлыймсың? Мин сине күкләр, йирләр кадәре, күктәге йолдызлар кадәр сөям, сөйим. Син мине аз гына, аз гына, тары бөртеге кадәр генә!.. Мин көтәрмен. Мин синең җәрәхәтең төзәлеп беткәнен көтәрмен. Аның ярасыны яшем берлән юармын. Йөрәк суым берлән аңарга яшь ит тартырга ярдәм итәрмен. Туташ! Тыңла мине! Тыңла мине... Мин синең дустың, мин синең иптәшең булырмын! Мин, син ни теләсәң, улың булырмын!.. Туташ, тыңла... Ел үтәр, көн үтәр... Синең җәрәхәтең бетәр... Минем йөрәк утымда син дә янарсың... Туташ...

Фатыйма *(торып)*. Юк, юк, Габдулла әфәнде... Юк. Шулкадәр зур кыйммәтне бурычка ала алмыйм... Синең кебек яраткан, ихтирам иткән бер кешемә каршы булган бурычны ялган акча берлән түли алмыйм... Юк... Юк... Синең алмаздан саф сөюеңә каршы янган йөрәкнең көлене, өрдең исә, җилгә оча торган көлене бирә алмыйм... Мин татар хатыны... Мин намуслы татар хатыны! Беләмсең, намусым, намусым сине, сине... синең кебек, мин кулыны үбәргә тиеш кешене алдарга ирек бирми, бирми... Сөйләмә, Габдулла әфәнде, сөйләмә! Аңла... Әгәр гакыл берлән эшләп булса иде, мең йөрәгем булса, меңе берлән дә сине сөяр, мәңгегә сөяр идем... Юкны сорама!.. Мин синең дустың, мин синең иптәшең, син пакь, син хөрмәтле, син... Булдыра алсаң, гафу ит!.. *(Икесе ике якта кычкырышып елыйлар.)*

Фатыйма. Габдулла әфәнде... Габдулла әфәнде...

Габдулла. Туташ!

Фатыйма. Без бергә тора алмыйбыз... Мин китәм...

Габдулла. Юк, мин китәм...

Фатыйма. Юк, юк. Мин... Синең монда сигез еллык эшең бар... Синең монда иксез-чиксез хезмәтең бар,

---

*Улың* — ул кешең.

алар сине үзенә үзе бәйләр, синең җәрәхәтеңне төзәтергә ярдәм итәр... Мин китәм...

Габдулла. Мин нишлим?

Фатыйма. Син чыда, сабыр ит! Ир бул!.. Бервакыт...

Габдулла. Бервакыт шул ут янып бетеп көл булырмы?..

Фатыйма. Бәлки, кисәү көе, күмер көе сүнәр... Хуш, Габдулла әфәнде... Аңла! Иң олуглаган, хөрмәт иткән кешемнән аерылам.

Габдулла *(Фатыйманың кулын үбә)*. Хуш!.. *(Акыртын гына чыга башлый. Ишек төбенә җиткәч.)*

Фатыйма *(акыртын гына)*. Габдулла әфәнде!

Габдулла *(борылып)*. Нәрсә, туташ...

Фатыйма *(бик тиз өстәлдән барып алып бер рәсем китерә)*. Габдулла әфәнде, теге тәрәзә төбендә елаган көнне шуның артыннан ук йөрәгемне кая куярга белмәенчә йөрегәндә тәрәзәдә шул рәсемне күрдем. Шул рәсем минем күңелемнең рәсеме кебек күренгәнгә, ике сәгать магазин ачылганны көтеп, шуны алдым. Айвазовскийның «Тугызынчы валы». Рәхим итеп алыңыз, миннән ядкяр булсын... *(Суза.)*

Габдулла. Рәхмәт, туташ, рәхмәт. *(Ала да тагы бераз туктап әллә ни әйтмәкче була. Борылып.)* Фатыйма туташ... Бервакытны син икенче мәртәбә тәрәзә төбенә барганда ул сине кабул итеп, синең пакь, янган йөрәгеңне былчыратып чыгарып ташласа, бервакытны тормышның дулкыны синең берлән уйнап, пакьлегеңнең сафлыгыны ватса... бервакытны син шундый ыжылдый торган тормыш җилендә ялгыз калсаң, еракта, еракта синең дустың — синең иптәшең, сине нинди генә төстә булса да сөючең бар икәнен онытма!..

Фатыйма *(еглап барып)*. Рәхмәт, Габдулла әфәнде, рәхмәт... *(Барып кулыны кыса. Габдулла аның кулыны үбәргә бөгелә.)*

Акрын гына пәрдә төшә.

## ТАРТЫШУ

*Дүрт пәрдәле драма*

КЕШЕЛӘР:

З а к и р — шактый бер бай кешенең баласы. Элгәре рус мәктәбендә укучы, соңыннан партиядә эшләүче.
Ш ә м с е т д и н — Закирның атасы. Карт кына фикерле, динле агай.
Г а й ш ә — Закирның анасы, гади татар хатыны.
Н а с ы й р — укучы, партиядә хезмәт итүче.
С а б и р — укучы, ишан угылы, партиядә хезмәт итүче.
Г а л и м — укучы, мужик баласы, партиядә хезмәт итүче.
Ш ә й х и — укучы, язучы, партиядә хезмәт итүче.
Ш а к и р ә — укыганрак кыз, соңыннан Закирның хатыны, партиядә хезмәт итүче.
Б ә д р е т д и н — укучы, соңыннан чиновник.
А с р а у — гади асрау.
Ш ә к е р т — гади, ачык фикерле шәкерт.
Г а б д у л л а — яшерен типографиядә торучы.
М а р җ а — гади марҗа.

Вакыйга Казанда.

Пәрдә күтәрелер алдыннан сәхнәдә ишетелә:

Ташлыйк, туганнар, иске тормышны,
Ул тормыштан илгә файда юк.
Булса, байлар белән тик түрәләр
Аркамызда рәхәт күрәләр.

Кирәкми, ташлыймыз иске юлны,
Кирәкми, яңа юл башлыймыз.
Яңа юл, яхшы юл, бер җәберсез,
Тигез, рәхәт тора башлыймыз.

Торыңыз, күтәрелеңез, эшче кешеләр!
Каршы тор дошманга, ач кешеләр!
Яңгыра дөньяга үч авазы,
Алга, алга, алга, алга, алга!

Байлар, җуан корсаклар, комсызлар
Тирә-яктан безне камыйлар.
Безнең арка тиремездән симереп,
Актык азыгымызны талыйлар.

Ачыгыйкмы шулар симерсен дип?
Ачыгыйкмы шулар туйсын дип?
Көн изсен, төн изсен күкрәгеңне,
Ахырдан эт итеп күмсен дип.
Торыңыз...

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шәмсетдин абзыйның өе. Кечкенә генә чарлак күренә. Кәнәфи, бер карават, бер язу өстәле, түбәнгә таба баскыч, өй түбәсенә ишек.
Закир ялгыз.

Закир *(өстәл янында китаплар актарып маташа).* Эш күп. Әллә никадәр язасы бар. *(Китапларны караштырып.)* Әллә никадәр укыйсы бар. Иртәгә словесностьтан Гогольнең әсәрләренең рус әдәбиятына тәэсире хакында сөйләргә кирәк. Әйе, Гоголь хакында! Эмм... Аның хакында шактый сөйли алам. Учитель теләгәннән артыграк та сөйли алам. Ләкин ничек булса да бик әче тел белән сөйләүдән сакланырга кирәк.Беркөн Пушкин хакында да Писаревтан да уздырдым да, учитель ачуланды. Улсы булды. Иртәгә кыска гына план язармын. *(Кулына бер дәфтәрне алып.)* Черчение*. *(Ачып-ачып карап.)* Йа, яратмыйм шул фәнне! Ярар, калып торсын. Әле тагы нәрсә бар? *(Дивардагы язуга карап.)* Дин дәресе, әһә, дин дәресе... *(Бер китапны алып читкә куеп.)* Ә, «Кяфер булуның сәбәпләре». Кяфер булырга теләгән кеше моны укымаенча да кяфер булырга юл табар әле. Монда синнән башка да эш күп әле. *(Тагы язуга карап.)* «Гыйльме хайванат». Менә моны мин хәзерләми ярамый. *(Бер китапны алып.)* Никадәр шуны укып чыгыйм дидем. Өлгерер хәл юк. Йә ярый, дәфтәрләрдә ни бар? *(Дәфтәрләрне актара башлый.)* Боларны төзәтмичә ярамый икән әле. Ах, моны акка күчермичә ярамый әле. *(Сәгатенә карап.)* Әти мазаны китәрмәсә, шактый вакыт бар. *(Утыра да язарга тотына. Бераз вакыт яза. Шул арада баскычтан йөгереп асрау менә.)*

---

*Бу сүз оригиналда рус хәрефләре белән язылган.
*Гыйльме хайванат* — хайваннар турындагы фән; зоология.

А с р а у. Закир абый! Абзый: кәләпүш санарга төшсен, ди. Хәзер, ди, җәмә? Төш!

З а к и р *(әйләнеп карап)*. Ярар, ярар, бар. Бар! Башны әйләндермә! Синнән башка да эш күп.

А с р а у. Тизрәк төш! Мине икенче кат менәргә ясама! Керләр чайкарга барасым бар. Тиз төш!

З а к и р *(урыныннан торып)*. Ярар, димен. Әллә саташтыңмы! Бар, төш.

А с р а у. Әллә мин үзем чакыраммы? Абзый кушты.

З а к и р *(ачуланып)*. Бар, димен. *(Асрау мырылдап төшеп китә.)*

З а к и р *(үзе генә)*. Бар менә, эшлә... *(Чарлак буе йөрергә тотына.)* Никадәр башымны әйләндерде. Әйтерсең лә миннән башка кәләпүш санап булмый. Бер-ике йөз кәләпүш бардыр инде. Шуны иләктән чиләккә бушата-бушата эштән чыгып бетә. Бу бәла кайчан гына китәр инде. Бер иркенләп сулыш алыр идем. Бер эш эшләр хәл юк. Алай да эшләмәенчә ярамый. *(Утыра, тагы язарга тотына. Бераз яза.)*

Түбәннән: «Закир! Закир!» — дигән тавыш ишетелә. Закир дәшми. Тавыш якынлаша бара: «Закир! Әтиең сине көтеп тора. Нишләп торасың?» Закир тагы тора. Баскычта Закирның әнисе Г а й ш ә күренә.

Г а й ш ә. Әтиең сине көтеп тора, кәләпүш санарга, ди.

З а к и р. Минем эшем бар, йөдәтмәңез. Әллә никадәр эшем, бер сәгать вакыт бирмисеңез. Миннән башка санап булмыймыни? Әллә кәләпүш санау бик авыр эшме? Син ник санамыйсың?

Г а й ш ә. Мин ирләр эшен белмим. Атаң көтеп тора, төш!

З а к и р. Әйтәм ләсә, минем эшем күп. *(Китапларны күрсәтеп.)* Әнә никадәр!

Г а й ш ә. Аны, урыс китапларын, син генә бетерә алмассың инде. Урысның ысказкасы бик күп аның!

З а к и р. Ул «ысказка» түгел. Ул сабак.

Г а й ш ә. Пәриләнеп бетәсең шунда... Төш, әтиең ачуланыр. *(Гайшә күздән югала.)*

З а к и р *(тагы бүлмәдә бер-ике әйләнеп)*. Уф! Арыдым. Бу тормыштан арыдым, тизрәк, тизрәк! Бу — тормыш түгел. Бу — коллык! Кеше әмере белән аша, эч. Кеше әмере белән кәләпүш сана. Кеше әмере белән тире сана. Булмый, булмый. Миннән булмый. Хәерле булсын, ни чикле эш! Кайчаннан бирле этләнәм, шул дәфтәр эшен дә бетерә алмадым.

Тагы утыра. Яза башлый. Бераз яза. Түбәннән дөбердәтә башлыйлар. Закир дәшми. Тагы катырак дөбердәтәләр. Бу һаман дәшми. Тагы дөбердәтәләр. Атасының «Закир, Закир!» дип кычкырган тавышы ишетелә.

Закир *(урыннан торып, баскычка барып)*. Нәрсә бар?

Шәмсетдин *(түбәннән)*. Әллә дүндеңме? Ник дәшмисең?

Закир. Нәрсә бар?

Шәмсетдин. Тагы «нәрсә бар»? Әйтмәделәрмени? Нәрсә бар, нәрсә бар... Кәләпүш санарга төш!

Закир. Минем эшем күп, иртәгә санармын.

Шәмсетдин. Иртәгә санарга булгач, сине бүген чакыралармыни?

Закир *(үзеннән-үзе)*. Менә болар белән эшлә, менә болар белән укы!..

Шәмсетдин. Анда тагы нәрсә бытырдыйсың? Әллә тагы атаң менеп күтәреп төшергәнне көтәсеңме? Оятсыз...

Закир *(ялгыз)*. Кадалып бетмәсләр кәләпүшләре белән! Йөз өсте килсеннәр! *(Тагы утырып язарга тотына. Бераз яза. Тагы дөбердәтәләр. Бу илтифат итми.)* Ярый, исмасам, монысы бетте. Алар белән бер дә назланып торырга ярамый. Алар кушканны бер эшли башласаң, алар баскан-нан баса гына баралар. *(Йөренергә тотына.)*

Шул арада Насыйр килеп керә.

Насыйр *(пальтосын салып ыргытып)*. Уф, арыдым. Хәзер сабактан киләм. Башым үземнеке түгел. *(Кургаш койган кебек караватка ятып.)* Шайтанны, тагы берсенә барасы бар. Өч тәңкәгә, өч тәңкәгә шәһәрнең бер очыннан икенче очына йөгер. Иртәгә безнең нәрсә, Закир? Бүген кулыма китап та тотканым юк.

Закир. Гоголь, аның арты хайванат.

Насыйр. Әһә... Гоголь, беләм: «Борынгы алпавытлар», «Ревизор», Чичиков. Эмм... мөмкин! Хайванатны кичкә укып була. Аннан башкасы: «Кяфер булуның сәбәпләре — тугыз әгъзада тугрылыктан чыкмак» — беләм. Син ник бик күңелсез? Нишләдең? Әтиеңнәр кәләпүш саныйлар...

Закир. Син дә шул кәләпүш белән башымны әйләндермә әле. Әтиләр әйләндергәне дә җитәр. Һич укырга вакыт юк.

Насыйр. Миңа бармы?

Закир. Син, исмасам, үз иркеңдә. Теләсәң укытасың, теләмәсәң — юк!

---

*Исмасам* — ичмасам.

Н а с ы й р. Тамак. Юк, мин дә үзенә бертөсле коллыкта, син дә үзенә бертөсле. Синең белән без анның шикелле нәрсәләргә илтифат итәргә генә ярамый.

З а к и р. Ничек илтифат итмисең? Менә язарга утырдым, кәләпүш санарга чакыралар. Әлгәре асрау менде, аннан ары әни, аннан соң әти. Ничек илтифат итмисең?

Н а с ы й р. Менә шулай тотасың да илтифат итмисең! Син, туганкаем, үзеңнең кем икәнеңне белмисең. Без хәзер укучылар гына түгел. Без, рус шәкертләре кебек, мәктәп балалары гына да түгел, без иске гадәт, иске тормыш белән тартышучылар, иске дөнья белән сугышучылар, безнең укуымыз, безнең киләчәк хезмәткә хәзерләнүемез — һәммәсе иске тормышны ватыр өчен, бетерер өчен, без үземезнең һәрбер адымымыз, һәрбер хәрәкәтемез белән иске тормышның нигезен җимерәмез һәм эшемез белән иске кешеләрнең гадәтләрен мыскыл итәмез. Шуның өчен без тартышучылар, без сугышчылар, без яңы тормышның алдагы гаскәре. Безгә һәр минутта, һәр секундта иске тормыш белән сугышырга тугры килми хәле юк. Сугыш ни икәнен белеп, үз ихтыяры белән барган солдат мылтык-кылычтан курыкмаган кебек, без дә андый авырлыклардан курыкмаска тиеш. Мин үземнең тормышымның һәр авырлыгына иске тормышның угы дип карыйм. Шуның өчен авырлык никадәр каты булса, минем иске тормышка дошманлыгым арта бара. Мин үзем өчен, үземнең артымнан килә торган меңнәр, миллионнар — татар яшьләре өчен юлны шул авырлыклар, шул кыенлыклардан аруларга тырышам, җиңәм икән җиңәм, җиңә алмыйм икән — үләм. Ләкин җиңелмим! Дөрест, безгә хәзер бик авыр. Без хәзер казакиның төймәсе , бишмәтнең кесәсе өчен әллә никадәр гайрәт әрәм итәргә кирәк! Нишлисең! Шунсыз булмый. Тарих шул майлаган арба кебек шома гына бармый. Ул үзенең көпчәге арасына әллә никадәр кешеләрне эләктерә. Әллә никадәр кешеләрне зәгыйфь ясый, әллә никадәр кешеләрнең өстеннән таптап үтә. Безнең татар тарихының да көпчәге селкенә башлады. Аның да каткан бозлары эри башлады. Ләкин аны селкетергә, чынлап хәрәкәткә китерергә бик күп көч кирәк, бәлки без шуның янында бозны әрчи-әрчи көпчәк янына йитмәс борын ук көчемез бетеп һәлак булырмыз, бәлки көпчәкне тәгәрәтергә безнең көчемез йитмәс, бәлки без үземез тәгәрәткән көпчәкнең астында үземез калып тәләф булырмыз... Ни булса да булыр, көпчәк кузгалмый кал-

---

*Тәләф булу* — һәлак булу, юкка чыгу.

мас. Шуның өчен синең этиләреңнең кәләпүшләре, тиреләре, минем акчасызлыклар — барысы да безнең эштә гади нәрсә, аларның барысына да күнәргә кирәк.

Ш ә й х е т д и н килеп керә. Кулында китаплары.

Ш ә й х е т д и н. Мин аз гына театрга китмәдем, бүген театрда бик һәйбәт нәрсә уйнала. Акча гына булмады, билет ала идем. *(Өстәлгә барып актарынырга тотына.)* Монда синең күмәчең-фәләнең юкмы? Ах хәзер чәй эчәргә! Мин хәзер әллә никадәр укыдым. Шуннан, чәй вакыты йитә дип, ашыга-ашыга килдем.

З а к и р. Анда этине күрдеңме? Алар анда кәләпүш саный торганнардыр.

Ш ә й х е т д и н. Анда кем дә юк.

З а к и р. Менә бераздан ул йә «Әмин тәзәк» укырга тотыныр, яисә чыгып китәр. Аннары чәй эчәрбез.

Ш ә й х е т д и н. Язмышка разый булмый хәл юк. Китап кибетендә әллә никадәр яңы китаплар бар, аз гына алмадым. Акчам булса яисә китаплар янында хуҗасы булмаса, шөбһәсез, ала идем. Нәрсә сез икеңез дә кашларыңызны коеп утырасыз?

Н а с ы й р. Мин арыдым. Менә шул урындыклардан, шул өстәлдән, шул ишектән, шул куй мае исеннән, шул тормыштан арыдым.

Ш ә й х е т д и н. Мин шул көн дә бертөсле ачлыктан арыдым. Ачлыгы ачлык, ичмасам, бүгенге ачлык белән иртәгәге ачлык башка булса, үзенә күрә төрлелек булыр иде. Иртәдән алып кичкә кадәр чәй, күмәч тугрысында уйла, имеш...

Н а с ы й р. Ачлык бертөрле булса да — ачлык, кырык төрле булса да — ачлык.

З а к и р. Мин ачлыкка чыдар идем. Шул сасы тормыш эскәнҗәсеннән котылсам, ач булсам да риза булыр идем.

Шул арада С а б и р килеп керә.

С а б и р. Каһәр суксын, эти мөридләрен җыеп килгән. Берсе мәктәп ишеге төбендә, берсе Әхмәдиләр чатында, берсе мәйдан янында каравыллап торалар. Нишләргә кирәк?

Н а с ы й р. Көтәр-көтәр дә китәр. Бу — Казан бу. Монда торырга акча кирәк. Сала ишаны акча чыгарырга яратмый ул. Синең фатирыңны беләләрме?

С а б и р. Белмим, мин өйдә кунмыйм. Монда килмәсләрме?

З а к и р *(караватны күрсәтеп)*. Килсәләр, әнә тегендә керәсең дә ятасың.

Шәйхетдин. Анардан алдап-йолдап акча алып булмыймы? Синең чәчең йитмәгән әле. Минем казакины киясең, бик яхшы булган булып барасың: «Менә шул арада ахунлыкка имтихан кылынам. Учительгә бирергә акча кирәк»,— дисең. Валлаһи, сала мулласы ышана.

Сабир. Юк, булмый. Ул инде андый сабакларны укыды. Мин аңардан ахунлыкка түгел, казыйлыкка имтихан кылынам дип акча алдым инде.

Шәйхетдин. Ах, аяныч! Хәзер без харчевникка барып аш ашар идек.

Насыйр. Моның бөтен уе — ашау.

Шул арада түбәннән дөбердәтәләр: «Закир, Закир! Намазга төш, Закир!» — дигән тавыш ишетелә.

Насыйр. Менә таптылар эш! Мин үзем бунда укыйм диген.

Түбәннән тагы дөбердәтәләр.

Закир. Нәрсә?

Түбәннән тавыш: «Намазга төш! Әтиең көтеп тора».

Закир. Ярар, ярар. Укысын. Әле намазның вакыты чыкмый.

Шәйхетдин. Мин ач булсам ач. Ләкин мине беркем дә команда белән йөртә алмый.

Дөбердәтәләр, тагы: «Закир, намазга!» — дигән тавыш.

Насыйр. Төш, күңеле булсын!

Закир. Юк, булмый. Бәлки, шулай команда белән булмаса, үзем дә укыр идем. Шул команда, шул полицейски форма шулкадәр туйдырды... Әйтеп бетерер хәл юк.

Түбәннән дөбердәтәләр. Шәмсетдин тавышы: «Закир, намазга!»

Сабир. Монда менә, каһәр суксын! *(Закир янына барып.)* Бар, төш. *(Түбәннән дөбердәтәләр.)*

Шәйхетдин. Тагы низаг кына чыга. Бар, төш, зинһар, төш. Әллә биш минут басып тору бик авыр эшме? Юкса әтиең менеп мәҗлеснең кәефен йибәрәчәк.

Насыйр. Төш.

Тагы дөбердәтәләр. Насыйр, Шәйхетдин Закирны төртеп төшереп йибәрәләр. Тавыш басыла.

Шәйхетдин. Вөҗданыңа хилаф эш кылу бик авыр.

Сабир. Мондый кечкенә эшләрдә генә зарар юк. Хатты мөстәкыйм белән хәрәкәт итү мөмкин түгел. Хосусән,

безнең тормышта. Хәзер шул намаз өчен Закирның атасы шәм яндырып сугыш ача бит... Әйдә, күңеле булсын! Укы!

Насыйр. Алай булгач, ник атаңнан качып йөрисең?

Сабир. Минем эшем бөтенләй башка. Ул мине бөтенләй алып китеп җәһәннәмдә дүнектермәкче була. Бер-ике намаз укырга гына булса, мин качып та йөрмәс идем.

Шәйхетдин. Бүген гәзитә укыдыңызмы?

Сабир. Мин укыдым. Бернәрсә юк, Петербургта бал булган. Төрек пашасы белән тансавайт иткәннәр. Әллә нинди генерал үлгән.

Шәйхетдин. Татар галәменнән?

Сабир. Татар галәменнән: Тәтеш өязеннән бер мулла мәктәптән мөгаллимне куган. Мужиклар мулланы куганнар. Томскида кызлар мәктәбе ачмакчы булалар. Оренбургта җәмгыяте хәйрия ачарга йөриләр. Касыймда кызлар имтиханы булган...

Насыйр. Шул гынамы?

Шәйхетдин. Йитәр. Татар бик кызу кузгалмый.

Шул арада түбәндә аяк тавышы ишетелә.

Сабир. Атасы менә. Каһәр икән! Кайда качыйм?

Шәйхетдин. Карават асты минеке!

Баскыч дөберди башлый. Шәйхетдин карават астына керә. Сабир ишектән өй түбәсенә чыга. Насыйр көтеп алып, укыган булып утыра. Шәмсетдин, аның артыннан Закир менә.

Шәмсетдин. Әссәламе галәйкем! Исәнме, мулла Насыйр! Мин сине намазга чакырырга да оныткканмын.

Насыйр. Мин укыган идем.

Шәмсетдин. Укыган булсаң ярый. Намаз укыгач, күңел тынычланып китә. Кайвакытта тимер юлда намаз укып булмый. Урыс тимер юлында намаз уку бик мәшәкать бит. Мине йокы алмый.

Насыйр. Әйе, гадәтләнелгән шул.

Шәмсетдин. Юк, гадәт кенә түгел. Аллаһе Тәгалә күңелгә салган. Менә Закирга әйтәм, намазыңны укыгач теләгәнчә кылын, дим. Ахры баланы-чаганы үзеңә догачы булсын дип укытасың. Шуның өчен без картларның намаз укытырга теләвен дә гаепләргә ярамый. Соң, этиеңнәрдән хат аламсың?

---

*Хатты мөстәкыйм* — туры юл.
*Хосусән* — бигрәк тә, аеруча.

Н а с ы й р. Алам.

Ш ә м с е т д и н. Соң, мулла ясарга теләмиләрме? Тамга җыймыйлармы?

Н а с ы й р. Юк, андый яңы хәбәрләр юк әле.

Ш ә м с е т д и н. Синең әтиең Сәлах хәзрәттә укыганмы?

Н а с ы й р. Юк, безнең әти Кышкар шәкерте.

Ш ә м с е т д и н. Моназарәгә остадыр алай булса, соң, бик моназарә кылышасызмы?

Н а с ы й р. Кылышамыз.

Ш ә м с е т д и н. Син, мулла Насыйр, үзең нинди һәйбәт егет. Мөселманча гыйлемең бар, русча да беләсең. Өстене-башыны гына мөселманча йөртмисең. Менә нәрсәгә бу кыска казаки?

Н а с ы й р. Безнең яшьлек инде.

Ш ә м с е т д и н. Шулай шул. Менә безнең Закир яшьлек дигәч тартышырга тотына.

Шул арада карават астында Шәйхетдин кулын бутый.

Ш ә м с е т д и н. Сез укый идеңезме? Укыңыз, укы! Угылым, кунакны чәй эчер. *(Тора башлый.)* Хушыңыз әле, мулла Насыйр!

Н а с ы й р. Хуш, Шәмсетдин абзый.

Шәмсетдин төшеп китә. Карават астыннан Ш ә й х е т д и н чыга. Тузанга буялган.

Ш ә й х е т д и н. Уф! Пешеп беттем, бусы тагын аның белән фәлсәфә сата. Йөткерәсе килә, арка кычый, көчкә чыдадым.

Шул арада С а б и р чормадан чыга.

С а б и р. Ыж-ыж! Туңдым. Уф, туңдым! *(Калтырый.)* Валлаһи, тагы әзрәк торса, катып үлә идем. *(Кесәсеннән бер сумса чыгара.)* Туңсам туңдым!.. *(Ашарга тотына.)* Каты, теш үтми.

Ш ә й х е т д и н. Валлаһи, белмәдем, сиңа карават астын биргән булыр идем. Тагы менсә генә ярар иде. Чормага качар идем.

С а б и р. Инде анда бернәрсә калмады. Бер пешмәгән каз гына бар, кимереп карадым — чи!

Ш ә й х е т д и н. Закир, нишләп торасың? Ул бит: «Кунакны чәй эчер»,— диде, тизрәк!

З а к и р. Хәзер мендерәләр, әнә килә.

Шул арада самавыр күтәреп а с р а у менә.

---

*Моназарә* — бәхәс, сүз көрәштерү.

Асрау *(Шәйхетдингә)*. Кара, бу әрәмтамак тагы бунда икән әле. Менә мин абзыйга әйтим әле.

Шәйхетдин. Шаштыңмы әллә син, Әсма! Без бит синең белән бик дуст. Син менә бунда ашарга күбрәк меңгер. Анда паштет-фәлән юкмы? Сумсадыр-фәләндер... Бәлеш тә ярый, суык булса да ярый, гаепләмибез.

Асрау. Тагы как-төш кирәк түгелме!

Шәйхетдин. Бал булмаса да ярый. Варенье генә мендер.

Асрау *(төшә башлый)*. Менә каткан икмәк мендерермен. Монда сез әрәмтамакларны туйдыра алмассың! *(Асрау югала.)*

Закир *(Шәйхетдингә)*. Ничек иренмисең?

Насыйр. Эше шул...

Сабир. Ул кызлар белән сөйләргә өйрәнеп беткән.

Шәйхетдин. Тормыш бу, тормыш бу, туганнар, өйрәнерсең!

Шул арада асрау чынаяклар күтәреп менә. Тәрилкәләрне куйганчы, Шәех, Сабир, Насыйр паштетны ашап бетерәләр.

Асрау. Бирәннәр икән! Закир абыйга калдырмадылар да.

Шәйхетдин. Мин әйттем ич сиңа, күбрәк мендер дип. Менә үзеңә генә хезмәт күп була. Мендерми хәлең юк. Мин сиңа, Әсма, әле бәйрәмгә бүләк алыйм дип торам. Син нәрсә яратасың? Ислемаймы, сабынмы?

Асрау. Хәерче! Бүләк дигән була бит... Акчаң булса әле, күмәч алып ашар идең!..

Сабир. Мин сөйләсәм дә ярый, исмаса, Әсма, ә? Минем акчам бар.

Асрау. Барыңыз бер — бетле инде.

Шәйхетдин *(асрауның аркасыннан кагып)*. Ул синең бүләгеңә исе китми. Менә үзем алам.

Асрау. Мин, бик уйнасаң, авызыңа да сугармын. Бунсын да ашап бетерсәңез, валлаhи, менгермәм. *(Төшеп китә.)*

Шәйхетдин чәй ясап эчә башлый, барысы да чәй ясыйлар да эчәләр. Шул арада Галим килеп керә.

Галим. Бәхетле авыз. Мактап йөрим икән... *(Сабирга.)* Синең әтиең үзенең дружинасы белән сине каравыллый. Миңа чынаяк кая?

Шәйхетдин. Соңга калмаслар...

Закир. Хәзер асрау менә.

---

*Как-төш* — чәкчәк.

Г а л и м. Мин шатлык белән килдем, иртәгә бәйрәм. Шунда әллә бәраәт, әллә гашура!..

Н а с ы й р. Ә «Кяфер булуның сәбәпләре» тагы калды.

З а к и р. Бәйрәм! Мин туйганчы йоклыйм.

Ш ә й х е т д и н. Мин бүген туйганча ашыйм.

Шул арада **а с р а у** бик күп күмәч күтәреп менә.

Г а л и м. Әсма, миңа стакан юк ич! Без бит синең белән якташ. Быел таш кабак җыенына кайтамсың?

Ә с м а. Бетмәс бунда сезнең бирәннәреңез... Барыңыз берьюлы килсәңез ни була? Тагын берсе юк әле. Туйсаңыз, туеңыз. Шуннан артык күмәч юк.

Ш ә й х е т д и н. Май менгерәм дигән идең, кайда? Үзең мине бүләк бирми дип ачуланасың, үзең сүзеңне тутырмыйсың!

А с р а у. Мин сиңа кайчан май мендерәм дидем?

Ш ә й х е т д и н. Бая.

С а б и р. Дөрест, Әсма, әйттең!

Г а л и м. Мин дә ишеттем.

А с р а у. Менә инде, күземә карап ялганлыйлар. Монысы мондук юк иде. Абызтай күрмәсә, мендерермен. Якташ хакына гына. *(Төшеп китә.)*

Г а л и м *(кесәсеннән тәмәке чыгарып)*. Тышка чыгар хәлем юк. Атаң менсә менәр. *(Тарта башлый.)*

Н а с ы й р. Мичкә тарт!

С а б и р. Берне бир!

Н а с ы й р. Төтен тутырасыз. Картны мендерерсез...

А с р а у *(ике стакан, май күтәреп менә. Тәмәкене күреп.)* Монысы ярамый. Хәзер абызтай менә. Тышка чыгып тарт.

Г а л и м *(чәй ясап)*. Актыгы.

А с р а у. Караңыз, үзеңезгә авыр булыр. *(Төшеп китә.)*

Ш ә й х е т д и н. Чын да, мичкә тартыңыз! Сезнең өчен тагы караватастына керер хәлем юк.

С а б и р. Караватастына үзем керермен. *(Чәй эчәләр.)*

Ш ә й х е т д и н. Мин ашамыйча калырмынмыни?

Г а л и м. Үзем сыйлармын, минем акча күп! *(Кесәсен шалтырата.)*

Н а с ы й р. Ялганлый, төймә генә.

Г а л и м. Акча. Ышанмыйсыз? *(Кесәсеннән бер уч көмеш акча чыгарып өстәлгә сала.)*

Ш ә й х е т д и н. Акча, акча! Мин акча йөзе күрмәгәнгә бит ел була! Хәзер харчевняга ашарга барабыз, ярыймы, Галим?

Г а л и м. Ярый, ярый. Монда ашап бетер әле.

С а б и р. Кайдан алдың?

Г а л и м. Толыпны ломбардка кунакка йибәрдем — сигез тәнкә. Фатир өчен өч тәнкә бирдем. Чәй, шикәр алдым. Әле калганын да кая илтеп бетерер хәл юк.

Н а с ы й р. Миңа тетрадьлар кирәк.

З а к и р. Театрга барырга кирәк.

Ш ә й х е т д и н. Миңа бер түгәрәк зур көмәч алырга кирәк.

Г а л и м. Мин хәзер харчевняга барып чәй эчик, дим.

Ш ә й х е т д и н. Ашап.

Н а с ы й р. Риза.

Шул арада дөбердәтәләр. «Закир! Закир!» — дигән тавыш ишетелә. Бердән тыналар. Шәйхетдин караватг янына бара. Галим папиросын кесәсенә тыга. Тагы дөбердәтәләр. З а к и р төшә. Баскычта: «Ник тәмәке тартасыз! Бөтен өй төтен тулды»,— дигән тавыш ишетелә. Мыгырдыйлар. Монда бер сүз дәшми торалар. З а к и р менә.

Н а с ы й р. Әйттем бит, тартырга ярамый, дип. Болар кеше сүзенә карамыйлар.

З а к и р. Бетмәс аларның... Йөз өсте белән китсеннәр!

Ш ә й х е т д и н. Әтиең менмәсен.

З а к и р. Юк.

Шул арада Б ә д р е т д и н килеп керә.

Б ә д р е т д и н. Болар берни булмаган кебек чәй эчеп яталар.

Һ ә м м ә с е б е р а в ы з д а н. Ни бар, ни бар?

Б ә д р е т д и н. Сипагинны үтергәннәр.

Бары да катып калып:

Н а с ы й р. Сипагинны үтергәннәр? Министр внутренних дел Сипагинны үтергәннәр?

Б ә д р е т д и н. Әйе, министр внутренних дел Сипагинны үтергәннәр.

Һәммәсе дә бердән йөрергә тотыналар.

Н а с ы й р. Сипагинны үтергәннәр, әйе, без монда каһәр суккан ачлык белән, каһәр суккан тормыш белән тартышырга кирәк!

Ш ә й х е т д и н. Без монда кәләпүш өчен, төймә өчен әллә никадәр гайрәт сарыф кылырга кирәк...

Н а с ы й р. Әйе, Сипагинны үтергәннәр, революционерлар Сипагинны үтергәннәр. Әйе, иптәшләр, һәммә йирдә тартышу, һәммә йирдә сугышу... Без шулкадәр үземезнең вак тартышуымызга батканмыз, без шулкадәр үземезнең татар тормышы белән изелгәнмез, бүтән нәрсә

хакында уйларга да вакытымыз калмаган. Мин моңарчага кадәр, татарны тәрәкъкый иттерү дип әллә никадәр сөйләсәм дә, шуның өчен үземне корбан кылырга риза булсам да, бу минутка кадәр татарның алга китүе Русиянең алга китүе белән, Русиянең идарәсенең яхшыруы белән бергә үскән, бергә береккән икәнлеген хәтеремә китермәгәнмен. Әйе, иптәшләр, безнең эшемез рус халкының эше белән бергә бәйләнгән, рус халкы тәрәкъкый итмәгәндә без тәрәкъкый итә алмыйбыз. Русиянең идарәсе үзгәрмәгәндә без бер эш эшли алмыймыз.

Ш ә й х е т д и н. Кая ул революционерлар? Ник алар безгә килмиләр? Ник алар безгә юл күрсәтмиләр? Ник алар безгә юлбашчы булмыйлар?

З а к и р. Вакыт, иптәшләр, вакыт, бу сасы куй маеннан аерылырга, күземезне зуррак ачарга, киләчәкне ачыграк күрергә вакыт! Без моңынча анда бер җәмгыяте хәйрия ачылуына, монда бер мәктәп салынуына әллә нинди бер зур эш дип карый идек. Ул хата. Нигез черек булганда ул мәктәптән генә, ул җәмгыяте хәйриядән генә берни чыкмый... Безгә нигезне тазартырга кирәк.

Н а с ы й р. Әнә ул революционерлар нигезне тазартырга тели.

Ш ә й х е т д и н. Мин дә телим.

С а б и р. Мин дә телим.

Н а с ы й р. Без барымыз да телимез.

Ш ә й х е т д и н. Кайдан тотынырга, кайдан якты эзләргә, туганнар?

Б ә д р е т д и н. Безнең, туганнар, барымызда бер кимчелек бар. Безнең күземез күрми. Без барымыз да тугры юлны эзлимез. Без барымыз да халыкка хезмәт итмәкче буламыз. Ләкин халык юлын таба алмыйбыз.

С а б и р. Без укырга кирәк.

Н а с ы й р. Әйе, без укырга кирәк. Без ул юлны табарга кирәк. Без күз алдымыздагы караңгылыкны бетерергә кирәк. Без шул караңгылык белән тартышырга кирәк. Шул караңгылыкны саклаучылар белән тартышырга кирәк.

З а к и р. Без үземезнең гайрәтемез белән хәзер татар тормышының начарлыкларын белдек. Аның нигезенең череклеген аңладык. Без татар революциясе аша үттек. Без Русия революциясенә хәзерләнергә кирәк.

Ш ә й х е т д и н. Татар тормышының эче кайнаган кебек, бөтен Русиянең дә эче кайный. Бөтен халык бу авырлыкка чыдый алмаенча ыңгыраша. Бөтен халык, үзен

*Тәрәкъкый* — алга китү, прогресс.

ничек коткарырга белмәенчә, ком сахрасында сусызлыктан үлә торган кеше кебек тыпырчына. Без, татарның алдагы егетләре, без, татарның алдан баручылары, күз алдымыздагы бу төтенне бетерергә кирәк. Без үземез чынлап аңларга кирәк, үземез аңлаганны аңламаганнарга аңлатырга кирәк.

Н а с ы й р. Бездә гайрәт бар! Бездә ышаныч бар, бездә яшьлек бар, без аларны табарга тиеш. Без тугры юлны табарга тиеш. Без табамыз! Без табамыз!

Б а р ы *(беравыздан)*. Табамыз!.. *(Һәммәсе бергә.)*

Җитәр инде, күрдек күп хурлыклар*—
Бар да иске тормыш шомлыгы;
Тарлыкта, коллыкта күп яшәдек,
Бар да залим патша шомлыгы.
Нигә соң без болай тик ятамыз?

Бүлмәдән чыгалар.
Ш ә м с е т д и н күренә.

Нигә соң бер казык какмыймыз?
Патшасын, төрмәсен һәм җасусын,
Шул казыкка бәйләп атмыймыз...

Шәмсетдин өсткә менә дә, яшьләрнең бу хәлләренә аптырап, баскычта катып карап кала. Гайшә гаепле кыяфәттә аның артында еглап тора.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ш ә м с е т д и н абзыйның өе; зур гына бер бүлмә, яхшы гына җыештырылган. З а к и р киенгән көенчә килеп керә. Киемнәрен төрлесен төрле йиргә салып ыргыта да йөрергә тотына.

З а к и р. Тагы берни булмады. Нишләргә кирәк? Һәммәсе миңа каршы килә. Попечительгә бардым. «Не могу»**,— ди. Ректорына бардым. Анысы: «Не могу»,— ди. «Тыңларга гына рөхсәт бирерсез»,— дидем. «Не могу!» — ди. Тыңларга рөхсәт булса, правасы өчен бер дә исем китми иде. Анысы өчен дә казенный урында хезмәт

---

* Бу җырның актык юллары ерагая-ерагая барырга тиеш. *(Г.Исхакый искәрмәсе.)*

** «Не могу» сүзләре оригиналда һәр урында рус хәрефләре белән язылган.

*Җасус* — шымчы, шпион.

итәргә, ди. Мин кайдан казенный урын табыйм? Университетка керер өчен полициягә хезмәткә кериммени? Гаҗәп! Кеше укырга тели, белергә тели, хезмәт итәргә тели, аның юлын әллә нинди йиде катлы киртәләр белән киртәлиләр.

Элгәре, рус галәменә үземезнең татар дөньясын чагыштырып, читтән генә караганда рус галәме җәннәт кебек күренә иде. Әдәбият дисәң, бөтен дөньясы китап белән тулган. Мәктәп дисәң, бөтен урамнары укучы егетләр, кызлар белән тулган. Музыка дисәң, гакылдан шашарлык итеп тәрәкъкый иткән. Бөтен шәһәрләре әллә ничә төрле фәнни җәмгыятьләр белән тулган. Ул вакытта мин шул рус галәменә идеал иттереп карый идем. Черегән татар тормышын рус әдәбияты, рус музыкасы, рус мәктәпләре белән яңартып, җанландырып була дип уйлый идем. Ул вакытта мин шат идем. Ул вакытта мин мәсгуд идем. Ул вакытта мин хатты мөстәкыйм белән үземнең идеалыма хәрәкәт итә идем. Ул галәмгә якынлашкан саен минем шатлыгым арта иде. Тизрәк, тизрәк шул мәсгуд галәмгә үземнең татарларымны кертү планын кора идем. Үземнең планнарым белән шатлана идем. Менә шул ерактан мәсгуд күренә торган рус дөньясына кердем. Аның мәктәбенә карадым. Котым очты. Ул мәктәп түгел икән, ул полицейский правления икән! Үземә үзем ышанмый башладым.

Әдәбиятына тотындым. Миңа ерактан гына чәчәк аткан гөл бакчасы кебек күренгән әдәбиятын, янына килгәч, кипкән, кысылган, изелгән кышкы күл кебек рухсыз, җансыз таптым, минем идеалым йимерелде. Мин рус галәме дә изелгәнен, рус галәме дә татар галәме кебек көчкә-көчкә генә сулыш алганын күрдем.

Әйе, рус галәме дә изелә. Әйе, рус галәменә дә әллә ни йитми, чат саен икешәр городовой булса да, бөтен урамнары полиция, солдат белән тулса да, рус тормышының да әллә ние йитмәгән, әллә кай йире тулмаган. Уйладым, уйладым — таптым.

Ул тулмаган нәрсә — Ирек икән.

Рус әдәбияты ирексезлектән җансыз кебек күренә икән, рус мәктәбе ирексезлектән, корыдагы балык кебек, үләр-үлмәс тыпырчына икән!..

Безнең дә әдәбиятымыз, мәктәпләремез, җәмгыятьләремез шул ирексезлектән алга китә алмый икән. Һәрнәрсәнең нигезе ирек икән. Һәр начарлыкның бар сәбәбе ирексезлек икән!

---

*Мәсгуд* — бәхетле.

Шул арада Шәмсетдин килеп керә. Ул урындыкка утыра. Закир йөри. Бераз дәшми торалар.

Шәмсетдин. Әллә: «Әти, исәнме?» — дисәң ярамыймы? Ай бала, бала!

Закир. Мин синең исәнлегеңне беләм, белмәсәм иде, тагы бер хәл иде. Нәрсәгә кирәкмәгәнгә авыз арытып сөйләп торырга кирәк!

Шәмсетдин. Әйе, сез яшьләр шулай инде. Без картларның, шул, шундый сүз белән дә күңеле була. Җә, утыр. Минем синең белән сөйләшәсем бар. *(Закир утыра.)* Әле Печән базарында булдым. Харчевняга кереп утырдык. Һәммә кеше сине сораша: «Эшкә тотынамы инде?» — ди. Ни әйтергә дә белмәдем. Син нишлисең соң инде? Мин ни дип җавап бирим инде?

Закир. Аларның миндә ни эше бар? Теләсәм нишләрмен.

Шәмсетдин. Юк, алай түгел. Безнең халык кешене тикшерергә ярата. Кешедән үрнәк алырга ярата. Сине хәзер дүрт күз белән: «Ни булыр икән!» — дип көтеп торалар. Әгәр син үрнәк алырлык булсаң, бары да укытырга тора. Менә кешегә үрнәк булырга тырышырга кирәк. Мин дә карт, минем дә тынычлык белән гыйбадәт кылып торасым килә. Үзеңә дә, эш булгач, тыныч булыр.

Закир. Мин эшсез түгел, минем эшем бар. Мин укыйм.

Шәмсетдин *(көлеп)*. Әһе, әһе... Уку эш түгел ул, мин дә укыйм. Аның белән генә тамак туйдырыр хәл юк.

Закир. Мин эш итеп укыйм. Укудан эш чыгарырга дип укыйм.

Шәмсетдин. Кем булмакчы буласың? Адвокат булырга яхшы булыр иде. Безнең мөселман арасында эш күп. Күп акча эшләп булыр иде. Ләкин бик озак укырга кирәк. Дуктыр булырга тагы шулай. 15 тәңкәлек писер булу, яисә харчевнядан харчевняга кереп прашения язып йөрүдә бер дә хикмәт юк!

Закир. Син һәрнәрсәгә акча аша карыйсың?

Шәмсетдин. Шунсыз булмый. Дөнья шулай төзелгән! Син ни чикле белсәң дә, акчаң булмаса, син кеше түгел.

Закир. Минемчә, синең никадәр акчаң булса да, белемең булмаса, син кеше түгел.

Шәмсетдин. Син яшь әле, дөнья күрмәгән. Ярар, синеңчә дә булсын. Белеме дә булса, акчасы да — тагы да яхшы. Шулай бит?

Закир. Белмим.

Ш ә м с е т д и н. Менә шуның өчен сиңа хәзер эшкә тотынырга кирәк. Әлхәмдүлиллаһ, шактый сумамыз бар. Әгәр эшне белеп йөртсәң, син яшь кеше, бер-ике елда икеләтә арттырырсың! Мин дә әле, «карт» дигәч тә, мич башына менеп ятмыйм. Әле Печән базарында Әхмәдиләрнең кибетләре бушый икән. Шуны сөйләдем. Урыны бик яхшы. Читек, кәвеш, кәләпүш, калфак белән бик яхшы эш итеп була. Эшне үзең теләгәнчә йөртерсең!

З а к и р. Юк, миңа кибет кирәкми. Миннән башка да сатучы бетмәгәндер әле.

Ш ә м с е т д и н. Бетүен бетмәгән дә, алар бит синең өчен сату итми. Ашарга да кирәк бит, ярый ла әле сине карт атаң ашатып тора... Мин гомергә тора алмам. Өйләнерсең, балаң-чагаң булыр...

З а к и р *(торып йөрергә тотына. Ачуланган тавыш белән)*. Мин синнән ашарга сорамыйм. Аның белән мактанма!

Ш ә м с е т д и н. Мин «сорыйсың» димим. Сорамасаң да, менә 26 га яшең йитте. Әле атаң өстеннән ашап торасың. Синең яшьтәшләрең дөбердәтеп сату итәләр. Сума арттыралар. Син ни эшлисең?

З а к и р. Мин укыйм. Мин синнән ашарга сорамыйм. Мин бүген чыгып китәргә риза. Мин шулай торуыма риза булсаң торам, булмаса — чыгып китәм. Мин Печән базарына чыгып сату итә алмыйм.

Ш ә м с е т д и н. Син алай дулама әле, чынлап уйла. Беркем дә сине «чыгып кит!» дигәне юк. Баладан малны кызганмыйсың. Әле син үзеңнең балаң юкка белмисең. Син мине дә уйла. Мин ничек кеше күзенә күреним? «Угылың ни эшли?» дигәнгә ни җавап бирим?

З а к и р. Сиңа җавап табар өчен мин Печән базарына чыгып сату итә башлыйм диме! Юк, булмый миннән! Мин үз юлымнан кайтмыйм.

Шул арада Г а й ш ә килеп керә. Ул көлеп кенә урындыкка утыра.

Г а й ш ә. Нишлисез?

Ш ә м с е т д и н. Менә угылың белән кычкырышып утырамыз. Теге кибет тугрысында.

Г а й ш ә. Хәйрия абызтай бар. Шаһиләрдән Закирга җаучы булып килгән.

Ш ә м с е т д и н. Бик рәхмәт безне кешегә санап йөрүләренә! Бу малайга кыз әрәм итәрлек түгел шул!

З а к и р. Мин сездән кыз сораганым юк.

Г а й ш ә. Син сорамасаң да, без синең өчен кайгыртырга кирәк. Без синең атаң белән анаң. Угыл, кызның кияү, кыз сораганын көтеп тормыйлар...

Ш ә м с е т д и н. Ни әйттең соң?

Г а й ш ә. «Рәхмәт, киңәш итеп карашыйк әле»,— дидем. Кызлары бик һәйбәт, күзе-башы сәламәт. Әгъзасы камил. Анасыннан калган йорты кыз исемендә, ди. Банкада акчасы да бар, ди. *(Закир ачуланып-ачуланып йөри.)*

Ш ә м с е т д и н. Мин моңарга кеше баласын әрәм итәргә күңелем риза булмый, бу — җәмәгать тәрбия кылырлык кеше түгел.

З а к и р. Сездән кем кыз сораганы бар? Мин җәмәгать тәрбия кылырлыкмы, түгелме, анда кемнең эше бар?

Ш ә м с е т д и н. Бик кызуланма! Без синең өчен тырышып йөрсәк, сиңа зарарга йөрмимез. Сиңа кибет ачарга теләү сиңа зарар итүмени? Сине бай кызга өйләндерергә теләү сиңа зарар итүмени?

З а к и р. Әйе, миңа зарар итү. Мине үземнең теләгән юлымнан аеру.

Г а й ш ә. Әле бик сикермә... Әллә син җаучы килгәч тә хәзер үк бирәләр дип белдеңме? Шулай күп җенләнеп торсаң, кыз да таба алмассың! Әле без атаң белән исемеңатың чыкмас борын өйләндереп калдырыйк димез...

З а к и р. Мин сездән өйләндерергә сорамыйм. Кирәк булса, үзем дә табармын.

Г а й ш ә. Син үзең табарсың? Кайдан табарсың? Урамнан алып керерсеңме?

З а к и р. Теләсәм, урамнан алып керермен, анысы сезнең эшеңез түгел!

Ш ә м с е т д и н. Юк, анысы безнең эшемез. Юк, без урамнан алып керергә рөхсәт бирмәбез.

З а к и р. Миңа сезнең рөхсәтеңез кирәк түгел. Мин үземә үзем хуҗа.

Г а й ш ә. Юк, кирәкми. Әле дә син ни теләдең, шуны эшләп тордык. Монысында ирек бирмәмез. *(Шәмсетдингә карап.)* Нәрсә аның белән сөйләп торырга! Тотарга да үзара эшне бетерергә!

З а к и р. Карап караңыз! Мин сез өйләндерергә теләгән кешегә өйләнмим!

Г а й ш ә. Син теләгәнгә без риза булмыйбыз!

З а к и р. Ярар, булмаңыз, сездән ризалык сораган кеше юк!

Ш ә м с е т д и н. Нәрсә шул юньсез белән сөйләп торырга... Дүнексен!

Г а й ш ә. Ул миңа бала шул!

Ш ә м с е т д и н. Ул сине ана итәме соң? Итмәгәч, ни дип аның артыннан йөрергә? *(Чыгып китә. Бераз тик торалар.)*

Г а й ш ә. Син саташма, Закир, атаңның юкка ачуын

китерәсең. Өйләнмәсәң, өйләнмим диген. Ник ул кадәр каты сөйләргә кирәк! Шаһиләр кызын яратмасаң, Әхмәтҗаннар кызы бар, аңардан да чибәр.

Закир. Минем башта өйләнү мәсьәләсе түгел әле. Аңлыймсың шуны? Ник юкка эчне пошырып йөрисез?

Гайшә. Соң кайчанга өйләнерсең? Минем дә килен күрәсем килә...

Закир. Кайчанга теләрмен, шунда әйтермен. Хәзергә туйдым.

Ишектә Сабир белән Шәйхетдин күренә. Гайшә качып чыгып китә.

Шәйхетдин. Нәрсә син читлектәге җәнлек кебек кылынып торасың?

Закир. Аз гына җаным чыкмады. Элгәре эти килде дә кибет ачу тугрысында сөйләргә тотынды. Улсы гына йитмәгән, әни өйләндерү тугрысында сөйләндерергә тотынды. Көчкә чыдадым.

Сабир. Мин учитель таптым, дүшәнбедән укырга тотынам.

Закир. Латин бикләргә көчең йитәме?

Сабир. Йитә.

Закир. Акча кайдан аласың?

Сабир. Кайдан табылса, шуннан. Безнең иптәшкә алай бик тирәннән уйларга ярамый...

Закир. Синең гайрәтең күп, миннән булмый.

Шәйхетдин. Минем китап цензордан кайтты. Каһәр суккан, китапны эштән чыгарып бетергән. Бастырырлык та түгел.

Закир. Бик бозганмыни?

Шәйхетдин. Әйтәм ләсә, китап төсе калдырмаган. Алты ай тотты да, аннан соң эштән чыгарып кайтара, ничек итеп чыдап торырга кирәк! Ничек итеп кулыңа каләм алып язарга кирәк!

Сабир. Бер эш эшләр хәл юк.

Шәйхетдин. Юк, бар. Һәр золымның чиге бар, һәр кабахәтлекнең җәзасы бар. Син этләнеп мәшәкатьләнеп яз, имеш, ул кызыл кара алсын да сызсын да бетерсен, имеш. Мин аны аның өчен язганмыни?

Закир. Әйе, авыр. Белергә теләсәң, укырга юл юк. Белдерергә теләсәң, белдерергә юл юк. Һәммә йирдә киртә, һәммә йирдә городовой.

Шул арада Галим килеп керә.

Галим *(кулындагы китапларны ыргытып бәреп)*. Каһәр суксын! Эштән чыгып беттем. Бер ай йөрдем.

Бүген генә «Отказ» кәгазенә кул куйдырдылар. Кәгазендә: «Политический благонадежныйлыгы мәгълүм булмаганга күрә рөхсәт бирелми»,— дигән...

Ш ә й х е т д и н. Нәрсә хакында сөйләмәкче булган идең?

Г а л и м. Франция мәктәпләре хакында фәлән китап, фәлән китап буенча дип күрсәтеп бирдем. Юк, рөхсәт юк, ди. Ахырдан үзем тагы губернатор канцеляриясенә бардым. Анда: «Русча булса, тагы мәктәпләр хакында булмаса, бәлки бирер идек»,— диләр. Соң: «Нинди мәсьәлә хакында булса бирер идегез?» — дип сорадым. Чиновник: «Кәҗә асрау хакында, кәҗәнең файдалылыгы хакында, кәбестә үстерү тугрысында булса, бирер идек. Мәктәпнең сәяси мәсьәләгә катышы бар»,— ди. Шулкадәр ачуым килде. Авызын сугып ярырлык булдым!

Ш ә й х е т д и н. Мөбарәк булсын! Мин бүген цензурадан китабымны алдым. Син әле бер генә ай йөрдең. Мин элгәре никадәр мәшәкатьләнеп яздым. Ахырдан алты ай көттем. Бернигә ярарлык түгел...

З а к и р. Мин дә үземнең шатлыгымны әйтмәгән икәнмен әле! Миңа да попечитель дә, ректор да отказать итте. «Казенный урында хезмәт итәргә кирәк»,— ди.

С а б и р. Барыгызга да бер-берегезне котлашырга ярый.

Шул арада Н а с ы й р белән Ш а к и р ә килеп керәләр. Егетләр барысы да рәтләбрәк утыралар, Шакирә барысы белән дә күрешә.

Н а с ы й р. Иптәшләр, мин шатлык белән килдем. Шакирә туташ менә уйнарга риза булды, тагы бер-ике кыз табылыр, ди.

Ш а к и р ә. Әйе, табылыр төсле күренә. Кызлар арасында риза булучылар күп тә, аталары йибәрми: «Театрда уйнарга Аллаһем сакласын!» — диләр.

Н а с ы й р. Нәрсәне уйныймыз?

Ш а к и р ә. Мин сез әйткән китапларны барысын укып чыктым. Театрга ярарлыгы бик аз. Русчаларның тәрҗемәсе бик начар. «Кызганыч бала»ны уйнарга кирәк. Хатын-кыз роле дә күп түгел.

Ш ә й х е т д и н. Минемчә дә шуннан мәслихәте булмас. «Өч хатын»га хатын-кыз йиткереп булмас.

Ш а к и р ә. «Өч хатын»га яхшы хатыннар кирәк. Бездән булмас.

Н а с ы й р. Егетләр, нишлибез?

С а б и р. Әйдә, шул «Кызганыч»ны уйныймыз.

З а к и р. Шул ярый.

Ш а к и р ә. Кайда уйныймыз?

Насыйр. Урын бар, Яңы клубта зал бирәләр. Ремесленный собраниядә дә бирәләр. Аннан эш калмый.

Шакирә. Рөхсәт бирделәрме соң?

Насыйр. Рөхсәт бирәләр. Вәгъдә кылганнар иде. Аның артыннан Бәдретдин йөри. Бүген аны повестка белән губернатор канцеляриясенә чакырдылар. Шул рөхсәт язуын алып төшәргә булырга кирәк. Озакламаенча килеп йитәр. Извозчик белән кил, дидем.

Шакирә. Алай булгач, хәзер рольләрне бүләргә кирәк. Фатихны кем ала?

Шәйхетдин. Мин алам.

Шакирә. Сез Фатих түгел. Сезгә ул роль килми.

Галим. Мин атасы булам.

Шакирә. Сезне белмим. Минемчә, сезнең ролеңез түгел ул. Закир әфәнде аны булдырыр иде.

Закир. Мин булдырырлык булсам, алам.

Шакирә. Сез булдырырсыз. Доктор кем була?

Шәйхетдин. Мин.

Шакирә. Насыйр әфәнде кем?

Насыйр. Мин — суфлер.

Шакирә. Хатын-кыз рольләрен без үзара бүлешермез. Ләкин безгә тагы җыелмаенча ярамый әле. Репетиция кайчан башлыймыз?

Насыйр. Тизрәк кирәк. Руза гаетенә куярга кирәк.

Шакирә. Айдан артык әле. Өлгереп була. Репетиция бездә ясап була.

Шул арада кызарынып-бүртенеп Бәдретдин килеп керә.

Бәдретдин *(Шакирә белән генә күрешеп)*. Харап булдык. Рөхсәт бирмиләр.

Бары да *(сикереп торып)*. Рөхсәт бирмиләр?

Бәдретдин. Бирмиләр. Рөхсәт бирмәүне игълан кылырга чакырганнар.

Насыйр. Ни дип бирми?

Бәдретдин. Элгәре бер сүз дә әйтмәде. Тугрыдан-тугры: «Рөхсәт юк!» — кына ди. Ахырдан сөйли-сөйли: «Элгәре,— ди,— ул китаплар русчага тәрҗемә кылынырга кирәк. Аннан соң цензурага бирергә кирәк. Ул рөхсәт бирсә, бәлки без бирермез»,— ди. Кыскасы гына, очы-кырые чыкканчы, башыңдагы чәчләрең агарыр.

Шәйхетдин. Мөбарәк булсын театр! Без үземез тиле. Моңынчага кадәр Русиядә эшләргә мөмкин түгеллекне белмәгән идекмени? *(Шакирәгә.)* Бу «шатлык» хәбәр, Шакирә туташ, безгә бүген беренче түгел. Минем китабым алты ай торып цензурадан кайтты. *(Кесәсеннән чыгарып ыргыта.)* Мәңез, караңыз, бастырырлыкмы-түгелме?

Шакирә карый башлый. Барысы да аның янына җыелалар. Бәдретдин тәмәке тарта.

Шакирә. Бик бетергән!

Шәйхетдин. Менә шуның өчен язып йөрергә ярыймы инде, уйлап карагыз!

Галим. Беттеме? Бетсә, минем шатлыгымны да ишетеңез, Шакирә туташ! Франция мәктәпләре хакында халык җыеп укырга рөхсәт сорап бер ай йөрдем. Полиция белән губернатор вәгъдә кылдылар. Бүген отказать иттеләр.

Закир. Миңа да университеттан колак кактырдылар.

Шакирә. Чын, бу көн сезнең барыңызга да бәхетсез көн икән.

Галим. Мин әйтмәдем әле. Минем бер дуст студентым бар иде. Аңардан андый-мондый язулар алгалый идем. Бүген төнлә белән үзен арестовать иткәннәр дә фатиры янына каравыл куйганнар. Мин бүген барсам: городовой тора. Шикләндем, кача башладым. Ул минем артымнан свисток бирә башлады. Кешеләр йөгерә башладылар. Күрше йортка кереп кенә котылдым.

Насыйр. Русиядә эшләргә мөмкин түгеллеккә яңа дәлил. Бу идарә булганда эшләп тә булмый, бу идарә булганда язып та булмый. Сөйләп тә булмый, театр да ясап булмый.

Закир. Мин дә шул фикергә килдем. Ирек булмаганда берни эшләп булмый.

Шәйхетдин. Без эшлимез дигән булып үземезне-үземез алдап йөрмәскә кирәк...

Насыйр. Хәзер без лыгырдап йөрүне ташлап, партияләр белән чынлап танышып, алар белән бергә хезмәт итәргә кирәк.

Шәйхетдин. Яисә үземезгә бер татар җәмгыяте корырга кирәк.

Закир. Ни булса да булсын, бүгеннән башлап шул юлда эшли башларга кирәк. Төрмәдән куркып торып булмый. Безнең шикелле кешеләр яталар ич, без генә кем булган!

Сабир. Минем бер студентым бар, аның шундый китаплары бар, шуны чакырыйк.

Насыйр. Вакыт, вакыт. Югалган өметләр туйдырды. Чын эш кирәк.

Шул арада Шәмсетдин килеп керә.

Ш ә м с е т д и н. Бу нинди собрания? Әле миңа мохтаҗ түгел диген идең, әле этләреңне җыеп килгәнсең! *(Шакирәне күреп.)* Бу нинди кыз? Урамнан алып кердеңмени?! *(Һәммәсе торалар.)*

З а к и р. Авызыңны үлчәп кенә ач. Миңа теләсәң ни әйтергә ярагач, бөтен кешегә шулай ярый дип белдеңме?

Ш ә м с е т д и н. Дуңгыз! Эт көтүе кебек кешеләр җыю йитмәгән, инде кызлар алып керә башлаган!

Н а с ы й р. Син ни сөйлисең, Шәмсетдин абзый? Бу кызның кем икәнен беләмсең?

Ш ә м с е т д и н. Кем булсын, шунда бер эттер...

Ш а к и р ә *(Закирга)*. Ник минем өчен ул кадәр тавыш чыгарасыз? Мин хәзер чыгам да китәм.

Н а с ы й р *(Закирга)*. Закир! Син бу тиле карттан бик күп күтәрдең, әллә никадәр мыскыл күрдең, барысына да чыдадың, ләкин бунысы чыдарлык түгел. Вакыт, сиңа да вакыт!

Ш ә м с е т д и н. Әллә ялыналармы? Йөз өсте белән кит!

З а к и р. Китәм, китәм. Бу мыскылга чыдар хәлем юк.

Ш а к и р ә. Минем өчен ул кадәр зур эш чыгармаңыз...

Ш ә й х е т д и н. Чуан моңынча да тулган иде, хәзер тишелде генә, Шакирә туташ!

Ш ә м с е т д и н *(Закирга)*. Сал пальтоны!

Н а с ы й р. Сал! Мә минем пальтоны, мин пальтосыз китәм...

Закир, пальтоны салып, Насыйр пальтосын кия. Шул арада Г а й ш ә килеп керә. Ул хәзер качмый.

Г а й ш ә *(Закирга)*. Кая барасың?

З а к и р. Китәм, бу хурлыкка чыдар хәлем юк, китәм...

Г а й ш ә *(Закирны тотып)*. Кая китәсең, Закир, нишлисең? Кал, бәбкәм, кал! *(Закир тартылып китә башлый, Гайшә Закирның чабуына тотынып.)* Ничек кеше күзенә күренермез? Китмә, Закир, китмә!

Н а с ы й р. Йитәр! Бик күп уйнадыңыз!..

Барысы да чыгып китәләр, Гайшә җыларга тотына, Шәмсетдин катып кала. Бераздан соң Гайшә кычкырып җылый. Шәмсетдин: «Закир, Закир!» — дип кычкыра.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ике елдан соң. Уртача гына бүлмә. Ятак, урындыклар, өстәл, китаплар, гәзитәләр. Бүлмә — Насыйр бүлмәсе. Тәмәке төтене белән тулган. Насыйр, Сабир, Шәйхетдин, Галим, Шакирә — һәммәсе дә утырганнар.

Насыйр *(Шакирәгә)*. Закир киләме?

Шакирә. Белмим, киләм, диде. Ләкин килә алыр микән? Бик авыру.

Галим. Йөткерүе бер дә йомшармыймы?

Шакирә. Беркөн азрак йомшарган иде, мунчадан кайтканда тагы суык тидерде. Тагы артты. Аннары үзе дә бер дә сакланмый, көне-төне китап өстендә.

Шәйхетдин. Бераз хәл җыярга кирәк иде.

Шакирә. Әллә нишләр хәл юк, мин дә шулай дим дә, ул сүзне тыңламый шул. «Үләргә булгач, барыбер үләргә»,— ди.

Сабир. Тәрбия яхшы булганда чахотка белән бик озак та яшиләр.

Шакирә. Ул: «Исән кешеләргә зарар итеп, микроб таратып торганчы, тизрәк үлеп, якыннарыңны мәшәкатьтән коткару артык»,— ди. «Корыган агач, никадәр кисмәенчә тотсаң да, яңадан яфрак ярмый, бәлки, таза агачларны гына корыта»,— ди.

Насыйр. Әйе, авыр. Үлемгә хөкем кылынган итеп хис кылу бик авыр. Аны алай булса көтмибез?

Шакирә. Юк, көтмибез, монда бит безнекеләрдән Сабир бар, мин бар.

Насыйр. Бәдри киләме? Кем күрде?

Шәйхетдин. Юк, килми. Ул: «Теләсәңез нишләңез!» — ди.

Насыйр. Алай булса, башлыймыз. Менә, иптәшләр, эш нидә: барымызга да мәгълүм, хәзер безнең татар җәмгыяте эш эшли алмый. Чөнки замана безнең җәмгыятьтән узып китте. Без булдырырга теләгән нәрсәләрнең кайсылары бик кечкенә булып калды, кайсылары булды. Тагы, шуның өстенә, җәмгыятемезнең әгъзалары җәмгыятьнең программасы белән генә канәгатьләнә алмадылар. Кайсылары с.д.ларга кушылды. Кайсылары с.р.ларга кушылды. Кайсылары кадетларга китте. Шуның өчен без, хәзер бу мәҗлестә шул җәмгыятьнең идарәсе җыелганга, җәмгыятьне бетерү-бетермәү хакында, әгәр бетерелсә, җәмгыятьнең акчасын кайда итү хакында сөйләшергә һәм дә бер карарга килергә тиеш. Шул хакта сөйләргә теләгән кеше сүз алыңыз!

---

*С.д.лар* — социал-демократлар.
*С.р.лар* — социал-революционерлар (эсерлар).

Ш ә й х е т д и н. Мин.

С а б и р. Аннан ары мин.

Н а с ы й р. Ярый. Нәүбәт Шәйхигә.

Ш ә й х е т д и н. Минемчә, артык сөйләп торырлык эш юк. Монда безнең арада низаг та булмас. Мин үземезнең с.р.ларның карарын сөйләмәкче булам. Без җәмгыятьне бетерергә һәм дә җәмгыятьнең калган акчасына кечкенә генә булса да бер көтепханә ачарга карар бирдек. Җәмгыятьнең пичәте, язулары хакында — аларны ышанычлы бер йирдә саклап, югалтмаска карар бирдек. Чөнки, шөбһәсез, бервакытны алар барысы да тарих ноктаи нәзарыннан бик әһәмиятле нәрсә булачаклар. Мин беттем.

С а б и р. Хәзер миңамы?

Н а с ы й р. Әйе.

С а б и р. Без дә шул карарга килгән идек. Минем арттыра торган сүзем шул гына: көтепханә өчен китап алырга с.р.лардан, с.д.лардан берәр кеше сайлансын, аннары көтепханәнең китаплары партия әгъзасы булмаган кешеләргә дә бирелсен. Мин беттем.

Г а л и м. Мин.

Н а с ы й р. Сөйлә!

Г а л и м. Безнең җәмгыять күп эш эшләдеме, аз эшләдеме, халык арасында исеме бар, күп йирләрдә җәмгыятьнең шөгъбәләрен хәзерләшүчеләр бар, шуның өчен, халыкны чынлап җәмгыятьнең ябылуы белән таныштырыр өчен, ябылуның сәбәпләрен ачык бәян кылып игълан таратырга кирәк. Ул эшне озакка калдырмаенча, бүген үк шуңарга бер комиссия сайларга кирәк. Мин беттем.

С а б и р. Мин.

Н а с ы й р. Сөйлә!

С а б и р. Мин Галимнең фикеренә кушылам. Әлбәттә, шундый бер игълан таратмаенча ярамый. Ләкин комиссиянең әгъзалары ике партиядән дә тигез булырга кирәк.

Н а с ы й р. Аның өчен низаг чыкмас.

С а б и р. Алай түгел. Без бунда икәү генә. Сез өчәү. Тавыш белән сайлаганда, комиссия әгъзаларын барысын да сез үз араңыздан сайлау ихтималыңыз бар.

Н а с ы й р. Юктан куркасың! Без — с.р.лар, андый иттифакый күплектән генә файдаланырга яратмыйбыз. Без с.д. түгел.

Ш а к и р ә. С.д. лар шулай итәләрмени?

Г а л и м. Әйе, бәхетсезлеккә каршы, итәләр.

---

*Ноктаи нәзарыннан* — караш ноктасыннан.
*Шөгъбә* — бүлекчә.
*Иттифакый* — очраклы.

Ш а к и р ә. Кая шулай иттеләр?

Г а л и м. Алафузов заводында эшләүчеңез ни сөйләде? С.р.лар хакында ни диде? Без аны кеше дип санасак, иптәшләр хөкеменә чакыра идек.

С а б и р. Чакыру кирәк иде. Сезнең Шәйхиләр с.д.лар хакында мәдрәсәдә ни сөйләде?

Г а л и м. Шәйхи үзе монда, үзеннән сора!

Ш ә й х и. Мин нәрсә сөйләдем, мин ни сөйләгән булсам — шуларның барысына да җавап бирергә хәзер.

С а б и р. Авыл халкына с.д.ларның каравы хакында ни әйттең?

Ш ә й х и. Социал-демократлар эшченең файдасын күзәтәләр. Алар авыл халкын эшчедән бөтенләй аера. Икесе ике сыйныфтан, ди. Алар авыл халкының файдасын күзәтми, дидем*.

С а б и р. Бу ялган түгелме? Бу ифтира түгелме? Без бөтен йирне конфисковать итүне признать итәмез. Авыл халкына йир өчен тартышуында ярдәм итмибезме?

Ш ә й х и. Конфисковать ителгән йирне кайда итәсез? Сезнең аңарга бер сүзеңез дә юк. Аның өчен монда кычкырышырга да ярамый. Социал-демократ — мин хәйсиһи социал-демократ авыл халкын йирле итәр өчен тартышмый, ул эшчеләр партиясе. Эшчеләргә авыл халкының йирле булуы файдалы булса, йирле ясарга тырыша, йирсез булуы файдалы күренсә, йирсез ясарга тырыша. Без, с.р.лар, эшче белән үз көче берлән иген игә торган авыл халкын аермыймыз. Аның файдасын, эшче файдасыннан аермыймыз. Шуның өчен үземезнең флагымызга «Җир, ирек!» дип язамыз.

Н а с ы й р. Сез бөтенләй шәкерт моназәрәсенә кереп киттеңез.

Ш а к и р ә. Минемчә дә шулай. Бөтен Русиядә икегә аерылган партияләрне сез кычкырышып кына берләштерә алмассыз инде.

С а б и р. Мин шул комиссиядә ике партиядән дә тигез булсын, дим.

Н а с ы й р. Без риза.

Шул арада З а к и р килеп керә. Насыйр, Шәйхи, Галим белән күрешә. Урындыкка утыра да бик озак йөткерә. Һәммәсе аңарга карап торалар. Шакирә барып, башын тота. Бераздан соң Закир йөткерүдән туктый. Ләкин сөйләгәндә һаман йөткерә.

---

*Вакыйга социал-демократларның дүртенче съездларына кадәр. *(Г.Исхакый искәрмәсе.)* Социал-демократларның (РСДРПның) дүртенче съезды 1906 елның апрель аенда Стокгольмда уза.

*Ифтира* — яла ягу.

*Мин хәйсиһи социал-демократ* — чын, саф социал-демократ.

Н а с ы й р. Монда, Закир, без сине көтмәдек. Җәмгыятьне ябуга, аның калган акчасына көтепханә ачарга, китаплар алырга ике кешедән...

С а б и р. С.р.дан — бер, с.д.дан — бер...

Н а с ы й р. Дөрест. Комиссия ясарга, игъланны язып таратыр өчен с.д.лардан бер, с.р.лардан бер кешедән мөрәккәб комиссия ясарга карар бирдек. Син ни әйтәсең?

З а к и р. Мин сезнең карарыңызга кушылам.

Н а с ы й р. Алай булгач, хәзер шул комиссияләрне сайларга кирәк. Әүвәл китап комиссиясе. Без үз тарафымыздан Шәйхине сайлыймыз.

З а к и р. Без Сабирны.

С а б и р. Мин Шәйхи белән бер комиссиядә эшли алмыйм. Ул артык с. революционер. Ул үзенең с.р. китапларын алдырырга тырышыр. Мин — с.д. китапларын. Китап магазинында сугышыйкмыни?

Н а с ы й р. Син дә артык с. демократ. Безнеңчә, безнең тарафтан Шәйхидән мәслихәт кеше юк. Без, Сабир эшли алмый дип, Шәйхине сайламый калдырмыймыз. Сез, теләсәңез, бүтәнне сайлаңыз.

З а к и р. Миннән булмый. Син бул, Сабир.

Ш а к и р ә. Мин сезнең кылынышыгызга исем китә! Бер ике-өч ай элек бер савыттан ашаган кешеләр, бер партиядә хезмәт иткән кешеләр берсе с.р., берсе с.д. булган да, бергә комиссиядә хезмәт итә алмыйлар, имеш.

С а б и р. Ярар, алай булса.

Ш ә й х е т д и н *(көлеп)*. Сугышырга булса — магазинда түгел, йә элек сугышырга, йә соңыннан. Миңа кеше бар йирдә сугышу файдалы түгел. Мин нелегальный.

С а б и р. Ярар, ярар, элек сугышып барырмыз.

Н а с ы й р. Редакционный комиссиягә. Безнең тараф мине сайлый. Сез кемне?

С а б и р. Әлбәттә, Закирны.

З а к и р. Ярый.

Н а с ы й р. Алай булса, мин хәзер мәҗлесне ябам.

С а б и р *(Шәйхи янына килеп)*. Акчаны кайчанга аламыз? Әй, председатель! Акчаны кемнән аламыз?

Н а с ы й р. Элгәре казначейдан икәү барыңыз да алыңыз. Карарны аңар сөйләңез. Бәдретдин белән ул барысына да риза.

С а б и р. Ярый. *(Шул арада Насыйр Закир янына барып утыра. Закир, Шакирә, Насыйр акрын гына әллә ни сөйлиләр. Сабир Шәйхигә.)* Соң, без кайчан җыеламыз? Без элгәре нинди китаплар алу турысында уйлашырга кирәк?

---

*Мөрәккәб* — оешкан, төзелгән.

Ш ә й х е т д и н. Тукта, хәзер әйтәм. *(Уйлап торып.)* Бүген... Бүген кичкә эш бар. Иртәгә... Эмм... Иртә белән тегендә, көндез — анда, кич белән сигезгә кадәр — теге эш. *(Сабирга.)* Иртәгә сигездән соң.

С а б и р. Ярый.

Ш ә й х е т д и н. Кайда җыеламыз? Минем фатир андый түгел.

С а б и р. Миңа кил. Беләмсең?

Ш ә й х е т д и н. Юк.

С а б и р. Собачий переулокта, уң яктан өченче йорт. Капкасына калуш сурәте ясап куйганнар. Эчтәге йортта, түбән ишектә «квартирант» дип кенә сора.

Ш ә й х е т д и н. Ярый.

Сабир күрешеп чыга. Шәйхи утыра.

Н а с ы й р *(Закирга)*. Без кайчанга җыеламыз?

З а к и р. Минем бүген дә вакытым бар.

Н а с ы й р. Минем — юк. Иртәгә сәгать дүртләрдә, ярыймы?

З а к и р. Ярый, миңа җыеламыз.

Н а с ы й р. Ярый. Соң нишләп торасыз, Закир? Әтиеңнәргә барамсың?

З а к и р. Баргалыйм, алай да сирәк.

Н а с ы й р. Финансыңыз ничек?

Ш а к и р ә. Торамыз әле. Ломбард исән булсын.

З а к и р. Син ничек?

Галим белән Шәйхи үзара сөйләшәләр. Кәгазьләр белән маташалар.

Н а с ы й р. Этләнәмез. Эш бик күп, бик арытты. Революция бетсә, быел кымызга барам.

З а к и р. Әйе, сез эшне бик күп куйдыгыз. Гәзитә, китап бастыру, организация...

Г а л и м. Безнең әле син белмәгән нәрсә дә бар. *(Кесәсеннән чыгарып, татарча типографиядә басылган прокламацияне күрсәтә.)*

З а к и р *(кулына алып)*. Зур эш.

Ш а к и р ә. Кая әле *(карыйлар)*.

З а к и р. Куя алдыңыз? Браво! Бик күп эшлисез. Мин сезне көнлим. *(Үзе йөткерергә тотына.)*

Ш а к и р ә *(әйләндереп-әйләндереп карый да, Галимгә)*. Мин моны алыйммы?

Г а л и м. Алыңыз! *(Шакирә бөтәрләп ридикюленә тыга.)*

Шул арада дөбердәп, С а б и р килеп керә.

С а б и р *(Закирга)*. Синдә тентү!

Ш а к и р ә. Кем әйтте?

Сабир. Үзем күрдем. Бөтен тирә-якны сырып алганнар.

Барысы да сикереп торалар.

Закир. Нәрсә бар иде?

Шакирә. Рәтләп белмим!

Закир. Теге, кичәге прокламацияләр бармы?

Шакирә. Аларны мин илттем. Язу өстәлендә ниләр бардыр?..

Закир. Бер дә белмим. Алырга килгәннәр инде...

Насыйр. Анысында сүз дә юк!

Сабир. Нишлимез? Болай катып торып булмый.

Насыйр. Берни дә эшләмисез. Син китәсең үзегезнекеләргә, тентү икәнлекне белдерәсең.

Закир. Әйе, әйе, бүген 2 сәгатьтә миңа Иван килермен дигән иде. Барып әйт. Харап булыр.

Шәйхетдин. Хәзер Закирга үз киемен үзгәртергә кирәк. Аннары мыегын алырга кирәк. Оста йөрегәндә бер ел йөреп була.

Закир. Әйе, бар, Сабир, син шуларны эшлә. Тукта, тагы барасы йир юкмы? Тагы үзең беләсең.

Сабир. Мин сине кайдан табармын?

Закир. Шакирә әйтер.

Гали. Шакирә ничек? Бәлки аны да алырга тели торганнардыр?

Шакирә. Юк. Татарка белән нишләсеннәр.

Шәйхетдин. Алай кылынырга ярамый. Полиция ул мәсьәләдә интернационал... Элгәре сезгә дә фатирга кайтмаска кирәк.

Закир *(Сабирга)*. Алай булса, мин Ольгада булырмын.

Сабир. Ярый. *(Чыгып китә.)*

Галим. Хәзер, Закир, синең мыегыңны алырга кирәк. Ала беләмсең?

Закир. Юк.

Галим. Менә бритва. Утыр, булмаса, үзем алам.

Закир. Тукта. *(Шакирәгә.)* Шакирә, син китәмсең?

Шакирә. Мин сине мыексыз күрәсем килә.

Шәйхетдин. Тукта, тукта! Закир, синең анда карточкаң калдымы?

Закир. Белмим.

Шакирә. Бар. Минем сандыкта.

Шәйхетдин. Мыек беләнме, түгелме?

Шакирә. Мыек белән.

Шәйхетдин. Мыексызы бер дә юкмы?

Шакирә. Юк.

Ш ә й х е т д и н *(Галимгә)*. Алай булса, әйдә ал!

Закир утыра, Галим кайчы белән элгәре мыегын кырка, аннан ары алырга тотына.

З а к и р. Мыек кызганыч!

Ш ә й х е т д и н. Иске идарә рухына мыекны гына кызганырга ярамый.

Г а л и м. Бритвасы да рәтләп үтми, шайтанны!

З а к и р. Әй... әй! Авырттырасың!

Г а л и м. Авыртмас!

З а к и р. Чыдар хәл юк! Әллә бөтен тиресе белән аласыңмы? Исмасам, үткәр бритваңны!

Г а л и м *(бритваны кулына тарта башлый. Аннары биленнән ремень ала да аңарга тарта. Шакирәгә)*. Менә нәрсә, Шакирә, әнә самавырда йылы су бардыр, шуңардан әнә теге стаканга су ал әле. Аннан соң мич янында сабын бардыр. Шуны китер.

Шакирә барысын да эшли. Шәйхетдин книгә укый. Насыйр бер язу төзәтә. Закир утырып тора. Галим пәке кайрый.

Г а л и м *(пәкене сачена каптырып карап)*. *Булды. (Закирга.)* Кая әле, авызыңны йом. Хәзер сабынны хутка йибәрәмез. *(Закирның мыегын сабынларга тотына. Закир йөткерә. Бераздан соң мыекны алырга тотына. Закирга.)* Авыртмыймы?

З а к и р. Исмасам, сорама, язмышка риза инде!

Ш ә й х е т д и н. Онытмаска яхшы булыр...

З а к и р. Бу онытырлык ясамый.

Г а л и м. Фәлсәфәне соңыннан сатарсың, тик тор! *(Ала. Бераздан.)* Менә бетте. *(Кулындагы сөлге белән Закирның сабыннарын сөртә. Закир тора. Һәммәсе көләргә тотыналар. Закир көзгегә карый.)*

Ш ә й х е т д и н. Бөтенләй башка кеше!

Ш а к и р ә. Бөтенләй үзгәрде.

Н а с ы й р. Хәзер Габдулла бутышникның күзенә керергә ярый!

Ш а к и р ә. Мин киттем.

З а к и р. Бераздан Ольгага бар. Артыңнан «шгыйб»*-ны алып барма!

Ш а к и р ә. Ярар.

Н а с ы й р *(Закирга)*. Менә хәзер киен. Шулар арасыннан нәрсә ярый, шуны ал!

---

*«Шгыйб» дип «шпик»ны атыйлар иде. *(Г.Исхакый искәрмәсе.)*
*Үткәр* — үткенлә.

Барысы да торалар. Закир киенергә тотына. Бер пальто кия, ярамый, бик озын. Икенчесен кия. Монысы ярый.

Закир. Бүрекне дә үзгәртергә кирәк. *(Закир тагы берсен кия, ярамый. Тагы кия, ярый.)*

Галим. Башлык?

Шәйхетдин. Башлык бер яктан файдалы, бер яктан зарарлы. Алай да ал әле, син башлыксыз йөри идең бит!

Закир. Башлыксыз. *(Башлык бәйли.)*

Насыйр. Тәмам булды.

Шәйхетдин. Менә хәзер сине яңы тормыш белән котларга ярый. Нелегальный тору хәзер легальныйдан йиңел. Урамда йөргәндә артыңа карама! Татар харчевнясына кермә! Городовойдан качма, мөмкин кадәр аның белән сөйләшергә тырыш! Трамвайга утырма! Фатирыңны айдан айга алыштыр! Фальшивка белән торма. Чын паспорт тап! Йөз ел яшәрсең!

Закир. Хушыңыз.

Насыйр. Кунарга-фәләнгә Бәдретдин дә ярый.

Закир. Аның котын очырып маташырга! Табылыр әле!

Шәйхетдин. Шуны катнаштырмаңыз, тик үз кадетлары белән маташсын.

Закир чыгып китә.

Насыйр. Әйе, менә Закир да нелегальный!

Шәйхетдин. Нелегальный гына булса ярар иде дә... Аның бөтенләй эше башка!

Галим. Әйе, ул хәзер тәмам үлек. Күзенә карадыңызмы?

Насыйр. Әйе, тартышу юлында үлүче бер генә түгел. Ул әүвәле булмаган шикелле, ахыры да булмас әле.

Галим. Анысы шулай. Ләкин үзеңә килгәч бик авыр. Мин Закирны ничек тә үлек итеп уйлый алмыйм.

Шәйхетдин. Ул бу нелегальный тормышка чыдый алмаячак, тизме-озакмы, үләчәк. Шуның өчен бүгеннән үк аны үлгән дип карарга кирәк.

Насыйр. Әйе.

Галим. Кем белгән! Бәлки без аңардан да элек үләрмез.

Шәйхетдин. Белмәссең!

Насыйр. Бүген үлмәгән әле. Үлмәгән кешенең әллә никадәр вазыйфасы бар. Безнең татар интеллигентының вазыйфасы тагы күп. Кайда ни эш бар, шуны карарга кирәк! Закир үлсә, үлгәч тә кайгыртырмыз. Әле ул үлмәгән, нелегальный гына.

Галим. Безгә дә бик йибәрелеп йөрергә ярамый. Бу фатирны чистартырга кирәк.

Шәйхетдин. Миңа барырга вакыт йитә. Миңа бу яңылардан унлабыны биреңез әле. *(Галим кәрзинкәдән алып санап бирә. Шәйхи шуларны күлмәге астына тиярга тотына. Ул, яхшылап тияп, поясын бәйли.)* Кая, миңа вагунга акча бармы?

Насыйр. Миндә бар. *(Кесәсеннән алып бер тәнкә бирә.)*

Шәйхи. Алай булса, мин киттем. *(Чыгып китә.)*

Галим. Теге прокламацияне басып алырга кирәк. Масса чоландамы?

Насыйр. Чоланда, икесен дә алып кер! Тиз генә басып алырмыз.

Галим чыга.

Насыйр *(үзе генә)*. Фатирны тизрәк җыештырмаенча ярамый. Әле дә бу фатир бик озак түзде.

Галим бер кулына буш калай форма, икенче кулына масса күтәреп керә.

Галим. Каһәр икән! Чоланның ишеген ачык калдырганнар. Берсен эт ашаган.

Насыйр. Самодержавиянең эте дә безгә зарар итә.

Галим массаны идәнгә куя да чүпрәк белән сөртергә тотына. Насыйр кәгазь күтәреп килә. Галим, кәгазь ябыштырып, массаны корылата. Шуннан кәрзинәдән оригиналны алып, массага ябыштыра. Үзләре кәгазь кисәргә тотыналар. Шактый гына озак кәгазь кисәләр.

Насыйр. Өлгергән дәдер.

Галим. Бераз торсын әле. *(Тагы бераз торалар. Галим каерып карап.)* Өлгерде. *(Акыртын гына ала, Насыйр кәгазьне алып бирә. Галим басарга тотына. Берсен ала да бик җентекләп карарга тотына.)* Әһе, ярый. Менә монда гына тоныграк төшкән, баса төшәргә кирәк.

Басарга тотыналар. Галим баса, Насыйр җыя бара, береаздан бөтен бүлмә кәгазь берлә тула. Насыйр өлгеләрне җыеп алып пичәт басарга тотына. Соң бер егет килеп керә.

Егет *(Габдулла)*. Китердем. Өлгесе — сигез йөз. Яңысы — мең. *(Пальтосын салып, Насыйрга)*. Арттан каешны чиш! *(Насыйр чишә. Әүвәл төймәләрен чишә башлый, күлмәге астыннан әллә никадәр кәгазь төшә.)* Монысы — өлгесе, минем катаны тарт. *(Насыйр катасын тарта башлый. Катаны кага. Эченнән әллә никадәр басылган кәгазь чыга. Икенчесен тарта. Анысын да шулай итә. Бөтен өй кәгазь берлә тула. Шул арада Галим дә басып бетерә.)*

---

*Тияү* — төяү.

Габдулла. Тагы ни бар?

Насыйр. Боларны тагы өчәр мең хәзерләргә кирәк. Аннары менә яңы прокламация, авыл халкына. *(Өстәлен ачып алып бирә.)* Үзеңез ничек торасыз?

Габдулла. Яхшы.

Насыйр. Андый-мондый нәрсә юкмы?

Габдулла. Юк әле. Безгә акча кирәк булыр. Фатирга биш сум бирергә, ашарга кирәк.

Насыйр. Эһе, эһе. Хәзер монда акча күп түгел. Бераздан акча була. Алай да мин сиңа менә сигез сум бирим әле.

Габдулла. Ярый, алай булса, мин китәм.

Насыйр. Хуш. Сакланып йөреңез!

Габдулла югала. Насыйр җыештырырга тотына. Шул арада бер марҗа килеп керә, икесе белән дә күрешә.

Марҗа. Миңа татар литературасы кирәк.

Галим. Хәзер. Күпме?

Маржа. Белмим. Өч кеше авылга китә.

Насыйр. Өчәр йөз. *(Галим алып бирә.)*

Маржа *(барысын да алып, борылып, корсетына тияргә тотына.)* Бүген Верага барырга ярамый. Анарда обыск.

Насыйр. Үзе беләме?

Марҗа. Белә. Аннан ары кичә урамда Максимны тотып алганнар.

Галим. Максимны? Әйбер тапмаганнармы?

Марҗа. Бүген невестасы полициягә барды. Берни дә юк, ди. *(Үзе борылып.)* Хәзер беленмиме?

Насыйр. Беленми.

Марҗа. Тагы бүген сәгать 8 дә Петрга береңез барсын, диделәр. Хушыңыз. Мин киттем. *(Марҗа югала.)*

Галим. Бүген авылга китә торган шәкертләр бар иде. Ник килми торганнардыр?

Насыйр. Килерләр әле.

Галим. Мин шуларны, йөзләп булыр, куйдым. Мин киткәч килсәләр, бирерсең. Кеше саен йөздән артык бирмә. Менә болары мәдрәсәләргә.

Шул арада бер малай килеп керә, кулында бик күп кәгазьләр, хатлар, гәзитәләр.

Малай. Почта килде. Хатыңыз бик күп.

Галим. Повестка бармы?

Малай. 12 тәнкә бар.

Галим. Бер генәме?

Малай. Юк, түгел. Өч тәнкәлек бар, бер сум илле тин, тагы шундыйлар. Тагы аннан — типографиядән килделәр. Баш мәкалә кирәк, ди. Фельетон буламы, ди.

Насыйр. Әһә, алай икән. Хәзер. *(Өстәлдән кәгазьләр актарырга тотына.)* Менә баш мәкалә. Фельетон Шәйхидә иде, ул калдырмадымыни?

Малай. Бар. Алай булса, шуларны илтеп бирик.

Насыйр. Бирегез.

Малай. Анда тагы бер эшче килде. Бүген сәгать 7 дә элгәрегә урынга барсын, диде.

Насыйр. Ярый.

Малай. Аннары анда, бер мулламы шунда, Галим абзыйны сорый. Без «юк» дидек. Ул «бар» ди.

Галим. Ни төсле?

Малай. Сарырак кына, яшь кенә.

Галим. Килсә, әйтегез, мин бер сәгатьтән булам. Көтеп торсын.

Малай. Тагы анда авыл кешеләре бар. Гәзитәләр, китаплар сорыйлар. Әнә теге шәкерт китерде үзләрен.

Галим. Кайсы шәкерт? Озынмы?

Малай. Ак бүрекле.

Галим. Әһә, бирегез! Алай булса, менә боларны да бирегез. *(Алып прокламацияләр бирә. Малай, бүреген алып, бүрек астына тыга.)*

Насыйр. Тагын ни бар?

Малай. Бер урыс килеп, Шәйхи абзыйны сорады. Күзлек кигән, шадра гына. «Юк» дидек.

Насыйр. Шпиондыр, каһәр. «Юк» диегез.

Галим. Теге татар шпион һаман каравыллыймы?

Малай. Бүген ул юк. Бүген әллә нинди ике урыс йөри.

Насыйр. Беттеме?

Малай. Тагы типографиядән килделәр. Китаплар басарга кәгазь кирәк, ди.

Галим. Ярый. Тагы килсәләр, үзем барам дип әйтте, диң. Беттеме?

Малай. Бетте.

Насыйр. Ярый алай булса, бар. *(Малай югала.)*

Галим. Ул китаплар өчен кәгазьгә синдә акча бармы?

Насыйр. Юк, бар акча өч тәнкәме, дүрт тәнкәме калды.

Галим. Кайдан аламыз соң? Акча кирәк бит!

Насыйр. Җыярга тырышырга кирәк. Мин бүген берике кешегә барып карыйм әле. Кәгазьгә күпме кирәк?

Галим. Утыз тәнкәләр кирәк.

Насыйр. Урысларда юк микән? Бүген Петрга син барамсың? Ул вакытта минем «түгәрәк» бар.

Г а л и м. Ярый.

Н а с ы й р. Шунда сөйләп кара. Бәлки аларда акча бардыр. Булмаса, мин ничек тә иртәгә, татар арасыннан теләнергә кирәк. Ләкин бик туйдырды. Татар арасында акча җыю бик авыр.

Шул арада бер ш ә к е р т килеп керә.

Ш ә к е р т. Исәннәрмесез?

Г а л и м. Аллага шөкер.

Ш ә к е р т. Безнең мәдрәсәдә тагы бер «түгәрәк» булды. Мәдрәсәдә җыеламыз, диләр. Баручы булыр микән?

Н а с ы й р. Булыр, булыр! Үзем барам. Нindиләр?

Ш ә к е р т. Барысы аңлы егетләр. Авылда хезмәт итә алырлыклар.

Н а с ы й р. Кайчанга башлыйлар?

Ш ә к е р т. Алар бәйрәмгә кадәр «түгәрәк»не үтәргә телиләр. Шуның өчен тизрәк кирәк иде.

Н а с ы й р. Кайвакыт вакытлары бар?

Ш ә к е р т. Кич белән сигездән соң.

Н а с ы й р. Дүшәнбе көн кил! *(Хатирә дәфтәренә алып яза.)*

Г а л и м. Менә сезнең мәдрәсәгә, ал!

Ш ә к е р т. Мин хәзер «Күл буе»на барам. Аларныкын да алмыйммы?

Галим бирә. Шәкерт кесәләренә тияргә тотына.

Н а с ы й р *(шәкерткә)*. Сәгать ничә?

Ш ә к е р т. Сәгать өч.

Н а с ы й р. Миңа бик вакыт икән. Син нишлисең, Галим?

Г а л и м. Миңа да моннан кузгалырга вакыт. Ашыйсы килә. Ашап, түгәрәккә китәргә кирәк тә, менә шәкертләр килмәде.

Ш ә к е р т. Кемнәргә? «Мөхәммәди»ләргәме?

Г а л и м. Монда барысына да бар.

Ш ә к е р т. Бир, барысын да үзем таратам.

Г а л и м. Менә рәхмәт! *(Насыйрга.)* Алай булгач, мине көт. Хәзер бергә чыгамыз. *(Шәкерткә тияргә тотына. Тияп бетерә. Насыйр киенә. Галим шәкерткә.)* Мине сорасалар, иртәгә үзем барам. Тизрәк авылга йибәрсеннәр. Бер-ике көннән яңысы була дип әйтте, диң.

Ш ә к е р т. Хушыңыз.

Н а с ы й р. Дүшәнбе көн?

Ш ә к е р т. Дүшәнбе көн. *(Чыга.)*

Г а л и м *(ишекне бикләп, паузадан соң, киенә башлап)*. Эш беттеме соң?

Н а с ы й р. Төрмәгә кергәч, бетәр! Әйдә тизрәк, мин соңга калам. Хәзер «түгәрәк»кә, аннары редакциягә, аннары тагы «түгәрәк»... Көн дә шулай үтә, төн дә шулай... Төрмәгә чикле.

Г а л и м. Әйе, безгә хәл җыю төрмәдә генә.

Н а с ы й р. Кабердә дә.

Г а л и м *(киенә-киенә)*.

Әйе, безгә тынычлык тик бер кабердә,
Монда көн дә бурыч хәзерлә...
Патша җуан байларның атасы,
Аңа тагын каныңны әзерлә.

*(Чыгарга дип җыенып торганда, полиция ишек кага. Галим ишеккә барып бераз тыңлап торгач, яшен суккан шикелле, җитез бер хәрәкәт ясап.)* Тегеләр!..

Н а с ы й р.Ә?!

Тәрәзәдән качкан вакытта п о л и ц и я килеп керә. П о л и ц е й с к и й л а р куып тәрәзәдән чыгалар. П р и с т а в белән берничә г о р о д о в о й бүлмәдә калып, кәгазьләрне тикшерә-җыештыра башлыйлар.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бер елдан соң. Җәй көне. Кич, сәгать 11 ләр. Шәйхи бүлмәсе. Кечкенә генә бүлмә. Китаплар, төрдек-төрдек иске гәзитәләр. Бүлмә начар гына мебельле. Ш ә й х и гәзитә укып утыра.

Ш ә й х и. Һәммәсе бетте, һәммәсе! Бер ел эчендә никадәр үзгәрү, бер ел эчендә никадәр артка китү! Кайда карасаң, анда катылык. Гәзитәләр тагы баллар хакында, генералларның чин алулары хакында яза башлады... Тагы 902 нче ел кайтты, әдәбият тагы кысылды, тагы изелде... Җәмгыятьләр тагы юк хөкеменә китерелде. Кайда карасаң анда тентү, кайда карасаң, анда арестлар, кайда карасаң да, анда суд, төрмә, ссылка, каторга, үлем!.. Бөтен Русия эскәнҗәгә кысылды! Безнең җәмгыятьләремездән, безнең эшләремездән ни калды? Гәзитә? Ябылды. Нәшре китап? Ябылды. Җәмгыять?.. Бетте. *(Гәзитәләргә күрсәтеп.)* Шуларга никадәр хезмәт сарыф иттек, никадәр мәшәкать чиктек. Һәр нумиры, һәр юлы, һәр сүзе ул вакытта безгә үзенә бертөрле ләззәт бирә иде. Һәр кәгазьнең шылтыравы безнең күңелнең әллә нинди тулмаган йирләрен шатлык белән тутыра иде. Без шулар өчен көн-төн йокламый яза идек. Үземезнең ачлы-туклы торуыбызны, үземезнең һәр минутта

төрмәнең ишегә төбендәлегемезне оныта идек. Бетте, барысы да бетте. *(Үзе торып йөрергә тотына.)* Ул вакытта бөтен кешенең кулында безнең гәзитә иде. Ул вакытта бөтен фабрикалар, заводлар, авыллар безнең гәзитә, безнең китаплар белән тулган иде. Мәдрәсәләр, мәктәпләр безнең юлда, безнең эздә тәрбия кылына иде. Без бөтен татарның хәрәкәтенә тон бирә идек. Һәр шарлатан безнең гәзитәдән яшеннән курыккан шайтан кебек качына иде. Ул үзенең начар уен, начар эшен безнең гәзитәдән куркып, безнең каләмнән куркып яшерә иде. Хәзер аларның көне! Алар падишаһлык сөрә. Алар бөтен эшкә тон бирә. *(Тагы йөреп.)* Хәзер нишләргә кирәк? Шул җансыз гәзитәләрдә язарга күңел бармый! Итәк асты эшләргә юл юк. Исмасам, төрмәгә дә алмадылар...Төрмәдә булсаң, төрмәдә эшләп булмый дип вөҗдан газапланмас иде.

Галим килеп керә. Ул хәзер аксый.

Галим. Уф, арыдым. Миңа буннан китәргә кирәк. Монда Казанда җыелып ятуда хикмәт юк. Кайда булса да мин китәм. Син ни уйлыйсың, акча табып булырмы? Мин Бакуга китәргә телим. Беләмсең, аннан элгәре чакырып хатлар килә иде. Анда татар эшчеләре бик күп, ни булса да бер-бер эш чыгарып булыр. Монда тын алыр да хәл юк. Монда мин эшсезлектән үләм!

Шәйхи. Белмим. Мин ни дә әйтә алмыйм. Минем баш шундый каткан, һични итәр хәл юк. Судың кайчан соң?

Галим. Шайтан белә! Аны көтеп торсаң, эшләрсең!

Шәйхи. Залог нишли?

Галим. Мин барыбер судтан качарга тиеш. Мин шул өч йөз тәңкә өчен тагы бер-ике ел крепостька кереп ятыйммыни? Юк, анысы булмас. Миннән шунысы да йитәр.

Шәйхи. Соң, акча иясе ни ди?

Галим. Мин аны күрдем. Бер сүз әйтми. Ул яхшы кеше.

Шәйхи. Әйе, китәргә кирәк. Монда ятуда мәгънә юк. Менә мин нишлим, мин? Татар гәзитәләрендә яза алмам. Организация юк. Нишлим? Эшсезлектән үләм.

Галим. Син дә кит! Син дә үзеңә бер урын тап! Бербер шәһәрдә эшләргә тотын! Син бу реакциядән курыкма! Ул озынга барачак түгел. Менә Насыйр да киләм диде әле. Өчәү уйлашыйк та, бер эшкә тотынырга кирәк. Ул да эшне бик тансыклап кайткан. Аның хәзер тәҗрибәсе дә күп. Ул Бутырка күргән.

Шәйхи. Кирәк, кирәк. Мин бу гәзитәләргә карап

һәркөнне көям. Нинди вакытлар бар иде... Гәзитә, китап бастыру, типография... Эшче арасында хезмәт, шәкертләр арасында, авыл халкы арасында... Барысы да бетте!

Г а л и м. Юк, бетмәде, берсе дә бетмәде! Чәчкән орлык чыкмый калмый. Безнең чәчкән орлык та чыгачак. Хәзер көннәр салкын булганга, бәлки, яшьли чыкканнарын кырау төшеп көйдерер дә, бәлки, суыкта катып калырлар, ләкин озакка түгел — тагы яз булыр, тагы ягъмур явар, без чәчкән орлыклар тагы ямь-яшел итеп йирне каплар. Мин ышанам, шуның өчен эшлим.

Ш ә й х и. Мин дә ышанам. Бу проваллар миңа бик каты тәэсир итте. Минем аз гына өметемне йимермәде.

Шул арада Н а с ы й р килеп керә, икесе белән дә күрешә.

Н а с ы й р. Нишлимез? Эзләдем, эзләдем, көчкә бер урыс кисәген таптым. Бөтен эшнең рәте юк, ди. Комитет бөтенләй төрмәдә утырадыр, ди. Бер тиен акча юк, ди. Эшчеләр арасында эшләргә кеше юк, ди. Авыл халкы арасында эшләргә тагын юк, ди. Без нишлимез? Болай торырга ярамый.

Г а л и м. Мин юлга чыгам. Акча табып булса, Бакуга китәм.

Н а с ы й р. Анда нишләрсең? Синең явкаң да юк, ниең дә юк!

Г а л и м. Мин үзем явка! Минем Оренбургта да явкам юк иде, тоттым да эшләдем. Минемчә, син дә бер йиргә кит. Хәзергә Казанда эшләргә мөмкин түгел.

Н а с ы й р. Әйе, минемчә, элгәре иптәшләр белән күрешеп сөйләшергә кирәк иде. *(Шәйхигә.)* Шәйхи, син нишлисең?

Ш ә й х и. Мин дә бер-бер эш эшләргә кирәк. Монда Галим төрмәдә утырды. Син ссылкада яттың, мин бер эш эшли алмадым. Мин туйдым эшсезлектән, миңа да эш кирәк. Арыдым эшсезлектән!

Н а с ы й р *(Галимгә)*. Акча кайдан?

Г а л и м. Анысын белмим инде!

Ш ә й х и. Минем бер китап бар. Шуны сатарга кирәк. Илле тәнкә бирерләр.

Н а с ы й р. Алай булгач, әйдә сат кына!

Г а л и м. Тагы тотынамыз. Тагы эш башлыймыз...

Ш ә й х и. Тагы тотынамыз, тагы гәзитәләр, тагы типография, тагы китаплар, тагы эшчеләр, тагы авыл халкы...

Н а с ы й р. Яңы куәт, яңы көч белән, иске тәҗрибә белән тагы тотынамыз.

Шул арада Ш а к и р ә юл киемендә килеп керә. Барысы да сикерешеп торалар. Барысы да күрешәләр.

Ш а к и р ә *(Насыйрга)*. Син дә монда? Кайчан кайттың?

Н а с ы й р. Күптән түгел.

Ш а к и р ә. Табан ялтыраттың?

Н а с ы й р. Әйе.

Ш а к и р ә. Галим, син нишләп аксыйсың?

Г а л и м. Стражниклар кыйнап аксаттылар.

Ш ә й х и. Закир кайда?

Ш а к и р ә. Менә мин шуның өчен килдем. Ул ерак түгел, бер кызның бүлмәсендә калды. Аңар фатир кирәк. Бүгенгә сездә кунарга мөмкин түгелме?

Н а с ы й р. Хәле ничек?

Ш а к и р ә. Бик начар. Бүгенгә булса, иртәгә үзем дә фатир табармын.

Ш ә й х и. Ярый, ярый.

Ш а к и р ә. Алай булгач, әйдә, берегез минем белән барыгыз. Аны ялгыз гына алып китеп булмый.

Г а л и м. Мин.

Н а с ы й р. Синең аягың бик конспиративный.

Ш ә й х и. Үзем барам. *(Шәйхи белән Шакирә югалалар.)*

Н а с ы й р. Үлә диең, ә? Күз алдында иптәш үлә. Син уйлап кара, Галим! Ята да үлә. Ике ел элгәре тап-таза егет ята да үлә. Ләгънәт суккан тормыш! Кемнәрне син харап итмәдең! Кемнәрнең син башын ашамадың!

Г а л и м. Әйе, бу тартышта чыдый алмады. Ике революцияне берьюлы үтә алмады. Татар революциясенә, төймә, казаки, чалбар тартышуына әллә никадәр вакытын, көчен әрәм итте, чын революциягә чыдамады.

Н а с ы й р. Әйе, бик күп көч сарыф кылды. Бик күп гайрәтен әрәм итте, яшь вакытында шул иске татар дөньясы белән тартышырга, аның наданлыгы, дорфалыгы белән сугышырга мәҗбүр булды.

Г а л и м. Безнең кайсымыз иске татар дөньясы белән сугышмады, кайсымыз шул сугышта үз гомеренең иң матур вакытларын әрәм итмәде! Мин хәзер үземнең артыма әйләнеп карасам — котым оча! Иске татар тормышы үзенең бөтен ямьсез сурәте белән күз алдыма килә. Мин тагы аннан куркырга тотынам!

Н а с ы й р. Әйе, мин дә исем китә. Ләкин мин үземне үзем аңламыйм. Без ул вакытта ни белән тартыштык, ул тартышудан ни файда иттек? Кемне җиңдек? Менә мин шул вакыттагы үземезнең дошманны танымыйм, шул вакыттагы үземезнең ни теләгәнне белмим.

Г а л и м. Әйе, ул вакыттагы безнең дошманны аермачык күрсәтергә, безнең ни теләгәнне аерымачык сөйләргә мин дә булдыра алмыйм; мин дә шуны аңлый алмыйм! Ләкин без тартыштык, без бик күп тартыштык. Шул тартышка әллә никадәр көч әрәм иттек, әллә никадәр вакытымызны шуңарга сарыф кылырга мәҗбүр булдык. Хәзерге кешеләр, бәлки, безнең ул тартышулардан көләрләр дә, бәлки, алар безне гакылсызга да санарлар. Ләкин без шул төймәләр өчен, шул чалбарлар өчен, гәзитә укыр өчен, китап укыр өчен, рус мәктәбенә керер өчен тартыштык. Рус егетләренең иске идарәсе белән тартышуыннан ким тартышмадык. Менә шул тартышта безнең иптәшләремезнең күбесе сугыш сафында егылып калды. Кайсылары, чыдый алмаенча, иске тормышка кол булды. Кайсылары түзә алмаслык җәрәхәт алып калдылар. Хәзер ул сугыш бетте, ул вакытта без теләгән нәрсәләрнең күбесе булды. Ләкин алар безнең күңелдә бик тирән җәрәхәт калдырдылар. Алар безнең алга баруымызны әллә ничә еллап бикләп торырга сәбәп булдылар. Менә хәзер Закир шул сугышның корбаны, шул иске тормышның актык корбаны!

Н а с ы й р. Һәр халыкта, һәр милләттә, милләтнең уянган вакытына тугры килгән кешеләр, милләтнең уянуына тырышкан кешеләр, әллә нинди авырлыклар күтәргәннәр, бик юка гына, кечкенә эшләр өчен әллә никадәр тартышырга мәҗбүр булганнар. Без дә татар халкының уянган көннәренә тугры килгәнгә, безгә дә шул авырлыкларны күрергә тугры килде. Без дә, безнең иптәшләремез дә шул юлда әллә никадәр зәхмәт чиктеләр. Ләкин безнең авырлыклар актыгы булды, безнең корбан актык корбан булды. Без үземезнең шул мәшәкатьләремез, авырлыкларымыз белән киң, хөр, якты дөньяга юл ачтык.

Ишек дөберди. Шул арада акыртын гына, бер яктан Ш ә й х и култыклап, икенчесеннән Ш а к и р ә култыклап, З а к и р н ы китерәләр. Галим белән Насыйр караватка урын салалар. Закир утыра да бик озак йөткерә. Һәммәсе бер сүз дәшми торалар. Шакирә башын тотып тора.

З а к и р *(Насыйрга кулын сузып, акрын гына)*. Син дә кайттыңмы?

Н а с ы й р. Кайттым. Сиңа авыр булса, ят, Закир!

З а к и р *(акыртын гына, авыру тавыш белән)*. Сезне күрәсем килә. *(Галимгә кул бирә. Аягына күрсәтеп.)* Ни булды?

Г а л и м. Стражниклар сындырдылар да аксап калды.

З а к и р. Барыңыз да бар, Сабир гына юк. Ул әллә кайда, Вологда губернасында ач тора! Минем Казанга киләсем бик килде. Сезне күрәсем бик килде. Сезнең һәммәңез белән минем тормышымның иң матур чаклары бәйләнгән. *(Йөткерергә тотына, какыра. Идәнгә таз китерәләр.)* Карчыклар әйткәнчә, әллә туфрак тартып китерде... Әй, Сабир юк! Насыйр, мондарак кил! Мин сезгә туйганча карыйсым килә. Шәйхи, лампаның шарын ал! Утыңны күтәрә төш! *(Барысы да янына киләләр.)* Уф, эссе! Тәрәзәне ачыңыз! Эссе! *(Галим тәрәзәне ача.)*

Н а с ы й р. Әле терелерсең. Сабир да кайтыр.

З а к и р. Юк. Ул юк инде, үләм. Менә, иптәшләр, мин үләм. Мин берни эшли алмадым. Мин каләм белән хезмәт итә алмадым. Мин гыйлем таратырга хезмәт итә алмадым. Мин, белмим, әллә берникадәр эшченең үзен-үзе тануына сәбәп булганмын. Егерме ике ел дөньяда торуга, егерме ике ел кеше икмәген ашап яткан кешегә бу гына бик аз! *(Үзе йөткерә.)* Менә мин шуның өчен кайгырам. Менә шуның өчен вөҗданым газаплана! Миңа мин әрәмтамак булып яшәдем кебек күренә. Мин бервакытта да *(йөткерә)* үзем туйганча хезмәт итә алмадым!

Н а с ы й р. Алар тугрысында уйлама! Синең эшләгән эшләрең бик күп, Закир! Безнең татар тормышында, безнең Русия идарәсендә беркем дә шуннан артык эшли алмый. Без барымыз да күзгә күренмәгән наданлык белән сугыштык. Без барымыз да татар галәменә яктылык кертер өчен тәрәзә ачарга тырыштык. Син үзеңнең сәбатың белән әллә никадәр татар балаларына үрнәк булдың, бервакытта шактый зур татар җәмгыятенең иң тырыш хезмәтчесе булдың. Синең исемең бервакытта да онытылмаячак. Без дусларың, без иптәшләрең сине һәрвакыт яхшылык белән яд итәчәкмез. Син әрәмтамак булмадың, син үрнәк булдың, иптәш!

З а к и р. Уф! Эссе! Ишекне ачыңыз! *(Шәйхи ишекне ача.)* Мин, иптәшләр, бәлки яңлышканмын. Бәлки үзем эшли алырлык эшләрне дә эшләмәгәнмен. Ләкин мин чын күңелдән хезмәт итәсем килде, чын күңелдән үзем ышанган юлда хезмәт итәргә хәзерләндем. *(Шул арада Шакирә еларга тотына. Закир Шакирәнең кулын тотып.)* Елама, Шакирә, елама! Мин үлгәндә генә елама! Йитәр күз яше! Безнең татар хатыны синнән башка да *(йөткерә.)* бик күп күз яше түкте. Йитәр күз яше! Мин үз тормышымның актык сәгатьләрендә татар хатыны-

---

*Сәбат* — ныклык.

ның күз яшен күрәсем килми. *(Шакирә күзен сөртә.)* Бу иптәшләр арасында син авырлык күрмәссең! Уф, эссе! *(Йөткерә.)* Шәйхи! Пәрдәңне ач, җил керсен. *(Шәйхи пәрдәне ача. Таң күренә.)* Таң! Тагы таң ата! Тагы көн туа. Ләкин бу кояш чыкканда мин булмам. *(Йөткерә.)* Бик озак! Мин... мин үләм. Әтиләрне чакырыгыз! *(Йөткерә. Шәйхи бик тиз чыгып китә.)* Иптәшләр, мин үләм, сез каласыз! Сез иртә үк тагы эшләргә тотынырсыз. Тагы шул алган юлыңызда эшкә керешерсез. Мин булмам. *(Туктап торып.)* Минем күз алдыма сезнең эшләрегез күренә. Сезнең төркем-төркем гәзитәләрегез күренә. Сезнең эшчеләр арасында эшләүләрегез, сөйләүләрегез ишетелә. *(Йөткерә.)* Сез эшләрсез, иптәшләр! Мин булмам. *(Бик озак йөткерә.)* Эшләгез, иптәшләр! Минем эшне дә эшләгез! Сезнең алда бик күп эш бар. Сезнең алда бик күп дошман бар. *(Йөткерә.)* Берсеннән дә курыкмагыз. Эшләгез, иптәшләр, эшләгез! Уф, эссе. *(Йөткерә.)* Эчәсем килә. *(Шакирә су бирә. Закир эчә. Көн дә яктыра.)* Уф, эссе, тегендәрәк китегез, эссе! *(Озын йөткерә.)* Шакирә, бир кулыңны. *(Шакирәнең кулын кыса.)* Хуш бул, үләм, иптәшләр! Иптәшләр, әй, Сабир юк! Үләм. *(Барысы да киләләр. Закир акыртын гына.)* Таң ата. Мин үләм. Яңы таң ата. Иске тормыш үлә, иптәшләр! Хуш, Шакирә! Шакирә, хуш! Таң ата! *(Сузыла. Иптәшләр бер сүз дәшми торалар. Үлә.)*

Шакирә. Үлде! *(Үзе еглый.)*

Насыйр *(тотып карый)*. Үлде, үлде. Моңынчага кадәр һәр тартышуымызда бергә булган иптәшемез үлде. Иске тормыштан алган җәрәхәт белән бүген иптәшемез үлде. Ул үлде, ләкин аның эше, аның идеясе үлмәде. Без, аның иптәшләре, аның фикердәшләре, аның юлында хезмәт итәчәкмез, аның идеясен таратачакмыз. Иптәш үлде. Иптәш кара тормышка, мәлгунь иске тормышка корбан булды. Ләкин бу корбан безнең тарафтан актык корбан. Бу корбан безнең гаетебезнең корбаны! Хәзер караңгы төн үтте, таң атты. Яңы тормышның таңы атты!

Шул арада Шәйхи килеп керә.

Шәйхи. Үлде?

Шакирә. Үлде.

Галим. Әйе, иптәш үлде, кыйммәтле иптәш үлде! Хәзер безнең алдымызда бетмәслек-төкәнмәслек эш бар. Хәзер безнең алдымызда эшләп бетерә алмаслык вазыйфа бар. Без моңынча килгән юлымыздан аерылмаенча һаман шул юлда барырга кирәк. Иптәшнең үлүенә карамыйча, сафымыздагы гаскәрнең кимүенә илтифат итмичә,

без һаман тартышырга кирәк. *(Шакирә акрын гына еглый. Галим Закирга күрсәтеп.)* Тыныч ят, иптәш! Без, синең иптәшләрең, синең белән бергә, бер сафта сугышып килгән иптәшләрең, үзләренең күтәргән флагларын төшермиләр; үзләренең дөрест дип ышанган фикерләреннән кайтмыйлар, тартышалар. Алар тартышачаклар.

Шул арада Закирның а н а с ы белән а т а с ы килеп керә.

А н а с ы. Үлде? Балам, бәгърем, үлде! *(Кычкырып еглый. Атасы катып тора.)*

Н а с ы й р. Үлде. Иске тормышка корбан булды!

П ә р д ә т ө ш ә.

# ЗӨЛӘЙХА

*Драма 5 пәрдәдә, 6 манзарәдә*

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘДӘ ИШТИРАКЪ ИТҮЧЕ КЕШЕЛӘР:

Зөләйха.
Гыймади карт.
Мәхбүбә карчык.
Кыз балалар.
Әхмәтҗан.
Сәлимҗан.
Мостафа.
Тимерҗан.
Сибгатулла.
Фәхретдин.
Хәзрәт.
Поп.
Малай.
Татарлар, урыслар һәм казаклар.

Вакыйга алтмышынчы елларда

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур бер өй. Диварга каршы тәрәзәләр. Сул яктагы тәрәзәләр урамга карый. Уң якта зур ишек. Почмакта тәре куяр өчен өчпочмаклы киштәшүрлек. Урам ягында дивар буйлап озын сәке. Ишекнең арт ягында зур мич. Өйне бүлмәгә, түргә бүлгән чаршау җыелып тора. Түр сәкедә бик карт карчык җеп җегерли. Урам тәрәзәсенең янына утырган кара башлы, тукызлы-унлы ике кыз курчак уйный. Бүлмә сәкесенә утырган Зөләйха аягы белән сикертмәгә элгән бишекне тирбәтә. Үзе җөй тегә. Өйдә тын. Пәрдә ачылганда авыр-авыр сулаган мич башындагы бер картның гына «Алла, Алла!» дип көчләнеп сулавы, әбинең орчык җегерләве, бишек сикертмәсенең моңланып чыгырдавы ишетелә.

Кызлар *(курчак уйный-уйный)*. Исәнмесез диеп әйтте, ди. Кунак килде, ди. Аллага шөкер, кодача, утырыңыз, кодача, тукта, аш бирик дип әйтте, ди. *(Тәрәзәдән көзге кояш керә.)*

---

*Манзарә* — күренеш.
*Иштиракъ итү* — катнашу.

Карчык *(орчыгыны кулына алып, кызларга карап)*. Кайтмадылармы?

Кызларның берсе. Юк, әби, юк. *(Курчагын уйнап.)* Хушыңыз, кодача, хушыңыз, шул күстәнәчләрне алып китеңез, гаеп итмәңез, кодача, диеп әйтте, ди.

Карчык *(туктап тора, балаларга карап)*. Әй балалар! Курчактан бүтәнне белмиләр. Боларга, шул, әле ике кашык — бер тиен. *(Зөләйхага таба.)* Озакка калдылар. Бүген теге кара йөз дә килмәсен әле.

Кызлар. Әби! Озын чәч киләмени? *(Бер-берсенә: «Тиз, тиз!» Курчакларны яшерәләр.)*

Зөләйха. Килер шул.

Карчык. Менә, балалар, сезгә курчактан битәр сабакка ябышырга кирәк. Әнә теге кара йөз нинди бозарга маташа, кечкенә вакыттан сеңеп калган күңелдән чыкмый! Сез бернәрсә дә белмисез!

Балалар. Беләбез, беләбез!

Карчык. Җә, алай булса, кич ятканда нәрсә укып ятырга кирәк?

Бер кыз. Элгәре «Әгузе бисмилла» әйтергә кирәк. Аннан соң «Аллаһөммә зид»не укырга кирәк.

Икенче кыз. Юк, юк, әби. «Бисмиллаһи әлләзи» укырга кирәк.

Карчык. Шулай кирәк. «Әгузе бисмилла»дан шайтан кача. Аллаһе Тәгалә дошманнарның күңелен сындыра.

Бер кыз. Әби! Ул поп нигә безгә килә дә Мәрфугаларга килми?

Зәләйха. Безнең язмыш шулай!

Карчык. Гөнаһ шомлыгыбыз өчен, гөнаһ шомлыгыбыз өчен!

Бер кыз. Әби! Ник безне керәшен диләр? Без мөселман түгелмени?..

Зөләйха. Мөселман, мөселман! Алай дигән кешеләр үзләре мөселман түгел. Без чын мөселман!

Карчык. Мөселман, бәбкәм, мөселман. Алар белми сөйлиләр.

Бер кыз. Әнә көтүдә кызлар мине: «Сине урыс авылына алып китәләр, сине чиркәү суына коендыралар»,— диеп үртиләр. Ник Мәрфугага алай димиләр?

Зөләйха. Без яңа мөселман, алар иске мөселман.

Мич башыннан Гыймади *(авыр гына сөйли. Сүз арасында ыңгыраша)*. Юк, юк, без дә иске мөселман. Балаларның башын бутамаңыз. Минем этием, бабам мөселман булган, бабамның бабасы мөселман булган. Без

*Күстәнәч* — күчтәнәч.

Мамайдан бирле мөселман! *(Кызлар аптырап торалар.)*

Карчык. Кара йөзләр безгә килеп алдап тамга алганнар да «урыс булды» дигәннәр. Без чын мөселман.

Зөләйха. Сез андый кызлар белән уйнамаңыз. Алай дигән кызлар белән дуст та булмаңыз!

Кызлар. Бар да шулай ди. Бар да керәшен кызлары, ди.

Карчык. Дисә, гөнаһысы үзләренә булыр. *(Җеп җегерләргә тотына.)*

Кызлар тагы курчак уйнарга башлыйлар.

Гыймади *(ыңгыраша)*. Әле бусы җитмәгән кебек, тирә-күршең тагы җәрәхәтли! *(Тик торалар.)*

Зөләйха. Бик озакка калдылар. Әллә кайтмадымы икән? Кичә суга барганда, урман астына чиркәү салабыз диеп килгәннәр, диеп сөйләделәр. Бу поп бик усал, диләр. Минем күңелем бик курка.

Гыймади *(ыңгырашып кына)*. Күңелең таза булса, бернәрсә дә булмас... Безне йөртмәгән җире калмады. Һәр бәйрәмендә чиркәүгә алып китте. Һәр зур көндә әллә кая монастырена озатты. Монахы әллә нинди тәреләре белән имләп бетерде. Алла язмаган эш булмады. Алар тик мине «Василий» диеп язып йөртсеннәр, мин мөселманлыктан кайтмадым. *(Ул тагы ыңгыраша.)* Мин күргәннәрне эт күрсә — ул да үләр иде. Теге, Әхмәди абзыйлар эше белән моннан Казанга кадәр богаулап алып бардылар. Юл буе кыйный-кыйный киемемезне генә түгел, тәнемезне тишкәләп бетерделәр. Мескен Мирсәяф чыдый алмады, үлде. Поп алдында «Алла» диеп, иман китереп үлде. Теләсә кайда күмсеннәр, кыямәт көнне Аллаһе Тәгалә мөэминнәр гөруһыннан аермасын. Ул казаматтагы кылынышларны әйтмә дә инде! Карчык судка килгәч танымады.

Карчык. Танымадым. Алдындагы дүрт теше бердән төшкән. Бите-йөзе тирән-тирән сызыклар белән тулган. Чәче-сакалының яртысы агарган.

Гыймади *(балаларга)*. Менә, кызым, без нинди мөселман! Без — ут аша, су аша чыккан мөселман. Аллаһе Тәгалә үлгәндә газиз иманымыздан аермасын!

Карчык. }
Зөләйха. } Амин!

Кызлар. Амин!

Зөләйха. Мин әллә шул кичә бик куркып ятканга-мы, бик ямьсез төшләр күреп, куркып беттем.

Карчык. Хәерлегә булсын, садака бирерләр!

---

*Гөруһ* — төркем.

З ө л ә й х а *(тегүеннән туктап)*. Менә төшемдә әллә нинди көн, биниһая караңгы, карабогдай суга торган көннән дә караңгы, күзгә төртсәң күренми... Менә шунда мин зур бер урманның эчендә ялгыз. Урманда төрле урман пәриләре туй итеп йөриләр, имеш... Аюлар акыра, мәчебашлы ябалак бала кебек еглый... Шуларның барысы да мине эзли, мине ашарга, мине тетмә-тетмә тетәргә тели, имеш... Мин зур бер агачның төбендә торам — белгән догаларымны укыйм. Телем бәйләнә дә онытам, догаларымны бутыйм. Менә кояш чыга. Көн булды, бердән тавыш бетте, мин курыкмый башладым. Мин көн булды диярге генә өлгермәдем, бөтен урманны ут алды; урман утта кайнарга тотынды. Тагы теге хайваннарның тавышы, аю бакыруы, бүре кычкыруы белән тулды. Ут, зур дулкын кебек, акырып-бакырып, өстемә таба килә башлады. Бөтен тирә-ягым ут диңгезендә калды. Куркуымнан телем бәйләнде. Укырга, кычкырырга сүзем бетте. Чабарга, качарга аягым кыймылдамады. Менә минем яныма утырган агачны ут суырган кебек, аны йотарга теләгән кебек булды. Аңарга да ут кабынды. Куркуымның иге-чиге бетте; шул куркуга да «Алла!» дип җибәрдем, үзем дә уянып киттем.

К а р ч ы к. Хәерлегә булсын, хәерлегә!

Г ы й м а д и. Алла дигән сүзне онытмагансың. Бик яхшы булыр.

К ы з л а р *(курчакны туктатып, әниләре янына килеп)*. Әни, мин куркам! Әни, мин куркам! *(Әниләренә ышкыналар.)*

Г ы й м а д и. Нинди вакытта да Алла дигән сүзне онытмаска кирәк. Һәр эшне Алла үз юлына куяр.

З ө л ә й х а *(кызларының башларыннан сыйпап)*. Нәрсә куркасыз? Көндез куркалармыни?

К а р ч ы к. «Әгузе бисмилла» әйтсәң, шайтан да алмый, пәри дә алмый; ут та яндырмый, суга да батмыйсың. «Әгузе бисмилла» әйтеңез!

Кызлар эчләреннән «Әгузе бисмилла» әйтәләр.

Г ы й м а д и *(ыңгыраша, ыңгырашкан тавыш белә)*. Явым-салым булыр, ахры. Бөтен сөякләрем сызлый. Алла, Алла!

К а р ч ы к. Әллә мунча ягып сылыйкмы?

Г ы й м а д и. Яшең siксәнгә җиткәч, инде сылап-сыйпап кына булмас. Аллаһе Тәгалә газиз иманны юлдаш итсен!

Урамда ирләр тавышы ишетелә.

К ы з л а р. Әнә киләләр, киләләр!

Зөләйха, торып, ике арадагы чаршауны төшерә. Әби яулыгын рәтләп бәйли. Мич башыннан бабай башын күтәрә. Үзе ыңгыраша. Кызлар, курчакларын җыеп, чаршау артына чыгалар. Ишек ачыла. Ир уртасы Әхмәтҗан, Тимерҗан, Мостафа; алардан яшьрәк Сибгатулла, Фәхретдин, Сәлимҗан керәләр. Кергән берсе: «Әссәламе галәйкем», «әссәламе- галәйкем»,— диеп сәлам бирәләр. Мич башындагы бабай, ыңгырашып: «Вәгаләйкем әссәлам, вәгаләйкем әссәлам!» — ди.

Әхмәтҗан *(бабайга)*. Исәнме, Гыймади дәдә? Сәламәт торамсың? *(Кулын суза.)*

Гыймади *(ыңгырашып кына)*. Аллага шөкер, Әхмәтҗан, Аллага шөкер. Чыкмаган җан тәндә әле. *(Кулын суза.)*

Сәлимҗан. Утырыңыз, утырышыңыз! *(Барысы да утырышалар.)*

Әхмәтҗан. Йә, Гыймади дәдә, дога кылыйк! *(Карт кул күтәрә, аның артыннан башкалары да күтәрәләр.)*

Гыймади *(йөзен сыйпап)*. Аллаһе Тәгалә һәммәбезгә иманымызны юлдаш итсен! Хәзрәте Рәсүлне шәфагатьче итсен! Мөселман каберенә күмелеп, мөселман гөруһыннан кубарылырга насыйп итсен! *(Үзе ыңгыраша.)*

Барысы да. Амин!

Карчык *(чаршау артыннан чыгып)*. Исәнме, саумы, Әхмәтҗан? Йөргән җирләрең исән калдыларммы?

Әхмәтҗан. Биргәненә шөкер, Мәхүб абыстай. Үзең сәламәтме?

Карчык. Илтеп күмгәнгә кадәр торабыз әле. *(Башкаларга.)* Сез исәннәрме, угланнар? Бала-чагалар саумы?

Мостафа.<br>Тимерҗан.<br>Сибгатулла. } Шөкер әле, Мәхүб абыстай, Ходайга шөкер.

Карчык. Исән булсыннар!

Гыймади *(ыңгыраша. Бераздан башын суза төшеп)*. Җә, Әхмәтҗан, сөйлә безгә: нинди шатлыклы хәбәр алып кайттың?

Карчык тыңларга диеп яулыгыннан колагын чыгара. Чаршау кырыеннан Зөләйха күренә.

Әхмәтҗан. Урман астыннан Тубылгы тавына бардым. Анда шулай Шәмси абзый дигән кеше бар икән. Бик һәйбәт тора, тегермән тота икән. Угылы, кызы йиткән, үзе дә унсигез елдан бирле шул эш артыннан йөри икән. Эшне бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Попымыз бик усал, урман астына чиркәү салырга тели, балаларны көчләп урыс монастырена җибәртә, кызларны көчләп урыска бирә, шуны нишлик, санатка прашения бирергә

телибез, дидем. Шулай, бик һәйбәт, чәйне үзе хәзерләде, әйдә, энем, түргә чык, диеп түргә утыртты.

Шунда ул үзенең хәлен аңгартты. Аларның поплары юаш икән. «Аңарга,— ди,— бәйрәмнәрендә ашлык җыеп илтсәң, башкада эше юк,— ди.— Без, алай-болай ачуын китермәс өчен, йомыркасыннан йомыркасыны, ашлыгыннан ашлыгыны — һәммәсене илтеп торамыз, теге безгә килергә юл чыкмасын димез,— ди.— Дошманны, киләнитә калса, балаларга-фәләнгә күзе төшмәсен димез,» — ди. Үзләре шулай яхшы гына торалар икән. Үзләренә аерым мәсҗедләре булмаса да, бер байлары бар, җомгага шуларның өйләренә җыелалар икән. Гаеткә күрше авылга баралар икән. Зур үлеккә күрше авыл мулласын китерәләр икән. «Сез дә шулай итә алмыйсызмы?» — диде. «Юк, абзыкаем, юк. Бик кире бу дин дошманы,» — дидем. Аннан, уйлап торды да: «Менә Идел буенда зур бер авыл бар, бөтен халкы безнең кебек. Шул эш артыннан йөргәндә шул авылның Галәветдин исемле бер кешесене күргән идем. Үзе солдат булган кеше, сөйләгәндә, авызыннан ут чыга, әрхиреендә дә булган, губернаторын да күргән, таш астыннан чыккан кеше, менә син инде, энем, шунда бар!» — диде. Юлны сорашып чыгып киттем. Ул якын якынын да — дүрт йөз чакрым икән. Ак Идел буенда. Шулай беркөнне иртә берлән барып җиттем. Зур авыл, мәсҗедләре булмаса да, очраган-күргән кеше бар да мөселман кыяфәтендә. Бер картка сәлам биреп: «Галәветдин абзый кайда тора?» — дидем. «Син кайдагы, кем?» — диеп сорады. Шуннан юлны күрсәтеп бирде. Капка төбенә туктадым. Бер җегет чыкты. Сәлам биреп, сораштым. «Монда»,— диде. Ул ара да булмады, аппак сакаллы, таза гына бер карт чыкты. «Кереңез»,— диде. Кердек. Аш вакыты икән. Ашка утырдык. Аштан соң: «Ни йомыш, кунак?» — диде. Мин тагы сөйләдем. Карт кызды, күкрәгенә сугып: «Мин ул канальяларны шулай итәрмен, болай итәрмен, килгәч үтергәнчә кыйнаңыз. Сары май булыр. Менә күрәсең безнең авылны. Авылның буеннан-буена хәерче төсле ашлык җыеп йөри. Бала-чаганың сабак укыганнарын ишетсә, чакыртып кыйната иде. Беркөнне сабан туе иде. Беләсең, яшьләр сырасын-балын яратучан була. Бу килгән, су сибә, ашлык җыя. Хатыннардан йомырка ала. Менә бер картыбыз бар иде. Колагы ишетми иде. Намазчан-ниязчан иде. Шул чалма белән урамга чыкмасынмы?.. Попымыз тилерде, сикерде, бакырды, тегене кыйнамакчы булды. Карт,

---

*Прашения* (прошение) — гариза.

аны аңлап, тугры килгән йортка чабып керде. Ул йорт чын мөселман йорты иде, поп килеп кенә кергән иде, кунакка җыелган җегетләр чыктылар да: «Син безне көчләп урыс ясаргамы!» — дип тотындылар... тегене, кай җире кычыта... Аның артыннан казагы кергән иде, ансын да кыйнадылар, кыйнадылар, эштән чыгардылар. Попның кул-аягы сынды, казагының кабыргалары ватылды. Шуннан соң арбаларына төяп озаттылар. Суд китте, суд китте, 62 картыбызны Себер җибәрделәр. Егерме ике кешене казаматка яптырдылар. Мин дә өч ел яттым. Халык судлаша-судлаша бөлеп бетте. Шуннан, син күр дә мин күр, попның эзе югалды»,— диде. Мин: «Без булдыра алмыйбыз, безнең халык берсүзле түгел»,— дигәч, ул: «Мин шуннан башканы белмим»,— диде. Сөйләшә торгач, бая мин юл сораган кеше килеп керде. Ул муллалары икән. Үз араларыннан, ди. Шул менә: *(Һәммәсе тын да алмыйча тыңлап торалар.)* «Бәләбәй шәһәрендә бик оста язучы бар, шуңарга бар, бик оста вәли, сүзе бик үтә, агасы Петербургта, бик зур бер генералда аш, чәй биреп кенә тора, ди; син инде шунда бар»,— диде.

М ә х б ү б ә. Чибәр юл.

Ә х м ә т җ а н. Ни эшлисең, Мәхбүбә абыстай, башлагач, ярты юлда калдырырга ярамый.

К е ш е л ә р. Ие, ие.

Ә х м ә т җ а н. Киттем, доверенностьне күрсәттем. «Мин бу эшне эшләрмен, ди. Сезне көчли алмас, эшләрне миңа бирегез, үзем йөртеп чыгарам, ди. Җан башына биш тәнкә бирерсез, ди. Моны санатка бирергә, санатны күреп сөйләшергә кирәк»,— ди. Сөйли торгач, өч тәнкәгә килеште. Менә хәзер шуңарга «урман аст»лары разый булалар. Сез нишлисез?

Г ы й м а д и. Хәерле эш булсын! Алла ярдәмчегез булсын!

М о с т а ф а. Соң инде үзе шулай булырга охшыймы? Эчеп-сасып беткән түгелме?

Ә х м ә т җ а н. Алай бит бер-ике күргәндә кайдан беләсең? Кайтканда тирә-күрше мөселман авылларына кердем, мактыйлар.

С ә л и м җ а н. Ул бит һаман дин дошманы, алдап кына куймасын, димен.

Ә х м ә т җ а н. Юк, үзе боларның «старовер» дигән нәрсәләре икән.

С и б г а т у л л а. «Урысның атасын үтер дә акча бир»,—

---

*Вәли* — яклаучы, опекун.

диләр. Анысыннан куркырга ярамый. Булдыра алырмы гына?

Карчык. Болай да бит күрәсез, угланнар, дерелдәп кенә торабыз. Үләргә вакытымыз җиткән. Тынычлап үлә дә алмыйбыз бит. Ни булса да бер эш эшләңез инде.

Гыймади. Теге Галәветдиннең әйткәне дөрест. Бу йөзе караның кабыргаларын санасаң, сабак булыр иде. Картаеп киттем, мин аны өйрәтер идем... *(Ыңгыраша.)*

Әхмәтҗан. Кеше табылыр иде дә, Гыймади дәдә, беләсең бит, әле зарар итмик диеп куркабыз.

Сибгатулла. Юк, дәдә, закун белән йөрергә кирәк. Прашения бирергә кирәк: губернаторына бирергә кирәк, падишаһына бирергә кирәк.

Мостафа. Шулай итеп йоклаган дошманны гына уятмыйк, дим. Шулай торган көенчә торыйк, димен.

Мәхбүбә *(балаларны күрсәтеп)*. Бу балаларны нишлик? Шуның сүзе белән чиркәүгә илтикмени? Аларны сасы суга манчыйкмыни? Бүген яшер, иртәгә яшер, беркөнне күрер бит. *(Гыймади дәдә ыңгыраша.)*

Балалар. Әни, куркабыз, әни, куркабыз. *(Чаршау артына качалар.)*

Фәхретдин. Соң падишаһка прашения бирик. Менә безне көчлиләр, динебезне бозалар, балаларыбызны чукындыралар, диик. Карасын түрәләрне, ул динне кысмаска унике падишаһ алдында ант иткән.

Әхмәтҗан. Анларга барып җитәргә юл юк шул. Шуны эзлибез әле. Әнә теге Бәләбәй урысы үзенең браты аркылы генералга сүз кичереп булыр; генерал прашениене алыр да, туры падишаһка китәр дә, манифест алыр, димез.

Тимерҗан. Поп бит, сезгә урыс диненә чыгарга манифест булган, унике генерал, унике әлхирей алдында падишаһ кул куйган, ди.

Мәхбүбә. Карга карганың күзен чукымый, бар да бер кара йөрәк инде. Бар да бер дошман инде, Алла гына ярдәмчебез булсын!

Фәхретдин. Алай булса, хәлифә падишаһка хәбәр бирик. Монда мөселманнарны көчләп чукындыралар, кызларны көчләп урыска бирәләр, шәһри Болгарга чиркәү салалар, диик.

Әхмәтҗан. Аны да ничек бирик? Ничек прашениябезне хәлифә падишаһ кулына җиткерик? Ул да җиңел түгел. Аннары, ярый ла, ул безнең сүзне тотса, аннан да файда килмәсә, болары тагын каныгыр бит.

---

*Әлхирей* — архиерей.

Ф ә х р е т д и н. Казанда хаҗга баручы юк түгелдер. Үзебезнең хәзрәттән бәйнә-бәйнә бәян кылдырып, Әхмәди абзыйларны Себергә җибәрүләрене, Миннисаны урыска сатуларыны, Садри абзыйны төрмәдә утыртуларыны, Куян авылы хәзрәтен үлек күмгән өчен Себергә җибәрүләрене — барсыны да языйк. Аңарга да ышанмасмы? Вәзирләр мәҗлесен корсын да тыйсын моны! Биләргә чиркәү салганда ник бик тиз хәлифә падишаһ кырык мең гаскәр куйгач, песи булдылар?

С ә л и м җ а н. Шулай да итик. Хәлифәсенә дә, падишаһына да прашения бирик. Берсе булмаса, берсе булыр.

Ә х м ә т җ а н. Һәммәсенә бит акча кирәк. Менә бит өч атна йөрдем, минем дә бит, җәмәгать, йортым-җирем, бала-чагам бар. Казанына да бар, Уфасына да бар. Теге Петербургка барса, санатына да бүләксез булмас.

Г ы й м а д и. Булсын! Бөтен йортны сатармын да бирермен. Алла исәнлек бирсә, угланнар, мал табылыр, актык атларыңызны сатыңыз, балаларыңызны сөтсез калдырып, актык сыерларыңызны сатыңыз, юлы булса, шуны булдырыңыз! Менә, угланнар! Әле сез яшь кеше, белмисез. Менә мин көне-төне үлем көтәм. *(Ыңгыраша.)* Әллә кайчан үләргә вакыт йиткәнне беләм. *(Җылаган тавыш белә.)* Урыс каберенә күмелмәс өчен Алладан, Газраилга сабырлык бир, диеп ялбарам. Яшем сиксәнгә йитте, Аллага шөкер, Аллага шөкер, мөселманлыктан аерылмадым, Аллага шөкер, нинди вакытта да — көчләп чиркәүгә алып барганда да, көчләп сасы суга чумырганда да «Алла» сүзен онытмадым. Шуның өчен кыйнадылар, таладылар, бөтен йорт-йирне бөлдерделәр — мин чыдадым. Шуларны әнә үзем өчен генә түгел, угланнар, барыңыз өчен дә кылдым. Инде үлем көненә килдем, кабер якасына бастым. Бер — Алладан, икенче, сездән [сорыйм], мине урыс мазарлыгына күмдермәңез! Миңа үләр алдыннан мөселман каберенә күмелеп, газиз баш көннәрне Коръән тыңлап, рәхәтләнеп ятарлык ясаңыз! Угланнар, сиксән ел яшәдем. Бала-чага үстердем; юл кунагыны борып җибәрмәдем; кеше малына җинаять итмәдем; үлем түшәгендә тынычланырга, Газраил белән юлыкканда мөселманча юылып, мөселманча җеназам укылып, мөселман каберенә күмелергә ышанасым килә шул. Җаным тәнемдә вакыт кертә алмаган чиркәвенә минем җансыз-нисез тәнемне өстерәп илтеп тыгар диеп куркам шул. Алла! Алла! *(Ыңгыраша.)*

Кызлар җылыйлар.

Ә х м ә т җ а н *(сикереп торып, бабайга барып)*. Чү, чү! Ни булды?

Гыймади дәдә мичкә таба ава. Аның авызыннан күбекләр чыга. Балалар тагын кычкырып җылый. Зөләйха чаршау артыннан чыга. Бөтен өй асты өскә килә. Ирләр, торып, Гыймади бабайны күтәреп сәкегә салалар.

М ә х б ү б ә *(янына утырып, кулы белән тотып)*. Ут кебек яна.

Ә х м ә т җ а н. Башына суык сулы тастымал куеңыз! Береңез хәзрәткә барыңыз! Карт кешенең бары бергә. Алла сакласын! *(Сибгатулла чыгып китә.)*

С ә л и м җ а н. Тиз йөр.

Ә х м ә т җ а н. Мостафа, син хәзрәт килгәнчә белгәнеңне укый тору кирәк иде.

М о с т а ф а. Безнең белгән инде, Аллаһе Тәгалә үзе кабул итсен.

К а р ч ы к *(балаларга карап)*. Үз эчеңездән «Колһуалла» укыңыз! Әнә бабаңыз ничек авырайды. *(Үзе авызын селкетә. Мостафага ишарә кылып, утырырга күрсәтә. Ул, утырып, авыз эченнән Коръән укырга тотына.)*

Бөтен өйне курку баса. Авыр тынлык белә өй тула. Пауза. Чалмадан, чапаннан х ә з р ә т, аның артыннан С и б г а т у л л а керә.

Х ә з р ә т. Әссәламе галәйкем!

Х а л ы к. Вәгаләйкем әссәлам!

С ә л и м җ а н. Хәзрәт, бабай авырып китте.

Ә х м ә т җ а н. Исәнмесез, хәзрәт?

Б а ш к а л а р д а. Исәнмесез, хәзрәт?

Х ә з р ә т. Аллага шөкер, исәнме, Мәхбүбә абыстай?

М ә х б ү б ә. Биргәненә шөкер, хәзрәт, биргәненә шөкер. Гөнаһ җыеп торабыз әле, хәзрәтем!

Х ә з р ә т *(бабайның башын тотып)*. Машалла! Машалла! Яна. *(Бисмилла әйтеп йөзенә өферә. Бабай күзләрен ача. Башкалар тик торалар.)*

Б а б а й *(һәммәсенә дә карап)*. Уф Алла!

Х ә з р ә т. Гыймади агай, бала-чаганы куркыткансың!

Г ы й м а д и *(ыңгырашып)*. Вакыт, хәзрәт, вакыт! Ризык бетмәгәнгә әле дә тордым. Күптән вакыт. Уф Алла! *(Ыңгыраша.)* Әллә ни, хәзрәт, суда йөзгән кебек булып киттем. Шуннан ни булганын белмим.

М ә х б ү б ә. Бөтен йөзеңә тир чыкты.

Г ы й м а д и *(ыңгыраша)*. Бөтен тәнем яна, телем кибә, су биреңез! *(Зөләйха суга чыга. Гыймади тагын селкенә башлый. Авыр гына.)* Тунымны салдырыңыз! *(Ирләр тунын салдыралар. Зөләйха су кертә. Мәхбүбә юрган белән өстен яба. Хәзрәт башын тотып тора.)* Менә, хәзрәт, Әхмәт-

җан шатлыклы хәбәр белән кайтсын да тынычлап үлим диеп өмет итеп тора идем. Рәхмәт, бик күп йөргән. Теге, хәзрәт, безгә ул көнне күрергә Алла язмагандыр, ахры, ул шатлыкны күрергә безгә насыйп булмагандыр, ахры. Картайгач, хәзрәт, күңел нечкәрә икән! Актык туемның үз йортымда, дустым-ишем арасында, имам, мөәззиннең хозурында булуыны күрәсем килгән иде, угырланмаенча, качмаенча *(үзе җылый)*, Алла диеп үләсем, Алла диеп җан бирәсем килгән иде. Кеше кебек, хәзрәт, минем җеназам да мәсҗед алдында, олуг-кечек хозурында укылып, бабайлар каберенә күмеләсем килгән иде. *(Туктап торып, җылаган тавыш белән.)* Мин, хәзрәт, Василий түгел, мин, хәзрәт, Гыймаддин! *(Бөтен кешеләр бер-берсенә карашалар.)*

Хәзрәт. Әлхәмдүлиллаһ, әлхәмдүлиллаһ, Гыймаддин ага!

Гыймади. Әлхәмдүлиллаһ, мин мөселман!

Хәзрәт. Бик беләм, Гыймаддин ага, бик беләм. Дин өчен әллә никадәр мәшәкать, зәхмәт чиктең, әллә никадәр мыскыл күрдең. Сиңа, Алла теләсә, Аллаһе Тәгалә дин юлында сугышкан сәхәбәләр савабыны язар. Китап әйткән: дин юлында зәхмәт чиккәннәр газилар белән бергә кубарлар, хәзрәте Хәмзә разый Аллаһе ганһенең ливасы астында булырлар, дигән. *(Һәммәсе баш селкәләр.)*

Гыймади *(ыңгырашканнан соң)*. Ишеттеңезме, угланнар?

Һәммәсе. Ишеттек, Гыймади дәдә, ишеттек!

Гыймади. Ишетсәңез, шул юлдан аерылмаңыз! Нинди көчләсәләр дә, газиз динеңездән, бабаларыңызның диненнән аерылмаңыз. Дөнья дәүләтенә, дөнья ләззәтенә алданмаңыз! Ир гомере — бер көн. Үтә дә китә. Ахирәт — мәңгелек. Ахирәтне югалтмаңыз! *(Зөләйха еглый. Аның артыннан балалар җылый.)*

Хәзрәт. Әлхәмдүлиллаһ, Гыймади агай, һәммәсе ихласында, һәммәсе шәригать юлында. Нинди авырлыкларны да күзгә алмыйча мәсҗедтән калмыйлар, балаларны мәдрәсәдән чыгармыйлар. Мостафа угылы, Сибгатулла энесе, Гыймади агай, иң тырыш шәкертләрем.

Кешеләр. Хәзрәт, үзеңә рәхмәт инде. Олуг башыңны кече итеп, балалар өчен тырышасың, авырлыкларыннан курыкмыйча, безне башкалардан аерып йөртмисең.

Хәзрәт. Миңа, җәмәгать, һәммәңез дә бер. Әхмәтҗан белән Мөхәмммәтҗан арасында, Сибгатулла белән

---

*Газилар* — изге сугышта сугышучылар.
*Разый Аллаһе ганһе* — Алла аңа риза булсын.
*Лива* — байрак.

Төхфәтулла арасында аерма юк. Китап әйткән: «Мән калә ля илаһе илля Аллаһе фәһүә мөслиму»,— дигән. Кайсымызның Аллага якын икәнлегебез Аллаһе Тәгаләнең бер үзенә генә мәгълүм. Миңа урядник, аларга мәҗлескә барсаң, Коръән укысаң, указыңны алырмын, ди. Мин ничек мөселман кешенең үтенечене кайтарыйм?

Гыймади. Рәхмәт, хәзрәт!

Мәхбүбә. Рәхмәт, хәзрәт, рәхмәт!

Гыймади *(ыңгыраша. Юрганын өстеннән ташлап)*. Хәзрәтем! Бик зур йомышым бар!

Хәзрәт. Кулдан килгәнне, Алла теләсә, эшләрбез.

Гыймади. Хәзрәтем! Дөньяда бик күп гөнаһ эшләгәнмен. Аллаһе Тәгалә кичерсен! Актык бер теләгем бар, хәзрәтем! *(Ыңгыраша. Теле тотлыга башлый.)* Менә, хәзрәтем! *(Җылый. Балалар җылый. Ирләр дә кайсылары күзләрен сөртә.)* Өемнән җеназамны алып чыгып, мәсҗед капкасы төбендә җеназамны укып, мөселман каберенә күмсәнә!

Мәхбүбә *(тезләнеп, җылаган тавыш белә)*. Хәзрәткәем! *(Балалар да кычкырып җылый.)*

Хәзрәт *(аптырап калып)*. Ул бит, Гыймади агай, мөселман берлә кяферне Аллаһе Тәгалә үзе аера. Кяфер каберенә мөселман күмелсә, фәрештәләр мөселман каберенә күчерә, дигән.

Гыймади *(җылап)*. Алланың рәхмәте киң, хәзрәтем! Әле, хәзрәтем, бу поп урыс авылына иттереп күмдерә икән, диләр. Ай хәзрәтем! Күңел бик рәнҗи шул. *(Зөләйха кычкырып җылый.)*

Мостафа. Гыймади дәдә! Хәзрәткә дә авыр шул. Ул да бит ил кешесе.

Гыймади. Юк, хәзрәтем! Сиңа авырлык булуны теләмим. Ләкин, хәзрәт, күңел шул баш кичләрдә, атнакичләрдә минем дә җаным шунда булсын иде, минем дә җаным шундагы бала-чаганың Коръәнен тыңлап шатлансын иде, дим... Ай хәзрәтем!

Мәхбүбә. Ай хәзрәтем! *(Хәзрәт күңеленнән әллә ни уйлаган кебек тора.)*

Сибгатулла. Хәзрәтнең дә дусттан дошманы күп, указын алдырырлар.

Хәзрәт. Бик күп мәшәкать чиктең. Мәсҗед карты булып гомер үткәрдең, Гыймади ага, ярый, синең җеназаңны васыятеңчә кылып, мөселман каберенә күмдерермен.

Гыймади. Рәхмәт, хәзрәтем! Рәхмәт, хәзрәтем! Ал-

---

*Мән калә ля илаһе илля Аллаһе фәһүә мөслиму* — «Алладан башка илаһи юк» дигән кеше мөселман була.

laһе Тәгалә сигез оҗмахның ишекләрен ачык кылсын!

Мәхбүбә. Рәхмәт, хәзрәт, рәхмәт, рәхмәт! Без моңлыларны сөендергән өчен Аллаһе Тәгалә сиңа ахирәт шатлыкларын бирсен! *(Хәзрәтнең кулын алып үпмәкче була. Хәзрәт бирми.)*

Һәммәсе *(аякка торып, кул багълап)*. Рәхмәт, хәзрәт!

Гыймади. Бу шатлыкны күрермен диеп уйламаган идем. Мин хәзер, угланнар, атасының куенында йоклый торган бала кебек, көлә-көлә үләм. Мин хәзер, угланнар, барыңызны да хәзрәткә тапшырып, сезнең өчен дә тынычлап җан бирәм. Хәзрәтем! Боларның аталары бул, дәдәләре бул! Боларга тугры юлны күрсәт! Әүвәл Алла, аннан соң син, хәзрәт!

Хәзрәт. Дин юлыны күрсәтү безнең вазыйфабыз, Гыймаддин ага. Әлхәмдүлиллаһ, Аллаһе Тәгалә безгә шундый зур бер вазыйфа муеныбызга салды. Кимчелекләребезне үзе кичерсен! *(Карт тагы тына. Кешеләр тик торалар.)*

Хәзрәт *(Сәлимҗанга)*. Андый-мондый эш булып китсә, бер кешедән дә сорамыйча барыңыз да кабер казыңыз! Башкасы минем эшем.

Кешеләр. Рәхмәт, хәзрәт, рәхмәт!

Мәхбүбә. Хәзрәтем! Угылым Әхмәт бик авырып тора ласак. Әле әнисе, бик җөдәткәч, бишеккә салды. Берәр генә төкереп йибәрмәссеңме икән? Зөләйха, ал әле!

Хәзрәт. Юк, Мәхбүбә абыстай, йокысыннан уятмаңыз! Өстенә генә төкерим! Бу соң әле минем Галинең яшьтәшеме?

Мәхбүбә. Белмим, хәзрәт! Казлар суйганда дүрт яшь тула.

Сәлимҗан бишекне хәзрәткә китерә.

Хәзрәт. Шул шул! *(Бишеккә карап.)* Сиңа шәкерт булырга вакыт җиткән, син авырып ятасың. *(Өшкерә. Халык тик тора. Өшкереп бетергәч, дога кыла да Зөләйха, сандыкны ачып, Мәхбүбә әбигә сөлге бирә. Мәхбүбә әби хәзрәткә бирә.)* Рәхмәт, Мәхбүбә абыстай, рәхмәт! *(Гыймади агай карап тора. Ыңгыраша.)*

Гыймади *(хәзрәт өшкереп бетергәч)*. Хәзрәт, мине дә өшкерсәң!

Хәзрәт. Ярый, Гыймади ага, ярый. *(Хәзрәт өшкерергә тотына.)*

Менә шул арада бер җегет килеп кереп: «Поп килә, поп килә!» — диеп кычкыра. Балалар еглашырга тотыналар. Кешеләр куркып китәләр. Зөләйха, су өстенә каплаган тәре тактасын алып, почмакка куя, ирләр-

нең Сәлимҗаннан башкасы кәләпүшләрен мич башына ыргытып, яланбаш калалар. Мостафа ыштан кесәсеннән крестен ала. Хәзрәт һаман укуында дәвам итә. Поп, алды-артлы өч казак килеп керәләр. Алар артыннан берничә татар киемендә яланбаш кешеләр килеп керәләр.

Поп *(ул исе китеп, аннары ачуланган тавыш белә.)* Бу ни бу?

Ул кызу-кызу Гыймади дәдәнең янына килеп, аны чукындырмакчы була. Ике кулыны җәеп, Мәхбүбә әби, аның янында Зәләйха, попның юлын кисәләр. Кызлар акырырга тотына. Шул арада, хәзрәт өшкереп бетереп, догага кулын күтәрә.

Поп *(аяк тибеп)*. Бу ни бу? Бу ни бу? Мин сезне казаматта черетермен!

Хәзрәт, попның тавышын ишеттермәс өчен, догасын кычкырыбрак укый; хәзрәт белән кешеләрнең бик күбесе кулларын күтәрә, поп борылып карый башлагач, барысы да кулларын төшерәләр.

Поп *(аптырый, кычкыра)*. Мулла, ник монда килдең? Мин сине Себергә җибәртермен!

Хәзрәт. Аллаһе әкбәр! *(Йөзен сыйпый да.)* Гыймади ага! «Ля илаһе илля Аллаһе Мөхәммәд Рәсүлуллаһ!» диген! *(Гыймади әйтә.)*

Поп *(тагы сикерергә тотына. Урыныннан торган муллага каршы килеп)*. Син ник котыртасың? Син ник христиан өенә кереп, Коръән укыйсың?

Мулла. Болар — мөселман!

Поп. Христиан!

Мулла. Мөселман.

Гыймади *(ыңгыраша-ыңгыраша)*. Мөселман! Ля иляһе илля Аллаһе Мөхәммәд Рәсүлуллаһ.

Мәхбүбә.<br>Зөләйха.<br>Башкалардан бер-икесе. } Мөселман!

Поп. Мөселман?! Мин сезне Себердә черетермен, төрмәдә киптерермен. Мин сезне өйрәтермен, башка юл белән өйрәтермен.

Тегеләр. Без мөселман, без курыкмыймыз... Без — мөселман!

Поп *(бакырынып, сикереп)*. Христиан!

Мулла *(авызына кергән кебек)*. Мән калә ля илаһе илля Аллаһе фәһүә мөслиму — бу хәдис! Ахмак, аңладыңмы? *(Попның өстенә килеп.)* Аңладыңмы?

Поп аптырап тора. Һәммәсе аягүрә баскан. Зөләйха белән Мәхбүбә кулларына табагачлар тотканнар.

Карт. Ля иляһе илля Аллаһе... *(Сузып әйтә.)*

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур йорт. Сәхнәнең сул тарафында каралтылар. Уң тарафында капка. Сәхнәгә каршы өйләрнең ишеге күренә. Йортта такталардан тәбәнәк озын утыргычлар ясап ирләр, егетләр утырганнар. Аларга каршы якта бик күп хатыннар, кызлар. Ирләрнең дә, хатыннарның да бик күбесе яшьләр. Барысы да бәйрәмчә киенгәннәр, тирә-юньдә әллә никадәр балалар. Пәрдә ачылганда йиргә җәелгән аш урынын ике уртача хатын җыеп маташа. Скрипкәне көйләү тавышы берлә пәрдә күтәрелә. Бер яшь ир берлә бер яшүсмер зур чиләктән савытларга салып ирләргә бал өләшәләр. Көзге, кояшлы җылы көн. Балалар арасында Зөләйханың ике кызы кулларына бер малайны тотканнар. Пәрдә ачылгач та, бал өләшүче утырган бер егеткә савыт күтәреп барып:

Яле, кода! *(Егет ала.)*

Егет. Ай-ай, Әхмәди, апасы матур чыктымыни?

Әхмәди. Чыкты шул! Әллә син дә өйләнеп җибәрәсеңме? Балдыз бар бит. *(Кызлар көлешәләр. Икенче җегеткә бирә.)*

Беренче егет. Рәхмәт, Әхмәди кода. Менә элгәре музыкантка бир.

Габдери. Без гел монда, син безне кайгыртма.

Икенче егет. Яле, Габдери, уйнап җибәр әле.

Габдери. Чү, ашыкма, өшкерим әле. *(Бал өләшү дәвам итә.)*

Беренче егет *(эчеп бетереп)*. Әмма шәп тә икән! Бөтен тамыр буйларыннан йөгерде.

Габдери *(бетереп)*. Миннесафа абызтай ясадымы, Әхмәди?

Беренче егет. Кем ясаса да ясады. Безнең эш аны тикшерүдә түгел, син эч тә эч.

Халык. Шулай, шулай.

Икенче егет *(кызларга карап)*. Ай, кодачалар да бигрәк тә асыллар икән! Карасана шул кодачаның буена! *(Берсенә күрсәтә. Кызлар арасында хәрәкәт. Көлешәләр.)*

Кодача. Әй мәхәббәтсез!

Икенче егет. Мәхәббәтсез булса, хәзрәттән өшкертермез. *(Мыегын сыпыргалый.)*

Беренче егет. Яле, бик моңаеп киттек, Габдери, әйттер әле.

Габдери. Ашыкма, өлгерерсең әле.

Беренче егет. Ашыгам шул, beләмсең, бу туй бит! Туй! Әнә кодачалар биергә тора!

Бармак шартлаталар. Кызлар көлешәләр. Кешеләр күбәя, хатыннар, кызлар, балалар һаман килә бара, балны эчәләр.

Егет *(йырлый)*.

Ай-һай дигән әй-й тавышка...
Сандугачлар качай... камышкай...

Алай шул, болай шул, чакыргачдин килдек шул,
Матур булгач, сөйдек шул.

Син булмасаң, ул булыр...
Салма башларыңны... сагышка!
Матур шул кодачам, зифа шул кодачам,
Кодачамны куралмасам, төннәр буе саташам...

Бер егет. Йөз яшә! Синең исәнлеккә! *(Эчеп йибәрә.)*

Җырчы егет. Кодача исәнлегенә! *(Кызлар көлешәләр.)*

Габдери уйнап йибәрә. Ул әүвәлге көен уйный, бары да тыңлап торалар. Уйнап бетергәч:

Бер егет *(Габдеригә)*. Өздең, абзыкаем, үзәгемне!.. Әллә ниләр уйлаттың... Вакыты килер әле... *(Кызларга карап.)* Безнең урамда да бәйрәм булыр. Бик борының-ны күтәрмә! *(Йырчы егеткә.)* Йә, абзыкаем, җырлап йибәр! *(Скрипкә уйный, егетләр кушылалар.)*

Сусадым, җаный, сулар кайда —
Дәрья суларында юк файда...
Әллимсең, бәллимсең —
Газиз гомерләреңне жәллимсең?

Беренче егет. Бас, Мәфтуха, син басмасаң, мин басам.

Бар егетләр. Инде безгә... күрешү кайда... *(Кызларга таба кулын бутыйлар.)*

Төшләремдә күрсәм — шул файда...
Әллүки, бәллүки...
Сагынып җырлыйм, җанеки.

Габдери көйне үзгәртә, аның артыннан скрипкә дә үзгәрә.

Ай җаным, җан дустым,
Синең өчен мин үстем.
Җандым, беттем, киптем, көйдем —
Синең өчен, җан дустым.

Бер егет. Шулай! Шулай! Рәхмәт, туган!

Балчы. Яле, эчеп йибәреңез! *(Бар да эчәләр.)*

Икенче егет. Әйдә, Габдери, уйна! *(Габдери уйный.)*

Йырчы егет:

Минем бәгырем түзалмый,
Өметләрен өзалмый,
Сыкрый-сызлый картаядыр,
Үз дигәнне әйталмый.
Алма пешсә — аллана, үтә пешсә — баллана.
Сөйсә сөйсен егет үзе,
Кызлар сөйсә — назлана.

Е г е т л ә р. Шулай! Шулай! *(Кызлар арасында пыш-пыш кына сүзләр ишетелә.)*

Й ы р ч ы е г е т:

Җаным, җаным, җантирәк,
Җаным, сиңа ни кирәк?
Җаным җарып бирер идем —
Сине сөяргә кирәк.
Миңа каршы ник бактың?
Ник элек сүз каттың?
Йөрәгемә ут яктың,
Керәшен дип, утка аттың.

Кызлар арасында зур хәрәкәт. Алар бер-берсенә карашалар. Егетләр арасында да хәрәкәт.

Б е р е н ч е е г е т. Икенче көй, икенче көй! Туй, егетләр, бу, туй! Туй, туй!

И к е н ч е е г е т. Туйда эчмәсәң, кайчан эчәрмез, сал, егет! *(Эчәләр.)*

Габдери озын бер көй уйный. Тагы теге егет йырлый:

Мәдрәсәдә мин булдым — китап Коръән мин күрдем.
Кайный түгел, яна йөрәк — *(кызларга карап)* синең өчен хур булдым.

Б е р е н ч е е г е т. Бию көе, бию көе, егетләр, бию көе! *(Бер егет чыгып, кесәдән яулыгын чыгарып, биергә хәзерләнә. Скрипкә бию көенә көйләнә; икенче егеткә.)* Бу кем?

И к е н ч е е г е т. Шакирҗан. Ул, малай, саташырга йиткән, ике ел инде Закир кызыннан өметен өзә алмый.

Б и ю ч е е г е т. Алар безнең халыктан түгелмени?

Е г е т. Түгел шул. Кыз да бик борынын күтәргән. *(Скрипкә уйный башлый. Егет бии. Кызларның янына килеп төрле миналар ясый; бераздан соң ул бер кызның янына барып.)* Әйдә, кодача! *(Кыз тартына.)*

Е г е т л ә р. Йә, Мәрфуга, йә, Мәрфуга!

М ә р ф у г а. Юк, мин бии белмим.

Е г е т л ә р. Йә, Мәрфуга, бие! *(Берсе, торып, Мәрфуганың кулыннан тартып чыгара. Ул чыкмаска тели. Кызлар төртәләр: «Чык, чык!» — дип әйтәләр; егет берлә кара-каршы биергә тотына.)*

Б е р е н ч е е г е т. Уздыра Мәрфуга! Кызы да бит! Бер кашык суда йотарсың! *(Биеп туктыйлар. Мәрфуга, битләрен сөртеп, кызлар янына барып баса.)*

---

*Миналар* — хәрәкәтләр мәгънәсендә.

Беренче егет *(торып, бер савыт бал алып, Мәрфугага әйтеп бирмәкче була. Мәрфуга алмый)*. Эч, эч! *(Кызлар да: «Эч!». Мәрфуга аз гына эчә.)*

Беренче егет. Уздырды түбән очлардан, шулай, Мәрфуга!

Икенче биюче. Мин кодача берлә бии, яле, кодача! Әйдә инде, кодача!

Кодача. Мин белмим, мин белмим.

Егет. Йә инде, Мәсрүрә, безнең Куян авылын оятка калдырма!

Кодача. Белмим, белмим.

Балалар да сикереп биергә хәзер торалар. Тагы бии башлыйлар. Шул арада Сәлимҗан вә башка — беренче пәрдәдәге кешеләр килеп керәләр. Биючеләр бии. Яңа килгәннәргә бал бирәләр.

Икенче биюче *(кодачаны кулыннан тотып чыгара)*. Белгән кадәре йитәр. *(Бии башлыйлар.)*

Икенче егет. Шулай, шулай, ай кодача, әллә икенчегә алыйммы үзеңне, карасана буйларына! *(Кызлар көләләр. Бию бетә. Алар туктагач та, балалар һаман биеп маташа.)*

Беренче егет *(чыгып)*. Йә, Сәлимҗан абзый, берне әйттереп җибәр әле. Баядан бирле сине көтәмез.

Сәлимҗан. Минем бит, егетләр, вакыт үткән. Аннан, беләмсез, безнең кайгылы көннәр...

Беренче егет. Юк, юк, Сәлимҗан абзый, бу туй бит, бу туй! Гыймади бабай яхшы кеше иде, Алла үлгәч тә урынын җәннәттә кылсын! Туйны онытырга ярамый; йә, Сәлимҗан абзый, йә!..

Өй хуҗасы. Сәлимҗан, Сәлимҗан, дисез. Тамакны азрак майлаңыз әле, майсыз кашык авызны ерта, диләр. *(Бал бирә.)*

Сәлимҗан *(эчеп)*. Мин бит, егетләр, картайган инде, башта да ул түгел.

Икенче егет. Минем башта да... Сәлимҗан абзый... Инде туй бу! *(Бераз исергән.)* Янган йөрәкне салкын бал берлә сүндерәбез монда... Йә, Сәлимҗан абзый, йә...

Сәлимҗан. Алай булса, «Тәфкилеф»не уйна әле. Акрын гына уйна.

Габдери уйный башлый. Сәлимҗан җырлый.

Беренче егет. Ай, абзыкаем, өзде үзәгемне! Габдери! Бию көе! Бию көе! *(Габдери бию көенә күчә.)*

Бер егет *(чыгып, кызлар янына барып, бер кызның кулыннан тотып)*. Әйдә, Зәйнәп, әйдә...

Зәйнәп. Юк, юк, мин бии белмим.

Кызлар. Бар, бар!

Е г е т л ә р. Әйдә, Зәйнәп, әйдә. Йә, Зәйнәп, безне ары яклар алдында кимсетмә, әйдә! Йә, Зәйнәп!

З ә й н ә п. Юк, юк, мин белмим. *(Чыкмый.)*

Г а б д е р и *(бию көе уйнаган көенчә)*. Белмисеңмени?

З ә й н ә п. Юк! *(Егет башын иеп утыра башлый.)*

Б а ш к а е г е т л ә р. Бии, бии!

Егетне төртеп чыгаралар. Кызлар арасыннан бер кыз үзе килеп чыга. Икәү биергә тотыналар. Бик кызу биеп торганда азан әйтә, музыка да, биючеләр дә туктый. Биюче балалар гына әйләнеп маташалар. Азан тавышы ишетелә. Дога кылалар да тагы бию башлана...

Б е р е н ч е б и ю ч е. Яшь килен кайта, яшь килен!

Һ ә м м ә с е б е р г ә. Аяклары төкле булсын!

Яшь килен капкадан яңы чиләк-көянтәле су күтәреп керә, аның артыннан җиткән кызлар, хатыннар. Хатыннар арасында З ө л ә й х а да бар.

Б а л а л а р. Яшь килен су юлыннан кайтты, су юлыннан! Яшь килен!

Б е р е н ч е е г е т. Монда, яшь килен! Монда, яшь килен!

Б а р ы д а. Монда, монда! *(Кызлар, хатыннар куллары берлә бутыйлар. Бер егет яшь килен янына барып әллә нәрсә сөйли; Габдери бию көе уйнарга тотына. Зөләйханы ике яктан ике кыз чорнап ала. Ул угылыны кулына күтәрә. Акрын гына атлап, яшь килен килә. Ул килеп җиткәч, бөтен кешеләр:)* Төкле аяк берлә, яшь килен! Яшь килен!

Б е р е н ч е е г е т. Йә, яшь килен, биеп җибәр!

Я ш ь к и л е н. Бик кызу уйный!

Габдери сирәкләтә. Яшь килен биергә тотына. Бию арасында ерактагы кыңгырау тавышы ишетелә. Халык һаман үзен-үзе оныта бара.

Һ ә м м ә с е б е р г ә. Шулай, шулай, яшь килен! Яшә! Төкле аяк белә кил!

Шул арада кыңгырау бик якынлаша. Ул туктый. Балалар урамга таба карыйлар. Халык һаман аңламый. Капкадан п о п, с т а н о в о й биш-алты с т р а ж н и к, бер-ике у р ы с килеп керәләр. Тегеләрне күргәч, балалар чыр-чыр итеп качалар. Габдери туктый. Хатыннар, кызлар читкә чабыша. Ирләр урыннарыннан торалар. Кайсылары кача, кайсылары урынында басып кала. Килгәннәр вәкарь белән генә сәхнәгә кереп басалар да тик карап торалар. Озын гына пауза.

П о п *(становойга)*. Мин әйттем бит!

С т а н о в о й. Кая староста? Хәзер табып китереңез! *(Берничә кеше йөгерәшәләр.)*

Становой. Бу ни бу?!

Бер кеше. Безнең авылның Сибгатулланың энесе Куян авылыннан Шәйхулла кызыны алды да шуларның туе.

Поп. Туй? Туй? *(Становойга.)* Мин әйттем бит!

Становой. Өстәл чыгарыгыз монда!

Кешеләр, акрын гына, бал савытларыны-фәләннәрене җыялар. Балалар, хатыннар сәхнәнең кырыеннан гына куркынып карап торалар.

Становой *(утырып)*. Хәзер монда Василийны, аның хатыны Марфа Васильевнаны, Митрофанны алып килегез.

Бер кеше. Василий?.. Ул үлде.

Поп. Үлде? Ничек үлде?

Сәлимҗан. Ятты да үлде.

Поп. Ничек үлде? Кем күмде? Ник мине чакырмадыгыз?!

Сәлимҗан. Кем күмсә дә күмде...

Бер кеше. Бүген, Аллага шөкер, җидесен үткәрдек.

Поп *(становойга)*. Әйттем бит мин, болар берлә башкача кирәк дип! Бу туй кем туе? Чакыр монда шуларны! *(Бер кеше дә селкенми тора.)*

Становой. Сезгә әйтәләр! Чакыр монда шуларны!

Сибгатулла *(чыгып басып)*. Бу безнең туй!

Поп. Сезнең туй? Ә... Кайда никях укыттыгыз?..

Сибгатулла. Без әле туй ук итмәдек, бу әле... болай гына... Туйдан сезне калдырмабыз... Бездә татар гадәте буенча гына...

Поп. Татар гадәте буенча... Мин сезгә татар гадәте күрсәтермен! *(Күкрәгенә значок таккан бер кеше, бүрегене алып, становой алдына килеп баса.)* Староста нигә килми?

Становой. Староста?

Староста. Шул, гаспадин пристав!

Становой. Хәзер бер минутта Василий, аның хатынын, ничек аның исеме?

Бер кеше. Мәхбүбә.

Становой. Тфү, черт! *(Кәгазьгә карап.)* Марфа Васильевнаны, Митрофанны, Дмитрийны, Павел Егоровны, мулланы алып кил.

Староста. Василий үлде.

Становой. Кем күмде?

С т а р о с т а. Мин белмим, мин ул көнне шәһәрдә идем. Менә кияве, шуннан сораңыз.

С ә л и м җ а н. Мин күмдем!

П о п. Син ничек күмдең?

С ә л и м җ а н. Кабер казыдым да күмдем! Васыяте буенча күмдем.

Староста чыга, бер кеше — доносчы башыннан бүреген алып килеп баса.

С т а н о в о й. Сиңа ни кирәк?

Д о н о с ч ы. Василийне мулла күмде. Боларның туен да мулла итте. Сибгатуллаларның угылларын да мулла укыта. Василийнең зиярәтен дә беләм. Теләсәңез, күрсәтермен!

П о п. Мулла монда килдеме?

Д о н о с ч ы. Килде, чалма берлә килде. Никях укыды. Коръән укыды. Бүген Василийның җидесендә дә Коръән укыды. Барсына да бара. Мәдрәсәдә балаларны укыта. Мәсҗедтә намаз укыта, иман өйрәтә.

П о п *(становойга)*. Яз, яз!

С т а н о в о й *(яза, доносчыга)*. Синең исемең ничек?

Д о н о с ч ы. Әхмәт Мөхәммәтшин.

П о п. Син болардан түгел?

Д о н о с ч ы. Юк, түгел, түгел, мин чын мөселман, чын!

С т а н о в о й. Беттеме?

Д о н о с ч ы. Тагы менә, ваша благарудия, бояр кырыннан көлтә урладылар дип, минем өсттән урәтник язу куйган иде, шуны бетереп булмасмы? Пажалысты, барин, пажалысты, бәтүшкә!

С т а н о в о й. Кит, кит. *(Теге акрын гына чыга.)*

П о п. Балаларны мулла укыта. Боларны барсын да җыеп алмый булмас.

С т а р о с т а килеп керә.

С т а р о с т а. Мин хәзер десятникларны җибәрдем. Мәхбүбә абыстай авыру. Мин бара алмыйм, ди.

С ә л и м җ а н. Ие, ул авыру, йөри алмый.

П о п. Мулланы китермәдеңезме?

С ә л и м җ а н. Кирәк булса, китерерсез.

С т а н о в о й *(Сәлимҗанга)*. Син кем?!

П о п. Бу — Митрофан.

С т а н о в о й. Ә алаймы? Кил монда! *(Урядниклар яны-*

*на киләләр.)* Василий авырганда батюшканы благословить итүдән син тыйдыңмы?!

Сәлимҗан. Мин түгел, үзе тыйды. Мин, диде, мөселман, мөселман булып үләм, диде.

Поп. Әһә! Ул крестить ителгәнме? Син ителгәнме?

Сәлимҗан. Юк! Ул да, мин дә мөселман!

Становой *(попка карап)*. Моның белән сөйләп торырга да тиеш түгел, анда полициядә сорарлар! *(Стражникларга.)* Ал шуны! *(Ике стражник Сәлимҗанны тотып алалар.)*

Сәлимҗан. Мине ни дип тотасыз? Мин закунга каршы килгәнмени?

Становой. Менә күрсәтермен мин сиңа закунны!

Урядниклар. Тик тор! *(Камчылары belә бутыйлар. Әллә никадәр кеше килеп керә.)*

Староста. Менә килделәр.

Становой. Марфа кайда?

Староста. Зөләйха, Зөләйха!

Зөләйха *(кереп)*. Ни бар?

Становой. Син кем?

Зөләйха. Минме? Минем сиңа бик кирәгем бармыни?

Становой. Сораганга җавап бир!

Зөләйха. Зөләйха.

Становой. Зөләйха, син татармы?

Зөләйха. Әлхәмдүлиллаһ, дин исламда!

Поп. Моны монастырьга җибәрергә кирәк, мин архирей белән сөйләштем. Алыңыз. *(Зөләйханы тотып алмакчы булалар. Зөләйха кача башлый. Стражниклар тотып китерәләр.)*

Становой. Максим, Федор, Захар — бары да мондамы?

Бернича кеше *(башларын салып)*. Бары да монда.

Становой. Менә сезне барыңызны да исправник чакырган, сөйләшәсе бар, ди. Аңладыңызмы?!

Сибгатулла. Ни өчен соң, господин пристав? Без, Аллага шөкер, налогын түлибез, ил хезмәтен итәбез, күрше-күләнгә зарар китермибез, менә старостадан сораңыз.

Становой. Анда баргач белерсез. *(Стражникларга.)* Алыңыз! *(Тегеләр тота башлыйлар.)*

Бер кеше *(чыгып)*. Господин пристав! Бу бит за-

кунсыз җир түгел. Син боларны ник аласың? Алуыңнан купия бир.

Становой. Тик тор, синең эшең юк!

Теге кеше. Юк! Минем эшем! *(Кесәсеннән бер медаль чыгарып кия.)* Мин падишаһка тугрылык белән 25 ел хезмәт иттем! *(Аяк тибеп кычкыра.)* Син не смей мине мыскыл итәргә! *(Өстенә килә.)*

Становой. Кит моннан! *(Стражникларга.)* Алыңыз шуны!

Аның артыннан тагы берничә кеше керә.

Берничә татар *(килеп)*. Тукта, сабыр ит!

Теге кеше. Сабыр ит — бу закунсыз йирмени? *(Моны үз кешеләре алып чыгып китәләр. Поп бер кәгазь чыгарып становойга бирә.)*

Становой *(старостага)*. Мулла кая?

Староста. Мулла намазда. Минем хәзер падишаһка дога кыла торган вакытым, башка вакытта килермен, дигән.

Становой. Хәзер алып кил! Бер минут тотма. Максим, бар староста белән мулланы алырга! *(Китәләр. Становой кәгазьгә карап.)* Захар!

Бер мөселманча киенгән кеше. Мин.

Становой. Синең ике угылың бар икән, берсе Петр, берсе Федор. Шуларны быел батюшкага укырга итәргә хәзерлә.

Теге кеше. Минем байлыгым юк, йорт-йир карарга кирәк.

Поп. Муллага укытырга бар. *(Халык тавышларга тотына. Бер кешегә.)* Петр, синең Мария исемле бер кызың илә Василий исемле бер угылың бар икән. Шуларны батюшкага укытырга китер.

Теге кеше. Минем андый укырга барырга балаларым юк. Алар үзем күк мужик булырлар, аларга уку кирәкми.

Становой. Күп сөйләмә, хәзер китер! *(Балалар арасында тавыш чыга. Капкадан әллә ничә кеше килеп керә. Шулар арасында табагачка таянган Мәхбүбә әби дә бар.)* Максимов! *(Бер кеше дә дәшми.)* Максимов! *(Читтәге кешеләр әллә нәрсә сөйлиләр.)*

---

*Иту* — илтү.

Ә х м ә т җ а н *(становой алдына басып)*. Господин пристав, господин пристав!

С т а н о в о й. Ни бар?

Ә х м ә т җ а н. Болар барысы да батюшканың кляузы гына, аның сүзенә ышанып йөрмәңез. Безнең падишаһка биргән прашениямез бар.

С т а н о в о й. Мин аны белмим. Мин ни кушсалар, шуны эшлим. Менә монда унсигез бала бар икән, аннары ике җиткән кыз — ул балаларны школага озатыңыз. Озатмасаңыз, мин барыңызны да арестовать итәм. Ике кызны монастырьга җибәреңез. Берсе Марфа, берсе Федосья.

Ә х м ә т җ а н. Мәйлең, без аны эшли алмыймыз!

С ә л и м җ а н *(стражниклар кулыннан котылып)*. Ул кыз түгел, хатын! Минем хатыным!

З ө л ә й х а. Мин кыз түгел, хатын, минем балаларым да бар. *(Становойның янына килеп басалар.)*

П о п. Кыз, кыз! Минем метрикада никяхы язылмаган.

С ә л и м җ а н. Господин пристав, ул минем хатын. Ун елдан бирле минем хатын.

П о п. Юк, юк! Ул кыз, менә мин бик матур жених таптым. Элгәре монастырьда тәүбә кылсын, аннары кияүгә бирербез.

С ә л и м җ а н *(Зөләйханы кулыннан тотып)*. Мин бирмим! Мин бирмим! Үтерәсең булса, үтер. *(Становойга.)* Закуның булса, үтер!

Капкадан яшь кенә к е ш е чабып килеп керә дә становойның алдына басып:

К е ш е. Ни эшләгән Федосья?

С т а н о в о й. Син кем?

К е ш е. Мин мөселман!

С т а н о в о й. Синнән русча сорыйлар. Син кем? Ни кычкырасың? Әй, стражник! *(Стражниклар килеп тота башлыйлар.)*

Т е г е к е ш е *(карышып)*. Мин Федосьяның ире. Син минем хатынымны алмакчы буласың, хәләл хатынымны алмакчы буласың! *(Стражникларның кулларыннан ычкынып, өстәлгә куллары берлә сугып.)* Мин авызыңны җимереп бетерермен! *(Тавыш күтәрелә.)*

М ә х б ү б ә ә б и *(килеп басып)*. Йә, мине ник чакырдың? *(Табагачка таянган. Становой аны күреп куркып китә.)* Йә, мине ник чакырдың?

---

*Кляуза* — әләк, яла.

Становой. Син кем? *(Аны күп кеше чорнап алалар. Халык улый.)*

Мәхбүбә әби. Белмәгәч, ник чакырасың? *(Попка табагачны бутап.)* Әй йөзе кара, әй кара йөз!

Әхмәтҗан. Акрын, Мәхбүбә абыстай, акрын!

Становой *(стражникларга)*. Алыңыз шуны, алыңыз! *(Берсе килеп тота башлый, бер егет юлыны бәйли.)*

Егет. Бәйләнеп кара, кабыргаларыңны санарсың!

Читтән бер тавыш. Нәрсә көтәбез инде? Үлем бер, җәмәгать, безне көчләп чукындырмакчы булалар ич! Әй, егетләр!

Бер кеше. Юк, юк, туктаңыз!..

Мәхбүбә әби *(попка)*. Йә, йөзең кара, ник чакырдың?! *(Зөләйханы стражниклар арасында күреп.)* Сиңа ни булды тагы?

Зөләйха. Менә тоттылар. Монастырьга итәбез, диләр. *(Еглый.)*

Мәхбүбә әби *(попка карап)*. Синме шулай иттең, кара йөз?! *(Попка табагач белән суга. Стражниклар аны тотып алалар.)*

Становой. Бир кирәген! *(Стражниклар кыйнарга тотыналар.)*

Балалар арасында еглаган тавыш ишетелә. Бөтен кеше җыелып попны, становойны кыйнарга ябышалар. Тавыш, кычкырыш зурая бара. Бер-ике мәртәбә мылтык тавышы ишетелә.

Пәрдә төшә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бер рус өе. Дивар буйларында озын, тар утыргычлар. Ишек буенда зур гына сәке. Почмакта төрле зурлыктагы кәгазьләр берлән зиннәтләнгән тәреләр; тәреләр алдында шәм яна. Пәрдә ачылганда сәхнә буш. Тыштан чиркәү кагуы гына ишетелә. Зөләйха килеп керә. Ул иләгән тун кигән. Башына кара яулык бәйләгән. Өйгә кергәч тә, бишектәге баланы карый. Өйгә караңгы төшеп килә; өй шәм яктысы белән аз гына яктырган. Ул өстен-башын чишенә дә лампа кабыза. Тәре алдындагы утны өреп сүндерә. Эскәмиягә утыра да, муенындагы крестны чыгарып, почмакка күтәреп бәрә.

Зөләйха. Ләгънәт төшсен! *(Туктап уйланып тора; торып «Әгузе бисмилла» әйтеп.)* Йа Рабби! Кичер гөнаһларымны! Йа Рабби, кичер! Үзеңә мәгълүм, көчләнгәннән генә кылам. *(Өй уртасында кулын догага күтәргән*

*көенчә.)* Ярлыка, Раббем! Ярлыка! Мин гөнаһлыны ярлыка! *(Кычкырып җылый.)* Ике елдан бирле... *(Яшенә карлыгып.)* шул кяфер белән зина кылып торганымны ярлыка! Ике елдан бирле синең гыйбадәтең урынына чиркәүгә йөрүемне ярлыка! Ике елдан бирле хәрам икмәк ашавымны ярлыка! *(Кычкырып.)* Ярлыка! Бер Ходаем, ярлыка! *(Тагын үкереп-үкереп җылый.)* Минем хәсрәтемнән анам үлде. Мәрьям анамның күз яше хөрмәтенә ярлыка! Кичер гөнаһларымны! Каф тавыннан зур, дәрья суыннан күп булган гөнаһларымны кичер! Газиз балаларымнан аердылар, иремне, тол иремне казаматка тыктылар. Яшь урынына кан түктерделәр. Раббем! Үзең шаһит, Раббем! Үзең шуларның җәзасын бир! Кырларына боз яудыр! Терлекләренә үләт йибәр! Балаларына җәбер сал! Сал, Раббем, сал! *(Акырып җылый-җылый тәрәзәләрне пәрдәләр белән каплый; сандыгыннан бөти алып үбеп кия; намазлык алып җәя, шуның өстенә утыра да кулыны күтәреп дога кыла башлый. Әлгәре акрын гына, тора-бара куәтләнгәннән- куәтләнеп җылый.)* Адашканнарга юл күрсәтүче, сусаганнарга су бирүче, ачларга икмәк бирүче, кил! Кил! Кяфер кулында тоткарлыкта, кяфер түшәгендә зинада торучы Зөләйханы коткар! Коткар! Юлыны югалткан кемсәгә юл күрсәтүче, ач бүрегә җим бирүче Ильяс! Кара урыс, кара кяфер арасында адашкан Зөләйхага юл күрсәт! Күрсәт! Күрсәт! *(Кычкырып җылый.)* Хатыннарны карый торган, ятимнәргә ана була торган, үксезләргә ата була торган, мөселман гаскәренә суда күпер була торган, корыда кала була торган гаиб ирәннәр шул баласыз калган анага, ирсез калган толга, дин дошманына кол булган хатынга ярдәм ит, ярдәм ит, ярдәм ит! *(Кычкыра.)* Бөтен әүлияләр, бөтен пәйгамбәрләр, дин юлында шәһид булган бөтен мөселманнар, еглый-еглый күзләре беткән, агарга яше кипкән шул хатынга шәфагатьче бул, бул! *(Тагы җылый, үкереп-үкереп бик озак җылый; бераз сабыр иткән көенчә.)* Мин монда, урыс өендә, кара урысның түшәген бүлештем. Балаларым, белмим, кайдалардыр, атасыз-анасыз сөренәләр. Кем белсен... бәлки, капчыклар асканнардыр да хәер сораша торганнардыр... Бәлки, әллә кемгә хезмәтче булганнардыр да кичен җеп җегерли, көндез бала карый торганнардыр... Сукыр анам, угылсыз, кызсыз калган анам, бәлки, урамнан урамга, йорттан йортка

теләнеп йөри торгандыр... Ирем, хәләл ирем, әллә кайларда... кош очып җитмәс җирләрдә богаулы аягы белән чалдыр-чолдыр таш кисә торгандыр... Мин монда! Мин монда урыс тоткарлыгында! *(Уйланып торып.)* Алла һәр эшне күрә, һәр яхшылыкны, һәр начарлыкны белә; һәркемнең күңелен сизә, ул һичкемне онытмый, һичбер нәрсәне хәтереннән чыгармый. Гөнаһ шомлыгыбыз беткәч, безгә дә рәхмәтен ирештерер, ирем белән кавыштырыр, балам-чагамның янында картайтыр, карт анама үлем түшәгендә авызына су салырга насыйп итәр. Язмышны күрми хәлең юк. Болытлы көннең бер аязы да булыр әле. Без дә кеше кебек үзебез теләгәнчә укып, теләгәнчә үсеп, теләгәнчә үлеп гомер итәрбез әле.

Тыштан дөбердәгән тавыш ишетелә. Зөләйха, бик тиз торып, намазлыгыны яшерә. Ишектән Петр кереп килә. Ул исерек.

Петр *(селкенә-селкенә)*. Мин килдем, мин! Беләсең, мин кем? *(Селкенә-селкенә почмакка таба бара. Кулыны төртенергә күтәреп, утның юклыгын күреп.)* Кайда, кайда, дим? *(Егылыр-егылмас утыра. Өстәлгә сугып.)* Мин азау тешләреңне суырырмын. Мин, беләмсең, кем? *(Өстәлгә сугып.)* Мин синең сасы татарың түгел. Әй, Марфа? Марфа, дим! *(Зөләйха дәшми. Петр, торып, Зөләйханың янына килеп, кул күтәреп.)* Ник дәшмисең? Ник дәшмисең? Сугармын да көл итәрмен!

Зөләйха. Сук! Сук!

Петр. Ә-ә, алаймы? Алаймы, йомшадыңмы?.. *(Көлеп, кулыннан тотып, кочакламакчы була. Зөләйха төртеп җибәрә. Петр аз гына җыгылмый. Петр кулын күтәреп килеп.)* Татарыңны сагындыңмы? Сасы, черек! *(аяк тибеп кычкыра.)* Як шәмне! Як димен! Әй, Марфа, Марфа, аракы китер!

Зөләйха. Үзең бар, йөз өсте белән кит!

Петр *(тагы янына барып)*. Ә-ә? *(Сугып җибәрә, Зөләйха егылып китә; Петр барып тагы кыйнарга тотына.)* Дуңгыз! Хәерче!

Зөләйха *(кычкырып)*. Алла!

Петр. Ә, Алламы, Алламы? Менә синең Аллаң, менә Аллаң!

Зөләйха. Үтерә, үтерә! Караул!

Тыштан тавыш ишетелә, ишектән бер карт урыс, ике марҗа, алар артыннан бер [яшь] урыс килеп керәләр.

Карт урыс. Дурак! Кеше үтерәсең! *(Хатыннар барып ябышалар, Петр һаман кыйнавында дәвам итә. Зөләйха кычкыра. Карт урыс, аерып алып, Петрны читкә илтеп утырта. Башы-күзе канлы көенчә, Зөләйха икенче якка барып утырып җыларга тотына.)* Дурак! Кеше үтерәсең! Себергә китәсең киләмени?

Петр. Ул кешемени?! Ул — эт! Ул — татар эте! Мин аның измәсен измәсәм... *(Торып, тагы бармакчы була; марҗалар кычкырына башлыйлар; карт урыс тотып утырта. Петр Зөләйхага.)* Аллаң ярдәм иттеме? Ә? Мин күрсәтермен Аллаңны! *(Марҗалар Зөләйха янында башларын селкеп торалар.)*

Карт урыс *(Петрга)*. Оялырга кирәк! Праздник булды исә урамны тутырып сугыш чыгарасың. Мин членга әйтермен! Хатынын үтерә диярмен.

Петр. Ул минем хатыным түгел. Ул — татарныкы. Ул ник шәм яндырмаган? *(Марҗалар карашалар.)* Ул ник миңа аракы китермәде?

Яшь урыс. Яндырсын! Ул ничек алай шәм яндырмый ала? Бу татар авылы диеп беләмени? Ныграк, Петр, ныграк! *(Петр тагы йөгереп барып сукмакчы була. Зөләйха тагы кычкыра, карт урыс Петрны җибәрми.)*

Марҗалар. Үзебез күрдек, бүген чиркәүгә барды. Син эчеп йөрисең.

Петр. Барса, ул анда чукынамыни?! Ул эченнән гел усаллыгында, ул Алласын күңеленнән чыгармый. Төнлә торып намаз укый.

Яшь урыс. Син йомшак, Петр. Мин аңарга ничек динне мыскыл итәргә өйрәтер идем.

Зөләйха. Мин мыскыл итмим.

Марҗалар. Алай булгач, ник татарча гыйбадәт кыласың? Ник?

Карт урыс. Ул татарга күрә татарча гыйбадәт кыла. Син аны урыс диеп белдеңмени? Поп талап алып кияүгә бирү белән генә дин бетә диеп белдеңмени?

Петр. Күрсәтермен мин динне! Татар эте! Гомеремне әрәм итте. Минем яныма ятмый. Мин өйрәтермен! Захар, әйдә берәрне кагыйк әле. Дөньяның асты өскә килсен! *(Тора башлый.)*

Карт урыс. Нәрсә кагасың? Ату җитмәс диеп белдеңмени? Әллә бөтен йорт-җирне эчеп бетерергә телисеңме?

П е т р. Мин кайгыдан эчәм. Хатының хатын булмагач — эчәрсең. Ул мине кешегә дә санамый. Бөтен көнетөне теге татар ире тугрысында уйлый. Татар эте! *(Тагы торып сукмакчы була. Карт җибәрми. Петр җыларга тотына.)* Поп мине әрәм итте, ул: «Петр, син Марфаны ал, мин сине ташламам. Архиерейдән сорап мин сиңа наград алдырырмын, балаларыңны укытырмын, поп булырлар, ашап кына ятырсың»,— ди. Ятты!.. Көне көн түгел, төне төн түгел. *(Кулыны сугып.)* Мин сине өйрәтермен! *(Карт урыс Петрны илтеп яткыра. Өй тын кала.)*

Я ш ь у р ы с *(Зөләйхага күрсәтеп)*. Аны монастырьга җибәрергә кирәк. Рус авылында татарча гыйбадәт кылдырып торырга... Ансыз да бу елда ягъмуры булмый, вакытында җиле булмый. Барсы да асты өсткә килде.

К а р т у р ы с. Минемчә, иренә кайтарып җибәрергә кирәк. Кешене көчләп дингә кертеп булмый.

М а р җ а. Ничек, ничек, ул бит чукынган?

К а р т у р ы с. Чукынса, аны көчләп чукындырганнар. Ул һич тә татарлыгын онытмас. Мин аны аңлыйм. Мин Польшада бунт вакытында полякларның көчләп католик ясаган бер кызны күрдем. Еглаганына полковый командир чыдый алмады.

М а р җ а. Мескен!

К а р т у р ы с. Монда Марфа да шулай. Ул да еглый. Һәркем үз динендә торырга кирәк. Көчләп урыс итеп булмый, көчләп татар итеп булмый. Болар бары да юк эш. Безнең поп кына чыгарды. Алхирей алдында күзгә кермәкче була. Благочинный булмакчы була. *(Петр мышнарга тотына, марҗалар бер-берсенә карашалар. Карт, торып, Зөләйхага.)* Син, Марфа, тагын кыйнаса, миңа кер, мин членга әйтермен.

Бары да чыгалар.
З ө л ә й х а, акрын гына, аяк очы белә генә басып, кулын-башын юа. Акрын гына өстәлгә ашъяулык җәеп, аш урыны хәзерли. Аш ашый. Өйдә П е т р н ы ң мышлау тавышы, тышта җилнең ыжгыру тавышы ишетелә.

З ө л ә й х а *(тәрәзәне ачып карап)*. Нинди буран! Аллам! Юлдагыларга ярдәм бир! Мескен Сәлимҗан бу суыкта нишли икән? Яисә якмаган казаматта катып ята торгандыр, яисә Себер юлларында шакыр-шокыр туңып, авыр богауны өстерәп, арестант чикмәне белән йөри торгандыр. Әхмәтҗан абзый, Тимерҗан абзый, Мостафалар,

---

*Алхирей* - архиерей.

белмим, нишләгәннәрдер... Бәлки, кем белсен, хәзрәт мескен, карт хәзрәт, каядыр... Аны да казаматта черетә торганнардыр. Бер Ходаем ярдәмче булсын! Ике ел булды. Ике ел уен түгел. Беркемнән хәбәр алганым юк, беркемнән! Былтыр бер кырык тартмачыдан гына әни сукырайганны ишеткән идем. Ул да имеш иде. Әллә нинди түрәләрнең килеп соравыннан гына, Петрның исерек вакытта мыгырдавыннан гына Сәлимҗанның казаматта икәнен белдем...

Тәрәзә шакыйлар. Зөләйха сискәнеп китә. Ул тәрәзә янына бара да тик тора. Тагы тәрәзә шакыйлар.

Зөләйха *(пәрдәне ачып, акрын гына)*. Кем бар?

Тыштан. Юлчы! Бик туңдым. Йылынып кына чыгарга кертсәнә.

Зөләйха. Син кем?

Тыштан. Алла кунагы. Сиңа зарарга килмәдем. Бик туңдым. Ишек ач, тизрәк ач!

Зөләйха *(аптырап)*. Бу тавыш таныш кебек күренә. Әллә авылдан берәр кеше... *(Петрга карап торып.)* Йокла әле, йокла! Дүн! *(Тәрәзәгә.)* Хәзер, ачам! *(Ишеккә барып, акыртын гына ачып чыгып китә.)*

Ерактан гына сәгатькә чиркәү сукканы ишетелә. Бераздан соң Зөләйха, аның артыннан толып кигән, карга буялган бер татар — Габдулла керә.

Габдулла. *(Өйнең уртасына килеп басып, өйне карап бетереп, Петрны күрсәтеп)*. Бу иреңме?

Зөләйха. Әйе. Әйдә, чишен, туңгансың!

Габдулла. Туңарсың! Икенде алдыннан чыккан идем. Исәбем белән иртәгә иртә намазын ишан хәзрәткә оеп укырга иде. Алла язгач, менә кайда кунарга тугры килде. Юлдан яздым, киләм, киләм — очы юк. Өмет беткән иде. Әллә кайда ут күренде дә юлсыз-нисез тугры төштем. Ул бу авылның тегермәне икән. Миңа төнне кунарга рөхсәт булыр бит? *(Үзе Петрга карый.)*

Зөләйха. Кунарсың, кунарсың. Ул исерек, берни белми, самавыр куйыйммы?

Габдулла. Улсы синең изгелегең.

Зөләйха *(самавыр куя башлый)*. Син кайдагы?

Габдулла. Мин ерактан, бик ерактан.

Зөләйха. Алай да кайдан?

Габдулла. Чистай диеп ишеткәнең бармы, шул яктан.

Зөләйха. Бар, ник булмасын, кайсы авылдан?

Габдулла. Туган авылым Әмин авылы, укыган авылым Дүртөйле, тора торган авылым Чишбаш. *(Габдулла чишенеп бетереп, толыпларын салып, килеп утыра.)*

Зөләйха *(самавыр янында)*. Кәсебең нәрсә?

Габдулла. Алла ни кушса, шуны эшлибез. Иләктән чиләккә, чиләктән иләккә. Хәзер ишан хәзрәткә барам. Син кайдан болай татарча беләсең, әллә син керәшен кызымы?

Зөләйха. Беләм инде шунда, менә син дә беләсең бит.

Габдула. Мин, әлһәмдүлиллаһ, үзем мөселман.

Зөләйха. Бәлки, мин дә мөселманмын. *(Габдулла башын селкеп, бармагы белән Петрга төртеп күрсәтә. Зөләйха кызара да бераздан соң.)* Мине көчләп алдылар, Син Әминнән булгач белә торгансың, безнең авылны Карга, диләр, мин Гыймади кызы.

Габдулла *(исе китмән булып)*. Син Зөләйха?

Зөләйха. Әйе, Зөләйха!

Габдулла. Хәзер шуның белән разый булып торасыңмы?

Зөләйха. Разый булмасаң, ни эшлисең, язмыш шулай булгач?

Габдулла *(башын селкеп)*. Син Зөләйха, ә?

Петр йокы арасында әллә нинди тавышлар белән ыңгыраша.

Зөләйха. Акрынрак, уянса, сугыш чыгарыр. *(Габдулла янына килеп утырып.)* Син безнең авылда күптән булдыңмы? Минем әнине күрдеңме? Минем кызларым кайда, беләсеңме? *(Габдулла Петрга борылып карап тора.)* Ул йоклый. Курыкма! Тизрәк сөйлә. Ике елдан бирле бер хәбәр алганым юк, бер хәбәр!

Габдулла. Күрдем, күрдем. Мин хәзер тугры сезнең авылдан. Әниең бик сәламәт, күзе генә бетте. *(Зөләйха күзләрен сөртә.)*

Зөләйха. Кызларым?

Габдулла. Кызларың? Алар да сәламәт. Алар өчен кылмаганны калдырмадылар. Бөтен авылны тентеделәр. Алар кул-күз җитәрлек, ерак түгел.

Зөләйха. Исәннәр?

Габдулла. Исәннәр, туп кебек тәгәрәп үсәләр.

З ө л ә й х а. Угылым?

Г а б д у л л а. Угылың? Угылың бит юк. Аны бит монда — синең яныңда тора, диләр.

З ө л ә й х а *(яшен сөртеп)*. Алай булгач аны әллә кайда олактырганнар инде. Монастырьга җибәргәннәрдер. *(Петр тагын әллә нинди тавышлар чыгара. Габдулла туктый. Зөләйха, акыртын гына торып, самавыр хәзерли.)* Сәлимҗан нишләде?

Г а б д у л л а. Сәлимҗан казаматта! Син соң бер дә белмисеңмени?

З ө л ә й х а. Кайдан белим соң, абзыкаем, алып киткәч тә, өч-дүрт көн бербуйдан аттан атка күчереп чаптылар. Чаптылар да монастырьга итеп тыктылар. Анда тугыз ай тоттылар. Кылмаганнарын калдырмадылар. Ач та тоттылар, кыйнадылар да, үгетләделәр дә. Иртә чиркәү, кич чиркәү, әле дә ничек гакылдан язмадың, диең... Тел белмим, сөйли алмыйм, кая киттем, ни булдым. Берсен дә белмим. Шуннан соң менә шунарга бирделәр. *(Габдулла башын селкеп тора.)* Тора торган җирем кай җир, безнең авыл кай җакта — һичберсен белмим. Былтыр бер кырык тартмачы килгән иде. Шунда гына әнинең исәнлеген белдем. Аның белән сөйләтмәделәр. Кайдан белим? Зинһар, сөйлә, мин киткәч ни булды? *(Самавырны хәзерләп.)* Сөйлә!

Г а б д у л л а *(Петрга күрсәтеп)*. Мин монардан шикләнәм.

З ө л ә й х а. Юк, юк, ул дүнгән. Сөйлә, зинһар, ни булды?

Г а б д у л л а. Теге сугыштан өченче көнендә үк кырык казак белән исправник килеп авылны басты.

З ө л ә й х а. Аны беләм. Шул көнне бит мине ындырдан, салам астыннан табып алып озаттылар.

Г а б д у л л а. Менә шуннан сорау башланды. Өйгә алып керәләр дә өсте-башы тетелгәнчә камчы белән яралар. Иң әүвәл Гыймади дәдәне чакырдылар. Аннан Әхмәтҗанны. Мин [үз] күзем белән күрдем, чыгарып каравылга биргәндә, Әхмәтҗанның теле юк иде, диделәр. Казаматка озатканда юлда үлде. Мескен, Алланың рәхмәтендә булсын, бик күп зәхмәт чикте. Аннары әллә кайдан тотып, Фәхретдинне китерделәр. Аны камчы белән кыйныйкыйный битләре чиләнеп беткәч,— беләсең сезнең авылның Мифтах солдатны,— ярый, шул кереп исправникка

бик каты бәйләнде: «Син монда кеше үтерергә килгәнмени? Падишаһның «Һәркем үз динендә торсын» дигән указы бар, мин Санатка язам!» — дип бик гайрәтләнде. Теле телгә йокмый. Теге дин дошманнарының күңелләренә Аллаһе Тәгалә курку салды. Шуннан соң берәм-берәм Сәлимҗанны, Мостафаны, Сибгатулланы чакырдылар. Аларны да кыйнадылар кыйнавын да, ул чикле түгел, ди. Менә һәммәсен каравылга биреп... *(Зөләйха җылый-җылый тыңлый.)* бетергәч, исправник: «Мулланы китереңез! Мулланы!» — диде. Ул вакытта мин дә анда идем. Халык җыелып йитте. Шул арада хәзрәт өстеннән, шул ук авылның бер затсызы бар икән, исемен белмим, шул кереп, Гыймади агайны мөселман каберенә күмде, дип, исправникка сөйләгән икән. Халык шуның кирәген бирмәсенме! Руслар һаман хәзрәтне чакыралар. Хәзрәт килми. Менә ил картлары китте. «Хәзрәт! Булмый инде, әйдә кил!» диделәр. Хәзрәт килде. Мескен мәрхүмә абыстай да калмады.

Зөләйха. Абыстай үлдемени?

Габдулла. Үлде, кайгысыннан үлде. Менә хәзрәтне эчкә чакыралар, халык бирми: «Менә монда чык та сораыңны ал!» — диләр. Ахырда чыкты. Бер якта руслар, бер якта халык. Хәзрәт, әле дә күз алдымда басып тора, аппак чалмадан, чапаннан. Теге якта казаклар, казаклар... Исправник килеп чыкты: «Синме мулла? Ник халыкны котыртасың?» — ди. Хәзрәт каушамаенча: «Әлхәмдүлиллаһ, мин мулла, әлхәмдүлиллаһ, ислам дине өйрәтәм»,— ди. Мифтах солдат тылмачлык итә. Түрә тагы: «Ник бунт чыгарасың, ник котыртасың?» — ди. Хәзрәт тагы: «Мин котыртмыйм, мин дин өйрәтәм, әмере мәгъруф һәрбер мөселманга фарыз»,— ди. Түрә тагы: «Ник христиан Василийне өенә килеп котырттың, ник христиан өендә Коръән укыдың?» — ди. Хәзрәт тагы: «Мин Василийне белмим. Мин Гыймади агайга бардым, ул минем мәсҗед картым, ул мөселман, безнең шәригатьтә мөселман үлгәндә Коръән уку — сөннәт, иман әлка кылу — фарыз»,— ди. Түрә тагы: «Ник син христиан Захар, хри-

---

*Әмере мәгъруф* — шәригать кушуы.

*Сөннәт* — бу урында: гадәткә кергән; эшләсәң — әҗерле, эшләмәсәң гөнаһсыз булган гамәл.

*Иман әлка кылу фарыз* — иманны искә төшерү тиеш.

стиан Василий, христиан Петр, христиан Дмитрийләрне котыртып ислам диненә керттең?» — ди. Хәзрәт: «Алар христиан түгел, мөселман. Шәригать әйтә: «Мән калә ля илаһе илля Аллаһе фәһүә мөслиму»,— ди. Аңладыңмы?» — диде. Түрә аптырап калды. Шуннан хәзрәтне каравылга бирергә теләде. Халык: «Бирмибез, ул ат урлаганмыни?» — диеп кычкыра башлады. Шуннан судебный үзенә барырга кушты. Хәзрәт: «Закун сезнеке, барырмын»,— диде. Шуннан тегеләрне алып киттеләр. Иртәгесен хәзрәт китте. Ләкин керү белән хәзрәтне тотып япканнар. Кыйнау-кыйнамауларын белмим, ләкин өч айдан соң хәзрәт үлде. Сезнең бөтен халык сөйли, хәзрәтнең яткан зинданының өстендә нур балкып тора икән, ди.

Зөләйха. Мескен!

Габдулла. Кайгысыннан абызтай да үлде. Хәзер мәхдүмне мулла итәргә телиләр. Ләкин теге түрәләр, атасына охшар диеп, каршы киләләр, ди. Аннан берәмләп-берәмләп сезнең ишенең барсын да алып бетерделәр. Хатыннар качып бетте. Әхмәтҗанның бер кызын монастырьга җибәргәннәр, диләр. Сине алып киткәннең икенче көнне русларны күреп куркуыннан Сибгатулланың хатыны суга төшеп үлде. Судның әле һаман да очы чыкканы юк. Теге поп дүрт ай хастаханәдә яткан, диләр. Ул хәзер әллә кая күчеп киткән инде.

Зөләйха. Менә, ник мине эзләмиләр, дим, ул ничек икән. Угылым шулай югалды алай булса?

Габдулла. Югалды. Кызларыңны Иделнең аръягында, бер-ике атна гына әле күрдем.

Зөләйха. Бер-ике атна гына. Исәннәр? Сәлимҗан, Сәлимҗан, Сәлимҗан мескен, ни булды инде, ни булыр?

Габдулла. Дошманнар Себергә йибәрергә диләр дә, Аллаһе Тәгалә ярдәм итмәсме әле. Йорт-йир бетте. Һәммәсенең дә йортлары ташландык булып калды. Үләт кергән диеп белерсең.

Зөләйха. Мин нишлим? Мин гомерем буе шунда торырмынмыни? *(Бишеккә күрсәтеп.)* Менә тагы балам булды, ни эшлим, Алла эше...

Габдулла. Сабыр ит, сеңлем, сабыр ит! Хәзер болай булды инде. Без бит синең үзеңне югалттык. Мин йөрмәсәм, инде мин йөрмәсәм! Хәзрәт тәбәррек әйтте, Габ-

---

*Тәбәррек итү* — фатиха бирү, изге эш дип белдерү.

дулла, бу эшне сиңа багышладым, диде. Бөтен тирә-күрше авылыны кыдырдым. Урысын, татарын сорамаганын калдырмадым, сорадым. Әллә нинди хәбәрләр чыкты. Берсе сине Оренбурда күреп кайттым дип сөйләде. Бик һәйбәт тора икән, ди. Әниең анда, белешеп-сорашып, Куян авылыннан күчеп килгән Хәмидулла абзыйга хат яздырды. «Юк» дигән хәбәр килде. Аннан берсе, кемдер шунда, сине урыс боярында тора, бөтенләй чукынган, мине танымаганга салынды, татар, татар диеп мыскыл итте, диеп сөйләде. Менә эзеңне хәзер күрсәтте. Идел аръягы савыт-сабачы бер татар Чирмешән базарында безнең авылның ат белә сату итүче белән бер өйдә кунганнар. Шул, сүз ияре сүз чыгып, безгә бер урыс кереп кунды, шул безнең авылда бер татар хатыны бар диеп әйтә, дигән. Менә ничек бит таптык.

З ө л ә й х а. Алай булгач, син мине белеп килдең?

Г а б д у л л а. Мин, ялгыш булмасын диеп, сезнең авылдан бер-ике үттем инде. Синең суга барганыңны күреп, аяк атлавыңнан Мәхбүбә абыстайга охшаттым.

З ө л ә й х а. Әй мескеннәр! Әй мескеннәр! Мин монда җәфа чиктем, алар миннән биш артык чиккәннәр. Инде мин нишлим? Коткар мине бу тоткарлыктан, коткар!

Г а б д у л л а *(Петрга күрсәтеп)*. Тс!

З ө л ә й х а *(карап торганның соңында)*. Юк, юк. Мин нишлим?

Г а б д у л л а. Менә мин әниеңне күреп сөйләшим. Хәзрәттән фатиха алыйм, аннары карарбыз. *(Акыртын гына.)* Сәлимҗаннарны шул көндә казаматтан качырырга газапла免аналар, Алла морадымызга йиткерсә, озын юлга китәргә тугры килер. Хәлифә падишаһка, урыс-улак җитми торган җиргә. Син, сеңлем, сабыр ит! Аллаһе Тәгалә сиңа хәзрәти Әюб хатынының савабын, фиргавен кызы җәсарәт Асиянең савабын язар. Сабыр ит, алар күрмәгәндә намазыңны укы! Күңелеңнән Алланы чыгарма! Кая, намазлыгың бармы, мин намаз укып алыйм!

З ө л ә й х а *(тәрәзәләрне каплый, чаршау тартып, Петрны чаршау артында калдыра. Габдулла намазга хәзерләнә)*. Мин дә укыйм! Тәһарәт алыйм. *(Мич артына югала.)*

Г а б д у л л а. Мескен, йөрәге янган... Әлхәмдүлиллаһ,

---

*Җәсарәт* — батырлык, кыюлык.

хәзер таптык. Мин чыннан да күңеле бик каралгандыр диеп, котым очкан иде. Шәехләрнең мәдәде аркасында, Алла теләсә, хәзер юлга салырбыз. Йа Рабби, мәдәд бир! Йа Рабби, кяфер тоткарлыгындагы бөтен мөселманны азат кыл! Биргәнеңә шөкер. Бу баланы ислам диненә кайтарырга миңа насыйп кылдың, биргәнеңә шөкер. *(Зөләйха керә, икәү намаз укыйлар.)*

Габдулла *(намаздан соң)*. Аллаһе Тәгалә хәзрәтләре бөтен мөэмин-мөселманга ике дөнья рәхәте бирсен. Аллаһе Тәгалә кяфер хезмәтендә тоткар булган мөселманнарның эшләрен җиңеләйтсен!

Зөләйха. Амин!

Габдулла. Ислам дине өчен зинданда ятучыларның күңелләренә куәт бир!

Зөләйха. Амин! *(Үкереп җылый.)*

Габдулла. Ислам дине өчен Себергә йибәрелгәннәрнең юлларын кыска кыл! Үлгән вакыт иманнарын юлдаш кыл!

Зөләйха. Амин! Амин! *(Җылый.)*

Габдулла. Дошман кулында грифтар булып торучыларны, дошман кулында атасыннан, баласыннан, хатыныннан, иреннән мәхрүм булып торучыларны *(Зөләйха кычкырып җылый.)* рәхмәтең аркасында кавыштыр! Амин!

Зөләйха. Амин!

Габдулла. Баласыз калган анага, атасыз калган балага, ирсез калган хатынга, йа Раббем, сабыр бир, сабыр бир! *(Зөләйха кычкырып җылый.)* Шул мескен, атасыз, анасыз калган, дошман кулына грифтар булган, баласыннан җөда, иреннән мәхрүм булган Зөләйханың эшләрен асат кыл!

Зөләйха. Амин, амин!

Габдулла. Пәйгамбәреңнең хөрмәте, әүлияларның кыйммәте өчен шул хатынның күз яшен киптер! *(Зөләйха тагы кычкырыбрак җылый.)* Ислам өчен чиккән зәхмәтләрен, мәшәкатьләрен кабул итеп, баласына-чагасына, атасына-бабасына, иренә кавыштыр!

Зөләйха. Амин!

---

*Шәехләр (мәшәихләр) мәдәде* — изгеләр ярдәме.
*Грифтар булу* — тоткын булу.
*Җөда* — аерылган.
*Асат кыл* — җиңеләйт.

Габдулла кул күтәрә. Зөләйха еглаган көенчә кул күтәрә. Ул әһ-әһ диеп еглый. Зөләйха: Амин! Амин! диеп куя.

Габдулла *(дога беткәч торып)*. Инде, сеңлем, рәхмәт! Инде мин китим, юл кунагы юлда булуы яхшы. Әниеңә барып сөенеч бирим. Хәзрәткә барып дәртеңне аңлатыйм, синең өчен мәдәд сорыйм. Син инде, сеңлем, сабыр ит! Бу көнгә кадәр чыдагансың. Чыда! Алла теләсә, мәшәехләр мәдәдчемез булыр. Без сине монда калдырмабыз.

Тәрәзә шакыйлар, Зөләйха куркып китә.

Зөләйха *(Габдуллага)*. Чү, тик тор! Күрше-күләндер. Бик явызлары бар. *(Габдулла ишек янына поса. Тәрәзәне тагы шакыйлар. Тәрәзәгә килеп, пәрдәне ачып.)* Кем ул?

Тыштан. Суыктан туңып үләм! Алла хакына, җылытып кына чыгар әле!

Зөләйха *(куркып, Габдуллага)*. Бу кем тавышы? *(Үзе дер-дер калтырый.)* Зинһар, әйт, бу кем тавышы? Бу тавышны мин ишеткәнем бар.

Габдулла. Бу дошман тавышы түгел.

Зөләйха *(ишек төбендә)*. Минем йөрәгем күкрәгемә сыймый, зинһар, әйт, бу кем?

Габдулла. Мин дә кемлеген белмим, ләкин күңелем тавышның калтыравыннан дуст кеше икәнен сизенде. Аллаһе Тәгалә ярдәмче булсын, мәшәехләр мәдәдче булса, изге булыр, бар. Ач. Озак көттермә! *(Зөләйха, ишеккә баргач, Петрга карый.)* Буласы эш булган, ач! *(Зөләйха акрын гына чыгып китә.)* Бу кем? Әллә ишан хәзрәтнең кәрамәте белән миңа каршы корылган бер-бер уйны белергә килгән гаиб ирәнме? Әллә минем савабымны көнләп, шул изге эшне миннән алырга килгән бер дустмы?

Ишек ачыла. Алдан, чабып кергән кебек, Зөләйха керә. Аның артыннан арестан чикмәне өстеннән тун кигән, астыннан чикмәне күренеп тора торган Сәлимҗан килеп керә. Зөләйха өйнең уртасына килеп баса, ул катып кала.

Сәлимҗан *(аңа каршы килә дә, бераз карап торгач)*. Син, Зөләйха, мине танымадыңмы? *(Үзе тунын чишә. Чикмәне ачыла.)*

Зөләйха. Сәлимҗан! Сәлимҗан! *(Муенына асыла. Үкереп җыларга тотына. Башыннан яулыгы төшә, чәче таралып китә. Сәлимҗан, бер сүз дәшмичә, Зөләйханың*

*башын сыйпарга тотына.)* Сәлимҗан, Сәлимҗан! Син исәнме, бәгырем? *(Үкереп җылый.)* Син исәнме? Сине күрергә Алла яздымыни? *(Габдулла чыгып боларга карап тора.)* Бу көнне күрермен диеп уйламаган идем.

Сәлимҗан *(җылаган тавыш белән)*. Мин дә уйламаган идем. Үлгәнчә балаларны күрмәм, теге дөньяга бармыйча сине очратмам диеп өметне кискән идем. Алланыкын белеп булмый. Аллага яраган бер эшебез булгандыр. Бу көнгә әле ярдәм итте.

Зөләйха *(янына кысылганнан-кысыла барып)*. Син минем ниләр күргәнемне белмисең! Ниләр күрдем?! Ниләр күрдем!.. *(Сәлимҗан бик озак үбә дә тагы башын сыйпый.)*

Габдулла *(яннарына килеп)*. Менә Аллаһе Тәгаләнең ярдәме, мәшәехләрнең мәдәде аркасында кавыштыңыз!

Сәлимҗан *(куркып китеп, Зөләйхадан аерыла)*. Кем бу?

Габдулла. Курыкма! Курыкма! Дошман түгел, дуст. Хәзер без алга таба карарга кирәк. Без бит монда үз йортымызда түгел, дошман илендә. *(Йоклый торган Петрга күрсәтә.)*

Сәлимҗан. Бу кем?

Зөләйха. Бу безнең дустымыз, ике ел буена мине эзләп бүген тапкан бер чын мөселман.

Сәлимҗан *(Петрга карап тора, әллә нинди бер фикергә килгән кебек, Петрга таба барып, аяк балтырыннан пычак чыгарып)*. Җәһәннәмгә җибәрим шул шайтанны!

Габдулла *(каршы чыгып)*. Юк, юк, бир пычакны!

Сәлимҗан *(бераз карап торгач, пычагын урынына куя да эскәмиягә утыра. Ул бик озак Петрга карап тора да Зөләйхага)*. Бу синең иреңме?

Зөләйха. Шуңарга көчләп бирделәр. *(Баш ия дә җыларга тотына.)*

Габдулла. Аларны сөйләргә вакыт булыр. Хәзер безгә китәргә кирәк. Беләсең, Сәлимҗан, юл кунагы юлда яхшы. Ай-көн калыкканчы бер мөселман авылына йитәргә кирәк. *(Өстенә күрсәтеп.)* Синең бу киемең берлән көндез йөреп булырлык түгел.

Сәлимҗан. Арыдым, аякларым калмады. Төн килдем, көн килдем, ике көн бербуйдан бер локмә капмадым.

З ө л ә й х а *(торып)*. Мескен! Самавыр кайнар әле. *(Чәй ясый. Сәлимҗан бер кабуда чәйне йотып йибәрә. Зөләйха икмәк, сөт бирә.)*

С ә л и м җ а н. Үтми! *(Селкенеп китеп.)* Салулы юлда барган кебек булды. Алла, аякларым!

Г а б д у л л а. Өченче көн ычкындыңызмы?

С ә л и м җ а н. Өченче көн иптәшләр чыга алмады, мин генә бер карак белән. Аның белән дә шул көнне үк аерылыштык.

Г а б д у л л а. Куа чыкмадылармы?

С ә л и м җ а н. Төнлә белән ычкынганны сизә алмадылар.

Г а б д у л л а. Мәшәехләр ярдәме. Монда кайдан белдең?

С ә л и м җ а н. Баяр урманын кисеп тотылып бер урыс кергән иде. Бу авылныкы икән. Шул сөйләгән иде. Йорт-җирен шуннан сорашып белгән идем. *(Пычагын күрсәтеп.)* Менә монда йә чөк, йә бөк ясарга дип тугры килдем.

З ө л ә й х а. Мескен! Мескен! *(Җылый, Сәлимҗан сөтне эчә.)*

Г а б д у л л а. Бик яхшы. Хәзергә бу көенчә бер эш эшләп булмый. Без синең белән китик. Урын эзләгәч, ишан хәзрәттән изен алгач, Зөләйханы алырмыз. Тор, күрешеңез!

С ә л и м җ а н. Син белмисең, абзый, эч яна! *(Күкрәген күрсәтеп.)* Эч яна!

Г а б д у л л а. Беләм, беләм, сабыр ит!

С ә л и м җ а н *(Зөләйхага)*. Тагы чәй бир! *(Зөләйха чәй ясый.)* Балалар кайда?

З ө л ә й х а. Менә бу абзый, ышанычлы җирдә, ди. Угылың юк, югалды, әллә кая олактырдылар, ди.

Г а б д у л л а. Исәнлек булса, бары да булыр.

С ә л и м җ а н. Әби?

З ө л ә й х а. Әни сукырайган, ди. Мин ике ел хәбәр ала алмадым.

С ә л и м җ а н. Ник качмадың?

З ө л ә й х а. Кая? Мин ни беләм? Тугыз ай монастырьда тоттылар. Аннары монда китереп олактырдылар. Тел белмим, юл белмим, кая китим? Көне-төне саклыйлар.

---

*Изен* — рөхсәт.

С ә л и м җ а н *(өйдә күзен йөртә, бишеккә күзен төшереп)*. Бу да синекеме?..

З ө л ә й х а *(баш иеп, акыртын гына)*. Минеке. *(Сәлимҗан ашардай булып карап тора, Зөләйха җыларга тотына, яшенә карлыгып.)* Валлаһи газим, гөнаһым юк, көчләделәр... Мин нишлим?! *(Сәлимҗан да баш ия.)*

Г а б д у л л а *(бераз туктап карап торгач, Сәлимҗанның янына килеп, башын сыйпап)*. Әйдә, энем, әйдә! Күрешеңез дә, әйдә!

С ә л и м җ а н. Йөрәк яна! Ничек үч алмаенча китим?

Г а б д у л л а. Үч алу көне әле килмәгән. Һәр эшнең вакыты бар.

Сәлимҗан аягүрә тора, ул аз гына егылып китми.

С ә л и м җ а н *(утырып)*. Алла! Алла! Аякларым беткән! Мин кая барыйм?

Г а б д у л л а. Алла кая кушса, шунда. Озак түгел. Үр төшәргә дә үр менәргә. Бар котыңны җый! Зөләйха, сеңлем, син сабыр ит, бер-ике көн... Күп вакыт үтмәс, аннан соң без сине коткарырбыз.

С ә л и м җ а н *(торып)*. Хуш! *(Зөләйха кулын ачып килә. Аны кочаклый.)*

З ө л ә й х а. Мине калдырасызмыни? Мине, мине шул кяфер тоткарлыгында калдырасызмыни? *(Петрны күрсәтеп.)* Шул дин дошманының түшәгене бүлешергә калдырасызмыни? *(Үкереп җылый. Сәлимҗан да җылый. Габдулла аның кулыннан тарта. Ул китмәкче була. Ишеккә таба бер атлый, бер туктый. Зөләйха аягына җыгылып.)* Сәлимҗан, Сәлимҗан! *(Аягын кочаклый.)* Аяк астында тупрак булыйм. Калдырма! *(Үкереп җылый.)* Калдырма!

Г а б д у л л а. Сеңлем, сабыр ит, сабыр ит! Хәзер булмый.

З ө л ә й х а. Юк, юк, минем сабырым калмады.

Сәлимҗан аптырап тора. Петр ыңгыраша башлый, йокы арасында: «Марфа! Марфа!» — дип кычкыра. Сәлимҗан тагын пычагын ала.

Г а б д у л л а *(акрын гына кулыннан тотып)*. Тик тор! Бөтен эшне харап итәсең. *(Зөләйха һаман җылый.)* Сеңлем, сеңлем, сабыр!

З ө л ә й х а *(тыңламый)*. Сәлимҗан, Сәлимҗан калдырма! Җаным, калдырма!

Габдулла *(ачуланган тавыш белән)*. Юк, сеңлем, юк, син иреңне харап итмәкче буласың. *(Сәлимҗанга күрсәтеп.)* Бу аяк белән, бу өст-баш белән ул кеше качырырлыкмыни?

Зөләйха. Мине шул урыс тоткарлыгында калдырасызмыни? Минем күргәннәрем җитмәдемени? *(Үкерепүкереп җылый.)*

Сәлимҗан *(алга килеп)*. Әйдә! Киен! Алла язмаган эш булмас!

Габдулла. Әй угланнар, әй угланнар!

Зөләйха тунын, катасын алып кия, бишек янына килә дә аптыраган кебек тора.

Сәлимҗан. Тиз бул! Тиз бул! *(Зөләйха бишек яныннан китмичә тора.)*

Зөләйха *(сөаль иттереп бишеккә карап)*. Сәлимҗан! *(Сәлимҗан борылып карый. Тагы селкенә, бер сүз дәшми.)* Сәлимҗан! *(Җылый.)*

Сәлимҗан *(дерелдәгән тавыш белән)*. Ал! Ал! *(Зөләйха баланы күтәрә, Сәлимҗан янына килә. Сәлимҗан ишеккә таба атлап.)* Алла, Алла, аякларым! *(Бер кулына Габдулла, бер кулына Зөләйха керә, акрын атлыйлар.)*

Габдулла. Шулай, шулай, Алла юлына тугры! Алла ярдәмчеңез булсын!

Петр ыңгыраша. «Марфа!» дигән сүзе ишетелә. Тегеләр туктыйлар.

Петр *(сикереп торып)*. Ә, качарга? Ә, качарга? *(Барып Зөләйханы тотмакчы була, Сәлимҗан каршы килеп баса.)* Караул! Караул! *(Сәлимҗан Петрның муеныннан тота. Алар сугыша башлыйлар.)*

Габдулла. Йа шәехем, мәдәд, йа шәехем, мәдәд!

Петр егыла. Сәлимҗан Петрның өстендә бик озак аның муенын буып торганның соңында читкә китә. Петр һушсыз кала.

Сәлимҗан. Җәһәннәмгә кадал!

Габдулла. Йа шәехем, мәдәд! Тиз, тиз, угланнар! *(Зөләйха катыбрак тора.)* Тизрәк, угланнар, тизрәк!

Бар да чыгып китәләр, качалар. Сәхнә озын гына буш тора. Ишек ачык кала. Петр озын гына һушсыз ятканнан соңында һушка килә. Өстерәлеп ишеккә барып кычкыра.

П е т р. Караул! Караул! Үтерәләр, караул!..

Бераздан бер р у с килеп керә.

Р у с. Ни булды, ни булды?

П е т р. Үтерделәр, татарлар үтерделәр... Будылар үземне... аннары качтылар, качтылар... Куыгыз!.. *(Тора башлый.)* Караул! Караул!..

Р у с. Караул!.. *(Петрны торгызып алып чыгып китә.)*

«Караул» тавышы зурая. Чиркәү набат суга. Урамда төрле тавышлар, кычкырышлар. Сәхнә озак кына буш тора. Тавыш якынлаша, кычкырыш. Еглау кушыла. П е т р З ө л ә й х а н ы өстерәп өйгә алып керә. Р у с л а р, м а р җ а л а р бергә керәләр.

П е т р. Ә, качарга? Татар эте! Качарга! Ә, тагы качасың! *(Сугып җибәрә. Зөләйха егыла. Петр тагы янына барып.)* Тор, татар эте, тор! *(Зөләйха тормый, ыңгыраша. Петр аяк тибеп кычкыра.)* Тор! *(Марҗалар шәлләрен селкеп торалар.)*

Р у с л а р д а н б е р с е. Шулай, шулай, качмасын!

П е т р. Миңа әйтмәсәң, менә становойга әйтерсең! *(Шундагыларга.)* Становойга киттеләрме?

Б е р р у с. Киттеләр, киттеләр.

П е т р. Танык булыгыз, минем акчамны урлаганнар. Сандыктан 25 сум акчамны урлаганнар.

Б е р р у с. Юкны сөйләмә... Сиңа 25 сум кайдан килсен!

П е т р. Кайдан килсен, падишаһтан килгән. Син дә татарларны якларгамыни тагы?

Б е р р у с *(теге руска)*. Син белмәгәнгә катышма!

П о п. Җитәр, становойга аңлатырсың. *(Зөләйханы күрсәтеп.)* Моны хәзер болай калдырырга ярамый. Становой килгәнчә каравылга бирергә кирәк.

П е т р. Ә-әй, сотский, каравыл куй.

Б е р р у с. Монда нинди каравыл? Әллә качар диеп куркасызмы? Элгәре төсенә карагыз!

Зөләйха ыңгыраша. Тыштан тавыш ишетелә.

Б е р р у с. Юк, болай ярамый, сәкегә салыгыз!

П е т р. Идәндә дә ятар!

Б е р р у с. Кулын бәйлә, кулын бәйлә! *(Бер рус җуан сөлге алып кулын бәйли, Зөләйха ыңгыраша. Ике рус, берсе аягыннан, берсе башыннан тотып, сәкегә салалар. Зөләйха катырак ыңгыраша.)*

Б е р  м а р җ а *(марҗалар бар да төртенәләр)*. Монда эш бетте, әйдәңез!

П е т р. Сотский! Каравыл куй!

Барысы да чыгалар. Иң ахырдан марҗалар чыгалар, алар бер-берсенә, бер Зөләйхага карап чыгып китәләр. Өй тын кала. Зөләйха тагы ыңгыраша. Менә тагы тыштан Петрның: «Үтер, үтер!» — дигән тавышы ишетелә. Арыш суккан кебек кыйнаган тавыш ишетелә. Шулай итеп шактый озак дәвам итә. Кыйнау тавышы һаман өзелми. Ишек ачыла, тыштан: «Юри кылана, юри дәшми!» — дигән тавышлар килә. Картрак кына бер м а р җ а керә, Зөләйха янына килеп баса.

М а р җ а *(бераз карап торганнан соң)*. Марфа! Марфа! *(Зөләйха ыңгыраша.)* Марфа, Марфа! Марфа! Мескен, нишләгән! *(Зөләйха күзен ача. Марҗа шуны күреп.)* Марфа, Марфа! Марфа!

З ө л ә й х а. Мин кайда? Мин кайда? *(Ыңгыраша.)*

М а р җ а Өеңдә! Өеңдә!

З ө л ә й х а. Өемдә?.. Өем кайда? *(Ыңгыраша.)*

М а р җ а. Су биримме?

З ө л ә й х а *(ыңгыраша. Үз-үзенә)*. Мин кайда? *(Селкенә, тормакчы була, кулын селки алмый.)*

Марҗа, суны куеп, Зөләйханың кулын чишә. Зөләйха кулы белән таяна да марҗа биргән суны эчә. Су эчкәч, бераз карап тора. Шул арада тыштан бик нык тавыш ишетелә.

З ө л ә й х а *(теге марҗадан)*. Анда ни бар?

М а р җ а. Теге сине урлаган татарны кыйныйлар.

З ө л ә й х а *(селкенеп китә. Сикереп торырга теләгән кебек була, ләкин тора алмый. Бераздан соң үкереп җыларга тотына)*. Йа Рабби! Мин башына җиттем! Мин башына җиттем! *(Теге марҗа бераз карап тора да акрын гына чыга; ишектән тагы тавыш килә.)* Үтергәннәрдер инде мескенне, үтергәннәрдер инде!.. Алла! Алла! Йа Рабби! Ни гөнаһ шомлыгым өчен боларны күрдем? Әй Раббем! *(Кычкырып җылый.)*

Тыштагы тавыш якынлаша. Зөләйха тагы ята. Ишек ачыла. Бер канлы кешене — С ә л и м җ а н н ы — бер ике-өч рус тоткан килеш килеп керәләр, канлыны идән уртасына ташлыйлар.

П е т р. Менә кач! *(Руслар тирә-ягына җыелып карап торалар.)*

Б е р с е. Кирәген бирдек!

Б е р с е. Сотский, каравыл куй, без тегесен тотарга

китәбез. Әй җегетләр, атларны хәзерләңез, тимер сәнәкләрне алыңыз.

Берсе *(Зөләйхага карап)*. Бусы ятамы? Ята, ят! Юк, бик тиз кача алмассың!

Берсе. Әйдәңез, әйдәңез, тизрәк! Татар авылына кергәнчә артыннан барып җитик. *(Чыгалар.)*

Тыштан. Каравыл куй, каравыл куй!

Өй тын кала. Тыштагы тавыш җырагая. Бара-бара бетә.

Зөләйха *(акрын гына баш калкытып, өенә карый. Ыңгыраша-ыңгыраша утыра. Башын сузып карый да канга буялган Сәлимҗанны күрә)*. Сәлимҗан! Сәлимҗан! *(Бик акрын гына, тотына-тотына сәкедән төшә. Сәлимҗанга карап тора-тора да, янына тезләнә, үкереп-үкереп җылый. Ыңгыраша.)* Сәлимҗан! Сәлимҗан! Үлмәгән, үлмәгән, үлмәгән! Йа Раббем, ярдәм бир! *(Башын күтәреп убә-убә дә егылып китә. Сәлимҗан ыңгыраша. Зөләйха торып, су алып килеп, Сәлимҗанның авызына кашык белән сала.)*

Сәлимҗан *(бер-ике йотым йоткач)*. Алла!

Зөләйха *(башын итәгенә алып)*. Сәлимҗан! Сәлимҗан!

Сәлимҗан *(күзен ача)*. Алла! Алла! Мин кайда?

Зөләйха. Сәлимҗан, Сәлимҗан, мине танымыйсыңмы?

Сәлимҗан *(ыңгыраша)*. Су бир, су! *(Зөләйха тагы су бирә. Сәлимҗан күзен ачып.)* Мин кайда?

Зөләйха. Оныттыңмыни? Мине танымыйсыңмыни? Мин — Зөләйха!

Сәлимҗан *(ыңгырашып)*. Эчем, эчем! Шул аягыма нәрсә баскан, алып ташла! *(Зөләйха җылый. Сәлимҗан, күзен ачып, Зөләйханы күреп.)* Зөләйха, синмени? *(Кулын селкетә. Бик авыр сулап.)* Ай, кулым! *(Зөләйха башын күтәрә. Сәлимҗан ыңгырашып.)* У-у, эчем, эчем! Ни булды моңар? Сиңа ни булды, сиңа ни булды, Зөләйха? Мин кайда? Казаматтамы? *(Ыңгыраша.)* Син ник монда? Әллә мин саташаммы?

Зөләйха. Бисмилла әйт! Сәлимҗан, Сәлимҗан, бисмилла әйт! Күзеңне ач!

Сәлимҗан *(күзен ачып)*. Ни булды сиңа? Сиңа ни булды, Зөләйха? Ник йөзең канлы? Алла, Алла, эчем!

Зөләйха. Син белмисеңмени? Без качтык бит, безне тоттылар, кыйнадылар.

С ә л и м җ а н. Кыйнадылар... Казаматта кыйнадылар... Әхмәтҗан абзыйны да кыйнадылар... Фәхретдинне дә кыйнадылар... Хәзрәтне дә кыйнап үтерделәр... Мин кайда?.. *(Зөләйха кычкырып җылый.)*

С ә л и м җ а н *(айныган кебек, күзен ачып торып)*. Зөләйха, Зөләйха! Габдулла абзый кайда?

З ө л ә й х а. Качып котылды. Качты.

С ә л и м җ а н. Аллага шөкер икән! Зөләйха! Мин хәзер бабайны күрдем. Син күрдеңме? Ул акбүз атка атланган.

З ө л ә й х а. Бисмилла әйт, бисмилла!

С ә л и м җ а н *(бисмилла әйтә. Ул тагы ыңгырашып)*. Зөләйха! Зөләйха! *(Ул тагы күзен өйдә йөртеп, тәрене күрсәтеп.)* Капла! Капла! Фәрештә керергә куркып тора. *(Зөләйха чүпрәк белән каплый. Сәлимҗан исенә килеп.)* Зинһар, кил! Кил! *(Зөләйха килә.)* Өшкер мине! Өшкер! *(Зөләйха бисмилла әйтеп өшкерә.)* Зөләйха! Бир кулыңны! Бир! Мин үләм! Әлхәмдүлиллаһ, рус кулында шәһид китәм. Әлхәмдүлиллаһ, әлхәмдүлиллаһ, Алла! Алла! Эчем! Мин үләм. Мин бу дошманнарның кулыннан котылам. Син каласың. Син шулар кулында каласың, Зөләйха, син шулар кулында каласың. *(Ыңгыраша. Зөләйха кычкырып җылый.)* Коткарлык бир! Коткарлык бир! Зөләйха, Зөләйха, мин үләм. Күрсәң, әбидән бәхиллек сора. *(Ыңгыраша.)* Балаларга миңа Коръән укырга куш! Мин урыс каберенә күмелсәм дә, күңелем гел аларда булыр. Мине монда ялгыз калдырмасыннар. Алла! Алла! Бөтен тәнем үземнеке түгел, Зөләйха! Коръән укы! Минем җаным чыкканда, Коръән белән чыксын! *(Зөләйха укырга тотына, үзе үкереп-үкереп җылый.)* Еглама, Зөләйха! Миңа хәзер рәхәт. Тәнем дә авыртмый, мин хәзер майда йөзгән кебек булдым. Әнә бабай иярле ат тотып тора.

З ө л ә й х а *(җылап)*. Сәлимҗан, Сәлимҗан! Синең болай булуыңа мин сәбәп булдым. Мин! Бәхил бул!

С ә л и м җ а н. Бәхил, Зөләйха, бәхил, бердән меңгә кадәр бәхил! Алла! Алла!

З ө л ә й х а. Әйт, ни васыятең бар?

С ә л и м җ а н. Васыятемме? Васыятем шул: бу рус белән торма! Ни күрсәң күр — бу рус белән торма!

З ө л ә й х а *(җылап)*. Тормам, тормам!

С ә л и м җ а н. Әссәламе галәйкем! Бабай, исән торасыңмы? *(Көлгән тавыш белән.)* Аллага шөкер, бик сәламәт! Хуш, бабай, хуш! Хәзрәт исәнме, бабай? Ник кил-

мәде, бабай? Ә, килә диең... килә диең... Килсен, килсен сабак хәзрәтебез.

Зөләйха. Саташа! Саташа!

Сәлимҗан. Әйе, үзем генә җыенам инде. Хатын-кыз белә, хаҗ сәфәре озын бит, бабай. Ә, манифест, диең!.. Чыккан, диең!.. Безнең хакта әле... *(Тагы ыңгыраша.)* Алла! Алла! Зөләйха! *(Җан бирә.)*

Зөләйха *(бераз карап торгач)*. Үлде, ахры!.. Үлде! *(Маңлаен үбә.)* Йа Раббем! *(Дога кыла.)* Синең юлыңда үлгән ирем хөрмәтенә мине коткар! Коткар! Йа Рабби, шул канга буялып үлгән шәһиднең каны хөрмәтенә коткар! Коткар! *(Җылый. Бераздан соң торып.)* Раббем! Моны күрсәттең! Сабыр итәм. Әлхәмдүлиллаһ, савап дәфтәренә моны да яздың! *(Акрын гына тора. Егылып китә башлый. Мичкә тотына-тотына барып, бер сандыкны ача. Аннан бер салфет, бер Коръән алып килеп, йөзенә салфет яба; баш очына Коръән куя, үзе тагы тезләнеп, кул күтәреп, авыз эченнән дога кылырга тотына. Үкереп-үкереп җылый. Бераз сабыр итеп.)* Инде, Раббем, мине кемнәр кулына калдырдың? Теге абзыйны да тотсалар, тагы башым олага инде. Нишлим? Йа Рабби, үлем бир, бир! Йа Рабби, бир! Ник мине кыйнап үтермәделәр? Йа Рабби, җанымны ал! Шул минут, шул секундта ал! Шул дин дошманнарын тагы күрергә язма! Раббем, ярдәм ит! Изге ирләр, изге хатыннар, шәфәгатьче булыңыз, шәфәгатьче булыңыз! Җанымны ал! Җанымны ал! *(Туктап җылый. Бераздан.)* Инде нишләрмен? Йа Рабби, гафу ит! Торыр хәлем калмады, үзең гафу ит! Бик зур гөнаһ эшлим, рәхмәтең киң, Раббем! *(Акрын гына барып, сандыктан чүпрәккә төргән мышьяк ала. Мышьякны суга салып.)* Раббем! Бөтен серләрем үзеңә мәгълүм. Кич шул гөнаһымны, йа Рабби! Бу дөньяга күземне ачып карарга күзем калмады. Өметләнеп яшәргә өметем калмады. Бөтен дуст-ишем, якын хәләлем теге дөньяга китте. Мин дә китәм, үз якама үзем кулымны салам. Йа Рабби! Кич, кич! *(Мышьякны бутый.)* Дөньяда күргән михнәтләрем, зәхмәтләрем өчен җанын фида иткән шул хәләлемнән аерма! Шуның куенында җанымны көчләп чыгаруымны гафу ит! Үзеңә мәгълүм, Раббем, сабырсызлык түгел, ни биргәнеңә разый, дөньяда торырга хәлем калмады, калмады! Мин дә әнә ул үлгәндә күргән этиләр, хәзрәтләр арасына барасым килә, кич, Раббем!..

Ишек ачыла. П е т р килеп керә, ул исерек.

П е т р *(әвенә-түенә, Зөләйханы күргәч)*. Әх, әх, качтыңмыни? *(Зөләйха акыртын гына тора, чынаяк белән суны да ала. Сәлимҗанга.)* Ә, качырдыңмы? Качыр, качыр! *(Үзе селкенә-селкенә йөри.)* Кач, Марфа, ә, кач! *(Сәкегә утыра.)* Юк, әле становой алдында болай гына булмас! *(Кулын сәкегә суга.)* Мин күрсәтермен! Марфа! Марфа! *(Зөләйха эндәшми.)* Марфа! Марфа, дим! Су бир!

З ө л ә й х а *(мич янында торган чынаякка таба берике атлый. Туктый. Ул әллә нәрсә уйлаган кебек була. Ахырдан тиз-тиз бара да чынаякны алып)*. Мә! *(Петр голт итеп йота. Зөләйха халыкка карап.)* Ходаның язмышы шулайдыр!

П е т р *(эчеп бетереп)*. Бу ник әче? *(Тәкеренә. Берасдан йоклап китә.)*

З ө л ә й х а. Эчем бушап китте. Өстемнән тау кадәр йөк төшергән кебек булдым. *(Сәлимҗан янына килеп, салфетын ачып.)* Рәхәт йокла! Мин синең үчеңне алдым.

П е т р *(ыңгыраша башлый. Ул бердән сикереп торып, күкрәген тотып)*. Яна! Яна! Су бир! Яна! *(Ул сикереп йөри башлый. Зөләйха мич янына поса. Петр уларга тотына.)* У-у, үләм, яна! *(Тунын салып ташлый, күкрәгенә кулын суга.)* Бөтен күкрәгем яна. Инде эчем яна! Бөтен тәнем яна! Марфа! Марфа! Су бир! Су, су! *(Сикереп йөргәндә, Сәлимҗанга абынып егыла.)* Су! Су! Янам, су!

Зөләйха шул чынаяк белән су китерә. Петр эчә, җыгыла. Берникадәрле вакыт кычкырына. Аякларын бутый, чәчләрен йолкый, күлмәкләрен ертып бетерә.

П е т р. Уф! *(Үлә.)*

З ө л ә й х а *(акрын гына чыгып, еракътан гына Петрны карап)*. Үлде! Җәһәннәмгә китте! Мин бер кайгы, бер шатлык арасында калдым. *(Кыңгырау тавышы килә. Тавыш якынлаша. Атлар туктый. Сүзләр ишетелә.)* Килделәр, килделәр! Килсеннәр, мин үз эшемне эшләдем. Күңелем тыныч! Кая алып китсәләр дә китсеннәр!

Ул ике үлекнең башлары очында басып тора. Ишек ачыла. Иң әүвәл фонарь күтәргән бер с т р а ж н и к керә, өй яктырып китә. Аның артыннан толыптан с т а н о в о й керә. Аның артыннан — башка р у с л а р.

С т а н о в о й. Кайда ул качкын? *(Ул, ике үлекне күреп, баскан җирендә аптырап катып кала; башка руслар да*

*аптырыйлар. Зөләйха дәшми. Руслар аптырап торгач, берсе шапкасын салып төртенә. Урядник та, башкалары да салалар.)* Бу кем?

Бер рус. Петр! *(Марфага күрсәтеп.)* Моның ире!

Бер рус *(килеп, Петрның башын тотып карый).* Үлгән! Кышкы квас кебек суык!

Становой. Тегесе? *(Сәлимҗанның өстеннән салфетын алалар да, урядник фонарь китереп карый. Становой тартынып китеп.)* Бу да үлгән?.. *(Зөләйхага.)* Бу ник үлде? Син шуны әйт! Бу ник үлде, дим?

Зөләйха *(Сәлимҗанны күрсәтеп).* Бу ник үлде?

Становой. Каналья, син үтергәнсең! *(Зөләйха дәшми. Урядник аның йөзенә фонарьны китереп карый. Аның канлы йөзе ап-ачык күренеп тора.)* Староста! Кара шул татарны, кем ул?

Руслар Сәлимҗанны актара башлыйлар, аның арестант чикмәне күренә.

Становой. Ә, менә ул кем икән!.. Бүген, төрмәдән качкан, диеп эзләргә приказ килгән иде, менә ул кайда!

Руслар һәммәсе җыелып карыйлар.

Становой *(Петрга карап).* Караңыз, шул үлгәнме?

Руслар *(беравыздан).* Үлгән, үлгән!

Становой *(торып).* Кая, син сөйлә әле, хатын, исемең кем синең?

Зөләйха. Зөләйха.

Становой. Нинди Зөләйха?

Руслар. Марфа! Марфа!

Становой. Җә, сөйлә, бу синең иреңме?

Зөләйха *(Сәлимҗанга күрсәтеп).* Бумы? Әйе, ирем. Хәләл ирем.

Становой. Черт, ул түгел, менә бу! *(Петрга күрсәтеп.)* Иреңме?

Зөләйха. Түгел.

Становой. Ник үлде?

Зөләйха *(Сәлимҗанга күрсәтеп).* Ул ник үлде?

Становой. Ул минем эшем түгел, сораганга җавап бир!

Зөләйха. Мин үтердем! *(Күкрәген сугып.)* Мин үтердем! Мин җәһәннәмгә җибәрдем, аңладыңмы? Илтәсе җиреңә илт, кыласы җәзаңны кыл!

Становой *(бер урыска).* Богауларны алып кереңез!

З ө л ә й х а. Алып кереңез! Курыкмыйм. Үтереңез! Кыйнаңыз! Кыйнап үтереңез! *(Сәлимҗанны күрсәтеп.)* Менә моны үтергән кебек үтереңез!

С т а н о в о й. Күп сөйләмә! *(Богаулар алып керәләр. Урядникка.)* Богаула кулларын! *(Бер руска.)* Әй, шуның арестант халатларын салдыр! Приказда халатын да табарга кушканнар. Казна малы югалмый. Ха-ха-ха! *(Көлә. Руслар Сәлимҗанның халатын алалар.)*

У р я д н и к *(богаулап бетерә)*. Бетте!

С т а н о в о й. Шул халатны кидереңез! *(Зөләйхага канлы чикмәнне кидерәләр.)* Кайда стражниклар? Керсеннәр! *(Ике стражник керә. Зөләйха кулы богаулы килеш сәхнәгә карап тора.)* Шуны алыңыз! Шәһәргә илтеңез! Полициягә, теге качкынны да таптык, халатын да таптык, диеңез! *(Стражниклар Зөләйханың ике ягына икесе басалар.)* Әйдә, марш! *(Зөләйха уртада, стражниклар ике ягында атлый башлыйлар.)*

П ә р д ә т ө ш ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бер кечкенә генә өй. Өйнең эче ак балчык белән сыланган. Зур мич күренә. Өй пөхтә генә. Дивар буенда сәке. Икенче, өченче пәрдәдәге өйгә охшый. Сәхнәгә таба икегә бүленгән: берсе зур бүлмә, берсе кечкенә. Ике арада ишек бар. З ө л ә й х а инде карчык.

З ө л ә й х а *(акрын гына идән буеннан килеп, җәйгән урынына утыра)*. Әлхәмдүлиллаһ, биргәнеңә шөкер! Бу көнне дә күрдек. *(Акрын гына, ыңгыраша-ыңгыраша урынына кереп ята.)* Инде бу дөньяда бер генә теләгем калды. Газраил якадан тотканча, кызларымны күреп калсам, тынычлап җан бирер идем. Аллаһе Тәгалә ярдәм бирсә, күрермен. Алла теләсә, күрермен! Габдулла бабай табар, Алла теләсә, табар. Кеше әйтеп, кеше ышанмас бит. Егерме ел балаларыңнан аерылып тор, имеш... Егерме ел бит... Бер кеше гомере. Йа Рабби! Биргәнеңә риза — кимчелекләремез күп булгандыр. Үзең кичер! Егерме ел диң... Атасыз, анасыз калган бу сөкүте тәмам кара урыс булып беткән. Йа Рабби, шул хәтеремә төшсә, йөрәгем ярыла. Шулай ук дин дошманы булып калыр

---

*Сөкүт* — дәшмәүче.

микәнни? Йа Рабби, үзең ярдәмчем бул! Алла! Алла! Бүген хәлем бигрәк начар. Бөтен йирдән тәнем бердән, берьюлы зур чуан кебек авыртканы гына җитмәгән, сөякләрем аерым-аерым сызлый. Әллә бөтен тәнем инде тузылып китәргә тели. Әҗәлгә сабырлык бир дә, шул кызларымны күреп актык васыятемне әйтеп калыйм.

Бер р у с керә. Карт.

Р у с. Исәнме, Марфа?

З ө л ә й х а. Менә, күрәсең, исәнлек кайда, мин кая? *(Торып утыра төшеп.)* Утыр! *(Рус аптырап тора.)* Утыр! Син әле мине качмады микән диеп карарга килгәнсең? *(Көлеп.)* Качтым, качтым. *(Куллары дерелди.)* Менә бу кул-аяк, бу исәнлек белән качарсың!..

Р у с. Юк, Марфа, юк, мин үзем генә кереп чыгыйм, дидем.

З ө л ә й х а *(көлеп)*. Шулаймы? Утыр! Кунак итәргә исәнлегем юк.

Р у с. Рәхмәт, мин китим!

З ө л ә й х а. Старостага барып әйтәсең бармыни? *(Көлә.)* Качкан диең, качкан, эзләү чыгарсын! *(Ыңгырашып.)* Сез миңа иркенләп үләргә дә ирек бирмисез, күрәсең.

Р у с. Миндә бит гаеп юк. Мин нишлим? Безнең кушканны эшләми хәлебез юк. Староста әйтә, без бөтен ил белә аны сакларга булып калдык, мин ил пичәте басып сакларга сүз бирдем, мин башымны Себер җибәрәсем килми, ди. Һәр атнаны начальствога хәбәр биреп торырга кирәк, ди.

З ө л ә й х а. Йә соң, үзең кара инде, өйдә аяк атлый алмый торган кеше кача ала диме соң? Тагы мин качып кая барыйм? Мин йөрисе йиремне йөреп бетердем. Әлхәмдүлиллаһ, биргәнеңә разый, егерме ел йөрдем, мин йөргәнне синең старостаң йөрсә, табаннары тузар иде. Мин күргәнне Аллаһе Тәгалә кяфер дошманыңа да күрергә язмасын!

Р у с *(акрын гына утырып)*. Синең эшләрне бездә хәзер әкият итеп сөйлиләр. Син җиде кеше үтергәнсең, имеш!

З ө л ә й х а. Сөйләсеннәр, гөнаһыма кәффарәт булыр. *(Бераз торып, катырак тавыш белә.)* Бар да ялган! Бар да ялган! Мин Петрдан башка берәүне дә үтермәдем. *(Ыңгырашып, тагы ята.)* Алла! Алла!

---

*Кәффарәт* — гөнаһны йолу, гафу итү.

Т е г е  р у с *(торып)*. Хуш бул!

З ө л ә й х а. Хуш!

Рус чыгып та өлгерми, яшь кенә, шәһәрчә киенгән бер к ы з кереп килә, рус аңар баш ия. Бүрек ала. Бераз тора да чыгып китә.

К ы з. Исәнмесез!

З ө л ә й х а. Акрын гына.

К ы з *(янына утырып)*. Сез, түтәй, һаман авырыйсыз.

З ө л ә й х а. Язмыш шулайдыр шул.

К ы з. Сиңа докторга күренергә кирәк иде.

З ө л ә й х а. Мин синең дуктырыңа күренгәнчә, хәзрәткә барып өшкертер идем дә шул, ирек бирмиләр.

К ы з. Ник алай дисең, түтәй, әле дә бит инде шул тискәрелегең өчен әллә ниләр күргәнсең.

З ө л ә й х а. Тискәрелек өчен түгел, дин өчен! Дин өчен! Мине үз динемнән, хак диннән чыгарырга теләделәр, көчләп алып, ирем бар өстеннән руска иргә бирделәр. Көчләп чукындырдылар. Көчләп ата-анамнан, балачагамнан аердылар. Мин, әлһәмдүлиллаһ, барсына да чыдадым, барсына да! Дин ислам өчен мин зәхмәт чиктем.

К ы з *(аптырап карап)*. Шул эшләрең өчен бер дә үкенмисеңме? Шул бушка үткән гомереңне кызганмыйсыңмыни?

З ө л ә й х а. Юк, үкенмим. Алла юлында сугышка үткәргән гомер буш түгел. Әлхәмдүлиллаһ, хатын булсам да, күп ирләргә насыйп булмаган дин сугышында булдым. Егерме ел бербуйдан сугыштым.

К ы з. Егерме ел бербуйдан!..

З ө л ә й х а. Егерме ел бербуйдан, төрмәдән каторгага, каторгадан Себергә, Себердән Себер аръягына...

К ы з. Мескен, бәхетсез! Ничек, түтәй, шуңарга арымадың? Бервакытта да шул кылганнарың бушкадыр диеп үкенмәдеңме?

З ө л ә й х а. Юк, үкенмәдем. Хәзер дә үкенмим. Безнең китапта әйткән, Аллаһе Тәгалә дин юлында күргән бер авырлыкка ике җиңеллек бирер, дигән.

К ы з. Менә бирми ич! Син, шәт, егерме ел мәшәкать чиккән, син эт гомере белән яшәгәнсең, бу көндә дә поднадзор торасың. Ашарыңа ашың, эчәреңә чәең юк.

---

*Поднадзор* — күзәтү астында.

З ө л ә й х а *(ыңгырашып).* Көне килеп җитмәгәндер. Әле тагын күрәселәрем бардыр. Гөнаһыбыз күптер. Алланың хикмәте бик зур. Без белә алмыйбыз.

К ы з *(аптырап карап торгач).* Түтәй, җә сөйлә әле, зинданда ниләр күрдең? Андагы начарлыкның исәбе- хисабы юктыр инде.

З ө л ә й х а. Күрмәдем түгел, күрдем. Бик күп нәрсә күрдем. Ләкин ирektә күргән начарлыкны төрмәдә күрмәдем. Ниләр булмады, ниләр баштан кичмәде. Кыйналдым, мыскыл ителдем, суктырылдым. Бөтен тән җәзаларын күрдем. Ләкин мондагы кебек, ирektәге кебек күңелемә каравыл куймадылар. Теләгәнчә намазымны укыдым. Теләгәнчә рузамны тоттым. Катышкан кеше булмады. *(Ыңгырашырга тотына. Кыз карап тора. Бераздан акрын гына Зөләйха егларга башлый. Кыз аптырап кала.)*

К ы з. Әллә бер-бер нәрсә биримме?

З ө л ә й х а *(яшь арасыннан).* Юк, юк, күңелем нечкәреп китте дә чыдый алмадым. Бетте хәзер. *(Ыңгырашырга тотына. Кыз тик тора.)* Син яшь әле, аңламыйсың. Менә минем дә синең кебек кызларым бар иде. Кем белсен, хәзер кая? Угылым бар иде... ул да... юк... Син әле ана бәгырен аңламыйсың! *(Зөләйха җылый.)*

К ы з. Захар Петрович бар ич!

З ө л ә й х а *(баш селки, бераз кычкырыбрак җылаган тавыш белән).* Юк, ул минем угылым түгел, түгел... Аңлыймсың, мин Зөләйха. Мин — Гыймаддин кызы Зөләйха! Мин мөселман! Минем Захар атлы угылым юк, юк! *(Бераздан.)* Минем Әхмәт атлы угылым бар иде, югалды. Поплар олактырдылар. *(Тагы җылый.)*

Шул арада З а х а р килеп керә. Зөләйха да, кыз да аны күрмиләр.

К ы з. Шул синең угылың инде, һәммә кеше шулай ди бит.

З ө л ә й х а. Минем урыс угылым юк!

Захар килеп алдына баса, Зөләйха юрганын томаланып ята, юрган эченнән ыңгырашкан тавыш белән җылаган тавыш кына ишетелә. Сәхнә тын кала. Кыз торып, күзен тутырып Захарга карап, бер сүз дә дәшмиләр.

К ы з *(акрын гына Зөләйханы күрсәтеп).* Ул синең белә сөйләшми?

З а х а р. Юк. Аны әллә нинди муллалар бозып бетергәннәр.

К ы з. Мескен, бәхетсез хатын!

З а х а р. Нәрсәсе бәхетсез? Тискәреләнмәсен! *(Ыңгырашкан тавыш ишетелә.)*

К ы з *(баш селкә)*. Юк, юк.

З а х а р *(идән буенда йөрергә тотына. Ул әллә нәрсә уйлый. Шул тынлык байтак дәвам итә. Захар бер килүендә кызның янына килеп туктый да Зөләйхага күрсәтеп)*. Ул минем атамны үтергән.

К ы з. Тс! Ул йоклый, акыртын!

З а х а р *(утыра. Бераз карап торгач, тагы башлап)*. Минем атамны үтергән!

К ы з *(башын селкеп)*. Ул кызганыч! Син аның хәлен белмисең, ул ниләр, ниләр күрмәгән! *(Акыртын сөйли. Ыңгырашып йоклаган тавыш килә.)*

З а х а р. Күрсә, үз тискәрелегеннән күргән. Кем кушкан аңар татар булып маташырга!.. Ул бит крещеный. Алла аңарга диннән чыкканы өчен шулкадәр зәхмәтләр чиктергән.

К ы з. Кызганыч, бик кызганыч! Минем дә синең кебек кызларым бар иде, ди. Белмим, хәзер кайда йөри торганнардыр, ди. Үзе еглый. Синең туталарың бармыни, Захар Петрович?

З а х а р. Белмим, белгәнем, күргәнем юк. Булса, шунда, әллә кайда татар булып йөри торганнардыр... Әйдә, бу мәсьәләне ташлыйк әле, beләсең, ул мәсьәлә — минем авыру йирем. Семинариядә иптәшләр әллә кайдан белеп, татар, татар, диеп еглатканчы үртиләр иде. Улсы җитмәгән кебек, менә монда бусы кайтты... *(Тик торалар.)*

К ы з. Мин иртәгә Максимовканың батюшкасына бәйрәм котлап барабызмы диеп килгән идем.

З а х а р. Иртәгә барабыз, барабыз. Җә, тагы ниләр бар?

К ы з. Берни дә юк. *(Захар аның кулын ала.)* Күрер!

З а х а р. Юк, йоклый. *(Үзе кызны кулыннан тартып үбә.)* Йә, сөйлә! Беләмсең минем нинди кәефсез икәнемне! Сөйлә, ичмасам, кәефне китер! *(Тагы үбә.)*

К ы з *(Захарның муеныннан кочаклап)*. Әни белән тагын да сөйләштем. Әти һаман синең читкә китәргә теләвеңә разый булмый: «Монда приход зур. Ул булмаса, башкасы була, ят кеше килгәч приход бозыла»,— ди.

З а х а р. Мин инде ул сүзне кырык ишеткән. Мин монда поп булып калырга разый түгел. Синең әтиең мужикларны талый-талый әллә никадәр акча җыйса да, үзенә дә шулкадәр дошман җыйган. Авылда аның сүзен тыңлый торган бер кеше бармы?! Аның нәсыйхәтен колагына ала торган бер христиан бармы?! Ул һәрнәрсәне базарга чыгарган. Гыйбадәт өчен дә акча бир, никях өчен дә бир, үлек өчен дә бир! Авылны диннән биздереп бетергән, поплыкны сатучылык, кулаклык дәрәҗәсенә төшергән! Юк, мин ул теләгәнчә поп буласым килми. Мин чын поп булам. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, диләр. Мин дә аның кебек хатыннарның актык йомыркаларын, мужикларның актык орлыкларын дин өчен диеп җыеп йөрим, ди!.. Юк, ансы булмас. Мин поплыкны үзеңнең якыныңа хезмәт итү диеп аңлыйм. Иисус ничек аңлаган булса, шулай аңлыйм. *(Зөләйханы күрсәтеп.)* Менә шул хатын сиңа никадәр ят булса, синең әтиең дә миңа шулкадәр ят, аңладыңмы?

К ы з. Аңладым, аңладым... Ул кадәр тискәре булырга ярамый. Син никадәр яратмасаң да, ул — синең анаң! Күз карашлары белән сиңа никадәр охшамаса да, ул — минем атам. Балалык хисе булырга кирәк.

З а х а р. Атам, анам — христианлык! Минем уем — приходыма хезмәт! *(Торып йөри башлый.)*

К ы з *(паузадан соң)*. Димәк, син мине сөймисең?

З а х а р. Ул тагы ни дигән сүз ди... *(Кызның кулын алып үбеп.)* Сөймәгән кеше шулай буладыр димени?! *(Тагы үбә.)* Ләкин мин үтерсәләр дә, бу приходта калырга разый түгел, шуны бел! Мин сине никадәр сөйсәм, үземнең идеалымны шулкадәр сөям. Онытма, минем тамырларымда бит татар каны! Гөнаһлы бабадан бабага гөнаһлы татар каны ага! *(Анасына төртеп күрсәтеп.)* Христианлыкны шулкадәр мыскыл иткән шул хатынның каны ага. Шул канны юар өчен, шул нәселдән нәселгә килгән гөнаһны бетерер өчен бик күп изгелек, бик күп гыйбадәт кылырга кирәк. Аңладыңмы? Шуның өчен миңа тыныч, гөнаһтан ерак приход кирәк. Шуның өчен синең кебек яхшы, шәфкатьле христиан хатын кирәк. Шул юлда минем белән барырга разый булсаң гына минем берлән бар!

К ы з. Разый, разый! Мең мәртәбә разый! *(Үбә, үбешәләр, бераз тын.)*

З а х а р. Алай булса, мин үзем батюшка белән сөйләшермен. *(Тагы кочакланып үбешәләр.)*

К ы з. Җә, иртәгә барабызмы?

З а х а р. Барырбыз.

К ы з *(торып)*. Мин киттем.

З а х а р. Мин сине озатыйм. *(Чыгып китәләр.)*

Өйдә тынлык. Зөләйха ялгыз.

З ө л ә й х а *(ыңгыраша)*. Алла! Алла! *(Ул саташа.)* Габдулла абзый, хуш килдең! Әлхәмдүлиллаһ, хәзрәти Рәсүлнең шәфәгате белән яшибез... Ашаңыз әле! Әни, менә сиңа юлдан... Ник мине көчлисез? Мин — мөселман!.. Мин — Зөләйха! *(Кычкыра һәм уянып китә. Юрганын ачып.)* Уф Алла! Әллә нинди төшләр күреп бетердем! Төшемдә Габдулла абзый кып-кызыл буйлы-буйлы яулык китерде. Юл була торган иде. Кызларым, бәлки, килә торгандыр... *(Акыртын гына торып карангалый да.)* Шул кара йөз юкта намазымны укып алыйм. *(Акрын гына, тотына-тотына идән буйлап йөри, су янына килеп, тәһарәт ала. Битен сөртеп.)* Өй дә суынып киткән, әллә азрак ягып алыйммы? *(Аксап-аксап кына барып, мичкә ут төртә. Яна башлый. Үзе почмактагы тәрене каплап, баш очыннан намазлык алып, баш очыннан «Һәфтияк»не күтәреп, намазлыкка утыра. Җирдә төшкән ут яктысы аны каплап ала, күккә таба кулын күтәреп, авыз эченнән дога кыла. Догага күтәргәч, башы бертуктамый селкенә. Дога арасында ыңгырашып җибәрә. Акрын гына, тын тавыш белән.)* Йа Раббем! Биргәннәреңә риза! Бердән меңенә кадәр риза! Азыксыз, ризыксыз, Раббем, озын юлга чыгам. Башымнан ашкан гөнаһ дәфтәремне күтәреп, синең каршыңа киләм. Пәйгамбәрләрнең, әүлияларның, мөселманлык өчен сугыш сафларында кан агызган хәзрәти Гали сәнҗагы астында күтәрелә торган шәһидләрнең хөрмәте өчен мине дә ярлыка! Рәхмәт диңгезең киң, Раббем, шул гөнаһына баткан, рәхмәтеңә сусаган бәндәңне дә пәйгамбәрнең шәфәгатеннән мәхрүм итмә, биргәнеңә разый! Гөнаһлы күңелем белән каршыңа барырга, тез чүгәргә *(җылый)*, актык теләгемне сорарга батырчылык юк, Раббем! Рәхмәтең киң, шул кяфер дөньясында җаным чыкканда,

---

*Сәнҗак* — байрак, әләм.

шул гөнаһлы тәнемнән мөселман җаным аерылганда, йа Рабби, иманымны юлдаш кыл! Баш очымда угылым, кызымны күрергә насыйп ит! Гөнаһлы җанымны Коръән, «Ясин» тавышы белән ал! Атам үлгәндә күзен тутырып-тутырып мине эзләгәндер, анам үлгәндә актык сүзене «Зөләйхам» диеп җан биргәндер, мине дә шулай итмә! Күрсәт кызларымны! Актык сулышымны синең исемең белән алыйм, амин! Күкләрдәге фәрештәләр, урыс өенә керергә куркып тора торган фәрештәләр, минем белән амин диеңез! Амин!

Һатифтан зур бер хор тавышы килә. Амин! Амин!

Зөләйха *(аптырап кала. Як-ягына карана. Куллары калтырый, тагы калтырап кына).* Амин!

Һатифтан. Амин! Амин!

Зөләйха *(тормакчы була. Аягы калтырый. Аз гына егылмый. Тагы тора, кул күтәрә).* Каф тауларыннан зур, мохит диңгезләреннән киң, күктәге йолдызларыңнан күп гөнаһым бар... Синең биргән ризыгыңны ашап, синең биргән матур кояшыңда җылынып, синең биргән саф һаваңны сулап, сиңа каршы көфране нигъмәт кылдым. Үземнең каршымда *(кычкырып җылый)* мөселман дошманы үстереп, ике аяклы, ике куллы Захар... *(Шул арада ишектән Захар килеп керә; Захар басып тора, Зөләйха күрми.)* шайтанны тудырдым. Мөселман анадан мөселман дошманы — кяфер тудырдым. *(Җылый, Захар катып тора.)* Атасы Сәлимҗанның дин өчен күргән михнәтләре хөрмәтенә шул балага һидайәт бир! Шул балага иман нуры яудыр, амин! *(Хор ишетелми.)* Амин! *(Як-ягына карап.)* Фәрештәләр, амин! *(Хор тагы ишетелми. Зөләйха кул төшереп, баш иеп карангалый башлый, Захарны күреп.)* Син, кяфер! Син минем фәрештәләремне качырдың! *(Кулын селкеп.)* Имезгән сөтем хәрәм булсын! Ләгънәт сиңа!

Захар *(кызу-кызу килеп).* Үз өемдә мин үз динемне мыскыллатырга ирек бирмәм! Былчырак чүпрәкләрең белән божий матерны капларга, аның рәхмәтләреннән

---

*Мохит диңгезе* — Тын океан.
*Көфране нигъмәт кылдым* — шул ризыклар кадерен белмәдем.
*Һидайәт бирү* — туры юлга кертү.

мине мәхрүм итәргә разый булмам! *(Барып, чүпрәкне алып ыргыта.)* Җитәр, күп мыскыл иттең! *(Зөләйха тик тора. Захар килеп, кулыннан «Һәфтияк»ен тартып [алып] мичкә ыргыта.)*

Зөләйха *(куллары белән аңа ябышмакчы була).* Алла! *(Кычкырып, намазлыгына егыла.)*

Захар *(шарт-шарт басып, идән буенда йөри-йөри дә күрше бүлмәгә кереп китә. Сәхнә тын кала, урамнан шакылдатып каравылчы уза. Аның тавышы озакка кадәр ишетелә. Зөләйха ыңгыраша. Күрше бүлмәдә Захар берәр бүлмәне әйләнә дә тәре алдына барып тезләнә; кулын тәрегә таба күтәреп тора. Озак кына торганның соңында кычкырып җылап җибәрә).* Ярлыка! *(Үксеп-үксеп җылый.)* Ярлыка! Динсез анадан, динсез атадан туган колыңны ярлыка! Шул ана, шул ананың... чында да мин шул татар баласымыни? Мин Захар Петрович түгелме? Бу хатын... бу ана... минем атамны үтергәнмени?.. Мин кем соң? Гөнаһлары тамырларыннан ага торган бәндәңне ярлыка!.. Христианлыкка каршы ителгән таулар, ташлар кадәр аталар, бабаларымның гөнаһын юып бетерергә, тәүбә кылып бетерергә юл күрсәт! Юл күрсәт! Көч бир, Ходаем, көч бир! *(Җылый, озак җылый да, урынына барып ята. Утны сүндерә.)*

Аның җылаганы, Зөләйханың ыңгырашканы ишетелә. Мич яныпяныпсүнә. Бераз тынлыктан соң ерактан гына «Тәфкилеф» көенә йомшак бернәрсә уйналганы ишетелә. Аннан соң бер җыр җырлана башлый. Шактый озак җырлаганнан соң, бүлмә яктыра башлый. Яктыра-яктыра, берәм-берәм әллә нинди кызларга охшаган зәңгәр канатлы фәрештәләр күренә. Алар һаман йырлыйлар. Берсе башкаларыннан матур да, зур да, өстеннән нур чәчелеп тора. Рәхмәт фәрештәсе Микаил туктаган вакыт.

Зөләйха ыңгыраша.

Фәрештәләр, Зөләйха, Захар.

Захар *(үз бүлмәсендә сикереп торып).* Бу нәрсә? Нинди музыка? Бу нинди тавыш? Чү, чү!.. Бу көйне мин әллә кайда ишеткәнем бар... бар... бар... *(йырлыйлар.)* Хәзер, хәтерлим... Юк... Кемнәр йырлыйлар?..

Фәрештә акрын гына торып ишекне ача, ишектән нур дулкыны кереп, бүлмәне яктырта. Захарның күзләре камашып, читкә китеп баса. Җыр туктый. Йомшак кына музыка тавышы дәвам итә. Ул да туктый. Рәхмәт фәрештәсе вә башкалар Зөләйханың янына киләләр.

Р ә х м ә т  ф ә р е ш т ә с е *(Зөләйхага карап)*. Йоклый! Бу хатын, туганнар, егерме биш ел үзенең дине өчен тартышты; бу хатын атасыннан, анасыннан аерылды, иленнән, йортыннан җөда булды; иреннән тол калып, баласыннан-чагасыннан мәхрүм булды. Алланың, пәйгамбәрнең исемене, үзенең динене ташламады. Бүген ул үлә. Аллаһе Тәгалә буның өчен фирдәүс оҗмахында сарай хәзерләргә кушты. Моны каршы алырга хәзрәти Гомәр үзе яңа хөлләләрен киенде. Фирдәүс кавеме Гайсә анасы Мәрьям, Хәсән, Хөсәен анасы Фатыйма оҗмах ишеге төбенә каршы алырга җыенды. Моның түккән бер бөртек күз яшенә Аллаһе Тәгалә йитмеш мең фәрештәнең меңьеллык гыйбадәтенә язды.

Б е р  ф ә р е ш т ә. Ай, мин дә шул хатын булсамчы!

Б а ш к а л а р ы  д а. Ай, мин дә шул хатын булсамчы!

Р ә х м ә т  ф ә р е ш т ә с е. Дин юлына аягына тимер богау тагып атлаган һәрбер адымына җиде шәһид савабын язды. Дәрәҗәсен бөтен христиан гаскәренең котын алган Сәлахетдин әл-Әюби[нең], Истамбулның Фатыйхи солтан Мөхәммәднең дәрәҗәсеннән биек кылды.

Ф ә р е ш т ә л ә р. Ай, мин дә шул хатын булсамчы!

Ай, мин дә шул хатын булсамчы!

Р ә х м ә т  ф ә р е ш т ә с е. Менә Аллаһе Тәгалә сезгә үзенең рәхмәтеннән, мәрхәмәтеннән шул хатынның аякларындагы яраларын юарга әмер итте. Китер рәхмәт суын!

Бер фәрештә комган кебек нәрсә, берсе тас кебек нәрсә күтәреп килә. Рәхмәт фәрештәсе Зөләйханың канлы, шешкән аягын ача.

Ф ә р е ш т ә л ә р *(бердән)*. Уф! Уф! Бу изге хатынның аягын кемнәр шулкадәр канаткан? Безгә рөхсәт бир, шуларга ләгънәт укыйк!

Р ә х м ә т  ф ә р е ш т ә с е. Аның кебек адәм балалары.

Ф ә р е ш т ә л ә р *(бердән)*. Әлхәмдүлиллаһ. Әле дә адәм баласы булмаганбыз, әлхәмдүлиллаһ, адәм баласы булмаганбыз!

Р ә х м ә т  ф ә р е ш т ә с е. Күп сөйләргә вакыт юк. Тасны куй. *(Бер фәрештә куя.)* Син рәхмәт суы сал. *(Бер кыз сала. Рәхмәт фәрештәсе юа.)* Бу су белән мин Җәбра-

---

*Җөда булу* — аерылу.
*Фирдәүс* — җәннәт, оҗмах бакчасы.
*Тас* — таз.

ил фәрештә белән хәзрәти Мөхәммәднең йөрәгендәге кара канны юган идем. Бу рәхмәт суы белән мин Әюб пәйгамбәрнең кортлар ашаган битен юган идем.

Фәрештәләр. Нинди изге кешеләр! Йа Рабби, ник безне адәм баласы итеп яратмадың!

Рәхмәт фәрештәсе юа.

Бер фәрештә. Туган, бу изге хатынның аягы ни берлән болай җәрәхәтләнгән?

Рәхмәт фәрештәсе. Тимер белән! Бунның аягына тимердән ясалган чылбыр кигезгәннәр. Ул тимер, агачны ашый торган корт кебек, моның сәламәтлегене ашаган, җилеген киптергән.

Фәрештәләр. Рөхсәт бир, Аллаһе Тәгаләдән нияз итик, Аллаһе Тәгалә адәм балаларыннан тимерне бетерсен.

Микаил. Мин байрагым астындагы җитмеш мең фәрештә белән җиде йөз ел: «Йа Рабби! Адәм балаларына тимерне белдермә!» — диеп гыйбадәт кылдым. Аллаһе Тәгалә кабул итмәде. Аллаһе Тәгаләнең хикмәтен без белмибез. Дөнья яратылуның без серләрен аңламыйбыз.

Фәрештәләр. Алай булса, рөхсәт бир: без шул тимерне зарарга тотучыларга ләгънәт укыйк!

Рәхмәт фәрештәсе. Юк, юк! *(Рәхмәт фәрештәсе юып бетерә. Зөләйха ыңгыраша. Захар катып тора.)* Без йир йөзенә рәхмәт иңдерәбез, ләгънәт безнең эшебез түгел.

Бер фәрештә. Туган, миңа шул изге хатынның шул канлы чүпрәген алырга рөхсәт бир, мин аны бөти итеп янымда йөртер идем.

Рәхмәт фәрештәсе. Юк, Алланың әмере юк! Беттеме? Моның хәзер гомере кояшның соңге буе күтәрелүе кадәрле генә калды. Шул вакытта моның кызлары килеп җитәргә кирәк. Әнә күрәмсез, киләләр. Барыңыз, барыңыз! Газраилгә әйтеңез, тый зәмин кылсын!

Фәрештәләр. Мин, мин. Мин!

Рәхмәт фәрештәсе *(берсенә)*. Бар син!

Башкалар. Ай, мин шул булмаган, ай, мин шул булмаган!

---

*Нияз итү* — ялвару, сорау.

Захар акрын гына, үзене көчләп, батырланып, ишектән чыга башлый.

Фәрештәләр. Кяфер! Кяфер! *(Качыналар.)*

Захар куркынып тагы бүлмәсенә керә. Фәрештәләр тагы күренәләр.

Рәхмәт фәрештәсе. Бу бала — шул изге хатынның явыз баласы. Бу бала — шул изге хатынның күңелендәге иң зур җәрәхәте.

Фәрештәләр. Рөхсәт бир, без аңа бер ләгънәт укыйк!

Рәхмәт фәрештәсе. Юк, юк, мин сезгә әйтәм: без рәхмәт фәрештәсе, Алла аңар рәхмәт бирсен, диеңез! Тугры юлга күндерсен, тугры юлга!

Фәрештәләр, канатларын ачып, дога кылалар. Захар көчкә генә аяк өстендә басып тора. Ул калтырый, тагы чыкмакчы була. Киткән фәрештә килә.

Фәрештә *(хәзер генә килүче)*. Йир кыскартылды. Хәзер ялкау юлаучының атларыны куркытыр өчен корткош фәрештәсе бүреләргә куарга кушты.

Захар тагы чыкмакчы була. Ул калтырый. Ишек яныннан борылып китә. Тышта чана тавышы ишетелә.

Фәрештәләр. Килделәр! Килделәр!

Рәхмәт фәрештәсе. Әйдәңез!

Музыка тавышы тагы ишетелә. Фәрештәләр югалалар, музыка ерагаяерагая бетә, ишек шакыйлар. Захар калтыраган көенчә бүлмәгә чыга. Аяк өстендә басып тора алмый.
Захар ялгыз.

Захар. Бу ни бу? Минем шулкадәр ышанган юлым дөрест түгелмени?! Бу ни булды? Ходаем, ярлыка! Үзең тугры юл күрсәт!

Ишек шакыйлар, Захар, һаман илтифат итмичә, ишеккә тотынып җылый. Шул арада ишек ачыла. Алдан фонарь тоткан Габдулла абзый, ике хатын, бер ир килеп керәләр.

Захар. Килделәр! Килделәр! Тегеләр әйткән сүз дөрест чыкты, килделәр!

Бүлмә яктырып китә. Зөләйханың йөзенә ут яктысы төшә.

Габдулла. Менә шул өй инде! *(Төртеп күрсәтеп.)*

Менә шул инде сезнең әниеңез! *(Кызлары янына килеп тезләнәләр.)*

Бер кызы. Әнием бәгырем, әнием, бәгырем, сине күрер көнем бар икән! *(Җылый.)*

Икенчесе *(кулы белән кочаклый)*. Әнекәем! Әнием!

Габдулла. Чү, чү... йоклый! *(Кияве тик тора. Захар ишектән карап тора.)*

Зөләйха *(уянып)*. Әлхәмдүлиллаһ! Әлхәмдүлиллаһ! Чү, чү, бу кем?

Бер кызы. Әни, мин! Бу — без, синең кызларың, бәгырем! Без, әнием, сине күрергә килдек. *(Кочаклап.)* Әнием, әнием, бәгырем, Ходай бу көнне күрергә насыйп иткән икән.

Зөләйха. Сез... сез... (*Кулыны әле берсенең, әле берсенең башына куеп.)* Зур булган икәнсез, Алла тәүфыйк, бәхет бирсен! *(Үзе тормакчы була.)* Хәлем беткән... *(Кызлары торгызалар, аркасына мендәр салып утырталар. Зөләйха карангалап.)* Бусы кем?

Бер кызы. Бу, әнкәй бәгырем, киявем инде, минем ирем, әлхәмдүлиллаһ!

Зөләйха. Алай икән, кил, бәбкәм, кил. Син инде угылым булгансың, кил!

Әхмәдулла килеп тезләнә.

Зөләйха *(башын сыйпап)*. Угылым юк иде, менә, Аллаһе Тәгаләнең рәхмәте киң, үлгәндә угылым да булды.

Габдулла. Аллаһе Тәгаләнең кодрәте киң. Шәехем мәдәд бирсә, барысы да булыр.

Зөләйха. Габдулла абзый, бу синме?

Габдулла. Мин! Алланың гөнаһлы бәндәсе. *(Кызлар җылый.)*

Зөләйха. Йә, утырыгыз! Мин сезне барыңызны да бик күрәсем килгән иде. Йә әле, ут кабызыңыз әле, йөзеңезне күрим әле! *(Кызлар торып киемнәрен салып ташлыйлар. Берсе ут кабыза.)* Әлхәмдүлиллаһ! Әлхәмдүлиллаһ! Бу көнне дә күрәсем бар икән! *(Өй бик яктыра. Зөләйха Гайниҗамалга.)* Кара син, бөтенләй хатын булгансың!

Гайниҗамал. Әйе, әйе, догаңызда!

Зөләйха. Балаларың бармы, кызым?

Гайниҗамал. Аллага шөкер, ике угылым, бер кы-

зым бар. Угылымны быел этисе хәзрәткә мәдрәсәгә илтте.

Зөләйха. Син ник бик җылыйсың, Фәхриҗамал? Кил монда. *(Фәхриҗамал килеп тезләнә. Зөләйха аның башын сыйпый.)* Ник җылыйсың?

Фәхриҗамал. Әнкәем, бәгырем, бик зур оятым бар! Киявең сигез елдан бирле синең хәбәреңне иртә-кич көтсә дә, Габдулла абзый килгәндә өйдә булмады. Шуны гафу кыл инде, әнкәем, бәгырем.

Зөләйха. Мине алай кадерләнергә, иркәләнергә өйрәтмәделәр! Кызым! Алла үзе хәерле сәламәтлек бирсен! Киявең кем?

Фәхриҗамал. Габдерахман исемле, әнкәем, сатуалу итә. Өченче ел, әлхәмдүлилләһ, әнкәем, хаҗ шәрифкә дә барды. Синең өчен Мина тавында корбан чалдырып, синең өчен бик һәйбәт бер хаҗидан хаҗ кылдырган.

Зөләйха. Ай рәхмәт, кызым. Ай рәхмәт! Мин үләр алдыннан шундый зур шатлыклар ишетермен диеп уйламаган идем. Гайниҗамал, самавыр куй, мин дә сезнең белән бергә берәр чынаяк чәй эчим!

Гайниҗамал. Куям, әнкәй, куям!

Габдулла белән Әхмәдулла чишенеп читкә утыралар.

Әхмәдулла *(сәгатьне ачып карап)*. Ай, минем сәгать туктаганмыни? *(Колагына китереп.)* Юк, йөри. Килдек, килдек, әллә никадәр вакыт үтте кебек булды, актык ат ашаткан җиремездән чыгуга сәгать чирек кенә булган.

Габдулла. Шәехләрнең мәдәде.

Әхмәдулла. Теге бүреләрнең дә ярдәме бардыр, мин чын да курыктым, Габдулла абзый. *(Габдуллага Захарны күрсәтеп, әллә нәрсә пыштыр-пыштыр гына сөйләшәләр.)*

Зөләйха *(Фәхриҗамалга)*. Бала-чагаң бармы, кызым?

Фәхриҗамал. Балаларым, шул, әнкәем, кыска гомерле булып туалар. Үсмиләр. Киявең шул синнән шуның хакында дога алырга булган иде.

Габдулла. Аллаһе Тәгалә ярдәм итсә, шәехләрнең мәдәде белән булыр.

Зөләйха. Ләүхелмәхфузда язылган булса булыр, кы-

зым. Нинди зур булгансыз! Мин сезне күрә алмаганга инде егерме елдан артык вакыт үткәндер.

Кызлар *(янына килеп)*. Әй, әнкәем, без сине сагындык, әй сагындык! *(Икесе дә җыларга тотыналар.)*

Зөләйха *(аркаларыннан сөя)*. Хәзер инде егларга ярамый, Алланың биргәненә шөкранә итәргә кирәк, менә, әлхәмдүлиллаһ, күрештек.

Фәхриҗамал. Мин, әнкәем, сине һәрвакыт төшемдә күрә идем, бер мәртәбә сине, әнкәем, хәзрәти Рәсүл белән бер мәҗлестә итеп күрдем, әй шатландым, әнкәем, әй шатландым!

Гайниҗамал. Мин дә, әнкәем бәгырем, һәрбер эштә сине төшемдә күрәдер идем. Кияүгә чыгар алдыннан, әнкәем, киявем тугрысында бик күп сүзләр ишеттерделәр. Гел егладым. Беркөнне сине төшемдә күрдем, әнкәем, син аппак киемгә бөркәнгәнсең. Миңа кияү буләге онытма, дисең; үзең көләсең, шуннан уянып киттем дә күңелем утырды. Әлхәмдүлиллаһ, киявем бик яхшы чыкты.

Зөләйха. Рәхмәт, кызларым, рәхмәт! Мине онытмаганга рәхмәт! Мин дә сезне һичбер вакыт хәтеремнән чыгармый идем.

Самавыр кайный, кызлар чәй урыны хәзерлиләр. Захар ишектән чыкмакчы була, тагын тартыла.

Зөләйха. Каторгада, андый-мондый суктырган вакытларында, һәм тегеләй дә, авыр хәлләремдә, һәрвакыт сезне уйлап күңелемне җуата идем.

Фәхриҗамал. Әни, бик авыр булгандыр синең хәлең, безгә сөйләсәнә! Синең кайгыларыңны без дә, ичмасам, күз яшемез белә генә бүлешик.

Зөләйха. Аларны, бәбкәләрем, хәтеремә төшермәңез инде! Габдулла абзый менә сөйләр! Барсын да тыңлады, барсын да ишетте.

Гайниҗамал. Әнкәем, эткәйнең каберен белмисеңме?

Зөләйха. Аны Алла белә инде, күңелемне йомшаттыңыз. Әтиеңез җаны чыкканда минем кулымда булды. Әлхәмдүлиллаһ, иманын әйтеп вафат булды, менә шул авылда аны кыйнап үтерделәр. Мин аның канына буялган чикмәнен киеп төрмәгә киттем. Өч ай бербуйдан әтиеңезнең канлы чикмәнен өстемдә йөрттем, өч ай бербуй-

дан зинданда шул канлы чикмәнне үбеп, кочып, күңелемне юаттым. *(Кызлар җылыйлар, Әхмәдулла күзен сөртә.)* Шуннан соң чикмәнне алдылар.

Габдулла. Аллаһе Тәгалә шуларның барысына да шәһидлек савабы язсын! Әлхәмдүлиллаһ, Зөләйха, син бик күп авырлыклар күрдең.

Зөләйха. Аллаһе Тәгаләнең мине башкалардан аерып алып шулкадәр михнәтләр күрергә насыйп итүенә мең, мең разый!

Кызлар чәй урыны хәзерлиләр. Чәй янына утырышалар.

Фәхриҗамал. Әни! Безнең энемез Әхмәт бар иде, ул кая китте? *(Гайниҗамалга.)* Беләмсең, аның күзләре нинди матур иде, без синең белән аны сөяр өчен оршыша идек.

Захар ишектән чыкмакчы була, атлый, аяклары тыңламаенча, тагы катып кала. Габдулла да, Әхмәдулла да Захарга карыйлар; кызлар Захарны беренче мәртәбә күрәләр.

Кызлар *(бердән)*. Әни, бу кем? Әни, бу кем?

Зөләйха. Шунда бер урыс, кяфер!

Гайниҗамал. Ул урысның монда ни эше бар?

Фәхриҗамал. Ул ни диеп безнең мәҗлесемезне былчырата? Мәхәббәтсез! Кара әле, күзләре нинди ямьсез! Тфү! Тфү! Бисмиллаһир рахман иррахим!

Захар *(халыкка)*. Мин ни эшлим? *(Калтыраган тавыш белән.)* Белмим, мин кем? Мин Захар Петрович түгел! Мин шул Сәлимҗан угылы Әхмәт!.. Әнә шул хатыннарның сөйләгәннәре Әхмәт! Мин шул... мин... семинариядә бөтен рузаларны тоткан... бөтен гыйбадәтләрне... кылган... Захар... түгелме? Шулмы? Шулдыр... шул. Белмим! *(Башкалар чәй эчәләр.)*

Фәхриҗамал. Менә, әнкәем, сиңа диеп хаҗ хөрмәсе алып килдем! Менә монысы зәмзәм суы! Менә кап әле, әнкәем! Менә монысы, әни, сумсалар! Менә монысы бәлешләр!.. Менә монысы бераз кош теле!

Гайниҗамал. Әнкәем, менә монсы кортлы май!.. Сыерым бозаулаган иде. Менә чәкчәк. Менә монсы бал, үз умартамыздан. Әнкәем, кап әле!

Зөләйха. Рәхмәт, бәбкәләрем, рәхмәт! Бу кадәр мәшәкатьләрдән соң зәмзәм суы белән хаҗ хөрмәсен авыз итәрмен диеп уйламаган идем.

Габдулла. Ризык! Ризык өләшкән көнне синең дәфтәреңә: «Зөләйха шуларны ашар»,— диеп язылган.

Зөләйха. Биргәнеңә шөкер!

Кияү. Менә, әби, монсын да аша әле! Мин хәзрәттән өшкертеп алдым. Өй үрдәгемез.

Зөләйха. Рәхмәт, балакаем, рәхмәт!

Захар *(халыкка)*. Түгел, минем атамны динендә ныклыгы өчен кыйнап үтергәннәр, анамны, әнә шул карчыкны, бүген төнлә фәрештәләр килеп аягыны юган карчыкны, егерме ел каторгада йөрткәннәр. Минем каным алар каны. Мин ничек шул, дине өчен гомере буе күргән җәзаларына шатлана торган анамны, дине өчен корбан булган атамны ташлап, шул, чиркәүне кибеткә, гыйбадәтне сату-алуга әвергән батюшкага угыл булыйм? Юк, юк, мин алардан... *(Тагы тегеләргә бара башлый. Тегеләрнең илтифат итмәгәннәрен күреп, туктый.)*

Фәхриҗамал. Менә, әнкәем, нинди матур мәҗлесемез. Күңелем тулмаганы булса, әнкәем, ирем булмавы.

Гайниҗамал. Минем күңелем китеклеге, әнкәй, шул мәҗлестә Әхмәт булмавы. *(Габдулла белән Әхмәдулла Захарга таба карыйлар.)*

Зөләйха. Аны онытыгыз, кызым. Минем күңелемне җәрәхәтләмәңез! Минем андый угылым юк. Сезнең андый энеңез юк! Ул кяфер, кызым!

Гайниҗамал. Шул безнең матур күзле Әхмәтемезме? Шул атасы дин юлында шәһид булган, анасы егерме ел дин өчен Себердә изелгән кешеләрнең баласы кяферме? Әстәгъфирулла! Әстәгъфирулла!

Фәхриҗамал. Әстәгъфирулла! Әстәгъфирулла!

Әхмәдулла. Аллаһе Тәгалә дин дошманына күрсәтмәсен!

Захар *(кызу-кызу килеп, алларына басып)*. Менә мин... Әхмәт! *(Калтырый.)* Менә... мин... сезнең энеңез...

Фәхриҗамал. Кит! Кит! Безнең синең кебек энемез юк, юк, юк... Без мөселман, әлхәмдүлиллаһ, мөселман! *(Үзе еглый.)*

Гайниҗамал *(еглап)*. Карасана күзләренә, бөтенләй Әхмәт! Чын да син Әхмәтмени? Ай бала! Ник син урыс булдың? *(Кычкырып җылый.)*

Зөләйха *(тавышыны күтәреп)*. Җитәр! *(Захарга.)* Җитәр, мин синнән бик күп татыдым. Монысына чы-

дый алмыйм. Кит, үләр алдыннан күземә күренмә! Кяфер! Ләгънәт! *(Габдулла, Әхмәдулла барып Захарны тотмакчы булалар.)*

З а х а р *(идәнгә тезләнеп)*. Мин китмим! Мин сезнең белән, мин синең угылың! *(Туталары янына тезләнеп барып.)* Мин сезнең энеңез! Энеңез!

К ы з л а р. Кит! Кит! Безнең кяфер энемез юк!

З а х а р *(үксеп-үксеп җылап, Зөләйханың кулын тотып)*. Әнкәем! Мин синең угылың!

З ө л ә й х а *(җылаган тавыш белән)*. Минем кяфер угылым юк!

З а х а р. Минме? Мин... мин... кяфер түгел. Мин синең аягыңдагы җәрәхәтеңне фәрештәләр юганнан бирле кяфер түгел!.. Мине кичер! *(Зөләйха тик тора.)*

К ы з л а р *(бердән)*. Әнкәем, кичер!

З ө л ә й х а. Алла кичерсен! *(Кулын акрын гына күтәреп, Захарның башын сыйпарга тотына. Захар җылый. Әнисенең кулларын үбә.)*

З а х а р. Минем гөнаһларымны гафу ит! *(Карчык, бер сүз дәшмичә, кулы белән кочаклап аркасыннан сөя.)*

З ө л ә й х а. Менә Аллаһе Тәгалә ярдәм итте. Угылым да кайтты. Әхмәт тә кайтты.

З а х а р. Кайтты, кайтты!

Ф ә х р и җ а м а л *(Әхмәтне барып кочаклап)*. Әхмәт, Әхмәт, синме? Синме?

З а х а р. Мин! Мин! Сезнеке булдым. Үлгәнче сезнең берлән бергә булырга булдым!

Г а й н и җ а м а л. Карасана, күзләре нинди матур! *(Зөләйха җылый.)*

Г а б д у л л а. Шәехләрнең мәдәде берлән һәр эш Алла кушканча булыр!

Ф ә х р и җ а м а л. Кил, Әхмәт! Кил, утыр, чәй эч!

Г а й н и җ а м а л. Кил, кил! Менә монысы чәкчәк, менә монысы бал, үз умартамыздан.

Ф ә х р и җ а м а л. Менә монысы хаҗ хөрмәсе, менә монысы сумса!

З ө л ә й х а. Мин арыдым! Егерме биш ел үткәргән Себердәге тормыштан артык арыдым. Мине яткырыңыз! *(Кызлар яткыралар.)*

Ә х м ә т. Мин дә, әнкәем, сезнең егерме ел Себердә үткәргәннәрегезне бер кичтә барын да башымнан

үткәрдем. Белсәңез, шулкадәр озын вакыйганы кыска вакытта үткәрү никадәр кыен!..

Кызлар. Мескен! Мескен! *(Фәхриҗамал аркасыннан кага.)*

Гайниҗамал. Җә, чәй эч! Менә боларыннан!

Зөләйха. Аллаһе Тәгаләнең рәхмәте киң икән. Моны да күрермен диеп уйламаган идем. Угылым, кызым янымда, дустым-ишем тирәмдә... Рәхмәт, угланнар, инде мин тынычлап үләм. Беләсезме, балакайлар, бабаңызны, ул һәрвакыт, тынычлап үлсәң иде, әй тынычлап үлсәң иде, диеп дога кыла иде. Мин аны ул вакыт аңламый идем. Хәзер аңладым, менә мин тынычлап үләм. *(Кызлар җыларга тотыналар.)*

Фәхриҗамал. Юк, әнкәем, юк, үлә генә күрмә!

Гайниҗамал *(аягын кочаклап)*. Юк, әнием бәгырем, юк!

Әхмәт. Юк, әнием, үлмә, үлмә!

Габдулла. Тәкъдирдә ни язган, шул булыр!

Зөләйха. Юк, балаларым, үләм, менә сезне күреп шатланып үләм. Мин үләрмен... *(Тыны тыгыла башлый.)* Минем кабергә күмәрлек изгелегем булмаса да, минем тәнем этләргә ташланырга тиеш булса да, бәндәчелек, Алла гафу итсен! Кабергә күмеләсем, мөселман каберенә күмеләсем, анда бабаларыңыз, әбиләреңез белән бергә буласым килә. Мине мөселман каберенә күмеңез! Әхмәт! Сиңа васыятем! Мине урыс каберенә күмдермә!

Әхмәт. Юк, юк, әнкәем, юк, юк!..

Зөләйха. Кил, кил, менә аның өчен... *(Әхмәтнең маңлаеннан үбә.)* Бу шатлыкны үткәрергә котым калмады. Үләм. Кил монда, кияү. *(Аңар кулын салып.)* Рәхмәт сиңа! Балаларыңызны минем өчен үбеңез! Әбиеңез бик күп сәлам әйтте, Коръән укырга кушты, диеңез! *(Тагы торырга теләп.)* Әлхәмдүлиллаһ, моны күрдем. Фәхриҗамал, иреңә сәлам әйт! Бик рәхмәт диеп әйтте диең! Әҗәлгә хәзерләнергә вакыт йитте. Төшемдә бүген хәзрәти Хәдичәне күрдем. Әлхәмдүлиллаһ! Әлхәмдүлиллаһ, бу шатлыкка ничек чыдыйм! Габдулла абзый... *(Теле бәйләнә башлый.)* Кил!

Габдулла килеп тезләнә, һәммәсе тезләнәләр, Габдулла кул күтәрә, тегеләр дә күтәрәләр, ике кызы кулына ятып җыларга тотыналар, тагы еракта музыка ишетелә. Тагы әллә никадәр фәрештәләр күренәләр. Микаил үз фәрештәләре белән Зөләйханы чолгап ала. Микаил барысына да төрле рәхмәт суы сибә. Җырлыйлар. Шул арада Газраил керә.

М и к а и л  в ә  б а ш к а  ф ә р е ш т ә л ә р. Килде! Килде!

Ф ә р е ш т ә л ә р *(Газраилгә тезләнеп)*. Шул хатын балалары-чагалары белән бер генә ел рәхәтләнсен! Әҗәлгә сабырлык бир!

Г а з р а и л *(зур тавыш белә)*. Юк, юк! *(Музыка көен үзгәртә.)*

Ф ә р е ш т ә л ә р. Шул хатын балалары белән чүбердәшеп, бер генә ай торсын! Әҗәлгә мөһләт бир!

Г а з р а и л. Юк, юк!

Ф ә р е ш т ә л ә р. Шул бала, егерме ел анасын күрмәгән, егерме ел чит тәрбиядә үзгәргән бала бер генә атна анасы канаты астында яшәсен! Әҗәлгә мөһләт бир!

Г а з р а и л. Юк, юк!

Ф ә р е ш т ә л ә р. Бер генә көнгә!

Г а з р а и л. Юк! юк!

Ф ә р е ш т ә л ә р. Бер генә сәгатькә, бер генә сәгатькә!

Г а з р а и л. Сулар сулышы Алладан чикләнгән! Юк! Юк!

Ф ә р е ш т ә л ә р *(янына килеп кулларын селкеп)*.
— Мәрхәмәтсез!
— Шәфкатьсез!
— Мәрхәмәтсез!
— Шәфкатьсез!

Газраил канатын җәеп җибәрә. Фәрештәләрнең җылаганы ишетелә. Күк күкрәгән кебек була. Караңгыланып китә, пауза. Бердән яктыра. Зөләйха зур гөлләр белән тулган, әллә никадәр х а т ы н - к ы з, и р л ә р, фәрештәләр көтә торган оҗмахның уртасында күренә.

Б е р  ф ә р е ш т ә *(кычкыра)*. Зөләйха килде! Зөләйха килде! Сайраңыз, кошлар, сайраңыз! *(Музыка тавышы ишетелә.)*

П ә р д ә  т ө ш ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кар белән капланган тигез җир. Сәхнәнең уң ягында якында гына авыл күренә. Өйләрне кар баскан. Авылның биек йирендә ак чиркәү күренә, сул ягында ике маяклы юл китә. Маяклар кардан тун киеп утыралар. Ындыр ягы, салам өемнәре, кибәннәр күренә. Ачык йир ай яктысы белән

---

*Мөһләт* — кичектереп тору.

тулы. Пәрдә ачылганда икешәр ат җигелгән берничә чана, атларның җөгәннәреннән тотып тора торган берничә кеше күренә. Сәхнәнең артыннан атның селкенгәндәге тимер-томырларның шыгырдавы ишетелә. Кешеләрдә тимер сәнәкләр бар.

Габдулла, җегетләр.

Габдулла *(сәхнәнең артыннан чыгып)*. Егетләр, салам артынарак кереп тормыйбызмы? Язмышка каршы, юл югалткан бер урыс килеп чыкмасын.

Бер егет. Чыксын! Атасын, бабасын исенә төшерәсе килсә, чыксын! Менә генә! *(Кулындагы сәнәккә күрсәтә.)*

Икенче егет. Курыкма, курыкма, Габдулла абзый! Алла язмаган эш булмас!

Өченче егет. Килә башласалар, атка утырдык та, ку! Төшләрендә дә күрмәсләр!

Дүртенче егет. Тотсын капчыгыны! Мин Зөләйха әбине алмыйча китмим, үлсәм үләм, алам!

Беренче.
Икенче. } Шулай, мин дә шулай!
Өченче.

Берсе. Әллә син безне курыкты диеп белдеңме? Куркытырсың син моны, куркытырсың! Бәхәсләшеп, җиде төннең уртасында мәсҗедтән мулла таягын алып чыккан кеше бу! *(Берничә кеше арлы-бирле йөреп торалар.)*

Икенче егет. Анда бит мөселман пәрие, ә монда урыс пәрие!

Өченче егет. Яхъя мулла пәрие булса да курыкмыйм! *(Атының муенынан сөеп.)* Әй кашка! Нишләп моңайдың? Шулай, шулай. *(Муенынан сөеп.)* Карап торырга матур булмаса да, *(иптәшләренә.)* бу бит Иделнең аръягында мәйдан тоткан ат!

Икенче егет. Мәйданның арт ягындамы? Менә, исмасам, минем җирәнне сөйлә! Хайванга әле йөрү күп булды, өшәнеп китте. Беркөнне шәһәргә барып чәйгәшикәргә дип өч капчык арыш салдым, шәһәрдә тарттырып кайтырга дип, ике капчык борай төше салдым, солысын, печәнен алдым, юлга чыктым. Үрне менеп киләм, арттан пар атта бер бояр килә, бүре толып киеп утырган! Атларының баскан йиреннән ут чыга! Арттан килеп җитә башлагач та минем җирән пошкыра башлады. Тегеләр килеп җиттем дигәндә генә, менә алып китте ласак! То-

---

*Исмасам* — ичмасам.

тып булмый. Тегенең кучеры: «Юлдан кит!» — диеп кычкыра. Кая ул! Минә ук кебек бара да бара. Теге хурланды булырга кирәк, читкә төшеп узмакчы булды. Ә минем җирән тагы элдермәсенме! *(Атын сөеп.)* Хайван! Шәһәргә кадәр уздырмады. Барып җиткәндә, бояры: «Стой, князь!» — ди. Туктыйм, туктатып булмый, тегеләр туктамыйча туктамады бит. Аттан төште: «Князь, син кай авылныкы? Сат атыңны!» — ди. «Юк, барин, эти-әни төсе, сатмыйм»,— дим. «Менә ал йөз тәнкә!» — ди. «Юк, барин»,— дим. «Ал йөз тәнкә өстенә шул уртадагы атны!» — ди. «Юк, барин»,— дим. Теге: «Кырган баш»,— ди. Менә бу нинди ат!.. *(Иптәшләре көлешәләр.)*

Өченчесе. Синең бояр дигәнең шул йә бер юлаучы булгандыр, йә бер хәерчедер. Минем атым, исмасам, унике сөлге алган!

Габдулла керә.

Габдулла *(кереп)*. Җегетләр, шауламаңыз! Бөтен тавыш авылга ишетелә.

Бер яңы кеше. Ишетелә? Без әллә шулардан курка диеп торасың? Ансы булмас инде! Менә бервакыт урманда җиләк җыеп йөрибез, яшь вакыт, алай да инде миңа мыек чыгып килә башлаган. Мин ул вакыт инде Шәмси кызы Хәернисаның артыннан йөрим, әмма матур кыз иде! Сөйде дә инде мине! Син булмасаң, мин дөньяда тора алмас идем дия иде.

Икенче егет. Бик тора да алмады инде... Түбән авылда гөрләтеп тормыймыни? Дүрт баласы бар.

Яңы кеше. Син яшь әле, энекәш. Тору белән торуның аермасы бар. *(Күкрәгеген кагып.)* Эш йөрәктә, йөрәк нишли!..

Беренче егет. Йә, нишли?

Яңы кеше. Яна, әвен кебек яна.

Икенче егет. Әвен янамыни, әвен төти генә.

Яңы кеше *(кыюланган тавыш белә)*. Синең дә йөрәгең төти генә. Тфү! Егет булган булып йөриләр. Менә, исмасам, без егет идек! Йөрәкләренә мүк үскән! *(Ачуланып китә, егетләр көлә.)*

Ике картрак кеше *(арттан чыгып)*. Җил чыгып тора, әнә анда төн ягында болытлар да бар. Себерсә шәп булыр, чана эзе югалыр иде.

Габдулла *(килеп катышып)*. Шәехләр мәдәд бирсә, бар да булыр. *(Егетләр йөриләр.)*

Б е р  е г е т. Габдулла абзый! Ник бик озак?

Г а б д у л л а. Тәкъдирдә язылган сәгать килеп җитмәгәндер. Монда сулыйсы сулышларымыз бетмәгәндер. *(Чиркәү уникене суга. Габдулла кычкырып саный. Санап беткәч.)* Җегетләр! Хәзер булыңыз! Атларны борыңыз! *(Җегетләр китә. Габдулла белән бер кеше генә кала.)*

Б е р  к е ш е. Угылы мөселман булды диң?

Г а б д у л л а. Китап: «Мөселман каныннан яратылган кеше мөселман була, кяфер каныннан яратылган кеше кяфер була»,— дигән.

К е ш е. Шулай, шулай. Әле шунда йөриме?

Г а б д у л л а. Ул булмаса, без нишли алабыз? Без чиркәүнең рәтен кайдан белик? Хәзрәт әйткән иде, зиярәттән казып алырсыз диеп, Аллаһе Тәгалә ярдәм итте, болай булды.

К е ш е. Әле эш бетмәгән.

Е г е т л ә р *(икесе кереп)*. Бар да хәзер, русларың килсен генә!

К е ш е. Сез, җегетләр, уйнап сөйләмәңез! Бу эш уен түгел.

Б е р  е г е т. Түгел, түгел! Әле менә бервакытны тегермәннән кайтып киләм. Олуг авылның урманына кердем. Буран каплады. Анда да юл бар, монда да, урман улый, җил сызгыра... Буран сөяккә кадәрле үтә.

Сәхнәгә б а р ы  д а керә.

Г а б д у л л а. Хәзер булыңыз!

Б е р с е. Әллә сугыш чыгармы, нәрсә хәзер булыйк?

К а р т р а к  к е ш е. Чыкса да чыгар шул...

Е г е т л ә р *(бары да берьюлы)*. Менә! *(Тимер сәнәкләрне күтәрәләр)*.

Г а б д у л л а. Йа шәехем, мәдәд! *(Егетләргә.)* Күңелләрегезгә Алла исемен төшереңез! Хәзер алып яталар. Алла ярдәм бирсен! *(Пауза.)*

К а р т р а к  к е ш е. Менә җил себерә башлады түгелме? Болар бар да изгеләр догасында. *(Һәммә кеше уңга таба карап тора.)*

Б е р е н ч е  е г е т *(икенчегә)*. Бүген, беләмсең, Сабирларда кызлар җыены, кодачалар килгән.

И к е н ч е  е г е т. Без калдык алай булса.

Б е р е н ч е. Мин, өлгерә алмабызмы әле, дим.

И к е н ч е. Булмый. Ничек була? Минем ат яхшы да

бит, монда Вахит малаеның аты белән бик күпкә бара алмассың, иптәш булгач, калдырып китеп булмый.

Яңы кеше *(болар янына килеп)*. Мине курка диеп белмәңез, мин туңып киттем. Яңа тунны Әхмәди малае кунакка барам диеп сорап алган иде. *(Калтырый.)*

Егетләр. Кармазин тунны кимәдең?

Теге кеше. Сез көлүдән бүтәнне белмисез. *(Китә.)*

Бер кеше. Әнә, мин шәүлә күрдем!

Габдулла. Егетләр, салам артына ышыкланыңыз! *(Бар да качалар, Габдулла кала.)* Йа шәехем, мәдәд! *(Кулын зонтик итеп карый, берәм-берәм тегеләр чыгалар.)*

Кеше. Киләләрме, киләләрме? *(Бары да карый.)*

Бер җегет. Киләләр!

Икенче җегет. Мин Әхмәдулланы күрдем.

Өченче җегет. Әнә бер урыс, ул кайдан килгән?

Теге кеше. У, суык! *(Калтырый.)*

Габдулла. Алладан курык! Алай сөйләмә! Ул угыл синнән-миннән мөселман!

Беренче җегет. Мөселман?

Габдулла. Мөселман! Киләләр, киләләр!

Бер кеше. Атларны караңыз, китмәсеннәр!

Егетләр йөгерешеп чыгалар. Атларның шалтыравы ишетелә. Авыл ягыннан Әхмәт, Әхмәдулла, тагы ике кеше гроб күтәреп сәхнәгә килеп керәләр. Гробны куялар. Бөтен кеше җыела. Тегеләр кайсы яулык белә, кайсы җиңнәре белән тирләрен сөртәләр.

Әхмәдулла. Алла күрсәтмәсен! Җаным чыга язды! Ул чиркәүнең эче! Ул тәре, ул тәре! Бары да кеше кебек карап тора. Әхмәт булмаса беткән идем.

Берсе. Бар да менә кара туткылланып, өскә җикерергә теләгән кебек торалар.

Өченчесе. Бөтен белгәннәремне укып бетердем. Йа шәехем, мәдәд, диеп кенә торам. Ул җен-пәри, ул җен-пәри! Күтәртмәскә телиләр. Алла исемен әйткәч, тагын китәләр. Тагын киләләр, гробның өстенә утырдылар. Күтәрелми дә күтәрелми! Шул чиркәүдән чыкканча, илле еллык картайдым.

Габдулла. Әлхәмдүлиллаһ! Әлхәмдүлиллаһ! Гаиб ирәннәренең ярдәме! Шәехләрнең мәдәде. Егетләр, тиз-тиз, чаналарыңызны монда китереңез! *(Җегетләр чыгып китәләр. Ике атлы бер чана керә.)* Салыңыз! Салыңыз!

Теге кеше *(калтырый)*. У-у, суык!

Габдулла. Нәрсә карап торасыз? Күтәреп салыңыз. *(Әхмәдулла белән тагы берничә кеше күтәреп салалар.)* Җә, бәйлә! Тиз булыңыз! Тиз булыңыз!

Кешеләр *(бәйләргә тотыналар)*. Ай, бу кем?

Куркак кеше качып чыга. Бар да авылга таба карыйлар. Сәхнәгә яланбашлы поп кызы килеп чыга. Әхмәт аңарга каршы бара. Кыз Әхмәтнең кочагына ташлана, кешеләр исләре китеп карап тора.

Кыз. Захар! Захар!

Әхмәт. Маруся, Маруся, җылама!

Кыз. Захар! Захар! Китмә! *(Акырып җылый.)* Мине ташлап китмә!

Габдулла кулы белән кешеләргә бәйләргә ишарә итә. Кешеләр бәйлиләр.

Маруся. Захар, Захар! Үтер мине! *(Аның кулыннан котылып, кешеләр янына чабып бара.)* Мине үтерегез! Мине үтерегез! *(Сәнәкләргә күрсәтеп.)* Шуның белән чәнчеп үтерегез! Ник тик торасыз, үтерегез!

Әхмәт. Маруся, Маруся, сабыр ит!

Габдулла. Безнең диндә кеше үтерү хәрам. Әйдә, утыр атка, безнең кызымыз булырсың.

Әхмәт. Маруся! *(Кулыннан тотып.)* Маруся, аңла мине! Мин кала алмыйм! Мин бөтенләй башка кеше... Мин анам артыннан киттем... Мин булдыра алмыйм... Маруся, мин сине сөям!.. Маруся! Әйдә, минем белән, әйдә!

Маруся. Синең беләнме? Кая?

Әхмәт. Минем берлә, Маруся, минем берлә, әйдә, Маруся! Әйдә!

Маруся *(кочаклап)*. Синең беләме? *(Маруся, Әхмәт үбешәләр.)*

Әхмәт. Минем белән, үлгәнчегә кадәр минем белән...

Маруся. Әйдә! Әйдә!..

Габдулла. Тизрәк, атлар!

Тагы бер ат килеп керә. Габдулла Марусяның башын сыйпый. Маруся Әхмәтнең кулыннан тоткан килеш җылый.

Әхмәт. Утыр, Маруся!

Габдулла. Тукта, тукта, менә шушы толыпны ки! *(Өстеннән толыбын салып бирә. Әхмәт Марусяга толып кигезә.)*

Бер егет *(икенчегә)*. Сөя дә икән, малай!

Маруся утыра. Әхмәт Маруся янына утыра.

Габдула. Хәзерме?
Җегетләр. Хәзер!

Бары да атларына менәләр. Гробны алып чыгып китәләр. Әхмәтнең атлары кузгала башлый. Маруся сикереп тора.

Маруся. Юк, мин бара алмыйм! Юк, юк!

Әхмәт төшә, Габдулла атны туктата.

Әхмәт. Маруся, Маруся. Син мине үтерәсең! Маруся!

Маруся. Юк! Юк! *(Әхмәтне кочаклап үбәргә тотына.)*

Әхмәт. Маруся, Маруся!

Маруся *(котылып китеп)*. Прощай, прощай!* *(Китеп югала.)*

Әхмәт аның артыннан чанада «Маруся» дип кычкырып җылый.

Габдулла *(тышка таба)*. Туктаңыз! Туктаңыз! *(Килгән кеше күренми. Әхмәтнең янына барып.)* Ай бу яшьлек! Урынын да белми, көнен дә белми, кайда вакыты җитсә, шунда тишелеп чыга. *(Әхмәткә барып.)* Әхмәт! Әхмәт! Бала, тор! Тор! *(Әхмәт дәшми.)* Тор! Тор! *(Габдулла Әхмәтне күтәрмәкче була. Күтәрә алмый.)* Хәлем дә беткән бит! *(Чыгып китеп.)* Әй, әй, җегетләр! *(Чиркәүдә набат сугыла башлый; Габдулла тагы Әхмәтнең янына барып өстери башлый, булдыра алмый.)* Әхмәт! Әхмәт! Киләләр! Әхмәт! *(Өстери. Чана янына табарак китерә. Авылда этләр өрә башлый. «Пожар!», «Пожар!» — дигән тавыш ишетелә. Чиркәү һаман кага. Әллә никадәр кешенең тавышы ишетелә.)* Йа шәехем, мәдәд! Әхмәт! Әхмәт! Бала, тор! Киләләр!

Әхмәт *(башын күтәреп)*. Кемнәр килә?

Габдулла. Урыслар киләләр, безне үтерергә киләләр.

Әхмәт. Киләләр?.. *(Әхмәт акрын гына тора. Тавыш якынлаша.)*

---

*Бу сүз оригиналда рус хәрефләре белән басылган.

Т ы ш т а н. Әнә алар, әнә алар!

Сәхнәгә казыклар, сәнәкләр күтәреп, ун-унбиш у р ы с, әллә никадәр м а р җ а килеп керә. «Үтер! Үтер!» — дигән тавышлар ишетелә. Кыйнарга башлыйлар. Элгәре Габдулланың: «Йа шәехем, мәдәд!» — дигәне ишетелә. Аннан кыйнау ишетелә. Халык күбәя бара, тавыш зурая бара. М а р у с я килеп чыга. Кыйнаучыларга барып: «Чү, чү, тр»,— диеп кычкыра. Халык туктый.

М а р у с я. Захар, Захар! *(Өстенә егыла. Җылаган тавыш белән.)* Үлгән, үлгән! Захар, Захар! *(Каплана. Кешеләр тик торалар. Хатыннар күзләреннән яшьләрене сөртәләр.)*

Г а б д у л л а *(башын калкытып, акрын гына)*. Әлхәмдүлиллаһ! Әлхәмдүлиллаһ! Дин юлында безгә дә шәһид булырга яздың!..

Б е р р у с. Ни сөйли? Үтер, үтер! *(Берьюлы биш-алты кеше казыклар белән кыйный.)*

М а р у с я *(сикереп торып, Әхмәткә күрсәтеп)*. Сез үтердеңез! Сез үтердеңез! Мин үтердем... Сез үтердеңез!..

Набат туктамый. Халык күбәя.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ИСКӘРМӘЛӘР

Бу томга Г.Исхакыйның 1900—1918 елларда басылып чыккан тугыз драма әсәре урнаштырылды. Дөрес, Г.Исхакый чит илгә чыгып киткәнче барлыгы ун пьеса язган. Аның Кызылъярда (Петропавелда) язылган «Юлсызлар» исемле пьесасы хакында әдипнең кызы Сәгадәт Чагатай 1989 елның 17 апрелендә төзүчегә язган хатында болай дигән иде: «[Этием] «Юлсызлар» әсәрен 1918—1919 елда Сибириядә «соң язган китабым» дип артист Абдулла Карига тәслим итеп китүен сөйләр иде...» Бу пьесаның «Салих хаҗи балалары» исеме белән Казанда, Әстерханда куелып йөрүе турында гәзитәләрдәге хәбәрләрдән һәм өлкән буын кешеләрнең истәлекләреннән белә алсак та, кызганыч, әсәр китап булып та басылмаган, әлегә кулъязмасын да таба алмадык. Бу пьесада сүз әсәрнең төп герое сәүдәгәр Салих хаҗиның, байлык артыннан гына куып, балаларын юньләп тәрбияли алмавы һәм шуның нәтиҗәсендә яшьләрнең юлдан язулары турында бара.

Г.Исхакый пьесаларының күбесе әдипнең төрмә, сөрген чорларында язылган. Пьесаларның барысы да иртәме-соңмы сәхнәдә уйналган, ләкин автор аларның кайберләрен генә күрә алган. Спектакльләрдән килгән каләм хакы юк дәрәҗәсендә булган. Язучы үзенең гарәп хәрефләре белән төрек телендә язылган, берничә вариантта каралама килеш сакланган «Тәрҗемәи хәлем»ендә сөргеннән качып йөргән елларын тасвирлап болай яза: «Театр әсәрләремне Габдулла Кари җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасына тапшырдым. Ләкин Уфадагы, Әстерхандагы, Оренбургтагы труппалар да әсәрләремне сәхнәгә куялар иде. Әмма минем «Сәйяр» труппасыннан каләм хакы алмавымны белеп, алар да бернәрсә дә бирмиләр иде. Петербургта ялган паспорт белән яшәгәнгә күрә матбугатта мәкаләләр язып акча табу мөмкинлеге дә юк иде. Даими акчага кытлык хәлендә яшәдем. Ике ел ялган исем белән дәвам иткән хосусый бер хокук факультетының дәресләрен дә ташларга мәҗбүр булдым».*

Г.Исхакый инде сөргеннән кайткач та, иректә йөргәндә дә үзенең сәхнәгә куелган әсәрләре өчен каләм хакы алмаган

---

*Томда текстлар, «Тәрҗемәи хәлем»нең төрле вариантларыннан алынып, ирекле тәрҗемәдә бирелә.

*Тәслим итү* — тапшыру, бирү.

дияргә мөмкин. Ф.Әмирхан Г.Исхакыйга багышлап үткәрелгән кичәдән болай яза: «Ул Казанның эшләрлек көче зур икәнен, шул көчне яхшы беректерерлек бер милли гомуми бинага ихтыяҗ зур икәнен сөйләп, «Ирек йорты» салу фикере чыгуын тәбрик итте... башлангыч буларак, үзенең «Тартышу» исемле әле басылмаган пьесасыннан киләчәк бөтен театральный гонорарын «Ирек йорты» наменә һәдия иткәнлеген игълан итте... Бераздан «Ирек йорты»ның иганә фиһристенә язылган акчаларның ун мең сумнан артканлыгы игълан ителә. (Гаяз әфәнде шәрәфенә.— Кояш, 1917, 11 апрель).

Г.Исхакый пьесалары 1906 елдан алып егерменче еллар башына кадәр сәхнәдән төшми уйналган. Алар төрле елларда Казан, Уфа, Оренбург, Чистай, Эстәрлетамак, Уральск, Түбән Новгород, Әстерхан, Мәскәү, Ташкент, Андижан шәһәрләрендә тамашачыларга күрсәтелә. Г.Исхакый пьесаларын сәхнәдә иң күп куючы «Сәйяр» труппасы артистлары була. Рус театрларыннан үрнәк алып, артистлар бенефислар үткәрә башлыйлар, үзләренең бенефисларына Г.Исхакыйның әсәрләрен сайлыйлар. Мәсәлән, «Алдым-бирдем» С.Гыйззәтуллина, «Мөгаллим» В.Мортазин, «Мөгаллимә» Г.Болгарская, «Зөләйха» Г.Кариев бенефисларында уйнала.

«Сәйяр» труппасы, шулай ук «Ширкәт», «Нур» труппалары, һәвәскәр коллективлар куйган спектакльләр турында матбугатта бик күп мәкаләләр дөнья күрә. Аеруча «Алдымбирдем», «Мөгаллимә», «Зөләйха» спектакльләре турында күп языла. Ләкин бер җәһәткә игътибар итәргә туры килә: күпчелек рецензияләрдә сүз чынында исә Г.Исхакый пьесалары турында түгел, ә сәхнәдә уйналган спектакльләр турында бара. Ул замандагы театрларның хәлен, үз бинасы булмыйча, төрле җирләргә күченеп йөрүләрен, матди һәм техник мөмкинлекләрен, профессиональ артистларның аз булуын истә тотканда, бәяләмәләрнең кемгә — авторгамы, әллә уйнаучыларгамы адреслануын ачыклау кыен.

Г.Исхакый турында күпме генә язылмасын, әмма чын анализ — тәнкыйтьләрнең әлегә күренмәвен Җ.Вәлиди билгеләп үтә: «Гаяз әфәнде аңлы язучыларымыз вә укучыларымыз тарафыннан тәкъдир һәм ихтирам ителә... Анда һәркем әллә нинди яшерен хәзинәләр барлыгына ышана. Ләкин ул яшерен хәзинәнең эчендәге нәрсәләргә һичбер бәһа куелган юк. Матбугатымызда Гаяз әфәнде хакында күренгән фикерләр, мөхакәмәләр, әйтергә яраса, тәнкыйтьләр бик өстән һәм бик бертарафлы... күбесе аны мактау яки яманлаудан башка бернәрсә аңлатмый... Мин әлегә Гаяз әфәнде хакында мөкәммәл бер тәнкыйть көтмим. Шулай да аның әһле каләм тарафыннан искә төшерелә торуын җиддән арзу итәм. Бәгъзе бундай

---

*Иганә* — ярдәм.
*Фиһрист* — исемлек.
*Әһле каләм* — каләм ияләре, язучылар.

искә төшерүләр арасында яхшы гына сүзләр сөйләнә». (Җәләй.— Гаяз әфәнде.— Вакыт, 1913, 5 март).

Г.Исхакый драмалары татар театрын үстерүдә зур роль уйный. Татар профессиональ театр тарихы аның пьесасын («Өч хатын берлән тормыш»ны) сәхнәгә кую белән башланса, татар сәхнә сәнгатендә беренче тапкыр махсус музыка да Солтан Габәши тарафыннан Г.Исхакыйның «Зөләйхасына языла.

Драматургның теле ягыннан аңлаешлы, темалары белән халык тормышына якын булган пьесалары милләттәшләрендә милли аңны уятуга хезмәт итә. Спектакльләргә халыкның күп йөрүе шул турыда сөйли. Г.Исхакый пьесалары Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина, Г.Болгарская кебек сәхнә йолдызларын, алар артыннан башка күп сәхнә осталарын җитештерүдә, үстерүдә зур этәргеч була. Бу артистларны бүгенге профессиональ татар театрының нигезен салучылар, аның максатын, юлын билгеләүчеләр дип атыйбыз икән, монда Г.Исхакыйның да өлеше бар дигән сүз.

Г.Исхакый пьесалары татар театры репертуарыннан кайчан төшә соң? Билгеле булганча, әдип 1919 елда инде чит илдә була. Ул киткәч, пьесаларының сәхнәдә кайчан куелуы турында матбугаттагы хәбәрләрдән белә алабыз. 1922—1923 ел сезоны репертуарына эмигрант Гаязның «Салих хаҗи балалары», Г.Исхакыйның соңгы әсәре дип, гәзитәнең беренче битендә... афишалар ике тапкыр куела. Аның янына шул ук кешенең «Алдым-бирдем»е килеп баса... 23—24 елда сезон «Салих хаҗи балалары» белән ачыла. Шулар янына... «Җәмгыять», «Кыямәт»...ләр тезеләләр (Зәки Мөхсинов.— Татар дәүләт академия театры.— Казан.— 1930, 15 б.).

Менә шул еллардан соң Казанда Г.Исхакый пьесаларын кую туктала. Аларның Әстерханда, Ташкентта, шулай ук байтак еллар авыл сәхнәләрендә уйналуы билгеле.

Г.Исхакыйның иҗатын кабат үз халкына кайтару эше туксанынчы еллар башында активлашты. 1991 елда әдипнең «Зиндан» җыентыгы басылып чыкты. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры 1992 елдан башлап шул җыентыкта басылган өч пьесаны Празат Исәнбәт режиссерлыгында сәхнәләштерде: «Зөләйха» (1992) «Алдым-бирдем» (1994), «Җан Баевич» (1995). Тамашачы аларны зур кызыксыну белән карады, яратып кабул итте. Башкортстандагы «Нур» татар дәүләт театры да «Зөләйха»ны тамашачыга күрсәтте (1994, режиссеры Байрас Ибраһимов).

Г.Исхакыйның күп кенә хикәяләре, повестьлары, романнары темасы һәм сюжеты белән сәхнәдә уйнарлык һәм кинофильмнар төшерерлек әсәрләр. Беренче булып әдипнең бер

---

*Җиддән* — чынлап.
*Арзу иту* — теләү.

повестен — «Көз»не Башкортстандагы «Нур» татар дәүләт театры сәхнәләштерде (1996, сценарий авторлары Фәрит Бикчәнтәев, Илтөзәр Мөхәммәдгалиев; режиссеры Ф.Бикчәнтәев). 2002 елда Чаллы татар дәүләт драма театры Г.Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» хикәясен сәхнәгә куйды (сценарий авторлары Ренат Әюпов, Руслан Садриев; режиссеры Р.Әюпов). Хикәянең басылып чыгуына 100 елдан артык вакыт үтсә дә, спектакльдәге вакыйгалар бүгенге тормышыбыздагы хәлләргә бик аваздаш булып яңгырый.

Г.Исхакый пьесалары һәркайсы аерым китаплар булып басылган. Пьесалар техник эшләнеше ягыннан укыр өчен шактый кыен. Сәхнә күренешләрен, персонажларның хәрәкәтләрен тасвирлаганда, сүзләрен биргәндә бер-берсенә керешеп, буталып киткән урыннар бар. Пьесаларда кайбер геройларның исемнәре «катнашучылар» исемлегендә күренми яисә гомумиләштерелеп («кешеләр», «егетләр» һ.б.) бирелә. Шулай ук бер үк персонажны һәм аның сүзләрен рәттән берничә тапкыр бирү дә еш очрый. Текстлар мөмкин кадәр хәзерге заман кагыйдәләренә — драмаларны техник яктан кору тәртипләренә туры китереп хәзерләнде.

Әсәрләр төрле елларда язылган. Шуңа күрә язылышта, әлбәттә, төрлелек күзәтелә. Һәр әсәрдә язылыш төрләре оригиналдагыча калдырылды. «Җ»ләштерү — «й»ләштерүдә эзлеклелек юк, бер үк сүз «җ» белән дә, «й» белән дә язылган (мәсәлән, җир-йир), алар бертөрлегә әйләндерелмәде, ә бәлки ул чорда телдә орфография нормаларының эшләнмәгән булуын, язылыштагы тотрыксызлыкны күрсәтү өчен төп текстта-гыча калдырылды. «Яңы-яңа», «исмасам-ичмасам» һ.б.ш. ике төрле язылыштагы сүзләр дә унификацияләнмәде, төп нөсхәдәгечә бирелде.

5 бит.

**Өч хатын берлән тормыш** — Драманы басарга рөхсәт С.-Петербургта 1900 елның 20 ноябрендә бирелә. Казанда Б.Л.Домбровский типографиясендә 1900 елда басылып чыга. 56 бит. Имза: Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый. Әсәрнең икенче басмасы кереш мәкалә («Мөкаддимә») белән Казанда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкәсе» наширлегендә И.Н.Харитонов типографиясендә 1912 елда басыла. 59—120 битләр. Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның сигез томлык «Мәҗмугаи асар»ендә 3 нче җилд, 2 нче китап. «Мөкаддимә»нең ахырына «Пинега, 6 май, 1908 ел» дип куелган. «Мөкаддимә»дә автор «вак-төяк гыйбарәләрне төзәтүдән үтмәенчә, бөтен тасвирларымны элгәрегечә калдырдым» дип яза. Бу «вак-төяк төзәтүләргә нәрсәләр керә соң? Аерым сүзләрне алмаштырып кую: мәсәлән, «келәү», «берлә», «ласа» кебек сүзләр икенче басмада «теләү», «белән», «ләбаса» дип язылган; чыгтай шәклен куллану: «күзен», «хатыннарын», «гомерен» һ.б. сүзләр «күзене», «хатыннарыны», «гомерене» һ.б.

булып килә. Беренче басмада «җ» белән язылган (җабып, җибәреп, җук, җә) сүзләре «й»гә (йабып, йибәреп, юк, йә) үзгәргән. Шулай ук «утызлар чамасында» гыйбарәсен «утыз яшьләр чамасында», диалогта «Мәрьям» урынына «асрау кыз» дип күрсәтә һ.б. Шулай итеп, драманың икенче басмасында техник һәм стилистик яктан аз гына төзәтүләр күзәтелә.

Әдип «Тәрҗемәи хәлем»ендә болай яза: «Русча һич белмәгән вакытымда [«Күл буе» мәдрәсәсендә укыганда] беренче тапкыр Казанның русча театрына киттем. Караган әсәрем «Блуждающие огни» иде. Телен аңламасам да, формасын һәм эчтәлеген күзәттем һәм театр ысулындагы әдәбиятның әһәмиятен аңладым. Бездә дә театр әсәрләре булырга тиеш дип илһамланып, «Өч хатын берлән тормыш»ны яздым. Бу һәм моңа кадәр язган әсәрләрем госманлы әдәбияты тәэсирендә язылган әсәрләремдер».

Матбугатта әсәр турында фикерләр беренче тапкыр 1906 елның 21 апрелендә Уфада Приказчиклар клубы сәхнәсендә уйналганнан соң күренә башлый... «Казан мөхбире» гәзитәсе болай яза: «Безнең Агыйдел, Волга буйларында яшәгән кардәшләрнең әүвәлдә вә хәзергә кадәре өстерәлеп килгән кызганычлы вә бик аянычлы көн итешләрене, шәригатемез сыйдырмаган вә инсаният намусы яхшы санамаган [күп хатынга өйләнү] фәкать ирләрнең тәрбиясезлегеннән килгән бер начар гадәт икәне бик яхшы тасвир ителде... Яшәсен менә яңа гына терелә башлау, кергән начар гадәтләрне ташлау!» (Уфалы Габдулла бине Габдерахман.— Уфада, Агыйдел буенда яңа терелә башлау, яисә төркичә телдә театру.— Казан мөхбире, 1906, 30 апрель.) Мәкалә авторы бу спектакльнең фәкыйрь һәм мохтаҗ шәкертләр файдасына куелуын искәртә.

Казанда исә яшьләр бу спектакльне 1906 елның 8 декабрендә Яңа клубта куярга теләсәләр дә, ниятләре барып чыкмый. Цензор Н.Ашмаринның «әсәрдә гаепкә алырлык берни дә юк» дигән белешмәсе булуга карамастан, губернатор куярга рөхсәт бирми (ТМА, 1 ф., 4 тасв., 2090 эш, 332—340 кәгазьләр). «Казан мөхбире» гәзитәсендә (1907, 18 февраль) «Өч хатын берлән тормыш»ның Казанда беренче тапкыр Яңа клуб залында «Императорский университет һәм Ветеринарный институт фәкыйрь мөселман студентлары файдасына» 1907 елның 13 гыйнварында куелуы турында хәбәр бар.

11 апрельдә Казанда махсус хатын-кызларга багышланган спектакль куела. Моның өчен Г.Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш» драмасы сайлап алына. Спектакльдә уйнаучылар да, тамашачылар да хатын-кызлардан гына гыйбарәт була. (Тавыш, 1907, 23 апрель).

Ф.Әмирханның «Тәрбияи әтфаль» журналының 1907 ел, 1 гыйнварында балаларга мөрәҗәгать итеп басылган мәкаләсендә мондый юллар бар: «Бу драманы укыган вакытта мәгыйшәтемезнең иң караңгы вә иң куркыныч якларын күреп, күңелеңезгә ихтыярсыз бер кайгы вә уңайсызлык килер. Ихтыяр-

сыз мондый үзләренең әхлаксызлыклары белән әллә никадәр гөнаһсыз кешеләрне җәзага салучыларга ачуыңыз килер вә мондый мәгънәсез вә рәхәтсез мәгыйшәткә дошманланып, бер егълыйсыңыз вә бер хурланып көләсеңез килер вә күңелеңез зыя, зыя, зыя ягына очарга ашыгыр».

«Өч хатын берлән тормыш»ның 1913 елның 12 августында Әстерханда Зәйни Солтанов, Сәгыйть Рәмиев катнашлыгында сәхнәгә куелуы турында да хәбәр бар (Габделгалим.— Татарча театр.— Идел, 1913, 27 август).

Драманың беренче тапкыр сәхнәдә уйналуына ун ел тулуга багышлап язган мәкаләсендә Фатих Сәйфи-Казанлы «Ул заманда театр әсәрләрен язучылар да, шул яңа әсәрләрне химая кылучы яшь фикерчеләр дә «театр гыйбрәт йорты» булырга тиешкә ышанганга, һәрбер театр әсәрләреннән гыйбрәт, «гөнаһсына күрә җәзасының булуы» көтеләдер иде,— ди.— Вакыйган, «Өч хатын берлән тормыш» драмасы беренче күренештән башлап актыгына кадәр яшькә, канга буялган гыйбрәт иде... Халыкның фикеренә тәэсире, шөбһәсез, җилд-җилд хатын-кыз мәсьәләсендә язылган китапларның тәэсиреннән бик күп артык вә бик күп көчле иде?! («Өч хатын берлән тормыш». Милли сәхнә төзелүне искә төшерү мөнәсәбәте илә.— Тормыш, 1916, 24 сентябрь.)

Г.Исхакый 1910 елның 19 декабрендә Максим Горькийга язган хатында «Знание» җыентыгына дип «Алдым-бирдем» пьесасының тәрҗемәсен («Брачный договор») җибәрүен хәбәр итә һәм пьесага бәяләмә бирүен үтенә. Әдипнең М.Горькийга язган башка хатларыннан аңлашылганча, М.Горький аңа татар телендә басылган үз әсәрләрен һәм башка татар язучыларының уңышлы әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп бер җыентык хәзерләргә киңәш бирә. «Тормышмы бу?» повестеның тәрҗемәсен җибәрүен үтенә һәм «Өч хатын берлән тормыш» пьесасын да тәрҗемә иттерүне мәгъкуль күрүен әйтә. Татар әдәбияты үрнәкләре тупланган ул русча җыентыкның басылып чыгуы билгеле түгел. Шулай ук Г.Исхакыйның «Тормышмы бу?» повестеның тәрҗемәсен М.Горькийга юллавы мәгълүм. Ләкин ул русча беркайда да басылмаган. «Өч хатын берлән тормыш» драмасының русчага тәрҗемә ителүе турында мәгълүматлар юк.

«Өч хатын берлән тормыш» драмасы — Г.Исхакыйның беренче сәхнә әсәре. Алда әйткәнебезчә ул, шулай ук, театр белгечләренең фикеренчә, татар театры тарихында зур сәхнәгә чыгарылган беренче рәсми спектакль, ягъни татар профессиональ театрының тарихы Г.Исхакыйның шул драмасын сәхнәгә куюдан башлана.

Текст әсәрнең икенче (1912 елгы) басмасыннан алынды.

---

*Зыя* — яктылык, нур.
*Химая кылу* — яклау.

6 бит.

*Печән базары* — XVIII гасырның икенче яртысында барлыкка килә һәм 1930 елларга кадәр яши. Казанның хәзерге Киров, Париж Коммунасы һәм Татарстан урамнарының шактый өлешен биләп, татар байларының эреле-ваклы кибетләре, складлары, харчевнялары белән беррәттән, гәзитә-журнал редакцияләре, «Болгар», «Амур», «Сарай» кебек Г.Тукай, Ф.Әмирхан һ.б. күренекле кешеләр яшәгән кунакханәләр дә шунда урнашкан булган. Татарлар өчен яңалыклар белән уртаклашу, хәбәрләшү үзәге булып киткән бу атаклы базар һәм аның халкы — сатучылары, алучылары, гайбәтчеләре, алдакчылары Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Исхакыйларның әсәрләрендә тәнкыйть һәм сатира объекты булып хезмәт итәләр.

Җамал Вәлиди болай ди: «Печән базары» дигәч тә, гади бер печән сата торган урын дип уйларга ярамый. Анда татарның әдәби, икътисади хәяты тәмәркәз итә. Ул татар тормышының иң җанлы бер сәхнәсе. Анда безнең көленерлек, хурланырлык йиремез никадәр күп булса, мактанырлык, куанырлык йиремез дә шундадыр. Шуның өчен инде «Печән базар»ы дигән сүзне һәрвакыт бер истихкар вә истиһза мәкамендә кулланудан туктарга вакыт! (Бер ел узгач.— Вакыт.,— 1914., 6 февраль.)

11 бит.

*Аршын* — метр системасы кертелгәнгә кадәрге озынлык үлчәү берәмлеге, 71 сантиметрга тигез.

14 бит.

*Штоф* — тукып рәсем төшерелгән авыр ефәк яки йон тукыма.

15 бит.

*Бака кашыгы* — кабырчык эчендә яши торган су хайваны — анадонтаның кабыгы, кабырчыгы.

18 бит.

*Икенде* — төштән соң, кояш баеганчы укыла торган намаз.

19 бит.

*Ташаяк* — Казанда Болакның борылган урыны белән Кремль калкулыгы арасында (Болакның сул ягында) 15 га-

---

*Тәмәркәз итү* — туплану.
*Истихкар* — түбән күрү, хурлау.
*Истиһза* — көлү, мыскыл итү.
*Мәкамендә* — урынында.

сырда барлыкка килгән ярминкә. Идел буенда яшәүче сәүдәгәрләр генә түгел, Урта Азия, Кавказ, Кырым, Иран, Төркия сәүдәгәрләре дә килеп сату иткәннәр. 15-16 гасырларда Идел буенда төп ярминкә саналган. Сәүдәгәрләрдән алынган пошлинаны — акчалата җыемны мәйдан уртасына куелган таш савытка — таш аякка салып барганнар. Ярминкәнең исеме шуннан алынган.

1524 елда сәүдә үзәге буларак Казанның әһәмиятен киметү өчен кенәз Василий III рус сәүдәгәрләренә Казан ярминкәләрендә катнашуны тыя һәм төп ярминкә Түбән Новгород янындагы Мәкәрҗә бистәсенә күчерелә. Ташаякта исә ярминкәләр һәр елны яз көнендә (май аенда) гына үткәрелә башлый. Элек Ташаяк ярминкәсе булган мәйдан хәзер Ярминкә мәйданы дип атала.

*Зәкят* — дин буенча, һәр мөселманга еллык керемнең 40 тан бере күләмендә салынган еллык налог.

*Сарт* — үзбәкләрне шулай атаганнар.

29 бит.

*«Казан алган көй»* — «Казан көе», «Кала алган көй» дигән исемнәр белән дә йөргән татар көе.

Махсус әдәбиятта бу көйне «Казан бәете» исемле бәет белән бәйлиләр. Г.Рәхим, мәсәлән, бәетләр бер вакыйгага махсус көй белән чыгарылып, вакыйга онытылгач, җырга әйләнеп китәләр, ди (Халык әдәбиятымызга бер караш. Казан. 1915, 74 б.) К.Насыйри бу бәет «кадимнән ишетелә килгән, языла килгәндер»,— дип яза. («Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре». Казан. 19125, 14 б.) «Казан бәете» көен 1897 елда Уфа губернасы Бәләбәй өязе Курчеево авылында Н.Ф.Катанов та ишеткән. «Казанның руслар тарафыннан алынуы турындагы җырның көен миңа керәшен татарлары — берсе скрипкәдә, икенчесе гөсләдә уйнады. Ә сүзләрен беркем дә белми иде». (Исторические песни казанских татар. Казань. 1899, 5 б.) А.Ключарев «Казан көе» хакында: «XIX гасыр урталарына карый торган иске көй, «Порт-Артур» дигән өстәмә исеме дә бар, «Порт-Артур» буларак башкарылганда 1904—1905 еллардагы рус-япон сугышы белән бәйле рәвештә үз текстына җырлана,— ди һәм көйнең сүзләрен бирә:

Казанга туп аталар,  
К(е)репостьне ваталар,  
Каршы килгән дошманнарга  
Тау башыннан аталар.

(А.Ключарев.— Татар халык көйләре.— Казан. 1986, 470 б.)

Кышкар мәдрәсәсе шәкерте Гасыйм Лотфи мәдрәсәдә «күңел ачу» кичәләрен тасвирлаганда бер сабакташы турында: «Ул, гадәттә, «Казан алынган көй»гә бии:

Балалар балалар, таш каланы алалар,
Кергәнегез керегез, чыкканыгыз чыгыгыз,—

дип салмак кына җырлап, ун пар йодрык барабан кага башлагач, Мансурыбыз ике бөеренә таянып, башын кырынайтып мәйдан тирәли йөзеп китә»,— дип яза (Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. Казан, 1992, 164 б.).

Галим Җәмил Зәйнуллин «Казан алынган көй»нең «Фаҗигаи Казан» дип исемләнгән вариантын (сүзләре белән бергә) Татарстанның Чирмешән районының Иске Кади авылында язып алган. Анда шундый юллар бар:

Моннан дүрт йөз еллар әүвәл нинди заманнар бар иде.
Ятка хезмәт итми идек, үз ханыбыз бар иде.
Дошман дигән бәдбәхетнең җирләре бик тар иде,
Башкаларның кенәзенә безнең татар хан иде.

(Хан кызы.— Казан. 1994, 58 б.). Әсәрнең «Ханымнар, калкыңыз!» исемле вариантын фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗанов «Шәһри Казан» гәзитәсендә бастырып чыгарды.

31 бит.

*Духовный собрание* — Дини идарә (Диния нәзарәте). Екатерина II Указы белән 1789 елда Уфада төзелә. Ул елларда Уфа воеводасы Оренбург губернасына кергән, шуңа күрә нәзарәт Оренбург диния нәзарәте дип йөртелгән. Аның башында мөфти торган.

*Гыйддәт* — ирсез калган хатынның икенче иргә бармый торырга тиешле булган вакыты. Биредә сүз шул вакыт аралыгында ялгыз яшәгәндә кирәк булачак матди ярдәм турында бара.

*Аресный* (арестный) — судка кадәр ябып тоту урыны; төрмә.

33 бит.

*Мәкәрҗә* — Түбән Новгород янындагы Макарьево бистәсендә урнашкан ярминкә. 1524 елда Василий III рус сәүдәгәрләренә Казан базарларына чыгуны тыйгач оештырыла. Ярминкә ел саен июль-август айларында эшләп килә. Руслардан, татарлардан тыш, Мәкәрҗә ярминкәсенә Урта Азия, Кавказ, Һиндстан, Иран сәүдәгәрләре дә киләләр. Мех, тире, металлдан эшләнгән әйберләр, тукымалар һ.б. белән сату итәләр. 1817 елдан ярминкәнең рәсми исеме «Түбән Новгород» ярминкәсе» дип алмаштырылса да, халык телендә элеккечә «Мәкәрҗә ярминкәсе» дип йөртелә.

Г.Исхакый «Тәрҗемәи хәлем»дә Мәкәрҗә ярминкәсен түбәндәгечә сурәтли: «Соңгы елларда Төркестан, Сибирия сатучылары үзләренең сатулары өчен кирәк булган дәфтәрчеләрне, бухгалтерны, мәхәлләләре өчен кирәк булган мөгаллим,

мөгаллимәләрне дә моннан алып китә иде. Шуңа күрә ярминкәнең ахырына таба Мәкәрҗәгә эш эзли торган бик күп зыялы Идел-Урал яшьләре дә тула иде. Яшь милләтче урта хәлле сәүдәгәрләр безнең китапларымызны сата, безгә икътисади таяныч була иде. Мәкәрҗә ярминкәсе безнең бөтен Русия мөселман зыялыларыбызның фикер алышу, аңлашу җире булды һәм милли бәхәсләребезнең фикер базары хәлен алды. Шуңа күрә мин үзем һәм минем фикердәшләрем һәр елны Мәкәрҗәдә айларга кала идек, анда иң мөһим мәсьәләләребезне мәйданга ата идек. 1905 ел революциясеннән соң Идел-Уралның бөтен гәзитәчеләре Мәкәрҗәдә абүнәче туплый, Казан театрлары Мәкәрҗәгә ташына, шагыйре, әдибе Мәкәрҗәдә яңа әсәрләрен укый, драматурглары яңа драмаларын беренче тапкыр уйната. Шулай итеп, Мәкәрҗә Русия мөселманнарының, шул исәптән Идел-Урал төрек-татарның фикер, гыйлем, сәнгать үзәгенә әйләнгән иде».

Мәкәрҗә ярминкәсе 1917 елга кадәр яши.

34 бит.

*Мәүлед бәйрәме* — Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне бәйрәме. Ай елының өченче — рабигыль әүвәл аеның 12 сендә үткәрелә.

*«Хәмде бихәдд»* — китап исеме. Мәдрәсәләрдә дәреслек булып йөргән.

*«Дарелмәҗалис»* — («Мәрҗәннәр энҗесе»), Сәйфе Баһар бине Борһанетдин Нәүбаһарның суфыйлык буенча китабы. Татарлар арасында популяр әсәр булган.

36 бит.

*Вексель* — бурычка алган акчаны билгеләнгән вакытка кире кайтару турында бирелгән язма йөкләмә.

37 бит.

*Залог* — өскә алынган бурыч яки ссуданың ышанычлылыгын тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт.

*Окружной суд* — Октябрь революциясенә кадәрге Россиядә ике-өч өяздән торган округта эш итүче суд органы.

*Повестка* — чакыру кәгазе.

42 бит.

*Доверенный* — ышанычлы, ышанып эш тапшырылган кеше.

43 бит.

*Кыйбла* — шәригать буенча мөселман намазны йөзен Мәккә шәһәрендәге Кәгъбәгә юнәлтеп укырга тиеш. Коръәннең 2 нче «Бәкара» («Сыер») сүрәсенең 143 аятеннән күренгәнчә, Ислам диненең башлангыч чорында мөселманнар Бәйтелмө-

катдәстәге (Иерусалим шәһәрендәге) әл-Акса («Иң ерак мәчет») юнәлешенә карап намаз укый торган булганнар. (Гарәп телендә Иерусалим шәһәренең күп санлы исемнәреннән берсе — «Беренче кыйбла»). Ә инде Мәккәдәге Кәгъбә мөселманнарның изге урыны дип кабул ителгәч — намазны Кәгъбә ягына таба карап укуны канунлаштырганнар. Үлем түшәгендә яткан яки үлгән кешене дә йөзен кыйбла ягына борып яткыралар.

45 бит.

**Ике гашыйк.**— Комедияне басарга рөхсәт С.-Петербургта 1902 елның 20 мартында бирелә, Оренбургта М.-Ф.Кәримов типографиясендә 1903 елда басылып чыга. 77 бит. Имза: Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый. Титулда «Казан халкы тормышыннан» дип куелган.

Китапның басылып чыгуы турында азәрбайҗан гәзитәсе хәбәр итә. (Таза китаплар. «Ике гашыйк».— Шәркы рус, 1903, 14 май.)

Пьесаның беренче тапкыр 1906 елның көзендә Уфада уйналуы турында Фуад Туктаров болай яза: «Театрда халык күп булган... һәм уеннары менә дигән яхшы чыккан. Уйнаучылардан Гомәр Терегулов, Хәдичә Ямашева, Өммегөлсем Әхтәмова бик оста уйнаганнар.» (Усал.— Татарча театр.— «Ике гыйшык».— «Таң йолдызы», 1906, 4 октябрь). 1907 елда куелган пьесаның афишасы сакланган (Казан милли мәдәни үзәге).

«Сәйяр» труппасы «Ике гашыйк» спектаклен Казанда беренче тапкыр «Шәрекъ» клубында 1912 елның 9 гыйнварендa куя. Моннан соң да ул бу пьесаны ел саен репертуарына кертә.

46 бит.

*Дипломат* — үзенә бертөрле өлге белән тегелгән, гәүдәне нык томалый торган озын пальто.

47 бит.

*Хан мәсҗеде* — Казан Кремлендәге архитектура истәлеге булып саналган Сөембикә манарасы. Уналтынчы гасырның беренче яртысында корылган.

*«Ясин»* — Коръәннең 36 нчы сүрәсе. Гадәттә бу сүрәне үлем түшәгендә яткан кешенең баш очында укыйлар.

48 бит.

*Хуҗа Насретдин* — Көнчыгыш халыклары фольклорында атаклы персонаж. Аның турында мәзәкләр җыентыклары басылып чыккан. 1940 елда Нәкый Исәнбәт «Хуҗа Насретдин» исемле комедия иҗат иткән.

*...бер киленне бик кызгандым...*— биредә Г.Исхакый үзенең «Бай угылы» исемле хикәясе эчтәлегенә ишарәли (Хикәянең текстын шушы басманың беренче томыннан карагыз).

49 бит.

*«Галимнәр чагыр эчеп зина кылгай!»* — Шигъри «Тәкый гаҗәп» («Ахырзаман китабы»нан) өзек. Китап — динин-нәсыйхәт әдәбияты ядкяре. Авторлыгы Сөләйман Бакырганига нисбәт ителә. Кыямәт көнен, «теге дөньяны» тасвирлауга багышланган. Егерменче йөз башына кадәр татарлар арасында иң киң таралган әсәрләрдән. 1847 елдан башлап берничә тапкыр басылып чыга.

52 бит.

*Әфләтун* (Платон) — безнең эрага кадәр 427—348 еллар тирәсендә яшәгән борынгы грек галиме һәм философы.

*Аресту* (Аристотель) — безнең эрага кадәр 384—322 еллар тирәсендә яшәгән борынгы грек галиме һәм философы.

57 бит.

*«...күзләрендә май чабалар...»* — май чабу — рус, чуваш, мари һәм керәшен татарларының яхшы атлар җигеп сәйранга чыгуы белән характерлы булган борынгы бәйрәм, кышны озату бәйрәме (русчасы: масленица). Славяннарның мәҗүсилек дәвереннән калган бу бәйрәмнәрен руслардан да артыграк бер ләззәт белән татар сәүдәгәрләре һәм татар мастеровойлары бәйрәм итәләр, кыш буе көтеп алып, атна буе май чабалар... (Ф.Әмирхан.— Май чабу.— Кояш, 1914, 18 февр.) «Май чабу»ны Г.Исхакый биредә күчмә мәгънәдә — «күзләре әрсезләнеп уйнап тора» дигән мәгънәдә кулланган.

58 бит.

*«Самолет»* — Россиядә пароходлар йөртү компаниясе. 1853 елда төзелә. 1857 елда пароходлар Казанга кадәр йөри башлый. Компания 1918 елда национализацияләнә.

62 бит.

*«Сәедбаттал»* — «Кыйссаи Сәедбаттал газый. («Сугышчы Сәедбаттал хикәясе») — урта гасыр төрек-госман әдәбияты ядкяре. Татарлар арасында кулъязма хәлендә киң таралган булган, XIX гасырда китап булып басылган. Дин хакына сугышларда катнашкан легендар геройның тормышы һәм каһарманлыклары тасвирлана. Татар басмалары төрле исемдә очрый: «Сәедбаттал китабы»; «Мәнакыйбе Сәедбаттал газый» («Данлыклы сугышчы Сәедбаттал»), «Сәрайәте Сәедбаттал газый» («Сугышчы Сәедбатталның тормышы»).

*«Фәттахетдин»* — («Кыйссаи Фәттахетдин») — Көнчыгыш фантастик хикәяте. Казанда 1881 елда басылып чыккан.

72 бит.

*«Бәдәвам»* — татар дини-нәсыйхәт әдәбияты ядкяре. Ав-

торы билгесез. Язылу вакытын төрлечә — монгол чорына кадәрге дип тә, 17—18 гасырга карый дип тә санаучылар бар. Мәҗүсилеккә караган гореф-гадәтләр тәнкыйтьләнә; китап ислам нигезләрен пропагандалый. Кулъязма килеш тә, китап булып та татарлар арасында киң таралган. 1846 елдан башлап Казанда берничә тапкыр басылып чыккан.

*«Хәмде бихәдд»* — 455 биттәге искәрмәне карагыз.

77 бит.

*Морозовлар товары* — Савва Васильевич Морозов (1770—1862) уллары белән бергә 1820 елда крепостнойлыктан акча түләп ирек ала. Алар мануфактура фабрикалары ачалар. 1915 елда ул фабрикаларда 54 мең кеше эшли.

*Әҗемнәр бәзе* — Әҗимов Мортаза Мостафа улы (1819—1877) — Казан сәүдәгәре, почетлы гражданин, кытай тукымасы һәм бәз буяу фабрикалары хуҗасы. Биредә сүз шул фабрикалардан чыккан товар турында бара.

78 бит.

*«Әл хатты нисфелмөлякат»* — «Хат — күрешүнең яртысы»; хат башламы.

80 бит.

*Апоплексически(й)* удар — апоплексия — мигә кан йөгерү нәтиҗәсендә паралич сугу.

81 бит.

*Гыйддәт* — 454 биттәге искәрмәне карагыз.

*Флер* — үтә күренмәле, күбесенчә, ефәк материя; берәр нәрсәне каплап тора торган серле пәрдә.

92 бит.

**Алдым-бирдем.**— Драма Казанда Габдерахман Хөсәенов һәм иптәшләре наширлегендә Шәрифләр типографиясендә 1907 елның 17 ноябрендә басылып чыга*. 99 бит. Имза: Мөхәммәдгаяз Исхаков. Әдип үзенең «Тәрҗемәи хәлем»ендә «Казан хибесханәсендә «Алдым-бирдем» исемендә бер драм яздым», ди. Казан төрмәсендә Г.Исхакый 1907 елның 4 июненнән сөргенгә җибәрелгәнче — 24 октябрьгә кадәр тоткынлыкта була. Шулай ук «Тәрҗемәи хәлем»дә мондый аңлатма да бар: «Француз, алман, инглиз, америка классикларын русчадан укыдым... Шекспир, Мольер, Островскийларның театр әсәрләре, шөбһәсез, минем драма әсәрләремнең техникасына тәэсир иттеләр. Ләкин мин һәрвакыт темаларның миллилеге, каһарманнарның

* Татарстан милли архивы. «Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының басылып чыккан әсәрләрне теркәү дәфтәре (420 ф., 4 тасв.).

рухи кичерешләрен, тормышларын милли җирлектә һәм милли үлчәүдә саклап килдем. «Алдым-бирдем» драмасында хатын-кызларның үз хаклары өчен көрәш темасы бөтен кешелек өчен гомуми тема булганы хәлдә, минем моны тулысынча милли бер юлга юнәлтә алуымда да бәлки шул ук классик драматургларның билгеле бер роле булгандыр».

Ф.Әмирхан китап басылып чыгу белән үк язган мәкаләсендә пьесадагы геройларны татар тормышыннан алынган типлар дип атый, «хатыннар типларына килгәндә, Гаяз әфәндене бу типлары ирләр кыйсьменә караганда да мөкәммәл буладыр»,— ди, әсәргә югары бәя бирә. Шулай ук рецензент «бөтен вакыйганың төбе булган мәхәббәт бөтенләй аз тасвир ителгән»,— дигән тәнкыйть сүзләрен дә әйтә. (Дамелля.— «Алдым-бирдем».— Әлислах, 1907, 19 ноябрь.

«Алдым-бирдем» спектакле беренче тапкыр Уральскида Городской театрда «Мөсафир артистлар җәмгыяте» тарафыннан 1908 елның 13 гыйнварында куела. «Бу «Алдым-бирдем» әсәренең Россиядә беренче мәртәбә уйналуы булса да, артистлар үз рольләрен яхшы чыгардылар. Хосусән, бу кичәдә бенефис иясе Сәхипҗамал ханым Гыйззәтуллина гаять гайрәт илә тырышты. Пәрдә төшерелгән саен кул чабулар тавышы театрханәне селкетерлек дәрәҗәдә булды». (Хәбәр.— Яңа тормыш, 1908, 2 февраль).

Ә Казанда «Алдым-бирдем» спектакле Яңа клуб сәхнәсендә 1908 елның 14 мартында һәвәскәр артистлар тарафыннан күрсәтелә. Бу турыда «Яшенче» имзасы белән Г.Камал (Йолдыз, 1908, 17 март), «Усал» имзасы белән Ф.Туктаров (Казан мөхбире, 1908, 17 март) икесе дә «Татарча театр» дигән исем белән мәкаләләр язып чыгалар. Мәкаләләрдә сүз нигездә рольләрдә уйнаучыларга бәя бирелә, канәгатьләнерлек уйнамаулары әйтелә. 1908 елда куелган пьесаның афишасы сакланган (Казан милли мәдәни үзәге).

Матбугаттагы мәгълүматларга караганда, пьеса Казанда еш уйнала, ул шулай ук Мәкәрҗәдә (Түбән Новгород), Әстерханда, Ташкентта, Уфада уйналган.

Шунысы кызык, спектакль сәхнәдә барганда тамашачылар арасында «үзләрен танучылар» да була. Ф.Туктаров, мәсәлән, алда күрсәтелгән мәкаләсендә бер гаҗәп факт китерә. Чаллыдан Исмәгыйль Сәгыйть дигән кеше «Казан мөхбире» гәзитәсенә һәм Яңа клуб мөдиренә телеграммалар җибәрә һәм анда ул «Кызның туй вакытында Ибраһимга китүе дөрес түгел, киресенчә, үз теләге барып чыкмагач, Ибраһим Казанга качып китте», ди. Шулай ук «Йолдыз» гәзитәсенең 1908 елгы 9 март санында «Идарәгә мәктүб» басыла. Анда: «Бу китапта язылмыш исемнәр безнең тарафтагы бер бай гаиләсенең исемнәренә бик тугры киләдер. Бу китап кушылып язылмыш бер әсәрдер»,— диелгән. Г.Исхакый бу хатка җавабында пьесадагы вакыйганың конкрет кешеләр турында түгеллеген әйтә, «дөрест, мине кушып яздырдылар, ләкин Ибраһим

түгел, Галия генә түгел, Галияләр, йөзләр, меңнәр Галияләр»,— ди.

1910 елның 19 декабрендә Г.Исхакый Төркиядән М.Горькийга язган хатында «Знание» нәшрияты аша аңа «Алдым-бирдем» пьесасының русчага тәрҗемәсен җибәрүен һәм аннан укып чыгып, «Знание» җыентыгында басарлыкмы-түгелме икәнлеген билгеләвен үтенә. М.Горький Г.Исхакыйга пьесаның басарга кабул ителгәнлеген хәбәр итә. Шактый гомер үткәч, 1914 елда С.-Петербургтагы «Заветы» журналының 6 нчы санында әсәр «Брачный договор» дигән исем белән рус телендә дөнья күрә. Тәрҗемәчесе: Г.Свердлова.

Әсәр «Зиндан»* җыентыгында басылды.

Текст 1907 елгы басмадан алынды.

96 бит.

*«Таң»* («Таң йолдызы») — Казанда Г.Исхакый оештырган беренче сәяси, әдәби һәм фәнни гәзитә (18 май — 17 нояб. 1906). Барлыгы 65 сан чыккан.

*Становой* — становой пристав — патша Россиясендә: өяз полициясе башлыгы.

102 бит.

*Зобани* — тәмугта яндырып торучы, газап фәрештәсе.

110 бит.

*Гакед* — килешү, сүз берләштерү; шаһитлар алдында егет белән кызның өйләнешүләренә ризалыкларын язу эше.

116 бит.

*Фидия* — үлгән кешенең гөнаһын йолып алу (коткару) өчен бирелгән садака. Шәригать кушуы буенча, андый садака үлгән кеше васыять әйткән булса гына тиеш санала.

117 бит.

*Алты-биш* — аңгырарак кеше турында әйтелә.

123 бит.

*Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди* (Баһаветдин Мөхәммәд бине Нәкышбәнди әл-Бохари, 1318—1389) — суфыйчылык-

---

* Гаяз Исхакый. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Татарстан китап нәшрияты. 1991. Җыентыкны төзүче, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Лена Гайнанова, җаваплы редактор Рәис Даутов.

ның киң таралган орденнарының берсенә нигез салучы; изгеләр рәтендә йөри.

*Мәкәрҗә* — 454 биттәге искәрмәне карагыз.

126 бит.

*«Әмин тәзәк»* — фарсы телендә язылган дини әчтәлекле тезмә китап.

*«Мөһер шәриф»* — («Пәйгамбәр мөһере») — китап исеме.

*«Сөбателгаҗизин»* — («Көчсезләрнең ныклыгы») — Урта Азиядә яшәгән төрки шагыйрь Аллаһияр суфый (1630 еллар — 1721 яки 1723) әсәре. Китап Казанда 1802 елда басылган. Гали Рәхим болай ди: «Бу китап безнең халык арасында 18 нче гасырда ук укыла килгән һәм кирәге зур булган. Ихтимал, ул безнең Идел буена язылуыннан бик аз гына соң килгәндер... Аллаһияр суфыйның тәрҗемәи хәленә гаид мәгълүматны без үзебезнең Идел буенда «Сөбателгаҗизин»гә шәрех итеп язылган «Рисаләи Газизә» исемле китаптан алабыз», (Г.Рәхим.— Идел буенда чыгтай әсәрләре. Китапта: Татар әдәбияты тарихы, 1922.— Беренче җилд, икенче бүлек, 144 б.) «Рисаләи Газизә»не татар шагыйре Таҗетдин Ялчыгол (1768—1838) 1795 елда яза. Язылу вакытыннан алып кулъязма һәм басма килеш киң таралган, бигрәк тә мәдрәсәләрдә күп укылган әсәрләрдән. Ул 1847 елда Петербургта, 1850 елда Казанда басылып чыга, шуннан соң ел саен диярлек (кайбер елларда икешәр мәртәбә) басыла. Әсәр мавыктыргыч сюжетлы, анда кызыклы ривайәтләр, төрлетөрле хикәятләр, Аллаһияр суфыйның «Сөбателгаҗизин» шигырьләре һәм Т.Ялчыголның күп кенә үз шигъри әсәрләре дә китерелә.

138 бит.

*Кызыл мал* — тукымалар, мануфактуралар.

*Дума* — патша Россиясендә югары, закон чыгаручы идарә исеме. *Дәүләт Думасы* — 1905—1907 еллардагы революция барышында төзелгән вәкиллекле орган. Революциягә кадәр дүрт мәртәбә сайланган. *Шәһәр думасы* — патша Россиясендә сайлап куела торган шәһәр идарәсе органы.

141 бит.

*Гыйддәт* — 454 биттәге искәрмәне карагыз.

*«Җәмигъ» (Җәмигы-р-ромуз»)* — («Ишарәләр җыелмасы). Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Таж әл-Шәриганең «Мохтасарел викая» исемле китабына аңлатма. Авторы: Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Куһстани әс-Саламати әл-Хорасани (1554 елда үлгән). Китапның кулъязма һәм басма нөсхәләре күп

---

*Гаид* — караган.

булган. Утыз Имәни тарафыннан китапның аңлашылмаган сүзләренә сүзлек тә төзелгән.

142 бит.

*Духовный собрание* — 454 биттәге искәрмәне карагыз.

*Вәли вәкил* — никяхлашучыларның тәрбиячеләре, иясе, хуҗасы. Никях вакытында кияү үзенә үзе дә вәкил була ала.

154 бит.

**Мөгаллим**.— Драма Г.Исхакыйның фото-рәсеме белән Казанда Хөсәен Әбүзәрев наширлегендә Н.М.Чижова типографиясендә 1908 елда басылып чыга. 84 бит. Имза: Мөхәммәдгаяз Исхаков. Әдипнең үз кулы белән 1951 елда язылган библиографиясендә пьесаның язылу вакыты 1906 ел дип күрсәтелгән. Петербургтагы цензор В.Смирнов пьеса белән кулъязма килеш тә танышкан. Әмма басарга рөхсәтен бирмәгән. Ә әсәр басылып чыккач, «сәхнәдә уйнарга ярамый» дип кире кайтарыла. Икенчесендә В.Смирнов ачуы килеп: «Мин бөтенләй аңламыйм, бер мәртәбә кире кагылган пьесага ничек инде икенче тапкыр рөхсәт сорарга мөмкин? Моны татарның гадәттәге үҗәтлеге яки цензураның игътибарсызлыгына исәп тоту дип аңларгамы? — дип яза (Россия Үзәк дәүләт архивы. 776 ф., 26 тасв., 85 эш, 13-14 кәгазьләр).

Китап басылып чыккач та бер-бер артлы рецензияләр дөнья күрә. Г.Камал «Гаяз әфәнденең бу әсәре театру өчен тәртип иткән китаплары арасында иң беренче диярлектер. Бу әсәрдә мөгаллимнәрнең әхлак вә кыяфәтләре, аларның үзләре белгән аз мәгълуматлары илә зур эшләр күрсәтергә иҗтиһадлары, анларның гавам илә бу хакта көрәшүләре, гаилә эчендәге хәятлары тәмам җанлы итеп, фотограф кадәр вакыйгга мотабикъ, хакыйкатькә якын итеп тасвир ителмештер... Китапның техника җәһәте дә әүвәлге әсәрләреннән күп төзек һәм яхшы чыккан. Гаяз әфәнденең әүвәлге әсәрләрендә сәхнәгә кую җәһәтеннән читен вә уңайсыз урыннары булгалый иде»,— ди. (Яңа китаплар.— Йолдыз, 1909, 2 июнь.) Мәкаләләр авторлары пьесадагы вакыйганың реаль тормыштан алынуына игътибар итәләр. Г.Баттал, мәсәлән, «Мөгаллим» тормышымызның [бер] кисәгене бик яхшы күрсәтәдер. Анда күрсәтелгән нәрсәләр мәгыйшәт вә вакыйгга да бик мотабикъ кеби күренәләр»,— дип яза. («Мөгаллим» китабы вә өйләнү мәсьәләсе.— Вакыт.— 1909, 27 июнь.) «Бу китапны укыган вакытта адәм үзен бер дә язудан укыган кебек күрми, чын мәгыйшәт уртасында торган кебек хис итә». Бусы — Кәбир Бәкер сүзләре (К.Б.— «Мөгаллим.— Йолдыз,— 1909, 13 октябрь.)

---

*Вакыйг* — чынбарлык.

*Мотабикъ* — туры килгән, охшаш.

Матбугаттагы мәгълүматларга караганда, «Мөгаллим» пьесасының беренче тапкыр сәхнәдә куелу урыны һәм датасы — Оренбург, 1910 ел, 7 март. Шуннан башлап ул сәхнәдә күп мәртәбәләр уйнала. Спектакльгә рецензияләр дә байтак языла. Һәм аларның һәркайсында тормыш вакыйгалары Г.Исхакый каләменнән гаҗәп табигый чыгуы ассызыклана. Әмма китап хакында һәм шулай ук спектакльләр турында язылган рецензияләрдә драманың соңгы — бишенче пәрдәсе турында тәнкыйть фикерләре, аның алдагы пәрдәләргә ябышмавы, артык булуы әйтелә. «Яңа тормыш каһарманнарын шулкадәр томанлы, яхуд тормыштан ерак күрсәтәдер» (К.Бәкер), «Актык пәрдәдә җәгъли бер халәт тасвир ителдекеннән вә ул да кирәгенчә эшләнмәдекеннән уйнаучыларга да бик ватылырга кирәк була, сүзләрнең ябышмаулары, кыланышларның урынсызлыкларын карап тору сәерчеләргә начар тәэсир калдыра» (Г.Камал).

Артистлар еш кына очракта «Мөгаллим»нең соңгы — бишенче пәрдәсен төшереп калдырып та уйныйлар. Ф.Әмирхан бу турыда түбәндәгеләрне әйтә: «Зур мөхәррирнең бу әсәре, хөррият хәрәкәтләре вакытындарак язылган бер әсәр булганлыктан, соңгы бишенче пәрдәсендә беркадәр бертарафлыкка мөбтәлядер. Ләкин зур талант, шул бертарафлыктан үзе дә курыккан шикелле, үзенең бөтен бертарафлыгын әүвәлге дүрт пәрдәсендә чыгара алмыйча килеп, фәкать бишенче пәрдәсендә генә кинәттән чыгарып ташлыйдыр. Шуңар күрә дә пьесаның иң йомшак йире дә бишенче пәрдәдәдер. Артистлар, бу пәрдәне бөтенләй калдырып, пьесаның иң куәтле вә иң матур йирен генә уйнадылар ки, моннан пьеса бернәрсәсен дә җуялтмады гына түгел, бәлки мөкәммәлрәк булып чыкты... Моны без хосусый әһәмият биреп әйтәмез ки, әгәр яхшы пьесалар булса, артистларымызның да бик яхшы тәрәккъый итә алачакларын күрсәтәдер. (Ф.Ә.— «Мөгаллим».— Кояш, 1914, 27 гыйнвар).

157 бит.

*Булыгин* (Александр Григорьевич, 1851—1913) — 1905 елда Россия империясенең эчке эшләр министры, эре алпавыт.

159 бит.

*«Иман шарты»* («Шараит әл-иман») — мәдрәсәләрдә укырга-язарга өйрәнә башлаган балаларга бирелә торган беренче дәреслек ролен уйнаган китап. Бу китапның эчтәлеге шуннан гыйбарәт: башта гарәп әлифбасы бирелә, аннан хәрефләрнең исемнәре, иҗекләрне уку күнегүләре, саннарны бел-

---

*Җәгъли* — ясалма.
*Мөбтәля* — дучар булу.

дерү өчен кулланыла торган хәрефләр, гарәп телендә төрле догалар китерелә.

162 бит.

*«Тәрҗеман»* — Россия җирлегендәге төрки халыклар арасында нәшер ителгән беренче гәзитәләрдән. 1905 елга кадәр гомум төрки һәм рус телләрендә, аннан соң гомум төрки телендә чыга (апр., 1883 — 1918, Бакчасарай шәһәре, Кырым).

*Хуҗа Баһаветдин* — 460 биттәге искәрмәне карагыз.

167 бит.

*Мушкатан* — ату коралы (мылтык төре).

170 бит.

*Әбүҗәһел* — Мөхәммәд пәйгамбәр атасының туганнан туган агасы, дин дошманы Әбү Хәким бине Әбелхәким бине Һашимның кушаматы. Әбүҗәһел Мөхәммәд пәйгамбәрне гаиләсе белән Мәккәдән куып бара, Бәдер сугышында үтерелә. Ислам динендә, гадәттә, аңа бәддога укыла, каргыш белдерелә.

174 бит.

*«Морадelгарифин»* — («Суфыйлык юлында иң югары дәрәҗәләргә ирешүчеләрнең максаты»), Аллаһияр суфыйның суфыйлык буенча фарсы телендәге тезмә әсәре. XVII гасырга карый. Татар мәдрәсәләрендә дәреслек булып йөргән.

176 бит.

*«Кәләпүшче кыз»* — Гаяз Исхакый әсәре, Казанда 1900, 1902 елларда басылган. (Әсәрнең текстын шушы басманың беренче томыннан карагыз).

*«Мәгыйшәт»* — Садри Максуди (1878 — 1957) әсәре. Казанда 1900, 1914 елларда басылган. Хәзерге укучы өчен «Казан утлары»ның 1994 ел, 7 санында дөнья күрде.

*«Шәкерт һәм студент»* — Фатих Кәрими (1870 — 1937) әсәре. Казанда 1899, 1903 елларда басылган. «Шәкерт илә студент» дигән исем белән 1903 елда Оренбурда да басылып чыга. Совет чорында 1925 елда «Татар әдәбияты китапханәсе» сериясендә 12 нче китап булып, 1979 елда М.Гайнуллинның «Татар мәгърифәтчелек әдәбияты» исемле китабында бераз кыскартылып дөнья күрә. 1996 елда Ф.Кәриминең М.Гайнетдинов төзегән сайланма әсәрләрендә басылды.

*«Сәлимә»* — («Сәлимә, яки Гыйффәт») — Риза Фәхретдинов (1859—1936) әсәре. Казанда 1899 елда басылган.

*«Өч хатын берлән тормыш»* — Гаяз Исхакыйның беренче сәхнә әсәре. 1900 һәм 1912 елларда Казанда басылган. (Текстын шушы томнан карагыз).

*«Сәедбаттал»* — 457 биттәге искәрмәне карагыз.

180 бит.

*...Кырымда мәдрәсәи галия ясамакчы булалар* — сүз югары белем бирә торган мәдрәсә ачу турында бара.

181 бит.

*Ярымчыбык* — үлчәү берәмлеге.

195 бит.

*Матамал* — тиргәп әйтелә торган сүз.

197 бит.

*Руза бәйрәме* — ураза гаете; мөселманнарда Рамазан аенда 30 көн ураза тотканнан соң уздырыла торган бәйрәм.

*Корбан бәйрәме* — мөселманнарның дини бәйрәме. Бәйрәм Зөлхиҗҗә аеның (һиҗри елның 12 нче ае) 9-13 көннәрендә уздырыла. Корбан чалуның да үз тарихы булган. Риваятьләргә караганда, Ибраһим пәйгамбәр Аллаһе Тәгаләгә чиксез бирелгәнлек билгесе итеп үзенең улы Исмәгыйльне корбан итәргә әзер булуын белдергән. Ләкин Алла кодрәте белән, аның алдына корбанга сарык килеп баскан. Бу вакыйга Коръәннең 37 нче сүрәсендә һәм хәдисләрдә тасвирлана. Корбан өчен сарык, кәҗә, сыер һәм дөя кебек пар тояклы хайваннар тәкъдим ителә. Бер генә тояклы булганга, ат рөхсәт ителми.

*Мукшы* — мордва халкындагы ике этник группаның берсе. Икенчесе — эрзя.

199 бит.

*Кәҗә Ягъкуб* (Якуб Ибраһим улы Хәлили, 1878—1938), журналист, педагог, мәгърифәтче. 1913—1918 елларда Казанда «Сөембикә» һәм 1917—1918 елларда «Балалар дөньясы» исемле журналлар чыгарган. Татар мәктәпләре өчен басылган «Гыйльме хәл» («Фән дөньясында»), «Иң яңа әлифба» исемле дәреслекләр авторы. 1917 елдан соң Казан һәм Буа дәүләт учреждениеләрендә эшли. Репрессияләнгән һәм үлгәннән соң акланган.

1905—1907 еллардагы революциядән соң Россиядә башланган каты реакция татарлар тормышында да төрлечә чагылыш таба. Мәсәлән, гәзитәләрдә ысуле җәдид мәктәпләренә һөҗүмнәр турында язып чыгалар. 1908 елның 21 гыйнварында «Әлислах»та дөнья күргән хәбәрдә берничә фанатик мулла-мөәззиннең Кәҗә Якубны мәктәпкә җибәрүләре, Кәҗә Якубның балаларны тентеп чыгуы, мөгаллимне куып җибәрүе әйтелә. «Шәкертләр» имзасы белән басылган бу хәбәр: «Без, шәкертләр, югарыда исемнәре мәзкүр адәмнәргә игъләне нәфрәт кыламыз»,— дигән сүзләр белән тәмамлана.

Бу вакыйгалар турында Г.Тукай да, Ф.Әмирхан да язып чыгалар. Күрәсең, реакция барган елларда Якуб Хәлили фанатик муллалар йогынтысында була.

*Печән базары* — 452 биттәге искәрмәне карагыз.

203 бит.

*Мещан* — революциягә кадәрге Россиядә шәһәр вак сәүдәгәрләреннән, һөнәрчеләрдән, вак хезмәткәрләрдән һ.б.ш. торган катлау. Шул катлауга кергән кеше дә шулай аталган.

207 бит.

**Кыямәт.**— Комедия Казанда Хөсәен Әбүзәрев наширлегендә «Үрнәк» электро-типографиясендә 1910 елның 18 февралендә басылып чыга. 56 бит. Имза: Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый. Әсәр, әдип сөргеннән качып кайткач, Петербургта 1909 елда язылган. «Тәрҗемәи хәлем»ендә Г.Исхакый болай яза: «Кыямәт» исемендә иске дәвернең хуҗаларының дөньяга карашлары никадәр көленеч булганын күрсәткән бер комедия мәйданга китердем... Нәшер итү өчен кайбер наширләргә тәкъдим иттем. Әсәрнең бик зур кызыксыну уятачагын чамалаган хәлдә Казан наширләре мөхәрриргә каләм хакын бик аз биреп, минем качкын хәятыннан килгән матди хәлемнең авырлыгыннан файдаланмакчы булдылар. Мин ризалашмадым. Оренбургтагы бер наширгә әсәремнең беренче басма хакын 250 лирага бәяләдем. Ләкин Казан китапчылары боларны котыртып, аларны ваз кичтерделәр. «Кыямәт»не дусларымнан Хөсәен Әбүзәрнең кулы белән нәшер итәргә булдым. Китап зур кызыксыну белән каршы алынды һәм берничә айда сатылып та бетте».

Матбугатта күренгән мәкаләләрдә «Кыямәт»нең моннан берничә ел элек Казанда булган вакыйгага нигезләнеп иҗат ителүе язылa. «Йолдыз» гәзитәсенең 1910 ел, 23 февраль санында мондый хәбәр бар: «Кыямәт» моннан унөч еллар мөкаддәм Казанда вакыйг улмыш язулы йомырка мәсьәләсе һәм шул хакта бөтен Казан халкының шаулавы хакында әдипләремездән Гаяз әфәнденең оста һәм матур каләме берлә тасвир ителмеш бик мәгънәле һәм көлкеле комедиядер». Г.Камал: «Гаяз әфәнде ушбу көленеч йирлекне, бик күп төрле чуар буяуларга буяп, әүвәлдә булып кичкәнгә караганда йөз өлеш көленеч сурәткә кертмештер», ди. (Яңа әсәрләр.— Йолдыз, 1910, 14 март).

«Кыямәт» китабы кулдан кулга йөреп укылып, бик популярлык казанса да, сәхнәгә менә алмый тора. Петербург цензурасы аны «Сәхнәдә куярга уңайсыз» дип таба. Сәбәбен миссионерлыкка каршы фикерләр, «рус» сүзенең күп «трепать ителүе» белән аңлата (РҮДТА. 776 ф., 25 тасв., 1163 эш, 3-13 кәгазьләр.) «Сәйяр» труппасы артистлары аны барыбер сәхнәдә уйныйлар. 1911 елның 24 гыйнварында Оренбургта куелган спектакльгә шул ук Оренбург матбугатында капма-каршы бәяләр дөнья күрә. «Вакыт» гәзитәсе: «Тамашачылар

---

*Лира* — Италиядә һәм Төркиядә акча берәмлеге.

уенчыларны түгел, гүяки мәгыйшәтемездәге чын каһарманнарны үз әхвальләрендә күреп тордылар. Хәтта пьесаның үзендә булган ноксаннар, бик күп тәкмил кылынып, тәмам төзәтелмеш иде. «Сәйяр» труппасының бу соңгы уены халыкта гүзәл тәэсир калдырды», дип яза («Кыямәт.— Вакыт, 1911, 27 гыйнвар).

Ә «Дин вә мәгыйшәт» журналы исә болай ди: «...Бернәрсә аңламаган руслар да «татарский кыямәт» дип бот чабып көлештеләр... Бу уенның монда уйналуы Оренбург татарларының диянәт градусыны түбән дәрәҗәдә күрсәтмәктәдер». Мәкаләдә, шулай ук, мондый уен Кавказиядә уйналса, бу «бәдбәхетләргә һөҗүм итеп», бу манзарәләрнең көлен күккә очырырлар иде... Казанда дин әһелләре тырышлыгы аркасында куелмаган көлкене Оренбургка китереп куйдылар, диелә. (Театрда булучы.— Татар театры, яхуд Имамнарны тәхкыйрь.— Дин вә мәгыйшәт, 1911, 28 гыйнвар.) Г.Гобәйдуллин «Кыямәт»не мәңгелек комедия дип язып чыга. (Газиз.— Тормышмы бу? — Вакыт, 1911, 1 май).

«Кыямәт» комедиясенә нигез итеп алынган вакыйга матбугатта болай тасвирлана: «Көннәрдән бер көнне Мөхәммәтҗан бай Кәримовның асрау кызлары тавык кетәгеннән язулы йомырка табып керәләр. «Тавык язулы йомырка салган» дип, өйдә шау-шу куба. Мөхәммәтҗан бай йомыркадагы язуны укый. Ләкин мәгънәсенә төшенә алмый. Бу эш хәерлегә булмас дип, мәхәллә мулласын чакырта. «Язулы йомырка» хәбәрен ишетеп, байның кардәшләре, якыннары да җыела. Укый торгач, бәхәсләшә торгач, язудан «Тиз көндә кыямәт булачак» дигән мәгънә чыгаралар. Беренче чиратта хатын-кыз арасында елаш, тәүбәләшү куба.

Йомырка тышына химик ысул белән калкытып язылган гарәпчә сүзләрнең авторы һәм «язулы» йомырканы кетәккә чыгарып куючы Мәхмүт Алмаев була». Алмаев Мәхмүт Садретдин улы (1874—1907) типограф, журналист, шагыйрь. 1899 елларда Германиядә укып, типография эшләренә өйрәнеп кайта. Оренбургта Кәримов, Хөсәеневләр типографиясендә хезмәт итә. Соңыннан Казанда Кәримовлар басмаханәсендә эшли. (Исмәгыйль Рәми, Рәис Даутов.— Әдәби сүзлек (Элекке татар әдәбияты һәм мәдәнияты буенча кыскача белешмә).— Татарстан китап нәшрияты, 2001, 17-18 битләр).

Байтак гомерләр узгач, 1929 елда «Кызыл Татарстан» гәзитәсенең 22-24 саннарында М.Сәгыйдуллин дигән кешенең Берлинда чыгып килгән «Милли юл» мәҗмугасын һәм аның мөхәррире Г.Исхакыйны тәнкыйтьләп язган озын-озын мәкаләләре басыла. Мәкаләләрнең берсендә әдипнең «Кыямәт» пьесасы сәяси әсәр итеп күрсәтелә, пьесадагы тупас, надан

---

*Ноксаннар* — кимчелекләр.
*Тәкмил кылыну* — тутырылу, төзәтелү.
*Тәхкыйрь* — хурлау.

персонаж Ситдыйк хәзрәтнең инглизләр, руслар турындагы сүзләре авторның үзенә кайтарып калдырыла. Гомумән, ул еллардагы бөтен матбугатка хас бары тик кычкырыну, мәгънәсез бәйләнүләрдән, төпсез чагыштырулардан торган бу язмага Г.Исхакый «Милли юл»ның өч санында (1929, 14-15, 16-17, 18-19 саннар) үтергеч җавап белән чыга. Мәкалә бер язмага җавап бирүдән узып, гомумән СССРда татар милли әдәбиятының аянычлы хәлен яктыртуга багышлана.

«Кыямәт»кә кагылышлы өлешендә Г.Исхакый болай ди: «Минем «Кыямәт»тән инглизләргә ничек каравым хакында китергән Ситдыйк хәзрәт авызыннан сөйләнгән сүзләрегезне ни дип тә тәфсир итә белмим. Аларны минем сәяси карашым иттерепме күрсәтмәкче буласыз, әллә минем фикеремнең үзгәрешенә дәлил иттерепме күрсәтмәкче буласыз, аңламадым. Гомумән, әдипләрнең... «ясаган типлары — үзләре» диюче укучылары булмый түгел. Ләкин бит моны минем кебек 35-40 әдәби әсәр язган кешегә татбикъ итү шактый авыр. Минем бит йөзләп типларым бар. Аларның барысы да үзем булып бетмәс... Шул ук «Кыямәт»тә шул ук Ситдыйк хәзрәт берлә бергә Фәйзерахман мулла да бар бит: «Алар (инглизләр) үзләренең телләре, гадәтләре берлә урыска бөтенләй башка»,— дип кычкыра. «Кыямәт» сәяси бер энциклопедия саналса, ник шуны алмадыгыз? Әллә Фәйзерахман мулла тибында яшерелгән шәхес — ул вакытның либераль имамы, патша хөкүмәтенең Себергә сөргән мөдәррис — сезнең атып үтергән кешеңез Габдулла мулла Апанай икәнен белдегез дә шул «хезмәтеңезне» хәтерләтмәс өчен алмадыңызмы? Әллә Ситдыйк хәзрәтне бик сөйгәнлегеңездән аңардан ривайәт китерденезме? Ул вакытта шул ук Ситдыйк хәзрәтнең «Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ — урыс ул, сасык, Сәмәркандны басты, Дагстанны алды, Хивәне басты, мотлак — урыс» дигәнен алу кирәк иде. Инглизләр белән урысны аера алмаган Ситдыйк өчен бу бит бер кәрамәт дияргә ярарлык. Чынлап та бит урыс хәзер, большевик төсенә кереп, иске китаплардагы кыямәт галәмәтләреннән саналган Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ ролен уйный — Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ кебек һәрнәрсәне җимерә, кыра. Һәрбер үскән нәрсәне корыта, бетерә... Шуның өчен Ситдыйк хәзрәтнең бу сүзләре сезгә тугры да килер иде, хакыйкатькә дә муафыйк булыр иде... Мин үземнең сәяси мәсләгемне тәнкыйтьтән курыкмаган кебек, әдәби әсәрләремне тәхлил вә тәнкыйтьтән бер дә курыкмыйм... Ләкин бутап-кисеп, аннан бер сүз, моннан бер җөмлә алып, аны сәяси бер мәкаләдә дәлил иттерүне бик ваклык саныйм». («Кызыл Татарстан»га җавап.— Милли юл, 1929, 18-19 сан, 5-6 б.)

---

*Тәфсир итү* — аңлату.
*Татбикъ итү* — яраклаштыру.
*Тәхлил* — анализлау.

*Кыямәт* (гар.— ахирәт көне, дөнья беткән көн; күтәрелү, кубарылу, яңадан терелү) — мөселманнар ышануынча, үлгәннән соң яңадан терелеп хисап бирү көне. Мәетне күмгәч тә аннан ике фәрештә (Нәкир, Мөнкир) сорау ала; бу фәрештәләр кешенең гөнаһлымы, түгелме икәнлеген билгелиләр. Үлгән кешеләрнең оҗмахкамы, тәмугкамы җибәреләчәге аларның терелеп, бергә җыелган (мәхшәр) вакытында, ягъни кыямәт көнендә генә хәл ителә. Кыямәт (мәхшәр) көне — кешелек дөньясының җирдә яшәүдән туктау көне, ерак бабалары һәм әбиләреннән башлап бөтен буын кешеләренең очрашу көне. Исрафил пәйгамбәр сур өргәннән соң, үлгән кешеләр барысы да терелеп, Аллаһ каршына килеп басачак. Аллаһ алардан берәм-берәм хисап алачак. «Сораудан» узганнарны ул тәмуг өстеннән салынган «кылдан нечкә, кылычтан үткен» Сират күпере аша үткәрә. Гөнаһлылар күперне кичә алмыйча, тәмуг утына егылып төшәчәк. Гөнаһсызлар, күперне үтеп, оҗмахка әләгәчәк, имеш.

209 бит.

*«»Дөррәтен-нәсыйхин»* — («Нәсыйхәт сөйләүчеләрнең энҗеләре»), урта гасырда язылган дини-әдәби әсәр. Казанда 1870—1879 елларда басылган.

*«Фикъһе Әбүләис»* — Әбүләиснең ислам динендә хокук белеме буенча китабы.

211 бит.

*Ишрак намазы* — иртәнге, кояш чыкканда укыла торган өстәмә намаз.

212 бит.

*«Әрбәгыйн» («Әрбәгыйн хәдис»)* — («Кырык хәдис китабы») — Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләре бергә тупланып нәшер ителгән шул исемдәге китаплар бик күп. 1855 елдан 1917 елга кадәр татар наширләре 33 тапкыр бастырып чыгарганнар, китапларда хәдисләр саны төрлечә булган.

*Савабы җария* — агымсу (чишмә) чыгаруга тиң савап.

213 бит.

*«Фәзаилешшөһүр»* — «Айларның хасиятләре»; дини-әхлакый хикәяләрдән торган китап. Авторы — Җамалетдин Бикташи (?-1873). Беренче тапкыр 1854 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга; 1856, 1874, 1876 елларда кабаттан басыла. Китап Нәҗип Исмәгыйлев эшкәртүендә Казанда «Иман мәркәзе» нәшриятында 1994 елда янә дөнья күрде. Кадими мәдрәсәләрдә әлифба — «Иман шарты»ннан соң уку китабы да булып йөргән бу җыентыкны Г.Исхакый үзенең әсәрләрендә өнәмичә, ирония белән телгә ала. Мәсәлән,

аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән әсәрендә мондый юллар бар: «Фәзаилешшөһүр», карәнчә бөтие, кысыргап догасы, фалнамә... вә шуның шикелләләр белән сату итү китап сәүдәсе түгеллеге беленде. Халык арасында булса да яңы әдәбият мәйдан ала башлады». «Кыямәт»тә автор «Фәзаилешшөһүр»не комедиянең герое Шаһиязданның наданлыгын, акны карадан аера алмавын ассызыклау өчен телгә ала.

215 бит.

*Салават әйтү* — гарәпчә «Аллаһүммә салли галя сәйидина вә нәбиина Мөхәммәдин вә галя әли Мөхәммәд» («Йа Аллаһ, безнең пәйгамбәребез Мөхәммәдкә һәм аның гәиләсенә сәламнәрең булса иде!») дигән гыйбарәне әйтү.

216 бит.

*Иннә әнзәлнаһ* — «Коръәндә 97 нче «Әл-кадр» («Кадер кич») сүрәсенең беренче аятенең башы. «Иннә әнзалнаһ филәйләтил кадр» — «чыннан да без аны (Коръәнне) кадер кичендә иңдердек».

*Тәкъсир* — руханиларга олылап эндәшү; хәзрәт.

217 бит.

*Кышкар* — Татарстанның хәзерге Арча районы Кышкар авылы мәдрәсәсе XVIII гасыр урталарыннан алып 1918 елга кадәр яшәп килә. Кышкар мәдрәсәсендә Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф, бабасы Зиннәтулла Әмиров, Уральскидан Камил Мотыйгый белән күренекле артистка Галия Кайбицкаяның әтиләре Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин, татар әдәбияты тарихында билгеле урын алган Таип Яхин, драматург Фатыйх Халиди һ.б. билгеле кешеләр укыган. Кышкар мәдрәсәсендә, башка бик күп кадим мәдрәсәләрдәге кебек, схоластикага өстенлек бирелә иде» дип яза Кышкар шәкерте, укытучы, балалар язучысы Гасыйм Лотфи («Кышкар мәдрәсәсе», китапта: «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе», 1992. 165 б.) Кышкарда телләр, дини гыйлемнәр укыту белән бергә формаль логика — мантыйк укытуга зур игътибар бирелә. Мәдрәсә бәхәсләшү, моназарәләр уздыру белән данлыклы була. Г.Исхакый үзенең «Мулла бабай» романында шәкертләрнең Кышкар мәдрәсәсенә моназарәгә бару эпизодын тәфсилләп сурәтли, башка кайбер әсәрләрендә дә мондый моназарәләрне тасвирлауга зур урын бирә. «Кыямәт»тә, мәсәлән, муллалар моназарәсен күрсәтә. Ә һәрбер зур һәм кечкенә мәсьәлә хакында «ут чыгарып», «әтәчләнеп» бәхәсләшүче Хәйрулла мулла турында «ул Кышкар шәкерте иде» дип искәртә.

219 бит.

*... авыруларны камчы белән кыйный* — Казанда Яңа бистәнең Габсаттар исемле ишаны авыруларны өшкергәндә камчы белән сугып өшкерә торган булган. «Камчылы ишан» дигән исем белән данлыклы бу зат Г.Тукай әсәрләренә дә кергән. Г.Исхакый да шул затка ишарә итә.

*Котыбы заман* — заман котыбы; котыб — дәрәҗәнең югары ноктасындагы үзәк фигурасы дигәнне аңлата.

*Шигый (шига)* — сөнниләрдән кала икенче зур мәзһәб. Шигыйлар пәйгамбәр итеп Галине таныйлар. Бу урында хәзрәт, «шигый» сүзен «Ираннан укып кайткан» дигән мәгънәдә куллана.

*Чәһарьяр гыйзамны инкяр кыла* — бу урында сүз «шигый» Шакирҗан муланың Мөхәммәд пәйгамбәрнең бөек сәхабәләреннән Әбүбкерне, Гомәрне, Госманны — танымавы турында бара.

*Кара такталар керттеләр* — сүз мәдрәсәләрдә акбур белән язар өчен кара такта кертү турында (ягъни укытуның җәдитләшә баруы турында) бара.

*Кәрамәт* — изге кешеләр тарафыннан күрсәтелгән гадәттән тыш күренеш, хәл; Алланың сөекле әүлияларына биргән могҗизасы.

220 бит.

*Ул вакытта әүлиулла пәйгамбәр булырга кирәк* — биредә хәзрәтнең изге эшне әүлиялар эшли ала, ә могҗизаны пәйгамбәр генә эшли, диясе килә.

223 бит.

*Сәҗдәи тилавәт* — Коръәнне укыганда 14 җирдә сәҗдә кылу.

*Сәҗдәи сәһү* — намазда ялгышканнан соң кылына торган сәҗдә.

*Хәзрәте Хуҗа* — 460 биттәге искәрмәне карагыз.

*Имам, хатиб, мөддәррис* — кешеләрне үзенә ияртеп намаз укытучы, җомга вәгазен сөйләүче, мәдрәсәдә укытучы.

224 бит.

*Ля иляһе илля Аллаһе Мөхәммәд рәсүлуллаһ йә әйүһәннас түбү илля Аллаһе вә әгъләму иннә әссәгате ляәтият кариб* — йомыркада язылган язуның тулы тексты: «Бер Алладан башка Алла юк, Мөхәммәд — аның илчесе, әй, кешеләр, Аллага тәүбә итегез, кыямәт сәгате якын».

225 бит.

*Фидия садакасы* — 460 биттәге искәрмәне карагыз.

*Тәһарәт, госелнең шәраитен ригая бетте* — юыну, пакьләнү шартларын үтәү бетте.

*Сәләфләр* — бу урында: борынгы кешеләр.

226 бит.

*Рәкәгать* — намазның аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә куюны эченә алган бер өлеше.

*«Колһуалла»* — Коръәндә 112 нче «Ихлас» сүрәсенең халык телендәге исеме.

*«Әлһәкумут-тәкәсури»* — Коръәннең 102 нче «Әттәкәсүр» сүрәсенең беренче аяте: «Сезне байлык артыннан куу әләктерде» дип башлана.

227 бит.

*Имам Газали* (1058—1111) — «Дин гыйлемнәрен терелтү» исемле китап авторы, күренекле дин галиме.

228 бит.

*Күк капусы* — дини ривайәттә: күкнең капкасы бар, билгеле бер вакытта гына ачыла, изге күңелле кешегә генә күренә, күргән кеше бәхетле була, шул чагында ул ни теләсә, шул кабул була.

*Иртә намазы* — иртәнге намаз, таң атканда, кояш чыкканчы укыла торган (беренче) намаз.

*Ястү намазы* — кояш баеп, шәфәкъ сүнгәч укыла торган (бишенче) намаз.

*Витер* — төнге, өстәмә намаз, ястүдән соң укыла.

*Ахшам намазы* — кояш баегач, шәфәкъ сүнгәнче укыла торган кичке (дүртенче) намаз.

*Мәгъҗүн* — мәк орлыгы, әфиюн һәм башка шуның кебекләрне катнаштырып ясалган, миңгерәүләтә торган наркотик әйбер.

234 бит.

*Бәдәлче* — кеше урынына ялланып хаҗга баручы.

*Зәмзәм* — Мәккә шәһәрендә изге кое исеме, шул коедан алынган суны зәмзәм суы диләр.

235 бит.

*Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ* — мифик ике халык исеме (русларда Гог һәм Могог); дини мифология буенча, Зөлкәрнәйн (Александр Македонский) стена корып, аларны башка халыклардан аерган, дөнья бетәр алдыннан стенаны җимереп чыгып, алар җир өстендәге барлык нәрсәне ашап бетереп барачаклар, имеш.

*Дәҗҗал* — кыямәт булыр алдыннан чыгачак дини-фантастик, алдакчы зат; аның бер ягында оҗмах, икенче ягында тәмуг булып, үзенә ияргәннәре оҗмахка кертә, ләкин оҗмахы тәмуг булып чыга, имеш.

*Диббәтел арыз* — җир астыннан чыккан кеше башлы хайван.

*Хәзрәте Гайсә* — пәйгамбәрләрдән берсе. (Христианнарда Иисус Христос). Коръәндә, яһүдләр Гайсәне үтерергә теләгәннәр, әмма аны Алла саклап калган, күккә күтәргән, яһүдләр Гайсәгә охшаган башка берәүне кадаклаганнар, кыямәт алдыннан Гайсә кабат җиргә иңеп, гаделлек урнаштыра, диелә. Коръән Гайсәнең күккә ашуын таный, аның могҗизалары турында сөйли.

*Хәзрәте Мәhди* — дөрес юлдан алып баручы. Дини ривайәт буенча, кыямәт көне алдыннан чыгып, азынган халыкларны туры юлга салачак, имеш.

*Бәни әл-әсфар* — дини ривайәт буенча, көнчыгыштан килүче сары тәнле билгесез бер халык исеме.

*«Мөхәммәдия»* — төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләби Язычы угылы (1451 яки 1453 елда үлгән) тарафыннан төзелгән. Мөхәммәд пәйгамбәр hәм мөселманнар турындагы дини-әхлакый үгет-нәсихәттән гыйбарәт тезмә әсәр; татарлар арасында киң таралган булган.

*Хәлифә* — мөселманнарның дин башлыгы. XVI гасырдан төрек солтаны хәлифә саналган. Биредә сүз Төркиядәге хәлифәт турында бара.

236 бит.

*Әмир Мозаффар* — Бохара әмире.

*Гаспар* (Исмәгыйль Гаспралы, 1851—1914) — 1893—1918 елларда Бакчасарайда чыгып килгән «Тәрҗеман» гәзитәсенең мөхәррире.

*Бомбей* — Индиянең үзәк шәhәрләреннән берсе.

237 бит.

*Хәдис* — Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре.

238 бит.

*Фазыйль* — галим кешегә карата кулланылына торган эпитет (өстен, инсафлы, намуслы).

*Һашим ыруы, корәеш кабиләсе* — Мөхәммәд пәйгамбәр чыккан кабилә.

239 бит.

*Әмре билмәгъруф нәhи ганилмөнкир* — шәригать кушкан эшне эшләп, тыйганыннан тыелырга боеру. (Коръәндә еш очрый торган сүзләр).

*Таш ярылып төя чыккач* — ривайәте болай: мөселманлыкка өндәгән Салих пәйгамбәргә сәмуд халкы, Аллаң хак булса, могҗиза күрсәт — таштан дөя чыгар, ди. Пәйгамбәр ташны яра ди, дөя чыга. Дөяне суялар. Һәркем дөя итен кискәләп, үзенә өлеш итеп ала башлый, әмма Алланы танымый. Алла шул халыкны юк итә (Коръәндә 91 нче сүрәнең 11-15 нче аятьләренә ишарә).

240 бит.

*«Мәвакыйф»* — дини китап.

*«Хикмәтел-гайн»* — («Белем чишмәсе хикмәте»). Авторы: Нәҗмеддин Гали бине Гомәр әл-Казвини әл-Кятиби (1276 елда үлгән). Шул ук авторның «Рисаләтүл гайни фи гыйлмил мантыйк» («Мантыйк белеме чыганаклары») исемле китабына өстәмә булып тора. Метафизика, физика турында трак-

тат. Бу өстәмә китап Көнчыгыш халыкларында бик популяр булган һәм аңа бик күп шәрехләр язылган.

240 бит.

*Бутышник* — Октябрьгә кадәрге Россиядә: будкасы янында торып каравыл хезмәтен башкаручы полицейский.

241 бит.

*Ай күрү мәсьәләсе* — рамазан ае башланыр алдыннан айның сызылып кына туып килүен берничә кеше күреп, шаһитлык итәргә тиеш. Шуннан соң инде ураза башлана.

242 бит.

*Галава* (голова) — патша Россиясендә: административ һәм шулай ук сайлану юлы белән идарә итүче волость, шәһәр хакиме; шул вазыйфаларны үтәүчеләрнең исемнәре.

*Гласный* — Октябрьгә кадәрге Россиядә: шәһәр думасы яки берәр җирле (земство) идарәгә сайланган депутат.

*Мукри* (Мокрый) — Казанда тимер юл вокзалы каршындагы урам исеме. Йортлар тоташ сүтелеп, ул урамдагы берничә йорт хәзерге Сакко һәм Ванцетти урамына карый.

*Дума* — 461 биттәге искәрмәне карагыз.

243 бит.

*«Шәрхе викая»* — («Викая»гә шәрех). Авторы: Гобәйдулла бине Мәсгуд әл-Махбуби, садр әш-шәригать ас-Сани (1346 елда үлгән). Улы Мәхмүд башлый, әмма бетерә алмыйча 1344 елда үлә, этисе тәмам итеп чыгара.

*«Шәрхе мәвакыйф»* — дини китап.

244 бит.

*«Гайде рисалә»* — китап исеме.

245 бит.

*Фикъһе* — ислам динендә хокук белеме.

*Хашия* — китап кырыендагы шәрех-аңлатма.

246 бит.

*«Мохтәсарел викая»* — мәдрәсәләрдә ислам законнарын (шәригатьне) өйрәткән дәреслек китабы. Авторы: Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Таҗ әш-Шәрига. «Шәрхе викая», «Шәрхе Мохтәсар» китаплары шул китапны шәрехләүгә багышланган.

247 бит.

*«Җәнаиз»* — җеназалар турындагы китап.

*Печән базары халкы* — Печән базары — 452 биттәге искәрмәне карагыз. Биредә автор комедиядәге надан муллаларның надан мөритләрен «Печән базары халкы» дип атый.

248 бит.
*Аяте хәдис* — Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре.

251 бит.
**Җәмгыять** — Комедия Казанда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе» наширлегендә И.Н.Харитонов типографиясендә 1911 елда басылып чыга. Сигезтомлыкта 3 нче җилд, 1 нче китап. 56 бит. Петербург цензурасы тарафыннан «Кыямәт» белән бергә бу пьесага да «сәхнәдә куярга уңайсыз» дип мөһер сугылса да, бу үткен сатирик комедия шул басылган елда ук тамашачыга күрсәтелгән. «Сәйяр» труппасы аны беренче булып 1911 елның 14 октябрендә Казанда Яңа клуб сәхнәсендә куя. (Йолдыз, 1911, 13 октябрь). Азәрбайҗан драматургы, җәмәгать эшлеклесе Н.Нариманов режиссерлыгында Әстерханда уйнала (Идел, 1911, 25 ноябрь).

Сәхнәдә уйнарга цензураның рөхсәте булмау, голяманың бик шаулавы тәэсир итми калмый, «Кыямәт» тә, «Җәмгыять» тә тамашачыга аз күрсәтелә.

Әсәр «Зиндан» җыентыгында басылды.

Текст 1911 елгы басмадан алынды.

*«Җәмигы-р-ромуз»* — 461 биттәге искәрмәне карагыз.

254 бит.
*Каргалы юлы* — хәзерге Чистай районына кергән Каргалы авылы район үзәгеннән көньяк-көнчыгышка таба 25 км. ераклыкта, элек-электән Казан белән Оренбургны тоташтырган олы юл өстендә урнашкан. Г.Исхакый әсәрдә шул юлны күз алдында тоткан булырга мөмкин. Хәзер монда автомобиль юлы үтә.

*Зикер* — Алланы искә алу догасы.

255 бит.
*Сәләфләр* — 471 биттәге искәрмәне карагыз.

259 бит.
*Миссионерлар* — башка диндәге халыклар арасында үз динен тарату өчен христиан чиркәве тарафыннан әзерләнгән руханилар.

16 гасырда христиан монастырьлары Идел буенда яшәгән халыкларны, 18 гасырда һәм 19 гасырның башында Себер һәм Кавказ халыкларын христианлаштыру буенча миссионерлык эшен бик көчәйтеп җибәрәләр.

Россиядә миссонерлык эше рус булмаган халыкларны көчләп чукындыру һәм монастырь колонизациясе белән, шулай ук төрле секталарга каршы көрәш белән бәйле була. 1867 елдан татарларны чукындыру эшләрен Казандагы Изге Гурия җәмгыяте алып бара. Россия буенча гомум христианлаштыру эшләре белән Синод җитәкчелек итә.

*Сенат* — элекке Россиядә: югары хөкем — суд инстанциясе сыйфатында шикаятьләрне карый торган һәм дәүләт аппаратына күзәтчелек итә торган югары хөкүмәт органы.

261 бит.

*Сәләфе салихин* — үткән замандагы изге кешеләр.

263 бит.

*Шәрик* — мәдрәсәдә бергә укыган иптәш.

264 бит.

*«Һәфтияк»* — китап исеме; Коръәннең җидедән бер өлеше.

*«Иман шарты»* — 463 биттәге искәрмәне карагыз.

265 бит.

*Әбҗәд* — борынгы гарәп әлифбасындагы хәрефләр тәртибен күрсәтү өчен ясалган мәгънә белдерми торган сүзләрнең беренчесе һәм шул сүзләрнең барысының исеме (бу сүзләр: әбҗәд, һәүвас, хоттый, кәләмән, сәгъфәс, коришәт, сәхоз, зазог. Бу сүзләрдәге тартыклар тәртибе берләләр, унлылар, йөзләләрне һәм ахыргы «2» мең санын белдерә.)

266 бит.

*Вирдләр* — йоклар алдыннан укый торган догалар; Коръән аятьләре.

267 бит.

*Каза кылу* — үз вакытында үтәлмәгән эшне үтәп өстән төшерү.

*«Бәдәвам»* — 457 биттәге искәрмәне карагыз.

268 бит.

*«Китабе җиһад»* — изге сугышлар турындагы китап.

269 бит.

*Духовный собрание* — 454 биттәге искәрмәне карагыз.

*Окружной суд* — революциягә кадәрге Россиядә: ике-өч өяздән торган округта эшли торган суд органы.

*Әндәлес* (Андалусия) — Көньяк Испаниядә тарихи бер өлкә: күбрәк халкы гарәпләр булган Кортоба (Кордова), Гарната (Гранада) шәһәрләре борынгы гарәп культурасы үзәкләре булганнар.

270 бит.

*«Җәлән яҗминү», «дараба ядрибү», «хәмидә йәхимү»* — биредә сүз гарәп фигыленең төрләнү рәвешләре турында бара.

*«Әхтәри»* — («Әхтәри Кәбир») — гарәпчә-төркичә зур сүзлек. Казанда 1902, 1905, 1913 елларда басылып чыккан.

271 бит.
*Маза китәрү* — тынычсызлау, борчу, йөдәтү.

272 бит.
*Тәяммем* — су булмаганда кулны туфракка яисә башка әйбергә сугып тәһарәт алу хәрәкәтләре ясау.

273 бит.
*Сәлам бирү* — намаздан чыгу рәвеше. Ике як тарафка карап (ике фәрештәгә) «Әссәламе галәйкем вә Рәхматуллаһ» дип әйтелә.

274 бит.
*Мөнкир-Нәкир* — мәетне күмгәч, кабердә сорау алучы фәрештәләр.

275 бит.
*Хәзрәти Мусаның таягы бар, диләр... теләсә җылан булган, теләсә...*— дини ривайәт буенча, Муса пәйгамбәр Мисыр Фиргавене янына барып, Фиргавенне иле белән хак дингә өнди, кол ителгән Бәни-Исраил халкын азат итүен сорый. Фиргавен күнми. Могҗиза өчен Муса пәйгамбәр таягын җиргә куя, бу таяк шунда ук аждаһага әверелә. Кулы белән тиеп, Муса пәйгамбәр аны тагын таякка әвереләдерә. Фиргавен кушуы буенча, сихерчеләр, мәйданга килеп, агач һәм җепләрен ыргыталар. Бу әйберләр еланнарга әверелә. Әмма Муса пәйгамбәр таягын җиргә салып, аждаһа итә. Бу аждаһа сихерчеләрнең еланнарын ашап бетерә. Моны күреп торган сихерчеләр Муса пәйгамбәргә иман китерәләр.
Алла тарафыннан Муса пәйгамбәргә бирелгән бу тылсымлы таяк («Гасаи мөбарәк») сурәте ясалган һәм дога язылган шәмаил дә бар.
*Артыш агачы* — җимеше медицинада кулланыла торган, һәрвакыт яшел ылыслы куак яки агач; русчасы: можжевельник.
*Җәбраил* — пәйгамбәрләргә Алланың вәхиләрен-хәбәрләрен җиткереп торучы фәрештә.

276 бит.
*Үрмәкүч белән күгәрчен оҗмахка керерләрме икән инде?* — Мөхәммәд пәйгамбәр дусты Әбүбәкер (Рәсүлебезнең хатыны Гайшәнең әтисе) белән Мәккәдән Мәдинәгә күчкәндә, арттан куып килгән кяферләрдән качып, Мәккә янындагы Үгез тавына менәләр һәм шул таудагы мәгарәгә керәләр. Мәгарә авызына Алланың әмере белән Үрмәкүч шунда ук пәрәвез корып куя, ә Күгәрчен, оя ясап, йомыркалар сала. Куып килгән кяферләр, үрмәкүч пәрәвезен, күгәрчен оясын күреп, бу мәгарәгә кешеләр кермәгән икән дип уйлап, ары узып китәләр. Биредә шул ривайәткә ишарә.

277 бит.

*Хәзрәти Салих тәвәсе* — 473 биттәге искәрмәне карагыз.

*Хәзрәти Галинең Дөлделе* — Гали хәлифә атланып йөргән канатлы ат.

279 бит.

*Пасха* — яһүдиләрдә: яһүдләрнең Египет коллыгыннан чыгуы истәлегенә язын үткәрелә торган дини бәйрәм. Христианнарда: Иисус Христосның үлгәннән соң терелү көне истәлегенә яз көне, көн белән төннең тигезләнүе узгач беренче якшәмбедә үткәрелә торган дини бәйрәм.

*Руза* — ураза; ислам динендә билгеләнгәнчә, таңнан шәфәкъкача ашау-эчүдән, бозыклыклардан, яман гадәтләрдән тыелу. Ураза тоту мөселманнар өчен фарыз санала. Шәригать рамазан аенда 30 көн ураза тотарга куша.

281 бит.

*Дума* — 461 биттәге искәрмәне карагыз.

283 бит.

*Сөннәт* — бу урында: мөселманнар үз итәргә тиешле Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре һәм эшләре.

283 бит.

*Перепись-фәләν, урысча укытулар, китап җыючылар килеп чыкмас бит инде?* — перепись — бу урында: халык санын алу. 18 гасырга кадәр Россиядә халык санын алу эпизодик характерда була. Мәсәлән, «Писцовые книги» — җан исәбен алу һәм милек исәбен язып бару кенәгәләре булган. 18 гасыр башында аларны «Ревизияләр» алыштырган. Соңырак кешеләрнең тууын, үлүен, өйләнешүләрен руханилар да теркәп бара башлаганнар. Ләкин халыкны исәпкә алуның бу төрләренә төрле дәрәҗәдә кимчелекләр, төгәлсезлекләр хас булган. 1897 елдагы халыкны исәпкә алу элеккеләренә караганда тулылыгы, Россиянең бөтен территориясен дә хисапка алуы белән аерылып торган. Исәпкә алу кәгазендә 14 сорау язылган булган.

18 гасырда Идел буе татарларын көчләп чукындыру куәтле төс ала. Шул чорга гомум халык исәбен алу да туры килгәнлектән, татарлар ул вакыйгаларны бер-берсе белән бәйләп караганнар. Г.Исхакый бу хакта үзенең «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә дә яза. Көчләп чукындырулар аркасында халыкта һәр яңалыктан, хәтта русча һәм җәдитчә укытудан да курку көчле була. Бу комедиядә автор яңа төзелгән җәмгыятьнең низамнамәсенә имза куюдан шөбһәләнүне дә шул ук «перепись» белән бәйләүләренә ишарәли.

*Гаиб ирәннәр* — «кырык газизләр» дип тә йөртелә, күзгә күренмичә генә кешеләргә изгелек эшләп йөрүче затлар.

285 бит.

**Мөгаллимә** — Драма Петербургта Г.Исхакыйның үз нәширлегендә Ш.Брюссель типографиясендә 1914 елның августында басылып чыга. Сигезтомлыкта 3 нче җилд, 3 нче китап. Титулга: «6-8 декабрь, 1913 ел, Финляндия» дип язылган.

Моңарчы Г.Исхакыйның «Мәҗмугаи асаре» Казанда «Гасыр» китап нәшриятында басылып килә. Петербургта Г.Исхакый нигезләгән «Ил» гәзитәсендә мондый хәбәр бар: «Ил» гәзитәсе әлегә кадәр кеше матбагасында басыла иде. Петербургта татар матбагаларының мөкәммәл куелган булмавы «Ил»нең нәшерен байтак читенләштерә иде. Шуңар күрә «Ил», яңа гына аякка басып килә торган бер җәридә булса да, үзенә махсус матбага куярга мәҗбүр булды. Бу нумирымыз берлә «Ил» матбагасы эшли башлаган саннардыр. Гаяз әфәнденең «Мәҗмугаи асаре»ннән «Гасыр» китапханәсендә басылмый калган әсәрләре шул формада һәм җилд саннары «Гасыр»дагасының дәвамы итеп, «Ил» матбагасында басылачактыр». (1914, 23 июнь).

«Тәрҗемәи хәлем»ендә Г.Исхакый бу әсәрен язу тарихын болай сурәтли: [Петербургта «Ил» гәзитен басмага хәзерләү эшләре] мине бик мәшгуль итте һәм ардырды. Кышның уртасында, берничә көн тоташ бәйрәм булудан файдаланып, Финляндиягә китеп ял итәргә карар бирдем... Финляндиянең кар белән өртелгән ямь-яшел нарат урманнары... мине беренче көнендә үк исертте һәм мин күптән күңелемдә туган бер хикәямне язу фикеренә килдем. Кулыма кәгазь, каләм алып, яза башладым. Ләкин, кинәт, моны театр өчен язсам бик әйбәт булачак, дигән фикер туды. Башымда эшләнгән манзарәләрне, фикерләрне сәхнә калыбына салдым да яза башладым. Иртән кофе эчкәннән соң өйлә ашына кадәр беренче пәрдәне бетердем... Һәр минуты эш белән тутырылган бу санаториемнең ял итүчеләре миңа сәерсенеп карыйлар. Яһүд докторның киңәше белән, иптәшләр белән урманда йөреп киләм дә, тагын язарга утырам. 10-12 сәгать рәттән каләм өстендә утырдым. Икенче көнне дә яздым. Кая барсам да драмамның дулкынландыргыч күренешләре эчендә гизәм. Бу гайре табигый хәрәкәтләрем күрше бүлмәдә яшәгән хатынны куркыта иде бугай. Ул мине тилергәндер дип уйлады ахыры. Бүлмәләр арасы такта белән генә бүленгән. Минем бүлмәдәге кызу-кызу, шау-шулы хәрәкәтләрем мине ачулы, ярсыган итеп белдергәндер. Өченче көнне өйлә ашына кадәр пьесамны язып бетердем һәм исемен «Мөгаллимә» дип куйдым. Бала тудырган ана кебек, күңелемдә бер җиңеллек хис иттем. Кулымда яңа бер әсәремне күреп, гадәттән тыш сөенеч эчендә калдым. Кызу-кызу киендем, урманга чыгачак булдым. Минем шул ашыгып киенүем, батыр-батыр атлавым мин ишекне ачуга күрше бүлмәдән башын тыгып карап торучы хатынны бик куркыт-

---

*Җәридә* — гәзитә.

кан. Ул мине тилергәнме-юкмы дип карый иде. Мин: «Гафу итегез, сезне рәхәтсез иттем, моннан соң мин санаторийның бик тәртипле кешесе булачакмын», дидем. Хатын уңайсызланып: «Юк, берни дә юк, фәкать сезнең гасаби-гасаби хәрәкәтләрегездән авырып киттегезме әллә дип кенә уйладым»,— диде. Мин дә: «Әйе! Хаста идем, бер бала төшердем, хәзер инде иң авыры үтте», дидем. Хатын, бу чыннан да тилергән икән, дип уйлап, куркынып тирә-ягына каранды. «Курыкмагыз, мин тудырган бала елап-сыктап сезне рәхәтсез итмәячәк, ул бер әсәрдер, бер китаптыр,» дидем. Үзем бик кәефләнеп көлдем. Хатын: «Әсәр шулай языламыни? Мондый хәлне гомеремдә беренче тапкыр очратам»,— диде... Тагын бер көн ял иткәннән соң өемә кайттым, әмма бер яңа әсәр белән кайттым!»

Пьеса кулъязма килеш Петербургта укып тикшерелә. «Мөгаллимә»не «Сәйяр» труппасы Мәкәрҗәдә (Түбән Новгородта) 1914 елның 16 августында сәхнәгә куя. Г.Исхакыйның үзе язуынча, ул «Сәйяр» труппасы куячак «Мөгаллимә»не күрермен дип Мәкәрҗәгә килә. Ләкин кемдер донос ясап, жандармнар өенә килеп тентү ясый һәм үзен дә кулга алырга ниятли. Әдип спектакльне күрә алмыйча, бөтен әйберен калдырып, Мәкәрҗәдән китәргә мәҗбүр була (Милли юл, 1931, 6 сан, 9 бит). Г.Исхакый «Мөгаллимә»сен 1915 елның 30 июлендә Уфада күрү бәхетенә ирешә. Артистлар — укучы яшьләр. Уен тәмамлангач, Г.Исхакыйны сәхнәгә чакырып бик озак алкышлыйлар, чәчәкләргә күмәләр. «Фатыйма ролен уйнаган Мәрьям туташны халык кат-кат чыгарып алкышлаган вакытта, Гаяз әфәнде дә, бик нык алкышлап, туташның өстенә чәчәкләр яудырды» (Татарча театр.— Тормыш, 1915, 4 август).

Ул чордагы матбугатка күз салсаң, иң күп мәкалә-рецензияләрнең Г.Исхакыйның «Мөгаллимә»сенә язылуын күрәсең, аларның саны унбиштән артып китә. Җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иткән төп нәрсә — пьесаның Г.Исхакыйның моңа кадәр язган әсәрләренә охшамавы, яңалыгы. Биредә элеккеге әсәрләрендәге кебек иске тормыш белән яңа тормышның тартышуы да, иске фикер белән яңа фикер каршылыгы да юк. Әсәрдәге мөгаллимә Фатыйма образы — ул әдипнең татарның киләчәге турындагы бөек хыялы җимеше. Әлбәттә, үткән тормыштан яисә бүгенге тормыштан алып язылган, хәтта кайчагында геройларның прототиплары да билгеле булган әсәрләре белән танылган Исхакыйның Фатыймасын тәнкыйтьчеләр төрлечә кабул итә.

Әсәрләр турында мәкаләләр «сериясен» «Мөгаллимә»не кулъязма килеш Г.Исхакыйның үз укуында ишеткән Г.Гыйсмәти башлап җибәрә. «Мөгаллимә» өч көндә язылып бетсә дә, аның мөндәриҗаты ничә еллар буенча җыелган. Андагы рух, андагы әмәлләр, андагы моңнар, теләкләр бик күп еллар-

ның арасында төрле рәвештә, төрле юл, төрле тармак буенча агып килгән мәгънәви, милли дулкыннан гыйбарәт... «Мөгаллимә»нең иң зур әһәмиятне хаиз булган җәһәте безнең татар галәмендәге идеальный типларның тормыш тәэсире аркасында реальныйлыкка әйләнер чагы якынлашканын күрсәтүдәдер.» Автор «Мөгаллимә»не А.Грибоедовның «Акыллылык бәласе» белән янәшә куеп бәяли. («Мөгаллимә» (Гаяз Исхакый әфәнденең яңа әсәре»).— Йолдыз, 1914, 12, 28 гыйнвар). Г.Исхакыйның иҗатын даими күзәтеп, матбугатта үзенең төпле фикерләрен әйтеп баручы Г.Кәрам «Мөгаллимә»не Истанбул, Берлин, Лондон сәхнәләренә чыгарырлык дигән фикер әйтә (Казанда «Шәрекъ» клубы сәхнәсендә «Мөгаллимә».— Аң, 1914, 19 сан).

Рецензияләр белән чыгучылар арасында аеруча ике авторның бәяләмәләре күзгә ташлана. Аларның берсе — әсәрдә чын «хакыйкый мөгаллимә язмышына гаид бер ишарә дә юк», әсәр реаль тормышны чагылдырмый, дип, пьесаны кискен тәнкыйть итеп чыккан Г.Ибраһимов. Автор хәтта бу әсәрне мәйданга кую «авыр тормышлы мөгаллимәләр сыйныфына каршы җинаять» дип тә, шул «авыр язмышны җиңеләйтү хакында бер чара күрә башлауга бундый әсәрләрнең вакытлы булса да бер пәрдә булып торуы ихтимал... әдәби вә иҗтимагый кыйммәте (хәятның көзгесе була алмаганга) нольгә якын» дип тә әйтеп куя. (Галимҗан Ибраһимов.— «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән.— Тормыш, 1915, 26, 27 февраль.)

Тәнкыйтьчеләрнең икенчесе — «Мөгаллимә»нең тууын хуплап, аңа һәм әдәби, һәм фәлсәфи анализ ясаган Җ.Вәлиди. Ул «әдәбият үткәннән, хәзердән файдаланган кебек, киләчәктән дә файдалана аламы?.. Тормыш әдәбияты тормыш белән бергә һәм тормышның артында калганнарын себереп алып барырга гына тиешлеме, әллә тормышның алдыннан җырып, аңа юл билгеләп барырга, тиздән булачагы, булырга тиешлеге күренеп торганнарны булды иттереп күрсәтергә дә хакы бармы?..» дип сораулар куя да, үзе үк болай җавап бирә: «әдәбиятымыз хәзерге хәлдә бер яктан тәнкыйди булса, икенче яктан тәрбияви булырга тиеш. Шуның өчен тормышның сәлби якларын күрсәтү [генә] йитми, иҗаби идеалларыны да күрсәтергә ихтыяҗ бар. Тормышның бүгенге хәле андый бербөтен идеал ясап бирә алмый, шуның өчен безнең әдәбиятымыз бу ягы илә тормышның азмы-күпме алдына чыгарга, аның «иртәгә»сен тасвир итәргә мәҗбүр була»... «Гаяз әфәнде [әсәрләрендә] яшьләр... дөньяда кеше өчен торалар, җәмгы-

---

*Хаиз* — җыйган, эченә алган.
*Гаид* — бәйләнешле.
*Сәлби* — кире.
*Иҗаби* — уңай.

ять өчен, халык өчен яшиләр. Шәхси булган хис вә хыялларга бик ул кадәр бирелмиләр. Идеалист булалар... әтрафка тәэсир итүне, дөньяда мөкатдәс бер эз калдыруны вазыйфа дип беләләр».

Җ.Вәлиди Г.Исхакый әсәрләрендәге яңалыкка омтылучы яшьләрне народниклар дип атый алабыз, ди. Һәм «Мөгаллимә» әсәрендә «без народниклыкның яңарак бер шәкелен, романтизм буявына буялган хәлен күрәмез», ди.

«Кем ул мөгаллимә Фатыйма?» дип исемләнгән мәкалә үзенең үзгә бәяләре белән истә кала. Мәкалә авторы — Әминә Мөхетдиния. Рецензентның хатын-кыз булуы һәм Фатыйма образын нәкъ шул хатын-кыз буларак аңлап тикшерүе игътибарны җәлеп итә дә. Автор әсәргә югары бәя бирә. «Сәхнәнең максаты — түгел тормыш көзгесе, бәлки, йөрәк, күңел көзгесе булудыр... Гади тормышта була торган трагедияләр икенче планда калып, рухани трагедияләрне маһиранә тасвир итү тиеш дип санала. Әлегә кадәр бу идея безнең татар сәхнәсендә күренми иде. Инде Гаяз әфәнде Исхаков үзенең яңа драмасы «Мөгаллимә» белән югарыдагы максатка бераз якынлаша дип беләм.» (Аң, 1914, 23 сан.)

«Мөгаллимә» татар мәдәниятендә бик зур яңалык булып кабул ителә һәм сәхнәдә иң популяр спектакльгә әверелә. Г.Исхакыйның сәхнәгә куелган пьесалары турында сүз чыкканда өлкән буын кешеләре иң беренче итеп «Мөгаллимә» спектаклен исләренә төшерәләр.

292 бит.

*«Бәйрәм бүген»* — Г.Тукай шигыре. «Әлислах» гәзитәсенең 1908 ел 13 октябрь санында басылган. Шигырьнең пьесадагы тексты шагыйрьнең 1909 нчы елда басылып чыккан «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынган. Шигырьнең «Әлислах»та икенче юлы:

Нәрсәдән бу? — Билгеле, бәйрәм бүген, бәйрәм бүген.— рәвешендә килә.

*«Сада көе»* — «Беренче сада», «Шәкертләр садасы» дигән исем белән йөргән җыр. Г.Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» исемле шигыре дә шушы көйгә җырланган. Аның көен татар музыканты Гали Зайпин иҗат иткән.

296 бит.

*Сукыр Каюм* (Каюм Насыйри, 1825—1902) — галим-мәгърифәтче, тарихчы-этнограф, телче, язучы.

297 бит.

*Габдулла Тукай* (1886—1913) — татар халык шагыйре.

298 бит.

*«Тәфкилеф»* — татар халык көе.

299 бит.
*«Кара урман»* — татар халык көе.

303 бит.
*Әлбиси җәдидә* — гарәп әлифбасындагы хәрефләр: әлеф, би, си, җи, ди.
*«Әллүки-бәллүки»* — татар халык көе.

307 бит.
*Юача* — майда кайнатып пешерелә торган камыр ашы — вак кына күмәч яки бавырсак.
*Синең әле фарызың өстеңдә* — биредә сүз намазның укымый калдырырга ярамый торган рәкәгатьләре турында бара.

312 бит.
*Мәхрәм* — шәригать буенча никяхлашу тыелган, әмма вакытлыча гына тыелган булырга да мөмкин. Мәсәлән, хатыны үлгәч, иргә аның сеңелесенә өйләнергә ярый.
*Намәхрәм* — шәригать буенча никяхлашу рөхсәт ителгән (чит кешеләр).
*Йәмәхрәм* — шәригать буенча беркайчан да никяхлашырга рөхсәт ителмәгән канкардәшләр.

312 бит.
*«Гакаид»* — тулы исеме: «Гакаиде Нәсәфи» («Ислам инанулары Нәсәфи аңлатуында»). Авторы: Нәҗметдин Нәсәфи (1068—1142). Мәдрәсәләрдә ул китапның үзен түгел, ә шул әсәргә шәрех китапларын өйрәнгәннәр. Халык арасында Сәгъдеддин Тафтазани (1321—1390) тарафыннан язылган «Шәрхе Гакаиде Нәсәфи» киң таралган булган. Бу китап Казанда 1897 елда басылып чыккан. Габденнасыйр Курсавиның да «Гакаид»не шәрехләп язган китабы бар.
*«Тәүзыйх»* — («Ачык аңлату»), авторы: Әбү Мөхәммәд Гобәйдулла бине Мәсгуд Тәҗушшари.

314 бит.
*Китән* — ак киндер тукыма.

315 бит.
*Гыйльманнар, вилданнар* — җәннәт хезмәтчеләре.

317 бит.
*Горбәт* — иленнән, туганнарыннан аерылып, чит, ят җирдә булучылык.

320 бит.
*Турне* — төрле җирләрне, шәһәрләрне, илләрне урап, сәяхәт итеп кайту; әйләнмәле маршрут буенча сәяхәт.

327 бит.

*Айвазовскийның «Тугызынчы валы»* (Гайвазовский Иван Константинович (1817—1900) — рус рәссамы. 1844 елдан Петроградта Баш диңгез штабында хезмәт итә. Рус хәрби флоты тарихы темасына меңләп картина ясый. Аның «Девятый вал» («Тугызынчы дулкын») картинасы (1850) Петербургта Рус дәүләт музеенда саклана.

328 бит.

**Тартышу**.— Драма Мәскәүдә Г.Исхакыйның үз наширлегендә «Шәрекъ» басмаханәсендә 1917 елда басылып чыга. Сигезтомлыкта 7 нче җилд, 2 нче китап. Титул биттә: «Языла башлады 1907 нче ел, декабрь 12 сендә Пинега шәһәрендә, Волгин йортында. Язылып бетте 1908 нче ел, гыйнвар 11ендә. Театрда уйнау хакы Казанда «Ирек йорты» файдасына багышлана» дигән искәрмә бирелгән.

«Тартышу» — Г.Исхакыйның басылуга рөхсәт көтеп яткан, Февраль революциясе нәтиҗәсендә цензура бетерелгәннән соң гына дөнья күргән әсәрләреннән берсе. Пьеса турында Г.Кәрам «1905 ел инкыйлабының кечкенә генә бер ядкяре булып, ул вакытлардагы бер фирка яшьләремезнең фикер вә хәрәкәтләрен гакес иттергән тарихи бер сәхифәдер»,— дип яза (Театр вә музыка.— Аң, 1917, 3-4 сан). «Тартышу»ны беренче мәртәбә 1917 елның 14 апрелендә Казанда Зур театр сәхнәсендә «Сәйяр» артистлары күрсәтә. «Нур» труппасы исә спектакльне Уфада 1817 елның 24 октябрендә куя.

Шулай итеп, репертуарга революцион идеяләрне ачыктан-ачык белдергән әсәр килеп керә. Драмада авторның үз биографиясенә ишарәләр байтак. Төп геройларның берсе Насыйр исә Г.Исхакыйның үзенә бик охшаган. Ул да социалист-революционер. Әдип шикелле үк «Бутырка күргән», сөргеннәрдә булган. Аның монологлары Г.Исхакыйның «Таң йолдызы» гәзитәсендәге мәкаләләрен хәтерләтә.

Әсәр «Зиндан» җыентыгында басылды.

Текст 1917 елгы басмадан алынды.

328 бит

*Ташлыйк, туганнар, иске тормышны...*— «Марсельеза», француз революцион җыры, Франциянең дәүләт гимны. Сүзләре һәм музыкасы 1792 елда Страсбургта К.Ж.Руже де Лиль тарафыннан язылган. Россиядә 19 гасырның 80 — 90 нчы елларында эшчеләр һәм интеллигенция арасында «Марсельеза» көенә җырлана торган революцион җыр таралган булган. Аны «Эшчеләр марсельезасы» дип атаганнар. Текстны П.Л.Лавров язган. «Марсельеза»ны татарчага С.Рәмиев тәрҗемә иткән.

---

*Гакес иттерү* — чагылдыру.

Пьесада «Марсельеза»ның җиде куплеты да бирелгән. Ләкин Г.Исхакый текстка кайбер үзгәртүләр керткән. Мәсәлән, беренче куплетның өченче юлында «илә» сүзе «белән» сүзенә, икенче куплетның беренче юлындагы «тормышны» сүзе «юлны» сүзенә алмаштырылган. Өченче куплет шактый зур үзгәрешләр кичергән. С.Рәмиевтә ул болай яңгырый:

Торыгыз, килегез, ач кешеләр,
Торыгыз, дошманга үч кешеләр!
Кушылып бер җиргә бар эшчеләр,
Тартышып табыйк якты ак көннәр.

Тәрҗемәнең башка куплетларында да кайбер үзгәртүләр күзәтелә. Г.Исхакый редакцияләгән шигырь юллары кискенлек,катгыйлык белән аерылып тора.

329 бит.

*Словесность* — тел-әдәбият фәне.

*Гоголь* (Николай Васильевич, 1809—1852) — рус язучысы.

*Пушкин* (Александр Сергеевич, 1799 — 1837) — рус язучысы.

*Писарев* (Дмитрий Иванович, 1840 — 1868) — рус публицисты һәм әдәби тәнкыйтьче.

*«Борынгы алпавытлар», «Ревизор»* — Н.В.Гоголь әсәрләре. «Старосветские помещики» (1835) әсәрен Г.Исхакый тәрҗемә итә һәм әсәр «Борынгы алпавытлар» исеме белән «Әлгасрелҗәдит» журналының 1906 елгы 1,2 саннарында басылып чыга.

*Чичиков* — Н.В.Гогольнең «Мертвые души» романы герое.

333 бит.

*«Әмин тәзәк»* — 461 биттәге искәрмәне карагыз.

338 бит.

*Бәраәт* — мөселман бәйрәме. Шәгъбан аеның 15 нче көненә туры килә. Изге кичә 14 нче шәгъбанда кояш баеганнан соң башлана. Ривайәтләргә караганда, кешеләрнең берьеллык язмышы, бәхете, тормышындагы уңышлы, рәхәт, бай яшәве шушы кичтә билгеләнә.

*Гашура* — мөселман бәйрәме. Гашура көне мөхәррәм аеның 10 нчы көнендә бәйрәм ителә. Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре, шушы көнне мөбарәк санап, ураза тотканнар, изге гамәлләр кылганнар.

339 бит.

*Ломбард* — әйберне ломбардка салып, шуның өчен вакытлыча бурычка акча биреп тора торган учреждение. Беренче тапкыр ломбард Франциядә Людовик XI (1461 — 1483) вакытында Төньяк Италиянең Ломбардия өлкәсеннән чыккан ростовщиклар (кешеләргә бурычка акча биреп торып, зур

табыш алучылар) тарафыннан төзелә, учреждениенең исеме шул өлкә исеменнән алынган.

*Сипагинны үтергәннәр* (Дмитрий Сергеевич, 1853 — 1902) — 1900 елдан Россиянең эчке эшләр министры. Революцион хәрәкәткә каршы иң каты җәза ысуллары инициаторы. Милли өлкәләрдә руслаштыру сәясәтен хуплаучы. Эсер С.В.Болмашев тарафыннан үтерелә.

341 бит.

*Попечитель* — кайгыртучы, тәрбия итүче; опекун.

342 бит.

*Городовой* — патша Россиясендә: шәһәр полициясенең түбән чины.

347 бит.

*«Кызганыч бала»* — төрек язучысы Намикъ Кәмалның (1840—1888) «Зәваллы чуҗык» (1873) дигән пьесасыннан Г.Камал тәрҗемәсе.

*«Өч хатын»* («Өч хатын берлән тормыш») — 464 биттәге искәрмәне карагыз.

353 бит.

*Алафузов* (Иван Иванович, 1837—1891) — Казан фабриканты һәм заводчысы, нәселдән килгән почетный гражданин. Сәнәгать һәм сәүдә эшен 1856 елда башлаган. 1858 елда С.Е.Александров белән бергә «Казан күн заводы товариществосы»н төзи, киндер эрләү һәм туку фабрикалары хуҗасы. Хатын-кызлар өчен кул эшләренә өйрәтү мәктәбе, Адмиралтейство бистәсендә эшчеләр өчен хастаханә, театр бинасы салдыра. Алафузов театры бинасы революциядән соң киндер фабрикасы мәдәният сарае була, 1996 елдан татар яшьләр театрына бирелә.

354 бит.

*Нелегальный* — рәсми рөхсәт ителмәгән, ачык эшчәнлек белән шөгыльләнә алмый торган. Яшерен («идән астыннан») эш йөртүче.

355 бит.

*Собачий переулок* — Казанда хәзерге Некрасов урамы.

362 бит.

*«Күл буе»* — Казанда Кабан күле буенда, хәзерге Ш.Мәрҗани урамы, 28 нче йортта урнашкан мәдрәсә. 18 гасырның ахырында нигез салына. Башта Апанаев мәчетендә эшли. 1877 елда И.Юнысов акчасына махсус бина төзелә. 1897 елдан 2 нче җәмигъ мәчете мулласы Мөхәммәдкасыйм Салихов исеме белән «Касыймия» мәдрәсәсе дип йөртелә.

Мәдрәсәдә төрле елларда Ш.Мәрҗани, Һ.Максуди. З.Вәлиди, Г.Коләхмәтов һ.б. укыткан. Мәдрәсә 1918 елда ябыла.

Г.Исхакый 1893—1897 елларда «Күл буе» мәдрәсәсендә укый.

*«Мөхәммәди»ләр* — сүз Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре турында бара. Мәдрәсә 1882 елда ачыла. Нигез салучысы һәм җитәкчесе Г.Баруди, мәдрәсәнең исеме аның әтисе Мөхәммәдҗан исеменнән алынган. Бу атаклы мәдрәсәдә төрле елларда Й.Акчура, Б.Шәрәф, З.Солтан укытканнар. Ф.Әмирхан, Ф.Бурнаш, М.Гафури, Н.Исәнбәт, Г.Камал, С.Сәйдәшев, К.Тинчурин, С.Габәши, Б.Урманче —мәдрәсәнең шәкертләре булганнар.

364 бит.

*Бутырка* — Мәскәүдә революциягә кадәр хөкем ителүчеләрне билгеләнгән урыннарына күчерү белән шөгыльләнүче үзәк төрмә. Тикшерү астындагы яки хөкем ителгән сәяси тоткыннар да шул төрмәдә утырган. Бутырка төрмәсе турында беренче хәбәрләр 17 гасырга карый. 1879 елда Мәскәүдә, Бутырка заставасы янында, Екатерина II тарафыннан төзелгән төрмә замогы урынында Бутырка төрмәсе төзелә. Төрмәдә режим рәхимсез булган. Ризасызлык белдергән тоткыннарны каты җәзага тартканнар. Г.Исхакый, сөргенгә озатканда, Бутырка төрмәсендә дә тотыла. Ш.Мөхәммәдьяров истәлегендә Г.Исхакый, «көз көне [1907ел] 26 октябрьдә Казаннан сакчылар илә Мәскәүгә җибәрелә. Анда Мәскәүнең мәшһүр, ул елларда сәясиләр белән тулы «Бутырка» төрмәсендә ике атна тотыла. Беренче декабрьдә ятап белән Архангель губернасына Пинега шәһәренә китерәләр», диелә. (Гаяз әфәнде.— Вакыт, 1913, 2 май).

371 бит.

**Зөләйха.**— Драма Мәскәүдә Г.Исхакыйның үз наширлегендә «Шәрекъ» матбагасында 1918 елда басылып чыга. Сигезтомлыкта 7 нче җилд, 1 нче китап. Титул биттә: «Беренче мәртәбә языла башлады 1907 нче елда Чистай төрмәсендә, икенче мәртәбә Истанбулда Кандилледә 1911 нче елда. Язылып бетте Петроградта 1912 нче елда, гыйнвар башында» дип язылган.

18 гасырда милли һәм дини басымның көчәюе аркасында чукындырылган татарларның күпләп кире мөселманлыкка чыгулары күзәтелә. Кәләй авылы (хәзерге Яүширмә авылы) халкының да бер өлеше чукындырыла һәм соңыннан керәшеннәр кире мөселманлыкка кайталар. Авылдан ерак түгел иске керәшен зираты да бар. Үз авылының тарихын Г.Исхакый бик яхшы белгән һәм пьесасына алынган вакыйгалар аңа таныш булган, әлбәттә. Күренгәнчә, үзенең бу әсәрен автор 6-7 ел дәвамында кабат кайта-кайта язган һәм аны җаны кебек саклаган. Сөргеннән качып киткәч, өченче мәртәбә Пе-

тербургка килгәндә ул бу әсәрен дус-ишләренә укый. «Темасы белән бу әсәремне бик мөһим бер әсәр дип санаганга, тикшерүгә куярга теләдем»,— ди Г.Исхакый үзенең «Тәрҗемәи хәлем»ендә. Бу хакта басманың икенче томына кертелгән «Бер тоткарның саташуы» исемле хикәягә бирелгән искәрмәләрдә шактый киң яктыртыла. Хикәядә саклык өчен драманың исеме аталмаган.

«Зөләйха» — татар әдәбиятында татарларны көчләп чукындыру турында язылган бердәнбер драма. 1914 елда аның «Ил» матбагасында басыла башлавы хәбәр ителә, ләкин китап басылмый кала (Ил, 1914, 21 август). Февраль революциясеннән соң, цензура бетерелгәч кенә «Сәйяр» труппасы спектакльне беренче тапкыр Казанда Зур театрда 1917 елның 17 мартында Габдулла Кариевның бенефисы уңае белән куя. Спектакльгә музыканы композитор Солтан Габәши язган. «Зөләйха» Казанда атна саен өч мәртәбә куела. 7 мартта уйналган спектакльне бу вакытта Мәскәүдә яшәүче Г.Исхакый үзе дә кайтып күрә. Аннары «Сәйяр» труппасы спектакльне Мәскәүгә алып барып, Корш театрында 4 майда күрсәтә. Аны Мәскәүгә җыелган Беренче Бөтенроссия мөселман съезды делегатлары да карый. Казанда да, Мәскәүдә дә зал тулы халык Г.Исхакыйны алкышларга күмә.

Спектакль куелу уңае белән матбугатта басылган рецензияләрдән, шулай ук беренче спектакльне үз күзләре белән күргән кешеләрнең сөйләүләреннән күренгәнчә, «Зөләйха» фаҗигасе тамашачыларга көтмәгәндә шартлап күк күкрәп, ярылып яшен яшьнәгән кебек тәэсир итә. Хәзерге Качалов исемендәге театр залы елау-иңрәүләр белән тула, сәхнәдә барган коточкыч көчләү күренешләреннән кайберәүләр аңын җуеп егыла. «Залда утыру түгел, басып торырга да урын юк иде. Кешеләр сәхнәгә терәлеп үк тыгызланган, тәрәзә төпләренә менеп баскан. Бераздан тәрәзәләрнең берәм-берәм шыртлап ватылулары ишетелә иде. Ул көнне залдагы бөтен тәрәзә кырылды. Әмма тамашачыларның дикъкатен бүтән берни били алмый: сәхнәдә коточкыч фаҗига, көчләп чукындыру. Бөтен кеше олы фаҗигане үзенең йөрәгеннән кичерә иде»*.

«Зөләйха» талантлы каләм, хәссасе рух белән язылган, урыны-урыны белән гаять тирән рухани фаҗигане караучының алдына китерә торган пьесадыр. Бу — иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт булуы белән бергә, милләтемезнең үз кодсияте юлында һичбер төрле фидаилектән кире тормас дәрәҗәдә куәтле рухка малик фәрдләре барлы-

---

*95 яшьлек укытучы-пенсионер Хаҗи Сальмушев белән әңгәмәдән. 10 февраль, 1993 ел.

*Хәссасе рух* — рухи сизгерлек.

*Кодсият* — изгелек.

*Малик фәрдләр* — ия шәхесләр.

гын күрсәтә вә бөтенлегемезне саклауда исламның нинди шәрәфле бер роль уйнаганлыгын исбат итә торган бер васикадыр,» — дип бәя бирә Ф.Әмирхан (Ф.— «Зөләйха».— Кояш, 1917, 19 март). «Бу әсәрнең мәйданга куелуына ирек бирелү хәзерге көндә татар өчен искиткеч зур вакыйгадан саналырга мөмкин. Бу әсәрне караганда шундый әсәрләрне сәхнәдә күрерлек хөррият дөньясына ирештек микәнни? дигән сүз һәрбер кешенең күңеленә килерлектер». (Шәһит Әхмәдиев.— «Зөләйха» — Йолдыз, 1917, 22 март). Мәскәүдә куелган спектакльне күргән Рамазан Тюменев аны «иске рус хөкүмәте өстенә ташланган гаепләү акты... тамашачыларны көйдергән, яндырган, еглаткан драма», дип атый («Зөләйха» Мәскәүдә.— Ил, 1917, 10 май.)

Г.Исхакый «Зөләйха»ны уйнау хокукын өч елга «Сәйяр» труппасы җитәкчесе Габдулла Кариевка тапшыра. Кариев «Зөләйха»ны куярга 1918 елның җәендә Идел буе, Кавказ, Төркстанга гастрольләргә чыгарга планлаштыра. (Ил, 1917, 28 май). Ләкин дөньялар үзгәреп китеп, Кариев бу зур планны тормышка ашыра алмый. Шулай да Октябрь революциясеннән соң «Сәйяр» труппасы «Зөләйха»ны 1917 елның 19 ноябрендә сәхнәгә куеп кала. З.Солтанов режиссерлыгында спектакль Әстерхан театрында уйнала. Тиздән Г.Исхакыйга караш үзгәрә. «Зөләйха» русларга каршы юнәлдерелгән һәм ислам динен пропагандалаган пьеса дип репертуардан төшерелә, татар әдәбиятында иң реакцион әсәр итеп карала башлый.

Матбугатта «Зөләйха»ның тыелу вакытын күрсәткән кызыклы мәгълүмат бар. «Татарстан хәбәрләре» гәзитәсенең 1922 ел, 20 март санында мондый белдерү укыйбыз:

«ЗУР СПЕКТАКЛЬ — КОНЦЕРТ — КАБАРЕ КИЧӘСЕ.

Җомга көн, 24 мартта Казандагы бөтен татар артист, җырчы, музыкант, әдип, шагыйрьләре, бөтен сәхнә һәвәскәрләре, педагогия техникумы, партия мәктәбе, хәрбисәяси курслар, команда курслары каршындагы сәхнә көчләре иштирагы белән шәһәрдә салына торган татар театры файдасына тантаналы кичә ясалачак.

Программада:

1.Зөләйха. Г.Исхакый. Туй пәрдәсе.
2.Таһир-Зөһрә. Ф.Бурнаш. Гөлләр бакчасы пәрдәсе.
3.Концерт.»

Гәзитә чыккан көнне үк «хата»ны күреп алалар һәм 21 март санында бирелгән шул ук игъланда «Зөләйха»ны про-

---

*Васика* — ышанычлы дәлил.
*Иштиракъ* — катнашу.

граммадан төшереп калдыралар, аның урынына К.Рәхимнең «Бүз егет»ен куялар.

1930 елда Казанда басылып чыккан «Татар дәүләт Академия театры» исемле китабында Зәки Мөхсинов «Зөләйха»-ны Г.Исхакыйның иң кабахәт әсәрләреннән дип атый. «Казанда ул әсәр аерым югарыдан кушу буенча көн-төн уйнала, иртән дә «Зөләйха», кич тә «Зөләйха», «Зөләйха» белән татар буржуазиясе акылдан шаша», ди.

Шулай итеп, «Зөләйха» сәхнәдән төшсә дә, аны русларга каршы, хәтта коммунистларга каршы котыртып язылган әсәр дип бәяләү 90 нчы елларгача дәвам итте.

«Зөләйха» драмасы төрекчәгә тәрҗемә ителеп, Төркиядә «Төрек йорты» журналында 1926 елда басыла. Г.Исхакыйның 1951елда үз кулы белән төзегән төрекчә исемлектә «Зөләйха»ның рус һәм поляк телләренә дә тәрҗемә ителүе күрсәтелә. Ләкин тәрҗемәләрнең кулъязмалары турында да, басылып чыгулары турында да әлегә мәгълүматлар юк.

Чит илләрдә «Зөләйха» эмигрант татарлар оештырган үзешчән драма коллективлары тарафыннан, мәсәлән, Кытайда Харбин (1921), Япониядә Токио (1933), Финляндиядә Тампере (1937) шәһәрләрендә уйнала. Харбинда куелган спектакльнең игъланы да сакланган.

**Игълан**

Иртәгә гаиде шәрифнең икенче көнендә (17 июнь 1921 ел) Харбин Мөселман төрек-татар яшьләре түгәрәге тарафыннан мәшһүр мөхәррирләремездән Гаяз әфәнде Исхакыйның бик зур муәффәкыять берлән язылган 5 пәрдәлек драма «Зөләйха» куелачак.

Русия дәүләте кул астында ясалган тарихымызның иң фаҗигале сәхифәләрен тасвир итүче бу әсәрне карау һәркемгә тиешле. Кичәдән килгән файда бу көндә Парижда эчке Русия вә Себер мөселман төрек-татарларының вәкиле сыйфаты берлән эшләп яткан Гаяз әфәнде Исхакыйга йибәреләчәктер. Кичә башланыр нәкъ сәгать сигездә. Күрергә ашыгыгыз! Бу мәүсимдә өченче мәртәбә сәхнәдә уйнала.

Токиода яшьләр «Зөләйха»ны Г.Исхакыйның килүе уңае белән 1933 елның сентябрь аенда куялар.

Әсәр «Зиндан» җыентыгында басылды.

Текст 1918 елгы басмадан алынды.

---

*Мәүсим* — сезон.

372 бит.

*Әгузе бисмилла* — Коръән сүрәләре башында әйтелә торган сүзләр: «Аллага сыенам, саклауны сорыйм». Һәр эшкә керешкәндә әйтелә торган гыйбарә.

*Аллаһөммә зид* — догадан өзек: «Аллаһөммә зиднә иманән вә тәслимән» — йа Рабби, иманыбызны һәм Аллага инануыбызны арттыр.

*Бисмиллаһи әлләзи* — догадан өзек: «Бисмиллаһи әлләзи ля йәдурру мәгасәмихи шәйүн фил әрдый вә ля виссәмәи вә һуә сәмигуль галим» — Аллаһ исеме белән, ул исем белән җирдә һәм күктә бернәрсә дә зарар китермәс. Ул ишетүче, белүче.

*Мамай* (?—1380) — Алтын Урдада бәкләр бәге, Кырым хакиме.

*Без яңа мөселман...*— чукындырылып, яңадан мөселманлыкка кайтучылар дип аңларга кирәктер.

376 бит.

*Санат* — элекке Россиядә: югары хөкем суд инстанциясе сыйфатында шикаятьләрне карый торган һәм дәүләт аппаратына күзәтчелек итә торган хөкүмәт органы (Сенат).

*Архирей (архиерей)* — православие динендә югары дәрәҗәдәге өлкә руханиларының башлыгы.

377 бит.

*Старовер* — христиан динендә иске, борынгы кагыйдәләрне яклаучы агым кешесе.

378 бит.

*Хәлифә падишаһка хәбәр бирик* — биредә Төркия патшасы-солтаны күздә тотыла.

379 бит.

*Газраил* — үлем фәрештәсе.

380 бит.

*«Колһуалла»* — 472 биттәге искәрмәне карагыз.

381 бит.

*Сәхабәләр* — Мөхәммәд пәйгамбәрнең иң якын көрәштәшләре.

*Хәзрәти Хәмзә разый Аллаһе ганһе* — (Хәзрәти Хәмзә, Алла аңардан риза булсын).— Пәйгамбәр әтисенең туганы.

384 бит.

*Хәдис* — Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләре.

*Ля иляһе илля Аллаһе, Мөхәммәд Рәсүлуллаһ* — Алладан башка иляһи юк, Мөхәммәд аның илчесе.

389 бит.

*Челек становой* (становой пристав) — 460 биттәге искәрмәне карагыз.

396 бит.

*Мәрьям ана* — Ходайның кодрәте белән Гайсә пәйгамбәрне тудырган кыз.

*Юлыны югалткан кемсәгә юл күрсәтүче, ач бүрегә җим бирүче Ильяс* — Хозыр Ильяс — «тереклек суын» эчеп, мәңге яшәү хәленә ирешкән һәм хәерче, көтүче яки юлчы кыяфәтендә изгелекләр эшләп йөри торган зат.

*Гаиб ирәннәр* — 479 биттәге искәрмәне карагыз.

399 бит.

*Благочинный* — православие чиркәве идарәсендә берничә чиркәү буенча административ вазыйфаларны үтәүче поп.

402 бит.

*Кырыктартмачы* — авылдан авылга йөреп, күбрәк галантерея белән сату итүче вак сәүдәгәр.

403 бит.

*Исправник* — Россиядә өяз полициясенең башлыгы. 1775—1802 елларда дворяннар сайлаган, аннан соң хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән.

405 бит.

*Чирмешән* — Татарстанның көньягында урнашкан хәзерге Чирмешән районы үзәге.

Г.Исхакыйның этисе Гыйләҗетдин Исхак улы Чирмешән районының Лашман авылында туган.

*Аллаһе Тәгалә сиңа хәзрәти Әюп хатынының савабын... яза.* — Ривайәте болай: Әюп пәйгамбәр мал-мөлкәтен югалтып, балалары үлеп, үзе дә бик каты авырып урын өстендә ятканда хатыны Рәхимә хәер сорашып йөреп, хәтта чәч толымын кисеп сатып иренең тамагын туйдыра. Биредә шул ривайәткә ишарә.

*Фиргавен кызы җәсарәт Асиянең савабын язар.*— Ривайәте болай: Мисыр Фиргавене янына күрәзәче килеп, шул җиргә күчеп яши башлаган Бәни-Исраил кабиләсендә бер ир бала туачак һәм ул илеңне таратачак, үзеңнең башыңа җитәчәк, ди. Бу хәл булмасын өчен Фиргавен Бәни-Исраил халкының һәр йортына кешеләр куя, барча туган ир баланы үтерергә боера. Нәкъ шул вакытта Муса галәйһиссәлам дөньяга килә. Баласын саклап калыр өчен әнисе аны сандыкка сала да,

---

*Җәсарәт* — батыр, кыю.

Аллага тапшырып, Нил елгасына агыза. Фиргавеннең хатыны Асия сандыкны, күреп, тота. Баланы уллыкка ала. Мусаның әнисе сарайга сөт анасы булып килеп урнаша. Биредә әсәр герое Габдулла шул риваятькә ишарә итә.

407 бит.

*Кәрамәт* — 471 биттәге искәрмәне карагыз.

409 бит.

*Салулы юл* — кышкы юл кырыеның чана читкә тайпылудан ясалган авыш урыны, бозылган урыны; чалу.

*Чөк-бөк* — ашыкның җәйпәк йөзендәге чокырлы һәм калку яклары исемнәре. Биредә күчмә мәгънәдә әйтелә.

413 бит.

*Сотский* — патша Россиясендә: авыл җирле полициясенә ярдәмгә билгеләнгән крәстиян, 1861 елгы реформадан соң авыл старостасына, волость старшинасына һәм полиция урядникгына буйсынган.

424 бит.

*Приход* — христиан динендә бер чиркәү тирәсендә берләштерелгән административ берәмлек; мәхәллә.

425 бит.

*Хәзрәти Рәсүл* — Мөхәммәд пәйгамбәр.

*«Һәфтияк»* — 476 биттәге искәрмәне карагыз.

*Хәзрәти Гали* — (Гали бине Әбүталиб, 661 елда үлгән) — 656—661 елларда хәлифәлек белән идарә иткән дүртенче ягъни соңгы тәкъва гарәп хәлифәсе. Галинең әтисе Әбүталиб Мөхәммәд пәйгамбәрнең әтисе белән бертуган, ятим Мөхәммәдне тәрбияләп үстерә. Гали Мөхәммәднең кызы Фатыймага өйләнә. Мөхәммәд җитәкчелегендәге барлык сугышларда да диярлек катнаша. Бәдер янындагы сугышта 16 тапкыр яралана, батырлыгы, кыюлыгы белән дан тота.

*Һатиф* — яшерен тавыш, гаибтән килгән тавыш; вәхи(хәбәр).

427 бит.

*Божий матерь* — Мәрьям ана.

*Микаил* — Алланың дүрт олы фәрештәләренең икенчесе; рәхмәт фәрештәсе (калганнары: Җәбраил, Исрафил, Газраил).

428 бит.

*Хәзрәти Гомәр* — Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң идарә иткән бөек хәлифәләрдән икенчесе (калганнары: Әбүбәкер, Гали, Госман).

*Хәсән, Хөсәен* — Мөхәммәд пәйгамбәрнең Фатыйма исемле кызыннан туган оныклары.

*Фатыйма* (якынча 605—633 елларда яшәгән) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең Хәдичә исемле беренче хатыныннан туган кызы, дүртенче хәлифә Галинең хатыны; Фатыйма турындагы сирәт (биография) авторлары Фатыйманы иң гыйффәтле, иң камил хатын-кыз итеп сурәтләгәннәр. Аның турында ривайәтләр барлыкка килгән.

*Сәлахетдин әл-Әюби* (1138—1193) — аурупалыларның тәре явына каршы Мисыр һәм Сурияне берләштергән хаким, милләте белән көрд, гаскәр башлыгыннан хакимлеккә күтәрелә.

«Сәйяр» труппасы гарәп язучысы Н.Әлхаддәднең «Сәлахетдин Әюби» исемле спектаклен Казанда Зур театр сәхнәсендә 1917 елның 20 октябрендә куя.

*Истанбулның Фатыйхи солтан Мөхәммәд*-солтан Мөхәммәд Фатыйх икенче («Яулап алучы», 1444—1446, 1451—1481).

*Җәбраил фәрештә* — 477 биттәге искәрмәне карагыз.

429 бит.

*Бу рәхмәт суы белән мин Әюб пәйгамбәрнең кортлар ашаган битен юган идем».*— Әюп пәйгамбәр юл читендә авырып яткан бер хәерчене «син инде озак ятасың, урыныңнан куч»,— дип, аны башка җиргә кузгатып җибәрә һәм «бу гидайның авыруларын миңа бир, аны савыктыр»,— дип дога кыла. Шул вакыт фәрештә килеп пәйгамбәргә: «Ни өчен бу хәерчене кимсеттең, Алланың теләгенә каршы килдең?» — дип әйтеп китә. Шуннан соң Әюп пәйгамбәргә төрле бәлаләр килә: куйлар, сыер, дөя көтүләре, иген басулары яна, балалары үлә. Әюп пәйгамбәр: «Аллаһе Тәгалә үзе бирде, үзе алды»,— дип кенә әйтә. Тәненә кортлар төшеп, аның итләрен ашый башлыйлар, сеңергә калдыралар. Әюп пәйгамбәр: «Күзләремне — үз хәлемнән гыйбрәт алу өчен, телемне — догада булу өчен, йөрәгемне — үзеңә мәхәббәттә булу өчен исән-сау калдыр!» — дип кенә үтенә, зур сабырлык күрсәтә. Шуннан соң пәйгамбәр савыга башлый, мал-мөлкәте дә, үлгән балалары да кире терелә. Әсәрнең герое шушы ривайәткә ишарә итә.

*Тый зәмин кылу* — могҗиза белән җирне (аралыкны) кыскарту.

432 бит.

*Мина тавына корбан чалдырып...* — Мәккәи Мөкәррәмә янындагы хаҗ вакытында шайтанга таш ату һәм корбан чалу урыны.

---

*Гидай* — теләнче.

*Ләүхелмәхфуз* — кешеләргә дөньяда вакытта нинди эшләр булачагы турында язылган такта, язмыш тактасы.

*Шәһидлек савабы* — хак эш өчен сугышта үлгән кеше савабы.

437 бит.

*Хәзрәти Хәдичә* — Мөхәммәд пәйгамбәрнең беренче хатыны.

439 бит.

*Яхъя мулла пәрие* — Яхья бине Сәфәр бине Арыслан 1838 елда Татарстанның Арча районы Шекә авылында үлгән. Ш.Мәрҗани аның турында: «Халык арасында әле дә куәтле җил яки тавыш ишетелгәндә, Шекә пәриләре дип сөйлиләр», дип яза. Яхья муллага буйсынган пәриләр, имеш, хуҗаларының һәммә теләген үтиләр икән. Шул хакта халыкта риваятьләр иҗат ителгән.

442 бит.

*Кармазин тун* — кармазин — кызыл төстәге борынгы юка сукно. Биредә шундый сукно белән тышланган тун күздә тотыла булса кирәк.

## ЭЧТӘЛЕК

Өч хатын берләп тормыш . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Ике гашыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Алдым-бирдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Мөгаллим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Кыямәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Җәмгыять . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Мөгаллимә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
Тартышу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328
Зөләйха . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 371
Искәрмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 446

Гаяз Исхаки
(Исхаков Мухаммедгаяз Гилязетдинович)

**СОЧИНЕНИЯ**

в пятнадцати томах

**Том 4**

(на татарском языке)

Рецензент *Рамил Юнысов*
Рәссамы *В.В.Булатов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Г.Г.Зиннәтуллина, Р.Н.Шакирова, Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 3.04.2003. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Т.Таймс» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 26,04 + фор.0,21 + рәс.1,68. Шартлы буяу-оттиск.26,57.
Нәшер-хисап табагы 27,04 + фор.0,36 + рәс.1,56.
Тиражы 5000. Заказ Б-616.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. 420111. Казан, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

**«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.**
**420066. Казан, Декабристлар ур., 2.**